# НУРИХАН ФӘТТАХ

## САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

БИШ ТОМДА

3

Том

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ф96

***Редколлегия:***

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин,*
*Т.А.Миңнуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Фәттах Нурихан**

Сайланма әсәрләр. — 5 томда, 3 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 464 б.

ISBN 5-298-01201-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2002

### Ерак тарихыбызга юл сызучы

Нурихан Фәттах дигәч, бүгенге укучы хәтерендә, иң башта, югары сәнгатьчә осталык белән эшләгән тарихи романнар яңара. Җәмәгатьчелек фикерендә аңарчы йөреп тә, анык бер рәвешкә керә алмаган караш-фикерләр турында ачык итеп язылган, көтелмәгән дөреслеге белән сискәндереп куя торган язмалар искә төшә. Татар театрының динчеләрне мыскыл итү белән артыграк мавыгуы турындамы ул, төрекчелек белән артык булышып, үз асыл нигезләребезне оныту куркынычы янавы турындамы? — уятып җибәрә торган мәкаләләр. Әдәбият дөньясына якынрак булган укучы Н.Фәттах алып барган, дәрвишлеккә охшаган тормышын, аның җәмәгатьчелек арасында сирәк күренүен, төрле купшы тантана-җыелышларны өнәмәвен дә исенә төшерер. Шулай да боларның барысын да күздән кичереп, Нурихан Фәттах һәм бүгенге татар җәмгыятенең үзара мөнәсәбәтен аңларга тырышсаң, соңгы берничә дистә елда бу әдипнең рухи тәэсирен ачык тоясың. Бу җәһәттән аны русның И.С.Тургеневы белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Парижда яшәп иҗат итсә дә, демократик рус җәмәгатьчелегенә гаять көчле йогынты ясаган, азатлык сөюче яшьләрнең рухи байрагына әйләнгән язучы белән, әлбәттә, безнең язучыбыз соңгы 40—45 елын яшәгән Дербышки — Париж да, аның кебек ерак та түгел, Казанның үзендә үк. Ләкин рухи дөньябызга тәэсире буенча чагыштырып була.

Дербышки дигәннән... Әдәби материалны тарих чоңгылларыннан, катлаулы фәнни хезмәтләрдән эзләп табучы галим-язучы өчен бикләнеп-ябышып иҗат итү шактый ук табигый хәл. Нәкый ага Исәнбәт шулай түгел идемени?! Ләкин шулай да Нурихан Фәттахны гомере буе шул рухтагы тормыш алып барган дип уйлаучылар хаталана. Иҗтимагый вакыйгалар агышында үзенең катнашуы кирәклеген, үз сүзен — язучы һәм гражданин сүзен кистереп әйтү тиешлеген ул сизгер тоя белүче дә. Бер генә мисал китерим. Күпләр өчен ул яңалык булыр.

...1956 елның язы. Илдә сталинчылык чоры тәртипләреннән баш тарту, аларны фаш итү рухы хөкем сөрә. Демократия кечтеки генә адымнар ясый. Ләкин ул югарыда утырганнарның ни теләсә шуны эшләүләре белән үрелеп бара. Шуның бер мисалы: көннәрдән бер көнне татар җәмәгатьчелеген тораташ хәлендә калдырып хәбәр ирешелде. Казан университетында 1944 елдан бирле яшәп килгән татар филологиясе бүлеген педагогия институтына күчерәләр, димәк, бетерәләр икән! Шул вакытлардагы борчулы халәт... Ничек инде, татарның чын милли кадрларны хәзерли торган соңгы учагын да сүндерергәме?! Лобачевский бакчасында төркем-төркем булып җыелып сөйләшүләр, еларга җитешеп зарланышулар... Әнә университетның

яшь укытучылары, соңыннан татарның күренекле галимнәре, академиклары булып җитешәчәк. Мирфатыйх Зәкиев һәм Рәфыйк Нәфыйговлар, аспирантлар — соңыннан шулай ук академиклар буласы Мансур Хәсәнов һәм Нил Юзиевлар, Ләлә Зарипова, яшь язучылар, журналистлар, алар янына елышкан 1—2 студент... Бу хәлгә юл куймауны, гомумән, татарны кыерсытуны, бу өлкәдәге һәртөрле тигезсезлекләрне бетерүне әйтеп, Н.С.Хрущевның үзенә язган хатны кайнарланып тикшерүләр, аның вариантларын эшләү... Боларның үзәгендә торучыларның берсе, әйе, Нурихан Фәттах; ул башлап йөри, хатның текстын да ул язган. Аңар имзаларны да, бер студентны ияртеп, ул җыеп йөри. (Монысының тарихы үзе бер мәкалә сорый.) Кыскасы, Нурихан Фәттахларның бу эш-гамәле, гомумән, шул вакытта яшьләрнең бер күтәрелеп алулары, ягъни заманасы өчен бер батырлык эшләве (чөнки бу имзалар өчен Өлкә комитетына җыеп «пешерү» белән генә канәгатьләнмәделәр, күпләр кайта-кайта җавап тоттылар әле) ул чакта шулай да үз нәтиҗәсен бирде — университетта татар бүлеге сакланып калды.

Әлбәттә, язучының җәмгыятькә тәэсире, иң беренче аның әсәрләре белән билгеләнә. Әсәрләрендәге җәмәгатьчелек фикерен алга үстерү өчен кирәкле һәм файдалы булган идеяләр билгели. Бу яктан алганда да Н.Фәттах иҗаты мөкәммәл бер күренеш булып тора.

Татар милләтенең яңарышына этәргеч бирү өчен аны, иң әүвәл, үз тарихы белән, үзенең милли чыганаклары белән таныштыру, аның тарихы аңын кузгату кирәклеген Нурихан Фәттах беренчеләрдән булып аңлаган һәм моны ул, игътибар итик, совет идеологиясенең иң көчле хакимлеге шартларында тормышка ашыра башлады. Татар-болгар тарихын әллә ниткән кара буяулар белән буяган, әллә нинди ялганнар белән төргән вакытларда ук керешә бу эшкә.

Бүген кайберәүләр сталинчыл идеологиянең аерым чиновниклары, кайбер җитәкчеләр белән үзләре арасында булган низагларын, хәтта очраклы гына бәрелешләрен дә гомумән совет системасы белән көрәш рәвешендә күрсәтергә омтылалар. Чама белү кирәк, егетләр! Ул система бар халыкка, барлык милләтләргә дә зарарын салды. Берәүләр өчен артык каты-бәгырьсез, кайберәүләр өчен ярарлык булды. Ләкин бу системаның бөтен яраксыз-зарарлыгын аңлап-күреп, аңлы төстә аның нигезләренә каршы чыгучылар, ай-һай, бүгенге «кыюлар» кебек үк күп булмагандыр. Киресенчә, моның өчен Гаяз Исхакыйлар, Садри Максудилар, Зәки Вәлидиләр югарылыгына күтәрелү кирәк иде. Кичәге системадан тегеләйме-болаймы җәрәхәт алганнардан җиңелрәк җәрәхәтләнгәннәр бүген катырак кычкыра булса кирәк. Ә Нурихан Фәттах кебекләр артык дәшми. Дәшәрлек кенә түгел, күкрәк кагып сөйләшерлекләре дә бар югыйсә! Чөнки аның эшчәнлеге дә, иҗаты да системаның үзенә каршы юнәлештә иде.

Бүген ачык бер агым төсен алган, борынгы тарихыбызга багышланган әдәби жанр төренең беренче әсәрләрен язуы да, бастыруы да бик кыенга туры килде. Монда барысы да беренче иде. Традицияләр юк дәрәҗәсендә. Чөнки тарихи әсәрләребезнең иң борынгы дигәне дә XIX гасыр вакыйгаларыннан да түргә узмый (Мәхмүт Галәү әсәрләре, мәсәлән). Шактый эшләнгәне исә — сыйныфлар көрәше, «революцион көрәш» тарихы темасы булды. Мең ел артка чигенеп, яки аннан да иртәрәк булган тарих битләрен әдәбиятта Нурихан Фәттах ача башлады. Икенчедән, бу дәверләр кешеләрнең телен, гореф-гадәтен бирәү дә әле белмәгән, өйрәнмәгән вакытта бу эшне ул беренче булып тәкъдим итте. Ул чорлардагы тарихи колоритны ничек бирергә икәнен ул хәл итте. Әлбәттә, борынгы бабаларыбыз нәкъ менә шулай сөйләшкәннәр һәм киенгәннәр, ышанганнар-табынганнар икән дип без бүген дә, тарихи әдәбият инде зур гына казанышлар яулагач та, кистереп раслый алмыйбыз. Ләкин бу өлкәдә Нурихан Фәттах тәкъдим иткән версияне дә юкка чыгара яки кире кага алмыйбыз. Борынгыларыбызның ул тәкъдим иткән, ул «ачкан» яшәү һәм сөйләшү-аралашу рәвеше безне, укучы буларак ышандыра, дулкынландыра, әсәрләндерә һәм сокландыра. Сәнгать һәм әдәбиятның иң югары билгеләмәсе дә шул түгелмени?! Өченчедән, һәм мөһиме, борынгы дәвер вакыйгалары һәм кешеләре образлары ярдәмендә язучы совет хакимияте шартларында аяк астына ташланган, артка чигерелгән гомумкешелек кыйммәтләрен тулы көченә яңгыратты. Гаделлек һәм миһербанлык, кешелекле һәм кечелекле булу, олыны хөрмәт итү һәм кечене яклау, җир-суга мәхәббәт һәм ата-анага хөрмәт, шәхескә, кем генә булмасын ул, тиешле игътибар һәм ихтирам һ.б. кебек, җәмгыятьне тотып тора торган, алга үстерә торган сыйфат-кыйммәтләр — безнең бүгенгебезгә дә җитми торган билгеләр — Нурихан Фәттах әсәрләрен бик тә заманча яңгырата, тарихи материалны яңача сурәтләүнең матур үрнәге югарылыгына күтәрә.

«Итил суы ака торур» романы да, «Сызгыра торган уклар» да — ерак офыклы, эпик әсәрләр. Киң диңгезне иңләп алу кебек үк, катлаулы эпик әсәр язу аерата бер талант һәм осталык сорый. Зур хезмәт соравын инде әйткән дә юк! Бу әсәрләр тармаклы-тармаклы, ләкин ныклы бер үзәккә тупланган, бик ыспай һәм җегәрлекле сюжетка корылган. Аны бер яки берничә персонажның, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең оешу һәм үсү тарихы дип кенә чикләп куеп булмый. Дөресен әйткәндә, боларда тулаем бер халыкның язмышы — үсү, тәҗрибә туплау тарихы, ачы сабаклар ала-ала җитлегү чоры гәүдәләнеш таба. Н.Фәттах каләме белән иҗат ителгән чын кешеләрчә хис итә, сызлана һәм шатлана белгән, чын акыллы хуҗаларча фикер йөртә белә торган, киң карашлы һәм фәлсәфи тирән, бай рухлы бабаларыбызның образлары белән бүгенге укучы горурлана, аларга соклана, аларны үз итә, ярата. Бәс шулай икән, димәк, ул тарихыбызга соклана, аннан гыйбрәт ала, горур һәм бәйсез булырга өйрәнә, дигән сүз. Ә болары — бүген мөстәкыйльлек өчен көрәш юлына чыккан милләтебез өчен иң кирәкле, җитешмәгән сыйфатлар. Ул сыйфатларны Н.Фәттах әнә кайчан ук тәрбияли башлаган икән инде, аларның халкыбызга күптәннән хас булып та, бүген исә тагын да әһәмиятлерәк икәнен әллә ничә ел алдан күргән-сизгән икән.

Әйткәнемчә, соңгы елларда «тарихчы» язучыларыбыз җитди уңышларга иреште. Бездә Болгар чоры, Казан ханлыгы дәверләре турында, Сөембикәләр, Колшәриф, Батырша һәм кайбер ханнарыбыз, батырларыбыз турында әсәрләр туды, легендар шәхесләребез театр сәхнәләренең түрендә урын алды. Алар иңләп алынган тормыш материалы белән дә, тарихны колачлап алу ягыннан да, сурәтләү үзенчәлекләре буенча да төрле-төрле. Ләкин аларның юл башында нәкъ менә Нурихан ага Фәттах торганын бер тәкъдир итеп, билгеләп куярга тиешбез.

*Азат Әхмәдуллин, 1994*

# ИТИЛ СУЫ АКА ТОРУР

*Тарихи роман*

Итил суы ака торур,
Кыя төбе кака торур.
Балык тәлим бака торур,
Күлең тәкый күшәрер.

*Борынгы заман*
*татар халык җыры*

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар Болгарга.
Кызганам моңлы баланы,
Үзем моңлы булганга.

*Хәзерге заман*
*татар халык җыры*

## Сүз башы

Татар халкының бай тарихы бар. Диңгездән бер тамчы алган кебек, менә шул бай тарихтан мин дүрт-биш елны аерып алдым. Дүрт-биш ел тарих өчен генә түгел, аерым кеше гомере өчен дә бик аз вакыт. Ләкин мин алган дүрт-биш елның әһәмияте татар тарихы өчен чиксез зур.

Кайсы чор соң ул шулай да?

Ул — Болгар чоры.

922 елның маенда Болгарга ерак Багдадтан илче килә. Болгар рәсми төстә ислам дине кабул итә һәм заманында иң зур, көчле дәүләтләрнең берсе белән дипломатик мөнәсәбәт урнаштыра. Шулай итеп, Идел-Чулман буендагы беренче дәүләт — Болгар дәүләтенең яңа тарихы башлана.

Багдад илчелегенең секретаре, борынгы тел белән әйткәндә, битекчесе Әхмәт Ибн Фадлан шул чордагы болгарлар һәм башка халыклар турында истәлекләр язып калдыра. Романда мин, нигездә, менә шул истәлекләргә таянып, Болгарга ерак илчеләр килер алдыннан һәм килгәч булган хәлләрне тасвирладым.

Алдан ук шуны искәртеп куясым килә: монда сурәтләнгән кайбер вакыйгалар, кайбер күренешләр бүгенге күзлектән караганда сәер тоелырга мөмкин. Ләкин шуны да онытмаска кирәк, ул борынгы көннәр, вакыйгалар, кешеләр... бик еракта, бик тирәндә күмелеп калган. Аларга инде мең дә илле ел чамасы!

Шулай итеп, тугыз йөз дә унсигезенче елга аяк басабыз.

Түрдән уз, хөрмәтле укучым, изге Болгар җиренә!

*Апрель, 1969*
*Казан*

## Беренче баб

### I

Менә тагын яз җитте. Кышкы озын төннәрдән соң, каты салкыннардан, ачы бураннардан соң тагын яз килде. Тәбәнәк, болаңгыр күктә ягымлы кояш күренде; тирә-якны яктыга, куанычка күмеп, җирдәге барлык терегә күз кысып, шаярып, кайнар укларын яудырды. Калын кар астында басылып яткан тигезлекләр, калкулыклар, урманнар, чокыр-чакырлар... әкренләп-әкренләп авыр йөктән арына бардылар. Кыш буена тынып торган җирнең өсте озакламый өтәләнгән тунын салып ташлады. Сыртларда яшел үләннәр мыек төртте. Яр буйларында тал бөреләре күзләрен ачтылар. Басулардан, үзәннәрдән челтерәп беренче сулар акты.

Сулар акты... Дөнья яралганнан бирле сулар кая таба аккан булса, быел яз да сулар шул бер якка юнәлделәр. Инешләр, елгалар, ермаклар, ташулар...— барысы да Чулман атлы олуг суның кочагына омтылдылар... кушылдылар, көчәйделәр, ургып-шаулап, алга ыргылдылар. Чулман исә еракларадан, якыннардан җыеп алган язгы суны, сыяларны1, бозны-карны тагын ары алып китте. Кайдадыр кояш баешта, кыялы ярлар янында, олуг Чулман үзенең бөек туганын очратырга тиеш. Алар шунда кавышалар, бергәләшеп, кочаклашып, көн ягына юл тоталар. Кайнар ком, кояш илендә, тау-ташлар,

камышлар илендә Итил-Чулман суын ямансулап иксез-чиксез диңгез, төпсез диңгез көтеп ята. Хазар диңгезе көтеп ята. Анда изге Хазар җире, анда изге каган[1]...

Сулар ага... Җир йөзендә сулар бертуктаусыз агалар да агалар. Җәй агалар, яз агалар, көз агалар... Агым сулар кешеләрнең, киекләрнең чир-чорларын, кайгыларын, языкларын алалар да еракларда упкыннарга, чоңгылларга ыргыталар. Агым сулар, җир өстенең чүп-чарларын, үлекләрен юып алып, үзләрендә юк итәләр. Шулай ел да җир яңара, җир яшәрә.

Җир яңара, җир яшәрә... Өзелмичә, тукталмыйча, бөек Чулман кебек, Итил кебек, көн-төн җирдә тормыш ага...

Яз килде, яз!..

Киң Чулманга — кояш белән, ай-йолдызлар белән яшьтәш Чулманга ашыгып төрле яктан сулар ага...

Утташ кам[2], туры караган кояшка күзләрен кысыштырып, җиңел генә атына атланды да ишегалдыннан чыкты. Ялына, маңгай чәчләренә, койрыгына төрле төстәге тасмалар, тимер, бакыр кисәкләре тагылган акбүз ат, су исе, кырлар исе сизеп, куанып кешнәп җибәрде, куганны да көтмәстән, кызуларга тотынды. Аның кешнәвенә башка атлар тавыш бирде. Кайдадыр яңгыратып әтәчләр кычкырды, анасыннан аерылган бәтиләр чәрелдәде. Түбә өстендә генә, биек тирәк башында, талпынып-талпынып, сыерчык сайрады. Яз килде, яз!

Урамда очраган кешеләр Утташ камга олылап баш иделәр. Язгы суда йомычка агызып, чыр-чу килгән бала-чагалар, Утташ камның бизәлгән, чылтыр-чылтыр килгән атын күреп, баштанаяк ап-ак киемен, каны качкан кырыс йөзен күреп, уеннарыннан туктап калдылар. Кечкенәләр, кинәт котлары алынып, җыларга тотындылар, өлкәнрәкләре, бу безне тотып ала күрмәсен дигән сыман, тизрәк читкә тайпылырга ашыктылар. Утташ кам узып киткәч, кешеләр артларына борылып карадылар. Куркып кына балалар яңадан уеннарына тотындылар, ярым пышылдап, ерактагы камны үртәргә тотындылар:

Камчы-кам,
Тамчы там!
Кем башына? —
Кам башына!

«Утташ кам өеннән чыккан. Имингә генә булсын!» — дип уйладылар кешеләр, пошынып.

Утташ кам, үзен күргән кешеләрнең телсез-өнсез калуларына да, балаларның җылауларына да әз генә дә исе китмичә, киресенчә, үзеннән куркуларына күңеле булып, эре генә баруында булды. Кәкре-бөкре урамның тәбәнәк өйләре арасыннан чыгып, ул бераздан кар суы инде агып беткән, шәрәләнеп, караеп калган калкулык итәгенә килеп җитте. Тапталып чокырланган тар гына юл кыйгачлап үргә менде, уңга борылды. Калкулыкның урта бер төшендә, иң биек җирдә биек койма белән уратып алынган би өе күренде. Тышкы якта, капка төбендә, кояшта йокымсырап утырган сакчы, тояк тавышын ишетеп, кабаланып аягына басты, күкрәгеп киерде.

— Иминлекме, балам! — диде Утташ кам, теләр-теләмәс кенә.

— Иминлек, кам баба! — диде сакчы, ашыгып, күзләрен челт-мелт ачып.

Утташ кам, аны-моны сорашып тормыйча, ярым ачык капкадан кереп тә китте. Сакчы капканы ишегалдындагы пычрак сулар аксын дип ачып куйган иде. Ул Утташ камның шулай шома гына кереп китүенә аптырагандай итеп торды да, ачу белән төкереп куйды, капкасын япты, сөңгесен кочаклап, яңадан йокымсырый башлады.

Үзсүзле, кырыс, Утташ кам бинең өй ишегеннән дә шулай сорамыйча гына, җиңел генә үтеп китмәкче булды, тик мондагы сакчы аңа аркылы төште.

— Би өйдә юк. Яр-капкада,— диде сакчы.

## II

Акбүре ыруының башы Күрән би үзенең ырудашлары белән яши торган Кызыл Яр катау[1] Чулманның уң ягына — биек, текә ярга җитеп, кырт кына киселгән ачык сырт өстенә урнашкан иде. Чулман ярыннан ераклашкан саен киңәя барган, тигезләнә, яссылана барган сыртның ике ягыннан да су ашаган тирән чокыр сузыла иде. Катаудан бер-ике чакрым арада, куе урман эчендә атлап чыгарлык киңлектә генә булган, катау янында исә чын-чынлап упкынга әйләнгән чокырлар төбеннән җәй көне челтерәп чишмәләр йөгерә, яз көнендә болганчык сулар ага иде. Шуңа күрә, күз күреме җиткән барлык җирне Чулман иңләп алган чакта, кыргый урманнар, таулар-калкулыклар арасында, иксез-чиксез су уртасында утрау гына булып күренгән Кызыл Яр катау бөтен дөньядан аерылган сыман тоела иде.

Тигезле-тигезсез өчпочмак шикелле калку җир кисәге текә ярлар буенча сузылган ике катлы койма белән уратып алынган иде. Катауның басуларга, урманнарга барып тоташа торган тигез ягы яу өчен иң уңай урын булганлыктан, сыртның батынкы билен аркылыга кисеп, бер як чокырдан икенче як чокыргача сузылган коймалар аеруча нык итеп корылган иде. Имән, нарат бүрәнәләрдән салынган ике кат бура арасына балчык, ком катыш чуерташ тутырылган, өстенә күпер җәелгән иде. Тышкы яктан

койма буйлап өч кат тирән ур[1] казылган, ур кырыйларына очлы башлы юан казыклар утыртылган иде. Койма яныннан үтә торган иң тирән урга, казык башларын күмәр-күммәс итеп, су тутырылган иде.

Катауның ике капкасы бар иде. Капкаларның берсе — Чулман яры буендагысы — «Яр-капка» дип, тигезлек ягындагысы — «Басу-капка» дип атала иде. Койма өстендәге каравыл өйләрендә, манараларда, капка түпләрендә көнен-төнен сакчылар кизү торалар иде. Чулманга су төшкәндә аеруча сак, уяу булырга кирәк. Мондый чакта астан да, өстән дә каекларда юлбасарларның, йә булмаса канга сусаган күршеләрнең килеп чыгуы бар.

Мондый чакта катау кешеләре, билгеле, яу килүен генә көтмиләр. Мондый чакта — каекларга, көймәләргә тоткарлыксыз юллар ачылганда, катау кешеләре чит илләрдән, чит җирләрдән шулай ук яхшы кунакларны да көтәләр иде.

Акбүре ыруының башы Күрән би Яр-капка янындагы манарага менеп карарга ярата иде. Бөтен катауда бу иң биек җир иде. Чулман өсте дә, ерактагы урманнар, калкулыклар да моннан уч төбендәгедәй күренә. Менә бүген дә ыру башы, манараның тар төннегенә[2] капланып, ерактагы күк читен шактый озак күзәтте. Бик бирелеп караганга, аның күзләре авыртты, су чите белән күк чите исә, бергә буталып, болганчык томанга әйләнде. Күрән би, яшь чакларындагы шикелле озак карый алмавына, башы әйләнүенә, йөрәге сугуына эче пошып, көрсенеп куйды. Күзләрен йомган килеш, бераз гына сөялеп торды да икенче як төннеккә килде. Чәнечкеле кара урманнар, калкулыклар белән чикләнгән су өстен ул бик үк теләмичә генә күзәтте — төн ягы аны артык кызыксындырмады.

Беравык онытылып торгач, би яңадан көньякка — Чулманның түбән ягына текәлде. Елга өстеннән салкынча җил исте; аста, яр буенда, балыкчыларның өзек-өзек тавышлары ишетелеп китте. Кешеләр тавышы тукталып торган арада, бөтен тирә-якны тигез бер шауга күмеп, берөзлексез дулкыннар шаулады.

Күпме генә караса да, су өстендә би бернәрсә дә күрә алмады. Ул тагын көрсенеп куйды, аптырап төннек каршында басып торды-торды да, авыр аякларын көчкә кузгатып, тар, текә баскычтан аска төшә башлады. Ул баскан саен басма яркаклары, авырлыкка түзә алмыйча, шыңшып-ыңгырашып калдылар. Басмалар гына түгел, буралап салынган манара да, би әкрен генә атлап аска төшкәндә, як-якка чайкалып торгандай булды. Илле яшьләр чамасындагы Күрән би богадай таза, имәндәй төз, озын буйлы иде. Тик бу тыштан караганда гына шулай. Таза «имән»нең эченә корт төшкән. Кыш урталарыннан бирле инде бине ниндидер яман чир тынгысызлый. Аның эче авырта. Элеккечә инде ул чиләкләп буза да эчә алмый, терсәгеннән майларын агызып симез итләр дә ашый алмый. Язга таба исә аның бу эчке авыруы тагын да көчәя башлагандай булды. Сул як касыгында ул бертуктаусыз авырту тойды, ниндидер көчсезлек тойды. Кайчакларда йөрәге авырта шикелле тоелды. «Үлемем якынлаша микәнни?» дип уйлады еш кына би, коты алынып. Әлегә ул үзенең чире турында имчеләргә дә, башкаларга да берни белдермәде. Әлегә ул эчтән генә пошынды. Шулай да аның көннән-көн сүлпәнләнә баруын, ыру эшләре, катау эшләре белән бик үк кызыксынмый башлавын якын кешеләре күрми калмадылар. Бу инде Күрән бинең кулыннан көч китә барганлыгын белдерә иде, бу инде аның кояшы баюга таба тәгәри дигән сүз иде. Ни генә булмасын, үзенең чирен би шуңа юрады. Бу аның туктаусыз күңелен тырнап торды. Эч пошу, күңел тырналу исә аның күзгә күренмәгән әлеге чирен генә көчәйтте.

Быелгы язны Күрән би менә шундый борчулар белән, аннан да бигрәк, яшерен теләкләр, ныклы ышанычлар белән каршылады. Чулманда боз кузгалу белән, ул көн дә шулай манара башына менде, киң болыннарга җәелгән су өстен күзәтте. Ул үзе генә түгел, башкалар да күзәттеләр.

Бөек елга боздан әрчелгәнгә инде бишенче көн булды. Башка елларда инде алар күптән килеп җитә торганнар иде. Кыр казлары сыман тезелешеп килерләр иде. Килеп җитәрләр дә, ач бүредәй комсызланып, ярга ташланырлар иде.

Быел менә юк... күренмиләр. Ни булган аларга? Җил-давыл чыгып, барысын да су иясе йотканмы? Хазар белән берәрсе үзара яу башлаганмы, әллә соң Итил буйлап юлбасар урыслар төшеп, барысын да кырып бетергәннәрме? Әйе, быел алар соңга калдылар. Биш көнгә... ун көнгә, бер җылга соңга калдылар!

Инде нишләргә? Көн дә менә шулай манарага менеп, күзләреңталганчы күк читен күзәтеп торыргамы, әллә соң аларның килеп җиткәнен көтеп тормастан, тизрәк үзеңә юлга җыена башларгамы? Килмәсәләр, нишләтергә барлык товарыңны? Маңгай тиреңтүгеп тапкан җыллык байлыгыңны нишләтергә? Киштәләрне сыгып төшкән төлке, кеш, ас, кондыз тиреләрен, тәпән-тәпән балларны, таудай өелгән ул күннәрне, савыт-сабаны, агач-ташны нишләтергә? Аннан да бигрәк... аларныкы кебек имчеләрне каян табарга монда, аларныкы кебек дару үләннәре, им суларын каян алырга?! Бөтен ышаныч бары аларда, бары аларда!

Күрән би, күңелсез уйларга бирелеп, койма өстендәге күпергә килеп чыкты. Текмә читенә якын килеп, су өстенә тагын бер карыйсы килсә дә карамады — ары китте. Койма өстендә, ышыкта җилсез иде, җылы иде. Аның бер дә моннан кайтып китәсе килмәде. Шулай үз-үзен кая куярга белми басып торганда, ул Яр-капкага якынлашып килүче Утташ камны күреп алды. Аның болай да караңгы йөзе

тагын да караңгыланып китте, ниндидер күңелсез сөйләшү буласын сизенеп, касыктан өстәрәк эче сызлый башлады.

**III**

— Иминлекме, би? — диде Утташ кам, койма өстенә менә торган баскыч янында туктап.

— Иминлек, кам баба,— диде би, тыелып кына, урыныннан кузгалмыйча.

Ул, култыксаны кысып тоткан көе, Утташ камның аттан төшүен, үз янына менүен көтеп торды. Утташ кам, теләр-теләмәс кенә, өзәңгедән аягын алды, ашыкмыйча гына, үзенең кемлеген белеп кенә баскычтан менде дә, би алдында бүреген салып, башын иде.

— Илгә тынычлык, бигә байлык бирсен, Тәңрем,— диде кам.

— Шулай булсын,— диде би, камның йөзеннән күзен алмыйча.

— Су азрак икән шул быел,— диде Утташ кам, текмә янына килеп.

— Юк, алай ук аз түгел, кам баба,— диде би.— Манара башыннан яхшы күренә — менәбезме?

— Юк, юк! — диде Утташ кам, кулын селтәп.— Монда җил. Аска төшик булмаса, сөйләшәсе сүзем барые синең белән, би.

— Ник аска төшеп торырга? — диде би.— Әйдә, каравыл өендә сөйләшәбез.

Ул, Утташ камның ни дә булса әйткәнен көтеп тормастан, кире борылды, койма өстенә салынган каравыл өенең ишек бавын тартып җибәрде. Каравыл өе тар гына, кысан гына иде. Аның Чулманга караган ягына — озынча төннек, түшәменә — төтен юлы уелган; балчык идән уртасына эре ташлардан өеп учак ясалган, учакның ике ягына, капма-каршына утыргычлар куелган иде.

Би килеп кергәндә, ике яшь сакчы, уты сүнеп җитмәгән учак өстенә иелә төшеп, көлешеп нидер сөйләнеп утыралар иде. Бине күрү белән, алар икесе дә урыннарыннан сикереп тордылар, ниндидер яман эштә тотылган кешеләр сыман, кызарынып үрә каттылар. Телсез калдылар.

— Чыгып торыгыз,— диде би аларга.

Сакчылар ишеккә ташландылар, би артыннан килгән камны күрмичә, аңа килеп бәрелделәр — чак-чак кына аяктан екмадылар. Ярый әле, Утташ кам ишеккә тотынып калды.

— Күзегез чыкканмы әллә? — дип кычкырды кам, ачу белән.

Сакчылар, агарынып, камның аяк астына егылдылар.

— Игелексезләр! — дип сукранды Утташ кам, сакчыларны чыбыркысы белән сыдырып.

Ыру башы белән икәүдән-икәү генә калгач та ул шактый тынычлана алмады. Күрән би, аның ыңгырашуына, сыкрануына эчтән генә көлемсерәп, тар утыргычка җәелеп утырды да кыска тунының көмеш каптырмаларын ычкындырып җибәрде — елгадан төннек аша салкын җил исеп торса да, учак янында эссе иде.

— Ни йомыш, кам баба? — диде би, сүзгә башлап.

— Йомышыңны да онытырсың монда,— диде кам, сөякчел куллары белән озын, нечкә сакалын сыйпаштырып.

— Шулай тиз онытырлык йомышмыни, кам баба? — диде Күрән би, көлемсерәп.— Кызың исән-сау... илдә тынычлык... Күреп торасың, Тәңренең боерыгына буйсынып, Чулман боздан әрчелде... Ишек артында беркемнең күзе юк.

— Тын алырга ирек бир, кияү,— диде Утташ кам, бинең шулай килделе-киттеле сөйләнеп утыруын ошатмыйча.— Мин синең белән эш турында сөйләшергә килдем.

— Сөйләшик, бабай.

— Яшел чирәм җирдән борын төрткән, кияү! — диде кам, ясалма бер күтәренкелек белән.

— Күргәнем булмады,— диде би, сүлпән генә.— Бу арада башлар катып тора.

— Каткандыр, кияү, каткандыр,— диде кам баба, тынычланып.

Тынычлангач, ул үзен бидән өстен сизә башлады. Үзен өстен сизгәч исә, аның күз алдында Күрән би, башка барлык ырудашлары кебек, аңсыз, белексез бер кешегә әйләнде. Бөек Тәңре турында, изге ияләр, яман ияләр турында, йола турында үзе нәрсә генә әйтмәсен, Күрән бинең берсүзсез ышаначагын, үзе белән килешәчәген ул алдан ук белеп утырды. Моны шулай ук би үзе дә белде. Утташ камны ул үзенең бабасы буларак кына түгел, ыруда беренче урынны яулап алырга, ыру башы булырга омтылучы көндәше, дошманы буларак та күралмады, шулай да түзде. Акбүре ыруының өлкән камы, имчесе, күрәзәчесе, аксакалы булган Утташны ул, би буларак, ыру башы буларак, олыларга тиеш иде. Элек тә ул еш кына аннан шүрләп куйгалый иде. Үзен чир корты кимерә башлагач, бу шүрләү еш кына анда чын-чынлап куркуга әйләнә иде.

— ...Аннары шул: сигез көннән, кияү, төн үзәге авышкач, беренче әтәч кычкырыр алдыннан яңа ай туа,— диде Утташ кам, ашыкмыйча гына, күзләрен йома төшеп.

— Шулаймыни? — диде би, камның сүзләренә ярашырга тырышып.

— Яңа ай туар алдыннан барлык эшләрне төгәлләргә кирәк, кияү,— диде Утташ кам, салкын җилдән читкәрәк китеп.— Нинди ай икәнлеген беләсеңдер, кияү... Яшел чирәм ае. Яшел чирәм белән

бергә изге ияләр дә, явыз ияләр дә уяна. Бөтен дөнья күзен ача, кияү! Быел су күп түгел. Быелгы җыл яман килә, кияү!

— Сыгыр җылы![1] — диде би, көрсенеп, Утташ камның куркыныч сүзләре йогынтысына бирелеп.— Сыгыр җылында орыш күп була, дип белми әйтмәгәннәр бабайлар. Яман килере инде күренеп үк тора — бүген бишенче көн, әнә беркем юк.

— Явыз ияләр яшел чирәмнән дә элегрәк уянганнардыр,— диде Утташ кам, бине тыңламыйча.— Чокырларда пычрак сулар торып калды, агачларга чүп-чар эләгеп калды. Җыл яман килә. Йолык[1] туен быел зурлап ясарга туры килер, кияү!

— Зурлап ясарбыз,— диде би, килешеп.

Шулай диде дә кинәт сагаеп калды. Бабасының нинди уй белән килүен ул әлегәчә белә алмый интегә иде. «Зурлап» дигәндә Утташ камның коры, шыгырдавык тавышы чак-чак кына калтыранып киткәндәй булды. Нәрсә каермакчы була бу? Ука белән каелган төлкетамак тунмы, энҗеле камчат бүрекме, көмешләнгән иярме, кырнакмы[1] — нәрсә?

— Бүген төш күрдем, кияү,— диде Утташ кам, беравык тынып утырганнан соң, әкрен генә, серле генә яңадан сүзгә башлап.— Атка атланып үзебезнең Басу-капкадан күпер аша чыгып барам, имеш. Күпер уртасына җиткәнием, каршыма Әрлик хан ялчысы Октуган килде чыкты! Бер кулы белән атның ялыннан тотты, икенче кулы белән сакалымнан тотып алды. Тешләрен ыржайткан, күзләре уттай яна! Йолаларны бозасыз, ди, йолык бирмисез, ди. Атыңны бирәсеңме, ыруыңны, җиреңне-суыңны бирәсеңме, ди...

— Ялган! — диде кинәт би, башын калкытып.

— Ни-нәрсә ялган, балам? — диде Утташ кам, өстенлеген, тынычлыгын әз генә дә үзгәртмичә, авыр күз кабакларын калкыткандай итеп.— Минем сүзләрем ялганмы, явыз Октуган сүзләре ялганмы? Тфү-тфү! Телемә дә аласым килми атын... котымны ала язды, көчкә котылдым.

Күрән би эндәшмәде, очлы бүрек кигән авыр башын салындырып, ачуыннан кызарынып-бүртенеп тик утырды.

— Әрлик хан ялчысы явыз Октуган сүзләре ялган, кам баба,— диде ул бераздан, ачуын эчкә йотып.

— Менә шул...— диде кам, өзелгән сүзен ялгап,— сакалымнан тотып алды бу. Тарта. Авызына якын ук китерде. Инде йота дип торам. Җиргә-суга да, ыруыма да тимә, атымны бирермен, мин әйтәм...

— Нинди атка атланганыең соң син, кам баба? — диде Күрән би, ачыктан-ачык мыскыл сиздергән бер тавыш белән.

— Мин, кияү, Йолдыз-кашкага атланганыем,— диде Утташ кам, тыйнак кына.

— Юк! — диде Күрән би, аягына басып.— Йолдыз-кашкага синең беркайчан да атланганың юк... төшеңдә дә! Атлана да алмыйсың, син аның янына да бара алмыйсың!

— Ялгышасың, кияү,— диде Утташ кам, коры, усал күз карашы белән бине өтеп.— Изге эшкә тел тидереп тору үзе язык! Күңелең бозык синең, кияү, шуңа да эшең алга бармый.

— Монысы инде яла,— диде Күрән би.

— Мин синең белән ызгышырга килмәдем,— диде Утташ кам, урыныннан торып, эре генә.— Яңа айның дүртенче көнендә йолык туе ясарбыз. Син шуңа каршы түгелдер ич?

— Ясарбыз,— диде би, теш арасыннан сыгып.

## IV

Акбүре ыруының башы Күрән би белән Утташ кам туганнан туганнар иде. Ыруда иң көчле кешеләр буларак, алар моңарчы үзара тату гына яшәделәр, каршылыклар килеп чыкса да, беркайчан да эшне зурга җибәрмәделәр, ничек тә җайларга, үзара килешергә тырыштылар. Бозылышу, чын-чынлап, ныклап бозылышу узган көздән башланды. Бинең өлкән хатыны Әди тилчәдән үлгәч, аның урынына кемнең өлкән хатын булырга тиешлеге турында туган-тумача арасында тартыш булып алды. Ыру йоласы буенча, өлкән хатын булып бинең яшькә иң өлкән хатыны, карт хатыны Каракүз калырга тиеш иде. Каракүз исә Утташ камның кызы иде. Карт, чулак хатынын Күрән би яратмый иде. Чулаклыгы, ямьсезлеге өстенә, Каракүз бераз гына аңгырарак та иде. Би аңа яшь чагында да «йола буенча» гына өйләнгән иде. Шулай ук бергә торганда да ул аның белән «йола буенча» гына торды — аннан аның бер генә баласы да булмады. Бөтен ыруда Күрән би уң кул булса, Утташ кам сул кул иде. Шуңа күрә бары яратмаган өчен генә ул аның кызын аерып та җибәрә алмый, читкә дә тибәрә алмый иде.

Шулай да Күрән би яңа өлкән хатын билгеләгәндә үзенчә эшләргә булды. Беренче тапкыр ул ыру йоласын бозды, беренче тапкыр бөтен туган-тумача алдында, бөтен ыру алдында үзенең Утташ кам белән санлашмавын күрсәтте. Өлкән хатыны итеп ул Каракүздән яшьрәк Койтым бикәне билгеләде.

Бинең өлкән хатыны булу ул мактаулы исем генә түгел иде. Бинең өлкән хатыны булу ул туктаусыз эш, кайгы, борчу дигән сүз иде. Өлкән хатын ул ашау-эчүне, өй карауны, кием-салым җитештерүне, терлек карауны, бинең бүтән хатыннарын, барлык балаларын, колларын-чураларын, кыз-кыркыннарын үз кулында тотарга тиеш иде. Катлаулы, четерекле бу эштә аңа ныклы кул да, яхшы, тиз уйлый торган

баш та, ару-талу белмәс йөрәк тә кирәк иде. Бинең бетмәс-төкәнмәс көндәлек эшен, таудай эшен Койтым бикәдән башка чыннан да беркем дә башкара алачак түгел иде. Моның шулай икәнлеген Каракүз үзе дә яхшы аңлады, шуңа күрә ул өлкән хатын булу турында бернинди теләк белдермәде. Аның өлкән хатын булуын, барыннан да бигрәк, аның усал атасы теләде, Каракүз аркасында ыруда тагын да зуррак көчкә, байлыкка ия булырга тырышкан туган-тумачалары теләде.

Өлкән хатын булып Койтым бикәнең билгеләнүен белгәч, Утташ кам ачуыннан шартлый язды. Күктәге Тәңрегә, җирдәге ияләргә таянган, шуңа күрә үзенең көченә кирәгеннән артык ышанган Утташ кам ырудашларын ачыктан-ачык та, яшертен дә бигә каршы котырта башлады: аның үзе турында, Койтым бикә турында яман сүзләр сөйләде, йола бозган өчен бөтен ыруга, катауга киләчәк кыран[1] белән, яу белән, талау белән куркытты. Үзенә каршы коткы тараткан өчен Күрән би, теләсә, билгеле, Утташ камны бер селтәнүдә юк итә алган булыр иде. Бабасы белән бик каты ызгыштан соң, ул чыннан да шулай итмәкче булды. Койтым бикә аңа икенче төрлерәк киңәш бирде, син йоланы боздың, шулай булгач, сиңа Утташ кам белән килешүдән башка юл юк, диде; моның өчен сиңа иң элек аксакаллар белән килешергә кирәк, юкса сине Утташ камның әйләндереп салуы бар, диде.

Күрән би өлкән хатынының сүзен тыңларга булды. Ул аксакаллар киңәше җыйды, үзенең ни өчен йоланы бозарга тиеш булуын аңлатып бирде. Аксакаллар бине яклап чыктылар. Утташ кам җиңелде, тик шуннан соң ул үзенең киявенә каршы эшне уйлабрак, астыртынрак эшли башлады. Әле генә Йолдыз-кашканы йолыкка соравы аның менә шул астыртын эшенең бер чагылышы иде.

Үзенең бабасын би каравыл өеннән озата чыкты, аска төшә торган баскычкача ул аның белән янәшә атлап барды. Шулай да ул җиргә төшеп тормады, койма өстендә торып калды. Мыек чылгыйларын чәйнәп, би Утташ камның атка атлануын, иярдә буен төз тотып китеп баруын карап торды.

Менә бер җылны бүдәнә симерсә, икенче җылны — тартар... Көрәш әле тукталмаган. Монысында ул җиңде. Йолдыз-кашка инде юк! Чыннан да, ялгышмады микән ул йоланы бозып? Ни отачак ул бабасы белән тартышып? Күрәсең, берни дә отмаячак. Бүген Йолдыз-кашка, иртәгә тагын башка нәрсә... Аның көче чиксез, турыдан-туры аңа каршы чыгып булмый. Ни дигән сүз бу? Әллә чыннан да аның каргышы төштеме? Ул чире, ул сартлары[1]... соңга калган ул сартлар-базарганнар[2]... Нишләп уйламады соң әле ул моңарчы бу турыда?! Йа Тәңрем, үзең ярлыка барлык языкларны!

Утташ кам күздән югалгач та, Күрән би баганаларга салынган басмалар өстеннән койма буенча Басу-капка ягына юнәлде. Аның күңелен икеләнү корты кимерде. Аннары аның юкка-барга ачуы килә башлады. Аның кемне дә булса тотып яңаклыйсы, тибеп җибәрәсе йә булмаса кылыч белән башын чабып өзәсе килде. Тик койма сакчылары барысы да урыннарында иде, барысы да кораллы, тыныч, кырыс иде.

Чирек чакрым чамасы баргач, койма буендагы басмадан уң якка икенче басма аерылды. Бу басма да биек баганаларга салынган иде, тик аның янында койма гына юк иде. Күп тә үтмәде, басмалар буенча би үзенең өенә кайтып керде.

Яшь, чибәр хатыны Койтым бикәне күрү белән, аның барлык ачуы юкка чыкты. «Юк, ялгышмаганмын,— диде ул үзенә үзе, баштагы уйларына кире кайтып.— Утташ кам теләсә ни сөйләсен — көч барыбер минем кулда!»

«Шулай да этне үскетмәвең яхшы,— дип уйлады ул бераздан.— Ярар, Йолдыз-кашка ике арадагы ызгышка чик куйсын. Шуның белән тамагы тыгылсын. Тату яшәүгә ни җитә!»

Өлкән хатынына ул үзенең әлерәк кенә Утташ кам белән очрашуы турында сөйләде.

— Мин каршы түгел,— диде Койтым бикә, иренең сүзләренә артык куаныч белдермичә.— Шулай да атның иясе белән дә киңәшсәк, ничек булыр икән?

— Тотыш беләнме?! — диде би, исе китеп.— Атасы-анасы белән киңәшергә аңа әле иртәрәк. Ни әйтсәләр, шуны тыңлар.

— Шулаен шулай да...— диде Койтым бикә, күңелсез генә.— Тугач та Йолдыз-кашканы аңа үзең атадың. Ул аны карап үстерде. Инде килеп, берни әйтми тартып алсак, ни дияр ул бала? Аңа инде бала дип тә булмый...

— Өйләнмәгән, димәк, бала! — диде ата кеше.

— Йола буенча шулай, чынында инде ул — җитлеккән ир,— диде Койтым бикә, бердәнбер улын яклап.

**V**

Язгы йолык туен кешеләр кояш көткән кебек көтеп алалар иде. Бу көнгә һәркемнең яшерен уетеләге була. Авырулар, явыз ияләргә йолык биреп, чирдән котылу, авырлылар — баладан, языклылар — языктан котылу турында уйлап юаналар иде.

Йолык туеның кайчан буласы билгеле булгач та, катау кешеләрен күңелле бер күтәренкелек биләп алды. Кешеләр, бу олы көнне тиешенчә каршылау, тиешенчә озатып җибәрү өчен, җыена да башладылар: өлкәннәр йолыкка биреләсе терлек-туар турында, аш-су турында кайгырттылар, яшьләр көн-төн үзара бәйге тоттылар — ук аттылар, сөңге чөйделәр, төрлечә көчләрен сынаштылар.

Иртәгә туй була дигән көнне катау кешеләре мунча керделәр, баштанаяк таза киемнәрен киенделәр — кышкы чирләрдән, языклардан, кайгылардан арыну шуннан башланды. Аннары, артыш яндырып, өй эчендәге почмакларны, абзар-кураларны төтәсләделәр, күздән кереп калган явызияләрне куалап чыгардылар.

Икенче көнне барлык катау кешеләре — яше-карты, тазасы-чирлесе — башка көннәргә караганда иртәрәк тордылар. Кояш чыкмас борын ишекләр, капкалар ачылды. Олуг Чулман аръягыннан, су астыннан чыгып килгән кояшның беренче яктысын кешеләр, җиргә яланаяк баскан килеш, йөзләрен көнчыгышка төбәгән килеш, елмаеп-куанып каршыладылар. Ырудашлар бер-берсен яңа туган көн белән котладылар, бер-берсенә изге теләкләрен белдерделәр.

Кояш чыгу белән бер үк мәлдә дип әйтерлек, көндәлек тормыш башланганлыгын аңлатып, учакларга утлар ягылды, катауның барлык түбәләреннән күккә зәңгәр төтеннәр үрләде. Төтеннәрдән бераз гына соңарып, Басу-капка ягында да, Яр-капка ягында да быргылар уйнап җибәрде. Капкалар ягыннан килгән таныш көй тынарга да өлгермәде, катау өстендә икенче төрле тавышлар яңгырады. Басу-капкадан Яр-капкагача сузылган борма-сырма урамнан Чулман ягына — кояшка каршы атлылар төркеме бара иде.

Барлыгы алар унлап кеше иде. Барысы да алар акбүз атларга атланганнар, барысы да баштанаяк ак киемнәргә киенгәннәр иде. Аларның атларына чигүле япмалар ябылган иде. Атларның ялларына, койрыкларына, маңгай чәчләренә очлы тимер, җиз кисәкләре, бөркет каурыйлары, бүре тешләре белән аралаштырып, төрле төстәге тасмалар тагылган иде. Шулай ук җайдакларның үз киемнәре дә иске-москы чүпрәк, тимер-томыр, агач-сөяк ише нәрсәләр белән бизәлгән иде. Шунлыктан атлар да, кешеләр дә әкрен генә атлап барган уңайга чыңлаган, чылтыраган, шакылдаган тавышлар чыгаралар иде. Шушы шалтыр-шолтыр тавышларга әледән-әле дөңгер — барабан тавышлары кушыла иде.

Акбүз атларга атланган ак киемле төркемнән берничә адым алдарак, төрлечә кыланып, ихахайлап, җылап, тырнашып, юл буенча ниндидер карачкылар кыймылдый иде. Алар барысы да әшәке, сәләмә киемнәргә киенгәннәр, алар коточкыч ямьсезләр иде: берсенең авызы кыек, икенчесенең күзе сукыр, өченчесенең аягы аксак иде. Болар шулай төрлечә киендерелгән, битләренә, маңгайларына корым буялган явыз ияләр — албастылар, өрәкләр иде. Дөңгер, быргы тавышлары белән куркытып, артларыннан уклар атып, аларны Чулманга куалап алып баралар иде. Урамнарда, капка төпләрендә җыелышып торган кешеләр, бигрәк тә бала-чагалар, бу «албасты, өрәкләргә» таш, балчык кисәкләре ыргытып, каргыш сүзләре яудырып калалар иде.

Ак җайдаклар төркеменең башында озын саплы ал байрагын югары күтәреп, ыруның өлкән йолачысы Утташ кам бара иде. Ат койрыгы сыман озын, тар байракның уртасына Ак бүре ыруының билгесе — ак бүре башы төшерелгән иде.

— Кайраккан! Кайраккан! Алас! Алас![1] — дип кычкырды Утташ кам.

Аның тавышы тынар-тынмас, арттагылар бердәмләшеп, аның соңгы сүзен күтәреп алдылар, бөтен катауны яңгыратып: «Алас!» — дип кычкырдылар. Бераз җир тын гына баргач, дөңгер, быргы тавышлары тыну белән, Утташ кам яңадан башлады:

— Ырудашлар! Уяныгыз — көн тугды! Уяныгыз — йолык туе!

Аның артыннан тагын да яшьрәк, көррәк тавышлар:

— Алас! Алас! — дип кычкырдылар.

Шушы беренче төркемнәрдән соң бераз калышып, Басу-капка яныннан икенче бер җайдаклар төркеме кузгалды. Болары барлыгы унике кеше иде. Алар барысы да, яуга чыккан сыман, баштанаяк күн, тимер киемнәргә киенгәннәр, ук-җәя белән, сөңге белән коралланганнар иде. Аларның да атларына төрле тасмалар тагылган, аларның да иң алдагысы ыру байрагын күтәреп бара иде.

Кораллы ирләр күренү белән, урамдагы кешеләр капка, койма артларына качышып беттеләр. Шул ук мәлдә дип әйтерлек коймаларга, капкаларга, берәр багана төбендәге ташка-нигә, йә булмаса өй түбәләренә шап та шоп уклар килеп тия башлады. Бу изге уклар иде. Өенә, каралты-курасына изге ук тигән кеше үзен өлешле итеп, бер ел буена үзен чир-чордан, талаудан, кайгы-борчудан котылган итеп саный иде.

Менә сөрәнчеләр дә узып китте. Күңелле ыгы-зыгы башланды. Ишекләр, капкалар яңадан ачылды. Капка төпләренә, урам якка байраклар чыгарып куйдылар; баганалардан баганаларга, өйләрдән өйләргә ыру тамгалары төшерелгән чүпрәкләр, агач, сөяк кисәкләре бәйләнгән баулар суздылар; ишек төпләренә, каралты-кураларга балаларны, карт-корыларны, терлек-туарны яман күзләрдән сакларга тиеш булган абаклар[1], сарыганнар[2] чыгарып утырттылар.

Еракта, йөрәкләрне җилкетеп, кам бабаның:

— Уяныгыз — көн тугды! Уяныгыз — йолык туе,— дигән сүзләре яңгырап торды.

Кояш су астыннан чыгып бер-ике таяк күтәрелгәндә, сөрәнчеләр, Яр-капкага җитеп, кире борылдылар. Күрән би урдасы янында аксакаллар төркеме туктап калды. Би өендәгеләр дә быргы уйнап җибәрделәр, байракларын күтәрделәр. Капка сакчылары каерып имән капкаларны ачтылар. Капкада би углы Тотыш күренде.

Атасы кебек ул таза, эре сөякле иде. Тик аңа караганда ул буйга тәбәнәгрәк, иңбашка киңрәк иде. Борын асты әле аның яңа гына караеп килә иде. Бүгенге көндә караңгы чырайлы булу яман саналса да, аның алсу иреннәре кысылган, матур кара кашлары җыерылган иде. Җылый-җылый аның күз төпләре кызарып беткән иде. Ул кайгылы иде, ул ачулы иде, ул ярсулы иде. Сул кулына ул яшел төстәге язгы йолык байрагын тоткан, уң кулына үзенең сөеклесе Йолдыз-кашканы җитәкләгән иде. Бүген ул туй башчысы санала иде. Аксакаллар кебек, ул да бүген баштанаяк актан киенгән иде. Биленә аның көмеш аеллы киң каеш буылган, муенына көмеш чылбыр белән ыруның сакчысы — кечкенә алтын бүре башы тагылган иде.

Яшь, чибәр җегет Йолдыз-кашка белән икәүләп капкадан чыкты да, тирә-якта җыелып өлгергән кешеләрнең берсенә дә карамыйча, төп юлга төште. Углы артыннан ук капкадан Күрән би чыкты, Койтым бикә, бинең башка хатыннары, балалары, туганнары чыкты. Ыру башы белән Койтым бикәгә урам яктагы сигез аксакал кушылды. Барысы да үзләренең урыннарын белеп, би артыннан, аксакаллар артыннан иярә бардылар. Ясанган, бизәнгән, куанып елмайган кешеләр төркеме, көчле бер агым булып, урамнан Басу-капка ягына юнәлде.

Тотыш җитәкләгән яшь айгыр искиткеч матур иде. Ул уттай янып торган җирән төстә иде. Маңгаенда аның уч төбедәй генә ак табы — йолдызы бар. Аның күкрәге киң иде, нечкә, нык аяклары озын иде. Ялт-йолт килеп, очкынланып торган күзләре зур, матур иде. Атлаганда аның аяклары җиргә дә тими шикелле иде — биюче яшь кызлар кебек, ул шундый җиңел, шундый матур атлый иде. Бүген аны кыз куенына керәсе кияүдән дә болайрак төзәндергәннәр иде. Өстенә аның ука белән матур итеп каелган күк төстәге зур япма салганнар. Япманың чит-читләреннән көмешләнгән ал, кызыл, сары чуклар асылынып тора. Япма өстенә сырлап, бизәп эшләнгән кечкенә, җиңел генә ияр салынган иде. Яллары, койрыгы аның матур итеп таралган, бизәлгән иде.

Барлык кешенең күзе бары Йолдыз-кашкада гына булды. Алар аңа, соклanudан бигрәк, куркып, аптырап карадылар. Күрән бинең мактанычы, яшь Тотышның куанычы булган атаклы чаптарның бүген менә йолык туенда чалыначагына беркемнең дә ышанасы килмәде. Бу ничектер башка сыймый торган, аңлап булмый торган нәрсә булып тоелды. Тик шулай да бу турыда беркем дә ачыктан-ачык әйтергә батырчылык итмәде.

Тотыш белән янәшә атлаган Йолдыз-кашка Басу-капкага җитәргә йөз адым чамасы калгач, капка сакчылары, туйны каршылап, быргы уйнадылар, дөңгер кактылар. Шыгырдап авыр капкалар ачылды, аркан белән күтәртеп куелган күперләр төшә башлады. Кырлар-басулар иркенлеген тоеп, Йолдыз-кашка кинәт тынычсызлана башлады: башын югары күтәргән килеш, борын тишекләрен киереп, язгы җил белән басудан килгән исерткеч исләрне иснәде, бөтен катауны яңгыратып, күкрәк түреннән ургылып чыккан бер куанычлы тавыш белән кешнәп җибәрде. Дөп-дөп атлап күпердән чыкканда, ул чын-чынлап ярсый башлады: авызлыгын чәйнәде, «Әйдә, чабабыз!» — дигән сыман, йомшак иреннәре белән яшь җегетнең иңбашына төртеп-төртеп алды, тартылды, колакларын шомартты.

Сөекле чаптарын кызганудан Тотышның күзләренә яшьләр килде. «Әллә качабызмы икәүләп?» — диде ул, күңеленнән айгырга эндәшеп. Кем тота аларны монда? Кем куып җитәр аларны? Беркем дә! Качарга да китәргә күршеләргә, Биар иленә. Йә булмаса урманга кереп яшеренергә. Яшәргә шунда Йолдыз-кашка белән үлгәнче бергәләп...

«Качыйк! Качыйк!» диде Йолдыз-кашка, юеш ирене белән аның битенә үрелеп. Әллә соң ул аны шулай үпмәкче булды микән? Озакламый үзенең Тәңре каршысына китәчәген аңлап, әллә шулай саубуллашырга теләде микән соң ул? Атлар, этләр, барлык терлекләр, киекләр ни буласын алдан белеп, аңлап торалар ди ич. Тик аларның әйтергә телләре генә юк.

Алар артыннан ябырылып, аларның үкчәләренә басып, меңләгән кешеләр, атлар килде. Колак төбендә генә шаулаган, кычкырган, көлешкән тавышлар ишетелеп барды. Бизәнгән, шау-шулы, куанычлы кешеләр төркеме, сабадан сыгып чыгарылган әйрән төсле, Басу-капка аша, күпер аша киң яланга агылдылар да агылдылар.

**VII**

Күпердән чыгып, бер чакрым чамасы баргач, төркем сулга борылды, сөзәк сырт өстеннән түбән төшә башлады. Баштарак сирәк-мирәк куаклар арасыннан сузылган, ары таба куе урман арасына барып кергән иске киң юл кешеләрне озакламый зур гына аланга китереп чыгарды. Көньякка таба авышрак булган бу аланның як-ягында, сакчылар кебек булып, төз, биек чыршылар, каеннар, усаклар калкып утыра иде. Тирә-якта язгы кояш исе, яңа җир, яңа чирәм исе аңкый иде. Монда үзенә бертөрле җиңеллек, иркенлек сизелә иде.

Аланның тач уртасында ялгыз нарат, бу тирәдә бердәнбер нарат үсеп утыра иде. Якындагы чыршы-усаклар белән чагыштырганда, ул төз дә, биек тә түгел иде. Аның кәкре-бөкре кызгылт ботаклары, ниндидер куллар сыман булып, бер-берсе белән аралашып беткән иде. Төптән ул бик юан иде, чатыр сыман җәелгән ябалдашы шундый киң иде,— яңгыр яуганда аның астына күпме генә кеше кереп утырса да, ул аларның барысын да сыйдыра алыр сыман иде. Кәүсәсенең җиргә якын төшенә аның җир астыннан бүртеп-кабарып көчле тамырлар килеп тоташа иде — җиргә нык берегеп утырганлыгы аның әллә каян күренеп тора иде. Бу искиткеч нык, юан наратны, карт, олы наратны әйтерсең бернинди җил-давыл да, бернинди күк күкрәүләр дә, җир тетрәүләр дә урыннарыннан кузгатырлык түгел иде.

Тик нишләптер бу наратның яшел ылысларында, кызгылт шома ботакларында агарып терлек сөякләре күренгәли иде. Язгы кояшта күзләрне чагылдырган, шомарып беткән шундый ук сөякләр, кыл-йон кисәкләре тирә-якта җир өстендә дә аунап ята иде. Яшел чирәм белән капланган җирнең битендә зур-зур яралар булып, кара тап булып, иске учак эзләре, чокырлар, кара күмергә әйләнгән агач башлары күренә иде.

Куе урман эчендәге бу алан — Акбүре ыруының көләүлеге иде, көләүлек уртасындагы ялгыз нарат — Акбүре ыруының табына торган изге нараты иде. Монда йолык урыны иде. Ыруның барлык язгы-җәйге, көзге туйлары шушында уздырыла иде.

Уйнап-көлеп, җырлар җырлап, шау-шу килеп кешеләр изге аланга җыела тордылар, өе-өе белән үзләренең ата-бабадан килгән билгеле урыннарына тарала тордылар. Атланып килгән, җигеп килгән атларны, туарып, тышаулап, утарга җибәрделәр. Арбаларны, изге нараттан билгеле бер ара калдырып, ялан уртасына боҗра сыман тезеп чыктылар. Ялгыз нарат боҗраның уртасында калды. Изге түгәрәккә керү-чыгу өчен ике якта ике капка калдырылды. Капкалар янына, катаудагы кебек, сакчылар куелды. Шунда ук байраклар кадалды. Изге түгәрәкнең эченә үзләре белән алып килгән сыннарны утыртып куйдылар. Арбадан арбага чуклы баулар эленде.

Коллар, чуралар арбалардан ачы бал, буза тулы чүлмәкләр, чапчаклар[1] алдылар, төргәкләрне бушаттылар. Ирләр урманга утынга кереп киттеләр, хатыннар, иске урыннарга учаклар ягып, казан асарга тотындылар. Сугымчылар пычак кайрады, аксакаллар, Утташ кам җитәкчелегендә, изге түгәрәктә мәш килделәр.

Изге боҗра эчендәге учакларга ут кабынып, күккә зәңгәр төтен күтәрелү белән, аландагы шау-шу кинәт тынып калды. Кешеләр, эшләрен ташлап, арбалар янына җыелдылар. Алданрак өлгергәннәр арбаларга менеп басты, кайберләре атларга атланды, яшьләр, бала-чага агач башларына үрмәләде.

Менә җил-давыл чыккан сыман, кинәт кенә дөңгер каккан, һай-һулап кычкырган тавышлар яңгырап китте. Кешеләр, тыннарын кысып, меңләгән күзләр белән изге нарат ягына текәлделәр.

Йолык кылу башланганны белдергән тавыш — кинәт купкан шау-шу шулай ук кинәт кенә тынып калды. Ыру башы Күрән би, атыннан төшмичә генә, ырудашларын быелгы яз белән, җылы кояш белән котлады, аннары, изге нарат ботаклары аша күккә карап, Тәңрегә үзенең теләкләрен юллады. Тәңредән ул быелгы язның, җәйнең Акбүре ыруы өчен игелекле булуын, чир-чорларның юкка чыгуын, терлек-туарның көрлеген, игеннәрнең уңуын, үз кешеләренең бай, көләч булуын теләде. Күрән бидән соң Утташ кам келәү әйтте. Ул Тәңрегә ырудашларының аерым-аерым ялынычларын юллады.

Шул чакны көнчыгыш капка ягында ниндидер шау-шу купты. Кешеләр барысы да шул якка борылып карадылар. Кылычларын баш өстендә селтәп, капкадан унике җәяүле ир йөгереп керде. Алар барысы да яшьләр, тазалар иде. Бик каты ярсыган-ачуланган шикелле кыланып, алар изге нарат янына йөгереп килделәр дә, наратны бар яктан да уратып алдылар. Изге аланны яңгыратып, бөтенесе бер авыздан: «Алас! Алас!» — дип кычкыра-кычкыра, алар күзгә күренмәгән явыз ияләрне кылыч белән туракларга тотындылар. Шуннан соң тиз генә кире чигенделәр. Чигенгәч алар, киек эзәрлекләгән сыман, ярым иелеп, як-якка ялт-йолт каранып, наратны бер-ике кат әйләнеп чыктылар да искәрмәстән җиргә капландылар. Шул ук мәлдә аларның баш өстеннән очып, каяндыр нарат төбенә ак каурыйлы уклар килеп төште. Шундый ук уклар, сызгырып, бер-берсенең юлын кисеп, баш өстеннән дә очып киттеләр. Бу укларны көнбатыш капкадан килеп кергән ирләр атты. Алар да, бердәм тавыш белән урман яңгыратып: «Алас! Алас!» — дип кычкырдылар.

Кылычлы, уклы ирләрдән соң изге түгәрәккә сөңгечеләр килеп керде. Сөңгечеләр, айналарны кадый-кадый, күздән югалырга да өлгермәделәр, ике як капкадан утчылар килеп кергәне күренде. Кулларына алар янып, төтәсләп торган артыш, миләш, юкә, шомырт агачлары тотканнар иде. Утлы агачларын кылыч сыман баш өстендә селтәп, сөңге белән кадаган сыман уңга-сулга төртеп-айкап, утчылар да изге түгәрәктә әйләнеп йөрделәр. Ул арада кылычлы, калканлы ирләр яңадан түгәрәк эченә килеп керделәр, яңадан күкрәк киереп кычкырып җибәрделәр. Аларны тагын укчылар, сөңгечеләр, утчылар алыштырды.

Шулай итеп, Әрлик ханның әшәке ялчыларын ике тапкыр турап атып, чәнчеп чыккач, үләксәләрен яндырып, төтен белән бергә күккә очыргач, изге нарат яны тулысынча арыкланып калды. Изге җиргә, арык җиргә, кулга-кул тотынышып, елмаеп, яшь, чибәр кызлар керде. Өсләренә алар төрле төстәге җиңел күлмәкләр кигәннәр иде. Муеннарына тал бөреләреннән төзеп сыргалар такканнар, чәчләренә,

күлмәкләренә төрле төстәге чәчәкләр кадаганнар иде. Алар барысы да яланаяк иде. Бу яшь кызлар, ышану буенча, яз килүен белдерәләр иде.

Менә алар, боҗра булып, изге наратны әйләндереп алдылар да, күктәге Тәңрене, кояшны, җирдәге тереклекне мактап, җыр башлап җибәрделәр. Аларга бөтен алан кушылды. Йөзләрчә, меңнәрчә күкрәкләрдән чыккан куанычлы җыр тавышы шундый көчле булды — бөтен тирә-як, давыл чыккандагы сыман, күкрәп, гүләп торды.

...Ил-көн биргән Тәңребезгә
Атак! Атак!
Җир-суларга, урманнарга
Атак! Атак!
Ил-көнемә, ыруыма —
Акбүрегә
Атак! Атак![1]

## VIII

Күмәк җыр тавышы тынуга, колакларны тондырып, аларның төрле җирендә унлап быргы чинап җибәрде. Көнчыгыш капкадан Тотыш углан җитәкләп, як-якка ыргылган Йолдыз-кашканы алып керде. Яшь кызлар өсләренә су сипкәндәй таралып беттеләр. Күрән би белән Койтым бикә дә читкәрәк тайпылды. Изге нарат янында бары тик Утташ кам да, аксакаллар гына торып калды.

Аксакаллар, йөзләре белән кояшка таба борылып, изге нарат ботаклары аша күккә карап, йолык келәве әйттеләр.

Күккә куе булып, ургылып аксыл-зәңгәр төтен күтәрелде. Яшь айгыр төтен эчендә күмелеп калды. Беразга тынып торган быргылар, дөңгерләр яңадан ярсып чинарга, дөпелдәргә тотындылар. Ул арада ирләр Йолдыз-кашканың алгы аякларына бәйләнгән арканны берьюлы тартып җибәрделәр. Йолдыз-кашка гөрселдәп җиргә ауды. Тиң дөңгер, быргы тавышлары арасында аның гөрселдәве дә, пошкыруы, мышнавы, гыжлавы да беркемгә ишетелмәде — җирдәге кешеләргә дә, күктәге ияләргә дә ишетелмәде.

Атны тунадылар. Сөякләренә пычак йөзе тидермичә, итен иткә, сөяген сөяккә аердылар. Итне тигез итеп ыруның барлык өйләренә өләштеләр. Үзләренә тигән кисәкләрне сак кына тотып, пешекчеләр үз учакларына ашыктылар. Алар аны тимер шешкә кидереп, утта кыздырачаклар, аннары үз өйләрендәге барлык кешеләргә бүлгәләп, таратып чыгачаклар. Изге аланга килгән бер генә кеше дә йолык итеннән авыз итми калмаячак.

Йолык кылынган Йолдыз-кашканы итеннән-тиресеннән, эчәк-бавырыннан арындыргач, шәрә сөлтәрне иплән кенә аягына бастырдылар, ычкынырга гына торган сөякләрен бер-берсенә бәйләп куйдылар. Шуннан соң тирене яңадан сөлтәргә кидерделәр, эченә коры ут-үлән тутырдылар. Тирене тектеләр, атның башыннан, биленнән нечкә кыл-аркан белән нарат ботакларына тарттырып куйдылар. Шулай итеп, Йолдыз-кашка яңадан элекке төсенә керде, бары тик аның күзләре генә сүнеп калган иде дә, торышында элеккечә тереклек, омтылыш, кайнарлык кына сизелми иде.

Бу эшләрнең барысын да аксакаллар башкарды. Алар үзара берни сөйләшмәделәр, бер-берсенә берәр нәрсә әйтергә кирәк булса, бары ымлап кына күрсәттеләр. Алар бик тиз, бик җитез кыландылар. Утташ кам, читтәге явыз ияләрне куркытып, бертуктаусыз аксакаллар тирәсендә йөренеп торды, дөңгер какты, кычкырды, әле уңга, әле сулга карап, әле кинәт артына борылып, бары үзенә генә күренгән явыз ияләргә каргышлар яудырды.

Йолдыз-кашкадан соң ике карт үгезне, аннары унлап тәкәне чалдылар. Аларны да шулай ук тунадылар, итен, эчен алдылар, сөлтәрләренә тиреләрен кидереп, тегеп куйдылар. Тик аларның карачкыларын барысын да нарат төбенә түгел,— аланның төрле почмакларына утыртып чыктылар. Йолдыз-кашка янына бары бер үгез дә бер тәкә карачкысы гына куелды.

Күп тә үтмәде, дөрләп янган учакларда итләр пешеп чыкты. Кисмәкләр, чүлмәкләр ачылды. Кояш яктысында балкып яткан киң аланда күңелле шау-шу әз генә дә тукталып тормады.

Ит исе, кан исе сизеп, түбә өстендә болыттай булып каргалар, козгыннар очып йөрде, якында гына агачлар арасында, күзләрен уттай яндырып, тешләрен ыржайтып, ач бүреләр посып яттылар.

Язгы кояш кичкә авышу белән, тамаклары карлыгып беткән кешеләр кайтырга җыена башладылар. Коллар, чуралар тышаулы атларны алып килделәр, җигеләсен җиктеләр, иярлисен иярләделәр. Байракларның, сыннарның беришен монда калдырдылар, беришен үзләре белән алдылар.

Кайтканда да ыру башы үзенең йөз кешелек кучеı[1] белән иң алдан кузгалды. Башкалар әкренләп-әкренләп алар артыннан иярә бардылар.

Сырт өстенә менеп, туры катауга илтә торган ачык юлга чыккач, Күрән би, үзенең өлкән хатынын алдан җибәреп, үзе читкә чыкты, арттарак калды. Юл читендә туктап торган килеш ул кешеләрне күздән кичерде.

— Тотыш юк,— диде Күрән би, Койтым бикәне куып җитеп.— Төштән соң мин аны күрмәдем. Истән чыккан.

— Мин күрдем,— диде бикә, пышылдап.— Ул өйгә кайтып китте. Аягыма су үтте, туңам, диде.
— Туңгандыр! — диде би.
— Аңа да ачуланып булмый инде,— диде ана кеше, улын яклап.
— Ярар, бетте! Әйттем исә кайттым! Шайтан колагы саңгырау булсын! — диде би, ачулы пышылдап.
— Аларның күзләре дә бар шул,— диде Койтым бикә.
— Капка каравылчысын үзең җайларсың. Мин берни белмим! — диде би, кырт кисеп.
Атасы белән анасы үзе турында шулай борчылып кайтканда, Тотыш изге алан янындагы тәбәнәк чыршы астында утыра иде. Яу чабарга җыенган ир кебек, кулына ул алдан монда яшереп куелган сөңгесен, калканын тоткан иде. Шунда ук агулы уклар белән тулы ике садак, җәя ята иде. Башына ул тимер алпак, өстенә күбә кигән иде. Ул чыннан да монда орышка дип килгән иде. Түземсезлек белән ул кешеләрнең тизрәк изге аланнан китеп бетүләрен көтә иде.

**IX**

Икенче көнне, таң атар-атмас борын, Күрән бинең капка төбенә Утташ кам килеп җитте. Ул чамадан тыш ачулы иде. Үзен капкадан кертергә теләмәгән сакчыларга ул ачулы сүзләр әйтте. Сакчылар аңа бинең йокыдан уянганын көтәргә куштылар. Утташ кам, теләсә дә, теләмәсә дә, көтәргә тиеш булды.
Би аны үзенең ак өендә каршы алды.
— Нишләп бик иртә? Бер-бер эш чыктымы әллә? — диде ул, бабасының таң тишегеннән килеп җитүен ошатмыйча.
— Чыкты, кияү! — диде Утташ кам, ачуыннан бүреген салырга да онытып.
Аның болай сөйләшүе, җимерелгән йөзе бинең күңелендә йокымсырап яткан кире тойгыларын уятты.
— Син бик тупас күренәсең, кам баба,— диде ул, коры гына, урынына утырып.— Сал башыңны, утыр, сөйлә.
Утташ кам, башындагы бүреген тартып алды да, күрсәтелгән урынга терәлгәндәй итте.
— Эш чыкты, би... кияү! — дип кычкырды ул, чәрелдек тавыш белән.— Нindидер явызлар изге наратны... бөтен ыругның изге сакчысын, яклаучысын мыскыллаганнар! Тәүбә! Тәүбә! Изге Алланы бозганнар, би! Изге Кайракканның йөзенә төкергәннәр! Тәүбә! Тәүбә!
— Кемнәр?! Кайчан?! — диде би, коты алынып.
— Кемнәр, имеш! — дип чәрелдәде Утташ кам, күз яшьләренә буылып, бизгәк тоткандагы сыман калтыранып.— Килмешәк Койтым кырнакның игелексез Тотышыннан башка кемнең шуңа кулы барсын?!
Би ап-ак булды. Шуннан соң ул бурлаттай кызарынды, еш-еш тын алып, йокысы качып бетмәгән усал күзләреннән куркыныч очкыннар чәчрәтеп, урыныннан торды да җөнтәс шәрә кулын ашыкмыйча гына алга сузды, бабасының сакалыннан учлап тотты.
— Аңлатыбрак сөйлә! — диде ул.
Өлкән камның тары бөртегедәй елтыр күзләре чәчрәп чыгардай булып акаеп калды. Кайнарлыгы, ачуы-ярсуы шундук юкка чыкты, бөтен явызлыгы, бергә җыелып, кинәт каядыр эчкә төшеп китте. Теле тотлыгып, беравык эндәшә алмый торгач, ул, этенә-төртенә:
— Б-б-бүген иртән б-б-барсам...— диде.
— Шуннан? — диде би, аның сакалын ычкындыргандай итеп.
— Ш-шуннан...— диде Утташ кам.— Из-зге нарат төбендә... ч-ч-чүмәлә дисәң, ч-чүмәлә түгел... у-утын дисәң, утын түгел... Йа Тәңрем! Үле бүреләр өелеп ята! Кайсын ук белән, кайсын кылыч, сөңге белән... Унлап-унбишләп! Бүре каны койганнар! Изге җиргә, изге нараткаебызга... бүре каны койганнар!
Утташ кам, сакалы ычкынгангамы, изге наратны кызганыпмы, кычкырып җылап җибәрде.
Күрән би, яшен суккан кебек, телсез-өнсез калды: бу чыннан да коточкыч иде, бу чыннан да беркайчан да булмаган, була алмастай яман бер эш иде.
— Арлар түгел микән? — диде ул, аптырап, бабасының җирәнгеч йөзенә карамаска тырышып.
— Язык! Язык! — дип такмаклады Утташ кам, тынычлана алмыйча.— Башы аягы астына гына килсен! Кулы корысын! Күзе чыксын! Йөргән җирендә җир йотсын!
— Кемне каргавыңны әйтеп карга,— диде би, кашларын җыерып.
— Тотыштан башка...— диде кире беткән кам, үксеп.
Күрән би ике куллап бабасының иңбашларыннан кысып тотты да, күзләренә карап:
— Күрдеңме? — диде, әкрен генә.
«Юк» дигәнне аңлатып, Утташ кам башын чайкады.
— Күрүчеләр булганмы? — диде би.
— Юк,— диде кам, мыгырданып.

Күрән би җиңел сулап куйды, маңгаена бәреп чыккан тир бөрчекләрен кулы белән сыпырды да, Утташ камнан читкәрәк китте, кинәт авырта башлаган эчен тотып, йөзен чытып, кояш яктысы төшкән төннек аша беравык тышка карап торгандай итте. Шуннан соң ул яңадан Утташ кам янына килде.

— Бу турыда беркемгә лыгырдыйсы булма! — диде ул, боерып, янап.

Монда килгәндә Утташ кам бине чын-чынлап өркетә алырмын дип уйлаган иде. Бинең бу кыланышы аның уйларын үзгәртеп җибәрде. Ул инде изге нарат турында да, үтерелгән бүреләр турында да уйламады, ул бары үзенең мыскыллануы турында гына уйлады. Бинең яңадан үзенә якынлашуын күреп, ул:

— Кычкырам! Сөрән салам! — диде, ишеккә ташланып.

Күрән би аның артыннан ыргылды, ишек бавын кулыннан йолкып алды да, үзен идән уртасына төртеп җибәрде.

— Син... белексез! — диде ул, төкерекләрен чәчеп.— Син минем Йолдыз-кашкамны алдың — каршы килмәдем. Инде минем углыма теш кайрыйсыңмы?! Мин сиңа углымны чалырга юл куймам! Әллә син үзең кыргансыңдыр ул бүреләрне... юрамалый... каян белим мин аны!

— А Тәңрем! А кояш! — диде Утташ кам, кулларын югары күтәреп.

— Бар, кычкыр! — диде би.— Синең миңа аяк чалырга маташуыңны ырудашлар белмиме әллә? Мин әйтермен, миннән, Койтым бикәдән үч алмакчы булып, үзе үтерткән, диярмен. Бар, ник кычкырмыйсың?! Шунда ук муеныңа элмәк салып, агач башына асып куярга боерырмын. Бар, бар, кам баба, бар, сөрән сал!

— Юк, болай булгач, салмыйм, кияү! — диде Утташ кам, өзелеп чыкмады микән дигән сыман, сакалын сыйпап.— Шулай да куркыттым дип уйлама.

— Изгелек, турылык эзләп йөри, имеш! — диде би, кызганнан-кыза барып.— Ыру кайгысын кайгыртып йөри, имеш, үле бүреләр күргән дә, дөньяның астын өскә әйләндерергә дә күп сорамас! Ыруда кем коткы тарата — син! Кем башбаштакланып йөри — син!

— Язык, язык! Тел тидермә, язык! — диде кам, мыгырданып.

Башка чакта Күрән бине юашландыра торган, куркыта-өркетә торган сүзләр аңа бөтенләй көчсез тоелды. Камның мыгырдануын ул колагына да элмәде.

— Мин инде языктан арындым,— диде ул, әз генә дә исе китмичә.— Кирәк булса, тагын арынырмын.

— Тотышның бүреләрне үтергәнен мин күрмәдем, башкалар да күрмәгән,— диде Утташ кам да, би эзенә төшеп, тышкы бер тынычлык белән.— Шулай да мин шикләнмим, би, ул үтергән! Анда аның уклары ята. Мин барысын да беләм, кияү! Төштән соң аның келәүлектән китүен дә беләм, кичә кич өендә булмавын да беләм. Синең углың башкисәр булып үсә. Йолаларга төкереп карый. Йола бозып язык ясыйсың да, языгымны йолып, тынычландым дип уйлыйсың. Ялгышасың, би! Ыруның иминлеге, тынычлыгы синең көчеңә генә таянмый, ыруны ата-баба йоласы тота. Кешеләр арасында мин түгел, син коткы таратасың, син башбаштаклык эшлисең. Агач башында мин түгел, синең углың асылынып торыр, кияү! Углыңны алып калырга тырышсаң, Тәңре синең үзеңне чакыртып алудан да тартынмас.

— Җитәр! — диде би.

— Җитмәс! — диде кам, кире чигенеп.— Ата-баба йоласы, ата-баба түрәсе барлык кеше өчен бер... бигә дә, чурага да...

Күрән би йомарланган йодрыгын Утташ камның борын төбенә китерде.

— Менә күрәсеңме... берме бармаклар? — диде.— Шуларны тигезлә, аннары бер булыр.

Кияү белән бабай, ыру башы белән кам шулай әйтештеләр, әйтештеләр дә кинәт тынып калдылар. Утташ камның күз алдында әйтерсең яктылык чаткысы кабынып китте. Болай ачыктан-ачык талашып, бозылышып берни кыра алмаячагын ул бер тапкыр аңларга тиеш булды. Утны ничек тә астанрак йөртергә кирәк иде.

— Синеке көч! — диде ул, уфтанган булып.— Тәңре каргышыннан курыкмаган булсам, мин монда килеп тә йөрмәгән булырыем.

— Кеше-кара күргәнче аларны юк итәргә кирәк, бабай,— диде би дә, юашланып.

— Шулай итәрбез, кияү,— диде Утташ кам.

Кешеләр торып йөренә башлаганчы дип, ашыгып, Күрән би белән Утташ кам, ике колны алдылар да, келәүлеккә киттеләр. Изге нарат төбендә чыннан да таудай булып бүре үләксәләре өелеп ята иде. Шунда ук, наратның икенче ягында, берни булмагандай, Йолдыз-кашка басып тора иде. Аландагы үгез, тәкә карачкыларының барысы да ботарланып, теткәләнеп беткән иде. Бу, билгеле, изге бүреләрнең генә эше түгел, монда тагын изге булмаган ике аяклы бүренең дә бик каты эшләгәне күренеп тора иде. Ул ике аяклы бүренең кем булуы турында күңеленнән әз генә дә шикләнмәсә дә, Күрән би, үләксәләрне күргәч, ах-вах килде.

— Кемнең йөрәге җиткән моңа?! — диде ул, шаккатып.— Ничек җир күтәрә ул кешене?! Тәңрем, кичер аны бу языгы өчен!

Коллар бүре үләксәләрен, шулай ук барлык карачкыларның сөяк-санакларын урман арасындагы тирән чокырга илтеп ташладылар. Берәрсе ялгыш күрә-нитә күрмәсен дип, Күрән би үләксәләргә ут төртергә кушты.

Өенә ул бик күңелсезләнеп кайтты. Кайткач та ул Койтым бикә белән Тотыш угланны үз янына чакыртты.

— Кем эше булыр икән бу? — диде ул авыр гына, изге аланда күргәннәрен сөйләгәч.

— Мин! — диде Тотыш, өй эчен яңгыратып.

Ул алай кычкырып та әйтмәде бугай әйтүен, шулай да ата белән анага аның бу «мин» дигәне күк күкрәве сыман булып ишетелде. Койтым бикә чак-чак кына артына аумады. Күрән би тораташтай катты да калды.

— Син... Син...— диде ул, тотлыгып.— Беләсеңме шуны — бөтен ыруга... атаңа-анаңа каргышы төшәр!..

Кинәт ишек ачылып китте, күзе-башы акайган яшь сакчы, тамак ярып:

— Сөенче! — дип кычкырып җибәрде.— Киләләр! Каеклар килә!

## X

Үргә таба әкрен генә кыймылдап, унлап-унбишләп каек килә иде. Аларның кем каеклары икәнлеген әле бик үк аерырлык та түгел иде. Шулай да ни генә булмасын, алар киләләр иде! Астан — Болгар ягыннан, Хазар ягыннан, кояшлы Хәрәземнән, йә булмаса ерак Румнан, Багдад якларыннан киләләр иде!

Каекларның килүе турындагы хәбәр тиз арада бөтен катауга таралды. Кешеләр, ашыгып, Яр-капкага агылдылар, ябырылып койма өстенә менделәр, манара башларына үрмәләделәр, текмә араларына кысылдылар. Койма сакчылары кешеләрне әле бер җирдән, әле икенче җирдән кудылар, шулай да артык усаллык та күрсәтмәделәр — катауга ерактан каеклар килүе Күрән би өчен генә түгел, башкалар өчен дә зур куаныч иде.

Би дә, бикә дә шундук терелеп киткәндәй булдылар. Бүреләр кайгысы, Тотыш кайгысы онытылды, бөтен катауны, бөтен өй эчен көндезге кояштай якты куаныч биләп алды. Әйе, киләләр, соңлап булса да киләләр. Соң булса да уң булсын... Төкле аяклары белән!

Күрән би үзенең өлкән углы, каравыл башы Акбогага төтен үрләтергә, икенче углы — субашы[1] Котанга ун каек, йөз ир белән кунакларга каршы китәргә боерды. Текә яр өстенә, коймага кушып салынган манаралардан тиз арада зәңгәр төтен күтәрелде. Яр-капканы ачып җибәрделәр. Яр битенең куен сыман уйдыкланып торган җирендәге баганалар өстенә авыр күпер сузылып ятты. Юан баганалар яныннан башланып, аска таба озын, текә баскыч сузыла иде. Котанның юлдашлары, иңбашларына ишкәкләр күтәреп, йөгергәләп, бер-бер артлы тар баскычтан төшә башладылар. Аста, Чулман яры буенда, киң генә коры җир кисәге бар иде. Монда катауның тамгасы — каеклар, көймәләр, улаклар туктый торган корылмасы урнашкан иде. Тамга янында, Чулман дулкыннарында чайкалып, Күрән бинең йөзләп каегы, көймәләре-улаклары тора иде. Шунда ук балыкчылар, бала-чагалар ыгы-зыгы киләләр иде.

Күрән би ишкәкчеләрнең яр астына төшеп җитүләрен, каекларга төялеп, кузгалып китүләрен өстән карап торды да, өенә таба кузгалды — кунакларны тиешенчә каршылау өчен җыена башларга кирәк иде.

Кояш төшлеккә күтәрелеп җиткәндә, ерактан килүче җилкәнле каеклар да, аларны каршыларга китүчеләр дә катауга килеп җитә яздылар. Кунаклар, бер җепкә тагылгандай, бер-бер артлы тезелеп киләләр иде. Акбүреләрнең каеклары, кунакларның артына да, алдына да төшеп, шулай ук тезелеп, тигез ара саклап киләләр иде.

Менә озын ишкәкләрнең салмак кына күтәрелеп төшүе, җилкәннәр, байраклар, байраклардагы билгеләр аермачык күренә башлады. Күрән би, күзләрен кыскалап, аларның кемнәр икәнлеген чамаларга тырышып карады. Тик, күпме генә караса да, әлегә ул берни аермады. Бу кунаклар сартлар да, румнар да, гарәпләр дә түгел иде, ахрысы. Кемнәр булыр бу шулай да?

— Базарганнар түгел, атай! — дип кычкырды шул чакны Тотыш углан.

— Телеңә тилчә! — диде ата кеше.

— Ямгырчы би килә! — диде Тотыш.— Әнә байракларында өч чатлы каз тәпие.

— Туктыйсыңмы син?! — диде би, үртәлеп.

Тотыш углан тынып калды. Ул тыну белән генә бинең күңеле барыбер тынычлана алмады. Ул инде үзе дә күреп тора — болар чыннан да сатучылар түгел, болар чыннан да казаяклар бугай. Күрән би авызлыгын чәйнәп, баскан урынында биеп торган Акколакның — Йолдыз-кашка анасының корсагына ачу белән төртеп алды. Акколак куркып читкә ыргылды. Үртәлгән би бар көченә тезгенне тартып җибәрде. Иясенең нишләргә теләвен аңламыйча, Акколак, авыр мышнап, ал аякларын күтәрде.

— Ыграк кара, кунаклар килә! — диде би, мыскыл белән атына эндәшеп.

Тамга күперенә иң элек Котан каегы килеп төртелде. Каектагы борынчы ыргакчыга аркан ташлады.

— Кая тыкшынасың — ары кит! — дип кычкырды би үзенең углына.

Борынчы ярга ташланган арканны бер сүз әйтмичә кире тартып алды. Атасы кебек үк чытык йөзле Котан ярга сикерде. Котан артыннан бераз ара калдырып, яр буена икенче каек килеп җитте. Монысы инде кунаклар каегы иде.

Борыннан, койрыктан казаяклар аркан ыргыттылар, уртадан басма суздылар. Каек, күпер читенә терәлеп, чайкалудан туктап калгач та, унлап кеше аягүрә басты. Кыска итеп киселгән сакал-мыеклы, озынча битле, очкынланып торган шаян, тере күз карашлы чандыр бер кеше, елмаеп, Акбүре ыруының башы алдында бүреген салды, башын иде. Күрән би белән чагыштырганда ул бик яшь күренә иде. Күп булса, аңа утыз биш-кырык яшьләр чамасы булыр иде.

— Казаяк ыруының башы Ямгырчы би синең җиреңә килде,— диде ул, Күрән бигә эндәшеп.

— Илме, яумы? — диде Күрән би.

— Ил! — диде Ямгырчы би.

— Төкле аягың белән, туганым Ямгырчы би! — диде Күрән би, бозылган йөзенә елмаю билгесе чыгарып.

Ашыкмыйча гына ул атыннан төште. Койтым бикә дә, бинең башка хатыннары белән балалары да, аксакаллар да — барысы да атларыннан төштеләр, бер тирәгәрәк җыелдылар.

Ямгырчы би басмага атлады, үзенә сузылган кулларга тотынып, елмаеп җиргә төште. Аның юлдашлары да шулай ук җиргә төштеләр. Үзләрен каршылаучы кешеләргә бер-ике адым килеп җитмичә, алар туктап калдылар, Күрән бине, аның якыннарын олылап, билләрен бөктеләр, башларын иделәр. Ямгырчы би, яхшы, бай тунының каптырмаларын чишеп җибәрде, бил каешына бәйләнгән янчыгын — көтүдән кайткан сыер җиленедәй бүлтәйгән зур янчыгын чиште. Янчыктан учлап-учлап ул көмеш акчалар алды. Күрән бинең, Койтым бикәнең, би балаларының, ырудашларының аяк астына акча сипте.

Көмеш табакка салып кыздырылган ит, пешкән балык, бодай көлчәсе тоткан Койтым бикә алгарак чыкты, кунакларга шулай ук баш иде. Кулындагы табакны ул Ямгырчы бигә тоттырды. Кунак би, бармак очлары белән генә чеметеп, табактан бераз ит, балык, көлчә алды, авыз итеп карады. Шуннан соң казаяклар табакны кулдан кулга җибәрделәр.

Кунаклар үз каекларыннан өч сандык төшерделәр. Сандыкларны ачып, Ямгырчы би Акбүренең өлкәннәренә бүләкләр өләшә башлады: Күрән бигә кышкы төлке тун белән бүрек бирде, Койтым бикәгә шулай ук тун бирде, көмеш беләзек бирде. Башкаларга да шактый өлеш чыкты. Кайберсенә күлмәк, кыекча, кайберсенә итек-читек, беләзек, йөзек, муенса ише нәрсәләр тиде. Кунакларны каршыларга төшкән кешеләрнең берсе дә бүләксез, күчтәнәчсез калмады. Акбүреләрнең күңелләре куаныч белән тулды. Салкын, кырыс чырайлар яктырып китте — Ямгырчы би үзе белән бүләкләр генә түгел, әйтерсең көньяк җылысы да алып килгән иде. Кызыл Яр катауга килгән бер генә кунакның да әле беркайчан да бу чаклы күп бүләк өләшкәне юк иде бугай. Менә ичмасам юмарт икән, менә ичмасам бай икән бу Ямгырчы би!

Казаяк ыруының башы Ямгырчы би белән Кызыл Яр катауга йөзләп кораллы ир килгән иде. Йөзләгән ир арасында бер хатын-кыз да бар иде. Ул да булса Ямгырчы бинең кызы Тәңкә иде.

## XI

Казаяк ыруы белән Акбүре ыруы арасында борын-борыннан туганлык яшәп килгән. Алар икесе дә бер тамырдан — Ак хан илендәге Ак җылан ыруыннан аерылып чыккан булганнар. Казаяк белән Акбүре ырулары кайчандыр Чулманның түбән агымында — Итил белән Чулман бергә кушылып, өчпочмак ясаган иркен җирләрне биләгәннәр. Бер-берсе белән алар җир-су өчен дә, терлек-туар өчен дә ызгышып-талашып яшәмәгәннәр. Киресенчә, бер-берсенә кыенлык килсә, үләт, кыран килсә, шундук бер-берсенә булышка ашыкканнар. Шуның өстенә алар ил башы Ак ханның иң көчле, ышанычлы ыруларыннан саналганнар.

Шулай итеп, ике ыру кешеләре, кайгы, талау күрмәенчә, тыныч кына, тату гына тормыш кичергәннәр. Тик шулай да мондый тыныч, тату тормыш мәңгелек булмаган. Көннәрдән бер көнне — моннан бик күп еллар элек — язгы сулар китеп җирләр кипкәч, көн ягыннан Итил буйлап кара яу басып килгән. Кара яуның башында явыз Кара хан торган. Аның кешеләре бик күп булган. Алар көчле булганнар. Аларның укларына, сөңге, кылычына беркем, берни каршы тора алмаган. Язгы ташкын суны берничек тә тотып торып булмаган кебек, Кара ханның чирүен дә беркем, берни тоткарлый алмаган.

Каяндыр Азак диңгезе буйларыннан кубып, алар шулай ташкын кебек, кара болыт кебек килгәннәр дә, урман-кырларны таптап, сулар кичеп, төн ягына таба юл тотканнар. Бөек Итил буенда, ике тау арасында Кара ханның кара явы белән иң беренче орыш булган. Ак ханның уң кулы Буртас би

үтерелгән, чирүе кырылып түгелгән. Шулай итеп, кара яу ике елга кушылган төшкә — Акбүре, Казаяк җирләренә якынлашкан.

Чирмешән суы буенда, киң болында икенче орыш булган. Сугыш көне буе барган. Ике як та бер-берсенә каршы нык торганнар. Кычкырган, ыңгырашкан тавышлар, тимергә тимер бәрелгән, атлар кешнәгән тавышлардан җир-күк тетрәп торган. Сугыша-сугыша кешеләр арып беткәннәр. Сөңгеләр, кылычлар сынып беткән, киемнәр ерткаланган, битләрне-күзләрне кара кан баскан.

Менә кич булган. Караңгы төшкән. Ике як та арып-алҗып җиргә ауган. Батыр алыпларның җеп өзәрлек хәлләре дә калмаган.

Шул чагында көтмәгәндә Кара ханга арттан өстәү килгән.

Ак хан кешеләре тагын җиңелгәннәр. Килмешәкләр тагын өстен чыккан. Бөек Итил, канлы дулкыннарын чайпалдырып, үксеп-үксеп яшен түккән. Итил буе бөркетләре, тилгәннәре туган җирнең алыплары баш өстеннән кайгырышып, сыкранышып очып йөргән. Ач бүреләр, таныш кешеләргә тимәенчә, Кара ханның үлекләрен ашаганнар. Үлгән-үтерелгән кеше белән бөтен болын чуарланган булган.

Соңгы орышта олуг йортның башы Ак хан кергеннәргә тоткын булган. Ханның, балаларының, туганнарының башын чабып өзгәннәр. Шулай итеп, тамырга балта чабылган, йорт-ил юкка чыккан. Исән калган ирләр, куркып-каушап, кайсы кая качып беткән. Кайберәүләр, башын саклап, Кара ханга бил бөккәннәр.

Әйе, Ак хан йорты юкка чыккан. Ирләр үлгән, ирләр качкан, Кара ханга бил бөккәннәр. Тик шулай да үтә батыр ирләр килмешәккә баш бирергә теләмәгән. Туган җирен-суын ташлап тәлим[1] кеше, төмән[2] кеше югарыга — төн ягына күчеп киткән. Шуларның беренчесе акбүреләр булган. Казаяклар, Кара ханга калан[3] түләп, Чулман-суның түбәнендә, уң як ярда торып калган.

Бөтен Чулман буе — бозлы диңгезгәчә — бик борыннан Ак хан җире булган. Акбүреләр Чулман буйлап, үз җирләре буйлап югарыга, бик еракка үрләгәннәр. Бернинди яу килә алмаслык, бернинди чит кеше күзе төшә алмаслык кыргый урманнар арасына, сазлар, күлләр арасына кереп яшеренгәннәр. Берничә ел шулай качып-посып яшәгәннәр дә, яулар тынгач, ачык җиргә — яр буена, болыннарга таралганнар. Катау корганнар, авыллар салганнар. Җир ачканнар — иген иккәннәр, ауга, балыкка йөргәннәр, сату иткәннәр. Беркемгә буйсынмыйча, беркемгә калан түләмичә, үз көннәрен үзләре күргәннәр.

Тик шулай да авыр язмыш Акбүрене тулысынча тыныч калдырмаган. Бөек су юлларын биләп алган Кара хан токымнары елдан-ел көч җыйганнар, байлык җыйганнар. Аларга инде Итил буе гына түгел, Чулман да кирәк булган. Үзен хан дип атаган кансыз Шилке моннан күп еллар элек бу якка да үтеп керә алды. Бөтен Чулман буен Биаргача канга батырып, талап, яндырып, күп җирләрне Шилке үз кулына алды. Моңа инде җегерме ел узды. Акбүреләр болгарларга унҗиде ел калан түләделәр. Шуннан соң, узган өч елда, болгарларның үз өйләрендә үзара талашуларын күреп, алар белән алыш-бирешне бөтенләй өзәләр. Өч ел буе инде Акбүре үзенә бер йорт-ил сыман булып, болгарларны санламыйча яши иде.

Бер-берсеннән бик еракта булсалар да, акбүреләр, казаяклар элегрәк бер-берсе белән аралашып торалар иде. Болгарлар белән ара өзелгәч, алар белән дә өзелде. Өченче ел инде Күрән бинең бер генә Казаяк кешесен дә күргәне юк иде. Болгарларның борын төбендә генә борынгы ата-баба җирен биләп яткан бай, атаклы Ямгырчы би әнә үзе килгән.

Ник килгән ул монда? Нинди җилләр, нинди уй-теләкләр куалаган аны монда — киң Чулманның салкын агымына каршы!

**XII**

Казаяклар өчен Күрән би үз урдасында киез өйләр кордырды, казан асарга дип, бер көтү сарык бирде. Шул ук көнне ул олы кунакның үзен, кызы Тәңкәне, тагын берничә якын кешесен үзенә ашка чакырды. Авыр, озын юлдан соң кунаклар бераз тын алдылар, ашадылар-эчтеләр дә, җыйнаулашып мунча керергә киттеләр.

Икенче көнне Күрән бинең ак өендә зур сөйләшү булды.

Сөйләшүдә акбүреләр ягыннан Койтым бикә, Утташ кам белән Майчан аксакал, Күрән бинең өлкән угыллары Акбога белән Котан катнашты. Ямгырчы би үзе белән бары ике генә юлдашын алып килде.

Казаяклар, тезелеп, өйнең бер ягына утырдылар, акбүреләр — икенче ягына, алар каршысына утырдылар. Аякчы[1] зур чүлмәк белән ачы бал — сычук кертте. Күрән би, көмеш аякка[2] сычук агызып башта үзе эчте, аннары кунакларны сыйлады. Зур сөйләшү алдыннан ачы бал белән тамак чылатып алу изге эш санала иде, ачы бал телләрне яза, күңелләрне йомшарта иде.

Күрән би, киез җәелгән җир идән уртасындагы учакның утлы кузларын бер тирәгәрәк өеп куйды да, үзенең кунагына эндәшеп:

— Башлап карыйк, алайса, би,— диде.

— Ә? — диде Ямгырчы би, сискәнеп.

Ул, онытылып, каршыдагы яшь, сылу бикәгә карап утыра иде.

Акбүреләр тыелып кына көлешеп алдылар. Үзенең ипсезлегеннән Ямгырчы би үзе дә көлеп куйган булды. Кинәт аның теле тотлыккандай булды. «Гарәпләр бездән белеклерәк — хатын-кызның урыны ирләр белән бергә түгел, аның урыны — чыбылдык артында!» — дип уйлады ул үзалдына.

Сүзне ул бик ерактан башлады: ике ыруның борынгыда бер-берсенә кардәш булуларын, элекке иркен тормышны, Ак хан, Кара хан турындагы бабайлар сүзен — барысын да искә төшерде дә, әкрен-әкренләп бүгенге көнгә күчте. Акбүреләр аны тыныч кына тыңлап утырдылар.

— Син, Күрән би, базарганнарны көтәсең булыр? — диде ул кинәт болай гына, сүз арасында гына сөйләнгән сыман.— Көтмә. Быел алар килмәячәк.

Акбүреләрнең колаклары үрә торды.

— Ник килмәсләр икән? — диде Күрән би.

Олы кунак беравык көттерергә кирәк тапты. Аннары әкрен генә, үз-үзенә ышанып:

— Алмаш хан сезне... безне буып үтермәкче була,— диде.

Өй эчендә, сүнәр-сүнмәс янган учак янында, тагын да ныграк тынлык урнашты.

— Ничегрәк бумакчы була инде ул... аты коргыры... ни... Алмыш хан? — диде Майчан аксакал, бераздан исен җыеп. Ямгырчы би, күрәсең, кирәкле сүзен таба алмыйча, тынып утыргандай итте дә, тагын да ерактан урамакчы булып:

— Моңарчы сез ирektә яшәдегез...— диде.

— Без әле дә ирektә,— диде Котан углан, аның сүзен бүлеп.

Аның шулай кирәкмәгәндә өлкәннәр сүзенә кысыла торган бер тыйнаксызлыгы бар иде.

— Ирektәсен ирektә дә...— диде Ямгырчы би, Котан угланга каршы килеп.— Сату-алусыз, сартларсыз ирекнең кемгә кирәге бар?

Акбүреләр җиңелчә генә гөрләшеп алдылар.

— Сартларга да, Алмышка да безнең кендек бәйләнмәгән,— диде Күрән би, кисәк кенә авырта башлаган эчен тотып.— Кендек безнең үз җиребездә. Сартлар килмәсә, без үзебез барырбыз аларга!

— Коры җирдәнме? — диде Ямгырчы би, күрәләтә шикләнү белдереп.— Тау-ташлар, сазлык-баткаклар ашамы? Үз җирегездән чыгу белән сезне башкыртлар кырып ташлаячак.

— Ташламаячак! — диде Күрән би, үртәлеп.— Элек тә булган мондый эшләр. Безнең бабайлар коры җирдән барганнар көньякка. Күп көч белән. Ник безгә бармаска?! Ул тиреләрне су төбенә салмам ла мин!

Быел астан базарганнар килмәгәнгә аның эчтән януын, тик тыштан гына мыс бирмәскә тырышуын Ямгырчы би сизми калмады.

— Көньякка булмаса, төньякка барырга була! — диде тиктормас Котан углан, атасын яклап.— Йура[1], Уйсу[2] аша Урыска[3], Франкка[4].

Үтә белексез сүз сөйләгән кешегә караган кебек, барысы да аңа аптырап, исләре китеп карадылар.

— Өлкәннәр сөйләгәнне тыңлап кына утырсагыз яхшы булмасмы? — диде Койтым бикә үги углына, кырыс кына.

— Ышанам сүзеңә, Күрән би,— диде Ямгырчы би, өзелгән сүзен ялгап,— ата-баба йөргән юл булгач анысы... Шулай да ата-баба юлы белән генә йөреп булмый. Безгә инде өнендә яткан аю кебек, урман арасында качып-посып ятарга ярамый. Болгарлардан куркып инде туганлыкны да онытып бетердек: бер-беребезгә барышмыйбыз, килешмибез... Йортың-илең белән кырылып ятсаң да, сиңа булышка кул сузучы беркем юк.

Акбүреләр, башларын иеп, тыңлап утыруларында булдылар. Кая бора соң бу сүзне? Ни әйтмәкче була бу шулай да?

— Нәрсә булган Болгарга, Алмыш хан нишләмәкче була дисезме? — диде Ямгырчы би, тәмләп кенә яңадан сүзгә башлап.— Монда эш Алмышта гына түгел — Хазарда. Итил торада[1] эшләр елдан-ел чуала бара. Җөфүтләр бөек Хазар йортны җыкка терәделәр. Тәңренең каргышы төште изге Хазар каганына. Ел саен корылык. Көтүлекләрен ком баса. Карасы ачтан интегә, аксөякләр үзара талаша. Быел яз да биш меңләп кешесе Итил буйлап югары менделәр. Алмаш ханнан торыр җир сорадылар. Бер яктан Рум кыса, икенче яктан Хәрәзем кыса, угызлар, беҗәнәкләр тынгы бирми, Куябыда урыслар бычкы кайрыйлар. Инде килеп, монда Алмыш хан көчәеп бара. Эшләр болай барса, бөек Хазар йорт, көяләгән тире кебек, таркалып юкка чыгачак.

— Бирсен Тәңрем! — диде Котан углан, кулларын югары күтәреп.

— Ашыкма! — диде Ямгырчы би, коры гына.— Хазар йорт таркалганнан безгә ассу[2] юк.

— Нишләп булмасын? — диде тыйнаксыз углан.

— Шундый бөек йорт таркалса, ата — улны, ана кызны белмәс,— диде Ямгырчы би.— Үзара ызгыш-талаш башланачак, яу артыннан яу китәр. Әйе, безнең ишеләргә ассу юк. Алмыш ханга бар!

Ямгырчы би авыр сулап куйды. Күрән би аңа чүлмәктән ачы бал агызып бирде.

— Муенындагы муенчагы бушый башлаганга сикерә дә Алмыш хан,— диде Ямгырчы би, эчеп җибәргәч, нечкә, матур мыегын сыпырып.— Үзенең муенындагы муенчагын алып ташладымы, шундук ул аны безгә кидерәчәк: сезгә, миңа... Биләр, Суарга... булдыралса — Биарга...

— Син, Ямгырчы би, тыңлап-тыңлап торам да, кыек сөйлисең! — диде кинәт Койтым бикә, кунакның сүзен бүлеп.— Алмаш хан инде күптән сиңа муенчак кидергән. Акбүрегә әле кидерәсе бар!

Күрән би, күңеле булып, хатынына ягымлы күз карашы ташлап алды. Кунак, сүзеннән бүленеп, тотлыгып калды, аннары мыскыллы гына көлемсерәде дә, Койтым бикәгә карап:

— Син дә бик үк турысын сөйләмисең, бикә,— диде.— Сезнең муенга да муенчак күптән салынган. Муенчак кына да түгел — богау!

— Болгарлар муенчагын өзеп ташлаганга быел дүртенче ел китте, би! — диде аңа каршы Койтым бикә.

— Сартларны үз теләкләре белән килмәгәннәрдер дисезме? — диде Ямгырчы би, башлап та очланмаган сүзенә яңадан тотынып.— Юк, бикә, аларны монда Алмыш хан җибәрмәде. Алмыш! Юл бикле, Чулман ябык! Менә шул була инде ул муенчак, Койтым бикә!

— Сартлар сиңа да килмәдеме? — диде Күрән би.

— Миңа да,— диде Ямгырчы би.— Ага-базар миңа якын. Мин аларны көтеп ятмадым. Сезнең эшләр башкачарак. Чулман баш бирми, Чулман калан түләми. Шуңа ачу итеп, быел Алмыш хан барлык сатучыларны Итил буйлап югары җибәрде... үзенә буйсынган ыруларга.

— Ярар, шулай да булсын,— диде Майчан аксакал.— Монда ятып без берни белмибез. Читтән килгән сатучылар ни диләр соң? Сату-алу безгә генә түгел, аларга да кирәк ич! Быел сартлар безгә килмәс, җирингә — Болгарга килмәс. Базар эшләмәсә... ни... аты коргыры... кем... Алмыш ханга акча каян килер?

— Шула-ай! — диештеләр акбүреләр, аксакалны яклап.

— Күреп торам: син миңа яңалыклар алып килгәнсең,— диде Күрән би кунакка.— Шулай да турысын гына әйт, уең ни?

Ямгырчы би җентекләп акбүреләргә карап чыкты, тирән итеп тын алды да:

— Уем шул,— диде.— Алмыш хан көчәйгәнче, безгә берләшергә кирәк, Күрән би! Без — Ак хан токымнары! Бөтен Чулман бер булып безгә болгарларга каршы чыгарга кирәк. Бүре безне берәм-берәм тотып ашаганчы, тупланып безгә аның үзен ашарга кирәк! Менә шуңа килдем дә мин сезгә, туганнар, акбүреләр. Сез көчле, бай. Бөтен Чулман буенда сезнең кебек көчле ыру юк. Сез кузгалсагыз, башкалары да кузгалачак.

— Алай микән? — диде Күрән би, эчен уып.

— Алай! — диде Ямгырчы би.— Күтәр байрагыңны, күтәр кылычыңны, Күрән би! Бөтен Чулман синең кул астыңа җыелачак. Синең тамырларда, минем тамырларда изге бабайлар каны ага. Борынгы ханлык тамыры турыдан-туры безгә тоташа. Мин сине үземнән өстен итеп, өлкән итеп таныйм, Күрән би!

— Таныйбыз, таныйбыз! — диделәр Ямгырчы бинең юлдашлары.

— Болгарларның муенын сындырсак, Иске йортның... Чулман йортның ханы ясыйбыз сине, Күрән би! — диде Ямгырчы би.

— Ясыйбыз, ясыйбыз! — диделәр аның юлдашлары.

## XIII

Күзләре уттай янган акбүреләр, тынычсызланып, утырган урыннарында кыймылдашып алдылар. Берсе елмайды, икенчесе кашларын җыерды, өченчесе җилкәсен кашыды. Күрән би әлегә берни эндәшмәде. Ул яңадан чүлмәгенә тотынды, онытылып, ачы бал тулы аякны эчеп җибәрде, аннары кунакларны, ырудашларын сыйлады.

Төн урталарында кунаклар кайту ягына кузгала башладылар. Ишек артына, ярым караңгы бүлмәдә йокымсырап аларны кырнаклар көтеп утыра иде. Кол кызлар Ямгырчы бигә, аның юлдашларына киенергә булыштылар. Кызларны күрү белән, кызмача Ямгырчы би чын-чынлап исереп китте: як-якка чайкалган булды, бәйләнешсез сүзләр сөйләде.

— Бер теләгең үтәлер, Ямгырчы би,— диде Күрән би, көлемсерәп.— Кызларның берсен үз яныңа алырсың. Икенче теләгең үтәлерме, юкмы — анысын үзара уйлашкач әйтербез.

Күрән би кунакларга, үз кешеләренә тыныч йокы теләде дә, кунарга Койтым бикә белән аның аерым өенә китте.

Башкаларга тыныч йокы теләсә дә, ул үзе бик озак тынычлана алмый ятты.

Хан булырга! Чулман-Итил йортның башы булырга! Мондый уйның килеп караганы булды микән берәр тапкыр аның күңеленә? Әйе, яшь чагында ул да уйламады түгел. Ул да болгарларны Чулман, Итил буйларыннан себереп түгү, бабайлар сөйләгән ниндидер Ак хан йортын аякка бастыру турында татлы уйлар уйламады түгел. Ул алай уйланып кына да калмады, ныклап торып сугышка да җыена

башлап, күршеләренә итәк астыннан ут җибәрде. Тач Ямгырчы би кебек коткы таратып йөрде! Чулман биләре каршы килмәделәр, тик шулай да сикереп тә төшмәделәр. Аннан-моннан ике-өч мең кеше җыеп, ул каекларда Чулман тамагына төште. Анда алар, коры җиргә чыгып, ат менделәр, болгарларга каршы яу чаптылар. Ямгырчы бинең атасы Кылыч би ул чакта беркемгә катнашмыйча читтә калды. Әйе, орыштылар... җиңелделәр... Биш йөздән артык кеше җирдә ятып калды.

Шула-ай... Кайчандыр ул да тилереп йөрде. Болгарлар кирәген биреп кайтаргач, шуннан соң беркайчан да үзенең катавыннан ул якка борын тыгып карамады. Кая ул! Кайчагында тик урман арасындагы арларга яу чапты да, бер-ике тапкыр биарларны талап кайтты. Соңгы елларда анысы да онытылды. Ни әйтсәң дә, картаелды. Менә ничә ел инде ул күршеләре белән тату гына, тыныч кына яшәп ята.

Ник кычытынып йөри соң әле бу Ямгырчы би? Казаяк ыруының башы аны — Күрән бине — хан ясарга килгән. Нинди җиңел икән ул хан булуы! Юк, булмый ул алай! Тора салып беркемнең дә икенче берәүгә буйсынып яшисе килми. Әле ул Алмаш ханга буйсынып яши, инде аның никтер Күрән ханга буйсынасы килә. Юк, булмыйрак торсын әле! Ямгырчы бинең астына су йөгергән — менә нигә килгән ул монда! Аңа никтер булыш кирәк, Акбүренең көче, байлыгы кирәк. Туп-туры әйтергә аның кыюлыгы җитми. Күрәсең, болгарлар аның үзенә яныйлардыр, аның үзенең Алмыш хан белән алыш-биреш ясыйсы бардыр. Менә шунда инде үзенең ерак туганын исенә төшергән дә ул. Юк, юк, алдыннан арты яхшы. Үгезе үлгән, уртагыннан аерылган. Казаяклар өчен кан коярга монда... акбүреләрнең башына тай типмәгән. Кирәк икән, сугышсын үзе. Монда беркем үтеп керә алмаячак. Монда килеп җиткәнче әле Алмыш ханнарга иксез-чиксез киртәләрне җимерергә туры киләчәк. Алмыш хан Шилке түгел. Су юлы белән монда тикле җитәргә аның каеклары юк. Коры җирдән килергә ул беркайчан да батырчылык итмәячәк.

Икенче көнне иртән ыру башы иң якын агай-энене, аксакалларны үзенең ак өенә киңәшкә чакырды. Киңәштә бары ирләр генә катнашты — яу эше тулысынча алар кулында иде. Киңәш озакка сузылды. Беркайчан да зур сугыш-орыш күрмәгән яшьләр бүгеннән үк болгарларга каршы тупланырга, яу чабарга кирәк, диделәр. Өлкәннәр каршы килде. Майчан аксакал әйтте, үзеңә килеп ябышмыйча торып, болгарларга каршы кылыч күтәрү ул башсызлык булачак, диде; Чулман иле таркау, аны инде Ямгырчы би дә, Күрән би дә туплый алмаячак, диде; угызлар безгә булышка килмәячәк — Алмыш хан аларның кияве, башкыртлар ышанычсыз — беркөнне алар синең яклы, икенче көнне болгар яклы, диде; Суар, Биләр бездән ерак, Биарның үз кайгысы кайгы, диде.

Күрән би дә Майчан аксакалны яклады. Сугышка атлыгып торган яшьләр — шулар арасында Акбога белән Котан да инде бирелә башлаганнар иде, шул чакны Утташ камның тавышы ишетелде.

Утташ кам яшьләрне яклады. Ул әйтте, Ямгырчы би шултикле ерак җирдән тикмәгә генә килеп йөрмәс, диде; Күрән би баш булырга теләми икән, Ямгырчы бине хан дип танырга да, барысын аңа ышанып тапшырырга кирәк, диде; ул яшьрәк, көчлерәк, диде; болгарлар аны-моны сизенгәнче, тупланып, көч җыеп алсак, олуг Тәңре белән, изге ияләр белән без аларның үзләрен туздырырбыз, диде; менә шулай кулны кушырып утырсак, көннәрдән бер көнне Алмыш хан, атасы Шилке кебек, монда да килеп җитәр, безнең бугаздан алыр, диде; ата-баба йоласы аяк астына салып таптаган Алмыш ханга каршы изге яуга кузгалыгыз, акбүреләр! диде.

Башка чакта мондый эшләргә бик үк катышмый торган камның шулай кайнарланып яуга өндәве өлкәннәрне шактый аптырашта калдырды. Яшьләр исә башларын югарырак күтәрделәр. Ыру башының эче пошып куйды. Утташ камның бары тик үзенә — ыру башына каршы коткы тарату, яшьләр алдында аның абруен төшерү өчен генә шулай ут белән уйнавын Күрән би яхшы төшенде. Кара нинди явыз, кара нинди мәкерле!

Күрән бинең чырае бозылды.

— Уртак сүз табылмады,— диде ул үзенең ырудашларына.— Җыен җыярбыз.

Шул ук көнне Күрән би Акбүренең өлкәннәрен — аксакалларны, авыл башларын чакырып тартыклар[1] җибәрде. Җыенга шулай ук игенчеләр, балыкчылар, аучылар, юллардагы, чик буйларындагы, яр буйларындагы каравыл башлары да чакырылды. Икенче көн туды дигәндә, чакырылган кешеләрнең барысы да катауга җыелып бетте. Җыенны урданың тышкы ягында, калку үр өстенә корылган йөз кеше сыйдырышлы киез өй эчендә ясадылар. Җыен киңәшкә караганда да шау-шулырак булды. Яшьләр, Утташ кам яклылар яуга чакырдылар. Картраклар, куркаграклар, шулай ук белеклерәкләр бер дә юктан ут белән шаярмаска өндәделәр. Безне әлегә кысучы юк, безгә җир-су җитә. Чулманда — балыкның, урманда киекнең беткәне юк, тыныч кына яшәп ятыйк, диделәр.

Күпчелек картларны, куркагракларны, шулай ук белеклерәкләрне тыңлады. Акбүре ыруы болгарларга каршы яу чыгудан баш тартты.

«Җыясы азыгым, эчәсе суым бетмәгән икән әле! Инде тынычлап йокларга да була»,— дип уйлады Күрән би, җиңел сулап.

Казаяклар акбүреләрнең соңгы сүзен аяк өсте тыңлап тордылар. Җыенның нинди карарга килүен ишеткәч тә, кунакларның йөзләре бозылды. Арысландай алып Күрән би дә яудан баш тарткач, бүтәннәргә ни сан?! Бозылды дөнья. Ак хан токымының күкрәгендә ялкын сүнде, арыслан дигәннәре сычкан булып чыкты. Барысы да үзенчә генә яшәргә, качып-посып яшәргә тырыша. Ил турында, бөек ата-бабаларның даны турында кайгыртырдай беркем калмады.

Күңеле кырылган Ямгырчы би Күрән бигә шундыйрак үпкә сүзләрен әйтте. Шул ук көнне ул юлга чыкмакчы булды. Акбүре ыруының башы аны болай үпкәләгән килеш кайтарып җибәрергә теләмәде. Ул аны тагын бераз кунак булырга үгетләде.

Чынында Ямгырчы би болай гына үпкәләгән булып кыланды. Аның әле бер дә буш кул белән кайтып китәсе килмәде. Аның уйлары, Күрән би сизенгәнчә, бик тирәнгә яшеренгән иде. Күрән бине хан ясау турында ул, билгеле, башына да китереп карамады. Аның үзенең хан буласы килә иде. Тик шулай да бар тотка Акбүредә иде! Аларны кузгатып булса, башкаларны кузгату чыннан да җиңелрәк булачак иде.

Юк, ул әле әз генә дә чигенергә теләмәде.

Ямгырчы би Койтым бикәнең үзе генә өйдә чагын белешеп, сагалап торды да яхшырак киенеп, чәченә, сакал-мыегына исле майлар сөртенеп, ялгыз өйгә юнәлде.

Ул барып кергәндә бикә өйдә иде. Әлерәк кенә төшке аш ашаганга, ул, күрәсең, бераз тын алмакчы булып, алсу ефәк тышлы мендәрләр өелгән йомшак урын-җирдә кырын-ярын ятып тора иде. Ике ягындагы ике кыз, аның чәчендәге энҗеле каптырмаларын, тезмәләрен салып-чишеп торалар иде. Шунда ук өченче берсе аның аягындагы каюлы читекләрен тартып ята иде.

Кунак килеп кергәч, бикә чишенүеннән туктап калды, артка ташланган башын күтәргәндәй итте дә, күз карашы белән генә ымлап, кызларга чыгып китәргә кушты.

— Түрдән уз, би,— диде Койтым бикә, керүчегә йөзен борып.

Ямгырчы би, елмаеп, түргә узды, күрсәтелгән урынга — бикә каршына килеп утырды. Бикә аңа никтер борчулы, күңелсез күренде. Аннары ул бераз гына таркау да, бераз гына салкын да, ачулы да шикелле тоелды. Кунакның Койтым бикәне мондый йөз белән күргәне юк иде әле.

Җыенда Койтым бикә дә катнашты. Баштарак ул шаулашучыларның берсенә дә кушылмады. Башкалар түгел, аның ире дә бикәнең ни уйлаганын анык кына белә алмады. Баштарак бикә Күрән бигә, син ничек уйласаң, мин дә шулай уйлыйм, дигән иде. Бу көннәрдә башы каткан Күрән би артык төпченеп тормады, ул чыннан да бикәнең үз сүзеннән чыкмаячагын яхшы белде. Аксакаллар аңа сорауны терәп куйдылар, син ил яклымы, яу яклымы? диделәр. Менә шунда инде Койтым бикә үзенең күңелендәгесен әйтте дә бирде. Иренә каршы чыгасы килмәсә дә, явыз Утташ камны яклыйсы килмәсә дә, барлык ырудашлары алдында ул турысын әйтте:

— Мин Алмыш ханга каршы яу чыгарга өндим! — диде.

Нәрсә уйласа, ул шуны әйтте. Күрән бинең йөзе караңгыланып киткәнен бикә, билгеле, күрми калмады.

Менә шуның өчен дә — иренең күңелен кырган өчен, ахрысы, аның әле булса эче поша иде. Әллә тагын бүтән төрле кайгылары, борчулары бар иде микән соң аның?

## XV

Койтым бикәнең бала чагы Чулман буйларыннан еракта, Җаек далаларында үтте. Ул Җаекның урта агымында күченеп йөргән бәҗәнәкләрнең Карабай ыруында туды. Ул Карабай ыруының башы Кайду бикнең[1] икенче ишеннән[2] туган икенче бала иде. Кайду бикнең илле мең баш куе, дүрт мең баш җылкысы бар иде. Җаек буенда тоткарланып калган бәҗәнәк ырулары арасында ул иң бае, иң көчлесе иде. Шуның өстәвенә Кайду бик алып ир иде. Ук атышта, сөңге ыргытышта, кылыч белән чабуда беркем аннан уздыралмый иде. Бөтен тирә-як — бәҗәнәкләр генә түгел, угызлар, башкыртлар да — аннан куркып, котлары алынып торалар иде.

Кайду бикнең балалары аталарына охшап үстеләр. Алар бар яктан да уңган булдылар, көчле, усал булдылар. Койтым бикә дә үзенең ир туганнарыннан калышмады. Алар кебек җилдәй җилеп атта да чапты, ук та атышты, сөңге дә ыргытты. Чаялыгы, батырлыгы өчен аңа яшьтән үк Алыпша дигән кушамат тактылар.

Үзенең туган даласында, туган ыруында — яшьтәшләре, туганнары арасында, терлек-туар арасында ул шулай уйнап, күңел ачып, кайгы-сагыш күрмәенчә, унбиш яшькә тикле яши алды. Унбишне тутырып, уналты белән барганда, көннәрдән бер көнне, җәйге чилләнең уртасында Җаек буе бәҗәнәкләренә олы талау килде. Төн ягыннан көтмәгәндә кара болыт булып кара яу килеп басты. Кояш сүнде, җир сыкранды, киң даланы ялкын чорнап алды. Ягы[1] көчле иде, санаусыз күп иде. Бәҗәнәкләр соңгы тамчы каннарына тикле сугыштылар. Кайду алып, арысланадй ярсып, кылычы белән уңга-сулга чапты — берсен урталай кисте, икенчесенең башын кыеп төшерде, өченчесен кулсыз калдырды. Аның янында таудай булып туралган ягылар өелде.

Бежәнәкләр каты сугыштылар, бежәнәкләр тын да алмый орыштылар. Тик шулай да ягы көчле иде, санаусыз күп иде. Кайду алып янындагы ирләр әкренләп-әкренләп кими барды.

Ирләр кебек тимер күбә киеп, кылыч тотып, Койтым-Алыпша да атасы янында торып сугышты. Ук яңгыры яудырып, карабайларны ягы кысрыклый башлагач та, ул атасы яныннан, алып туганнары яныннан бер адым да чигенмәде — ярсып кара яуга уклар атты.

Барысын да ул үз күзләре белән күрде, барысын да үзе тойды. Көтмәгәндә Кайду биккә агулы ук тиде. Ыру башы ияреннән җиргә ауды. Шул чагында кинәт кояш сүнде, шул чагында кинәт җирнең асты өскә килде! Бежәнәкләр каушап калды, бежәнәкләр кача башлады. Шул чагында кинәт кояш сүнде...

Алар җиңелделәр. Ыру юкка чыкты. Сарыкларны, җылкыларны, сыерларны ягы куып үз иленә алып китте. Исән калган кешеләрне, сарык, сыер кебек көтү-көтү төн ягына кауладылар.

Карабайны килеп баскан явыз ягы... кара ягы болгар ханы Шилке иде.

Үз кулына төшкән сарыкларны, сыерларны, җылкыларны Шилке болгарларга бүлеп бирде. Кулга төшкән кешеләрне, коллар итеп, сатып җибәрде. Койтым-Алыпшаның дүрт абыйсы, биш энесе, богауланган килеш, чит җирләргә озатылды. Яшь, чибәр кызларны, хатыннарны Шилке үзендә калдырды. Шулар арасында өч сеңелесе, өч апасы белән, ике үги анасы белән бергә Койтым-Алыпша да бар иде. Кызалактай[1] сылу, күз яшедәй керсез Койтым да бар иде.

Гүзәллеге, тазалыгы аның күзгә бәрелеп тора иде. Аның ялкынланып торган күз карашы, яшь, сылу йөзе, тубыгына җиткән кара толымнары, тулы, төгәл буй-сыны бер карауда ирләр токымының аңын җуяр иде. Илле ике яшьлек Шилке аны күреп алды... Күрде, телсез-өнсез калды. Ул аны башкалардан аерырга кушты. Ул аның үзен генә аерым өйгә ябарга кушты.

Илен-көнен таркатучы, атасының, анасының канын агызучы... туганнарын кол ясаучы җирәнгеч карт, исерек карт шул ук төнне аңа кияү булып керде. Ут-ялкыннан исән калган алсу чәчәк, гүзәл чәчәк-кызалакны кансыз Шилке таптап китте.

Берничә көн үткәч, качып-посып төнлә аның янына икенче ир килә башлады. Монысы яшь иде, чибәр иде. Монысы Шилке ханның өлкән углы Алмыш углан иде.

Көн дә шулай кабатланды: караңгы төшү белән аны ярым үлек килеш Шилке ханның өенә алып киттеләр дә төн уртасында үз өенә китереп куйдылар. Ул аңына килергә дә өлгермәде, өрәк булып, явыз ия булып, мыштым гына Алмыш углан килеп керде. Шулай итеп, бер-ике ай ата белән угыл качыш-качыш уйнадылар.

Ата кеше шулай да сизенә башлады, төпченә башлады. Сулган алсу чәчәк берни эндәшмәде, бары озын керфек очларыннан иртәнге чык сыман эре, кайнар күз яшьләрен генә түкте. Көндәгечә төнге өрәк үз янына килгәч, шулай да ул аңа картның сизенүен әйтте. Йа Тәңрем, ул, ахрысы, аны ярата иде!

Шуннан соң икенче төнне качып-посып аның янына икенче бер яшь ир керде — Алмыш угланның яшь энесе керде. Керүен керде... чибәрлеге белән болгарларны таң калдырган яшь кырнакның кайнар кочагын татырга шулай да аңа язмаган булып чыкты. Көтмәгәндә ишек ачылып китте, ярсып, котырынып Шилке-ата килеп керде. Бер кулына чыртлап янган чырак тотып, бер кулына уттай ялтыраган кылыч тотып, көнчел ата килеп керде. Күзенә ак-кара күренмәгән ата кеше бер селтәүдә углын кыеп төшерде, икенче селтәүдә яшь кырнакны чабып ташламакчы булды, тик... Койтым кырнактан инде җилләр искән иде.

Аны бары таң алдыннан гына таптылар. Ул урда коймасы буенда, чүп-чар арасында, песи баласыдай бөгәрләнеп ята иде. Аны хан каршына китерделәр. Шилке инде тынычланган иде. Ул аннан берни сораштырып тормады, аның күз яше белән чыланган яшь, сылу йөзенә бер генә карап алды да, теш арасыннан сыгып:

— Сатарга,— диде.

Ага-базарда аны Биарга юл тотучы җөфүт сатып алды. Биарга Кызыл Яр аша узганда, Күрән би аны кулбау[1] итеп үзенә алып калды. Би баштарак аны кырнак итеп тотты, Тотыш углан тугач, үзенең хатыны итте. Күрән би аны яңадан тергезде. Изгелеген аның беркайчан да онытмас ул!

Ямгырчы би килеп бөтен эшне бозды... иске яраларны кузгатты да, күкрәктәге кара кандай каткан үч, ачу тойгыларын актарып чыгарды. Ничек аңлатырга шуны Күрән бигә?!

**XVI**

— Тәңре сиңа күп яшь бирсен, саулык-байлык бирсен, бикә! — диде Ямгырчы би, бикәнең чибәрлегенә соклануын яшермичә, аның йөзенә туры карап.— Изге ияләр йортыгыз-илегезне, ыруыгызны, терлек-туарларыгызны уттан-күздән, яудан-кыраннан сакласын. Төн карасыдай ул чәчләрегезне, тулган айдай сылу йөзләрегезне, дүрт саны да төгәл, күркәм буегызны Тәңрем яман күзләрдән сакласын!

Бикә Ямгырчы бинең теләкләрен, мактауларын исе китмичә генә тыңлады. Аннары, чак-чак кына тешен агартып:

— Акбүре ыруында яман күзләр юк, булса, шул чит ырудан гына булыр,— дип куйды.

— Чит ыру кешеләре сезгә бары яхшылык кына телиләр, бикә! — диде Ямгырчы би, елмаеп. Аның тынычсыз икәнлеге сизелеп тора иде.

— Үз ыруымда да миңа шуны ук телиләр, би,— диде Койтым бикә.— Аяк өсте тору синә килешми, би. Утыр.

— Сезнекедәй күркәмлек каршында... күктән төшкән якты йолдыз каршында миңа тезләнеп торсам да килешә, бикә! — диде Ямгырчы би.

— Синең миңа йомышың бар бугай, би? — диде бикә, туры сүзгә күчеп.

— Бар, бикә, бар! — диде Ямгырчы би, яңадан артсыз урындыкка утырып.— Төп йомышым үтәлмәде. Бик күңелем кырылды, бикә. Акбүрене мин Казаякның өлкән агасы дип беләм. Үзеңнең туган агаң белән уртак сүзгә килә алмау бик күңелсез булды, бикә. Авыр чакта үз туганың да булышмагач, кем булышыр безгә?

— Нинди авырлык килде соң әле сиңа, би? — диде бикә.

— Килде дип... килеп җитмәгән дә соң әле,— диде би, тотлыккандай итеп.— Алмыш хан кузгалса, иң элек кемгә ташланыр дисең — миңа!

— Шулай шул,— дип куйды бикә, килешеп.— Икенче йомышың ни?

— Икенче йомыш? — диде би.— Икенче йомыш... Мин бернәрсә уйлаганыем, бикә. Килгәч килгәч, коры кул белән кайтып китәсем килми. Туганлашып булмас микән безгә, дим, бикә.

— Без болай да туганнар түгелмени?

— Җырак туганнар икән шул, бикә. Ныграк якынаергае безгә.

— Ничек итеп?

— Минем кызым Тәңкә ошадымы сезгә? — диде Ямгырчы би, сакал-мыегын сыйпаштырып.

Аның бу кыланышы бикәгә никтер: «Мин ошыйммы сиңа?» — дигән сымаграк тоелды.

— Ошады...— диде Койтым бикә, көттереп.— Шулай да син исеңнән чыгарасың, би: сез дә, без дә буртаслар түгел, ата-баба йоласы буенча бездә җегетне кызлар сайламый, кызны җегетләр сайлый.

— Гарәп йоласын тотсам да, мин ата-баба йоласына каршы түгел,— диде Ямгырчы би.— Ата-ананың килешүе язык түгел лә, бикә! Гарәп йоласы буенча...

— Мин ата-баба йоласын[1] артыграк күрәм,— диде Койтым бикә, бине бүлдереп.

— Тәңкә минем бердәнбер кызым,— диде Ямгырчы би.— Ул иректә үсте. Анасыннан иртә ятим калганга, мин аны бернидән тыймадым, кысмадым. Ул да ата-баба йоласын артыграк күрә. Инде менә үзенә кияү сорый. Чын. Үзара гына әйткәндә, шуның өчен алып килдем дә мин аны. Алмыш ханның күзе төшкәнче дип... Сезнең белән килешеп булса...

— Син кемне күз алдында тотасың, би? — диде Койтым бикә, кызыксына төшеп.

— Синнән туган Тотыш угланны күз алдында тотам мин, бикә! — диде Казаяк ыруының башы.

Койтым бикә, телен тешләгәндәй, сүзсез калды.

Әле кайчан гына Койтым кырнак аны — Тотышны карынында йөрткән иде! Нинди авыр булды аңа ул баланы табу! Уналты-унҗиде яшьлек кырнак ул чагында нәрсә генә белә иде соң йөкле булу, тулгак тоту, бала табу турында? Аңа әйткәннәр иде, яшь чагында бала табу җиңелрәк була ул, дигәннәр иде. Белеп әйттеләр микән, белми әйттеләр микән ул сүзне, тик шулай да аңа җиңел булмады ул бала табу. Аныкы үлем белән бер булды. Кендек әби белән Язай имче баланы ярып алдылар, юкса ул аны табалмаган булыр иде. Шулай итеп, аның углы дөньяга Тәңре яраткан капугтан түгел, кеше кулы белән уелган капугтан чыкты. Шуңа да ул бүре булып түгел, арыслан булып үсте![1]

Әйе, арыслан булып үсте... беркем сүзен тыңламыйча, беркемгә баш бирмәенчә... йолаларны, түрәләрне санламыйча... кыргый булып, усал булып үсте. Тугач аның зурлыгына, көрлегенә таң калдылар. Үсә төшкәч аның көченә, кыюлыгына... башсызлыгына шаккаттылар. Шушы көнгә тикле ул күпме баланың кулын-аягын имгәтте, күпме ырудашын кан-яшь түктерде! Ыру башының углы булмаган булса, күптән инде аның итен карга, козгын чукыган булыр иде. Ник? Ник шулай ул? Нигә шундый кире, үҗәт, башсыз? Анда, күрәсең, ике төрле кан шулай талашадыр. Әллә Тәңре аны болгарлардан ата-баба каны өчен үч алырга шулай көчле итеп, кыю итеп яратканмы? Әллә... Утташ кам әйткәнчә, туган чакта аның йөзенә явыз Октуган үзенең сасы тынын өргәнме? Тфү! Тфү! Үз каргышы үзенә!

Ни генә булмасын, менә шул Тотышны өйләндерер чак та җиткән! Бу турыда инде быел кыш та сүз булып алган иде. Алар аңа кызын да сайлап куйганнар иде. Күрән бинең Биар ханы белән туганлашасы килә. Биар ханының җитен чәчәгедәй зәңгәр күзле, җитен сүседәй аксыл чәчле сылу Ай-ярукны сорамакчы иде алар. Биар ханына әле кода җибәрелмәгән, тик шулай да төн яктагы бай күршеләр Күрән бинең теләген беләләр булырга тиеш.

— Мин каршы түгел,— диде бикә, беравык тынып утырганнан соң, уйчан гына.— Шулай да өздереп кенә мин берни дә әйтә алмыйм. Анасыннан башка аның әле атасы да бар. Болгарларга каршы яу чыгаргамы, юкмы дигән кебек, бу да бик катлаулы эш.

— Шуның өчен җыен җыеп тормабыз ич? — диде би, көлемсерәп.

— Җыймыйча да булмас,— диде бикә дә, елмаеп, йомшарып.

— Кайгырма, ул җыенда миннән башка бары Күрән би генә булыр. Үзем мин ничек тә синең теләгеңне аяк астына салмаска тырышырмын. Монысында инде минемчә булыр!

— Тәңре сезгә чуктин-чук яшь бирсен, байлык, саулык бирсен, гүзәл бикә! Мин иртәгә тагын белешермен,— диде елгыр би, бикә алдында бишкә бөгелеп.

**XVII**

Өлкәннәр Тотышны шулай башсыз дип, явыз дип уйласалар да, үзен ул бер дә алай дип белми иде. Ул яшь иде, көчле, кыю иде. Аның бертуктаусыз каядыр йөгерәсе, чабасы килә; нидер эшлисе, кырасы-ватасы килә иде. Аның йөрәге беркайчан да тынгы белми шикелле иде. Шуңа күрә дә ул, үзенең көчен, ярсу тойгыларын кая куярга белмичә, интегеп бетә иде. Шуңа күрә дә ул, ачуы килеп, йә үзенең яшьтәшләрен тукмап ташлый, йә булмаса, ат атланып чаба, уктан ата, сөңге чөя иде. Инде ул да булмаса, Чулман ярындагы текә кыяларга, биек агач башларына менеп, кош ояларын туздыра, төрле куркыныч уеннар эзләп таба иде.

Яшь угланны гел котыртып торган тыелгысыз көчтән башка тагын икенче бер нәрсә дә бар иде.

Ата-баба йоласы буенча өйләнгәндә кызның байлыгына, ярлылыгына карамыйлар иде. Чибәрлек, тазалык кызның иң зур байлыгы санала иде. Күрән би үзенең кырнагын хатын иткәч, беркемнең дә моңа исе китмәде. Киресенчә, яшь бикәнең күркәмлеге, матурлыгы бик күпләрнең күңеленә юш килде. Аны өйдә чын күңелдән ярата башладылар, олылый башладылар.

Арада көнчелләр дә табылды. Өлкән хатын Әди Койтым бикәне аеруча яратмады. Баштарак ул кече хатынны күз кырыена да чыгармады: аңа төрле яман сүзләр белән эндәште, әледән-әле кырнаклыгы белән йөзен ертты, аннары ничек тә аннан авыр, пычрак эшләрне генә эшләтергә тырышты. Шук, таза Тотышка исә бигрәк тә нык эләкте. Кеше күрмәгәндә ул аны сугып та җибәрде, тибеп тә җибәрде. Өлкәннәр арасында, баланың яшьтәшләре арасында ул аңа карата күрәләтә саксызлык, салкынлык күрсәтте.

Куркытылган, исен җыеп өлгермәгән яшь бикә үзен дә, баласын да чын-чынлап яклый алмады. Яңа җирдә, яңа ыруда, яңа өйдә ул Әдидән генә түгел, аның башка кардәшләреннән дә, шулай ук үз иреннән дә өркеп яшәде. Тумыштан булган кыюлык, иркенлек тойгысы аңа бик әкрен кире кайтты, шактый соңлап кайтты.

Куркып-өркеп, кыерсытылып яшәгән ананың углы да баштарак куркып-өркеп үсте. Аннан да бигрәк, ул үзенең «кырнак баласы», «кимчелекле бала» икәнлеген аңлап үсте. Аның моңа ачуы килде, күңеле кырылды. Аның үч аласы килде, үги анасы Әдидән, әледән-әле үзен кыерсыткан туганнарыннан, яшьтәшләреннән бик каты итеп үч аласы килде. Күкрәгендә, беләгендә көч барлыгын тоя башлагач, ул, бер дә юктан кабынып китәргә генә торган ярсуына, кимсенү тойгысына ирек биреп, үзен кыерсытучыларны еш кына тәпәләп тә ташлады. Кыйналган яшьтәшләренең шулай ук ачулары килде. Алар, аның юкка-барга үртәлүен күреп, тагын да ныграк үчекләделәр. Соңга таба, Тотыш углан үсә төшкәч, аның туганнарының телендә «юлбасар», «башкисәр» кебек сүзләр ешрак кабатлана башлады. Андый сүзләрне өлкәннәр дә бик теләп кабатладылар.

Шулай үсә-үсә бала күңеленә кара кан укмашты. Әле ул төшенкелеккә бирелде, әле аранын җимереп качкан яшь айгырдай тилереп йөрде. Үз яшьтәшләре арасында аның якын беркеме дә булмады. Унбишләп туганы янында ул үзен ялгыз сизде. Аны бары үз анасы гына яратты. Турыдан-туры читкә какмаса да, Күрән би дә, күрәсең, башкаларның йогынтысына бирелеп, үзенең «юлбасар» углына карата шактый кырыс булды.

Өлкән хатын Әди кинәт чирләп киткәч, Әдинең кулыннан эш китә башлагач, Койтым бикә башын күтәрде. Бинең үзен башкаларга караганда ныграк яратканлыгын ул инде күптән белеп, тоеп килә иде. Бу аңа икеләтә көч бирде. Ул инде үзен дә, углын да юкка-барга кыерсыттырмый башлады. Киресенчә, элеккеләрнең үчен кайтарырга теләп, көндәшләрен әкренләп-әкренләп үз кулына ала барды. Әди үлмәс борын ук инде ул өй эчендә баш булып өлгергән иде.

Әйе, искәрмәстән Койтым бикә бөтенесен үз кулына алды. Тик Тотышны гына ул тулысынча буйсындыра алмады. Үсмер Тотыш, җегет Тотыш, беркемгә дә баш имичә, койрык тоттырмыйча, үз көенчә яши бирде. Элеккеге ачы тойгыларга, үпкә-әрнүләргә яшьлек тилелеге, яшьлек кайнарлыгы өстәлде. Яшьтәшләр дә, өлкәннәр дә әле булса аңа чит кеше, ят кеше итебрәк карауларында булдылар. Әле булса ул моны сизеп-тоеп яшәде, әле булса үзен никтер, ни өчендер кыерсытылган итеп белде.

Атасы аңа быел беренче тапкыр ышанып эш йөкләде: кыш көне ул, этләр җигеп, кораллы йөз ир белән, илле йөк мал белән төн кешеләренә сату-алуга барды. Атасы аны юри җибәрде, сынап карау өчен... Аннары ул аның көченә, кыюлыгына да ышанды. Шулай ук аның бу углында баш та юк түгел иде.

Кыш көнендә бер дә кояш чыкмый торган дөм караңгы төн иленнән, боз иленнән Тотыш углан биш ай дигәндә кире кайтып төште. Чаналарга таудай тире төяп, бер тиенен, бер кешесен, бер этен дә

югалтмыйча, баеп, кырысланып, олыгаеп кайтып төште. Моңа тикле «шар тибүдән» башканы белмәгән «башкисәр», «юлбасар» угланның исән-аман кайтып керүен күреп, бөтен катауның исе китте. Ата белән ананың исә куанычы эченә сыймады. «Булдырдың, углым! — диде аңа атасы.— Синең кебек чакта атай мине дә шулай мал белән җибәргәние. Каты буранга юлыгып, этләрне, йөкләрне югалтып, кешеләрне туздырып, ярты юлдан кире кайттым. Болай булгач, атаңны уздырдың, углым».

Атасыннан мондый мактау сүзләре ишетеп, Тотыш угланның күзләренә яшьләр килде. Туганнан бирле бу аның атасыннан гына түгел, анасыннан кала барлык өлкәннәрдән ишеткән беренче мактау сүзе булгандыр. Ата белән угыл арасындагы салкынлык, кырыслык шул көннән соң әйтерсең мәңге юкка чыкты. Шул көннән соң Тотыш углан атасына Тәңрегә табынган кебек табына башлады.

Ул әйтерсең кинәт үсеп китте. Күңеле белән, уй-теләкләре белән үсеп китте. Ул үзен өлкәннәргә тиң итеп, алар эшли алган барлык эшләрне эшләрдәй чын ир итеп тоя башлады. Атасы белән анасының киләсе көзгә Биар ханының кызына өйләндерергә җыенуларын белгәч, аның чын-чынлап түбәсе күккә тиде. Тиздән, тиздән ул өйле, хатынлы ир кеше булачак! Тиздән, тиздән ул да кеше арасына кереп, үзенең сүзен әйтә алачак — аның белән санлаша башлаячаклар! Барлык ирләр кебек, ул да киңәшләрдә, җыенда катнаша алачак, кулына корал тотып, сакта-каравылда торачак. Кем итәр икән аны атасы — каравыл башымы, агычымы[1], амбарчымы, битекчеме?[2] Субашы булырга ул әле яшь. Түрә[3] буенча яшьләрне андый зур эшкә куймыйлар. Моның өчен яуда катнашырга, үз-үзеңне батыр итеп, башлы, белекле итеп күрсәтергә кирәк. Әлегә кечкенә алай[4] башы булып торсаң да ярый. Әллә соң сатучы итәр микән аны атасы? Анысы да яхшы булачак. Товар белән тагын төн кешеләренәме, Хазаргамы җибәрер. Җибәрсен! Чит илләрдә, чит телләр, чит кешеләр арасында күңелле. Анда бик кызык. Ят нәрсәләр күрәсең, ят азыклар ашыйсың.

Әллә көчле чирү[1] туплап, болгарларга каршы яу җибәрер микән соң аны атасы? Ике сүзнең берендә тиккә генә болгарларны, Алмыш ханны яман итеп телгә алмыйлардыр ич! Атасы ирек бирсә, болгарларның тетмәсен тетәр иде ул, урдаларын, авылларын көлгә әйләндерер, барлык ирләрен Итилгә тутырыр иде. Ул бары тик чибәр кызларны гына кызганыр иде. Аларны ул, коллар итеп, Кызыл Ярга алып кайтыр иде.

Яшь җегет еш кына шулай уйланды. Кулга төшерелгән чибәр кызларны, хатыннарны, алтын-көмешне каекларга төяп, күңеленнән катауга кайтып кергәч, аның күз аллары томаланды. Уйлары буталды. Шуннан соң нишләячәген ул ачык кына күз алдына китерә дә алмады. Барлык теләкләр, татлы уйлар иң ахырда бары бер нәрсәгә — ир буласы, зур кеше буласы килүгә кайтып калды. Шул бер теләгенә ирешә исә, никтер бөтен нәрсә үзгәрер, бөтен нәрсә бары ул теләгәнчә генә булыр шикелле тоелды.

Көтмәгәндә Ямгырчы бинең килеп төшүе, акбүреләрне болгарларга каршы яуга өндәве Тотыш угланны канатландырып җибәрде. Ул инде үзен чын-чынлап яуда итеп күрә башлады. Ыру аксакалларының киңәше тәкәнгәнне ул киеренке бер түземсезлек белән көтте. Аларның яу яклы булачагына ул әз генә дә шикләнмәде. Тик аксакаллар киңәше ул көткәнчә төкәнмәде. Шуннан соң ул бар ышанычын җыенга баглады. Инде җыен да баш тартса, ул чагында... ул чагында... Юк, булмас! Акбүреләр болгарлардан үч алырга тиешләр, акбүреләр борынгы атакларын кайтарырга тиешләр! Җыен каршы килсә, ул берүзе китәчәк, Ямгырчы би белән! Бөтен ыруга каршы ул берүзе сугышачак!

Түрә буенча, йола буенча, ыруга кагылышлы эшләрне тикшергәндә балалар катнаша алмыйлар иде. Тотыш моны бик яхшы белә иде. Шулай да ул, кайгылы башын иеп, атасы янына керде, аның үзен җыенда катнаштыруын үтенде.

Бу көннәрдә бинең чырае аеруча караңгы иде. Ул әле изге нарат янындагы күренешне дә онытмаган иде. Ук-җәя барлап, кылыч кайрап йөргән белексез углын ул пыр туздырып чыгарды.

— Мин синнән дә, туганнарыңнан да, аналарыңнан да, ырудагы барлык кешеләрдән дә олырак,— диде ул углына.— Мин бары ырудан, түрәдән, ата-баба йоласыннан гына олырак түгел. Син ырудан да, түрәдән дә, йоладан да... атаңнан да олырак булмакчы буласыңмы?

— Мин синнән олы булырга тырышмыйм, атам! — диде Тотыш углан, тезләнеп.

— Бар, күземә күренмә! — диде Күрән би.— Бер генә каршы сүз әйтсәң дә... Игелексез!

**XVIII**

Тотыш угланның җыены шуның белән төкәнде. Атасының тупаслыгы яшь җегетнең кытыгына килеп тиде. Йомыла башлаган күңел ярасы яңадан ачылды. Яңадан ул үзен читкә тибәрелгән, кимсетелгән итеп тойды. Аның тагын бар нәрсәгә ачуы килде, аның тагын кемнәрдәндер үч аласы килде. Йолдыз-кашканың йолыкка биреләсен белгән көнне дә аның бу тикле күңеле кырылмаган иде бугай.

Атасы яныннан ул туры атлар абзарына ашыкты. Күзенә күренгән беренче атка атланды да, кояшта кызынып утырган карт-корыга, судан кайтучы хатын-кызга пычрак су, ләпек чәчрәтеп, чыбыркысы белән атын яра-яра, Басу-капка ягына чапты.

Капка сакчылары ерактан ук аны күреп алдылар, туктатмакчы булып, аның юлына аркылы төштеләр. Капка ачык, күперләр төшерелгән иде, шулай да тикшерми-сорамый беркемне дә кертмиләр дә, чыгармыйлар да иде.

— Кит юлдан! — дип кычкырды Тотыш углан сакчыларга.

Атның йөгәненә тотынырга чамалаган Талутка ул, бар көченә кизәнеп, чыбыркы белән салды. Талут чинап җибәрде, тезгенгә сузылган кулын тиз генә тартып алды да чыбыркы очы тигән күзен учы белән каплады. Тавышка йөгереп башка сакчылар килеп җитте. Би углының холкын белгәнгә, алар аңа ныклап торып каршы килергә батырчылык итмәделәр.

— Китегез, кит! Берегезне калдырмый турап бетерәм! — дип кычкырды ярсыган яшь җегет, кылычын кынидан суырып.

Сакчылар шундук як-якка сибелделәр, сүгенү, мыгырдану тавышлары ишетелде. Тотыш углан, җилдәй очып, капкадан, күпердән чыкты да, басу ягына элдерде. Аның артыннан тик күпер яркакларының дөпелдәгән тавышлары гына гүләп калды да, ат тоягыннан каты балчыклар гына чәчрәде.

— Йа Тәңрем! Эт урынына да күрмиләр без караларны! — диде Талут, ачынып.

— Азынды! Түрәне санламый, атасын тыңламый,— диде сакчыларның берсе, сукранып.

— Би углына ничек телең бара? — диде икенчесе.

— Бара шул! — диде беренче сакчы.— Мин әле аны җыенда әйтәм... бөтен ыру алдында. Теңкәне корытты инде, эттән туган! Китсен әнә Тәңре катына! Муенына элмәк салып, асып куйсыннар агач башына.

— Юк, әйтмәссең,— диде икенче сакчы, тыныч кына.— Әйтсәң, үзең дә Тәңре катына юлларсың. Синең дә языкларың җитәрлек.

Кичкә таба, караңгы төшә башлаганда, арып-алҗып, Җирәнкәйне эштән чыгарып, Тотыш углан катауга әйләнеп кайтты.

— Атайга әйтмәдегезме? — диде ул, көчсез, кызганыч бер өн белән.

— Юк, Тотыш, әйтмәдек,— диделәр сакчылар.— Юкка кыздың баягынак. Талут күзсез калды.

— Кичерсен мине,— диде Тотыш, үкенү белдереп.

Куеныннан берничә акча алып, ул сакчыларга ыргытты.

— Талутка әйтегез: анай янына барсын — теләгәнен алыр.

— Әйтербез, Тотыш, әйтербез,— диештеләр сакчылар.

— Җыен беттеме? — диде Тотыш.

— Беткән. Яу булмаячак,— диделәр сакчылар, куанып.

Яшь җегетнең болай да бозылган йөзе тагын да ныграк бозылды. Сакчыларга ул бүтән эндәшмәде.

Ул өйгә кайтып кергәндә, аның энеләре, сеңелләре пыр тузып, шаулашып «күз бәйләш» уйнап яталар иде. Учакта төтәп кисәү башы яна,— шуңа күрәдер, ахрысы, өй эченә бераз гына әчкелтем ис чыккан иде. Балаларны караучы карчык өйдә юк иде. Күрәсең, ул чыгып киткән, йә булмаса күрше бүлмәдә йокы симертә иде.

Балалар, уеннарын онытып, Тотышны сарып алдылар.

— Тотыш кайтты, Тотыш!

— Ашка өлгермәдең!

— Кайда йөрдең? — диештеләр аның туганнары, төрлесе төрле яктан кычкырып, шаулашып.

Шушы ыбыр-чыбыр арасына кайтып керү белән, кайчан гына булмасын, Тотыш үзенең балалыгыннан оялу, тартыну кебек бернәрсә тоя иде. «Балалар өе» дип йөртелгән бу өйдә иң зурысы ул иде. Аның белән бергә тукмашып үскән туганнары инде барысы да аерым яшиләр — өйләнгәннәр, йә булмаса кияүгә чыкканнар иде.

Үзенең аягына-кулына уралган, өстенә менгән, башына атланган, чыр-чу килгән энеләренә, сеңелләренә бүген аның аеруча ачуы килде. Ул аларның кайсын кая төртеп, этеп җибәрде дә, билендәге кылычын салып, бала-чага буе җитмәслек биек чөйгә элеп куйды. Төн кешеләренә җибәрер алдыннан кылычны аңа атасы бүләк итеп биргән иде.

Балалар, кайсы шүрләп, кайсы үпкәләп, кинәт кенә тынып калдылар; күзләрен уттай елтыратып, борыннарын тарткалап, зур, усал абыйларының чишенгәнен күзәтеп тора башладылар.

— Абый, без бүген кыздырылган балык белән ботка ашадык, бал эчтек! — диде берсе, абыйсының күңелен тапмакчы булып.

— Абый, инәкәй сиңа да алып кайтты. Учак янында, чүлмәктә,— диде икенчесе.

— Кая, китерегез монда,— диде абый кеше.

Балалар, бер-берсен уздырырга тырышып, шундук учак янына ташландылар, кулларын пешереп, бер чүлмәкне биш-алтысы берьюлы тотып, абыйлары алдына китереп тә утырттылар. Күп тә үтмәде, балаларның күңеле яңадан күтәрелеп китте. Кырыс абыйларын онытып, алар тагын уйнарга керешеп киттеләр. Тотыш, киез өстенә, тәбәнәк табын янына утырып, үзенә дип куелган азыкларны ашады.

Ашагач-эчкәч ул тынычланып калды. Учак янында беравык тынып утырды да кызыксынып, кечкенә туганнарының уенына карап тора башлады. Шул чакны ул балалар арасында, ярым караңгыда ниндидер ят кыз күреп алды. Баягынак ишектән килеп кергәч тә аңа өй эчендә нишләптер кеше күбәеп киткән шикеллерәк тоелган иде, аннары таныш чыр-чу арасында ят тавыш та ишетелгәндәй булган иде. Теге Ямгырчы би кызы ич бу. Менә кем кергән икән аларга! Моңарчы ул аны читтән генә күреп калган иде. Озынча ак битле, кара кашлы бу чандыр кызның күз карашы, учак җылысы кебек, җылы да, ягымлы да иде.

— Абый, бу — Тәңкә! Кунак кызы! — диештеләр энеләр-сеңелләр, абыйларының ят кызга карап торуын күреп.

— Исәнме, Тотыш,— диде кыз, йомшак кына, оялчан гына елмаеп.

— Исәнме, Тәңкә,— диде Тотыш.

**XIX**

Кунак кызы Тәңкәгә аерым киез өй корылган иде. Ул анда өлкән яшьтәге бер асрау белән тора иде. Төн уртасы якынлашып, балаларның кайсы йокыга киткәч, кайсы уеннан арып-талып йокыга җыена башлагач, Тәңкә дә үз өенә кайтып китмәкче булды.

— Кал бездә генә! — диде Тотышның Айсылу атлы зур сеңелесе.

— Кал, кал — бергә йоклабыз!

— Әкият сөйләшербез! — диештеләр башкалар да.

Ярым караңгыда Тотыш кунак кызның беләгеннән тотып алды да колагына пышылдап:

— Калма! Үзем озатып куям,— диде.

Пышылдаган чакта аның маңгае кызның кайнар чигәсенә тиеп китте. Кыз берни әйтмәде. Тотышка ул озак, бик озак эндәшми торды шикелле тоелды.

— Кайтам,— диде Тәңкә Айсылуга, калтыранып чыккан бер пышылдау белән.

— Кайтсын, кайтсын! — диде абый кеше, кунак кызын яклап.— Курыкма, үзем озатып куярмын.

Тотыш, кинәт үзен искиткеч җиңел тоеп, кемнеңдер аягына басып, кемгәдер бәрелеп, түргә узды, чөйдән киемнәрен алды. Ул киенгән арада, Тәңкә, ишек бавына тотынып, дер-дер калтыранып, ярым караңгыда аны көтеп торды.

Язгы төн караңгы иде, салкынча иде. Каршыда гына кап-кара булып, җир өстендә өйләр калкып утыра, өйләрдән, каралты-куралардан арырак, койма ягында, озын муеннарын күккә сузып, кара манаралар очлаеп күренә иде. Ул якта — койма өстендә, тычкан күзе төсле генә булып, төнге сакчыларның утлары җемелдәшә иде. Күктән исә, җирдәге караңгылыкка исләре китеп, берән-сәрән йолдызлар карап тора иде.

Өй эчендә юаш, тыйнак тоелган Тәңкә тышка чыккач бер дә юктан көлеп җибәрде: Тотышның янбашына төртте дә, җегет аны-моны абайлап өлгергәнче, караңгыда юк та булды. Тотыш аның киез өйләргә таба юнәлгән аяк тавышларын гына ишетеп калды. Үзенең җебегәнлегенә чак-чак кына үртәлеп, чак-чак кына үкенеп, ул качкан кызны куа китте. Бер-ике атлауда ул өйләр арасына барып керде. Туктап як-ягына каранды. Якын-тирәдә беркем юк иде. Кайдадыр шунда гына кунак кызының тыелып кына көлгән тавышы ишетелде. Тотыш тавыш килгән якка ташланды. Аның инде караңгыга күзе ияләнә башлаган иде — чак кына ул кызның җиңеннән эләктереп алмады. Үчекләшеп, кыз тагын көлеп җибәрде.

— Тоталмыйсың, тоталмыйсың! — диде ул, әкрен генә көлеп.

Кинәт сулуы капкан Тотыш, берни эндәшмичә, уттай янган күзләре белән якындагы карачкыны күзәтте. Болай качышлы уйнаганда үзенең чыннан да аны тота алмаячагын ул бик яхшы төшенде.

Алар шулай караңгыда бер-берсенә карашып торгандай иттеләр дә, икесе дә берьюлы диярлек урыннарыннан кузгалып куйдылар. Тотыш, үзенең тиле көченә ышанып, ярсып яңадан куа башлады. Кыз, көлгән сыман бер өн чыгарды да, башын иеп, аның кул астыннан шуып китте.

— Тотмасаммы! — диде ул, янап.

— Тоталмыйсың! — диде кыз, үчекләп.

Шул чакны якында гына, урам якта тояк тавышлары ишетелеп китте — үзара әкрен генә сөйләшеп, урда коймасы буеннан төнге сакчылар узып бара иде. Яшьләр, караклыкта тотылган угрылар кебек, икесе дә сискәнеп киттеләр, тынып калдылар, сагаеп урам якка колак салдылар.

Кызга караганда Тотыш элегрәк исенә килде. Сакчыларны онытып, ул кисәк кенә Тәңкәгә ташланды. Кунак кызы бары көчсез бер тавыш белән «ах!» дияргә генә өлгерде — куйны эләктереп алган бүре кебек, җегет аны ике куллап тотып алды. Тотып алды да, кочып, кысып, җирдән күтәрде.

— Җибәр! — диде кыз.

Кулыннан ычкындырмыйча гына Тотыш кызны җиргә бастырды. Бераз каушап-калтыранып торгандай итте, бар кыюлыгын бергә җыеп, аны яңадан кочып алды. Яратып, иркәләп, оялып кочты.

— Минеке буласыңмы? — диде ул, пышылдап, кайнар сулышын өреп.

Кыз эндәшмәде.

— Әйт, буласыңмы? — диде ул, кабатлап.— Мин бернәрсә уйладым. Бүген генә... әле генә... Әйтсәң, әйтәм. Мине монда беркем яратмый. Санламыйлар. Биарга китәм, аннан көч сорыйм. Алмыш ханга каршы яу чыгам. Ишетәсеңме, Алмыш ханга каршы яу чыгам! Синең атаңа булышка барам. Күрерсең менә, Алмыш ханны җиңсәм, бөтен Итил йортка үзем хан булам! Шуңа күрә иң элек миңа хатын кирәк... Хатыным булмаса, Биар ханы миңа көч бирмәячәк, мине Итил-Чулман йортның ханы да ясамаячаклар. Аңладыңмы инде? Чыгасыңмы миңа кияүгә?

Тонык кына йолдызлар яктысында кыз, үзенең яратуын белдереп, аның яңа мыек чыгып килгән сылу йөзенә карады, очкынланып торган тере күзләренә карады. Теле белән әйтергә аның көче җитмәде, дер-дер калтыранып ул кайнар куллары белән, кайнар бите белән аның күкрәгенә сыенды да авыз эченнән ниндидер изге келәүләр әйтте.

## XX

Бу төнне яшьләр генә түгел, өлкәннәр дә тынычсыз уздырдылар. Тик аларның тынычсызлыгы куанычлы тынычсызлык түгел,— кайгылы, борчулы тынычсызлык булды. Койтым бикә үзенең болгарларга, Алмыш ханга булган каршылыклы уйларыннан, яшьлегенең куркыныч истәлекләреннән арына алмады. Ямгырчы би үз эшләре турында баш ватты. Күрән бинең кайгысы исә Койтым бикәнекеннән дә, Казаяк ыруы башыныкыннан да зуррак, тирәнрәк иде.

Киштәләрдәге елкылдавык тиреләр, өем-өем күннәр, тәпән-тәпән баллар әз генә дә аның күз алдыннан китеп тормады. Шунда ук борып-борып аның эче авыртты, Утташ камның каргышларын, үзенең, Тотыш угланның эшләгән языкларын искә төшереп, анда эчтә нидер туктаусыз агулап, сызлап торды. Ул чын-чынлап куркуга төште. Аңа инде ул Тәңренең каргышларын татый башлады шикелле тоелды. Үзенең авыруын, үзенең эше гел кирегә китүен шулай Тәңре каргышына юрагач, аның күңел төшенкелеге көчәйгәннән-көчәйде. Чит ил сатучыларының килмәве генә түгел, Ямгырчы бинең көтмәгәндә килеп төшүе дә, аның шулай күңелләргә коткы салып Алмыш ханга каршы яуга өндәве дә, җыен да, Койтым бикәнең үзенә каршы чыгуы да — барысы да, барысы да шул ук олы каргышның бер чагылышы булып тоелды. «Күрәсең, яшәр көннәрем күп калмагандыр инде»,— дип уйлады ул, әледән-әле сызланып.

Бераз шулай уфтанып, сыкранып, ыңгырашып ятканнан соң ул яңадан сатылмаган маллары турында, чит ил сатучыларында булырга тиешле ниндидер им үләннәре турында уйлана башлады. «Ярар, Алмыш хан быел безгә аяк чалды,— диде ул үз-үзенә.— Җәрингә дә, аннан соң да аяк чалса, ул чагында нишләргә?» Әйе, ул чагында нишләргә?! Ничек котылырга моннан? Алмыш ханны кемнәрдер килеп туздырып ташлаганны көтеп ятаргамы, әллә... Ямгырчы би әйткәнчә... Юк, булмый! Булмас! Алайса, түләнмәгән каланны түләп, шуның белән буаны ерып җибәрергәмени? Кайсын сайларга — ирекнеме, байлыкнымы? Ах, нинди кирәк алар икесе дә ир булган ир өчен!

Алайса, чыннан да коры җирдән аркыш[1] җибәрү кулайрак булыр микәнни? Башкача юл юк. Күрәсең, шулай итәргә туры килер. Ике ай барасы, ике ай кайтасы. Башка юл юк...

Соңгы уе Күрән бигә ышанычлырак тоелды. Бу турыда ул иртән тыныч күңел белән дә уйлап карады. «Бүгеннән җыена башларга кирәк»,— диде ул үз-үзенә. «Тик кемне җибәрергә соң?» — дип уйлады ул бераздан. Акбога булдыра алмас. Котан шулай ук. Булса-калса — Тотыш. Биш йөз, алты йөз кораллы сакчы, яхшы кылавызлар[2] булса, әйләнеп кайтыр. Товарын эт ашасын, им утлары, им сулары алып кайтса, шул да җиткән. Көзгә тикле Әди кебек китеп кенә бармаса ярар иде. Әди дә гел «эчем» диде, менә ул кая таба бара эшләр! Китсен Тотыш, китсен тизрәк! Эшкә җигелсә, тилелеген онытыр, кеше булыр.

Үзенең нишләргә җыенуын ул бикәгә дә сөйләде. Койтым бикә бүлдермичә тыңлап торды да:

— Тотыш миңа да кирәгие. Минем дә сиңа сүзем бар,— диде.

— Нинди сүз? — диде би, сагаеп.

— Ямгырчы би безнең Тотыш углыбызга үзенең кызын бирмәкче була,— диде Койтым бикә.— Туганлашыйк, ди. Безне олылап, ышанып шулай еректан килгән... болай гына китеп барса, яхшы булмас.

«Котыртышып та өлгергәннәр,— дип уйлады би, кире бер тойгы белән.— Өйләнешми торсыннар әле! Җилкуар Ямгырчы би белән туганлашасы гына калганые!»

Хатынына аның шулай дип әйтәсе килде. Тел очына килгән сүзен ул әйтә алмады — өйалдында кемнеңдер ишектән кереп килгәне ишетелде. Бүлмәгә каравыл башы Акбога килеп керде. Акбога бинең Әдидән туган өлкән углы иде. Имән кискәседәй таза, кырыс, авыр холыклы бер кеше ул. Кулына ул ниндидер бау-шу тоткан иде.

— Менә, атай, бау баскыч,— диде ул, кулындагы бауны идәнгә ташлап.— Текмәдә эленеп калган. Чулман ягында... текә яр өстендә!

Акбога, ниндидер чиктән тыш куркыныч нәрсә булганлыгын аңлатырга теләп булса кирәк, дулкынланып, кулларын бутап сөйләде. Өй эчендә авыр тынлык урнашты.

— Тагын Тотышмыни? — диде ата кеше.

— Кем булсын башка — шул! — диде Акбога, авыр йодрыгын йомарлап.

— Каян белдең? — диде ата кеше.

— Каекчылар менеп әйтте, Ямгырчы бинең кызы Тәңкәне алып киткән,— диде Акбога.

— Тәңкәне?! — диде би, күзләрен шар итеп, урыныннан кузгалып.— Ямгырчы би кызын?! Урлап? Угры кебек алып качкан? Инде шул гына калды. Би углы — угры!

— Ах! — диде Койтым бикә, йөрәк ачысы белән.— Нишләтергә ул баланы?!

— Нишләтергә кирәген уйлап торасы калмаган инде, анай,— диде Акбога, эчке бер сөенү сиздергән усаллык белән.— Болай булгач, зурга китте бу.

Бер дә юктан би ярсып кычкырып җибәрде:

— Телләшмә! — диде Акбогага.— Анаңа каршы сөйләргә кем булдың? Ул качканда син кайда калдың? Уяу саклыйлар аны, каравыл башы! Куанычы эченә сыймый. Бер-берсен тотып ашарга гына торалар...

— Кичер, атам, кичер, анам,— диде Акбога, тезләнеп, мыгырданып.

— Бар, йөрмә буталып! — диде би, утыз алты яшьлек углына аяк тибеп.

Акбога мыштым гына чыгып китте. Ата кеше, базга төшкән бүре кебек, үртәлеп, үз сакалын йолыккалап, әрле-бирле йөренә башлады. Чынлап та, болай булгач, зурга китте эшләр. Чуалды эшләр, чуалды!

Шулай ул үзалдына ярсып йөренде-йөренде дә, утырган урынында тынып калган хатыны каршында туктады; ачуын алыр кеше табылуына сөенгән сыман, каты гына, усал гына сорап куйды:

— Җә, нишләтәбез, анасы? — диде.— Синең дә балаң ич... нишләтәбез: асабызмы, кисәбезме, әллә төкерәбезме?

— Башкалар ни әйтер...— диде Койтым бикә, авыру кеше кебек, тыны бетеп, агарынып.— Ыру ни әйтер... Ямгырчы би... Шуннан куркам мин!

Күп тә үтмәде, өйалдында икенче бер кешенең кереп килгәне ишетелде. Ишек сакчысы, ишектән башын тыгып:

— Ямгырчы би килгән, керсенме? — диде.

Би белән бикә, телдән язган сыман, сакчыга карап тик тордылар. Сакчы соравын яңадан кабатлады.

— Керсен,— диде би, төшенке генә.

Күзе-башы акаеп, тузынып, Ямгырчы би килеп керде. Керде дә, бигә дә, бикәгә дә туры карамыйча, ашыгып исәнлек-саулык сорады. Шуннан соң, сулуы кабып, үз-үзен тыя алмыйча, эчендәге бар нәрсәсен түгәргә кереште.

— Мин синең кунагың, Күрән би,— диде.— Кунактан болай көлмиләрие. Углың минем йөземне каралтты. Калым түләмичә, кызның атасына, туганнарына берни белдермичә... юлбасар кебек! Изге йоланы, изге түрәне бозып...

— Сиңа кем йоласы изгерәк соң, би? — диде Койтым бикә, мыскыл белән, бинең сүзен бүлдереп.— Син гарәп йоласын тотасың түгелме соң?

— Миңа икесе дә изге! — диде Ямгырчы би, аптырап калмыйча.— Урынына карап мин гарәп йоласын тотам, урынына карап — ата-баба йоласын. Эш анда түгел. Моның өчен син миңа түләргә тиеш, Күрән би. Мин болай гына китмәячәкмен!

— Без сиңа түләрбез, би,— диде Койтым бикә, ире әйткәнне көтмичә.— Шулай да нигә тузынасың әле син? Кичәгенәк кенә үзең туганлашыйк дидең түгелме соң? Менә син теләгәнчә булган. Балалар бездән сорап тормаганнар. Моның өчен аларны салып суктыру кирәк. Шулай да...

— Юк! — диде Ямгырчы би.— Туганлашу болай булмый. Мондый туганлыкның, мондый кода-кодагыйлыкның миңа кирәге юк. Казаяк ыруының башы Ямгырчы би кызы төшеп калганнардан түгел. Юлбасар... угры белән туганлашу миңа килешми!

Күрән би, сөзешергә җыенган тәкәдәй, баскан урынында сикереп куйды, кылычын кыныдан суырып чыгарды да...

Ямгырчы би дә аптырап калмады — аның да кулында үткер тимер ялтырап китте. Күз ачып йомган арада баш очында, чәк-чәк килеп, кылычлар орыша башлады.

— Туктагыз! — дип кычкырды Койтым бикә, урыныннан сикереп торып.

Аны-моны уйламыйча, ул ирләр арасына ташланды — үз иренең кылычы чак-чак кына аның башын кыеп төшермәде. Күрән би, кылыч астына кергән хатынын күреп, беренче булып исенә килде, коралын атып бәрде дә эчке бер омтылышка буйсынып, үзенең дуамаллыгы өчен кичерү үтенгән сыман, бикәне кочагына алды. Үпкәләшеп, бозылышып торган берничә көн эчендә ул инде аны сагынып та өлгергән иде.

Ямгырчы би дә кылычын идәнгә орды, аннары иелеп алды да, кире кынына салып куйды.

— Әйдәгез ашарга,— диде Койтым бикә, тузган чәчләрен төзәткәләп.

— Башта эчик,— диде Күрән би, кипшергән иреннәрен ялмап, басынкы гына.

Аякчы чүлмәк кертте. Күрән би, чүлмәктән әчкелтем әйрән агызды да, йотлыгып эчеп җибәрде, аннары кунагы белән хатынын сыйлады.

— Инде тынычланып сөйләшергә дә була,— диде ул, урынына утырып.

— Була,— диде Ямгырчы би дә.

— Сүзеңне кире ал,— диде Күрән би.

— Алам. Кире алам, кире алам,— диде кунак.

— Инде әйт: күпме сорыйсың? — диде Акбүре ыруының башы, җиңел сулап.

— Мең тиен. Булмаса — йөз төлке, булмаса — утыз кеш,— диде кунак.

— Күбрәк,— диде Күрән би.

— Күп түгел,— диде Койтым бикә, ирләрне тизрәк килештерергә теләп.— Тотыш угланның белексезлеге өчен ата-ана языклы булмаса да, Ямгырчы би чыннан да оятка калды.

— Белегез: бу — калым түгел,— диде Ямгырчы би, кисәтеп.— Кызымны мин үзем белән алып китәм.

— Калым да булмагач... күбрәк шул,— диде Күрән би, киреләнеп, шулай да килешкән сыман итенеп.

— Калым түгел. Кызымны алып китәм,— диде кунак, кабатлап.

— Ярар,— диде Күрән би, килешеп.— Талау күргән өчен сиңа миннән йөз төлке. Калым турында аерым сөйләшербез. Быел көз мин сиңа кодалар җибәрермен. Йола, түрә кушканча туганлашырбыз.

— Белмим әле, би,— диде кунак, ялындырасы килеп.— Күңелем бик кырылды. Иң элек кызны табарга кирәк, шуннан сөйләшербез.

— Тапкансың кайгырыр нәрсә, би! — диде Койтым бикә, елмаеп, сүзне уенга борып.— Тотыш угланның качып китүләренә, югалып торуларына без инде күнегеп беткән. Кызыңа берни булмас. Яшь киекләр кебек туйганчы качып йөрерләр-йөрерләр дә үзләре үк кайтып килерләр.

**XXI**

Ана кеше үзен шулай юатса да, качаклар икенче көнне дә, өченче көнне дә кайтмадылар. Ул арада Тотышның югалуы, кунак кызын алып качуы турында бөтен тирә-як белеп өлгерде. Төрле имеш-мимеш китте. Кайберәүләр ачыктан-ачык ачу белдерде: Тотышның мондый кыланышларына түзеп торырга ярамый, диделәр, бер-бер эш кылмыйча, без аннан котыла алмабыз, диделәр. Утташ кам инде сөенеп бетә алмады. Ул тагын да, бер дә курыкмыйча, ыру башына, аның качак углына каршы яман сүзләр сөйли башлады.

Кеше арасындагы мондый имеш-мимешләр бинең үзенә дә, аның өендәге башкаларга да ишетелде. Яшьләр югалуга дүртенче көн булды дигәндә, караңгы төшкәч, борчылып Күрән би үз янына Акбога белән Котанны чакыртып алды.

— Эзләргә кирәк булыр,— диде ул угылларына.— Бүген үк чыгып китегез. Берегез түбән төшәр, икенчегез югары менәр. Үзегез качыргансыз — үзегез табыгыз!

— Аның башбаштак булуында безнең эшебез юк,— диде Котан, йөзен чытып.

Төсе-бите белән дә, холкы белән дә Котан нишләптер Утташ кам ягына тарткан иде. Ул, туган атасының сүзен тыңлауга караганда, аңа каршы кешеләрнең сүзенә күбрәк колак сала иде, ахрысы. Тотышны исә ул барысыннан да ныграк яратмый иде.

Ата кеше кызмады, кырыс, усал йөзе белән Котанга бер генә күтәрелеп карады — углан шундук шып булды.

— Кем генә булмасын, ул сезнең туганыгыз,— диде би.— Табыгыз, кайтарыгыз. Тотыш минем ышанычым, Тотыш — Акбүренең ышанычы. Күңелем шулай сизенә, балалар. Өйләнгәч, эшкә җигелгәч, басылыр.

— Боерыгың үтәлер, атай,— диде тиз килешүчән Акбога, атасы алдында баш иеп.— Мин түбән китәрмен. Каекчылар аны, агым уңаена китте, диделәр. Балыкчылардан сорашырбыз, яр буендагы авылларда туктарбыз. Ике ишкәк белән әллә кая китә алмаслар.

— Энә түгелләр — табарбыз, атай,— диде Котан да, кирелеген җиңеп.

— Табыгыз, угылларым,— диде ата кеше, күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып.— Тәңренең каргышы болар барысы да. Минем инде күп яшисем калмагандыр... күңелем шулай сизенә, балалар. Бер генә углымның да мин юлдан язуын теләмим. Үзем исән чакта мин аны ипкә кертергә тиешмен. Унар каекка унар кеше алыгыз да, көн-төн юлда булыгыз. Кайтканда якты күздә кайтмагыз катауга, кеше шаулаша, ул-бу була күрмәсен.

Ыру башының сүзләре чынга чыкты. Икенче көнне үк урда капкасы алдына шаулашып кешеләр җыела башлады. Алар эчкә, би янына керергә теләделәр, янадылар, кычкырдылар. Сакчылар, билгеле, беркемне дә кертмәделәр — тимер күгәнле имән капкаларны шундук эчтән бикләп куйдылар.

Атлылар, җәяүлеләр капка алдына килә тордылар. Шау-шу көчәйгәннән-көчәя барды. Акколакка атланып, Күрән би капка янына килде. Шаулашкан кешеләр арасында ул ерактан ук Утташ камны күреп алды. «Үләксә козгыны! Кан исен әллә каян сизгән»,— дип уйлады ул кам турында.

— Сөекле туганым, бабам, син тагын коткы таратасыңмыни? — дип кычкырды би капка аша Утташ камга.— Ни булды, сөйлә.

— Монда чык, монда, кияү! — дип кычкырды Утташ кам, чәрелдәп, кулын бутап.

— Анда чыксам, мин синең тиле башыңны чабып кулыңа тоттырырмын! — диде Күрән би.— Синең коткы таратып йөрүеңне бөтен ыру белә — тагын ни уйлап таптың?

— Угры углың кая? Күрсәт углыңны! — дип кычкырды Утташ кам капка аша.

— Таралыгыз тизрәк! Күземә күренмәгез! — дип кычкырды би, ярсып.

Ул шундый каты кычкырды,— шаулашкан кешеләр чыннан да тынып калдылар, шүрли төштеләр. Бары Утташ кам гына, үз иярченнәрен өстереп, туктаусыз чәрелдәвендә булды.

— Синең белексез Тотышың аркасында илдән тынычлык китте, җирдә чир-чор күбәйде, явыз ияләр азынды. Кичәгенәк балтачы Кылтимернең кызыл сыеры ярдан таеп аягын имгәткән; күнче Туктамышның хатыны икенче көн инде бала табалмый интегә; бүген таңда Котлыгыш аксакал үпкә чиреннән үлде; үзән төбендә эреп бетмәгән кар ята; әле булса яңгыр яумый... саный китсәң, тәлим яман эшләр тулып ята. Барысы да синең Тотышың аркасында!

— Барысы да синең коткың аркасында, Утташ кам! — дип кычкырды Күрән би, Утташ камның үзеннән дә яманрак итеп.— Килешәм: минем Тотыш углым усал, кыю... башсызлыгы да бар. Аның кебек чакта кем генә шулай булмаган! Күпме генә тинтәк, башсыз булмасын, шулай да балтачы Кылтимернең сыерын ярдан ул төртеп төшермәгәндер, күнче Туктамыш хатынының баласын да, тума, дип, ул котыртмыйдыр...

Төркем арасында, җылы җил булып, тыелып кына көлешү ишетелеп китте. Күрән бинең тавышы ышанычлырак яңгырый башлады.

—...Котлыгыш аксакалның үпкә чире белән чирләвен кем белми! — диде ул, өзелгән сүзен ялгап.— Үлгән икән — урыны оҗмахта булсын! Яхшы, тыйнак кеше иде. Син, Утташ кам, аны да минем углым Тотыш үтергән димәкче буласыңмы?

— Мин алай дип әйтмәдем! — дип кычкырды Утташ кам.

— Әнә сүзеңнән таңа да башладың! — диде Күрән би, җиңүче төс белән.— Җирдә чыннан да яман эшләр тулып ята. Изге келәүдә буласы урында, изге эшләр белән мавыгасы урында, син, Утташ кам, юк-барны чокчып, ыру котыртып йөрисең. Чир-чорны бетерү, албасты-өрәкләрне качыру синең эш. Җирдә явызлык күп икән, димәк, син келәмисең, үз эшеңне тиешенчә башкармыйсың. Бер-ике көннән сабанга төшәргә кирәк, орлыкларны, коралны барларга кирәк — чураларныı син эшләреннән аерасың, кешеләрнең тынычлыгын бозасың. Син языклы барысына да, Утташ кам!

— Чын шул!

— Би белеп сөйли! — диештеләр төркемдәгеләр, ачулы мыгырданып.

Кайберәүләр, исән-имин чакта китеп котылырга кирәк дигән сыман, шундук тәртәләрен кире бордылар. Утташ кам, бирешәсе килмичә, төкерекләрен чәчте, кулларын бутады. Шулай да инде төркемдәгеләр аның сүзенә колак салмадылар. Тотышның кыланышларын да, Утташ камның ни өчен бигә ачулы икәнлеген дә алар чыннан да яхшы беләләр иде. Шуңа күрә Утташ кам инде аларны тиешенчә кыздыра, ярсыта алмады. Әллә урлаган Тотыш кунак кызын, әллә урламаган — кем белә аны!..

Тора-бара кешеләр монда ни өчен килүләрен дә аңламый башладылар. Тотышны да исләреннән чыгардылар. Бөтен кызык би белән Утташ камның әйтешүенә кайтып калды. Үз тирәсендә кешеләр сирәгәйгәч, Утташ кам да тизрәк сыпыруны яхшы тапты. Би кешеләре аның артыннан көлеп, таш, балчык бәреп калдылар.

## XXII

Көн артыннан көн үтте, төн артыннан төн үтте — качакларны эзләргә киткән Котан белән Акбогадан бернинди яңалык ишетелмәде. Ул арада сабанга төшәр көн дә килеп җитте. Билгеләнгән көнне, кояш чыгу белән, игенчеләр үгезләрен, атларын җиктеләр, арбаларга сабан-тырмаларын, орлыкларын төяделәр дә Басу-капка аша яланга агыла башладылар.

Язгы сабанда бөтен ыру, бөтен катау катнашты. Койма, капка сакчыларыннан кала барлык ирләр, хатын-кызлар, бала-чагалар кырга чыктылар. Берәүләр сөрде, икенчеләре арттан тырмалап барды. Өченче берәүләр, иңбашларына тубаллар асып, шунда ук чәчә бардылар. Басу белән катау арасында — зур юлда, сөрелгән җир буйларында, әрәмә башларында, яшел чирәмле уйдыкларда ыгы-зыгы, уен-көлке әз генә дә тукталып тормады. Әле анда, әле монда күккә зәңгәр төтеннәр күтәрелде — пешекчеләр сабанчыларга ашарга пешерделәр, бала-чагалар иске салам, чүп-чар яктылар. Ераграк басулардан кешеләр кунарга өйләренә кайтмадылар — киез өйләр корып, төнә-куна шунда яттылар.

Каралар гына түгел, би дә бөтен өй эче белән, туганнары, кунаклары белән бөтен көнен кырда-басуда үткәрде. Иген игү иң изге эшләрдән санала иде, шуңа күрә үз аягы белән йөри алган барлык кеше ничек тә язгы сабанда катнашырга тиеш иде. Үз аяклары белән йөри алмаганнар исә, борынгы ышану буенча, иске җирнең җыртылуын, яңа җиргә орлык төшүен булса да үз күзләре белән күреп калырга тырышалар иде. Шунлыктан бу көннәрдә басуда бөкшәеп беткән карт-корыларны да, моңарчы түшәгеннән башын калкыта алмаган каты авыруларны да күрергә була иде.

Шундый көннәрнең берсендә, кич караңгы төшкәч, Кызыл Яр катау турысына, ташлы ярга бер көймә килеп туктады. Көймәдән ике карачкы төште. Тавыш-тынсыз гына алар көймәләрен яр читенә тартып чыгардылар да, вак чуерташларга сак кына басып, текә баскычка таба атладылар. Сабан көннәре булганга, яр буенда балыкчылар да, сакчылар да юк иде. Баскычның аскы башында да шулай ук бернинди сак күренми иде.

Көймәдән төшкән кешеләр, бер-берсенә тотынышып, текә баскыч буенча әкрен генә югары үрмәләделәр. Тиздән алар баскычның югары басмасына менеп җиттеләр, биек баганалар өстенә салынган, берни белән тоташмаган озынча күпер кырыенда туктап калдылар. Аларның артында, аста, бик тирәндә, төн карасында тагын да куркынычрак булып тоелган яр кырыенда, беленер-беленмәс кенә кара су елкылдап ята иде. Аларның каршысында — очлы манараларын күккә сузып, биек, кара коймa калкып утыра иде. Аларның аяк астында, күпер янында, тирән бушлык барлыгы сизелә иде. Бар яктан да аларны төпсез упкын чолгап алган иде.

— Кайтып җитүен җиттек — өйгә ничек керергә? — диде Тотыш, күпер кырыеннан артка чигенеп.

— Төнне шушында гына уздырыйк. Иртәгә ни булса да булыр,— диде Тәңкә.

— Ни булса да булыр дип көтеп ятсаң, булыр! — диде Тотыш.

Нишләргә дә белмичә, ул Тәңкә белән кочаклашып күпер кырыенда шактый озак басып торды. Ничек керергә катауга, ничек анасы, атасы янына барып җитәргә? — аның күңелен менә шундый сорау тынычсызлый иде. Кайтканда бу турыда ул артык борчылмады, кайтып җитсәм, ничек тә җаен табармын әле, диде. Күпер баганасы буенча шуышып аска төшәргә, аннары шома яр читеннән үрмәләп өскә менәргә булыр иде — кызгылт ком-ташларда аның үзенә генә билгеле булган ярыклар, чокырчыклар бар иде. Тик аннан коймага ничек үрмәләп менәргә дә, сакчыларга күренмичә генә ничек теге якка чыгарга? Үзе генә булса ул, билгеле, аптырап тормас иде. Икәү булгач, үзен ул тышауланган кебек тойды.

Алар шулай аптырабрак торганда, капка турысында чыгырлар шыгырдаган тавыш ишетелде. Шул ук мәлдә караңгы коймадан, тере булып, киң кара нәрсә аерылды. Күпер төшерәләр түгелме соң?! Каян сизгәннәр? Күреп торалар микәнни?

Тотыш, Тәңкәне кысып тотты да, артка чигенде, баскыч буенча ашыгып аска төшә башлады. Тик ике-өч басма төшкәч тә ул туктап калды. Ник кача соң әле ул? Кая кача? Өенә кайтып җиткән икән, ни булса да барыбер керергә кирәк түгелмени?

Асылмалы күпер, көчсез генә дөпелдәгән тавыш чыгарып, баганалар өстенә төште. Качаклар яңадан өскә мендеmenәр, куркып-калтыранып, күпергә керделәр, бер-берсенә нык тотынып, упкын аша караңгы капкага таба атладылар.

Ярым ачык капка төбендә аларны сакчы туктатты.

— Тотыш, сезме? — диде ул әкрен генә, эчке бер сагаю белән.

— Мамыш! — диде качак егет, куанып.— Син күзәтеп тордыңмыни? Бай бул, Мамыш! Изгелегеңне мәңге онытмам!

— Мин генә түгел, бөтен Яр-капка сезне күзәтеп торды,— диде Мамыш.— Бинең боерыгы шундый.

— Ачулымы миңа атай? — диде Тотыш.

— Юк,— диде Мамыш.

Тотышның кинәт өстеннән тау-таш ишелеп төшкәндәй булды. Күңелендә калыккан куаныч тойгысыннан, атасын-анасын кызгану тойгысыннан аның аяк буыннары йомшарып калды. Ах, күпме кайгы-борчу салды ул аларга! Моннан соң инде беркайчан да ул аларның сүзеннән чыкмас, моннан соң инде ул аларның иң күндәм, иң игелекле угыллары булыр! Тик... тик аны бары кичерсеннәр генә дә, Тәңкәне алуына каршы гына килмәсеннәр.

— Бар, тизрәк йөгер, сөенче алырсың! — диде ул Мамышка.

— Сөенче — уртак! — диде шунда аларны тыңлап торган икенче сакчы.

Алар ашыгыбрак алдан киттеләр, Тәңкә белән җитәкләшеп, Тотыш алар артыннан атлады.

Басудан арып-алҗып кайткан би каты йокыга талган иде. Аны уятып урыныннан торгыздылар. Шулай ук Койтым бикә белән Ямгырчы бине дә йокыларыннан уяттылар.

— Үзләре кайтыр дип әйттемме? — диде Койтым бикә, куанычыннан нишләргә белмичә.

— Мин дә кайтмаслар димәдем,— диде Ямгырчы би, коры гына.

Әйе, кайттылар. Үзләре кайттылар. Әнә икәүләшеп аталары алдында тезләнеп торалар. Бераз гына ябыгып калганнар, бераз гына үсеп киткәндәй, үзгәргәндәй булганнар. Тотышның иңбашлары, кыска

тунына сыймыйча, төртелеп тора сыман. Муены нечкәргәндәй булган, чәчләре үскән,— күзенә, маңгаена төшеп тора. Тәңкә тартылган, сулыккан; күз төпләре зураеп калган.

Кайттылар... Алар Биар ханына тикле барып җитә алмадылар. Катаудан ике көн ераклыгындагы балыкчы Карынчык өендә тукталып калдылар. Карынчык аларга Биар ханында болгарларга каршы яу чыгу кайгысы юклыгын әйтте. Быел тагын төн ягыннан аларга каеклы юлбасарлар төшкән икән. Көчләре артык күп булмаган, биарлар аларны бик тиз җиңә алганнар. Шулай да юлбасарлар Биар иленә шактый күп талау китергәннәр. Карынчык әйтте, анда йөреп юлыгыз уңмас, диде. Биарның Алмыш ханда эше юк, ул сиңа берни бирмәс, диде. Аннары өстәп куйды: теләгәнчә үземдә кунак булыгыз — би углына кайда да урын табылыр, диде.

Тотыш Карынчыкның сүзен тыңларга булды. Яр буенда, урман эчендә балыкчы аларга киез өй корып бирде, көн дә аларны яңа тотылган балык, яңа суелган ит белән сыйлады. Тотыш Тәңкә белән бергә тора башлагач, үзенең барлык кайгыларын, барлык үпкәләрен онытты. Чынында аның инде үзенең дә беркая яу белән дә чыгасы килмәде, кемнәндер, ни өчендер үч тә аласы килмәде. Тәңкә белән икәүдән-икәү генә ул ялгыз өйдә, изге Чулман буенда мәңге торып калуга да каршы килмәс иде. Тик аларга анда мәңге торып калырга туры килмәде. Аларны эзләп көтмәгәндә атасыннан кешеләр килеп - җитте. Ярый әле балыкчы аларны алдап җибәрде, күрмәдем, белмәдем, монда беркем булмады, диде. Эзләнүчеләр киткәч исә Карынчык качакларга әйтте, без капчыкта ятмый, сезне барыбер табарлар, диде. Болай качып йөрү, качып яшәү би углына килешми. Кайтырга кирәк, ил казанында кайнарга, ил кайгысын кайгыртырга кирәк, диде.

Менә алар кайттылар.

— Атам, анам, мин ир булдым,— диде ул, идәннән күзен алмыйча.— Моңарчы мин бала булганмын. Барысы өчен дә кичерегез мине! Кичер мине, Ямгырчы би! Миңа аерым өй бир, эш бир, атам. Минем дә башкалар кебек яшисем килә.

— Ата-анадан качып китеп ир булмыйлар,— диде Күрән би, шактый тынлыктан соң, нык береккән иреннәрен бер-берсеннән көчкә аерып.— Тәңре каршында, түрә каршында син ир түгел, син — угры, син...

Яшь җегет калтыранып китте, иңбашлары салынып төште, күз карашы томанланып калды.

— Угрылык өчен сезнең аяк-кулларыгызны чабып өзәчәкләр...

— Атай! — диде Тотыш, коты алынып.— Языклы мин! Ярлыкагыз мине, атам, анам!

— Чабып өзәчәкләр! — диде ата кеше, кабатлап, караңгы йөз белән.— Сезнең әллә икешәр башыгыз, дүртәр аяк-кулыгыз бармы?

Моңарчы бер сүз әйтми читтә басып торган Ямгырчы би телгә килде.

— Мин кызымның аяк-куллары агач башында асылынып торуын теләмим. Таң атканчы мин кузгалып китәргә тиешмен. Капкаңны ачарга боерык бирүеңне үтенәм, би,— диде ул.

— Мине ирем белән бергә ассыннар! Мин беркая китмим! — диде Тәңкә, Тотышка сыенып.

Ямгырчы би усал гына көлеп куйды.

— Мин үз сүземне әйттем,— диде ул, Акбүре ыруының башына карап.— Үз углыңны син теләсә нишләтә аласың. Кызымны мин калдырмаячакмын.

Тәңкә кинәт чыркылдап җибәрде, тынсыз калган, күңеле сынган иренең авыр башын күкрәгенә кысып, тыела алмыйча кычкырып җыларга тотынды.

— Бирмим! Бирмим! Асыгыз... мине дә асыгыз! Минем дә үләсем килә! — диде ул, такмаклап.

**Икенче баб**

**I**

Беренче тапкыр бүген күк күкрәде, яшен яшьнәде. Урамнардагы, ишегалларындагы, басулардагы барлык кешеләр, болыннардагы көтүчеләр, урманнардагы агач кисүчеләр, яр буендагы балыкчылар, каекчылар — өлкәннәр, бала-чагалар, тазалар, авырулар — барысы да, барысы да, күк күкрәвен ишетеп, җиргә егылдылар. Көтүдәге атлар, сыер-сарыклар ашауларыннан туктап калды, этләр, чинап, кешеләргә елыштылар.

Каяндыр көн яктан — Чулманның күкселләнеп яткан иксез-чиксез киңлеге өстеннән, ямь-яшел болыннар, куе урманнар өстеннән башланган яшенле күкрәү, дөбер-шатыр килеп, ачулы мыгырданып, Кызыл Яр катау турысына килеп җитте. Куар[1], утлы кылычы белән селтәнеп, биек яр башындагы чыршылыкка сыенган ниндидер албастыны сугып үтерде дә, ашыгып төн ягына таба китеп барды. Язгы сулар белән дә агып бетмәгән чир-чорлар, айналар, албастылар — барысы да Куарның бөек чирүеннән куркып, чит җирләргә, чит илләргә юл тоттылар.

Яшенле күкрәү узып китү белән, кешеләр сикерешеп җирдән тордылар, бер-берсен котларга, куанышып биергә, такмакларга тотындылар. Күп тә үтмәде, томалап яңгыр килеп җитте. Яңгыр шактый озак яуды. Ачык җирдә калган кешеләр манма су булдылар. Өйдәгеләр, каралты-курадагылар исә яңгыр астына үзләре чыгып бастылар. Беренче язгы яңгырның игеннәргә, чирәмнәргә, ут-үләнгә генә түгел, барлык тереклеккә — кешеләргә, мал-туарга, киекләргә дә ачуы бар иде.

Шулай итеп, Акбүре иленә җәй килде, җылы килде. Яңгыр туктагач та, кешеләр, куанышып, өйләренә ашыктылар, учакларын тергезеп җибәрделәр. Чыр-чу килеп урамда балалар чабышып йөрде. Әле анда, әле монда көлгән тавышлар ишетелде. Кичкә таба күңел ачу башланып китте.

Бөтен ыру кешеләре онытылып беренче яңгыр туен иткәндә, Күрән би урдасында ашыгып юлга җыендылар.

Кешеләргә, бигрәк тә Утташ кам яклыларга күзекмәсен дип, Күрән би Тотышны Чулман аръягындагы Талкысык авылына озатты. Кешеләр, билгеле, сизенми калмадылар. Шулай да би углының угрылыгын үз күзләре белән күрмәгәч, эчтән тындылар. Күргәннәр-белгәннәр исә май капты. Шулай ук Утташ камның да тавышы-өне ишетелмәде. Ул арада Күрән би, артык шауламыйча, шул ук Талкысыкта аркыш җыя башлады. Башта уйлавынча, товар белән көн якка ул Тотыш угланны җибәрергә булды. Күрән би берьюлы ике куян атарга уйлады: беренчедән, ул яманаты чыгып өлгергән углын усал күзләрдән, алай гына да түгел, үтерелү куркынычыннан саклап калырга; икенчедән, үзенең күптәнге яшерен теләген тормышка ашырырга булды. Углын Талкысыкка озатканда, ата кеше аңа үзенең эчендәге яман чир турында да әйтте. Бар ышанычым синдә, углым, диде. Булдыра алсаң, миңа яхшы, белекле берәр имче алып кайт, булдыра алмасаң, белешеп, сорашып, эч авырткангa им утлары, им сулары алып кайт, диде. Кара аны, акча кызганма — барлык товарыңны биреп булса да, минем теләкне үтәргә тырыш, диде. Атасының теләген үтәргә дип, көзгә исән-аман кайтып җитәргә дип, Тотыш ант эчте.

Ерак юлга чыгу алдыннан яшенле яңгыр явып узуны Күрән би изгегә юрады. Караңгы төшү белән ул каекларга соңгы кирәк-яракларны төятте дә, Талкысыкка Тотыш углан янына чыкты. Ул аңа ак юл теләде, тагын үзенең киңәшләрен, теләкләрен кабатлады, аны күкрәгенә кысып, озак кына ычкындырмыйча торды.

— Иртәгә таң ату белән кузгалыгыз, углым,— диде Күрән би, күз яшьләрен сөртеп.— Исән-сау әйләнеп кайтсаң, көзгә башлы-күзле итәрмен. Кайгырма — Тәңкә синеке булыр.

— Атай, күрерсең менә!.. Моннан соң беркайчан да... Ышан, атам, миннән дә тугрылыклы углың булмас! — диде Тотыш, дулкынланып.

— Ышанам, углым,— диде ата кеше.— Күңелем тыныч. Мин сиңа ышанам, углым.

Төн уртасында үз өенә кайтып йокыга яткач, шулай да би тиз генә тынычлана алмады. Аның күңелен бертуктаусыз нидер борчып, кымырҗытып торды. Нишләптер аның эче дә пошкан кебек булды, йокысы да килми сыман тоелды, шул ук мәлдә йокларга да кирәк иде шикелле. Әллә катаудагы җыр тавышлары тынгы бирмәде, әллә эт улаган тавышлар ачуын китерде. Эч пошу, борчылуга бераздан эчтәге чын авыру, сызлану-әрнү тойгысы кушылды. Йокыга киттем дигәч тә, ул әллә нинди куркыныч төшләр күреп саташты, йокламаган чагындагы борчулы уйлары исенә төшеп, тагын коты алынды.

Иртән аны ниндидер дөбердек уятты. Шыбыр тиргә баткан килеш ул сикереп торды, кылычына тотынды, аннары, калтыранып, ишек артындагы дөбердеккә колак сала башлады. Кем булыр бу? Нәрсә кирәк бу авыкта?[1] Кояш әле чыкмаган, әле бик иртә булырга тиеш.

— Кем бар анда? Нәрсә кирәк? — дип кычкырды ул, күпмедер тыңлап, көтеп торганнан соң, ишеккә якынаеп.

— Бу мин, каравыл Чынташ! — диде тыштагы ир кеше.

— Ни булды? Ник дөбердәтәсең? — диде би, ишек биген ычкындырып.

— Улакчы[2] килде, улакчы! — диде Чынташ.— Ашыгыч битек[3] китергән. Менә.

Би, каравылчы кулыннан битекне тартып алды да, шартлатып ишегеән япты, биген яңадан элдерде. Битекне ул ачу белән идәнгә атып ормакчы булды. Каравылчының «ашыгыч» дигән сүзен исенә төшергәч, бу уеннан кире кайтты. Тәрәзә янына килде дә, вак-вак пыяла кисәкләре аша үткән таң яктысында ал тамга сугылган, җеп белән кысып бәйләнгән күн тышлы битекне кулында әйләндергәләп карады. Аннары җепне теше белән өзде, аксыл каен тузына иҗекләп язылган түбәндәге сүзләрне укыды:

*«Атай! Алмыш хан килә. Төшкә монда булыр. Елга аша күпер салалар. Көче күп. Мин Чулманга чигенәм. Шуннан кайтырмын.*

*Алай башы Күзәмеш углан».*

Күрән бинең чәчләре үрә торды. Күрән бинең куллары, аяклары калтыранды. Суларга тын җитмәде, уйларга уй җитмәде. Аның тиз генә өстен-башын киенеп, коралларын алып каядыр чыгасы да килде, хатыннарын, балаларын, ырудашларын булышка чакырып, бөтен катауга, бөтен җир-суына сөрән дә саласы килде. Кулына утлы куздай пешерә торган битекне тотып, ул әрле-бирле йөренде, тешләрен шыгырдатты, башындагы чәченә ябышты, ыңгырашып-ыңгырашып алды. Идәнгә егылды да, ике кулын күккә сузып, күз яшьләрен түгеп, ялвара башлады.

— Тәңрем! Ата-баба! Көч бирегез, кыюлык бирегез! Яу килә, яу! — диде.

Яу килә, яу! Алмыш хан килә! Коры җирдән, Чулманның уң ягыннан, урман-сазлар аша, елгалар, чокырлар аша чирү килә!

Булмас ла! Туктале, ялган түгел микән бу? Берәрсенең коткысы түгел микән? Котан өйдә юк, Акбога өйдә юк. Күп ирләр Тотыш белән ерак юлга чыгарга тиеш. Катауда җитәрлек сакчылар да юк. Нинди яу ди әле ул мондый чакта!

Туктале, тукта... нәрсә бу? Шулай итеп, Акбүренең көне беттемени? Шулай итеп, Утташ камның каргышлары барып ирешә микәнни?!

А Тәңрем! Изге ияләр! Кичерегез... коткарыгыз Акбүрене бу кыраннан, бу талаудан!

## II

Икенче көнне, урда янындагы байракларны җилфердәтеп, манараларда ургыган кара төтеннәрне тузгытып, катау өстеннән беренче җил — салкынча таң җиле исеп киткәч тә, басу ягында дүрт-биш җайдак күренде. Алар, изге нарат аланыннан килә торган юлдан катау ягына борылдылар да, атларын юырттырып, туп-туры капкага таба юнәлделәр. Болар юл буенда төн кунган күзәтчеләр иде.

— Киләләр, киләләр! — дип кычкырдылар алар койма өстендәге ырудашларына, каядыр артка, урман ягына күрсәтеп.

Койма өстендәге сакчылар кузгалышып куйдылар. Өзек-өзек тавышлар ишетелде, яу якынлашканны белдереп, йөрәкләрне телеп, чыелдык быргылар кычкырды. Койма буенда, ачык җирдә учак ягып төн уздырган ирләр, ашый торган ашларын ташлап, кулларына корал алып, агач баскычлар буенча койма өстенә йөгерделәр. Атлылар атларына атландылар, коралларын барладылар. Койма тышында урның бозылган ярларын төзәтүче, ауган, какшаган баганаларны ныгытучы кешеләр тизрәк эшләрен төгәлләргә ашыктылар.

Чабып килгән күзәтчеләр урга якынлашу белән, капкачылар күперне төшерделәр, капканы ачтылар да тыштагы барлык кешеләрне эчкә керттеләр. Капка ябылды, күпер яңадан күтәрелде — су астыннан чыгып торган очлы багана башларына, болганчык су өстенә шыбырдап чүп-чар, балчык коелды.

Каравыл өендә йокымсырап утырган Күрән би, тояк тавышлары ишетеп, сискәнеп урыныннан торды.

— Килделәрмени?! — диде ул, кисәк кенә, куркып.

— Киләләр! — диде шунда кемдер, басу ягына күрсәтеп.

Шул чакны чыннан да изге нарат аланы ягыннан үр менеп килүче атлылар күренде. Иң элек аларның иртәнге кояш яктысында ялт-йолт килгән сөңге очлары, күк төстәге озынча байраклары калкып чыкты. Аннары әкренләп-әкренләп коралды ирләрнең тимер алпаклары, ат башлары, калканнар күренә башлады. Үрдән менгән җайдаклар унга борылдылар, киң юлга төштеләр.

Баштанаяк коралланган, көр-таза атларда нык утырган ул ят кешеләр, ягы кешеләр ашыкмыйча гына, иркен, тыныч кына киләләр иде. Алар күп иде, бик күп иде. Кечерәк төркем-төркем булып, җир астыннан чыккан сыман, сырт итәгеннән менә тордылар, тигез җиргә җәелә тордылар. Бераздан алар бодай чәчелгән җир өстен бөтенләй каплап алдылар. Шул ук мәлдә, тыелгысыз бер көч булып, тигез җиргә җәелеп аккан язгы ташкын булып, катауга таба басып килделәр. Тигез, ачык ялан күз алдында атлар, кешеләр белән тулды. Тигез, ачык, күркәм яланда — катаудагы меңләгән күзләр алдында — әйтерсең тиз арада кара урман калкып чыкты, әйтерсең берничек тә үтеп булмастай тау-таш калкып чыкты!

Акбүреләр, койма өстендәге калку урыннардан, ук атар өчен калдырылган уемнардан, манара башларыннан, өй түбәләреннән, багана башларыннан аларның шулай бөтен җирне иңләп, ябырылып килүләрен тын да алмый күзәтеп тордылар.

Байракларын югары күтәреп иң алдан килгән ирләр төркеме, катауга бер ук[1] чамасы килеп җитмичә, сөрелмәгән, чәчелмәгән тигез җирдә туктап калдылар. Арттан килүчеләр дә, алдагыларга якынлашып, шулай ук туктый башладылар. Акбүре кешеләренә аермачык булып аларның йөзләре, киемнәре күренде; аларның янау, көлү сүзләре ишетелде.

Юлның ике ягына да тезелгән ир-атлар кинәт кыймылдап куйдылар, як-якка тайпылгандай иттеләр. Юлда, тар аралыкта яхшы акбүз атка атланган бер кеше күренде. Бу кеше йөзләгән, меңләгән ир-атлар арасында таудай калкып, ерактан ук күзгә ташланып тора иде. Ул бик таза, көчле кеше күренә иде. Башындагы алпагы да, күбәсе дә, калканы да аның көмештән, алтыннан ясалган иде. Озын муенлы, биек, таза атының йөгәне, ияре, өзәңгеләре шулай ук алтын-көмеш белән бизәлгән иде. Күбә өстеннән ул ал төстәге бөркәнчек ябынган иде. Кара сакал-мыегы аның кыска итеп, түгәрәкләп киселгән иде. Аның болай да киң, түгәрәк бите шунлыктан тагын да түгәрәк булып, табактай зур булып күренә иде.

Эре сөякле, бай киемле бу ир-ат Алмыш хан иде.

Яшь, тук көрән атка атланган бер яшь ир, байракчылар төркеменнән аерылды да катауга таба чабып китте. Атта чабып барган уңайга ул җәясенә ук утыртты. «Һай» дип бер кычкырды да, акбүреләр ягына атып җибәрде. Төз атылган ук Басу-капка янындагы каравыл өенең ишек башына килеп кадалды. Сакчылардан берсе сикереп укны тартып алды; алды да, йөгереп аны Күрән бигә илтеп бирде. Укка каен тузы бәйләнгән, тузга шундый сүзләр язылган иде:

*«Мин Болгар йортының башы Алмыш хан, синең җиреңә килеп урда кордым. Атам Шилке үлгәч, син, минем колым Күрән би, өч җыл миңа калан түләмәдең. Шуны алырга килдем. Өч көндә бирмәсәң, катавыңны җир итәм, ыруыңны юк итәм. Ил белән бирәсеңме, яу беләнме?»*

**III**

Акбүре ыруында барлыгы ун мең өй санала иде. Болгар ханы Шилкегә Күрән би ел саен өй башыннан берәр кеш түләп килде. Берәр кештән бер елга ун мең кеш, өч елга — утыз мең кеш. Күрән би, Алмыш ханга калан түләргә туры килсә дә, өч елга түгел, никтер бер генә елга түләргә туры килер дип уйлаштыра иде. Өч елга! Уңган, беткән, суга аккан өч ел өчен дә калан түләргә!

Утыз мең кеш! Каян алырга утыз мең кешне? Булган барлык байлыгыңны чыгарып салыргамы, әллә соң булган барлык көчең белән каршы торыргамы? Катауны алар тиз генә ала алмаячаклар. Тиздән Котан белән Акбога кайтып җитәргә тиеш. Авыллардан кораллы алайлар килә тора. Атарга ук җитәрлек, ашарга азык җитәрлек. Җиңелергә туры килә икән, соңгы чиктә Яр-капка аша Чулман аръягына таярга була.

Нинди күп алар шулай да! Шултикле ерак җирдән юллар ярып, күперләр салып килгән бу чирүнең, күрәсең, балтачылары да күптер. Ур аша күпер салып, катауның капкасын җимереп, яндырып керү аларга берни тормас. Шулай булгач... катавың белән, ыруың белән бергә кырылуга караганда, сораганын биреп котылу яхшырак булмасмы?

Соңгы көннәрдә бик нык йончыган, тиешенчә йокламау аркасында, йөзе агарынып калган би аксакалларга, кораллы ирләргә күтәрелеп карады.

— Нишлибез? — диде ул, карлыккан тавыш белән.

Башкалар да үзләренә шул ук сорауны бирделәр. Тик беркем дә турысын гына ярып сала алмады. Бармакның кайсын тешләсәң дә авырта иде, ничек кенә боргалансаң да, башыңа таякның юан башы төшәчәк иде. Тынлык шактый озакка сузылды. Беренче булып Утташ кам авыз ачты.

— Туганнар, ырудашлар! — диде ул, кычкырып.— Мин сезгә әйтә килдем. Мин сиңа да әйттем, би! Колак салмадыгыз. Инде менә күреп торасыз: Тәңренең каргышы, авыр кылыч булып, баш өстебездә уйнап тора. Көн-төн эшләнә торган языкларыбыз өчен килгән талау бу! Мондый чакта, куркыныч килгәндә... бөтен ыруның язмышы кыл өстендә торганда... безгә йолык бирергә кирәк! Башкача котылу юк!

Кешеләр сагая калдылар. Утташ камның бөтенләй кирәкмәгән юлдан китүен аңласалар да, аның сүзен бүлдерергә беркемнең дә йөрәге җитмәде. Ырудашларының куркынган, таштай катып калган йөзләрен күреп, Утташ кам кызганнан-кыза барды.

— Биргән йолыгыбыз ияләргә барып ирешмәде,— диде ул, аксакалларның әле берсенә, әле икенчесенә карап, Әрлик хан ялчысы явыз Октуганның күңеле йомшармады. Кичәгенәк төш күрдем. Октуган якамнан алды. «Йолык! Йолык! Йолык!» — диде өч тапкыр. Мин аны беләм, өч тапкыр әйттеме, ул кеше сорый. Явыз Октуган йолыкка кеше сорый! Үтендем, ялвардым — сүзеннән кайтмады. Шунсыз сезгә котылу юк, ди. Юкса бөтен җир-суыгыз, бөтен ыруыгыз юкка чыгачак, ди. Бер языклы кеше аркасында бөтен ыру юкка чыгарга тиешме, юкмы — әйтегез шуны, ырудашлар?

— Йолык! Йолык! — дип кычкырдылар Утташ кам янындагы кешеләр.

— ...Октуган явыз... тфү, тфү! Телемә дә аласым килми...— диде Утташ кам, еламсырагандай итеп.— Канечкеч Октуган... явыз Октуган синең углың Тотышны сорады, Күрән би! Кая качырдың углыңны — кичекмичә тотып бир безгә!

Кешеләр, көчле җил искән чактагы урман кебек, кинәт чайкалып куйдылар. Куллар, ярлыкау сорап, үзеннән-үзе күккә күтәрелде, меңләгән йөзләрдә курку, кот алыну билгесе катып калды.

Майчан аксакал, ачуланып, таягын шакылдатып, койма өстенә менде.

— Ыхым, ыхым,— диде, тамагын кыргалап.— Оланнар... ырудашлар, мине тыңлагыз. Сезнең арада мин иң карт кеше. Яшем инде сиксәннән артып бара. Туганнан бирле мин бер генә күрдем йолыкка кеше биргәнне. Бик күптән... унбиш-уналты яшемдә. Ыруыбызның атаклы камчысы Айбаба әйтерие, ни... әшәке... аты коргыры... Октуган явыз... кешене йөз җылга бер генә сурай, диерие. Әле йөз җыл үтмәгән, ырудашлар.

Кешеләр, җиңеләеп, гөрелдәп алдылар. Майчан аксакалны яклап кычкырган тавышлар ишетелде. Утташ кам яклылар да авыз йомып тормадылар — кычкырдылар, кулларын, коралларын бутадылар. Майчан аксакал җиргә төшкәч, кызып-кайнарланып, өлкән кам яңадан сөйләргә кереште.

— Туганнар, ырудашлар! — диде.— Олуг аксакалыбызның сүзләре сезне буташтыра күрмәсен. Айбаба камчыны мин дә беләм. Белмәскә, минем үз атам, өйрәтүчем лә ул! Илгә яу-кыран килгәндә, йөз җыл тулганны көтеп торып булмый, диерие Айбаба камчы. Яу-кыранның кайчан килерен беркем алдан белми. Тагын шуны да онытмагыз, ырудашлар, канечкеч Октуганның йөз җылда эше юк. Ул үзенә тиешлесен генә сорый. Шунсыз без аның күңелен күрә алмабыз. Белегез: ыруның язмышы бу!

Тагын авыр тынлык урнашты. Тимер кораллар кулларны, иңбашларны асып төште, тимер киемнәр башларны, күкрәкләрне кысты. Күрән би изүен чишеп җибәрде, авыр кашлары астына яшеренгән авыр күз карашын кешеләргә йөртеп чыкты.

— Ырудашларым! — диде ул.— Капка төбенә яу килде. Безнең борын төбебездә генә, безнең изге җиребездә ул әнә урда корды. Җирем-суым өчен, ыруым өчен мин туган углымны гына түгел, үз-үземне дә кызганмыйм. Теләсәгез нишләтегез — углым да, үзем дә сезнең карамакта. Телисез икән — углымны, телисез икән — үземне... хатыннарымны, башка угылларымны изге эш өчен йолык кылыгыз!

— Кылырбыз да шул! — дип чәрелдәде Утташ кам, янап, куанып.

— Ашыкма, кам баба,— диде аңа каршы Күрән би.— Минем сиңа бер генә соравым бар. Син әйт безгә: йолыкка кеше биреп кенә Алмыш ханнан котыла алабызмы без?

— Йо-ок! — диделәр акбүреләр беравыздан.

— ...Без йолыкка кеше биргән өчен генә Алмыш хан үзенә тиешле каланнан баш тартырмы? — диде тагын да би.

— Йо-ок! — диделәр акбүреләр, язгы Чулман сыман шаулап.

— Шулай булгач,— диде Күрән би, күтәренкелек белән,— йолык бирү-бирмәү турында сөйләшкәнче, калан түләү-түләмәү турында сөйләшсәк, яхшырак булмасмы?

— Шула-ай! — диделәр кораллы ирләр, катауны яңгыратып.

— Алайса әйтегез: утыз мең кеш түлибезме, ягы белән орышабызмы? — диде ыру башы.

Кешеләр тагын тынып калдылар.

— Ыхым, ыхым,— диде Майчан аксакал, яңадан таягын шакылдатып.— Оланнар, ырудашлар! Утыз мең кеш безне аяктан җыкмас, ни... аты коргыры... кем... Алмыш ханның кылычы — җыгар. Эт күңеле бер сөяк. Алсын да китсен!

— Ах, бер генә сөяк булсачы! — диде Күрән би, ачынып.

Майчан аксакал сүзләрен башкалар да яклады.

— Түләргә кирәк!

— Алсын да китсен! — диештеләр кешеләр, шау-гөр килеп.

— Юк, түләмибез! — диде шул чакны кемдер, шау-шуны күмеп.

Кешеләр тавыш килгән якка — койма өстенә күтәрелеп карадылар. Сакчылардан, кораллы ирләрдән бер читтәрәк анда баштанаяк коралланган яшь бер углан басып тора иде.

— Тотыш!

— Югалган Тотыш! — диделәр акбүреләр.

Кайберәүләр моны куркып әйтте, кайберәүләр аптырап, кайберәүләр куанып әйтте. Утташ кам, үз-үзен белешмәстән тыгыз төркем арасыннан Тотыш ягына ташланды.

— Тотыгыз, тот! Аяк-кулларын бәйләгез! — дип кычкырды ул, явыз бер сөенеч белән.

Кешеләр, камга юл биреп, як-якка тайпылдылар, кайберләре, киресенчә, аның юлына аркылы төшәргә тырыштылар. Койма өстендәге кырыс сакчылар урыннарыннан кымшанмыйча басып тик тордылар.

Утташ кам килгән юнәлешкә капма-каршы яктан Тотышка таба икенче бер кеше ашыкты.

— Углым! — дип кычкырды Койтым бикә, коймага таба омтылып.

— Углым! — диде Күрән би дә, кузгалмыйча, эчке бер сагыш белән.

— Оланнар, туктагыз! — диде Майчан аксакал, тавыш, ыгы-зыгыны басмакчы булып.

Күрән би быргычыга ым какты. Күкне ярып шул чакны ачы быргы тавышы яңгырап китте.

— Сөйлә, углым! — диде Майчан аксакал Тотыш ягына таягын изәп, тынлык урнашкач.

— Сөйлә, сөйлә! — диештеләр башкалар да.

— Атам, анам! Олуг аксакал Майчан баба! Ырудашлар, ил агалары! Тыңлагыз, сезгә сүзем бар! — дип кычкырды Тотыш көр, яңгыравык тавыш белән.— Ыруыма куркыныч килүен ишетеп, мин, белексез углан, сезнең янга ашыгып кайттым. Элекке ярамаган эшләремнең барысы өчен кичерегез мине, ырудашлар!

— Кичерәбез, олан,— диде Майчан аксакал.

— Кичерәбез, кичерәбез, сөйлә! — диделәр коралллы ирләр.

— Менә шул...— диде Тотыш, яңадан сүз башламакчы булып. Тик куанычтан, дулкынланудан күрәсең, кирәкле сүзен таба алмыйча, беравык тотлыгып торгандай итте.— Күрәсезме, ырудашлар, безнең көчебез җитәрлек түгел,— дип кычкырды ул бераздан үзенең аяк астында тынып калган меңләгән кешеләргә карап.— Котан белән Акбога кайтып җитсә дә, күршеләрдән булышка алайлар килсә дә, безнең барыбер көчебез артмаячак. Безнең күбебезнең кулында уктан-җәядән башка берни юк. Киемнәр шулай ук таза, нык түгел. Карагыз болгарларга — күбәсез ирне күрерсезме, тимер калкансыз, тимер алпаксыз ирне күрерсезме? Алар нинди яхшы өйрәтелгән... шау-шу юк, ыгы-зыгы юк — мең кешесе бер кешедәй! Көч алар ягында, ырудашлар. Тик шулай да мин, утыз мең кеш түгел, ягыга бер тиен дә бирмәскә димен!

Аның бу сүзләре дөрләп янган учакка бер чиләк су сипкәндәй булды. Аста, кешеләр арасында шаркылдап көлгән тавышлар ишетелде.

— Атам, анам! Ырудашлар, туганнарым! — диде Тотыш углан, көлгән тавышларга колак салмыйча.— Моңарчы сез минем бер генә теләгемне дә үтәмәдегез. Яшьлегем, белексезлегем аркасында мин сезгә, ыруга күп кайгы салдым. Инде сезгә бер сүзем бар... бер теләгем бар: тыңлагыз! Мин Алмыш ханның иң көчле алыбы белән очрашырга телим. Мин берүзем ыру өчен ягыдан үч алырга телим! Җиңсәм, болгарлар буш кул белән китәр, җиңелсәм икән — калан түләрсез!

## IV

Акбүреләр башта аңламыйчарак тордылар. Аңлап алдылар да, кисәк кенә кузгалышып куйдылар, җиңелчә шауларга, гөрелдәргә тотындылар. Тирә-яктан:

— Яшә, Тотыш! Бай бул, Тотыш!

— Коткар ыруны, коткар катауны! — дигән сүзләр ишетелде.

Икеләнгән, каушап калган акбүреләр күңелендә Тотышның сүзләре ышаныч чаткылары кабызып җибәрде. Башлар югары күтәрелде, коралларга куллар ныграк тотынды. Әнә ул Тотыш углан, нинди таза, нинди көчле! Кем белә, җиңеп куйса, калан да түләнмәс, кешеләр дә исән калыр. Җиңелә икән инде, алай үзе атлыгып торгач, әйдә, урыны оҗмахта булыр.

Күпчелек шулай дип уйлады. Тик ата кеше генә икенче төрлерәк уйлады. Үзенең углын ул беренче тапкыр күргәндәй булды. Ул аның көче-батырлыгы белән дә, уйлары белән дә үзеннән — үз атасыннан гына түгел, мондагы барлык кешеләрдән, барлык ырудашларыннан өстен икәнлеген аңлады. Ул аны — кичәге башсыз углын — үзенең төп яклаучысы итеп тойды. Димәк, ата кешенең күңеле тоеı булган! Димәк, аңа ышаныч баглап ул ялгышмаган! Бинең күзләренә яшьләр килде.

— Углым! — диде ул, Тотышны кочагына алып.— Бүгеннән башлап син — сугышчы ир! Әй, ырудашлар, ишетәсезме, Тотыш углым минем ир булды! Мин аның теләгенә каршы килмим, мин аңа ак юл телим, җиңү телим. Орыш, углым, ягы белән, күрсәт ирлегеңне!

— Орыш ягы белән!

— Ак юл сиңа, Тотыш углан! — диделәр аксакаллар. Күрән би, углының теләген белдереп, болгарларга ук атарга кушты.

Болгарлар укны алдылар, битекне укыдылар да ат кешнәгән кебек шаркылдап көләргә тотындылар.

— Ничек көләләр бездән! — диде Тотыш, иреннәрен чәйнәп.

Күп тә үтмәде, болгарлардан икенче ук килеп төште. Каен тузына ике генә сүз язылган иде. Бу «бергә өч» дигән сүзләр иде. Акбүреләрнең йөзе каралай янып чыкты. Бергә өч! Димәк, Тотыш, бер-бер артлы өч алыпны җиңәргә тиеш, бары шул чагында гына ул җиңүче булып саналачак!

Яшь җегетнең нык кысылган иреннәре калтыранып китте. Шулай да ул куркуын тиз арада җиңә алды. Су астында озак чумып торганнан соң өскә калкып чыккан кеше сыман, ул озын итеп, күп итеп бер тын алды да:

— Мин орышам! — диде.— Мин сүземнән кайтмыйм.

— Юк! — диде Күрән би, болгарларның битеген урталай ертып.— Бу тигезлек түгел. Бу берниди йолага да, түрәгә дә туры килми. Алар бездән юри көләләр.

— Мин барыбер орышам, атай,— диде Тотыш, кабатлап.— Мин баш тартсам, алар бездән тагын да ныграк көләчәкләр.

Аның шулай дип әйтүе булды, болгарлар, күрәсең, акбүреләрнең икеләнүен күреп, тагын да ныграк шаркылдап көләргә тотындылар.

Акбүреләр аптырабрак калган бер мәлдә койма өстенә Койтым бикә килеп менде. Ул аста — кешеләр арасында тоткарланып калган иде. Инде ул түзмәде, кешеләрне ырып-җырып, туры коймага якын килде, каяндыр ирләр алып килгән күчерелмәле баскыч буенча югары менде.

— Углым! — диде ул, йөрәк түреннән чыккан бер өн белән.— Мин барысын да күреп, ишетеп тордым. Углым, күземнең яругы... бавыр итем, йөрәк маем! Бар, орыш! Мин сиңа изге теләктә булырмын. Бөтен ырудашларың изге теләктә булыр. Күп көттем мин шушы көн килүен. Үч ал ерак бабаң өчен, анаң өчен, ыруларың өчен, углым! Әнә явыз ягы безнең изге җирдә!

Койтым бикә алтын-көмешләр, тимерләр-җизләр елкылдаган, ят байраклар җилфердәгән якка төртеп күрсәтте. Аның сүзләреннән Тотыш кайбер нәрсәләрне аңлап та җитмәде. Ул бары бер генә нәрсәне аңлады — әйе, ул орышырга тиеш! Анасының ялкынлы сүзләре аның күкрәген бетмәс-төкәнмәс көч белән, куаныч белән тутырды, болгарларның икенче угыннан соң, атасының каршы килүеннән соң күңелендә баш күтәрә язган икеләнү, каушау тойгысы кул белән алгандай юкка чыкты.

— Бергә өч булуына исең китмәсен, углым,— диде Койтым бикә, аның уйларын сизенгәндәй.— Өчкә түгел, өч унга, өч йөзгә каршы чыгудан да курыкмый торган батыр бул, углым! Синең ерак бабаң Кайду алып шундый батыр булды, синең бик еракта калган ерак туганнарың барысы да шундый булдылар. Анаңның туган ыруын туздыручыдан, атаңның туган җирен басучыдан канлы үч ал, углым! Теләгем шул: куркуыңны салып тапта!

— Мин курыкмыйм, анам! — диде Тотыш, елмаеп.

— Куркуын курыкмыйсыңдыр да,— диде Күрән би, үртәлеп.— Бу — тигезлек түгел. Бу — бездән көлү!

— Син ни телисең, би? — диде Койтым бикә, иренә эндәшеп.— Ягыдан син кызгану, тигезлек, изгелек көтәсеңмени?! Ул сине таларга, үтерергә, яндырырга килгән, түбәнсенеп шуңа үпкәләргә уйлыйсыңмы?! Күтәр башыңны, күзеңне ач, Күрән би!

— Баш та каткан инде,— диде би, мыгырданып.— Әле өч көн бар, ашыкмыйк, уйлашыйк...

— Уйлашыр чак түгел — илне ягы баскан! — диде Койтым бикә, кискен генә.— Углыңны җибәрмәсәң, үзем чыгам Алмыш ханга каршы. Тик берне үтерсәм, өчкә саналырга тиеш. Җибәр укны Алмыш ягына!

Күрән би авыр башын күтәрде, көрсенеп: «Язмыш... каргыш»,— дип мыгырданды да битекчегә карап алды: «Мин орышам. Тотыш»,— дип язарга кушты.

Койма тышына тагын ук очты.

**V**

Тотышка киенергә атасы булышты. Ул аңа үзенең авыр күбәсен, нык, авыр калканын бирергә теләде. Тотыш атасының бернәрсәсен дә алмады. Ул җиңелчә генә киенергә булды. Өстенә ул иң элек юка, җиңел күлмәк, аның өстеннән кыска тунын киде. Муенына нечкә каешка тагылган кечкенә бүре башы — ыру бөтиен такты. Кыска тунның күкрәк турысына юка тимер кисәкләре тегелгән иде. Аның өс киемендәге тимер бары шул гына иде. Аннары баш киеме — алпагы тимердән иде. Алпак башыннан төшеп китмәсен өчен, ул ияк астыннан сакалдырыгын бәйләп куйды да, кысып билен буды да, кылычын такты. Шуннан соң ул бер кулына калкан, икенче кулына сөңгесен алды.

Атка атланыр алдыннан ул йөгереп койма өстенә менде, беренче тапкыр күргәндәй, як-ягына каранды; еракта көмештәй җемелдәп яткан Чулманга, татлы исләр аңкытып, ап-ак чәчәккә күмелеп утырган шомыртларга, чокырлар артындагы зәңгәрсу калкулыкларга, урманнарга күз йөртеп чыкты. Күңеленнән ул үзенең туган җире белән, үзенең барлык ыруы белән — атасы-анасы, туганнары белән саубуллашты. Ул үзенең үткән бала чагы белән, көн дә күреп өйрәнгән агач өйләр, тар урамнар, җилдә-яңгырда караеп беткән коймалар, капкалар белән, кырыс ирләр белән, зәңгәр төтеннәр белән саубуллашты.

Көн кояшлы иде, җылы иде. Кайдадыр якында гына чыр-чыр килеп кошлар очып йөри, баш өстендә көмеш шөлдер булып, тургай чыңлый иде. Тиздән менә орыш буласына, кемнәрнеңдер озакламый шушы җылыдан, киңлек, иркенлектән аерылачагына әз генә дә ышанасы килми иде. Әле кичә генә бала-чага уйнап йөргән болында, яшел бодай уҗымы җәелеп яткан киң яланда күңелләрне тетрәндереп шаулашкан ят, чит, ягы кешеләр барлыгына бөтенләй ышанасы килми иде.

Тотыш юри ул якка карамаска тырышты. Туган җирен күздән кичергәч, ул койма өстенә тезләнде дә ак болытлар күпереп йөзгән биек, зәңгәр күккә карады.

— Тәңрем! Мин, Акбүренең Тотыш атлы угланы, алыплар орышына чыгам. Миңа көч бир, кыюлык, җиңеллек бир, Тәңрем! — диде ул, ялварып.

Шуннан соң ул атасын, анасын кочты, туганнарын кочты. Алыплар орышына бар нәрсә җитеш икәнлекне белдереп, катау ягында быргы уйнадылар. Болгарлар да, шуны ук аңлатып, җавап бирделәр.

Шуннан соң ике якта да, йөрәкләрне җилкендереп, берьюлы унлап-унбишләп дөңгер кагарга тотындылар.

Менә ашыкмыйча гына ур өстенә күпер төшә башлады, капкалар ачылды, тешкә тиеп чыгырлар шыгырдады, тимер күгәннәр ыңгырашты. Тотыш Ташбәкәлнең тезгенен бушайтып җибәрде, күләгәле капка авызына чабып керде дә кояшлы ачык җиргә — яланга ыргылды.

Ул туп-туры хан чатырына таба карап чапты. Иң элек ул үзе белән орышачак алыпны күрмәкче булды, тик каршыда урмандай калкып торган ир-атлардан башка, аллы-зәңгәрле-сарылы ефәк чатырдан башка бүтән берни күрмәде. Бер җиргә тупланган шултикле күп кешеләрнең тере, усал, кызыксынучан күз карашларын тою аны чак-чак кына каушаткандай булды.

Шул чакта ул сөңгеләр, алпаклар, калканнар урманыннан аерылып, үзенә таба якынлашып килгән болгар алыбын күреп алды. Болгарларның бу иң атаклы батырлары Чәкән алпагыт[1] иде.

Чәкән алпагыт богадай таза, арыслandай көчле иде. Баштанаяк ул тимергә төренгән, шуңа күрә аның сөңге, кылыч үтәрдәй бер генә йомшак җире дә юктыр кебек иде. Үзенең таза, көр кола атында ул таштан уеп ясалган баганадай нык утыра иде. Ул киң битле, зур башлы иде. Күп орышларда бите-башы яраланып, ямьсезләнеп беткән бу усал, кансыз, коточкыч алпагыт турында, кылыч белән бер сукса, тимер киемле кешене урталай ярып төшерә, дип сөйлиләр иде. Аның белән орышкан бер генә батырның да әле исән калганы юк, дигән сүзләр дә йөри иде.

Чәкән алпагыт янында Тотыш углан бала-чага кебек кенә күренә иде. Буйга да ул аннан кайтышрак, киеме дә, кораллары да батырларныкына охшамаган кебек иде. Болгарлар аның йөзендәге кырыслыгын да, күзләрендәге очкынлы ярсуын да, киеме аша бүртеп торган беләк тычканнарын да күрә алмадылар. Алар бары аның яшь, җиңел... өтәләнгән булуын гына күрделәр. Алар аннан эчләрен тотып көләргә тотындылар. Чәкән алпагыт, гыжылдавык бер ямьсез тавыш белән:

— Әй, син, Камырбатыр! Бар, кайтып кит. Синнән өлкәнрәге килсен! — дип кычкырды.

Тотыш эндәшмәде. Аның бары иреннәре генә ныграк кысылды да куллары гына чытырдатып коралларын тотты. Күк күкрәгәндәй булып яңгыраган көлү тавышларын, йөзенә бәреп әйтелгән мыскыл сүзләрен ул әйтерсең ишетмәде дә. Чиксез ачу, үч тойгысы аңа көч бирде, корычтай ныклык бирде.

«Ананның туган ыруын туздыручыдан, атаңның туган җирен басучыдан канлы үч ал, углым! Теләгем шул: куркуыңны салып тапта!» — диде Койтым бикә аның колак төбендә, пышылдап, изге орышка өндәп.

**VI**

Алар шулай икесе дә бер-берсенә капма-каршы чабып килделәр. Атлар, арт аякларына басып, усал итеп кешнәп җибәрделәр. Чәкән алпагыт, сары тешләрен ыржайтып, җиңел генә, шаярткан кебек кенә сөңгесе белән төртеп алды. Сөңге башы шыгырдатып Тотышның тимер калканын тишеп чыкты. Егет агарынып китте. Тиз генә ул калканын тартып алды. Ташбәкәлнең корсагына төртте дә читкә ташланды. Чәкән алпагытның артына чыгып, ул аны узып китте. Шуннан соң кырт кына кире борылды, сөңге ыргытмакчы булды, тик каршыда гына болгар алыбының ямьсез, коточкыч йөзен күреп, каушап калды.

Ике батыр тагын да беравык бер-берсенә карашып торгандай иттеләр. Чәкән алпагыт, «сәләмә» батырны бер селтәнүдә сөңге очына элә алмавына ачуы килеп, күрәсең, монысында чынлабрак орды. Ул бик тиз, бик туры төбәде. Ул бик каты бәрде. Яшь җегет шулай да аның сөңгесеннән өлгеррәк булып чыкты. Күкрәгенә очлы тимер килеп керде дигәндә генә ул, ияреннән шуышып, уңга ташланды. Башы белән аяк астына егылып төшмәс өчен, кулындагы сөңге сабын җиргә төртеп алды да, җилдәй выжлап, тагын алпагытны узып китте. Бераз җир чабып баргач, ул җиңел генә ияренә утырды, өзәңгеләргә ныгытып басты, борылды да аткан уктай Чәкән алпагытка таба томырылды.

Аның бу күз иярмәс җитезлеген ике якта да күреп алдылар. Акбүреләр куанып гүелдәргә тотынды.

Икенче тапкыр оятка калу Чәкән алпагытны чын-чынлап котыртып җибәрде. Ияреннән калка төшеп, атының башы өстеннән үрелеп, ул, кыя таудан ычкынып киткән иләмсез зур таш кисәге сыман, Тотыш өстенә килә башлады. Күзен кан баскан усал үгез кебек дулап, үкереп килде. Монысында ул Тотышның үзен генә түгел, әйтерсең аты-ние белән бергә күтәреп ормакчы булды.

Шулай да ора алмады... Тотыш углан үзенә төбәлгән сөңгене калканы белән читкә тайпылдырып җибәрде. Карап торучылар таң калып, тагын гөрләп алдылар. Болгарлар ягында инде җиңелчә генә киенгән яшь җегеттән көләргә беркем батырчылык итмәде. Киресенчә, аның менә шулай җиңелчә киемле булуы, яшьлеге, өлгерлеге аларның күңелендә чын-чынлап соклану тойгысы тудырды.

Өченче кат буш сөңге тотып калган Чәкән алпагыт, ачуына булашып, күрәсең, онытылыбрак китте. Кирәк чакта ул атын борып өлгермәде — аты аны ераккарак алып чапты. Ике яктагы кешеләр, әле генә булган очрашу күренешеннән айный алмыйча торганда, Тотыш углан беркемнең башына килмәгән, көтелмәгән бер җегетлек эшләде. Үзенә төбәлгән сөңге башын читкә тайпылдырып, Чәкән алпагытны

узып киткәч ул атын борып тормады: сикереп кинәт иyргә басты, артына борылды... борылды да күз ачып йомган арада, сөңгесен ераклаша барган җайдакка тондырды. Туры ыргытылган саллы сөңге, тимер киемне, тимер-сөякләрне җимереп, киң арканы үтә-сүтә тишеп керде.

Үз көченә, үзенең үлемсезлегенә нык ышанган Чәкән алпагыт сөрлегеп китте, тезгенен тартып, атын кире борды. Күкрәген тишеп чыккан очлы тимерне кысып тоткан килеш, ул көчәнеп беравык иyр өстендә утыргандай итте дә, барлык авыр киемнәре, кораллары белән гөрселдәп, ишелеп җиргә төште. Аты туктады, куркынган зур күзләрен уйнатып, кызганыч тавыш белән кешнәп җибәрде. Җайдакның калканы доңгырдап читкә тәгәрәде, алпагы яртылаш туфракка буялды.

Акбүреләр ду килеп шауларга тотындылар.

Ул арада Тотыш углан, сөенеченнән очынып, катау ягына чабып килде. Тузан туздырып, баш очында сөңгесен уйнатып, яңадан хан чатырына якынлашты.

— Әй, хан, чыгар икенче батырыңны! — дип кычкырды ул.

Яңа орыш башланганлыгын белдереп тагын быргылар кычкырды, тагын дөңгерләр дөпелдәде. Киң чатыр артыннан яланга Будрач сукман[1] килеп чыкты.

Будрач сукман Алмыш ханның Чәкән алпагыттан кала икенче батыры иде. Чәкән алпагыт үзенең коточкыч көче, кансызлыгы белән, ат өстендә яхшы орышуы белән танылган булса, Будрач сукман икенче яктан атаклы иде. Ул чирмеш иде, урман кешесе иде, шуңа аңа беркем каршы тора алмый иде. Тотыш белән Чәкән алпагытның орышын күзәтеп утырган Алмыш хан яшь җегетнең көчле якларын да, йомшак якларын да тиз арада төшенеп алды. Аның иң зур өстенлеге җиңеллек булса, иң йомшак ягы да шул ук җиңеллек иде. «Җәяүлегә каршы торып карасын әле!» — дип уйлады хан, үзалдына көлемсерәп.

— Мин кылыч белән орышам! — диде Будрач сукман.

Тотыш берни әйтмәде, атыннан сикереп төште дә, сөңгесен җиргә кадады, кылычын кыныдан алды. Ташбәкәл, иясе өчен пошынган сыман, кыска гына итеп кешнәп куйды, теләр-теләмәс кенә катау ягына юыртты.

Ак чырайлы, саргылт кашлы Будрач сукман буйга калку түгел иде. Ул бик таза, нык, авыр сөякле иде. Чәкән алпагыт кебек, ул да баштанаяк тимергә төренгән иде. Аның да кылыч үтәрдәй бер генә йомшак җире дә юк шикелле иде.

Батырлар, бер-берсен сынап, күзгә-күз карашып тордылар да, икесе дә берьюлы кузгалып куйдылар, таптанып алдылар, кылычларын селтәп, ярсып шундук орышка да ташландылар.

Карар күзгә таш тутырылган капчык сыман авыр күренсә дә, Алмыш хан батыры да бик җитез, өлгер кыланды — андый җитезлекне, өлгерлекне Тотыш аннан бөтенләй көтмәгән иде. Будрач сукманның кулында кылыч уйнап кына торды. Тотыш, кысрыклауга чыдый алмыйча, әкренләп-әкренләп чигенә барды. Будрач исә, яшь җегеткә тын алырга да ирек бирмичә, шулай кысрыклап килде-килде дә, кинәт кылычын ике куллап тотып, бар көченә орды. Шундый иттереп орды — кылыч астында кеше түгел, таш булса, таш та урталай ярылып чыккан булыр иде! Тотыш ярылмады — җиргә егылды. Карап торучылар аһ итеп җибәрделәр. Сөенергәме, сөенмәскәме икәнлеген әлегә беркем белмәде. Нык селтәнгән кылычның яртылаш диярлек җиргә батканлыгын, яшь җегетнең үлемгә кыл арасы гына торып калганлыгын күргәч, акбүреләр дә, болгарлар да күкрәк тутырып тын алдылар.

Тотыш аягына басты, чирмеш алып ташланганчы, тиз арада кылычын, калканын ипләде, артка чигенде. Шул ук мәлдә аның күз алдына Тәңкә күренеп китте. Беренче төнне аның белән куышуы исенә төште. Яшьтәшләре белән куышлы, качышлы уйнаганда әле йөгереп, әле туктап, егылып калу, читкә тайпылу, шулай итеп, куучыны алҗытып бетерү алымын яхшы белсә дә, хәзер аңа бу ниндидер яңалык булып тоелды. Кылычын күтәреп Будрач сукман яңадан өстенә килә башлагач, ул тиз генә читкә сикерде. Ул моны берничә тапкыр кабатлады. Будрач кызып китте. Тотыш угланны ул туктаусыз эзәрлекләвендә булды. Тотыш исә әле башын иеп калды, әле йөгереп китте, йә булмаса, болгар батырының артына чыгарга итеп карады. Уңга-сулга боргалану тимер киемле кешегә шактый авырга туры килде. Яшь җегетнең нишләргә чамалавын ул бик яхшы аңлады, шулай да берни эшли алмады — Тотыш углан тиен кебек җитез, тиен кебек җиңел, тиен кебек тешле, усал иде.

Шулай мачы белән сычкан шикелле куышкан арада, Будрач сукман Тотыш угланның кая, ничек тайпылачагын алдан ук чамалап, тагын бер тапкыр — монысында инде соңгы тапкыр! — кизәнергә булды. Читкә киткән җегет исенә килеп өлгергәнче, ул аның артыннан килеп тә басты, кылыч сабын тагын ике куллап тоткан килеш, бар көченә селтәнеп тә җибәрде. Монысында ул өстән аска түгел, кыйгачлап, уңнан сулга таба селтәде. Чалгы белән печән чапкандагы кебек, ул Тотышны кай төшеннән генә булса да урталай кыеп төшермәкче булды.

Тик ул Будрач сукман уйлаганча уңга да, сулга да тайпылмады, ул туп-туры аның аяк астына ташланды. Үткер кылыч аның баш өстеннән ыжгырып үтте. Алмыш ханның икенче батыры, кылычы артыннан ияреп, баскан урынында әйләнгәндәй итте. Шул ук мәлдә бөтен яланны тутырып, йөрәк ачысы белән:

— А-а-а-а! — дип кычкырып җибәрде.

Тотыш кулындагы үткер тимер астан, корсак турысыннан сабынача йомшак иткә батып керде, эчәкләрне, бөер-бавырларны кисеп үтеп, күкрәгенә таба шуышты. Сукман кулындагы кылыч, калкан чыңлап җиргә төште. Ак чырайлы, саргылт кашлы чирмеш алып, авызын ачып, ашыгып тын суыра-суыра, баганадай артка ауды.

**VII**

Берьюлы ике батырыннан колак каккан Алмыш хан, Тотыш угланга тын алырга да ирек бирмичә, өченче кешесен чыгарды. Монысы Корыч-Тимер дип аталган яшь, чибәр алып иде. Ул Алмыш ханның чыбык очы туганы булып Алып-Тархан белән сөекле углы иде. Ул да болгарлар арасында атаклы алыплардан санала иде. Ул инде күп кенә яуларда булган, орышларда катнашкан, җиңгән, бүләкләр алган иде. Тотыш углан кебек, ул да җиңелчә генә киенгән иде.

— Мин дә кылыч белән орышам! — диде ул, ялан уртасына чыккач.

Батырларның кара-каршы килеп басулары булды, быргыларның чинарга тотынуы булды, шундук орыш башланып та китте. Яшен чаткылары чыгарып, тиз арада кылыч йөзләре чәкәшергә тотынды.

Тотыш углан беренче адымыннан ук ялгыш җибәрде. Будрач сукманны этләгән кебек, Корыч-Тимерне дә этләргә, алҗытырга чамалады. Тик болгар батыры аның бу алымын аңлап, өйрәнеп өлгергән иде инде. Шуның өстенә, Тотыш кебек үк, ул да бик җиңел сөякле иде, шуның өстенә ул әле әз генә дә көчен түкмәгән иде. Корыч-Тимер Тотыш угланнан бер адым да калышмады. Акбүре батыры нәрсә эшләсә, ул да шуны эшләде, ул кая тайпылса, ул да шунда тайпылды, йә булмаса, аның алдарга чамалавын сизеп, шундук аның юлына аркылы төште. Тотышка ул күтәрелеп карарга да ирек бирмәде.

Тотыш ярсый башлады. Нинди дә булса яңа нәрсә уйлап табарга аның башы җитмәде — күз алдында ялт-йолт килгән кылыч йөзе торган саен аның эчен пошырды, ачуын китерде. Ул яңадан анасының сүзләрен исенә төшерде. Тәңкәне исенә төшерде, тик инде берни дә аңа баштагы өстенлекне, салкын канлылыкны кайтара алмады.

Көтмәгәндә ул нәрсәгәдер абынып китте. Шул чагында Корыч-Тимер ач бүредәй аның өстенә ташланды. Аның кылычы Тотыш кулындагы калкан читен уеп төшерде, сул як беләкне кисеп керде дә, сөяккә җитеп, төртелеп калды. Тотыш углан чайкалып китте. «Беттем»,— диде ул үз-үзенә, бик тыныч кына, бөтенләй чит кеше турында уйлаган кебек. Булган бар көчен, ярсуын бер учка туплап, ул Корыч-Тимернең ияк астына, муен турысына орды. Болгар алыбы башын иеп өлгерде, бары тимер алпак өсте генә сыдырылып китте дә, киселгән беләктән, киемнәрне кызылга буяп, кайнар кан агарга тотынды. Шул ук мәлдә яшь җегетнең күңеленә: «Бетәм!» — дигән икенче уй килде. Бар нәрсәне онытып, ул канлы ярасын кысып тотты.

Корыч-Тимер куанып ырылдап җибәрде, бер селтәүдә Тотышны юк итмәкче булып, Будрач сукман сыман кылычын ике куллап югары күтәрде. Ярасы белән мавыккан Тотыш угланга яңадан көрәш тойгысы, каршы тору тойгысы кайтты. Үткер кылыч үзенең муенын чабып өлгергәнче ул җиргә егылып калды. Тик монысында ул баягыча ягының эчен айкый алмады. Ярасын ычкындырмаган килеш, сырты белән җиргә терәлеп яткан килеш, ул аңа бары кушаяклап тибеп кенә җибәрә алды. Авыртуга түзә алмыйча, болгар батыры чинап җибәрде, җиргә барып төште.

Җирдән алар икесе дә бер үк мәлдә сикереп тордылар. Тордылар да...

Тотышның уң кулы буш түгел иде. Тотышның кулында корал юк иде.

— Ы-ы-ы! — дип үкерде кара мыеклы чибәр алып, куанычыннан нишләргә белмичә.

Ул инде орган да булыр иде, урталай кискән дә булыр иде. Корыч-Тимернең үкерүеннән дә көчлерәк булып, көтмәгәндә әйтерсең күк күкрәп җибәрде.

— Тукта! — дип кычкырды кемдер аның артында гына.

Ирексездән ул туктап калды, артына борылды. Аның каршысында таудай булып Алмыш хан калкып тора иде.

— Тукта! — диде хан, кабатлап.— Син җиңдең!

Чибәр алыпның чибәр мыек очы тартышып куйды. Шулай да ул коралсыз Тотыш углан янына килде, янап:

— Җыгыл! — диде.

Үзенең җиңгәнлеген белдереп, ул кызыл итеге белән аның күкрәгенә басты, кылычын итек башы янына терәде. Сөңгеләр, алпаклар урманы шауларга тотынды. Акбүреләр, караларына коелып, беравык аңламыйчарак тордылар да, барысы берьюлы диярлек кычкырып җыларга тотындылар.

Тотыш җиңелде, Акбүре җиңелде. Нәрсә карап тордың, Тәңрем? Кайда булдыгыз, изге ияләр?! Тотыш җиңелде...

Җиңелде... Ул күзләрен ачты, үзенең борын төбендә генә җирәнгеч итек башын күрде, итек башы янында, үзенең бугазына якын төштә коточкыч салкын тимерне күрде. Тимер дә тик тора, итек тә кузгалмый. Тын алуы шундый авыр!

Җиңелсә дә, ул әле исән бугай. Әнә ул уйлый, күрә...

Ул җиңелде... Ах, нинди кыен, нинди оят очлы тимер белән итек табаны астында тын алып, күреп, уйлап яту!

## VIII

Орыш төкәнде. Языга[1] үлек күмүчеләр чыкты. Кан, тузан эчендә аунап яткан Чәкән белән Будрачны алар күтәреп алдылар, арбага салып, каядыр алып киттеләр.

Күмүчеләрдән соң, орыш урынына имчеләр чыкты. Алар яралы Тотыш янына килделәр, аның киселгән беләген карадылар; яраны яхшылап салкын су белән юдылар да киселгән иткә яра ташы кырып салдылар, шуннан соң беләкне ныгытып бәйләп куйдылар. Шул эшләрне башкаргач, төсе качып, агарынган яшь җегетне кабыкка салдылар, күтәреп шулай ук аны да каядыр алып киттеләр.

Ике як арасында кыскача гына сөйләшү булып алды. Күрән би Алмыш ханның катау янындагы яланнан үзе урда корган җиргә — Тәкәшүр болынына кайтып китүен теләде. Тиешле бурычны дүрт көндә үзем илтеп түләрмен, диде. Алмыш хан үз чирүенә шундук кире борылырга боерык бирде. Болгарлар, тузан туздырып, әкрен генә чигенә башладылар.

Тотыш углан көн ягына алып китәргә тиешле товарлар Талкысыкта тукталып калган иде. Күрән би андагы барлык байлыкны, кешеләрне кире катауга кайтартты. Инде каядыр җир читенә аркыш җибәрүнең дә, кемнәр беләндер сату-алуның да беркемгә кирәге юк иде. Ул җиңелде. Бетте. Бер теләге дә тормышка ашмады. Эх, эчендә нидер шулай борып авыртмаса да, алай ук кыен булмас иде! Бетте. Аны әйтерсең урталай бөгеп ташладылар, аны әйтерсең кисәкләргә өзгәләп ташладылар — бер өлеше тегеләр ягында калды, бер өлеше менә бу якта. Соңгы ышанычы — Тотыш углы да аның теләкләрен аклый алмады. Юк, ул үзен чын ир итеп, алып ир итеп күрсәтте, шулай да аннан ни файда?

Кич катауга Котан белән Акбога кайтып төште. Акбүреләр күбәеп киттеләр. Кешеләрнең күңелләре күтәрелде. Яу килгәндә читтә калган ирләр, калан түләмичә, төнлә болгарларны барып басарга, бөтен ояларын туздырырга кирәк, диделәр. Ыру башы кул гына селтәде. Аның инде бернәрсәгә кулы бармады, бернәрсәгә кыюлыгы җитмәде.

Икенче көнне иртүк катаудан болгарларга калан өчен бер көтү сарык озатылды — җиңүчеләргә иртәнге ашка ит булды. Шуннан соң Басу-капкадан бер-бер артлы олаулар агыла башлады. Изге алан авызы янында аларны болгар кешеләре каршы алдылар, хан урдасына тикле озата бардылар. Алмыш ханның теркәүчеләре, агычылары тиреләрне, күннәрне, балларны, чүлмәк савыт-сабаны, ашлыкны җентекләп карап, тикшереп алдылар. Бозылган, ертылган, тишелгән нәрсәләр кире кайтарылды, алынганын санап, аерым такталарга язып бардылар. Алынган байлык өчен акбүреләргә тамгалы язу бирделәр.

Ике көн эчендә акбүреләрнең бурычы тулысынча түләнеп бетте. Сыгылып торган киштәләр яңадан турайды, амбарлар бушап, иркенәеп калды. Агычылар авыр, калын ишекләрне иңеләй ачып җибәрделәр. Эт, бүре башы төсле итеп ясалган зур йозаклар, авызларын ачып, ишек кылдауларында эленеп калдылар. Бер почмактан икенче почмакка шыр идән буйлап күселәр йөгереп узды. Билләренә алъяпкыч бәйләгән чуралар, бик эшлекле кыланып, чүпле идәннәрне, амбар алларын себерделәр, шунда ук чыр-чу килеп чыпчыклар чүпләнде.

Әйе, амбарлар бушап калды. Амбарлар белән бергә Күрән бинең күңеле дә бушап калды. Ул нәрсә уйларга да, нәрсәгә барып тотынырга да белмәде. Анда сугылып, монда сугылып йөргәч, ул Басу-капка ягына юнәлде. Соңгы олаучының кайтуын ул койма өстендә көтеп торды, хан теркәүчеләре биргән тамгалы язуны күздән кичерде.

— Тотыш турында әле дә берни ишетелмиме? — диде ул олаучыга.

— Юк, беркем берни белми,— диде олаучы.— Алар безнең белән җүнләп сөйләшмиләр дә.

Би артык сораштырып тормады, атына атланды да урдага кайтып китте. Җиңелүе, амбарларның бушап калуы өчен күңелен игәгән кайгысы йомшарга да өлгермәде, аны инде яраланып теге якта калган углы өчен борчу тынычсызлый башлады. Ни булды аңа? Ник бирми аны Алмыш хан? Үлмәде ич ул! Үлсә, аны шундук кире бирерләр иде. Яраланды, аны имчеләр алып китте. Шулай булгач... барып сорарга, ягы алдында баш ияргә туры килер микәнни?

Үз урдасына якынлашып килгәндә, аны арттан бер җайдак куып җитте.

— Алмыш ханнан илчеләр килгән, би. Катауга кертүне сорыйлар,— диде җайдак.

— Илчеләр түгелдер алар, шымчылардыр,— диде би.— Теләнчегә көлә карасаң, ямаулык сорар. Тагын ни кирәк аларга?

Ул тун күнчелегендәге тамгалы язуларны яңадан карарга, бармакларын бөгеп, түләнгән каланның күпме чыгуын яңадан санарга тотынды. Бер тиен артык түгел, бер тиен ким түгел! Чыннан да, ни кирәк аларга? Ул кире капка ягына борылды.

Капка каршында, урлар артында атка атланган өч ир тора иде. Койма өстенә менгән бине күргәч тә алар, ягымлы кыланып, баш иделәр, үзләрен катауга кертүне сорадылар.

— Сезне түгел, сезнең ханыгызны да мин катауга кертмәдем,— диде би, кукыраеп, тупас кына.— Минем колак ерактан да ишетә. Әйтегез, ни йомыш?

— Безнең йомышны капка төбендә әйтмиләр, өйгә барып әйтәләр,— диде илчеләрнең берсе.

— Сез болай да минем өемдә,— диде Күрән би.

Илчеләр, бер-берсенә карашып, киңәшеп алдылар.

— Алайса, тыңла, Күрән би,— диде ак сакаллы карт, алгарак чыгып.— Болгар йортның башы Алмыш хан...

— Юк, Хазар йортның, изге каганның колы... Болгар йортның башы...— дип төзәтте Күрән би.

Илченең йөзе бозылып китте. Ул тагын үзенең юлдашларына карап алды да, өзелгән сүзен ялгап:

— ...Болгар йортның башы Алмыш хан сине, Акбүре ыруының башы Күрән би, хатыннарың, балаларың, туган-тумачаларың, якыннарың белән ашка чакыра.

— Миннән талап алган байлыгын күрсәтергәме? — диде би, усал итеп.

Ул үзенең илчеләр белән алай тупас сөйләшмәскә тиешлеген бик яхшы аңлады, шулай да берни эшли алмады. Әкренләп-әкренләп аның күңелендә бар нәрсәнең астын өскә китерә алырлык ачу-ярсу тойгысы кабара барды. Үзенең җиңелүе өчен ул әйтерсең илчеләрдән үч алырга җыена иде.

Аның тупаслыгына илчеләрнең ачуы килде.

— Күрән бине башлы, белекле дип сөйләгәннәрие чын булмады бу,— диде илче карт.— Илчегә үлем юк. Без сиңа әйтергә кушылганны гына әйттек. Әйтү бездән, тыңлау-тыңламау — синнән. Алмыш хан синең белән татулашырга тели. Монысын да әйтергә боердылар. Сау бул, Күрән би.

— Сау булыгыз,— диде би, теләр-теләмәс кенә.

Илчеләр, атларын борып, ашыкмыйча гына китеп бардылар. Алар көнбатышка таба, урман артында кечерәя барган кызыл-саргылт кояшка каршы киттеләр. Аларның алгы яклары, ян-яклары утлы күз төсле кып-кызыл булып, аркалары кап-кара булып күренде. Артларыннан әз генә дә калышмыйча, иләмсез зур күләгәләре сөйрәлеп барды.

Илчеләр китеп баргач, бинең тагын эче поша башлады. Илчеләрдән Тотыш турында сорарга башына килмәве өчен ул үз-үзен тиргәп ташлады. Аннары ул үзеннән талап алган икмәк белән үзен сыйларга җыенган Алмыш ханны, башлаган эшен җиренә җиткермичә кайтып киткән Ямгырчы бине сүкте. Шуннан соң ул бер дә юктан башын чайкап, авызлык тимерләрен чылтыраткан атын сүкте. Башка сүгәр нәрсә табылмады. «Тәңренең каргышы... Картайдым, беттем...» — дип уйлады ул, авыр сулап, караңгы бер төшенкелеккә бирелеп.

Кичке ашны, башка көннәрдәгечә, «ак өй» дип йөртелгән зур өйдә ашадылар. Ашка аның хатыннары, өлкән балалары, туганнары — барлыгы утызлап кеше җыелды. Барысы да үзләрен үлек чыккандагы кебек кыен, уңайсыз сизделәр. Сөйләшми генә ашадылар, сөйләшми генә таралыштылар. Койтым бикә ашка бөтенләй килмәгән иде. Аны чирләп урында ята диделәр.

Аштан соң би Койтым бикә өенә юнәлде. Бикә, башын юеш сөлге белән урап, таудай өелгән мендәрләр, йомшак тиреләр өстендә ятып тора иде.

— Белештеңме, исәнме, үлеме? — диде бикә, беренче сүзе итеп.

— Кай җирең авырта? — диде би аңа.

— Мин синнән Тотышны сорыйм,— диде бикә, ыңгырашып.— Углың бүре базында калсын да, ничек таза булмак кирәк?!

— Шул гынамыни? — диде би, юри исе китмәгән сыман.

— Тагын ни? — диде бикә, башын калкытып.— Тире, күн? Бал? Утыз мең кешне син бер кышта табасың, югалган углыңны табарсыңмы?

— Югалмаган,— диде би, шул ук ялган бер пошмаучанлык белән.— Күреп тордың ич: имчеләр бәйләделәр, алып киттеләр. Беркая булмас.

— Шымчы җибәрергә кирәк — барсын, күрсен, сөйләшсен,— диде бикә.

— Шымчы? — диде би.— Әлерәк кенә Алмыш ханнан илчеләрме, шымчылармы килде. Безне ашка чакырган, керген!

Койтым бикә, күзләрен зур ачып, аягына торып басты, башындагы сөлгесен атып бәрде.

— Син аларны борып җибәрдеңме?! — диде ул.

— Җибәрдем,— диде би.

— Кайчагында син минем эшемә кысыласың, би,— диде бикә, кызып.— Ашка чакырганнар икән, иң элек минем белән киңәшергәе. Барасыңмы? Бармыйсың? Үзем китәм!

— Үзең?!

— Үзем! — диде бикә, нык итеп.— Углым янына! Сакчылар бир. Җә Алмыш ханның канын коеп, углымны үзем белән алып кайтам, җә углым янында торып калам.

— Син беркая бармыйсың! — диде би, хатынының юлына аркылы төшеп.

— Үз углым янына барудан мине беркем тыялмас,— диде бикә.

**IX**

Атаклы ике батырыннан колак какса да, акбүреләр белән очрашуның шулай тиз генә, җиңел генә төкәнүенә Алмыш хан сөенми булдыра алмады. Ул җиңде, бөтенләй диярлек кан коймыйча, туздырмыйча-яндырмыйча җиңде. Мондый җиңүләр еш булмый, мондый җиңү теләсә кем кулыннан килми. Менә аның килеп күренүе булды, дошман, куркып, коты алынып, шундук бил бөкте. Күрдегезме, Алмыш ханның көчен, явыз күршеләр — суарлар, биләрләр?! Күрдегезме болгарларның кемлеген чит ил кешеләре,— илчеләр, сатучылар?!

Алмыш ханның барысына да шулай дип әйтәсе килде, кычкырасы килде. Сөенечтән, масаюдан күзе томаланып ул икенче көнне үк олы җиңүгә багышлап олы туй ясарга булды.

Акбүреләрнең соңгы олавы урдага килеп җиткәндә, көтүчеләр урман буендагы болыннан һай-һулап бер көтү җылкы куып кайттылар. Сугымчылар атларны тота тордылар, тотылган берсен суя тордылар. Шунда ук тиресен тунадылар, эчен алдылар, юан бүкәннәргә салып, җылы итне чаба тордылар.

Чулман ярына килеп терәлә торган ике сырт арасындагы киң болын өстендә, әле анда, әле монда учаклар кабынды. Кычкырып көлгән, җырлаган тавышлар ишетелде. Болын уртасында түгәрәкләнеп тезелеп утырган йөзләрчә ак өйләр арасында кораллы, коралсыз кешеләр кайнашты. Кешеләрнең аяк астында иснәнеп этләр чабышып йөрде.Урдадан читтә, урман буйларында, койрыкларын селтәп, бер-берсенә сыенып, йә булмаса, үзара ызгышып, иксез-чиксез күп атлар утлап йөрде. Юл өстендә, урман буйларында, Чулман ярында, ханның, чирүнең тынычлыгын саклап, каравыллар кизү торды.

Менә тиздән караңгы да төшә башлады. Көнбатыш яктагы урман читенә үкәлеп-ягылып калган кызыллык кай арададыр төтендәй очып юкка чыкты. Ерактагы урманнар, караеп, болынга, кешеләргә таба якынрак күченделәр. Тәкәшүр болынының Чулман ягында, бик зур болыт сыман булып, аксыл томан күтәрелде. Тирә-якны салкынча эңгер-меңгер чорнап алды. Үзләренең вак-төяк эшләре белән ыгы-зыгы килгән җир кешеләренә күктән җем-җем итеп йолдызлар күз кыстылар, бармак янадылар.

Авыр, озын юлдан соң, төрле кыенлыклардан соң болгарлар беренче тапкыр тынычлап, иркенләп туй иттеләр: туйганчы ашадылар, исергәнче эчтеләр, күңелләре булганчы җырладылар, биеделәр.

Шау-шу, җыр-бию, уен-көлке төне буена тукталып тормады. Учакларда утлар янды, учакларда итләр пеште. Дөпелдәгән, тыпырдаган аяклар астында мәңге тыныч, мәңге бөек җир йокымсырап ятты. Якында гына кешеләрнең кайгысын да, куанычын да... каннарын да, сөяк-санакларын да бик күп күргән, бик күп юган мәңге тере, мәңге бөек Чулман акты.

Чулман буеның чык каплаган яшел болынында, бер-бер артлы килеп юкка чыккан санаусыз җәйләрнең берсендә, санаусыз төннәрнең берсендә җиңүчеләр туй иттеләр...

Алмыш ханның мең кеше сыйдырышлы өендә аш-су башкаларныкына караганда да күңеллерәк, шау-шулырак булды.

Өй эчтән икегә бүленгән иде. Түгәрәк өйнең ишектән кергәч тә уң ягын — кечерәк өлешен хатын-кызлар били иде, бөтен өй эченең дүрттән өч өлешен алып торган сул ягы ханның үзенеке, ирләрнеке санала иде. Монда хан үзенә килгән кешеләр белән, кунаклар белән очраша, шунда ук аш-сулар, төрле уеннар, күңел ачулар уздыра иде. Зур якның урта бер җирендәрәк, бөтен өйне тотып торган биек терәктән арырак төрле төстәге ефәкләрдән баш өстенә киң чыбылдык корылган иде. Чыбылдык астына бай келәмнәр җәелгән җир идәндә, сырлап, алтынлап бизәлгән биек тәхет утыртып куелган иде.

Тәхетнең утыра торган җиренә рум ефәге капланган иде.

Шулай итеп, чакырылган кунак килмәде. Килмәсә килмәс! Кешеләр дә, кунаклар да ялыгып бетте — башларга кирәк.

Башына каурыйлы ак чалма ураган Алмыш хан, исле май исләре аңкытып, билбавындагы алтын-көмешләрен елтыратып, эчкәре бүлмәдән кунак бүлмәсенә — зур якка чыкты. Бераз гына калышып аның артыннан Айкын хатын чыкты. Бераздан өйгә хан-агасы[1] белән биләр, карачылар, башка кунаклар керә башлады.

Алмыш хан, йомшак итекләре белән йомшак кына басып, тәхет янына килде, якасына, изүенә кеш тиресе тотылган, эре бизәкле күк ефәк белән тышланган тун итәкләрен җыештырып, биек урынга утырды.

Ханның сул ягына, түбәнгәрәк, келәм өстендәге йомшак мендәргә аякларын бөкләп, Айкын хатын утырды. Ире кебек ул да озын буйлы, таза, симез бер хатын иде. Аның өс-баш киемендә, кулларында — әле анда, әле монда, күк йөзендәге йолдызлар төсле булып, чын ташлар җемелдәшә иде. Тары бөртегедәй утлы ташлар аның өс-баш киемнәрендә генә түгел, каюлы йомшак читек табаннарына да тегелгән иде — аякларын бөкләп утыргач, ул ташлар ялт-йолт килә башладылар.

Башына ул ас тотылган очлы бүрек кигән иде. Бүрек астыннан чыгып торган ак, матур колак очларында энҗе ташлы авыр алкалар тирбәлә иде.

Ханның уң ягына биләр утырды, сул ягына, Айкын хатыннан бераз читтәрәк, бөтен бер оя булып, Хәрәзем илчесе белән чит ил сатучылары урнашты. Тәхет алдына, өй уртасындагы терәккә табарак, зур бер төркем булып, Алмыш ханның унлап баласы — ир угланнар, кыз угланнар урнашты. Ханның башка якыннары — туган-тумачалары, алыплары, аксакаллары — барысы да үзләренә тиешле, билгеле урыннарына утырдылар.

Кунакларның күпчелеге ирләр иде. Арада хатын-кызлар да, яшьләр дә, картлар да бар иде. Аларның барысы да күзнең явын алырдай ачык төстәге, төрле төстәге озын киемнәр кигәннәр, барысы да йомшак урыннарга аякларын бөкләп утырганнар иде. Алмыш хан белән Айкын хатыннан кала барлык кешеләр яланбаш иде — очлы бүрекләре, калпаклары култык астына кыстырылган йә булмаса тез өстенә куелган иде. Ирләрнең кайберсенең чәчләре такыр итеп алынган, кайберсенең, киресенчә, җилкәләренә төшеп торырлык озын итеп үстерелгән, үремнәргә үреп куелган иде. Бу исә аларның төрле ырудан, төрле кабиләдән икәнлеген күрсәтеп тора иде.

Кешеләр тавыш-тынсыз гына утырыштылар, тавыш-тынсыз гына көтә башладылар. Барысының да күзе уртага — биек тәхеттә калкып утырган олы кешегә текәлде.

## X

Кунаклар урнашып беткәч, Алмыш хан үзенең уң ягына борылды, бер читтә, караңгыдарак басып торган кемгәдер ым какты. Ашыгып аның янына чандыр гына бер кеше — өй-агасы[1] килеп җитте, баш иде.

— Китер,— диде хан, әкрен генә.

Ачыккан кунаклар утырган урыннарында кыймылдашып алдылар, төкерекләрен йоттылар, борыннарын тарттылар. Ул арада икесе ике ягыннан тотып, ике кеше өйгә зур гына өстәл кертте. Өстәлгә чигүле ак ашъяулык җәелгән, ашъяулык өстенә — сай читле алтын табак, табакка — кыздырылган ит куелган иде.

Исле май, тир, сөрем исләрен күмеп, болындай киң, күк түбәседәй биек өй эченә кыздырылган ит исе таралды. Үзара сөйләшү, йөткерү, борын тарту тынып калды. Меңләгән күзләр, тирә-яктагы бар нәрсәне онытып, хан каршындагы өстәлне күзәттеләр.

Алмыш хан җиң очларын кайтарып куйды да кайнар ит өстенә капланган ак җәймәне өй-агасына тоттырды. Алтын табактагы пычагын алып, ярты ал санның иң тәмле, иң йомшак җиреннән бер кисәк ит кисте. Беркемгә карамыйча беренче кисәкне кабып җибәрде. Шуннан соң ул икенче кисәкне, өченче кисәкне кисеп алды, ашады. Өченче кисәктән соң, дүртенче кисәкне кисеп алды. Булары бөркелеп, майлары тамып торган бу зур гына кисәкне ул үзенең хатынына сузды. Чыбылдык артыннан шундук кыска аяклы өстәл чыгардылар, өстәлне Айкын хатынның алдына куеп, тезләре өстенә ак сөлге җәйделәр.

Хатыныннан соң Алмыш хан үзенең уң ягындагы биләрнең берсенә ит кисеп бирде. Бигә дә аерым өстәл, сөлге, табак чыгарып куйдылар. Шулай итеп, хан үз тирәсенә ярым түгәрәкләнеп утырган якыннарына, кунакларына ит өләшеп бетерде дә аерым төркемдәге балаларына тарата башлады. Хан кулыннан ит алган барлык кешегә аерым өстәл бирелде. Кешеләр, бер-берсенә катнашмыйча, бер-берсенең эчен пошырмыйча, тыныч кына үз алларына ашый бирделәр.

Күз ачып йомганчы Алмыш хан бер ал санны ботарлап та ташлады. Алтын табакта ялтырап бары күсәктәй деңдер сөякләре генә торып калды. Сөякләрне ашчылар алып чыгып киттеләр. Анысы — караларга, кыз-кыркынга, теләнчеләргә...

Сөяк-санак өелгән табакның күз алдыннан югалуы булды, аның урынына икенче табак белән икенче ал санны китереп, тагын хан алдына сузып салдылар. Алмыш хан анысын да бүлгәләргә тотынды. Аның кулында пычак уйнап кына торды. Шул ук вакытта унлап ашчы, көмеш табакларга салып, тагын зур-зур ит кисәкләре алып чыктылар, тиз-тиз атлап, тар аралыклардан арткарак уздылар. Аларга каршы икенче яктан өстәлләр китерделәр.

Ит күтәреп, өстәл күтәреп, кунаклар арасында тыз да быз чабып йөрүләр тиз арада тынып калды. Кунаклар, үз алларына иелгән көе, беркемгә комачауламыйча, тәмле яшь ит ашадылар, сөяк кимерделәр. Кемдер шунда пычакка бәреп җилек кагарга тотынды, кемдер бик белекле булып, ит ашасаң — тешкә кирә, ашамасаң — төшкә кирә, диештереп, каз каурые белән тешен казыштырды. Кайберәүләр үзләренә бирелгән кисәкләрне яртылаш кына авыз иттеләр, калганын балаларга булыр дип, куеннарына тыгып куйдылар — хан казанында пешкән «изге» итне аларның да татып карыйсылары килә ләбаса!

Бер-ике кабымлык ит белән генә тамак туймады туюын, шулай да беркемнең дә моңа күңеле кырылмады. Хан казанында пешкән беренче ит, «изге» ит тамак туйдыру өчен түгел, ашыйсыны китерү өчен генә бирелә иде. Күп тә үтмәде, ике колагыннан икешәр таза ир күтәргән зур, авыр, кайнар казан керттеләр. Казанны хан каршысына, идәннән калкыбрак торган түгәрәк бүкәнгә утырттылар. Казанның сырлы капкачын ачып җибәрү белән, өй өченә, ит исен күмеп, бары хан өендә генә, биләр өендә генә булгалый торган ят, җиңел ис таралды. Бу — йөзем катыштырып, яшь ит белән майда кыздырылган дөге исе иде.

Дөгене иң элек алтын табакка салып Алмыш ханга бирделәр, аннан соң Айкын хатынга, олы кунакларга бирделәр.

Бу юлы Алмыш хан ашарга ашыкмады. Үзенең кунакларын шундый ят, тәмле азык белән сыйлый алуына күңеле булып, ул янындагы кешеләргә, казан тирәсендә булашкан җитез ашчыларга карап-

карап алды. Ашчылар да ханны күздән ычкындырмадылар — кемгә ничек бүләргә кирәклеген киңәшкән сыман, әледән-әле аның ягына күз ташлап алдылар. Үзенең уң ягындагы биләргә, ыру башларына өләшеп бетергәч, Алмыш хан, бары ашчылар гына аңларлык итеп, сул ягына күз сирпеп алды. Аш бүлүче ир тирән көмеш табакка мул итеп пылау салды, пылау янына икенче бер савыттан алып бер-ике чеметем пешкән йөзем өстәде. Көмеш табак, кулдан кулга күчеп, Хәрәзем илчесенең алдына барып утырды.

Шул ук мәлдә ханның уң ягында күңеле кырылган икенче берәүнең түземсезләнеп тамак кырганы ишетелде. Бу атаклы Алып-Тархан иде. Башка чакта аш аңа биләрдән, ыру башларыннан соң бирелә иде. Алмыш хан берни ишетмәмешкә салынды. Ашчы, «ялгыш»ны үз өстенә алган сыман, ашыгып икенче табакка бүләргә тотынды, пылау янына бер-ике чеметем пешкән йөзем салды, бер-ике өрек салды. «Моның өчен Алып-Тархан бер җаен туры китереп, кирәкне бирә инде!» дип уйлады аш бүлүче. Шулай да ул бик үк пошынмады да. Бирсә бирер инде. Ханның әнә чит ил кешеләре алдында ялтырыйсы килә.

Бер казанны бүлеп бетергәч, икенче казан, икенче казан беткәч, өченче, дүртенче казан чыкты. Кунаклар тәмле азыкны мактый-мактый ашадылар. Анысы ашалып бетәргә дә өлгермәде, өй эченә балык исе таралды — ашчылар, ялт итеп торган бизәкле сай савытларга салып, ак балык ите тарата башладылар. Балыкны билләренә кыска гына алъяпкыч бәйләгән яшь җегетләр өләште. Яуга ташланган кебек, кунаклар янына алар берьюлы диярлек килеп керделәр, ашыгып, ябырылып керделәр. Чыгып киткәндә дә алар шулай барысы берьюлы диярлек тиз-тиз генә чыгып киттеләр. Балыктан соң кымыз бирелде. Монысын яшь кызлар өләште. Алар да үз эшләрен бик җитез, бик төгәл башкардылар.

Барысы да бертөсле киенгән яшь, өлгер җегетләрне күреп кунаклар бер аһ иттеләр, шундый ук яшь, сылу кызларны күреп ике аһ иттеләр. Чит ил кешеләре, ачыктан-ачык соклану белдереп, үзара гәпләшеп алдылар.

Түшәменнән идәнгәчә төрле төстәге ефәкләр салынып төшкән, ак киезләренә төрле ау күренешләре, чабып барган канатлы атлар, бүреләр, боланнар төшерелгән, төрле бизәкләр белән чуарланган биек, якты өй эчендә берьюлы меңләгән авызлар чапылдады, итләр чәйнәлде, алтын, көмеш табакларга тиеп, сөякләр, пычаклар, кашыклар шакылдады. Җиңүчеләр туй иттеләр...

Тышта, төн карасын ярып, багана башларындагы пыскыйларда карамайлар янды. Хан өе тирәсендә, кораллар тотып, сакчылар йөренеп торды. Ишек янында бераз гына тукталып тордылар да, алмашлап «теге якка» — пешекчеләр, ашчылар, аякчылар кайнаша торган якка барып әйләнделәр, ашыга-ашыга калдык-постыкларны ашадылар. Шунда ук теләнчеләр, аксак-туксаклар, каралар... тамагы ач башка төрле ыбыр-чыбыр ялманды. Алар инде башка өйләр, башка учаклар янында булырга да өлгергәннәр, анда да сөяк-санак кимергәннәр йә булмаса, бер-ике кабымлык ит эләктергәннәр, кайберләре исә тамак чылатып та алганнар. Чынында инде аларның тамагы күптән туйган. Аларның бары хан табагыннан, хан кулы тигән сөяк-санаклардан гына авыз итәселәре килә. Аннары алар туйның иң кызган чагын көтәләр. Анда инде башкасы да тамып куячак. Ачы бал, буза, кымыз... мул булып тамачак. Акбүрене җиңгән Алмыш хан, күңеле йомшарып, аяк астында чуалган каралларга бүләк өләшергә боера калса, анысы инде тагын да яхшырак булачак! Йа Тәңрем, ханыбызның күңелен юмарт кылгыл, ашчыларны, сакчыларны сукыр кылгыл!

**XI**

Хан өенең тышкы ишеге кинәт ачылып китте, утка баскан песидәй ашыгып, ишектән өй-агасы килеп чыкты. Аның чандыр буен, салынып төшкән озын мыегын күрү белән, кулларына сөяк тоткан сакчылар, майга буялган авыз читләрен ялмаштырып, тизрәк читкә тайпылдылар. Ярлы-ябагай, аксак-туксак, тилгән күргән чебиләр кук, як-якка сибелде. Караңгыга китеп постылар да, уттай янган бүре күзләрен елтыратып, өй-агасының яңадан биек, комсыз, убырлы өй эченә кереп юк булуын көтә башладылар. Өй-агасы тиз генә кереп китәргә ашыкмады.

— Комыш! Серкәч! — дип кычкырды ул, кемнәргәдер кул изәп.

Аякчылар — Комыш белән Серкәч — якындагы киез өйдән зур корсаклы авыр чапчаклар күтәреп чыктылар. Чапчакларны шундук хан янына китереп куйдылар. Алмыш хан үзенең алтын аягын[1] кулына алды, чапчакның бөкесен ачып җибәрде дә нечкә билле, зур авызлы аякка күбекләнеп торган ачы бал агызды. Беренче аякны ул үзе эчте. Тамагын кырыштырып, авыз читләрен сөрткәләп, икенче аякны тутырды. Монысын эчмәде, тулы килеш кулына тотып, аягүрә басты. Ул баскач, башкалар да урыннарыннан тордылар.

— Туганнар! Агай-эне... Ил агалары, кунаклар! — диде ул, яңгыравыклы көр тавыш белән.— Бүгенге олы җиңүгә багышлап күңел ачыйк!

Шул сүзләрне әйткәч, ул кире урынына утырды. Аның артыннан бүтәннәр дә утырдылар. Бөтен өй эче тынып калгач, шул ук тулы аякны тотып, Болгар ханы икенче тапкыр урыныннан торды. Кунаклар да торды. Хан баштагы сүзләрен яңадан кабатлады. Шуннан соң ул тагын утырды.

Өченче кат аягүрә баскач, күңел ачу турындагы сүзләр кабатлангач, яңадан утыргач, ачы бал белән сыйлану башланды. Ачы балны хан, ит өләшкәндәге кебек, кунакларына үзе агызды. Ханнан ераграк утырган кунакларны аякчылар сыйлады.

Барлык кунаклар да беренче кат ачы бал эчкәч, кемнедер эзләп, Алмыш хан кунакларга күз йөртеп чыкты.

— Корыч-Тимер, кил бире! — диде ул, каядыр читкә, уң яккарак кул изәп.

Үзен чакыруларын ишетеп, батыр көяз җегет атылып урыныннан торды, бер-ике сикерүдә хан каршына барып та җитте. Ул аның аягы астына егылды.

— Тор. Мә, тот шуны,— диде хан, кулындагы алтын аякны җиңүчегә сузып.

— Олтаның булыйм, ханым-атам! — диде Корыч-Тимер.

Хан биргән аякны ул, «эһ» тә итмичә, авызына каплады да, эре генә елмаеп, кунакларга борылып карады, тагын нәрсәдер көткән сыман, беравык урынында тоткарланып торды. Шуннан башка берни эләкмәячәген аңлап, йөзендәге елмаюын сүндермичә, әкрен генә үз урынына юнәлде. Кунаклар аңа кызыгып-көнләшеп карап калдылар. Читтәрәк, ерактарак утырганнар исә җиңүченең яманатын саттылар.

Яшь алыпны сыйлаганнан соң, хан кунакларга икенче кат ачы бал агызырга тотынды. Икенче аяктан соң кунакларның йөзләре ачыла төште, телләре чишелә төште. Кешеләр үзара кычкырыбрак, иркенләбрәк сөйләштеләр. Аларның күңелләрен, билгеле, ике аяк ачы бал гына күтәрмәде. Аннан да бигрәк бүген йорт башының йөзе якты иде. Менә ул, шаяртып, янындагы хатынына нидер әйтеп куйды, хатыны елмаеп җибәрде. Ханның шаяртуы кунакларга караңгы төндә кояш балкып киткәндәй тоелды.

Елмаеп, Алмыш хан тагын өй-агасына ым какты. Өй-агасы тавыш-тынсыз шундук күздән югалды. Күп тә үтмәде, сорнай, думбыра, курай, кубыз ише уен коралларын тотып, арткы ишектән көйчеләр килеп керде.

Алар барысы да ирләр иде, барысы да бертөслерәк итеп киенгәннәр иде. Аларның ярлы гына туннары да, башларындагы очлы бүрекләре, аякларындагы итекләре дә хан кунакларыныкыннан шактый аерылып тора иде.

Көйчеләр, кыр казлары шикелле бер-бер артлы тезелеп, түр янына килделәр, ханга баш иделәр, бүрекләрен салып, тезләнгәндәй иттеләр, яңадан билләрен турайттылар. Аннары, аякларын бөкләп, йомшак паласларга тезелешеп утырдылар. Көйчеләр җиңелчә генә коралларына чиертеп алдылар, барысы да бердәм булып, йорт башын, аның кунакларын котлап, дәртле көй башлап җибәрделәр.

Мең кешелек болындай өй эче, җиңелчә генә шаулаган, гөрелдәгән өй эче, тыңларга җыенып, тып-тын калды. Кешеләр күз алдында үзгәрделәр. Күршеләр онытылды, хан онытылды, ашау-эчүләр, кайгы-куанычлар — барысы да каядыр юкка чыкты. Күз алдында — артта, алда, ян-якларда — бөтен өй эчендә бары серле, моңлы көй дә, бер үк теләк янган, бер үк тойгылар белән тибрәнгән күңелләр генә торып калды.

Котлау көйләреннән соң бары җиңү туйларында гына яңгырый торган сугышчан көйләр уйналды. Көйчеләр кырыс кешеләрнең каткан күңелләрен шулай кузгатып алдылар да туктап калдылар. Пыскыйлардагы утларны, югарыдагы төннеккә үрләгән сөрем баганаларын тетрәндереп, киез өй эчендә көчле алкыш яңгырады, мактап әйтелгән сүзләр ишетелде. Алмыш хан, күрәсең, кирәгеннән артык күңеле нечкәреп, көйчеләргә көмеш акчалар чәчте. Аннан күрмәкче башка зуррак кунаклар да җиң очларына тыгылдылар, чылтыратып акчалар сиптеләр.

Җиңел көйләрдән соң көйчеләр тагын бер-ике озын көй уйнадылар. Болары Алмыш ханның иң яраткан көйләре иде. Аларны ул бары зур туйларда гына, аннары күңеле аеруча күтәренке чакларда гына уйната иде. Иң ахырда ул аягына басты. Лачын көйчегә — көйчеләрнең өлкәненә — үз кулы белән ачы бал бирде.

— Бай бул, ханым,— диде Лачын көйче, эчеп, баш иеп.

Бүтән көйчеләрне аякчылар сыйлады. Алар идәнгә, келәм өстенә чәчелгән акчаларын җыештырдылар да, тезелешеп, ишеккә юнәлделәр.

Көйчеләрдән соң хан өенә ике кеше килеп керде. Алар да ханга баш иделәр, тезләнгәндәй иттеләр, аннары кунаклар ягына борылып, кунаклар белән дә исәнләштеләр дә, нык яктыртылган ачык урында, бер-берсенә кара-каршы баскан килеш, тынып калдылар. Болар чәчәннәр иде. Алмыш ханның бүгенге җиңүенә багышлап, алар җыру әйтергә тиешләр иде.

Аларның берсе — тыныч-салкын йөзлесе — урта яшьләрдән узган, инде картая, симерә башлаган бер кеше иде. Аның чал кергән озын чәчләре бер генә үремгә үрелгән иде. Өстенә ул сарыга манылган озын итәкле алача тун кигән иде. Аның бил каешының көмеш каптырмасына җиз сандугач төшерелгән иде. Бу исә аның сандугачтай татлы телле, булдыклы чәчән икәнлеген белдереп тора иде.

Чәчәннәрнең икенчесе тар күкрәкле, чандыр гына, йолкыш кына яшь бер җегет иде. Аның дымланып торган зур, коңгырт күзләре тынгысыз иде. Ул әйтерсең үзенә-үзе урын тапмый иде. Ул мондагы беркемгә дә туры гына карамый — җитез күз карашын әле түшәмгә, әле үзенең итек башына, әле чыбылдыклардагы төрле бизәкләргә юнәлтә иде. Үзе тик кенә басып торган шикелле күренсә дә,

думбыра тоткан нечкә ак бармаклары аның ирексездән кыймылдап-кыймылдап ала иде. Аның ябык бит очлары бер кызара, бер агара — күрәсең, хан алдында аның әле беренче чыгышы иде.

Җыру әйтүне өлкән чәчән Турай башлады. Алтын бизәкле биек түр ягыннан күзен алмыйча, ул, сорнаена чиертә-чиертә, җитез генә, җиңел генә такмакларга тотынды. Җыруның башында ул Алмыш ханга, аның хатыны Айкын хатынга, ханның туган-тумачаларына, балаларына исәнлек-саулык теләде. Аннары биләргә, ыру башларына, тарханнарга исәнлек, бөтен Болгар йортка — байлык, тынычлык теләде. Шуннан соң ул Алмыш ханның «кайнар чүлләрдән бозлы тагларгача» булган иксез-чиксез биләмәләрен санап чыкты; аның кул астында булган, аңа калан түләгән ил-көннәрне телгә алды. Аннары болгарларның иң атаклы биләрен, ыру башларын, тарханнарын, алыпларын санады. Аларны ул яхшы өердәге яхшы атлар белән чагыштырды. «Өернең дә иң башында... яхшылардан яхшысы — син, көчленең дә көчлесе — син, башлының да башлысы — син, Алмыш хан, син — атабыз, йөрәгебез, башыбыз, күз өстендә кашыбыз»,— диде. Тәңре каргаган Хазар каганы булмаса... Бөек Итил, Чулман, ике диңгез арасындагы Каф тавы — урманнар, язылар — барысы да синең кулда булыр ирде, диде... Алла сиңа бетмәс-төкәнмәс көч бирсен, байлык бирсен, ягыларың җиңелсен — барчасы аяк астында калсын, диде.

Турай чәчәннең җыруы шулай бик озын, бик күңелсез булды. Монда утырган кешеләрнең күбесе аның нәрсә әйтерен алдан ук белеп торалар иде. Шулай да алар бик түземлек белән тыңладылар. Алмыш хан, киресенчә, таныш сүзләрне беренче ишеткән кебек, бирелеп, онытылып тыңлады — үзен мактаганны, бигрәк тә «иксез-чиксез» биләмәләрне, үзенә калан түләгән ыруларны телгә алганны ул аеруча ярата иде. Турай чәчән санап киткән «биләмәләр»нең күбесе чынында әле аныкы түгел иде, ул бары аларны яулап алу турында гына уйлый иде. Бу «иксез-чиксез биләмәләр» турындагы сүзләр чынында болгарларның үзләре өчен түгел, чит илләрдән — Хәрәземнән[1], Хытай[2], Синд[3], Рум[4], Багдад якларыннан килгән сатучылар өчен әйтелә иде.

Менә Турай чәчән кайберәүләргә билгеле, кайберәүләргә билгесез булган нәрсәләрне санап чыкты да соңгы җиңүне мактауга күчте. Өй эчендәге җиңелчә гүелдек тынып калды. Колаклар үрә торды, күз карашларында кызыксыну билгесе күренде. Ни әйтер икән, нинди яңа чагыштырулар, нинди тапкыр сүзләре белән куандырыр икән өлкән чәчән бүген аларны?

Кунаклар гына түгел, моңарчы Турай чәчәнгә күрәләтә ачуы килеп, үртәлеп торган яшь чәчән дә сагая калды. Думбыра кылыдай тартылган нечкә муенын сузып, ул үзенең юлдашына текәлде.

«Акбүренең Тотыш атлы эттән туган...» — дип башлады Турай чәчән, сорнаен чиертеп.

«Акбүренең Тотыш атлы арысланы!» — диде яшь чәчән, аның сүзен бүлдереп.

Бу сүзләрне ул бераз гына ашыгып, үртәлеп әйтте. Турай чәчәннең йокы китергеч көйләвенә күнегеп, оеп утырган кешеләр кинәт сискәнеп киттеләр. Барысы да чандыр, яшь чәчәнгә борылды. Яшь җегет аларның кызыксынуын шундук тоеп алды, чак-чак кына каушап, җилкенеп, чатнап торган бер тавыш белән җыру әйтә-әйтә, думбырасын ныграк чиертергә тотынды. Турай чәчән, кызарынып-бүртенеп, аның белән сүз көрәштерергә итеп караган иде дә, булдыра алмады. Яшь җегетнең тавышы торган саен ипләнеп, ныгый барды, тапкыр сүзләре, урынлы чагыштырулары, атылган ук кебек, утлы тимердән чәчрәгән очкыннар кебек, өй эченә туктаусыз сибелүендә булды.

Ул күрәләтә Тотыш угланны мактады. Бер яуда да җиңелмәгән, болгарларның терәге булган Чәкән алпагытны, Будрач сукманны «күккә олактырган», «үлем белән ук атышкан», «күп ирләрне таң калдырган» яшь бөркетне мактады. Әле аны көчле барс белән, әле каплан белән, бүре, шоңкар белән чагыштырды.

Яшь җегетнең кыюлыгына кунакларның исе китте. Бераз гына куркып, пошынып, тын да алмый алар тыңлап утырдылар. Хан каршында әле беркемнең дә мондый туры, чын җыру әйтергә батырчылык иткәне юк иде! Каян килгән бу? Кем моның атасы, анасы? Кайсы ырудан, кайсы төбәктән бу чәчән?!

Чәчәннең теле телгә йокмады, кулы кулга йокмады. Шулай ук меңләгән кешене кызган табада утырткандай, авызына каратып, очкынлы сүзләрен як-якка чәчте-чәчте дә, сүзне кинәт икенче якка борып җибәрде: Чәкән алпагыт белән Будрач сукманның үлеменә кызгану белдерде, Алмыш ханның, бөтен Болгар йортның кайгысын уртаклашты. Шуннан соң күзләрен күккә текәде дә, бу — Тәңренең язмышы, хан, диде; карт агачны аударганга урман корымый, диде; карт урынына яшьләр үсә, аталарның кылычын балалары ала; «Чәкән үлсә — Тотышың бар, Будрач үлсә — Корыч-Тимер» диде дә, йорт башына байлык-саулык теләп, тынып калды.

Соңгы сүзләре белән ул кузгатылган тынычсыз күңелләрне бераз гына йомшарткандай итте. Шулай да ханнан узып беркемнең дә кул чабарга кыюлыгы җитмәде. Болында, өй эчендә меңләгән ирләр, илме, яумы буласын белмичә, тыннарын кысып, шым гына утыра бирделәр. Алмаш ханның йөзен кара болыт басты. Ул да, башкалар кебек, нишләргә белмичә, тораташтай катып тик утыра. Соңгы орышта үзенең батырлары үлгәч тә ул бу тикле аптырашта калмаган иде бугай!

Тынын кысып, йөрәкне учка йомарлап утыру шактый озакка сузылды. Менә хан утырган урынында кымшанып куйды, җиң очыннан ярты уч чамасы көмеш акчалар алды да, теләр-теләмәс кенә, чәчәннәр

аягы астына сипте. Ул чәчәннәрнең икесенә дә ачы бал бирергә кушты, аннары ашыгып үзе буза чиләгенә тотынды.

**XII**

Яшь чәчәннең җыруы Алмыш ханның болай да күңел түрендә качып яткан кайгысын кузгатты. Аның күз алдында шундук орыш күренешләре яңарды. Яшь чәчән, әле генә үткән канлы орышны күз алдына бастырып, әйтерсең болгарларның макталган алыпларын икенче кат үтереп чыкты! Аның туры, тапкыр сүзләре ханның йөрәген телеп-телеп алды, өтеп-өтеп алды. Алай гына да түгел, ханга ул үзе Тотыш углан булып тоелды.

Туйның ямен җибәрмәс өчен, ул тешен кысып булса да түзәргә булды. Шулай да туйның яме инде бозылып өлгергән иде. Кешеләрнең күңелен буза гына күтәрә алмады.

Өй эчендә озак кына киеренке тынлык сакланды. Ханның холкын яхшы белгән өй-агасы, аяк очларына гына басып, түр янына килде дә, нининдер зур, яшерен сере бар кебек, аның колагына иелә төште.

— Рум базарганының яшь кызлары бар... Күрсәтсенме шуларны? — диде ул, пышылдап.

— Күрсәтсен,— диде хан, кушыла язган калын кашларын бер-берсеннән аерып.

Айкын хатын янында, чит ил кунаклары арасында утырган рум базарганы зур корсаклы, юан, озын бер кеше иде. Аның ияген, ияк асларын, чигәләрен — башының күз-колактан, авыз-борыннан кала барлык буш урынын кара сакал-мыек, чәч-төк каплаган иде. Шул куе чәч-төк, сакал-мыек урманы арасыннан кыя таудай булып аның зур, кәкре борыны тырпаеп тора иде дә, барлык нәрсәне ашардай булып, комсызланып карый торган ак бәбәкле шар күзләре елтырап күренә иде. Аның симез, юан муенына нечкә генә алтын чылбыр, чылбыр очына — кечкенә алтын тәре тагылган иде.

Өй-агасының әйткәнен төшенеп алгач та ул, зур, симез куллары белән тезләренә таянып, шактый җиңел аягына басты, шактый җиңел атлап, ишеккә юнәлде.

Бераздан ишек яңадан ачылды. Ачык ишектән караңгы төн кисәге, караңгы төн кисәгендә — кызлар шәүләсе күренеп калды. Шул ук мәлдә колакларга тыштагы җыр тавышлары килеп бәрелде. Кызлар бер-бер артлы өй эченә керә тордылар. Аллы-кызыллы, яшелле келәмнәр җәелгән киң сукмак буенча уртага, хан утырган тәхет каршысына килә тордылар. Уртадагы көчле яктыдан, ут яктысында ялт-йолт килгән алтын-көмешләрдән, чын ташлардан аларның күзләре чагылды. Бу тикле яктыга, бу тикле бай киемнәргә, алтын-көмештән дә, чын ташлардан да көчлерәк янган утлы карашларга тиз генә күнегә алмыйча, алар күзләрен йомдылар, башларын иделәр.

Алар барысы да яшьләр, озын буйлылар иде. Барысының да күзләре зур иде, кайсыныкы — кара, кайсыныкы — күксел иде. Кайберсенең озын чәчләре, нечкә кашлары карга канатыдай, пыскый корымыдай чем-кара, кайберсенең, киресенчә, аксыл-сары иде. Озын, сылу муеннары аларның яңа сауган сөттәй ап-ак иде. Өсләренә алар итәкләре бик үк озын булмаган, үтә күренмәле ефәк бөркәнчекләр бөркәнгәннәр иде. Аларның өстендә, башында, аягында шул юка бөркәнчектән башка бүтән берни юк иде. Юка бөркәнчек аша кызларның яшь, сылу буйлары, алмадай тыгыз күкрәкләре, сыгылмалы билләре — Тәңре яраткан барлык төгәл, тулы саннары күзгә бәрелеп тора иде.

Ишекнең бу ягында кызларны карап, санап кертеп торган, баштанаяк кара киемле рум базаргане, җитте дигән кебек, тыштагы кемгәдер кул селтәде, ишекне япты да койрыктагы кыз артыннан килә башлады. Аннары уртага тезелгән кызлар арасыннан хан катына чыкты да баш орды.

— Болгар йортның олук каны,— диде ул, болгар сүзләрен ватып-җимереп,— менә синга минен тавар. Без, рум базарганнары, кол кызларны сездән... болгарлардан яратып алабыз. Минен илдә, Румда, Кустантин[1] торамызда болгар кызларын яратып алалар. Сездекедәй сылу кызлар беркайда юк, олук кан! Мин синга кояшта пешкән өз кызларымны алып килдем. Бик сылуларын. Тәлим[2] илләрдән җыйдым синен үчен, олук каным! Барлыгы унҗиде баш. Үчесе юлда өлде, салкынга чыдамайча. Булары ин чыдамлары, сылулары. Чирләре юк. Тешләре, көзләре таза. Кылыклары юаш, күндәм. Кул эшен, уй эшен, җырны, биюне беләләр, думбыра чиертәләр. Бишесе Румнан, дүртесе Лангабардан[3], әнә каршындагы ин көркәме — Андалустан[4], аннан тагын икәү бар...

— Күрсәт,— диде хан, базарганның мактавына гына ышанмыйча.

Юан корсаклы рум сатучысы үз телендә кызларга нәрсәдер әйтте. Бер тирәгәрәк өелешеп торган кызлар кыймылдап куйдылар. Берәүләре, тәхет яныннан узып, олуг кунаклар каршыннан атлап киттеләр, икенче берәүләре әле генә кергән ишеккә таба атлагандай иттеләр дә борылгалап кире килделәр. Кайберләре исә баскан урыннарында торып калды. Алар, очарга җыенган кошлар сыман, ак беләкләрен як-якка сузып җибәрделәр. Өсләрендәге бөркәнчекләре, җиңел генә җилләнеп, идәнгә очып төште. Йөзен кара сакал-мыек баскан рум базаргany, юан, симез куллары белән аларның билләреннән, беләкләреннән тотты, әле алай, әле болай боргалап, ханга аларны яхшырак карарга булышты, тегесен-монысын әйтеп торды.

Алмыш хан аны бик үк тыңламады да — кол кызлар сайлауда аның белеме җитәрлек иде. Рум сатучысы чыннан да ялганламый иде, ахрысы. Товар чыннан да яхшы иде.

— Минеке! — диде Алмыш хан, рум кешесе әйткән Андалус кызын ошатып.

— Бай бул, олук кан! — диде базарган, бишкә бөгелеп.

— Калганнарын чыгарып тор, иртәгә көн яктысында карармын,— диде Алмыш хан.— Тияре турында да шунда сөйләшербез.

— Мин синга әйтмәдемме, олук кан? Мин боларды сатмасмын! — диде базарган, кара чытырман арасыннан эре ак тешләрен елтыратып.

— Сатмыйсың?!

Рум кешесе ханның соравын ишетмәмешкә салышты. Чылбыр очындагы кечкенә алтын тәресен уч төбендә сикерткәләп, ялагайланып, көтмәгәндә ул Болгар ханын мактарга тотынды.

— Олук кан! — диде ул.— Синен илен зур, җирен-суын коп, байлыгын җитәрлек. Бу салкын якларда сез, болгарлар, барлык телләр, ыруглар арасында алга киттегез. Сине, олук Алмыш кан, безнен Рум илендә яхшы беләләр. Рум кайсары синен мән туган булырга тели. Башка беркайда очрамас бу сылу кызларды ул синга бүләккә җибәрде!

Базарганның соңгы сүзләрен ишетү белән, ханның да, кунакларның да йөзләре яктырып китте. Болгарлар, үзләренең ханнары өчен куанып, кукыраеп, бер-берсенә карашып алдылар, телләрен шартлаттылар. Рум кайсары нинди шәп бүләкләр җибәргән, ә? Кара син аны! Кызлары ла кызлары, бер кашык су белән йотарлык! Уттай янып торалар! Ул күзләр, ул кашлар, ул буйлар! Ах!.. Болгар ханының мондый бүләк алганы юк иде әле. Изгегә генә булсын эшләр, Тәңрем-Аллам!

Мондый чибәр бүләкләргә Алмыш ханның үзенең дә күңеле булды. Шулай да ул бары тамагын гына кырып куйды да сакалын гына сыйпаштырды. Рум кешесенә ул үз кулы белән агызып сычук бирде.

— Рум кайсарының иле тыныч, байлыгы мул булсын! — диде хан.

— Бай бул, олук кан! — диде базарган, елмаеп.— Кайсарнын синга тагын битеге бар, тагын...

— Туктап тор,— диде хан.

Базарган баш иде, елмаюын сакал-мыек арасына яшерде дә, чыгарга кушып, кызларга баш какты. Кызлар, иңбашларына бөркәнчекләрен каплап, вак-вак атлап ишеккә таба китеп бардылар. Аларны рум сатучысы гына түгел, хан кешеләре дә озата чыктылар.

— Корыч-Тимер! — диде Алмыш хан, яңадан яшь батырны чакырып.

Корыч-Тимер, киек күргән аучы кебек, бүләк төшәсен сизенеп, алдындагы өстәлен-ниен аударып, урыныннан торды да, күршеләренә бәрелә-сугыла, хан янына узды.

— Бу кызны мин сиңа бүләк итәм,— диде хан, башын иеп, яктыда, урта бер җирдә басып торган кол кызга күрсәтеп.

— Бай бул, ханым! Күп яшь бирсен сиңа Тәңрем... Алла! — диде Корыч-Тимер, куанычыннан кояштай балкып.

Ул ханның әйткәнен дә көтмәстән, куйны капкан бүре кебек, бүләген кочагына алды, кешеләр арасыннан, зур өй аша үз урынына чапты. Алмыш ханның юмартлыгы, яшь егетнең чиксез куанычы башкаларга да йокты. Туй яңадан баштагы күтәренкелегенә кайтты.

## XIII

Рум сатучысы гына түгел, бүтәннәр дә хан катына буш кул белән генә килмәгәннәр иде, билгеле. Рум кешесеннән көнләшепме, болгарлар алдында үзләрен күрсәтәселәре килепме, башка чит ил базарганнары да утырган урыннарында кымшанып куйдылар һәм үзләренең бүләк бирергә теләкләре барлыгын белдерделәр.

Беренче булып рум кешесе кебек үк кара сакал-мыеклы, тик аннан тазарак, яшьрәк җөфүт сатучысы сүз сорады. Болгарда, Алмыш хан янында аның инде дүртенче тапкыр булуы иде. Ул инде мондагы йолаларны, тәртипләрне дә, телне дә яхшы ук үзләштергән иде. Мойша атлы бу Мисыр җөфүте бары тик коллар белән, затлы тиреләр белән генә сату итә иде.

— Бөек ханым! — диде ул, үз каршындагы хан-агасының башы аркылы түрдәге ханга эндәшеп.— Бай, көчле Болгарның алтын тәхетендә синең нурлы йөзеңне күреп куанычым артты. Синең көчеңне, байлыгыңны без — чит ил сатучылары үз күзебез белән күрдек. Синең бу якларга килеп чыгуың булды, буйсынмас кыргыйлар куркып синең алда баш иделәр, бил бөктеләр. Олуг җиңүгә ирештең син, бөек хан! Котлыйм сине! Моннан соң да барлык кыргыйлар синнән куркып торсыннар өчен, көннән-көн көчең, байлыгың артсын өчен, мин сиңа менә бу кылычны бүләк итәм.

Шулай дип әйтү белән ул киң чапан итәге астыннан кынысы алтын катыш көмеш белән сырлап бизәлгән кылыч чыгарды. Кылычны ул хан-агасына бирде, хан-агасы Алмыш ханга бирде.

— Димәшекъ корычы! — диде Мойша, үзенең бүләген мактап.— Сиңа дип ясаттым, бөек ханым.

Барысы да, чиктән тыш кызыксыну белән, җөфүт сатучысының бүләгенә текәлделәр. Алмыш хан аягүрә басты, кылычны кынысыдан суырып чыгарды. Ут яктысында яшен чаткысыдай булып кылыч йөзе ялтырап китте. Хан, кылычны күзенә якынрак китереп, төрле яктан караштырды да, уң кулы белән аның сабыннан ныгытып тоткан килеш, сул кулы белән очыннан урталай бөгә башлады. Күп яу күргән, корал күргән батыр ирләр, менә сына, менә сына дип куркып, тын да алмый аны күзәтеп тордылар. Алмыш хан да кылычның чыннан да Димәшекъ корычыннан ясалуына бик үк ышанып җитмәде, ахрысы,— шулай да, кызыксынуын җиңә алмыйча, камыштай юка корычны бөгүендә булды. Кылыч очы сапка тия язды. Ханның маңгаеннан бөрчек-бөрчек тирләр бәреп чыкты.

Кинәт ул кылыч очын ычкындырып җибәрде,— юка корыч, думбыра кылыдай чыңлап, сызгырып, кире атылды. Ирләр җиңеләеп, шаулатып тын алдылар. Тирә-якта мактау сүзләре ишетелде. Агарынган җөфүт сатучысы, үлемгә хөкем ителеп тә балта астыннан исән чыккан угры кебек, чак-чак кына чайкалып китте, елмаеп җибәрде.

Алмыш хан учы белән маңгаен сөртте.

— Бүләгең өчен ни сорыйсың? — диде ул.

— Берни кирәкми, бөек ханым,— диде Мойша.— Мин синдә кунакмын. Шулай да...

— Шулай да... Абрам улы Мойша,— диде Алмыш хан,— тамгалык өчен мин синнән... йөздән унны түгел, йөздән сигезне генә алырмын.

— Бай бул, бөек хан! — диде Мойша, хан алдында баш иеп.

Җөфүт сатучысыннан соң тәбәнәк буйлы, калын кашлы, сакал-мыексыз Кытай сатучысы торды. Ханга ул яшел, сары, ал төстәге өч төргәк ефәк һәм савыт-саба бүләк итте. Әрмән сатучысы күзнең явын алырлык ачык-куе ал-кызыл җепләрдән тукылган бай келәм бүләк итте. Синд сатучысы чәчәкле кәшәмир тукымалар, кием-салым, Бохар сатучысы — буй-буй бизәкле ефәк белән тышланган яхшы тун, кипкән йөзем, өрек бирде. Берничә сатучы үзләре белән бүләккә атлар, дөяләр, коллар алып килүләре турында әйттеләр.

Чит ил сатучылары биргән бүләкләрне, кучтәнәчләрне ханга, кунакларга күрсәтә тордылар, икенче якка алып чыга тордылар. Алмыш хан чит ил кешеләренең үзләренә дә бүләкләр бирде, мактау сүзләре әйтте, иң ахырда аларны үз кулыннан ачы бал белән сыйлады. Бүләкләрнең үзенә тикмәгә генә бирелмәгәнлеген ул бик яхшы аңлады. Тәмле телле, ач күзле, комсыз бу сатучыларның барысына да бер генә нәрсә кирәк иде — бүләк биреп алар ханның күңелен йомшартырга, аннан ничек тә чикләнмәгән ирек алырга тырышалар иде. Акбүреләргә, башка ыруларга ханнан тынычлап яшәү иреге кирәк булса, боларга сату-алу иреге, «кыргыйлар»ны талау иреге кирәк иде. Шулай да тамгалык өчен алына торган кулбауны Алмыш хан җөфүт сатучысыннан башка беркемгә дә киметмәде.

**XIV**

Бүләк бирү эше беткәч, Алмыш хан рум сатучысына күтәрелеп карады.

— Кайсар җибәргән битек синдәме? — диде ул.

— Миндә,— диде рум кешесе, куенына тыгылып.

Хан битекне кулына алды, тамгасын карады.

— Болгарча язганмы, румчамы? — диде.

— Болгарча да, румча да,— диде сатучы.— Үзем укыйм?

— Телдән генә әйт: кайсар ни тели? — диде хан.

— Мин синга, олук кан, кызлардан тыш, ике кисәк рум ефәге, үч кисәк юка җон тукыма, биш тун, чирек батман[1] кипкән йимеш алып килдем. Шундан тыш биш кисәк сабын, им сулары алып килдем...

— Бай бул,— диде хан.— Рум кайсарына минем теләкләремне әйт. Илегез тыныч булсын, кайсарыгыз күп яшәсен.

— Рум кайсары синга да шуны ук тели, олук кан! — диде алтын тәреле кеше, ханга баш орып.

— Бүләкләрең төбендә ни ята — минем шуны беләсем килә,— диде хан, базарганга туры карап.

— Бүләкләр төбендә, олук кан, алтын ачкыч ята,— диде рум кешесе, Алмыш ханга шулай ук сынаулы күз карашы ташлап.

— Синең түшеңдәге кебек алтын ачкычмы? — диде хан.

— Шул өзе,— диде кара кеше, алтын чылбырдагы алтын тәресен кулына алып.— Шундый ачкыч мән бөюк Рум кайсары синен күнгелен ачмак була, синен күнгеленгә мәнге яктылык салмак була.

— Минем күңелемне ачып, анда яктылык салып, ул нишләмәкче була соң? — диде Алмыш хан.— Нишләп ул шулай минем күңелне кайгырта соң әле? Әллә үз күңелен кайгыртамы соң?

— Әйе, әйе, өз күнгелен дә! — диде рум кешесе, елмаеп.— Бөюк су юлында барлыкка килгән олук йорт мән, синен йорт мән кайсар кызыксына. Болгарны син, олук кан, зурайттын, ныгыттын. Болгарны бездә көп телгә алалар. Рум кайсары синен мән якынлашырга тели. Монын сезгә дә, безгә дә чук-чук ассуы булыр.

— Сезгә нинди ассуы булыры аңлашыла,— диде Алмыш хан.— Сезне бер яктан гарәпләр, икенче яктан хазарлар борчый, өченче яктан урыс тынгы бирми. Сезгә булышчы кирәк, таяныр көч кирәк. Андый көч сезгә генә түгел, миңа да кирәк. Алтын ачкычка өстәп Рум кайсары миңа күпме акча бирә? Аның ачкычы белән, бүләккә җибәргән кызлары белән мин үз торама койма да коралмыйм, ягыларымнан да сакланалмыйм.

— Рум кайсары, синга, олук кан, койма кормага, таш сарайлар салмага белекле кешеләр җибәрә ала,— диде рум кешесе, сак кына.— Акча ягына килгәндә, ни... мин кайсарга җиткерермен.

— Син кайсарга җиткерерсең дә, кайсар синә җиткермәгән шул! — диде хан, ачы көлемсерәп.— Сине монда җибәргәндә ул иң кирәген оныткан. Рум йорты бай, Рум йорты бөек, көчле! Андый йорт белән туганлашкан өчен генә дә сез, кыргый болгарлар, Тәңрегә изге теләкләрегезне юлларга тиешсез! Сез безгә кирәк чакта көч бирегез, безнең ягыга каршы сугышып кан коегыз, шуның өчен без сезгә менә шул ялтыравык ачкычны бирәбез, шуның өчен сез рум йоласын тотып, безнең кайсарга иртә-кич күп-күп яшьләр теләрсез! Шулаймы?

Кара йөзен караңгылык баскан рум кешесе беравык эндәшми утырды. Үзенең туган иле Румга карата, рум йоласына карата әйтелгән туры сүзләр, кимсетелүле сүзләр аның ясалма ягымлылыгын юкка чыгарды. Күңеленнән ул бөрешеп калды. Аның бу кыргый илнең кыргый башлыгы алдында үз йортының, үз кайсарының йөз аклыгын саклап каласы килде.

— Олук кан,— диде ул, шактый бер корылык белән,— Рум йорты мәңгелек! Барлык дөньядын өзәге — Кустантин, барлык илләрнең атасы — Рум. Рум йоласы ин изге йола, ин туры йола.

— Син аны кайсарың алдында сөйлә,— диде Алмыш хан, тыныч бер өстенлек белән.— Румның мәңгелек чаклары үтте инде. Күршеләрнең канын эчеп, сөлектәй симереп күп яшәде сезнең Рум. Юк, сез инде артта калдыгыз. Күршеләрегезне үзара ызгыштырып, ачлар, ялангачлар каныннан алтын сарайлар салу, байлык җыю үтте инде. Хазарлар, болгарлар булышка килмәгән булса, моннан ике йөз, өч йөз ел элек үк инде сезне гарәпләр баш аркылы чөеп ыргыткан булыры. Беләм мин сезне, сезнең йолагызны! Синә чаклы да килделәр миңа, яңа дингә аудармакчы булып. Аларга да мин әйттем, акча бирегез, акча! дидем. Миңа аякка басарга кирәк, миңа коллыктан котылырга, янымдагы ягы ырулардан сакланырга кирәк. Мин нык булсам, минем йортымда сезнең йола да ныгый алачак. Шулай булгач, сезнең йоланы көчәйтү өчен мине көчәйтергә кирәк түгелмени? Мин башкаларга да шуны әйттем. Алар да синең кебек, кайсарга җиткербез, диделәр. Кайсар миңа ни җибәрде? Икейөзле, ялганчы рум йоласы!

Рум кешесенең йөзе тартышып куйды, алтын тәресен кысып тоткан килеш, ул үз телендә нидер мыгырданып алды.

— Алай рум йоласы да ошамагач, синенчә ниндәй йола якшы сун? — диде ул, сизелеп торган бер көлемсерәү белән.— Гарәп йоласымы, әллә җөфүт йоласымы?

— Минем өчен ата-баба йоласыннан да яхшысы юк,— диде хан.— Шулай да мин сезнең макталган Румыгыздагы кебек, беркемне дә кысмыйм. Сез, барлык Җир йөзендә бары рум йоласы гына булырга тиеш, дип уйлыйсыз. Барлык  телләр, барлык илләр бары рум йоласына гына, рум кайсарына гына табынырга тиеш, дисез. Үзегездән башкаларга сез кыргыйлар итеп карыйсыз, үзегезнең йоладан башка йолаларны ягы дип беләсез. Сез елгада бер генә балыкны, урманда бер генә киекне, болында бер генә чәчәкне калдырмакчы буласыз. Итилдә төрле балыклар иркенләп йөзгән кебек, урманда төрле киекләр яшәгән кебек, болында төрле чәчәкләр, төрле ут-үләннәр үскән кебек, минем йортта да төрле йолалар, төрле телләр, төрле ырулар иркенләп яши. Болгарда мосылманнар да, җөфүтләр дә, рум йоласын, ата-баба йоласын тотучылар да бар.

— Син минга ачуланма, олук кан,— диде рум кешесе, яңадан ягымлыланып.— Мин синга кайсарның өтенечен генә тапшырдым.

— Мин инде күп уйладым,— диде Алмыш хан.— Сезнең йола миңа батмый. Кустантинга кайтып җитсәң, кайсарга минем изге теләкләремне җиткер.

— Мин әле тиз генә кайтып китмәсмен,— диде рум кешесе.— Минем эшләрем бар... сату-алу... Синнән каршылык булмаса, монда...

— Алтын ачкыч таратырга уйлыйсыңмы? — диде хан, көлемсерәп.

— Әйе, андый уем да бар,— диде тәреле кеше.

— Миннән каршылык юк,— диде Алмыш хан.— Бүгеннән башлап бөтен Чулман буе — шушы югары өлешеннән... Кызыл Яр катаудан алып тамагыначa минем кул астында. Менә шул җирдә син үзең теләгәнчә йөри аласың, үз йолаңа өнди аласың. Минем кул астында нинди «кыргыйлар» яшәгәнен, ничек яшәгәнен үзең күрерсең. Ал тамгалы ярлыкны бирерләр. Ак юл сиңа, рум кунагы.

## XV

Сырт өстендәге юлдан сулга борылып, вак куаклар янына килеп җиткәч тә, Койтым бикәне болгар күзәтчеләре туктатты. Унлап атлы ир каяндыр караңгыдан килеп чыктылар да тавыш-тынсыз гына аларның юлларына аркылы төштеләр, төрле яктан уратып алдылар.

— Ым?[1] — диде күзәтчеләрнең алдагысы, сөңгесен югары күтәреп.

— Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны,— диде бикә, көттеребрәк, битенә капланган бөркәнчеген чак-чак кына ачып.— Мин Алмыш ханга барам.

— Үзең генәме? — диде бер күзәтче, күрәсең, алай башы.

— Үзем генә,— диде бикә.— Болар минем сакчыларым.

— Сезне бүген туйга чакырганнарые, шунда барасыңмыни? — диде алай башы.

— Мин болай гына барам. Мин — Койтым бикә. Минем углым Тотыш — хан кулында.

— Тотыш?

— Ә-ә! — диештеләр күзәтчеләр, үзара гөрелдәшеп. Аларның бу гөрелдәшүендә Тотышка карата олылау сизелде.

— Алайса, син Тотыш алыпның анасымыни? — диде алай башы, кызыксыну белдереп.

— Менә ичмасам орышты! Күпме яшәп шундый батырны күргәнем югые.

— Чәкәнгә каршы чыгарга йөрәге җитү үзе генә дә батырлык!

— Үзе шундый яшь, үзе чибәр,— диештеләр күзәтчеләр.

— Сез мине җибәрәсезме? — диде Койтым бикә.

— Ниерәк шул...— диде алай башы.— Ярар, барыгыз... алай Тотышның анасы да булгач...

Төнге күзәтчеләр, аларга юл биреп, як-якка таралдылар. Койтым бикә үз кешеләре белән тавыш-тынсыз гына кузгалып китте. Алар берничә адым ераклашырга да өлгермәделәр, алай башының арттан.

— Әй, туктагыз әле! — дигән тавышы ишетелде.

— Менә Кудаш сезне озатып куяр,— диде алай башы, якынаеп.— Юкса хан урдасына җиткәнче сезне адым саен туктатачаклар.

— Озатсын,— диде бикә.

Аларны чыннан да адым саен диярлек туктаттылар: әледән-әле караңгыдан каравылчы-күзәтчеләр килеп чыкты. Алар да барысы да ым сорадылар. Озатучы аларга бер-ике сүз белән генә аңлатып бирде дә төнге кунаклар яңадан кузгалып киттеләр. Хан өе янында Кудаш аларны каравыл башына тапшырды. Каравыл башы Койтым бикәне юлдашлары белән аерым өйгә алып керде. Ул аларга көтеп торырга кушты.

— Минем турыда ханга әйтерсеңме? — диде бикә.

— Юк,— диде каравыл башы.— Сезне туйга чакырдылар. Килмәдегез. Соңга калган кеше хан янына кертелми. Аш-су беткәнче, кунаклар таралганчы көтеп торырга туры килер.

— Алай икән...— диде бикә, таркау гына, бөтенләй икенче бернәрсә турында уйланып.

Кайчанга тикле көтәргә? Кунаклар әллә таң атканчы таралышмаслар. Юк инде, көтәргә икән көтәргә! Кайчанга чаклы булса да. Ул монда буш кул белән кайтыр өчен килмәде. Кайда булыр аның углы? Кайдадыр шушында... Ничек коткарырга аны? Ничек алдарга сакчыларны? Ничек катауга кире кайтырга? Кайткач нишләргә? Туктале, нишләптер башы буталды әле аның. Кайчан бетәр бу туй, кайчан ул аны... ханнымы, углынмы күрә алыр?

Койтым бикәнең күңеленә шундый уйлар килде. Тотышны коткару өчен үзенең нишләргә тиешлеген ул әле булса ачык кына күз алдына китерә алмады. Ул бары аны йолып алырга тиешлеген генә, үзен, углын, ыруын — ике ыруын да! — утка салган явыз кешене күргәч, аны нидер эшләтергә тиешлеген генә аңлады. Ул әледән-әле куенына кулын тыгып, хәнҗәр сабын тотып-тотып карады. Ярый әле аны тентемәделәр.

Көтеп тору Койтым бикә уйлаганча ук озакка сузылмады. Төн уртасы узып, җәйге караңгылык тарала башлаганда, хан өеннән җиңелчә шаулашып кунаклар чыкканы ишетелде. Каравыл башы, Алмыш хан йокларга ятканчы дип ашыгып, Койтым бикә турында әйтергә китте.

Күп тә үтмәде, каравыл башы кире килде, бикәне хан янына алып китте. Тышкы ишектән кергәч тә бикә, ак киезләр җәелгән тар гына аралыктан барды да кечерәк кенә дүрткел бүлмәдә туктап калды. Бүлмәдә бизәкле нечкә баганалар башына утыртылган пыскыйлар янып тора иде.

Каравыл башы, каршыдагы ишеккә башын тыгып, керергә ярыймы икәнлеген сорады, шуннан соң ул, башын кире алып, керергә яраганлыгын әйтте. Бикә аның нәрсә әйткәнен аңламады, йомшак урынында оеп тик утырды. Бу серле өй эчендә, тышкы яктан бернинди тавыш-тын ишетелми торган калын киезләр арасында, үзенең барлык күңел тынычлыгын алган явыз кеше янәшәсендә ул кинәт үзгәрә башлады. Тиктомалга аның аяклары карышты, куллары авырайды, йөрәге никтер куркып-өркеп тибәргә тотынды.

Тәңрем, нәрсә бу? Барлык тереклек иясендә була торган бер курку-өркү генәме бу... үзеңнән көчлерәк, баерак булган барлык кешеләрдән курку-өркү шикелле генә курку-өркүме, әллә соң монда тагын бүтән нәрсә дә бармы?

Койтым бикә урынына береккәндәй утырганда, каршыдагы ишек үзе ачылып китте. Чүлмәккә кычкырган сыман калын, көр тавыш белән таныш кеше:

— Кем бар анда? Керсен! — дип кычкырды.

**XVI**

Алмыш ханның «яшел бүлмә» дип аталган йокы бүлмәсе әле генә бикә утырган дүрткел бүлмәдән икеләтә-өчләтә зур иде. Як-якка тоташ яшел ефәкләр эленгән иде. Түшәмнән дә, чыбылдык кебек булып, ачык төстәге яшел ефәк салынып тора иде.

Идәнгә бизәкле зур палас җәелгән иде. Ишеккә каршы якта, имән агачыннан сырлап, матурлап ясалган киң, биек ятак урыны калкып тора иде. Ятак турысына ак ефәккә кара белән, гарәп иҗекләре белән изге сүзләр язып эленгән иде. Шунда ук түшәмнән көмеш чылбырга тагылган алтын эт башы да асылынып тора иде. Болгар ханының тынычлыгын гарәп йоласы да, ата-баба йоласы да бергәләп саклыйлар иде.

Әлеге зур ятакны, ятак янындагы тимерле тартманы, тартма өстендәге котычыкны[1] санамаганда, «яшел бүлмә»дә башка берни юк иде. Аннары идәннең урта бер җирендәрәк, бизәкле багана башында, пыскыйда — чүлмәк савытта чырт-чырт килеп карамай яна иде. Карамайның кара сөреме, баш өстендәге яшел чыбылдык янындагы ачыклыктан үзәк төннеккә таба сурылып тора иде.

Алмыш хан, алтын-көмешле киемнәрен салмыйча, ике кулы белән биленә таянып, ятагында утырып тора иде. Койтым бикә үзе дә сизмәстән тетрәнеп китте: ул шундый яхшы белгән яшь Алмыш углан танымаслык булып үзгәргән иде! Орыш көнендә ул аны ерактан гына күргән иде. Чынында ул аңа ныклап карамаган да иде. Тәнрем, нинди кансыз бу язмыш дигән нәрсә! Элекке яшь туйрадай таза, сылу Алмыш углан ботак-сатаклы карт имәнгә әйләнгән. Бите, күз кабаклары шешенке, корсагы үскән, симез. Ярый әле сакал-мыегын матурлап, түгәрәкләп кистергән.

Күрән бинең өлкән хатыны, ятактагы кешегә таба бер-ике адым атлады да, йола саклап, башындагы бүреген салды, тезләнде. Алмыш ханның йокламаудан, күп эчүдән бөтенләй йомыла язган күзләренә бер күтәрелеп карады да, коры, нык бер тавыш белән:

— Мин, Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны Койтым бикә...— дип сүзгә башлады.

Нәрсәдер исенә төшерергә тырышып та, төшерә алмыйча, кашларын җыергалап, аптырап утырган ханның йөзе кинәт ачылып китте.

— Койтым! — диде ул, урыныннан торып.

Иңбашыннан тотып ул бикәне аягына бастырды, күрәсең, ачы бал, буза кызуыннан айный алмыйча, элеккечә аны кочагына алмакчы булды. Бу ничектер бөтенләй көтмәгәндә булды. Койтым бикә ике куллап аны этеп җибәрде. Зур, авыр ир кеше чак-чак кына чайкалып китте. Ул, кызарынып, биленә таянды. Чын-чынлап ачуланырга да, ачуланмаска да белмичә, үзенең мәңгелектән кире кайткан яшьлегенә — ут ялкынлы, тере, сылу яшьлегенә карап торды.

— Койтым! — диде ул, яратып, ягымлы итеп.

— Мин сиңа үтенеч белән килдем... Болгар йортның... Алмыш хан,— диде Койтым бикә, никтер буталып, кабаланып.

— Чынмы бу, синме, Койтым?! — диде Алмыш хан, әле булса исенә килә алмыйча.

— Бу — мин,— диде бикә, үз-үзен тынычландырырга тырышып.— Онытма, син Алмыш углан булмаган кебек, мин дә Шилке ханның кырнагы түгел. Мин — Күрән бинең хатыны.

«Күрән би» сүзен Алмыш хан беренче тапкыр ишеткәндәй булды. Бу сүз аның кайнарлыгын сүрелдерә төште. Әйе, әйе, Күрән би, Тотыш углан... Каравыл башы әйткәние шул — бинең хатыны дигән иде. Катаудан килгән. Би хатыны. Каян килеп эләккән ул монда? Язмыш кая китереп ташлаган! Әйе, кырнак иде, инде әнә би хатыны булган. Алтынны юлга ташласаң да — алтын, шүрлеккә куйсаң да, утка тотсаң да — алтын! Койтым бикә түгел, Алтын бикә! Нишләп Күрән бине кызганды соң әле ул? Туздырасы калган оясын, аласы калган тартып хатыннарын, кызларын. Ах, кем белгән аның болай булырын!

— Алайса, син Күрән бидә? — диде ул бераздан, елмаеп, бикәнең күзләренә карап.— Белмәдем, монда мин элегрәк килгән булырыем.

— Ярый әле элегрәк килмәгәнсең,— диде бикә.

— Менә килдем, таптым! Алам! — диде Алмыш хан, эчке бер омтылыш белән.

— Инде соң,— диде бикә, салкын гына.

— Соң түгел!

— Соң! — диде бикә, ачуына ирек биреп.— Синең атаң Шилке минем туган ыруымны туздырды, атамнан-анамнан аерды. Инде менә син килдең минем икенче оямны туздырырга. Син миңа кан-яшь, кайгы алып килдең. Минем икенче туган ыруымны да син кара кайгыга салдың. Шулай булгач, ничек итеп син миңа, соң түгел, дип әйтә аласың?! Моннан унтугыз ел элек мин берни аңламыйдырыем. Инде

мин күп нәрсәне аңлыйм. Мин — Күрән бинең хатыны — сиңа үтенеч белән килдем. Тыңлыйсыңмы мине, Алмыш хан?

— Сөйләп кара,— диде хан.

Ул, күрәсең, истәлекләреннән дә, исереклегеннән дә айный башлады. Кисәк кенә ташкын булып калкып чыккан күңел тойгылары аның шулай ук ташкын булып тиз арада кире чигенде.

— Мин... Тотыш угланның анасы...— диде бикә, калтыранып.

— Тотышның?!

— Әйе. Син аны миңа кайтарып бир. Үлеме, тереме — кайтарып бир. Үтенечем шул.

Койтым бикә, тынын кысып, туктап калды. Алмыш хан да тып-тын булды. Җентекләп, нидер чамаларга тырышып, ул чибәр хатынның агарынган йөзен күзәтте.

— Синеке? — диде ул, үзалдына сөйләнгән сыман. Аннары башын калкытты да, бөтенләй чит кешегә, ханга әйләнеп: — Синеке генә түгел, минеке дә! — диде.

Аның «минеке»сен Койтым бикә үзенчә аңлады.

— Юк, синеке түгел! — диде ул, кычкырып.— Түгел! Мин бик яхшы беләм — түгел! Бир углымны миңа! Яралы килеш, үле килеш... теләсә ничек кайтарып бир. Мин шуңа килдем, шунсыз китмим!

— Китмә,— диде хан, тыныч кына.

Аның бу тынычлыгында буй җитмәслек көч, бөеклек сизелде. Беренче тапкыр бикә аны — үзе янындагы бу ир кешене — язмыш билгеләгән олуг хан итеп тойды.

— Мин сине кумыйм,— диде хан, шул ук тынычлыгын саклап.— Кал янымда, хатыным булырсың. Углың белән кал. Би хатыны булуга караганда, хан хатыны булу яман түгел.

— Миңа углым кирәк, Тотыш кирәк! — диде бикә, күз яше сизелгән бер йомшаклык белән.

— Синең углың миндә тотык[1] булып калачак,— диде хан.

— Күрән би тотыклыкка сиңа башка углан бирер,— диде бикә.

— Миңа Тотыш углан кирәк,— диде хан, үчекләшкән сыман.

— Бир Тотышны миңа, бир! — дип кычкырды бикә, көчсез бер ярсу белән.

Кинәт ул кулын тун изүенә шудырды, хәнҗәр сабына тотынды. Тик ул аны кыныдан суырып чыгарырга да өлгерә алмады, таза ир кеше, аның нишләргә теләвен күреп, җиңел генә беләгеннән кысып тотты да тез чүктерде.

— Белексез! — диде ул, ачусыз гына мыгырданып.

Бикә егылып китте, башы идәнгә бәрелде. Үзенең көчсезлегенә, булдыксызлыгына ачыргаланып, ул тыела алмыйча җыларга кереште. Ул бик озак җылады, күз яшьләре агып беткәнче, барлык ачу-ярсулары, барлык тойгылары юылып чыкканчы җылады. Үкси-үкси торып утырды да үзенең баш очында аякларын аерып басып торган коточкыч кешегә ялынычлы күзләрен текәде.

— Алмыш... углан, үтермә мине... бир углымны! — диде.

Берни аңлатмый торган таштай йөзен үзгәртмичә, Алмыш хан, бөек Тәңре кебек (тфү, тфү!), явыз рух кебек, албасты кебек, югарыдан аңа карап торды.

— Мин әйттем: ул синең генә углың түгел,— диде ул.— Мин аны үлем тырнагыннан тартып алдым. Мин! Корыч-Тимернең кылычын мин тотып калдым. Син аны тапкансың, мин аны үлгәч терелттем. Шулай булгач, Тотыш алып... Тотыш арыслан синеке генә түгел, минеке дә!

«Менә нәрсәне әйтә икән ул!» — дип уйлады бикә үзалдына, ниндидер бер тынычлык белән. Аның эченә җылы йөгерде. Тотыш алып... Тотыш арыслан! Алмыш хан үзе шулай ди!

— Алайса, син аны үтермәячәксең?! Коллыкка сатмаячаксың?! — диде аңа, пышылдап, елмаеп.

— Ул миндә тотык булып калачак,— диде хан, кабатлап.— Ике елдан соң ул синең яныңа исән-сау килеш кайтыр. Аның урынына тотык итеп миңа Күрән би үзенең бүтән углын җибәрер. Югыйсә үзеңә тиешле каланны да менә шулай яу белән килеп алырга туры килә. Моннан соң мин дә, каган кебек, үземә буйсынган биләрнең угланнарын тотыкка алачакмын!

— Син... сүз бирәсеңме? — диде Койтым бикә.

— Сиңа тагын нинди сүз? — диде хан.— Алмыш ханның сүзе бер булыр!

— Алайса, тагын бер үтенечемне тыңла,— диде бикә, аягына басып.— Углымны күрергә булмасмы?

— Ник? — диде хан, уйлангандай итеп.— Кочаклашып җылашыргамы? Үтерәсең киләмени? Аның янына имчеләр сине түгел, мине дә кертмәсләр. Кайгырма, миннән аңа кырын күз карашы булмаячак.

— Бай бул, сау бул, Алмыш хан! Бай бул, сау бул, углым Тотыш! — диде Койтым бикә, җиңел сулап.

Койтым бикә, китәргә җыенып, бөркәнчегенә тотынды.

— Иреңә әйт, килсен, баш орсын. Кирелек белән берни кыра алмас,— диде Алмыш хан.

— Әйтермен,— диде бикә.

— Туктале,— диде хан, ишеккә таба борылган бикәне туктатып.

Ул игләп кенә, ике куллап аның башыннан тотып алды.

— Чынын гына әйт әле, Тотыш... минем углыммы? — диде ул, ярым пышылдап.

Хан аның сөрмәле, тере, нурлы күзләренә сынап, яратып карады. Койтым бикәнең башы әйләнеп киткәндәй булды. Беравык ул, ни әйтергә белмичә, тотлыгыбрак торды.

— Юк,— диде аннары, шулай ук ярым пышылдап, башын чайкап.

## XVII

Чулман буена яу чыгар алдыннан Алмыш хан чит ил сатучыларын тоткарласа да, соңыннан, уйлана торгач, бу эшнең үзе өчен бик үк файдалы түгел икәнлеген аңламый булдыра алмады. Борын-борыннан килгән базар юлын бикләргә тырышу ул Итил суын буарга тырышу белән бер иде. Кечкенә инеш, елга суларын буып булса да, Итил, Чулман суларын буу кеше кулыннан килә торган эш түгел иде. Шулай итеп, Алмыш хан үз кулыннан килмәстәй эшкә тотынганлыгын аңлады.

Чит ил сатучылары Чулман буена керә алмасалар, моның авырлыгы Чулман буенда яшәүчеләргә генә түгел, аның үзенә дә төшәчәк иде. Бу инде тамгалыктан[1] керә торган байлык бермә-бер кимиячәк дигән сүз иде.

Аннары Болгар ханы чит ил сатучыларын Ага-базардан ары җибәрми икән, аларны тота икән, кыса икән, дигән сүз таралса, ул чагында инде бу якларга килергә нинди генә сатучы атлыгып торыр икән? Бу инде Болгар йортның амбарлары бушап калачак, Болгар йорт көчсезләнәчәк, ярлыланачак дигән сүз булыр иде.

Алмыш хан тиз арада үзенең ялгышын төзәтергә булды. Чулманның уң ягына чыгу белән ул Итил буенча югарыга үрләргәме, кире кайтып китәргәме, йә булмаса шунда гына алыш-биреш ясаргамы дип аптырап, Ага-базарда җыелып яткан базарганнарга, сартларга төн ягына юл ачык икәнлеген белдерде. Тик ул беркемгә дә үзеннән узып китәргә ярамаганлыгын кисәтте. Кайберәүләр, кызыксынып, зуррак табыш алмакчы булып, чирү артыннан коры юл белән киттеләр, кайберләре су юлын сайлады. Шулай итеп, язгы ташуда ук килергә тиеш булган чит ил сатучылары, соңлап булса да, Акбүре җиренә дә килеп җиттеләр.

Туйдан соң икенче көнне Алмыш хан әлеге чит ил сатучылары белән яңадан очрашты. Кайбер сатучылар аңа тагын бүләкләр китерделәр, үзләренең күпме, нинди товарлары барлыгын, кая баруларын әйттеләр. Хан аларның каекларын, олауларын тикшереп чыкты, үзенә тиешле кулбау алды да, Акбүре җирендә, шулай ук Чулманның түбән агымында сатарга, алырга ирек бирә торган ал тамгалы ярлыклар тапшырды. Сатучылар, бер-берсен узарга тырышып, Кызыл Яр катауга ашыктылар. Кайберәүләр, монда гына тоткарланып тормыйча, вак елгалар буйлап, кара урман эчендә яшәүче төрле ят, кыргый ырулар арасына юл тоттылар.

Кызыл Яр катауда ун көн буена зур базар булды. Базарга якын-тирәдәге авыллардан, урманнардан, Чулман аръягыннан күп кешеләр килде. Җиңелү кайгысыннан нишләргә белмәгән акбүреләргә әйтерсең яңадан кот керде. Күрәсең, сату-алучылар килү куанычыннан, шулай ук хатынының сүзләренә күнеп, Күрән би Алмыш ханга бил бөгәргә килде, аңа мәңге турылыклы булырга дип ант эчте.

# Өченче баб

## I

Тотыш шактый күп канын югалтты. Орыш бетеп, имчеләр яраны бәйләгәндә, ул инде аңын җуеп бара иде, ул инде төш белән өн, үлем белән тереклек арасында тартыша иде. Шул көенчә имчеләр аны урдага алып кайттылар, ялгыз өйгә урнаштырдылар. Янына агач күбәтә белән су, бодай көлчәсе куйдылар да шыпырт кына чыгып та киттеләр. Яралы батырны явыз ияләрдән саклау өчен алар, өйне әйләндереп, җиргә эт теше белән сызык сыздылар. Барлык им-том шуның белән төкәнде. Кояш җир астына төшеп, яңадан күк читеннән килеп чыкканчы аңына килә икән, куйган азыкны ашап, суны эчә икән — димәк, тереләчәк; аңына килми икән, анда инде берни эшләп булмый — суны да, көлчәне дә ияләргә бирергә туры киләчәк. Шулай итеп, аның азыгы да, суы да, коты да үзенә булмаячак.

Имчеләр шулай дип уйладылар. Шуңа күрә, төн узып, таң атканчы аның янына беркем аяк басмады. Икенче көнне кояш чыгып, җирдә яңа көн тугач кына, яралы батырның үлеме-тереме икәнлеген белү өчен, өйгә баштанаяк акка киенгән, битенә битлек япкан имче карт керде. Ул иң элек көлчә белән суга күз төшерде, аннары җегетнең аяк-кулларын капшап карады. Сулы күбәтә дә, көлчә дә үз урынында иде, яшь алыпның аяк-куллары да, култык аслары да җылы иде. Димәк, ул әле исән.

Имче карт суны җиргә түкмәде, киресенчә, җегетнең иреннәрен көчләп ачты да, аңа үзе алып килгән, имләтелгән берничә тамчы кымыз эчерде. Тотыш, нидер әйтмәкче булып, авызын кыймылдатты, кашларын җыерды.

Дүрт көн буена аның янына, шулай таң ату белән, Байтал имче килде, дүрт көн буена аның аяк-кулларын, култык асларын карап-тикшереп, авызына кымыз салып китте. Дүрт көн буена Тотыш күзен

дә ачып карый алмады, бары кашларын гына җыерды да иреннәрен генә кыймылдатты. Бишенче көнне аның күзгә күренмәс күбәләк булып якында гына очып йөргән коты кире авызына керде. Үлем белән яшәү арасында тартыш төкәнде. Яралы җегет күзләрен ачты, югарыда өйнең ачык төннегенә аша якты күк кисәген күрде, якында гына ниндидер ят тавышлар ишетте. Көн яктысын да, тавышларны да ул нишләптер беренче тапкыр — туганнан бирле беренче тапкыр күрә-ишетә шикелле тоелды. Бу бик кызык тойгы иде, шулай да бу бик үк ят нәрсә дә түгел иде. Ул инде кайдадыр шулай күкне дә күргән, тавышларны да ишеткән иде бугай. Әйе, ул кайчандыр яшәгән иде. Димәк, ул яңадан яши башлады! Менә шулай түбә төннегенә карап яту, кайдадыр якында гына кешеләр сөйләшкәнне, атлар кешнәгәнне ишетү нинди куанычлы икән!

Әкрен генә аны җиңел, татлы бер тойгы — күңел тибрәткеч бер җылылык, йомшаклык биләп алды. Бу җылы, йомшак тойгы, дулкын булып, аның тәненә таралды, аяк очларына барып җитте. Шушы татлы йомшаклыкка, җылылыкка бирелеп, тирә-якка колак салып, ул тын гына урынында ятты. Тавышлар бер ерагайды, бер якынайды, әле тоташ гөрелдек булып, әле аерым-аерым сүзләр булып ишетелде.

Бераздан ул үзенең кайдалыгы, нишләп ятуы белән кызыксына башлады. Ул үзенең яралы икәнлеген исенә төшерде — сул як беләгендәге яра кинәт сулкылдап-сулкылдап авыртырга тотынды. Бу авырту тойгысы аның барлык үткәнен — чынында берничә көн элек кенә булган, тик аның үзенә кайчандыр бик-бик күптән булып узган шикелле тоелган күренешләрне күз алдына китереп бастырды. Аның торасы килде, каядыр китәсе, нидер эшлисе килде. Ул, чыннан да, урыныннан кузгалды, тик, башы әйләнеп, кире урынына ауды.

**II**

Бер-ике көннән Алмыш хан урдасы, Акбүре җиреннән кузгалып, кире көн ягына таба юл тотты. Тотыш углан яткан ялгыз өйне, сүтеп тормыйча, киң арбага — каңгыга урнаштырдылар. Арбага албалап атлар җигелде. Меңләгән атлар, кешеләр, арбалар, меңләгән терлек-туар, Чулман буеның шау чәчәктә утырган болыннарын таптап, түмгәкләрне, куакларны сытып-изеп, тирә-якны шау-шу белән күмеп, түбән таба агылдылар. Көчле ташу алып киткән йомычка кисәгедәй, шушы меңләгән атлар, кешеләр, арбалар, кутәрмәләр[1] арасында Тотыш углан да каядыр кыймылдады.

Урданың кайчан, ничек кузгалып китүен ул бөтенләй сизмәде — ул, күрәсең, йоклаган булгандыр. Күзләрен ачып җибәрсә, яткан урынының як-якка тирбәлүен, бер урында гына тормыйча тирбәлүен сизгәч, баштарак ул берни аңламады. Белмәссең, әллә шулай җир әйләнә, әллә аның башы әйләнә!

Шулай да ул бераздан үзенең кемнәр беләндер, каядыр китеп барганын төшенә алды. Шул ук мәлдә беләктәге яра үзен сиздереп куйды. Авырту тойгысы, ачы әрнү булып, йөрәген кузгатып җибәрде. Аны каядыр алып киттеләр! Кая? Нишләтергә?!

Туган өй, туган ыру, катау кайдадыр еракта калды. Атасыннан-анасыннан аерып, аны алып киттеләр...

Аның җылыйсы, кычкырасы килде, кемгәдер үпкә белдерәсе килде. Тик ул берни эшли алмады. Кымшана да алмады. Әллә аны бәйләп ташлаганнармы соң? Ул, чыннан да, үзен бәйләгәннәрме, юкмы икәнлеген белергә теләп, таза кулына таянып, урыныннан торырга тырышып карады. Тора алмады. Шуннан соң ул үзен бәйләгән бауны капшап карамакчы булды. Кулы аның сулы чүлмәк белән агач күбәтәгә тиеп китте. Барлык тойгыларны җиңеп, шундук ачлык тойгысы баш калкытты. Ул, калтыранган кулы белән күбәтәдәге көлчәне алды да, комсызланып ашарга кереште. Бераз гына көйгән, катып ташка әйләнгән богдай көлчәсен ул тиз арада юкка чыгарды. Шуннан соң ул түгә-түгә нечкә муенлы чүлмәктән су эчте.

Тынычланып ул күзләрен йомды. Арба әкрен генә барды да барды. Туктаусыз тәгәрмәчләр шыгырдады, кешеләр сөйләште, шөлдерләр, авызлык тимерләре чылтырады. Кайдадыр көлгән яшь тавышлар ишетелеп китте. Шулай да нинди күңелле тирә-якны тоеп, ишетеп йомшак арбада бару! Кая барса да барыбер түгелмени аның өчен? Барсын гына, тик бер урында гына тормасын.

Искәрмәстән ул яңадан йокыга талды.

Кичкә таба атлар, арбалар туктап калдылар. Тавышлар басыла төште. Әле анда, әле монда учаклар ягылды, кыздырылган ит, май исләре таралды. Тотыш шул татлы исләрне йокы аралаш диярлек сизеп алды, күзләрен ачты да, үзен бөтенләй савыккан кешегә санап, урыныннан ук торып утырды.

Шул ук мәлдә диярлек кутәрмә ишеге ачылып китте. Кызгылт кояш яктысында сирәк сакаллы бер картның, урталай бөгелеп, киез ишектән килеп кергәне күренде. Күзләрен зур ачып, кызыксынып Тотыш аның үзе янына килүен көтте.

— Уяндыңмы, балам? — диде Байтал имче, йомшак кына итеп.

Тотыш карап тик торды. Имче карт та, күрәсең, аның ни дә булса әйтүен теләмәде. Сынап ул яралының сулган, агарынган йөзенә карады, йомшак бармаклары белән тагын аның аяк-кулларын тоткалады, аннары шулай ук йомшак кына итеп яра урынын капшап карады да урынга ятарга кушты.

— Мин кайда, имче баба? — диде Тотыш.
Үзенең тавышы аңа бик көчсез булып ишетелде.
— Син минем кунагым, балам,— диде Байтал имче.
— Минем ашыйсым килә,— диде Тотыш, сабый бала сыман җыламсырап.
— Син инде үзеңә тиешлесен ашагансың, балам,— диде имче баба, буш күбәтә белән чүлмәккә күз төшереп.— Сиңа күп ашарга ярамый.
— Мин терелдем. Минем ашыйсым килә! — диде Тотыш, үпкәләп.
— Шулайдыр, балам,— диде имче карт, чүлмәк белән күбәтәне кулына алып.— Күзеңне ачкансың, сөйләшә аласың — котың үзеңдә. Иртәгә таңгача түз, балам. Бары да Тәңре кулында.
Бу сүзләрне ул ничектер коры итеп, боергандагы кебек итеп әйтте. Тотыш аннан ялынып та, ялварып та берни ала алмаячагын аңлады. Аның картка ачуы килде. Ул аның тизрәк чыгып китүен көтә башлады. Байтал имче тоткарланып тормады: яралы җегеткә тыныч йокы теләде дә, арты белән чигенеп, ишектән чыгып китте.
Тотыш янына ул Алмыш хан кушуы буенча килде. Югыйсә төштән соң, бигрәк тә кояш баеганда, ул яралы, авыру кешеләр янына керүне өнәп бетерми иде. Байтал имче туры хан янына китте.
— Торып утырган. Тиздән аягына басар,— диде ул ханга.
— Болгар-торага кайтып җиткәнче ул аягына басмаска тиеш,— диде хан.
— Син әйткәнчә булыр, ханым,— диде Байтал имче, баш иеп.

**III**

Көндезен йоклап туйгангамы, карыны ач булгангамы, әллә инде имче карт белән сөйләшү күңелен борчыганга, кичтән Тотышның йокысы килмәде. Аның кайсыдыр җире авыртты, кайсыдыр җире сызлады, әрнеде — ул инде моны баштагыча нык итеп, ачы итеп тоймады. Аның күңелендә моңарчы үзен бик үк сиздермәгән бер кызыксыну уянды. Болгарлар аны каядыр алып баралар. Яралы булгач, ник аны туган җирендә генә калдырмадылар икән?
Аның кызыксынуы артканнан-арта барды. «Нинди җир бу, кайсы төш бу?» — диде ул үзенә үзе. Чулман еракмы? Кызыл Яр катау кайсы якта калды? Тышта, арба янында каравыл бармы, әллә соң имче аны, әле булса көчсез дип уйлап, үзен генә калдырып киттеме?
Аның тикшереп карыйсы килде. Ул, тышта тавышлар басылганны, урда йокыга талганны көтеп торды да, ишек янына шуышып килде. «Көч юк, ашыйсы килә,— дип уйлады ул, күңелен кытыклаган уен кире кагып.— Юк, булмый әле. Көч юк... баш әйләнә».
Ул, колакларын үрә торгызып, ишек төбендә беравык тыңлап ятты. Тышта шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Якында гына каравылчы булса, аның йөренгәне ишетелер иде. Юк, ишетелми. Алай гына да түгел, аның арбасына якын җирдә бөтенләй бернинди тавыш-тын ишетелми. Димәк, арба янында беркем юк. Болгарлар аны үзләренең арбаларыннан, өйләреннән читкә туктатканнар, ахрысы. Шулай булгач... шулай булгач, төшәргә дә, берәр җирдә качып калырга! Чулман гына якын булсын, анда инде күз күрер!
Яралы җегет, идәнгә җайлап утырды да, ишек бавын чишмәкче булып, ярыктан кулын тышка сузды.
Кинәт ул сискәнеп, тетрәнеп китте. Яшен суккандагы кебек, күз аллары яктырып, гөлт итеп китте. Аның коты алынды. Башына кан бәрде, йөрәге атылып чыгардай булып тибә башлады. Ул үзенең урынына ничек барып ятканлыгын да сизми калды.
Нәрсә булды соң әле бу? Анда, тышта, аның кулы икенче бер кеше кулына тиеп киткәндәй булды. Әйе, әйе. Аның кулы кеше кулына тиде! Ул моны бик яхшы тойды. Албастының кулы андый кайнар, йомшак булмас. Сакчы кулы дисәң, сакчы кулы да андый булмас — аның кулы каты, тупас булыр иде. Кем булды бу, нәрсә булды? Сакчы булса, ул берәр нәрсә әйтер иде. Бу берни әйтмәде... әйтми дә... Әнә тып-тын.
Аның күңеленнән бер-бер артлы әллә нинди куркыныч уйлар узды. Ул, дер-дер калтыранып, урыныннан кузгалмыйча ята бирде. Ул, үзен саклау өчен, бала чагында өйрәнгән каргышларын исенә төшерергә тырышып карады, тик күңеленә берни килмәде. Нишләргә белмичә ул шактый озак тынып ятты.
Көтмәгәндә тышта ниндидер серле тавышлар ишетелеп китте: кемдер ишек бавын чишәргә тырыштымы, киресенчә, әллә ныгытып бәйләмәкче булдымы — Тотыш аера алмады. Шунда ук ниндидер каты нәрсәгә чүлмәк кебек нәрсә тиеп китте.
Шулай да җегет түзмәде, барлык батырлыгын бергә җыеп:
— Кем бар анда? — диде.
Аның тавышы үзенә дә ишетелмәде. Ул кычкырыбрак соравын тагын кабатлады.
— Тотыш... синме? — диде тыштагы ниндидер нәрсә, пышылдап.

Бу ниндидер нәрсәнең калтыранып чыккан пышылдавык тавышы яралы җегеткә бик йомшак, бик ягымлы булып ишетелде. Бу, билгеле, имче дә түгел, сакчы да түгел иде. Ул ниндидер... кыз кеше булырга тиеш иде. Яшь җегетнең эченә җылы йөгерде — чын кеше идеме ул, албасты идеме — аның өчен барыбер кебек иде. Тыштагы ул шикле кызга аның: «Әйе, бу мин — Тотыш»,— дип кычкырасы килде, шулай да әле булса аны нидер тыеп торды.

— Тотыш, мин сиңа ашарга китердем,— дип пышылдады ят кыз, бераз тынып торганнан соң.

Тотыш барыбер кузгалмады. Караңгыдан күзен алмыйча, ул, бөтен күңеле белән бергә укмашып, тынын кысып ятуында булды. Ул арада тыштагы ят кеше ишек астыннан эчкә ниндидер авыр нәрсә куйды. Ач кешенең борынына шундук пешкән ит исе килеп бәрелде. Ул түзмәде, ишек янына килде, капшанып карады. Аның кулы ниндидер төргәккә тиде. Утка пешкәндәй ул шундук кулын кире тартып алды. «Юк, ярамый!» — диде ул үзенә үзе. Шул ук мәлдә ул тышка колак салды: анда инде бернинди кыштырдык та, пышылдау да ишетелмәде. Күз буу булмады микән бу? Күрәсең, шулайдыр...

«Күз буу? — дип уйлады ул бераздан, шикләнеп.— Алайса, нишләп соң ул итнең исе килә?!»

Ачлык тойгысы, кызыксыну тойгысы куркудан, төрле шикләрдән көчлерәк булып чыкты. Ул яңадан капшанып әлеге төргәкне табып алды, сүтте, андагы зур гына ит кисәген комсызланып ашарга да кереште. Бу инде каткан көлчә кебек кенә булмады. Авыз тутырып ит ашагач, тоткын егетнең күңеле күтәрелеп китте.

«Болай булгач, качам да качам инде!» — дип уйлады Тотыш, кыюланып.

Шулай да ул кача алмады. Әле генә иреккә омтылган уйлары, теләкләре, бөтенләй көтелмәгән каршылыкка очрап, бөтенләй көтелмәгән юнәлештән китеп барды: үзе дә сизмәстән ул ят, серле кыз турында уйлый башлады.

Юк, ул уйламады да. Үзенең ягымлы, серле пышылдавы белән, кайнар, йомшак кулы белән ул аның күңеленә керде дә утырды. Сиздермичә, сорамыйча керде. Сиздермичә, сорамыйча ул аның барлык уйларын, теләкләрен үзе теләгән юнәлешкә борып җибәрде. Алай гына да түгел, ул аның йөрәген дә әйтерсең бөтенләй башкача эшләтә башлады. Тиз арада ул аны биләп алды, буйсындырды, тез чүктерде. Ялгызлыктан, тоткынлыктан, авыртынудан интеккән яшь җегетне кулга алу өчен аңа бернинди тырышлык кирәкмәде.

Кем булыр ул? Чын кешеме ул, әллә кешегә әйләнгән берәр изге ияме? Килерме иртәгә, килмәсме? Яралы, яшь җегетне шундый сораулар борчыды. Ул көтәргә булды. Ул тизрәк төн узып таң атуын, көн узып караңгы төшүен көтте.

## IV

Менә ул көткән икенче көн дә туды. Кара тауларны, урманнарны кичеп, җиде кат җир астыннан, җиде кат күк артыннан үтеп, яңа көн туды. Мондый якты көнне, мондый куркулы-өркүле, мондый тынгысыз көнне Тотышның әле беркайчан да күргәне юк иде бугай. Таң арткач, аңа никтер төш җитмәс шикелле булып, төш җиткәч, никтер кич булмас шикелле тоелды. Кич булгач исә, караңгы төшми аптыратты. Беркайчан да, беркемне дә аның шулай өзелеп, сагынып көткәне юк иде бугай...

Тышта, ишек янында, кыштырдык ишетеп, ул кинәт дерт итеп китте. Урыныннан торды да сагаеп тыңларга тотынды. Күтәрмәнең киез ишеге ачылуга, кичәге кебек, кызгылт кояш яктысында имче картның сирәк сакалы күренде. Яшь җегетнең өстенә салкын су койгандай булды. Ул, күңелсезләнеп, кире урынына ауды. Иртән килеп киткән имчене ул инде тагын килер дип уйламаган иде.

Байтал имче көндәгечә аның кулларын-аякларын капшап карады, маңгаена кулын куеп торды. Иртәнгегә караганда аңа яралының маңгае кайнаррак тоелды.

— Башың авыртмыймы, балам? — диде ул аңа.

— Юк,— диде Тотыш.

— Яраң сызламыймы, балам? — диде имче карт, төпченеп.

— Юк,— диде Тотыш.— Мин инде терелдем, имче баба. Минем җиргә төшәсем, үз аягым белән йөрисем, йөгерәсем килә. Кайчан мине иреккә чыгарырлар?

— Анысын мин белмим, балам,— диде карт.

— Алайса, ашарга бирегез! — диде Тотыш.

— Анысы минем ихтыярда түгел, балам,— диде имче баба.

Тотышның башка сүз көрәштерәсе килмәде. Имче картның ни әйтсәң дә, нәрсә сорасаң да, бер үк сүзне кабатлаячагын ул инде бик яхшы төшенеп алды. Аның, бернигә карамыйча, каядыр чыгып йөгерәсе килде, үзен менә шунда урынга беркеткән ярасын бәйләре-ниләре белән ботарлап ташлыйсы килде. Ах, кем иде, кем булды ул! Берүзе бөтен ыруны саклап калмакчы булды. Берүзе болгарларның алыпларын кырып салмакчы булды! Берүзе! Нинди башсыз булган ул, нинди белексез булган ул шулай да! Ничек җиңмәк кирәк ялгыз башың шултикле күп көчне?! Акбүреләр барлык чирүләре белән каршы торсалар, җиңә алырлар иде микән соң? Юк, алай да җиңә алмаслар иде. Әйе, кем көчле — шул өстен,

кем көчле — шул бай, өлешле. Көчсезгә нишләргә соң, Тәңрем? Ул да синең балаң түгелмени? Синең балаң булса, нигә аны читкә тибәрдең? Нигә аны менә шулай аяк астына салып таптаттың?!

Ул җиңелде, катау таланды... талангандыр... Кемнәр исән, кемнәр үле икән анда, Кызыл Яр катауда? Ниләр булды икән анда ул югында? Үз-үзеңне, атаңны-анаңны, ыруыңны саклау өчен, яклау өчен каян бетмәс-төкәнмәс көч алырга, Тәңрем?!

Икенче кыштырдыкны ул бик тыныч каршылады. Баштарак ул никтер үпкәләп, киреләнеп: «Ашарга китерсә дә алмыйм!» — диебрәк тә уйлады.

— Тотыш... Тотыш? — диде серле кыз, кичәгечә ягымлы, калтыравык бер тавыш белән пышылдап.

Аның бу пышылдавын, инде таныш булып, якын булып әйләнгән пышылдавын ишетү белән, никтер, кемгәдер үпкәләгән яшь җегетнең күңеле эреде дә куйды. Аны татлы кайнар дулкын күмеп китте. Сөенеп, ашыгып ул ишек янына килде.

— Синме? Килдеңме? — диде ул, кызның кулын тотып.

Кыз кулын кире тартып алмады — күндәм генә, йомшак кына тик торды. Җегетнең кинәт башы әйләнде, йөрәге суга башлады. Ул үзенә серле кул аша искиткеч куаныч тойгысы белән искиткеч көч, әлерәк кенә үзе теләгән иксез-чиксез көч бирелгәнлеген тойды. Ул, телдән язган кебек, берни эндәшә алмыйча, үзалдына елмаеп торды да торды.

— Мин сиңа тагын ашарга китердем,— диде кыз.— Пешкән ит... кымыз. Тизрәк терел, Тотыш!

— Мин терелдем! — диде җегет, чиксез куанып.

— Мин китәм,— диде кыз.— Читтә сакчылар йөри. Синең арба янына имчедән башка беркем килергә тиеш түгел. Мин китәм. Күрсәләр...

— Китмә! Сөйлә берәр нәрсә,— диде Тотыш, аның тавышын ишетәсе килеп.— Кем син? Мин терелдем. Иртәгә киләсеңме?

— Тырышырмын,— диде кыз.— Сау бул, Тотыш, мин китәм.

— Килсәң, миңа ук-җәя китерәсеңме? Булса — кылыч?

Кыз кинәт тынып калды.

— Мин куркам,— диде ул бераздан, сүлпән генә.

Тотыш аның тавышындагы үзгәрешне сизми калды.

— Беркемгә дә әйтмә: мин моннан качарга булдым! — диде ул, ашыгып.

— Сине нык саклыйлар,— диде кыз.

— Булдыралсаң, кылыч китер — мин аларны искәрмәстән кырып салам! — диде яралы җегет, батыраеп.

— Мин куркам,— диде кыз, кабатлап.— Мин китәм, күрерләр...

— Туктале, тукта,— диде җегет, аны беразга гына булса да үз янында тотмакчы булып.

Шулай да ул аны артык кыстарга да базмады — ул аның үзе аркасында сакчыларга юлыгуын теләмәде. Аннары кызның корал алып килү турында берни әйтмәве дә ничектер искәрмәстән аның кыюлыгын сүрелдерә төшкәндәй булды. Ул ишек янында беравык тыңлап торды да кире үз урынына барып ятты. Бик ашыйсы килсә дә, нишләптер аның бүген кыз китергән азыкка тиз генә тотынасы килмәде. Бүгенге очрашу ул дигәнчә, ул теләгәнчә булмады шикелле. Аның күңелендә энә очыдай гына борчылу, пошыну торып калды. «Корал турында, качу турында әйтеп ялгыштым, ахрысы»,— дип уйлады ул бераздан, көрсенеп. Болгар кызына ышанып серен чиште! Эх, тишек авыз!

Икенче көнне кыз бөтенләй килмәде. Кайгыдан Тотыш нәрсә уйларга да белмәде. Онытыла башлаган ярасы яңадан кузгалды. Күңел ачысына, эчне борып торган ачлык тойгысына тагын үзәкләргә үтә торган икенче бер әрнү-үкенү тойгысы кушылды. Төнне ул йокламыйча уздырды. «Иртәгә килер әле»,— диде ул, үз-үзен юатып.

Кыз «иртәгә» дә, «иртәгә» соңыннан да килмәде. Суга төшкәндәй юк булды да куйды. Көндәгечә аның янына иртә-кич Байтал имче килде, ачтан үлмәслек кенә ашарга-эчәргә китерде, аның теге-бу төшләрен капшаштырды да, бер үк сүзләрне әйткәләп китеп тә барды. Килгән саен ул аңа: «Озакламый савыгырсың, балам»,— диде, тик ул әйткән «савыгу»ның бер дә очы-кырые күренмәде. Ул көннәр буена бер үк урында аунап ятты. Тора-бара аның өчен бөтен нәрсә тоныкланып, төссезләнеп калды. Истәлекләр ерагайды, тойгылар көчсезләнде, тынгысыз уйлары шулай ук каядыр качышып, таралышып беттеләр. Көндез кояш кыздырса да, яңгыр яуса да, арба тәгәрмәчләре казылмага батса да, якында гына җайдаклар шаулашса да, аның өчен барыбер иде. Ул әйтерсең тормыштан, дөньядан аерылып калган иде.

Кыз исә килмәде дә килмәде... Югалды, юкка чыкты. Күрәсең, ул чын кеше дә булмагандыр.

Шулай итеп, көн артыннан көн үтте, төн артыннан төн үтте. Атларга атланган, арбаларга утырган Болгар иле, бөтен Чулман буен тутырып, болыннарны, кырларны таптап, урман-суларны кичеп, үзенең төп җиренә таба кыймылдады. Юл өстендә таланган, яндырылган катаулар очрады; кешеләре яудан куркып, урман араларына, Чулман аръягына качып киткән буш авыллар очрады. Кайбер җирдә, киресенчә, Алмыш ханга буйсынуларын белдереп, ит, икмәк, тоз күтәреп, каршыга кешеләр чыкты. Җиңүчеләрне елмаеп каршы алдылар, йодрык күрсәтеп озатып калдылар.

Акбүре җиреннән кузгалып китүләренә бер ай чамасы булды дигәндә, болгарларның мең кешелек иравылы[1] Ямгырчы би җиренә барып керде. Ямгырчы би яши торган Шуран катаудан Болгар-торага нибарысы алтмыш-җитмеш чакрым ара калган иде.

**V**

Чулман буен яуларга чыгар алдыннан Алмыш хан үзе белән бөтен йортын-илен кузгатмады. Ул бары үзенең биш йөз кешелек өен генә алды. Болгарларның күпчелеге, шулай ук Алмыш ханга турылыклы ырулар барысы да үзләренең төп җирләрендә: җәйләүләрдә, авылларда торып калдылар. Билгеле, Болгар-тораны — ханбалыкны[2], Ага-базарны саклау өчен ул кораллы чирү калдырмый булдыра алмады. Шулай ук чик буйларында да күп кенә сакчылар калды. Чирүнең күпчелек өлешен Алмыш хан шулай да үзе белән яуга алды. Ник дигәндә, бу арада гына Болгарга яу килер дип куркыр урын юк иде. Бөтен Итил буена курку салып, авыл-калаларны талап, яндырып йөрүче урыс-улаклар да соңгы елларда тынып калдылар. Моннан биш-алты ел элек хазарлардан качып котылган юлбасар урысларның соңгы көчләре белән болгарлар арасында бик каты сугыш булды. Бер көн эчендә болгарлар утыз меңләп урысны, турап, Итилгә агыздылар. Шуннан бирле Итил буе тынычланып калды. Менә шуңа да Алмыш хан үзенең төп көчләрен Чулман ягына яуга алып чыкты да.

Алмыш ханның ягылары, билгеле, урыслар гына түгел иде. Урыслар еракта иде, алар каяндыр өстән, урманлы-сазлы җирләрдән төшәләр иде. Алмыш ханның ягылары монда якында гына да — үз йортында, күрше-тирәдә дә җитәрлек иде. Алар аның борылганын гына, тезгенне йомшартканын гына көтеп торалар иде. Чак-чак кына ялгыш бастымы, чак-чак кына күзен ачып карамадымы — алар шундук аны төртеп егарга, ботарлап, өзгәләп ташларга гына торалар иде. Шулар арасында иң көчлесе, иң усалы — Суар бие Килдеш би иде. Ярый әле узган кышны Алмыш хан аның белән татулык анты эчте. Юкса йөрер иде иркенләп менә болай Чулман буенда! Шулай ук биләрләр дә эттән туган нәрсәләр... Биләр белән Суар талаша. Биләрдә әле Болгар кайгысы юк.

Менә шуларны уйлап Алмыш хан бик зур эшкә тотынды. Беркемгә сиздермичә ул кыш буена көч туплады, үзендәге барлык балтачыларны җыеп, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән сал-күпер ясатты. Юри, күз буяу өчен ул Болгар-тораны икенче кат койма белән уратып алам, шуңа агач кистерәм дип сүз таратты. Аннары язга чыгу белән тагын, буйсынмаган башкыртларга каршы яуга чыгам, дигән икенче ялган таратты. Шулай итеп, беркем берни сизенмәде. Шулай итеп, утырды төп башына Биләр, Суар! Бөтен Чулман буе — аның кулында, бер йодрыкта. Биләр белән Суар киләчәктә дә үзара талашалар икән, берәм-берәм аларны да кабып йоту, тез чүктерү берни булмас.

Куанмасаң да куанырсың — күпме көч, күпме байлык артты! Әнә барысы да олау-олау булып арттан ияреп килә. Терлек-туар, алтын-көмеш, тире, бодай...

Кайчакларда ханның күңелен шундыйрак масаюлы уйлар биләп алды. Андый чакта аның комсызлыгы тагын арта төште. Аның еракка төбәлгән ач күзләренә Чулман буе гына түгел, Хазары-ние белән, диңгезләре белән бөтен Итил буе, далалар күренә башлады. Мондый чакта аның йөгерек уйларын берни дә туктата алмады, шулай да ул бөтенләй үк онытылып та китмәде. Татлы уйларга караганда, күз алдындагы чынбарлык усалрак та, тынгысызрак та иде. Шуңа күрә дә, күңеле күпме генә күтәренке булмасын, үз торагына якынлашу белән, аның бер дә юктан эче поша башлады. Аның тизрәк кайтып җитәсе, үз оясын исән-имин күрәсе килде. Тик күңеле ашыкса да, аяклары артка өстерәде. Ике-өч чакрымлык койрык булып сузылган олауларны, көтүләрне артта калдырып, берничек тә ул үзе генә алдан чаба алмады. Шунлыктан чирү бик әкрен кыймылдады, ат аягы белән түгел, сыер, сарык аягы белән кыймылдады.

Алмыш ханга буйсынган биләр арасында Ямгырчы би иң ышанычлыларыннан санала иде. Бүтәннәр кебек ул калан түләүне дә соңга калдырмый иде. Хан үзенә көч сораса, йә булмаса берәр җиргә чакырса, беркайчан карышып та тормый иде. Шуның өстенә ул, Алмыш хан кебек, үзе теләп гарәп йоласына күчкән иде. Ямгырчы би шулай үз кеше булганга да Алмыш хан Чулман аша сал-күперне аның катавына якын җирдә салды. Хан белән икәүдән-икәү генә сөйләшкәндә Ямгырчы би сал-күпергә тимәскә, киресенчә, болгарлар яудан кайтканчыга тикле уң як ярны үз көчләре белән саклап торырга сүз бирде. Үз ягыннан Алмыш хан Ямгырчы бине киләчәктә, бернинди тамгалык алмыйча, Итил буйлап аска да, өскә дә товар белән тоткарлыксыз үткәреп җибәрергә, аннары Чулман буенда таланган байлыктан телем[1] чыгарырга булды.

Алмыш хан үзе иравыл белән иде. Ямгырчы би җиренә аяк басып, төштән соң ачык, калку җирдә кирмән[2] коргач, ул, үзенең якын кешеләрен җыеп, киңәш ясады. Киңәштә нишләргә кирәклеге турында сөйләштеләр. Терлек-туар белән, олаулар белән сал-күпер аша чыгу озакка сузылачак иде. Аларны чирүдән алда чыгару яхшырак булырмы, арттан чыгару яхшырак булырмы? Алмыш хан көчне икегә бүләргә булды. Мең кешелек иравыл, өч меңлек уң кул[3] белән ул тиз арада кузгалып китеп, сал-күпердән чыга башларга уйлады. Үзенең өен, олауларын, терлек-туарны сакларга ул урта кул белән сул

кулны, чагдавылны[4] калдырырга булды. Алмыш хан иравыл, уң кул белән Чулман аша чыгып, сул як ярга урнашкан арада, көтүләр, олаулар чыга башларга, короллы ир-ат исә иң ахырдан кузгалырга тиеш иде. Барлык арт илгә[5] баш итеп хан үзенең өлкән улы Тәкин угланны калдырды.

**VI**

Кичүгә Алмыш хан икенче көнне таң алдыннан килеп җитте. Бер ярдан икенче ярга сузып, саллар өстенә салынган йөзмә күпер үз урынында иде, күперне саклау өчен калдырылган болгарлар да, Ямгырчы би ирләре дә исән-сау иде. Аяк астында — куе урман белән капланган текә яр кырыенда — иртәнге кояш яктысында, елкылдап, җемелдәп, иксез-чиксез су җәелеп ята иде. Юан арканнар белән яр читләрендәге баганаларга тарттырып бәйләп куелган сал-күпер, агым уңаена сыгыла төшеп, киң Чулманны билбау сыман буып ята иде. Елганың уртасын узгач, теге якка таба ул инде чыбыркы койрыгы шикелле нечкә генә булып күренә иде. Анда, теге якта, зәңгәрләнеп тар гына яр сызыгы беленә, яр сызыгы өстендә, ап-ак төрткеләр булып, ак чатырлар-өйләр күренә иде.

Каршындагы шушы күренешне күрү белән, Алмыш ханның тамак төбе кытыкланып, кымырҗып куйды. Үз торагына, үз җиренә юл ачык булганга, җәйге таң шундый якты, шундый җылы булганга, аның күңелен искиткеч бер куаныч, күтәренкелек биләп алды. Үзенә көч, байлык, җиңү биргән, сал-күперне яман күзләрдән, яман куллардан саклап калган Тәңрене олылап, ул кулларын югары күтәрде, күккә карады, тыелгысыз бер өн белән кычкырып җибәрде. Өсте-башы тузанланган, арыган-йончылган килеш, шулай да авызы колагына җитеп елмайган килеш, ул житез генә атыннан төште, бүреген салды. Чулман аръягына, кояш чыккан якка карап, маңгаен җиргә орды.

Меңләгән кешеләр шулай ук куанычлы өннәр белән җирне-күкне яңгыратып кычкырып җибәрделәр, атларыннан төшеп, маңгайларын җиргә ордылар. Яр өстендәге өйләрдән кешеләр йөгереп чыкты. Туганнар, танышлар бер-берсен табып, җылаша, сөенешә башладылар.

Куаныч ыгы-зыгысы бераз кими төшкәч, ерак юлдан кайткан болгарлар киез өйләр корып җибәрделәр. Илдә иминлек булуын белеп күңеле тынычланган Алмыш хан, баштагы уен үзгәртеп, арт ил килеп җиткәнче, үз атларына, кешеләренә бераз ял бирергә булды.

Болгарларның кайтуын түземсезлек белән көтеп торган Ямгырчы би, бер көтү сарык, кымыз, ачы бал алып, тиз арада хан янына килеп җитте.

— Җиңүең белән котлыйм сине, хан! — диде ул, ялагайланып.— Бүгеннән башлап син минем олы кунагым, ни телисең, шуны ал — барысы да синеке!

Алмыш хан тартынып тормады. Күчтәнәчкә дип китерелгән көтүне шундук суйдылар, тунадылар да, кыздыра да башладылар. Аш-су күңелле узды. Җиңүчеләр ашадылар, эчтеләр, мактандылар. Аннары йокыга аудылар. Йокыдан тордылар да, яңадан ашадылар, эчтеләр.

Ял итү, күңел ачу икенче көнне, өченче көнне дә тукталмады. Болгарлар, кирәгеннән артык туарылып китеп, башаяк йөрделәр. Таларга, көчләргә күнегеп киткән кайберәүләр, ханның боерыгын онытып, якын-тирәдәге авылларга ауга чыктылар. Казаякларны курку, ачу биләп алды. Кешеләр, яклау эзләп, үзләренең ыру башларына килделәр. Ямгырчы би, юатып, короллanырга кушып, аларны кире озата барды.

— Көтеп торыгыз, озакламый без аларның үзләренең бугазыннан алырбыз! — диде ул аларга.

Күңел ачуның өченче көнендә, Ямгырчы би Алмыш хан янына килде. Алар арасында тагын икәүдән-икәү генә сөйләшү булды.

— Юлың уңдымы, ханым? — диде би, хан биргән кымызны эчеп җибәргәч, ярарга тырышып.

— Уңды, би,— диде Алмыш хан.— Моннан соң Чулман Итилгә түгел, минем кесәгә коячак.

— Оуу! — диде Ямгырчы би, көлеп.— Синең кесәң шундый зур булыр дип башыма да китермәгәнием. Җыртылмасмы, ханым?

— Җыртылса, менә мондый энә булганда, теләсә нинди җыртыкны да тегеп була,— диде хан, билендәге кылычына тотынып.

— Шулай, шулай, ханым,— диде би, аның сүзен җүпләп.— Эш энәдә генә тормый... җебе кирәк, тегүчесе кирәк дигәндәй... синекедәй ныклы кул да кирәк. Алла сиңа моннан соң да күп яшь бирсен, байлык, саулык бирсен, ханым!

Алмыш хан, мактау сүзләренә күңеле булып, тыйнак кына тамак кырып куйды. Төн-көн эчүдән аңгы-миңге утырса да, Ямгырчы биңең тикмәгә генә килмәгәнлеген ул бик яхшы аңлады.

— Үзеңә тиешле телемне алырга килдеңме? — диде ул үзе, беренче булып.

— Әйе, ханым, телем дисәң дә була, кулагы дисәң дә була,— диде Ямгырчы би.

Алмыш хан, Ямгырчы биңең ялагай йөзен беренче тапкыр күргәндәй, кызарынган күзләре белән аңа сынап карады.

— Күпме сорыйсың... ни сорыйсың? Акчалатамы, таварлатамы? — диде ул.

— Синең кесәңдә күпме байлык барлыгын мин белмим,— диде би, еpактан уратып.

— Син түгел, аны мин үзем дә төгәл генә белмим,— диде хан.

— Шулай булгач, миңа тиешле кулагы да төгәл булалмый,— диде Ямгырчы би, шундук элеп алып.— Син миңа уннан берне бирмәкче булганыең.

— Шулай да булсын,— диде хан, тыелып кына.

— Үзең үк әйтеп торасың, ханым, юлың унган, кесәң калынайган,— диде би.— Шулай булгач, миңа тиешле кулагы да...

— Күпме сорыйсың: турысын әйт! — диде хан, түземлеген җуя башлап.

— Турысы шул, ханым...— диде Ямгырчы би, утка ташланырга җыенган кеше сыман,— бир миңа кызың Аппакны!

Алмыш хан, корт чаккандай, кинәт урыныннан сикереп торды.

— Ап-пак-ны?! — диде ул, Ямгырчы бинең елмаюлы оятсыз күзләренә карап.

— Әйе, Аппакны,— диде би, башын иеп.

— Аппакны мин беркемнән тартып алмадым,— диде хан.— Ул минем үз кызым.

— Анысына мин шикләнмим, ханым,— диде Ямгырчы би.— Шулай да ул миңа тиешле кулагына торырлык дип уйлыйм.

— Син... би, авызыңны үлчәп ач! — диде хан, кашларын җимереп.— Аппак турында синең белән сөйләшү булмаячак. Аппакка торырлык бернинди кулагы юк, бернинди байлык юк! Аннары, алдан килешү буенча, мин сиңа кулагы түгел, телем бирергә тиешмен. Әйт, ни кирәк — колларммы? көтүләрме? тиреме? алтынмы? җирме? Ни кирәк?

— Аппактан башка миңа берни кирәкми,— диде Ямгырчы би, нык итеп.

— Юк! — диде Алмыш хан.

— Йә Аппакны бирәсең, йә мин синнән аерылам,— диде би, тыныч кына, янап.

Алмыш хан, зур корсагын угалап, шаркылдап көләргә тотынды.

— Куркытты! Үтерде! Аерыл! — диде ул, мыскыллап.— Китә бир! Китеп кая барырсың икән? Кара аны, юлыма аркылы төшә күрмә — башсыз калырсың.

— Белексез сүзләр сөйлисең, хан,— диде Ямгырчы би.— Киявең булырга теләгән бер кешене кисә башласаң... кызың ирсез кала күрмәсен!

— Җитте! — диде Алмыш хан, аяк тибеп.— Аппак турында тыныңны чыгарма! Соңгы кат әйтәм, ни сорыйсың?

Чак-чак кына кайгылы, чак-чак кына ачулы, күңеле кырылган бер төстә Ямгырчы би башын иде.

— Сау бул, ханым,— диде ул.— Мин киттем.

— Кит! — диде хан, кулын селтәп.

## VII

Барысы да Ямгырчы би уйлаганча булып чыкты. Алмыш ханның чибәрлеге белән бөтен Болгар йортка, бөтен Итил буена даны таралган гүзәл Аппакны үзенә бирмәячәген ул алдан ук белде. Алай гына да түгел, Аппакны үзенә тиешле телем өчен алу турында ул уйлап та карамады. Ул башкачарак уй йөртте. Аңа телем дә, Аппак та аз иде, аңа Алмыш ханның бөтен байлыгы — җире-суы, иле-көне кирәк иде. Ничәмә-ничә еллар буена ул менә шул турыда баш ватты. Ничәмә-ничә еллар буена, төн йокыларын калдырып, менә шул юлда канлы тир түкте! Җае чыккан саен ул болгарларга каршы, Алмыш ханга каршы итәк астыннан ут йөртте, җае чыккан саен аларга каршы күршеләрен котыртты. Анысы гына җитмәгән, Алмыш ханның борын төбендә генә ул хазарлар белән яшерен эш алып барды — Хазар каганына Алмыш хан турында барысын да җиткереп кенә торды.

Ямгырчы би үзен Болгар ханыннан башлырак, булдыклырак дип исәпләде. Алмыш хан аңа беркатлы, аңгыра, тупас булып тоелды. Шуңа күрә аны баш аркылы чөеп ташлау Ямгырчы би сыман башлы, булдыклы, астыртын кешегә берни тормаячак иде. Мондый зур эшкә тотынырга аның бары тик көче, байлыгы гына җитеп бетми иде. Җитмәгән нәрсәсен исә ул Алмыш ханның үзеннән алмакчы булды. Чулман аша күпер салып, Акбүреләргә каршы яу чабарга ханны ул... Ямгырчы би котыртты! Шул ук вакытта ул суарлар белән, биләрләр белән барысын да алдан килешеп куйды. Тик бу юлы ул Хазар каганына гына берни сиздермәде. Шулай итеп ул берьюлы Алмыш ханны да, Хазар каганын да, булдыра алса — суарларны да, башка күршеләрен дә төп башына утыртмакчы булды.

Тик менә аның шунысы эчен пошырды: Чулманның теге ягында әле булса кара төтен күренми иде. Үзара килешү буенча, Болгар-калага иң элек Килдеш би бәреп керергә, андагы кораллы ирләрне кырып салырга, шуннан соң күккә кара төтен үрләтергә тиеш иде. Суарлар әллә сүзләрендә тормадылармы?

Үз кешеләре янына ул ачулы йөз белән килде.

— Алмыш хан биргән сүзен үтәмәде! — дип кычкырды ул үз кешеләренә.— Алмыш хан казаякларны алдады. Үзебезне канга батырганчы таярга кирәк моннан. Күперне ташлагыз, тизрәк Шуран катауга кайтыгыз.

Бинең сүзләре казаякларга җитә калды. Алмыш ханның ничек алдавын алар төпченеп тормадылар. Шундук ачулы шау-шу, кычкырыш башланды.

— Ит яхшылык, көт яманлык!

— Ханга ышанма, Итилгә таянма! — диештеләр ирләр, ачулы мыгырданып.

Казаякларның тавышлануын болгарлар да ишетеп тордылар. Ханның үз сүзен үтәмәвенә, казаякларның алдануына аларның да эче пошты, шулай да алар ачыктан-ачык Ямгырчы би кешеләрен яклый алмадылар. Киресенчә, ханга, болгарларга каршы әйтелгән усал-усал сүзләрне ишетеп, алар да кыза башладылар. Ике арада әйткәләшү, янау, сүгенү тавышлары ишетелде.

— Яндырырга кирәк күперне!

— Таларга кирәк олауларын!

— Болгарлар үзләре безнең авылларны талый! — диештеләр ачулы казаяклар.

«Ыграк шаулагыз — ыграк сугышырсыз!» — дип уйлады Ямгырчы би үзалдына.

Казаяклар, ашыгып, урман ягына юл тоттылар. Аларны беркем тоткарламады.

Ямгырчы би китеп күп тә үтмәде, Чулманның аргы ягында ургылып күккә кара төтен күтәрелә башлады. Казаяклар белән булган ызгыштан соң тынычланып җитә алмаган болгарлар кара төтенне тиз генә күрмәделәр дә. Күргәннәр иде, әле генә булган шау-шудан да көчлерәк бер тавыш белән, курку, шомлану белән шауларга тотындылар. Казаяклар онытылды, барлык күзләр аргы якка текәлде. Ни бар, ни булган анда? Кем белән кем сугыша?

Куркыныч килүен белдереп, шундук быргылар чинарга тотынды. Бөтен кирмән аякка басты. Һай-һулап, кычкырып, көтүчеләр болыннан атларны куып китерделәр. Ирләр кулларына коралларын алдылар, атларына мenделәр.

Шул чакны сал-күпердә бу якка таба чабып килүче җайдак күренде. Кулында ул кара төтен чыгарып янган кисәү башы тоткан иде. Ярга чыгып, яр башындагы Алмыш хан янына килеп җитәр-җитмәс, ул, тамак ярып:

— Яу килә, яу! — дип кычкырып җибәрде.

Хан янына менеп җиткәч, ул ачыклабрак сөйләде, Болгар-торадан улакчы килде, диде, Суар бие Килдеш ханбалыкны камап алган, диде, анда бик каты сугыш бара икән, диде. Мондый сүз ишетеп, Алмыш хан лачт итеп җиргә төкерде дә Килдеш бине сүгәргә, каргарга тотынды.

Шул вакыт хан артындарак торган ирләр арасында тагын ниндидер ыгы-зыгы башланды. Барысы да артларына борылып карадылар. Көнчыгышта, олы юл өстендә, ниндидер тузан болыты күтәрелгән иде. Дүрт күз белән көтеп торган олаулар, көтүләр булырга тиеш иде бу. Кешеләрнең йөзе яктырып китте. Алмыш ханның исә күз карашында тыелгысыз бер көч-омтылыш, ныклык чаткылары күренде. Олауларның кичүгә килеп җитүен көтеп тормастан, ул ир-атларга теге якка чыга башларга боерды.

Бер-ике көн эчендә көч җыеп, ял итеп алган атлар, пошкыра-пошкыра, сөзәк, киң юлдан аска ыргылдылар. Ташлы, тигез җиргә — яр читенә килеп төштеләр дә, кешнәп, авызлыкларын чәйнәп, суга тартылдылар. Тик бу юлы аларга Чулман суын татып карарга туры килмәде — дөп-дөп басып, вак ташларны, каты балчыкларны ияртеп, бәрелә-сугыла, кысыла-төртелә арттан бертуктаусыз башка атлар төшә тордылар, алдагыларны кысрыклый тордылар. Алдагылар исә, арттан куалаган тыелгысыз көчкә буйсынып, биек араталар арасына барып керделәр дә баскан саен тирбәлеп тора торган басмаларда кинәт тынып-юашланып калдылар, шак-шок басып, куркып-өркеп, су уртасыннан коры җиргә таба омтылдылар.

Күпер авызында тыгыз койма булып торган атлы чавышлар[1] атларны, кешеләрне салга икешәрләп кенә, билгеле бер ара саклап кына керттеләр. Кайберәүләр күпергә алданрак эләгергә, кайберләре, киресенчә, арттарак калырга тырышты. Кайберсенең судан куркып аты чыгымчыларга тотынды. Чавышлар бернигә карамадылар: киреләнгән атларга да, кешеләргә дә озын колга белән тондырып кына алдылар.

Дүрт мең кешелек чирү бары кич, караңгы төшкәндә генә чыгып бетте. Соңгы ир-атлар яр астына төшеп ятканда, арттан олаулар, көтүләр килеп җитте. Алмыш хан арт илне саклап килгән ике меңлек алайга, шулай ук аз гына да тоткарланып тормыйча, үзе артыннан сул якка чыга башларга боерды. Тәкин углан, иртәгә якты күздә олаулар, көтүләр белән күпердә озак тоткарланып тормас өчен, кораллы ирләрне төне буе чыгарырга — күпме булдыра алса, шул чаклы чыгарырга булды. Шулай итеп, төне буена сал-күпердән туктаусыз атлар, кешеләр агылды. Хан өе янында, олаулар, көтүләр янында Тәкин углан белән бер-ике меңлек гаскәр калды. Алмыш хан кебек, Тәкин углан да бу яктан куркыныч килер дип башына да китереп карамады. Алмыш хан кебек, башка бик күпләр кебек, ул да бары оятсыз суарлар турында гына уйлады. Ачуланып китеп барган Ямгырчы бине нишләптер барысы да исләреннән чыгарып ташладылар. Аннары Тәкин углан аның хан белән бозылышып китүен белмәде дә, ишетмәде дә.

Алмыш хан төнне сул якта кунды. Таң атар-атмас борын торып болгарлар ат менделәр, ярсып, оран салып[1], ханбалыкка юнәлделәр.

## VIII

Көннәрдән беркөнне Тотышның ярасы бөтенләй төзәлеп бетте. Тоткын җегет аягына басты. Аңа инде арба өстенә куелган күтәрмә генә тар, кысан була башлады. Байтал имче ашарга-эчәргә элеккегә караганда күбрәк китерә башлады, шулай да аның җиргә төшерү турындагы сүзләрен ишетмәмешкә салышты: хан боерыгын бозарга аның кыюлыгы җитмәде.

Алмыш хан, олауларын артта калдырып, кичүгә таба кузгалып киткәч тә, Байтал имче Тотышның үтенечен Тәкин угланга җиткерде. Яралы җегет инде савыкты, миннән эш китте — үзегез теләсәгез нишләтегез, диде. Тәкин углан атасының боерыгын белә иде. Шулай ук ул таза-сау җегетне — батыр җегетне имче карт карамагында гына калдыруның да бик үк яраган эш түгел икәнлеген аңлый иде.

— Ярар, имче баба,— диде ул Байтал картка.— Аның иленә инде кош та очып кайта алмаячак. Сак куярбыз, җиргә төшерербез.

Шул ук кичне, олаулар ялга туктагач, Тотыш өчен җирдә аерым өй кордылар. Бер ай чамасы арбада киез өстендә аунап килгәннән соң, Тотыш җиргә аяк басты. Аягы астында нык, каты җирне тоеп, куанычыннан ул елмаеп җибәрде, балаларча сикергәләп алды, күкрәген киерде, кулларын селтәде. Тирә-якта дулкын-дулкын калкулыкларны, урманнарны, болыннарны күрү, туганнан бирле таныш, якын күк читен — кызарып баеган кояшны, эрегән алтын белән өретелгән сыман болытларны, озын күләгәләрне күрү анда искиткеч бер күтәренкелек, сөенеч тойгысы тудырды. Аның еракта караеп күренгән урман буйларына, кояшның соңгы яктысы төшкән калкулык сыртларына йөгереп барасы килде, иркен болында утлап йөргән атлар арасында, йомшак ут-үләндә ауныйсы килде. Бу мәлдә ул үзенең тоткын икәнлеген бөтенләй онытып җибәрде.

Аңа дип корылган өй иркен генә иде. Идән уртасына учак ягылган иде. Учак өстенә казан-ни асылмаган иде. Бу бары беренче тапкыр корылган өй эченнән явыз ияләрне куалап чыгару өчен генә ягылган учак иде. Ишектән кергәч тә, каршы якта, учак артында, түрелгән урын-җир өелеп тора, шунда ук вак-төяк савыт-сабалар күренә иде.

Тотыш үзенең өенә бер генә күз ташлады да яңадан тышка чыкты. Ишек төбендә ул ниндидер ят кеше белән очрашты.

Чем-кара чәчле, каратут йөзле бу кеше Тотыштан калкурак та, өлкәнрәк тә иде. Төсе-бите белән ул кояшлы яклардан Итил-Чулман иленә товар белән килә торган сатучыларга охшашрак иде. Тик аның өсте-башы бер дә аларныкы кебек бай түгел иде. Өстенә ул кыршылып беткән кыска тун, тире ыштан, башына исә колакчынлы куян бүрек кигән иде. Матур кылыч борыны астында аның нечкә генә кара мыегы салынып тора иде. Матур кара күзләрендә аның юашлык, моңсулык сизелә иде.

— Исәнме, Тотыш,— диде ул, тыйнак кына, баш иеп.

Иелгәндә аның бүрек колакчыны ачылып китте. Шул чакны Тотыш аның уң колагы юк икәнлеген күреп алды. «Кол!» дип уйлады ул. Ник килгән ул монда?

— Исәнме,— диде ул, бер дә юктан елмаеп.

— Мине сиңа җибәрделәр,— диде кол.

— Кем? — диде Тотыш, чамадан тыш ашыгып, кычкырып.

Аның күңеленә шундук: «Әллә теге кыз микән?» — дигән бер уй килгән иде.

— Тәкин углан,— диде кол.

— Шулаймыни?..— диде Тотыш, сүрелеп.

Беренче карауда кызгану тудырган бу кисек колаклы кеше анда чиркәнү тойгысы уята башлады. Ул аның моңсу-юаш, җебегән йөзенә дә, киселгән колагына да карамаска тырышты.

— Минем атым — Торымтай,— диде юаш кеше.— Мин — Алмыш ханның колы.

— Мин аның тоткыны,— диде Тотыш.

— Юк, син аның тоткыны түгел, тотыгы,— диде Торымтай, төзәтеп.

— Сиңа миннән ни кирәк, Алмыш ханның колы? — диде Тотыш, коры гына.

— Мине сиңа Тәкин углан җибәрде,— диде Торымтай, яшь җегетнең кискенлегенә аптырагандай итеп.

— Ник җибәрде?

— Бүгеннән башлап — мин синең колың.

— Тоткынның колы булмый! — диде Тотыш, ачу белән.— Бар, кит, Тәкин угланга шулай диген.

— Тоткынның колы булмаса да, тотыкныкы була,— диде Торымтай.— Кума мине, Тотыш алып. Төне-көне терлек арасында аунауга караганда, синең колың булу миңа мең артык.

— Кал, алайса,— диде Тотыш, кулын селтәп.

## IX

Торымтайның өе якында гына иде. Ул, җиңел-җиңел атлап, үз өенә кереп китте, аннан бер кулына чүлмәк-казан, икенче кулына ниндидер агач чиләк белән ниндидер төенчекләр тотып чыкты. Тиз арада ул Тотыш өе янында учак җайлап җибәрде — таган ясады, казанга су салып кайнарга утыртты. Шуннан соң ул кыл иләктә тары ярмасы юды.

Тотыш, җиргә сузылып яткан килеш, тавыш-тынсыз гына аның эшен күзәтте. Юк, ул аның эшен генә дә күзәтмәде, ул тирә-якны — кешеләрне, киез өйләрне, төтеннәрне, утлап йөргән терлекләрне күзәтте. Аның ирекне-иркенлекне сагынган күз карашы, беркайда да тоткарланып тормыйча, бер нәрсәдән икенче нәрсәгә йөгерде. Бар нәрсәгә ул яратып, сокланып карады. Күрәсең, шуңа күрәдер үзе дә ул кемнеңдер үзен яратуын, иркәләвен теләде. Ул үзен тулысынча иректә итеп, берни белән чикләнмәгән, тыелмаган итеп тойды, шулай да аның кемгәдер сыенасы, кемнеңдер канат астына керәсе килде. Шул ук вакытта бу иксез-чиксез киңлек, бу иркенлек аңа сыеныр өчен тар булып тоелды. Аның күңеле каядыр икенче төрле киңлеккә, икенче төрле иркенлеккә ашкынды. Тик бу икенче төрле киңлекне-иркенлекне ул үзенең туган җире ягында — артта калган Кызыл Яр катау ягында эзләмәде, аның күзләре бөтенләй капма-каршы якка — көнбатышка текәлде. Анда, соңгы кояш яктысы төшкән серле калкулыклар артында, аңа теге серле кыз бардыр шикелле тоелды. Никтер ул аны еш кына ике аяклы, ике куллы кешеләр арасында — менә шушында, якында гына йөргән кешеләр арасында очратырмын дип түгел, кайдадыр алда, томанлы, билгесез күк читендә очратырмын дип уйлады. Кайчагында, киресенчә, ул аңа артта гына качып-посып торадыр шикелле булып, кинәт борылып карадың исә, шундук аның белән күзгә-күз очрашырсың шикелле булып тоелды.

Тик ул көткән кыз арттан да, алдан да килеп чыкмады. Көннәр үтте дә үтте. Кая булды ул? Шулай ук бөтенләй юкка чыкты микәнни?

Әкренләп кояш сүнә барды, күк читенең бизәкләре куера, үзгәрә, алмашына барды; җирдәге төтеннәр кимеде, тавышлар тоныкланды. Җир өстенә кичәгечә, былтыргыча, моннан йөз ел, мең ел элеккечә, аксыл томаннары белән, чикерткә чыңнары, серле пышылдау-уфылдаулары белән, йомшак кына булып, җәйге караңгылык төшә башлады.

— Тотыш, аш суына,— диде Торымтай.

Тотыш ишетмәде. Кыюсыз гына атлап, кол аның янынарак килде, үзенең сүзләрен кабатлады.

— Ә? — диде җегет, сискәнеп.

— Аш суына...— диде тагын да Торымтай.

Тотыш, урыныннан торып, өйгә кереп китмәкче булды. Торымтай аның юлына аркылы төште, кулындагы комганга күрсәтеп:

— Юынып алыйк,— диде.

— Мин инде юынуны онытып бетердем,— диде Тотыш, үзенең агарып калган кулларын караштырып.

Ул, беләкләрен сызганып, су чәчрәтә-чәчрәтә юынырга тотынды. Кулына, битенә салкын су тигәч, кинәт үзгәреп киткәндәй булды. Шундук туган ягы күз алдына килде, киң Чулман исенә төште. Эчне пошырган, күңелне әрнеткән моң-сагыш онытылды, аның урынына, усал мачы булып, бөтенләй икенче уйлар тырнашырга тотынды. «Качарга кирәк моннан, качарга!» дип уйлады ул.

Юынып бетәр-бетмәс ул билен турайтты, күндәм генә басып торган Торымтайның кулындагы сөлгене тупас кына тартып алды да кабаланып сөртенергә тотынды. Торымтайга ул күзләре белән ашардай булып карады. «Алмыш ханның колы!» дип уйлады ул, сыңар колаклы кешегә карата җирәнү тоеп. «Әнә шулай колаксыз калганчы, ычкынырга, сыпыртырга кирәк моннан!»

— Кем тешләде колагыңны? — диде ул, күрәләтә мыскыл белән.

Яшь җегетнең мондый тупаслыгына, искәрмәстән үзгәрүенә Торымтайның күңеле кырылды. Уңайсызланып, ул күзләрен түбән иде, ы-мы итте.

— Яуда чаптылармыни? — диде Тотыш, көлеп.

— Мин әйттем, мин — Алмыш ханның колымын. Миннән көлмәвеңне үтенәм, Тотыш,— диде кол.

— Кол шул, кол! — диде Тотыш.

Сөртенгәч ул сөлгене җиргә атып бәрде, үзалдына тузынып, өенә кереп китте. Өй эче эссе иде. Көйрәп яткан учак яктысында, идәндә җәелгән ак киездә нинди дер табак-савытлар күренә, өйдә нинди дер аш-су исе килә иде. Ашыйсы бик килсә дә, Тотыш табын янына утырып тормады — холыксыз балалар кебек үпкәләп, урын-җир өстенә менеп ятты.

«Ике ел буена шул сыңар колак Торымтай кебек кол булып яшәргәме! — дип уйлады ул, кем беләндер сүз көрәштергән сыман.— Терлек арасында аунаргамы, кемнәрнеңдер кулына су салып торыргамы?! Юк, беркайчан да булмас!»

Кемдер якында гына: «Син кол түгел, тоткын түгел, син — тотык!» — дип пышылдаган кебек булды. Тотыш, сискәнеп, як-ягына әйләнеп карады. Өй эчендә аның үзеннән башка бүтән беркем дә юк иде. «Тоткын белән тотыкның аермасы нидә соң?» — диде ул үз-үзенә. «Тотыкның колагын кисмиләр»,— диде кемдер.

«Әйе шул, минем колакларым исән! — дип уйлады ул, сөенү шикелле бернәрсә тоеп.— Мин — Торымтай түгел, Торымтай — мин түгел. Мин иректә. Минем үз колым бар».

Иректә... димәк, кайчан да булса ул кешеләр арасында иркенләп йөри алачак!

Тотыш ашап туйганда, башын түбән иеп, тавыш-тынсыз гына Торымтай килеп керде. Тавыш-тынсыз гына табынга якынлашты, булган савыт-сабаларны җыештыра башлады. Аның бик нык күңеле кырылганлыгы әллә каян күренеп тора иде. Тотышка ул кызганыч булып тоелды.

— Утыр, аша. Кайда йөрисең?..— диде ул аңа, җиңелчә шелтә белән.

— Мин ашадым,— диде кол.

Тотыш, чүлмәктән кымыз агызып, аңа сузды.

— Алайса, эчеп җибәр,— диде.

Торымтай көрсенеп куйды, үпкәсен-ачуын берьюлы йотып, елмайгандай итте дә, калтыранган кулы белән кымыз тулы аякны алды.

— Тотыш алып кулыннан кымыз алмак — зур сәвенеч. Мең яшә, би углы! — диде ул, күңеле тулып.

Аның бу мактау сүзләре Тотышка никтер ялагайлану булып тоелды. Үч иткәндәй, шунда ук аның кисек колагы күренеп китте. Тотыш үзе дә сизмәстән чыраен сытып куйды. Юк, ошамагач, ошамый аңа бу кол! Аның әле беркайчан да мондый юаш, мондый түбәләнгән кешене күргәне юк иде. Акбүредә дә коллар бар иде. Тик аларның коллыгы нидә икәнлеген Тотыш бик үк аңлап җитми иде. Алар, ыруның башка игенчеләре кебек, иген игәләр, балыкчылар кебек балык тоталар, аучылар кебек ауга йөриләр. Тик баштарак алар телне белмиләр дә, акбүреләргә ничектер бик үк катышмыйлар. Юк, алар анда беркайчан да хатын-кыз эше белән дә булашмыйлар. Кайда гына булмасын, алар ирләр белән. Аларның үз өйләре, үз куышлары бар. Үзләренең хатыннары, балалары бар. Аларның колаклары да исән. Тик коллыкка эләгүнең беренче елында аларның чәчләре генә алынган була. Чәч нәрсә ул — баш кына исән булсын!

— Каян син? Ничек бу көнгә төштең? — диде Тотыш, үзенең колына эндәшеп.

Торымтайның күз карашы элеккедән дә ныграк моңсуланып калды, мыек чылгыйлары калтыранып китте. Күрәсең, ул мондый сорау көтмәгән иде. Ул, нәрсә әйтергә белмәгәндәй, беравык тынып торды да, тирән көрсенеп:

— Мин алыстан,— диде.— Син юыныргa оныткандай, мин дә үземнең уйгур булдыгымны онытканмын. Моннан ун ел элек мине беренче тапкыр Күчәр базарында кол итеп саттылар. Бурычын түләргә атамның акчасы җитмәде. Шул. Мин үзем теләдем сатылмакка. Еглашып аерылдык. Мине Сәмәрканд сарты алды. Ул тагын бер җөфүткә сатты. Кулдан кулга күчеп, менә бу якка килеп чыктым. Шул... Сүләсәң сүз бетмәс. Монда менә өченче ел.

**X**

Алар озак кына сөйләшеп утырдылар. Торымтай сөйләде, Тотыш тыңлады. Тотыш элек тә чит җирләрдә, чит илләрдә булган, күпне күргән кешеләрнең сөйләгәннәрен тыңларга ярата иде. Андый кешеләр күз күрмәгән, колак ишетмәгән илләр, калалар турында, ят, кызык эшләр, яулар турында сөйлиләр. Аларның сүзен әкият тыңлаган кебек бирелеп тыңлыйсың. Чит илләр, чит җирләр турындагы сүзләр шулай ук күңелдә нindидер теләкләр, омтылышлар тудыра. Кешеләр сөйләгән серле, куркыныч, күңелле җирләрдә үзеңнең дә буласың килә башлый.

Торымтайның сөйләгәннәреннән соң да шулай булды. Тотыш, үз колының туган якларын, ул булган төрле ят җирләрне күз алдына китереп, уйланып, онытылып утырды. Вакытның узганын алар сизмәделәр дә. Тышта инде караңгы төшкән иде бугай. Торымтай соңгы кат көрсенде дә чыгып китәргә теләк белдерде.

— Бүген мин сиңа кирәкмәмдер? — диде ул Тотышка.

— Юк, китә бир,— диде Тотыш, уйчан гына.

Торымтай, тыныч йокы теләп, мыштым гына чыгып китте. Ул үз өенә кереп тормады, каядыр ары китеп барды. Бүген Тәкин углан, яр буенда үзе генә калгач, аш-су ясый иде. Анда акмаса да тамарга тиеш. Торымтай шунда ашыкты.

Тотыш, үзенең колы чыгып киткәч тә, урынына ятмыйча, озак кына учак янында уйланып утырды. Ул да үзенең үткән көннәрен исенә төшерде. Үткән көннәрдән бигрәк үзенең Тәңкәсе турында уйланды.

Әйе, аның Тәңкәсе дә бар ич әле! Нишләп бик тиз онытты соң әле ул аны? Төштә булганмы Тәңкә, өндәме — шулай да ул аның беренче елмаюларын, беренче якынлыгын, беренче куанычларын оныта аламы? Юк, юк, ул аны онытмас, оныта да алмас! Менә шулай онытып булмаган өчен дә соңгы көннәрдә ул еш кына аның алдында оялу, уңайсызлану кебек бернәрсә кичерә түгелме соң? Андый чакта ул шундук үз-үзенә «төзәлергә» — моннан соң гел аның турында гына уйларга, яратып, якын итеп уйларга сүзләр бирә. Аңа бераз гына җиңел булып китә. Аны инде беркем дә, берни дә борчый алмас сыман тоела башлый. Күп тә үтми, кемдер аны яңадан тынычсызлый башлый.

Ник болай бу? Нигә алар аңа беркайчан да тынгы бирмиләр?

Ул уфтанып куйды. Учакка утын өстәде. Уйланып, моңаеп аның таңга тикле утырасы килде. Аның инде күптән, бик күптән менә шулай учак янында изрәп утырганы юк иде. Нинди күңелле, нинди җылы-моңсу монда! Әллә тормыш шушы үземе соң? Тәңрем? Баш өстендә түбә, каршыңда — утлы күз. Тагын ни кирәк сиңа, адәм баласы?!

Шулай утыра торгач, тышта аңа ниндидер кыштырдык ишетелгәндәй булды. Аның колаклары үрә торды. Ул, эчке бер курку-каушау белән, тынын кысып көтә башлады. Үзенең шултикле куркаклыгына аның исе китте. Ул берни эшли алмады — каушаудан аның куллары, аяклары калтырана башлады.

Кемдер кыюсыз гына ишек бавын тарткалады.

— Керегез, кер! — дип кычкырды җегет, урыныннан торып.

Ишек ачылып китте, өйгә ниндидер карачкы килеп керде. Бу Торымтай түгел иде. Карачкы беравык ишек төбендәрәк торды да кыюсыз гына бер-ике адым алга атлады. Тотыш, керүчедән күзләрен алмыйча, артка чигенде. Ул, саллырак бернәрсә тапмакчы булып, идәнгә күз төшереп алды: учак янындагы утын агачларыннан башка берни юк иде.

— Син кем? Кем кирәк сиңа монда? — диде ул.

— Миңа... Тотыш кирәк...— диде карачкы, сынып-өзелеп чыккан бер тавыш белән.

Тотыш аның каушавын, калтырануын бөтенләй сизмәде, ул бары аның «Тотыш кирәк» дигән сүзләрен генә ишетте.

— Ник кирәк ул сиңа?! — диде ул, кычкырып.

Аның маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты, аның иреннәре кипте. Ни булды соң әле аңа? Ник, нилектән шулай кисәк кенә коелып төште соң әле ул?

Карачкы эндәшмәде. Тотыш та тынып калды, көтә башлады. Ул карачкыны аерыбрак күрә башлады. Чынында ул аны монда кергәч үк... кергәнче үк күргән иде бугай инде... Тик... Әйе, буйга ирләр кебек озын түгел, иңбашы да ирләрнеке кебек түгел. Тавышы да икенче төрле иде бугай.

Алар, нәрсәдер көткән сыман, баскан урыннарыннан кузгалмыйча тик тордылар. Карачкы тамак кырды, бер-ике адым учакка таба атлады да кинәт битендәге бөркәнчеген ачып җибәрде. Көтмәгәндә күзенә көчле яктылык төшкән сыман, йөзенә кисәк кенә ялкын бәрелгән сыман, Тотыш, исе китеп, аһылдап җибәрде. Аның каршысында, тулган айдай балкып, сокландыргыч гүзәл бер кыз басып тора иде. Ул да аның кебек каушаган иде, ул да аның кебек тынычсыз иде. Аның да оялчан керфекләре, алып җегетнең йөзенә туры карый алмыйча, бер йомыла, бер ачыла иде. Ап-ак бит очларында аның җиңелчә генә алсулык уйный иде. Юка бөркәнчегә аша аның калку күкрәге сизелер-сизелмәс кенә тирбәлеп тора иде. Аның серле, нурлы күз карашыннан ниндидер яктылык бөркелеп тора сыман иде. Аның киемнәреннән юкә чәчәге иседәй җиңел, татлы ис тарала иде. Ул үзе дә, болан баласыдай, җиңел, җитез сыман, учактагы ялкындай кайнар сыман иде.

— Мин сиңа... ашарга китердем... Тотыш,— диде ул, тотлыгып, сулуы кабып.

Ул өйнең табак-савыт торган төшенә килде, өстендәге бөркәнчек итәге астыннан көмеш күбәтә белән көмеш комган чыгарды. Шуларның барысын да ул савыт-саба янына утыртып куйды. Билен турайтканда ул качып кына, яшертен генә Тотышка бер күз карашы ташлап алды. Тотыш аның бу угрылыгын күрми калмады. Бераз гына дымсу, бераз гына томанлы, тере күз карашы яшь җегетнең йөрәгенә ут үрләтеп җибәрде.

— Теге... синмени ул? — диде Тотыш, пышылдап.

— Мин...— диде кыз, шулай ук пышылдап.

— Мин сине көттем,— диде җегет.— Нигә килмәдең?

— Җибәрмәделәр,— диде кыз, башын иеп.

— Кемнәр?

— Курыктым...— диде кыз.— Сизсәләр, күрсәләр... Ярамый...

— Кемнәр җибәрмәде соң? — диде Тотыш, соравын кабатлап.

— Иям,— диде кыз, көттеребрәк.

— Ашарга да ул җибәрдеме?

— Ул.

— Кем соң ул? — диде җегет, төпченеп.

— Аппак...— диде кыз, пышылдап.

— Аппак?! — диде Тотыш.— Алмыш хан кызымы?

Кыз баш какты. Тотыш аптырап калды, каушап калды. Алмыш хан кызы аңа ашарга-эчәргә җибәргән! Ник? Яратамы, кызганамы? Үзеннән калган калдык-постыкнымы? Димәк, бу кыз аның карасы... асравы, йомышчысы?

Ул искәрмәстән айнып киткәндәй булды. Үзендә ул күңел кайту сыман бернәрсә тойды. Бу гүзәл кызның кара булуы өчен түгел, монда тагын икенче бер кеше барлыгын белгән өчен ул күңел кайту шикелле нәрсә тойды. Кем белә, ул икенче кеше артында тагын өченче кеше дә бардыр! Хан кызы Аппак, имеш. Аның туган җирен килеп баскан ханның, үзен менә тоткын итеп кулга алган ханның... каргалган канечкеч ханның кызы, имеш! Юк! Юк булгач, юк!

Күзләрдәге дымлы элпә юкка чыкты, тамырларда ургып аккан кайнар кан бозга әйләнде.
— Мин тереләдем, миңа берни кирәкми,— диде ул, кызга тыныч бер салкынлык белән.
— Алырга кушты... күчтәнәч...— диде кыз, баштагыдан да ныграк каушап.
— Миңа хан кызыннан бернинди күчтәнәч кирәкми! — диде Тотыш, шактый тупас итеп.
— Ул сине ярата, Тотыш! — диде кыз.

Ул моны ничектер ыңгырашып әйтте. Аның тавышында курку да, ялыныч та, ярсу да сизелде. Шулай да ул тотык егетнең күңелен кузгата алмады. Бары ишетеп кенә белгән нинди дер кызның яратуы турындагы сүзләр күз алдында басып торган тере кызның гүзәллеге янында бөтенләй көчсез булып яңгырады. Алай гына да түгел, үзенең яратуын карасы аша белдереп яткан хан кызына карата җегет күңелендә ачу тойгысы кузгалды.

— Мин — Алмыш ханның тотыгы,— диде ул, кыздан күзен алмыйча.— Инде аның кызының тоткыны буласым юк!
— Ул сине ярата, Тотыш! — диде кыз, ашыгып, кабатлап.
— Мин аны яратмыйм! — диде Тотыш, усал итеп.

Ул кыз китергән күбәтә белән комганны алды да кире бирмәкче булды. Кыз алмады.
— Кирәге юк хан кызының калдыгы! — диде җегет, ачу белән.

Ул күбәтә белән комганны идәнгә орды. Көмеш капкач чыңлап, ыңгырашып читкә тәгәрәде, ашамлык көлгә түгелде. Комганның нечкә муеныннан, киселгән бугаздан аккан кан сыман, голт-голт килеп ачы бал агып чыкты.

Кыз, кулы белән битен каплап, чыркылдап кычкырып җибәрде. Кырт кына борылды да, итәгенә ут капкандай, ишеккә ташланды.

**XI**

Тотыш бик соң исенә килде. Исенә килде дә шулай ук ишеккә ташланды, атылып тышка чыкты. Кара мачы булып, шундук аның юлына караңгылык аркылы төште. Ул, өйдән берничә адым читкә киткәч тә, тукталып калды. Күзләрен зур ачып як-якка каранды, тавышларга, төрле кыштырдыкларга колак салды. Кычкырырга, кызны чакырырга аның йөрәге җитмәде. «Аңсыз! Белексез! Туң баш!» — диде ул, үз-үзен сүгеп, әрнеп, үкенеп.

Караңгылык, билгесезлек алдында аптырап, кая барырга белмичә ул торды-торды да, күзе ияләнә төшкәч, каядыр кузгалып китте. Аның өйгә керәсе килмәде. Аның ярсыган, өзгәләнгән күңеленә киез өй эче генә түгел, әйтерсең барлык күк эче дә, барлык җир йөзе дә кысан иде. Аңа йөрергә, каядыр барырга кирәк иде, аңа тик тору, утыру, яту ярамый иде. Тирә-якта адым саен дошманнар барлыгын да, төнге кирмәнне бик зур тимер кыршау сыман итеп каравыл уратып алганлыгын да ул бик яхшы белде. Шулай да ул өйләрдән дә, күзгә күренмәгән каравылдан да курыкмады. Үзенең кая барып чыгасын бөтенләй белмәстән, ул караңгы төннең күзенә туры карап алга атлады. Ул үзендә искиткеч бер җиңеллек тойды. Аның аяклары җиргә тисә тиде, тимәсә тимәде. Юк, ул йөгермәде, ул әкрен генә барды. Ул аны куып җитмәкче булып, аны яңадан күрмәкче, очратмакчы булып барды.

Кайда булыр ул? Кая китәр ул? Ул шушында гына, шушы тирәдә генә булырга тиеш. Әле генә ул аның яныннан чыгып китте. Өй эчендә аның татлы исе, күз алдында — күркәм, гүзәл төсе торып калды. Карачкы өйләр, әйтегез — кая китте ул? Күктәге болытлар, карачкы калкулар, әйтегез — кайда ул? Сез күрергә тиеш аны. Андый кызны күрмәү-белмәү язык булыр!

Ул чыклы үлән ерып барды. Ян-якта очлы кара өйләр калды, йөк тулы арбалар калды, кайдадыр атлар пошкырды, кайдадыр этләр өрде. Ул әйтерсең берни күрмәде, берни ишетмәде. Ул әйтерсең саташып йөрде. Ул әйтерсең нинди дер үләләр кирмәне аша барды. Ул, билгеле, өйләрне дә, йөк төялгән арбаларны да читләтеп үтәргә тырышты. Кайбер төштә ул кинәт җиргә ятты, кайбер төштә посып, тыңлап торды. Төнге каравылга эләкмәүдән аны нинди дер моңарчы билгеле булмаган бер тойгы саклап барды.

Күп тә үтмәде, ул нинди дер агачлар арасына барып керде. Ылыслы нарат ботаклары аның битеннән сыйпап-сыйпап алды. Борынына таныш ылыс исе килеп бәрелде. «Әллә кирмәннән чыктыммы?» — дип уйлады ул, артына борылып. Тирә-ягына ул беренче тапкыр нык ытыбрак карады, нык ытыбрак тыңлап торды. Күзгә күренмәс тимер кыршау, тимер кыршау эчендәге өйләр, кешеләр, арбалар — барысы да артта калган иде бугай. Тонык кына тавышлар ул яктан килә иде, сирәк-мирәк утлар да ул якта җемелди иде. Алда — тынлык, бушлык, караңгылык.

Туктале, котылды түгелме соң ул? Тоткыннан, коллыктан котылды түгелме соң ул?!
Әйе, әйе. Котылды...
Котылды!

Кинәт аның тыны бетте, аяк буыннары йомшап калды. Уттай янган күзләре белән ул тагын артына борылып карады. Карады да бар көченә чабарга тотынды. Ят җир булса да, урманда аңа куркыныч түгел иде. Урманны ул белә иде, урман аның күптәнге танышы, якыны, дусты иде.

Аның битенә, кулына чыбык очлары тиеп китте, аяклары җирдә яткан ниндидер агачларга, корыган төпсәләргә төртелде, ниндидер кечкенә чокырларга батып-батып китте. Ул бернәрсәгә карамыйча йөгерүен белде.

Шулай күпмедер йөгергәч, ул урманның сирәкләнә башлавын, җир өстенең түбәнәюен шәйләде. Ул яңадан туктады, як-ягына җентекләбрәк карарга тотынды. Караеп тын гына утырган агачлардан башка ул берни дә аера алмады, шулай да эчке бер сиземләү белән, аннары якын-тирәдәге тыгыз, куе тынлык буенча ул үзенең чыннан да камалудан ычкынганлыгын аңлады. Аның аз гына булса да тынычлап, ял итеп аласы килде. Тик аяклары аны туктаусыз алга өстерәде.

Алда урман яктырганнан-яктыра барды. Каяндыр үтеп кергән яктылыкта төз нарат кәүсәләре, бер-берсеннән аерылып, аермачык булып күренделәр. Таң атарга әле иртәрәк иде бугай. «Каян килә бу яктылык?» — дип уйлады Тотыш, исе китеп.

Яктылык үтеп кергән яктан аның борынына салкын су исе килеп бәрелгәндәй булды. Бераз баргач, урман бетте, тирә-як ачылып, яктырып китте. Тотышның аяк астында төнге Чулман җәелеп ята иде.

Чулман! Бөек елга, туган елга! Чынмы бу, ялганмы? Син өндәдең, син чакырдың мине, син коткардың тоткын углыңны! Сагындыңмы Тотыш угланны? Менә килдем, менә таптым сине! Без яңадан бергә, изге елга! Бергә булыйк, аерылмыйк мәңге, Чулманым!

Ниндидер ботак-сатакларга абынып, ул текә ярдан аска төште. Талгын гына чайкалып, агып яткан су янына килде, иелеп, битен-кулын юды. Аннары ул бер-ике адым эчкәрәк керде. Аяк тамырлары буйлап, кытыклап, татлы бер дулкын йөгерде.

Чынмы бу, ялганмы? Аның күз алдында, аның янында, ялангач аякларын иркәләп, сыйпалап, үз телендә нидер гөлдер-гөлдер килеп, йомшак, көчле, салкынча су акты да акты...

Чынмы бу, ялганмы? Юл ачык! Туп-туры Кызыл Яр катауга, туган җиргә юл ачык. Адашырмын, юлдан язармын дип куркасы юк. Күзләреңне кысып йомарга да, кулларыңны күтәреп бер омтылырга да, аяк очларыңны менә шулай суга тидереп ала-ала очып-йөгереп китәргә! Уңга-сулга каермыйча, имгәтмичә, егылтмыйча Чулман үзе алып кайтыр. Алып кайтыр да, туган җирнең, Кызыл Яр катауның ташлы яр буена куеп калдырыр.

Тизрәк, тизрәк! Таң атканчы, көн туганчы моннан ычкынырга кирәк!

## XII

Шул чакны кайдадыр якында гына «чык!» иткән тавыш ишетелеп китте. Ташка таш тидеме, тимергә тимер тидеме... Куркытылган киек кебек колакларын үрә торгызып, Тотыш ялт кына артына борылып карады. Яр башында, өскә ишелеп төшәрдәй булып, биек, калын урман капланып утыра иде. Яр астында, таудай булып, ауган агачлар, ишелгән ташлар, балчык кисәкләре өелеп ята иде. Шунлыктан ул, күпме каранса да, якын-тирәдә шикләнерлек берни дә күрә алмады.

Сагаеп, тынын кысып, ул коры җиргә чыкты, тыңлаудан-караудан туктамыйча, якындагы агач-таш өеменә таба атлады. Өем артында ниндидер йокылы ирләр тавышы ишетелеп китте. Тотыш туктап калды, ауган агачлар арасыннан муенын сузып, тагын да ныграк бирелеп тыңлый башлады. Анда, өем артында, кемнәрдер бар иде. Иренеп кенә, теләр-теләмәс кенә алар нидер сөйләнгәндәй итәләр иде. Алар үзләре күренмиләр, бары шул йокымсыраган ялкау тавышлары гына ишетелә иде.

Кемнәр булыр бу — болгар сакчыларымы, балыкчылармы — кемнәр?

Әле генә шундый якын булып, аңлаешлы булып тоелган Чулман юкка чыкты. Аяк астында төпсез, караңгы, куркыныч су барлыкка килде. Ник килде соң әле ул монда? Качып килдеме, адашып кына килеп чыктымы? Ялгышмады микән ул тоткынлыктан качып? Тоткынлыктан? Өйдән чыгып китү генә тоткынлыктан котылу була ала микән әле? Чыннан да, ул моннан качып китә алса, Алмыш хан аны эзләргә кораллы ирләрен җибәрмәсмени? Туган җиренә кайтып җитеп, анда атасы-анасы, ырудашлары күзенә күренде исә, яңадан зур көч белән килеп, Алмыш хан акбүреләрне пыр туздырмасмыни? Кайгы өстенә кайгы, талау өстенә талау...

Шулай булгач кемнәрнеңдер тотып алганын көтеп тормастан, яңадан үз өеңә, үзеңнең тоткынлыгыңа кире әйләнеп кайтудан да яхшысы булмас, ахрысы.

Тотышның күңеленә шундый каршылыклы уйлар килде. Ни генә булмасын, аның бу килеш... коралсыз килеш беркемгә дә күренәсе килмәде. Ул инде борылып кирегә китмәкче дә булган иде, посып тыңлап торган җиреннән кузгала да башлаган иде,— шул чакны көтелмәгән бернәрсә булды. Ул баскан коры агач кинәт шартлап сынып китте. Йокымсыраган тирә-якны сискәндереп, таң алды тынлыгында олы тавыш яңгырады. Шул ук мәлдә диярлек Тотышның колак төбеннән генә сызгырып ук очып үтте. Каяндыр аяк астыннан — әллә агач-таш өеме арасыннан, әллә яр буеннан ниндидер -кешеләр атылып чыкты. Чыктылар да, чыбык-чабык арасында буталып калган ят җегетне эләктереп тә алдылар.

Бу ничектер бөтенләй көтмәгәндә булды. Тотыш исенә килергә дә өлгерми калды. Кораллы кешеләргә ул бернинди каршылык күрсәтә алмады. Көчле ирләр, бернинди тавыш-тын чыгармыйча, аның кулларын бәйләделәр дә агач-таш өеме артына үзләренең куышлары янына алып киттеләр.

Монда аларны икенче кешеләр каршы алды. Болары да, барысы да кораллы ирләр иде. Аларның алпакларына каз каурые беркетелгән иде. Ямгырчы би белән бергә Кызыл Яр катауга килгән ирләрнең дә алпакларына шулай каз каурыйлары кадалган иде. Казаяклар кулына эләгүен аңлап, Тотыш тынычланып калды. Ямгырчы би җире микәнни бу? Ямгырчы би, Тәңкә... Аның Тәңкәсе, димәк, кайдадыр монда якында гына булырга тиеш! Шулай да ул моңа сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәде.

Монда, Чулман яры тугайланып эчкә кергән җирдә, су өстендә унлап көймә тора иде. Шунда ук берән-сәрән кешеләр күренә иде. Нишләп яталар соң болар монда җыйнаулашып?

— Кем син? — диде аңа куыш янындагы ирләрнең берсе.

— Кулны чишегез,— диде Тотыш.— Авырта.

Ирләрнең берсе мыскыллап көлеп куйды.

— Авыртамыни? — дигән булды.

— Минем кулым яралы,— диде Тотыш, тыныч кына.

Ирләрнең өлкәне — сорау алырга җыенганы, бәйләнгән кулны чишәргә кушты.

— Качса әле! — диде мыскыллап көлгән ир, мыгырданып.

— Синнән дә куркаграк булырга Тәңре язмасын,— диде Тотыш, үчекләшеп.

— Син кем — озын колакмы[1]? — диде ирләрнең өлкәне, кырыс кына.

— Озын колак? — диде Тотыш, исе китеп. Үзенең казаяклар өчен чит-ят түгел икәнлеген белгәнгә ул, беравык көттереп торды да, ирләрнең берьюлы авызларын томаламакчы булып: — Беләсезме, мин кем? Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең Тотыш атлы углы,— диде.

— Күрән би углы? — диде ирләрнең өлкәне, Тотышны баштанаяк күздән кичереп.— Би углына монда ни калган? Кая атың, кая шаең[2]?

— Хо! — диде мыскыллап көлгән ир.— Күрән би углы, имеш! Би угыллары белән безнең белешлек юк. Би янына алып барырга кирәк — таныса, ул таныр.

— Би йоклый булыр,— диде икенче бер ир, сүзгә катышып.— Нәрсә шуның белән ваклашып торырга, аяк-кулларын туракларга да балыкларга ыргытырга! Беткәнмени Чулман буенда каңгырып йөргән сукбай. Берәр нәрсә чәлдермәкче булып иснәнеп йөридер.

— Күрсәтермен мин сиңа сукбайны! — диде Тотыш, ярсып, үзен мыскыллаучыга борылып.

Ирләр аны-моны уйлап өлгергәнче, ул әлеге ирнең якасыннан эләктереп тә алды, ачу белән этеп тә җибәрде. Йокысыннан арынып җитә алмаган казаяк ире арты белән дыңк иттереп җиргә барып төште. Башка ирләр шунудк коралларына тотындылар. Кемдер арттан Тотышның яңадан кулларын тотып алды, кемдер бау белән бәйләргә тырыша башлады.

— Менә карагыз! — диде Тотыш, уң кулын алга сузып.

Аның урта бармагында көмеш йөзек елтырап күренде. Йөзек кашына Акбүре ыруының тамгасы сугылган иде. Казаяк ирләре яхшылап карасалар, тамганы күрми калмаслар иде, билгеле. Тик аларның күзе, тамгадан бигрәк көмеш йөзеккә төште. Ул арада арты белән җиргә барып төшкән ач яңаклы ир, аягына басты да, искәрмәстән егеткә сугып җибәрде. Шуны гына көткән кебек, ирләрнең икенче берсе аның бармагындагы йөзеген суырып алмакчы булды. Тотыш ачу белән кулын тартып алды да көмешкә кызыккан иргә сугып җибәрде, ач яңаклыга аягы белән типте. Алар икесе ике якка барып төштеләр. Шау-шуга шул чакны читтәге кешеләр җыела башлады.

— Туктагыз! — диде ирләрнең өлкәне, үз кешеләрен тыеп.

— Илтегез мине Ямгырчы бигә,— диде Тотыш.— Аңа минем сүзем бар.

— Сүзе бар, имеш! — диде ач яңаклы, яңадан аягына басып, бәйләнмәкче булып.

— Илтергә кирәк,— диде ирләрнең өлкәне.— Ниткән эш бу? Бер йөзек өчен талашып, бөтен эшне бозып куярсыз.

— Йөзеге барыбер үземә. Ул минем авызны канатты,— диде йөзеккә ябышкан ир, канлы авызын токалап.

— Әйдә, киттек! — диде ирләрнең өлкәне, Тотышка эндәшеп.— Башың исән чакта үкчәңне күтәр. Юкса йөзегеңне түгел, әллә нәрсәңне каерып алырлар бу башкисәрләр.

**XIII**

Үз өендә яланаяклы, яланбашлы Тотышны күреп, Ямгырчы би шаккатты. Каршысында басып торган яшь җегетнең чыннан да Тотышмы, түгелме икәнлеген белергә теләгән сыман ул аны токалап, капшаштыргалап карады. Алай да ышанып җитмәгәч, аны яктыгарак алып килде.

— Менә,— диде Тотыш, кулындагы әлеге дә баягы йөзеген күрсәтеп.

Ямгырчы би йөзеккә карап та тормады.

— Әйе, Күрән би углы... Тотыш...— диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Минем киявем... буласы кеше, качкын, угры, бозык Тотыш!

— Юк! — диде Тотыш, кызарынып.

— Ха-ха! Нәрсә «юк?» — диде Ямгырчы би, көлеп.— Атаңнан, ырудашларыңнан качып котылдым, дисең инде, ә? Юлбасар булдым, сукбайга әйләндем, дисең инде, ә? Ха-ха! Күрән би углы Тотыш! Минем кызымны station аздырып йөргәндә яхшыемы?.. Менә каптың кармакка! Тиреңне тунап, телгәләп, утлы табада кыздырып... мин сине... Ха-ха, би углы Тотыш! Кияү балакай!

Ул, шулай кинәт кабынып, үзалдына тузынды-тузынды да әрле-бирле йөренеп алды, туктады, тагын йөренеп алды, тагын туктады, билләренә таянып, ач бүредәй тешләрен шыгырдатып, үз кулына җиңел генә килеп капкан киеккә карап торды.

— Кызык,— диде ул бераздан, басылгандай итеп.— Шушы көнгә төштем дисең инде, ә? Ничек ычкына алдың соң син ырудашларыңнан? Атаң качырдымы, анаңмы? Утташ кам белми әйтмәгән икән: йоланы таптый, түрәне тотмый, дип... Инде таптый алмас, ха-ха! Минем сүзне тыңламады. Үзенә үпкәләгәндер. Син әле белмисеңдәдер, сөекле киявем, Алмыш хан синең йортыңны-илеңне пыр туздырып ташлады ич! Катавыгызның көлен күккә очырды. Атаңны-анаңны, туганнарыңны, ырудашларыңны турап чүплеккә, Чулманга ыргытты.

— Ялган сөйлисең, би! — диде Тотыш.

— Ха-ха! — диде Ямгырчы би, шаркылдап.— Ялган? Син бер дә миңа ышанмыйсың әле, кияү. Мин сиңа ишеткәнемне сөйлим: Алмыш хан Чулман буен яулап кайтып килә!

— Мин сиңа күргәнемне сөйлим, би: Алмыш хан синең борын төбеңдә утыра! — диде Тотыш.

— Күргәнне? Туктале, тукта... Алмыш хан карчыгадай барып сезнең ояны туздырганда, син әллә агач башында карап тордың, уңган җегет?

— Әйе, карап тордым,— диде Тотыш, теләмичә генә.— Шулай да син уйлаганча карап тормадым, би.

— Әт-тә-тә-тә! Кызык, яман кызык,— диде Ямгырчы би, чын-чынлап кызыксынгандай итенеп.— Алайса сөйләп җибәр, углан, нинди җилләр ташлады сине монда? Сөйлә, сөйлә, тартынма... син минем киявем... буласы кеше лә!

Ямгырчы бинең мыскыллы сүзләрен Тотыш бер агарынып, бер кызарынып тыңлап торды. Ул аны болай булыр дип башына да китереп карамаган иде. Ул аның янауларыннан әз генә дә курыкмады, шулай да ул аңа үзенең бу якларга ничек килеп чыгуын аңлатуны кирәк тапты. Үз башыннан кичкәннәрнең ул барысын да сөйләмәде. Ул бары Кызыл Яр катауның, Күрән бинең, анасының исәнлеген, акбүреләрнең Алмыш ханга калан биреп котылуларын гына әйтте дә, ханның үзен тотык итеп алып китүен генә әйтте.

— Синең җирдә туктап торганны белдем дә, тоттым да качтым,— диде ул, үзенең качуын шулай җиңел генә аңлатып.— Минем сугышасым килә, Алмыш ханнан үч аласым килә. Синнән башка кем корал бирер миңа, би?

Соңгы сүзләрен ул кискен бер омтылыш белән, эчке бер күтәренкелек белән әйтте. Ул сөйләгәннәрнең берсе дә кеше ышанмаслык булмаса да, яшь җегетнең бу чын күңелдән әйткән сүзләре бинең соңгы шикләрен юкка чыгарды.

— Син... Күрән би углы Тотыш... әле син шулай корал да тота беләсеңмени? — диде ул әкрен генә, бөтенләй үзгәреп.— Мин сине белмим. Өегездә сине башбаштак дип... ни... ы... сүз тыңламый торган бала дип сөйләделәр. Кызыл Ярдан буш кул белән кайтып киткәндә мин синнән, атаңнан үч алырга дип үз-үземә сүз бирдем. Мин үчлекле кеше. Инде менә үзең кармакка килеп капкач... Юк, Тотыш углан, мин кире уйладым. Минем дә, синең дә ягы бер — Алмыш хан. Аның сыртын сындырмыйча торып, миңа тынгы булмаячак. Туганымнан бирле мин болгарларга каршы астыртын эш алып барам, туганымнан бирле мин кылыч күтәрергә җай көтеп тордым. Менә ул җай килде! Акбүреләр сүземне аяк астына салып таптагач, бик күңелем кырылганые. Ни булса да булыр дип, мин язмышымны үзем генә сынап карамакчы булдым. Мин сиңа корал бирсәм, йөз кешелек алай бирсәм, син нишләрсең, Тотыш углан?

— Болгарларга каршы уктай атылырмын, би! Өсләренә арысландай ташланырмын, бугазларын чәйнәрмен!

— Антмы?

— Ант! Ант! — диде Тотыш, кайнарланып.

Ямгырчы би, кылычын кыныдан тартып чыгарды да, яшь җегеткә сонды.

— Үп! — диде.

Тотыш, кылычны ике куллап тоткан килеш, кайнар иреннәрен салкын тимергә тидерде.

— Биргән антымны бозсам, бу күк керсен, кызыл чыксын![1] — диде ул.

Ямгырчы би кылычын кире алды, шартлатып кыныга салды да, шундый кискен үзгәрештән соң тиз генә исенә килә алмагандай, идән буенча йөренеп килде, күкрәген киереп, аякларын аерып, яңадан Тотыш алдында туктап калды.

— Менә без килештек, Тотыш углан,— диде ул, бушанып, җиңел сулап.— Инде мин сине чыннан да үземнең киявем дип саный алам.

— Бай бул, эти,— диде Тотыш, тыйнак кына.

Ямгырчы би аның сүзен бөтенләй ишетмәде дә.

— Мин сиңа әйтеп бетермәдем, Тотыш углан,— диде ул, тавышын әкренәйтә төшеп.— Мин сиңа барысын да әйтеп бетерергә тиешмен. Мин бүген, кояш чыгу белән, яу башлыйм. Минем кешеләрем урман араларында, яр буйларында минем боерыкны гына көтеп торалар. Искәрмәстән мин болгарларның олауларын басып алачакмын, ирләрен турап ташлаячакмын. Алмыш хан үзе теге якта. Чирүенең күбесе чыгып бетте. Тәкин угланны мин аны!.. Чулман буеннан талап алган байлыгын... бер тиенен, төлкесен калдырмыйча... Ул безнең байлык — синең, минем байлык, Тотыш углан! Синең, минем ... караларыбызның тир түгеп тапкан малы! Ни өчен әле без аны юлбасарга биреп җибәрергә тиешбез? Кай җире артык аның бездән? Тәңре аны хан итеп яраткан икән, менә без аның ул ялгышын төзәтербез. Моннан соң бөтен Итил-Чулман буена Ямгырчы би баш булачак, Тотыш углан... кияү! Аргы якта аны суарлар кисәчәк, бу якта — без. Ике ут арасында, ха-ха! Тәңрем-Аллам, юлдаш булыгыз миңа!

— Мин олауларның кайдалыгын беләм,— диде Тотыш.

— Белсәң, сиңа бурыч шул: син олауларны, үз атаңның, бөтен Чулман буеның байлыгын... Аннан да бигрәк безгә ничек тә аның кызы Аппакны кулга төшерергә кирәк.

— Аппакны?! — диде Тотыш, ялгыш ишеткән сыман, кабатлап.

— Әйе, Аппакны! — Ямгырчы би, йодрыкларын йомарлап.— Аппак берүзе бөтен Болгар йортка тора. Алай-болай җиңелсәк тә, Аппак безнең кулда калырга тиеш!

Аппакны искә төшерү Тотыш инде бөтенләй оныттым дип уйлаган күп нәрсәне яңадан күз алдына китереп бастырды. Тотыш кинәт телсез-өнсез калды.

## XIV

Ямгырчы бинең кешеләре яшеренгән җирләреннән — урманнардан, чокыр-чакыр араларыннан чыгып, болгарларның төнге каравылына ташланганда, Тәкин углан да, аның ирләре дә берни белми йоклап яталар иде. Казаяклар, көчле ук яңгыры яудырып, болгарларның үзәк юл өстендәге каравылын кырып салдылар да, шауламыйча, мыштым гына эш итәргә дигән боерык булуына да карамастан, коточкыч тавыш, шау-шу куптарып, йокылы өйләргә, олауларга, болындагы көтүләргә ташландылар.

Яу чабып өйрәнгән, чыныккан болгарлар бик тиз уяндылар, аякларына бастылар. Өлгергәннәр атларына атланды, өлгермәгәннәр атсыз калды. Яшел урманнар, болыннар өстендә яңа көн туып килгәндә, ике арада канлы сугыш башланып китте.

Күктәге тургайларны, җирдәге күбәләкләрне куркытып, ямьсез тавышлар белән кешеләр кычкырды, өркеп атлар пошкырды. Чык тамчыларыннан арына алмыйча, авыраеп утырган чәчәкләрне таптап, тупас аяклар йөгерде. Баш очында үткер тимерләр уйнады. Котлары алынган хатын-кызлар, бала-чага, җылашып, шашынып, кайсы кая качарга тотынды. Болын буйлап, мөңгерәп, кычкырып, пошкырып, төркем-төркем сыер-сарыклар, атлар чабышып йөрде.

Казаякларның бер өлеше кичү янында болгарлар белән сугышканда, икенче өлеше, каекларга утырып, су өстеннән сал-күпергә якынайды. Болгарларның күпер өстендәге каравылы коры җирдәге каравылга караганда уяурак булып чыкты. Төне буена кешеләрне, атларны чыгарып торганга, алар әле булса аяк өстендә иде. Казаякларны алар күпергә якын да җибәрмәделәр — ук атып, таш ыргытып, кире бордылар. Ике каек яндырылды. Унбишләп кеше үтерелде. Яр буйлап килгән җәяүле казаякларның исә барысы да кырып салынды.

Башта ук эшнең үзе уйлаганча барып чыкмавына Ямгырчы бинең бик нык ачуы килде. Теләсә кая таралган кешеләрен җыймакчы, бергә тупламакчы булып, ул туктаусыз кычкырынды, сүгенде, янау сүзләре яудырды. Комсызлыктан күзләренә ак-кара күренмәгән ирләрне алай да тыңлата алмагач, чавышлар җибәрде. Кораллы ирләр белән сугышуны онытып таларга тотынган кешеләрне чавышлар сөңгеләр белән куалап, куркытып йөрделәр. Тик бозылган эшне инде чавышлар гына төзәтә алмады. Җылы кан күргән җырткычлар кебек, казаяклар барысы да диярлек бай олауларга ябырылдылар. Күзләре томаланган кешеләр арбаларны аударып ташладылар, тире, кием-салым, савыт-саба, ашлык тутырылган капчыкларны, төргәкләрне эләктереп алдылар да тизрәк таю ягын карадылар. Күтәрә алганы икешәр-өчәр кисәк күтәрде, күтәрә алмаганы юлында очраган бар нәрсәне ватарга, кырырга тотынды. Арбаларга ат җигәргә тырышкан болгарларга сөңге кададылар, атларның аякларын кистеләр, тәртәләрне, киергеләрне кырдылар. Икенче бер җирдә кораллы ирләр, кыйный-кыйный, ашыгып урманга көтү кудылар.

Казаякларның күпчелеге талауга бирелсә дә, Ямгырчы бинең үз янындагы яхшы өйрәтелгән, чыныккан ирләр — йөзләп кеше үз-үзләрен аямыйча сугыштылар. Бу яктагы болгар ирләрен тулысынча кырып салуның булмас эш икәнлеген күреп, Ямгырчы би үзенең барлык көчен үзәккә — күк төстәге байрак кадалган биек ак өйгә таба юнәлтергә булды. Алмыш ханның иң зур байлыгы, мактанычы Аппак шунда булырга тиеш иде.

— Казаяклар-арысланнар! Таптагыз болгарны, сытыгыз көчекләрне! — дип кычкырды Ямгырчы би, әледән-әле үз ырудашларының күңелен күтәреп.

Таркалган болгарлар, казаякларның бер йодрыкка тупланган бердәм, күмәк көченә чыдый алмыйча, әкренләп-әкренләп биек ак өй ягына чигенә бардылар. Аларны бер яктан Ямгырчы би кысса, икенче яктан Тотыш углан кысрыклый иде. Тотыш янында йөз кешедән нибарысы егерме-утыз кеше торып калган — башкалары үлеп, таралышып беткәннәр иде.

Үзәктәге божра кысыла барган саен, болгарлар да ныграк каршылык күрсәтә башладылар. Баш өстендә кылычлар, сөңгеләр селтәнде. Тамак ярып кычкырган, өндәгән, каргаган тавышлар, тимер чыңы, атлар кешнәве — барысы бергә кушылып, коточкыч бер шау-шу тудырды. Ике яктан да ирләр, атлар, киселгән урман кебек, туктаусыз кырыла тордылар.

Сугышның иң кызган бер чагында, ике як та, бер-берсенең бугазына ябышып, бер-берсен таптап үтәргә тырышкан бер мәлдә, болгарлар арасында Тотышның күзенә бер таныш кеше чалынып калды. Ул кеше кораллы түгел иде. Ул, кораллы ирләрдән качып, кая керер тишек тапмыйча, киез өйләр арасында әрле-бирле сугылып йөри иде. Тотыш, үзенең казаяклар ягында икәнлеген онытып:

— Торымтай! — дип кычкырып җибәрде.

Төрле тавыш, шау-шу арасында Торымтай, ахрысы, берни ишетмәде — кулындагы ниндидер агач табакны калкан сыман итеп тоткан килеш, тиз генә бер өй артына кереп яшеренде. Тотышның кемгә кычкыруын якындагы казаяклар ишетеп-аңлап алдылар. Агач калканлы Торымтайның кая качканын күреп калган бер казаяк, мыскыллап көлде дә, шул якка ук атмакчы булды. Тотыш, аркылы төшеп:

— Атма! — дип кычкырып җибәрде.

Нык тартылган кереш ычкынып китте. Тотыш кылычы белән бар көченә селтәнеп җибәрде — әле генә авызын ерып, Торымтай ягына ук аткан ирнең сул кулы беләзек турысыннан киселеп төште. Казаяк ире кан ага башлаган кисек кулын икенче кулы белән кысып тотты да кычкырып җыларга тотынды.

Тотыш, болгарлар тезмәсен өзеп, Торымтай янына ашыкты. Торымтайга дип атылган ук читкә киткән иде, ахрысы, агач «калкан» җирдә аунап ята, Торымтай үзе шуышып киез өй астына кереп бара иде.

— Торымтай! — дип кычкырды тагын да Тотыш.

Коты алынган кол, үзенең өстенә басып килгән атлы ирне күреп, телсез-өнсез калды. Шулай да ул Тотышны танып алды, куанычмы, куркумы белдергән бер өн чыгарды да, үз-үзен сакламакчы булып, кулларын битенә якын китерде. Тотыш, атыннан иелеп, аның якасыннан эләктереп алды, аягына бастырды.

— Курыкма! — дип кычкырды ул аңа.— Аппак кайда... кайсы өйдә?

— А-а-а-а...— диде Торымтай, теле тотлыгып, күзләрен акайтып.

— Алмыш хан кызы Аппак кайда? — диде Тотыш, соравын кабатлап.

Торымтай аңлап алды, Тәкин угланның биек өеннән бер йөз адым чамасы читтәрәк, уңдарак утырган бер өйгә төртеп күрсәтте.

Тотыш бүтән сораштырып тормады, атын борды да, юлына аркылы төшкән болгарларны уңга-сулга селтәп, Торымтай күрсәткән өйгә ташланды. Болгарларның тезмәсен өзгән унлап казаяк та аның артыннан иярде. Шул чакта болгарлар ягында буталыш булып алды. Аларның көче икегә бүленде. Ир-атларның бер өлеше, өзелгән тезмәне яңадан торгызырга теләп, казаякларны эчкә үткәрмәскә тырышты, икенче өлеше Тотыш артыннан куа китте.

Ул арада Тотыш, бернинди каршылыксыз диярлек, Торымтай күрсәткән ак өй янына килеп тә җитте. Тирмәне саклаучы болгарлар казаякларны агулы уклар атып каршыладылар. Тотышның калканына берьюлы ике ук килеп тиде; тиде дә чык-чык итеп читкә китте. Казаякларның берсе, эчен тотып, аты өстенә капланды, икенчесе, авыр капчык сыман, артына авып төште.

— Сытам! Изәм! — дип кычкырды Тотыш, тамак ярып.

Кемдер шунда аңа төбәп сөңге ыргытты. Тотыш иелеп калды, яныннан гына очып барган сөңгене кылычы белән урталай кисеп төшерде. Моны күреп торган болгарлар ахылдап куйдылар, каушап калдылар. Казаяклар исә, бүре талаган бурзайлар сыман, кыюланып, шашынып, болгарлар өстенә ябырылдылар.

Тотыш, атыннан сикереп төште дә, ишек янында таптанган болгарны артка чиктерде, ишек бавын кисеп, эчкә атылып керде.

**XV**

Киез өй эчендә ул ирләр киеме киеп, кулына кылыч тоткан бер кыз белән очрашты. Түбәдәге ачык төннектән киез өйгә иртәнге яктылык төшә иде. Идәндә урын-җир: мендәр, юрган, кием-салым ише нәрсәләр аунап ята иде. Котычыклар, бурдаклар[1] ачылган, йә булмаса урыннарыннан кузгатылган иде. Кемнеңдер монда ашык-пошык нидер эзләгәнеме, нидер яшергәнеме әллә каян күренеп тора иде.

Чит ир килеп керү белән, кораллы кыз кылычын күтәрде, аңа каршы атламакчы булды. Шул чакны аның кылычы да, калканы да шакылдап идәнгә төшеп китте. Тотыш та коралларын чак-чак кына төшереп җибәрмәде. Аның алдында ... аның танышы, аның сөеклесе, аның гүзәле басып тора иде!

Шундук аны, өермәдәй булып, бер-берсенә капма-каршы уй-теләкләр биләп алды. Иң элек аның күңелендә көчле ялкын булып сөенеч тойгысы кабынды. «Менә мин сине тагын таптым!» — дип әйтәсе килде аның. Шул ук мәлдә ул үзенең Ямгырчы бигә ант биргәнлеген, аның колы, ялчысы икәнлеген исенә төшерде. Ялкын сүнде, тимер кораллар авыраеп калды. Ул үзенең тирә-яктан дошманнар белән чолгап алынганлыгын, шуңа күрә бернәрсәгә карамыйча ашыгырга, башкарасы эшен тизрәк башкарырга тиешлеген аңлады.

— Аппак кая? — диде ул, кызга туры карамаска тырышып.

— Аппак кирәкмени? — диде кыз, мыскыллы көлемсерәп.— Аппак кирәкми дигәниең түгелме соң?

— Әйт, кайда ул? — диде Тотыш, кырысланып.

Кыз ялт кына кылычын алды, башын югары күтәрде.

— Аппак юк,— диде ул, матур иреннәрен кысып.— Аппактан җилләр исте!

— Кая китте? Әйтәсеңме, юкмы? — диде Тотыш, аның өстенә килеп.

— Аппак кирәк булган, Аппак! — диде кыз, шыр-шыр көлеп, аның янавын бөтенләй аңламаган сыман.

Тыштагы шау-шу көчәя төште. Тотыш, кызны онытып, тиз генә артына борылды. Ярый әле борылды — ишектән, этешә-төртешә, сөңгеле ике ир кереп ята иде. Тотыш, алар күзенә күренмәс өчен, читкә тайпылды да ишек янына килеп басты. Сөңгеле кешеләр аның кайдалыгын чамалап өлгергәнче, ул, ян яктан ташланып, аларның берсенең сөңгесен, икенчесенең калканын бәреп төшерде. Ирләр куркып кире чигенделәр.

Тотыш алар артыннан тышка ташланды. Монда тавыш, ыгы-зыгы тагын да ныграк көчәеп киткән иде. Сакчы болгарларны туздырып, үтерәсен үтереп, таптыйсын таптап, Аппак өенә казаяклар ябырылган иде. Тотыш алар арасында иң алда Ямгырчы бине күреп алды.

Сугыш исереклегеннән күзе маңгаена менгән, тилергән-шашынган Ямгырчы би атының тезгенен кисәк кенә тартып җибәрде.

— Аппак... булдымы? — дип кычкырды Ямгырчы би, тыны бетеп.

— Аппак юк,— диде Тотыш.

— Юк?! — диде Ямгырчы би, кыргыйларча чинап, күзләрен акайтып.— Ялганлыйсың, юлбасар!

Бер кызудан ул кылычы белән Тотыш ягына селтәнеп җибәрде. Тотыш башын иеп калды. Кылыч аның алпагына кадалган каз каурыен кыеп төшерде.

— Би, үз каурыеңны үзең кистең! Минем сиңа антым юк! — диде Тотыш, агарынып.

Ямгырчы би, кулларын бутап, үзенең ырудашларын изге көрәшкә: болгарларның теләсә кая сибелгән көчләрен юк итәргә, беркемне дә кичүгә җибәрмәскә өндәде.

— Күтәрегез өйне! Эзләгез! Җир тишегеннән табыгыз Аппакны! — дип кычкырды би.

Шуны гына көтеп торган казаяклар, дәррәү кубып, яуга ташландылар.

Шул чакны Тотышны кемдер әйтерсең кинәт алыштырып куйды, әйтерсең кемдер аңа канат бирде, тау-ташларны күтәрә алырлык, Чулман суын буа алырлык чиксез көч бирде!

— Җибәрмим! — дип кычкырды ул, казаякларның юлына аркылы төшеп.— Тәнре белән ант итәм: җибәрмим!

— Кисегез шуны, чабыгыз! — дип җикеренде Ямгырчы би үзенекеләргә.

Көтелмәгән каршылыкка очраган казаяклар аптырабрак калдылар. Берсе шунда «сатлык» җегеттән көлеп, сүгенеп алды, икенчесе, аны җиңел генә сөңге башына күтәрмәкче булып, якын ук килде.

Алмыш ханның алыплары белән орышкандагы кебек, Тотышны изге бер үч-ачу тойгысы, саклык-уяулык тойгысы биләп алды. Тегендә, алыплар орышында, үз артында туган атасы-анасы, туган ыруы барлыгын тойган булса, монда ул үз артында, өй эчендә үзенең сөйгәне барлыгын тойды. Бу тойгы аңа корычтай ныклык бирде, үз-үзенә, үзенең изге эшенә бетмәс-төкәнмәс ышаныч бирде. Күз алдында очлы сөңгеләр, үткер кылычлар күреп, ачулы ыржайган йөзләр, ерткыч күзләр күреп ул әз генә дә каушамады.

Үзенә беренче булып якынаеп килгән ирнең сөңгесен ул, искәрмәстән бәреп, кулыннан төшерде. Сөңге иясе кабаланып кылычына тотынды. Тик кылычын суырып чыгара алмады — туры ыргытылган сөңге, яртылаш күкрәгенә батып, аны шундук артка чөйлектерде.

Казаякларның ыржайган авызлары йомылып калды, ерткыч күзләрендә шүрләү билгесе күренде. Алдагылар ирексездән чигенеп куйдылар, арттагылар кычкырына башладылар.

Тынычлыгын аз гына да югалтмаган Тотыш, үтерелгән казаякның үзе сугып төшергән сөңгесен күтәреп алды да, тагын берәрсе каршы килсә, кадарга чамалап, кире ишек янына чигенде.

— Антын бозды! Тере килеш алыгыз шуны! — дип кычкырды Ямгырчы би, үз кешеләре арасыннан алгарак ерып чыкмакчы булып.

— Иң элек син боздың, би! — диде Тотыш, кауры киселгән алпагына күрсәтеп.

Казаяклар яңадан кыймылдашып куйдылар. Күсәкләр, сөңгеләр яңадан югары күтәрелде. Тотышны уратып алган ярым алка кысыла башлады. Алар күп иде, көчле иде. Бер кешене, күпме генә көчле, күпме генә батыр булмасын, таптап-изеп китү алар өчен әйтерсең берни тормый иде.

— Өйне әйләндереп алыгыз — анда тагын кемдер бар! — дип кычкырды би.

— Тотыш, бирешмә! Без икәү! — диде кыз, аны дәртләндереп.

Аларның соңгы сулышлары якынлашканда, Тәңре аларга изге кулын сузды. Казаяклар төркеме артында кинәт ниндидер шартлау тавышы ишетелеп китте. Казаяклар, куркып, артларына борылдылар. Кемдер тамак ярып:

— Артка төштеләр! — дип кычкырып җибәрде.

Татлы йокысыннан кинәт уятылган Тәкин углан башта каушап, аптырап калды. Шулай да үз янында кораллы ирләрен — төнге каравылны күреп, әкренләп аңа җан керде. Ул арада углан өе янына өс киемнәрен дә тиешенчә кияргә өлгермәгән атлы, җәяүле ирләр җыела башлады. Тәкин углан, әле кычкырынып, әле боерып, таралган, каушаган ирләрен әкренләп бергә туплый алды. Шактый соңлап булса да, алар казаякларга каршы сугышка ташландылар.

Ямгырчы би ирләре, аны-моны карамыйча, аңламыйча, буталып, бер-берсен этеп-төртеп, таптап-изеп, кайсы кая качыша башладылар.

Тотыш, иясез бер атны эләктереп алды да, сикереп атланды да, сөрән салып кычкыра-кычкыра, качучылар артыннан куа китте. Казаякларга бу җитә калды. Алар, артларына борылып карарга да куркып, таланган өйләр,ауган арбалар арасыннан, үтерелгән атлар, кешеләр өстеннән элдерделәр генә. Төрлесе-төрле җирдә бүленеп калган, йә булмаса әле анда, әле монда казаяклар белән сугышып яткан болгарлар да, Ямгырчы бинең качуын күреп, Тотыш артыннан, Тәкин углан артыннан иярделәр.

## XVI

Кулга төшерелгән байлыкларын — көтүләрне, олауларны, кешеләрне калдырып, кыйналып, казаяклар якындагы урманга качтылар. Инде урманга җиттем дигәндә генә, Ямгырчы би чак кына болгарлар кулына эләкми калды. Аны бары ырудашларының батырлыгы да, Тотышның яралануы гына коткарды. Тотыш исә бөтенләй көтмәгәндә яраланды.

Казаяклар теге кыз өен калдырып киткәч тә, ул шактый җир аларны үзе генә диярлек куып барды. Әллә ул бик нык алга чыккан иде, әллә инде якын-тирәдә бер генә болгар да калмаган иде — Тотыш берни белмәде. Аннары ул үзе янында болгарлар булмавына бик үк пошынмады да. Ул үзен болгарлар өчен сугышам дип уйламады. Ул бары Ямгырчы бигә каршы гына сугышты, ул, үзенең кызын саклап, бары аннан үч алырга гына тырышты.

Алдын-артын карамыйча, җилдәй очып барганда, каяндыр аның янына Торымтай килеп чыкты.

— Тотыш! — дип кычкырды ул, адашкан кеше сыман.

Торымтай да ниндидер ямьсез атка атланган иде. Кулындагы кылычыннан башка аның бернинди коралы да, тимерле киеме дә юк иде.

Шулай барганда, сул яктан, Ямгырчы бинең юлын кисеп, Тәкин углан ирләре килеп җитте. Ямгырчы би кырт кына уңга борылды, анда-санда үлекләр белән, төргәкләр белән чуарланган яшел болын буйлап җилдерә башлады. Тотыш та уңга каерды, бинең юлына төшмәкче булып, шулай ук бар көченә атын алга җибәрде. Ара кыскарганнан-кыскарды.

Казаяклар, урман аланындагы ниндидер ерганакка юлыгып, тоткарланып калгандай иттеләр. Ерганак атлар сикереп чыгарлык түгел иде бугай. Менә шунда эләгә язды да инде Ямгырчы би бүре базына! Бер яктан болгарлар килеп җитте, икенче яктан Тотыш белән Торымтай килеп басты. Ике арада каты сугыш башланды. Кешеләр, ярсуның, шашынуның соңгы чигенә җитеп, соңгы сулышлары, соңгы тамчы каннары калганчы сугыштылар. Тимергә тимер тиеп очкыннар чәчрәде, иткә тимерләр тиеп, каннар чәчрәде. Үзләренең җиңелә язып калулары өчен ачулары кабарган, инде канатланып киткән болгарлар казаякларны утын турагандай турадылар, ит чапкандай чаптылар. Соңгы чиккә килеп терәлгән казаякларның шулай ук җиңел генә бирeләселәре килмәде — болгарларга каршы алар арысланнар кебек сугыштылар. Казаяклар каны белән җиргә болгарлар каны да акты. Башы ярылган, кулы, аягы киселгән болгарлар казаяклар янына барып төштеләр, бер-берсенә аркылы килеп, йә булмаса баш-аяк килеп, кочаклашып, мәңге бергә тынып калдылар. Чокыр төбе үлеләр белән, яралылар белән тулды.

Тотыш, үзенә булышка килгән унлап болгар белән бергәләп, Ямгырчы би кешеләрен читкә җибәрмичә, бүлеп торды. Аның ничек тә тезмәне өзеп, Ямгырчы би янына үтеп керәсе, ничек тә аның үзе белән генә орышасы килде. Ул анда берничек тә үтә алмады. Киресенчә, казаяклар туктаусыз аның үзенә басым ясадылар, аның үзен таптап үтеп, чокыр буйлап качып китмәкче булдылар.

Менә шул чагында кемдер Тотышның башына күсәк белән тондырды. Үзенә суккан ирнең Тотыш бары усал күзләрен генә күрде дә таныш шикелле тоелган ач яңагын гына күрде. Күз алдында утлы бөҗралар биеште, бөтен нәрсә зырылдап әйләнде дә, баш-аяк килеп, каядыр түбән тәгәрәде.

Аның янына шундук Торымтай килеп җитте, атыннан авып төшкәндә аны тотып калды. Казаяклар, берничә бөртек болгарны як-якка сибәләп, камалуны өзделәр дә, ур буенча бераз җир чабып бардылар, аннары, сөзәк ярга туры килеп, барысы да чокыр эченә коелдылар, тиз арада икенче як ярга барып чыктылар, комга сибелгән су кебек, урман арасында юк та булдылар. Казаякларның калган бер өлеше, ур төбенә тулган үлекләр өстеннән чыгып, шулай ук урман арасында таралып бетте. Калган өлеше, атын-ниен ташлап, җәяүләп качты.

Уң кулны өзеп чыккан казаяклар арасында Ямгырчы би дә бар иде.

**XVII**

Тотыш күзләрен ачып җибәргәндә, ничектер төн дә шикелле иде, кич тә, иртән дә шикелле иде. Әйләнә-тирә нindидер болганчык караңгылыкка төренгән иде. «Кайда соң мин?» — дип уйлады ул, күзләрен бер ачып, бер йомып.

Күпме тырышса да, ул үзенең кайда ятканлыгын төшенә алмады. Аның бик каты башы авыртты. «Туктале, минем башка сукканнар иде ич!» — дип уйлады ул бераздан, әлерәк кенә булып үткән сугыш күренешләрен күз алдына китереп. Димәк, ул тагын исән калган! Тик менә Ямгырчы бинең артына гына җитеп булмады. Нишләде икән ул? Ничек бетте икән сугыш?

Ул, күзләрен нык ачып, яткан килеш тагын караңгылыкны бер айкап чыкты. Тыңлаштырып торды. Юк, ул берни дә күрә дә, ишетә дә алмады. Шуннан соң ул тирә-ягын капшап карады. Ул нindидер коры, йомшак җирдә ята иде. Ярый әле чокырда түгел! Якында гына нindидер тавышлар ишетелеп киткәндәй булды. Карале, аның колагы томаланган булган ич! Әллә күзе дә шуңа күрмиме? Күрә ич, күрә! Ул, башын калкыткандай итте дә:

— Торымтай! — дип кычкырып җибәрде.

Аның тавышы, төштәге кебек, үзенә дә көчкә ишетелде. «Әллә телдән дә язганмынмы?» — дип уйлады ул, коты алынып.

Бераз тынып яткач, ул тагын кычкырып карады. Монысында ул үзенең ишетүен, ишетмәвен аера алмады — кинәт аның күз аллары яктырып китте: кемдер аның каршындагы калын чыбылдыкны күтәреп куйды. Сыек кына көн яктысында Тотыш үзенең бай итеп җыештырылган киез өй эчендә ятканлыгын күреп алды.

Ул торып утырды, як-ягына каранды. Чыбылдыкның тартылып, җыерылып торган кырые янында нindидер хатын-кыз карачкысы күренде. Өстенә ул җиңелчә бөркәнчек ябынган иде, бер кулына озын муенлы комган, икенче кулына көмеш күбәтә тоткан иде. Менә ул урыныннан кузгалды...

Туктале, тукта... Бу соң тагын теге... ни... аның күзен буган, аның тынычлыгын алган... Әйе, шул! Тик бу тагын теге чактагы кебек төш күрү генә түгел микән? Бер күренеп, бер югалып тора торган нинди серле кыз булды соң бу? Димәк, аңа да берни булмаган. Ул да исән!

Аның баш авыртуы онытылды. Ул урыныннан сикереп торды. Елмаеп, сокланып, ул үзенең танышына, үзенең сөеклесенә карап тора башлады. Шул ук мәлдә аның күңеленә: «Тагын Алмыш хан кызы җибәрде микәнни?» — дигән бер уй килде. Чиксез куаныч тойгысына тузан бөртегедәй генә күңелсезлек өстәлгәндәй булды.

— Мин кайда? — диде ул кызга.

Кыз бөркәнчеген ачып җибәрде, чын күңелдән сөенеп, балкып-елмаеп, яралы егет янына килде.

— Исәнме, Тотыш! — диде ул, язгы тургай тавышыдай чыңлатып.— Башың авыртмыймы?

Тотыш берни әйтә алмады, ул яңадан телсез калды, ул яңадан күрми башлады. Ул, кызның яңгыравык, көйле тавышына, иртәнге кояштай балкыган гүзәллегенә исе китеп, таң калып, алыштырып куелган кешедәй карап тик торды. Кыз да оялып, шулай ук сокланып, елмаеп аңа карап торуында булды.

Беренче соклану кими төшкәч, Тотыш, пышылдап:

— Мин кайда — ник әйтмисең? — диде.— Тагын Аппак тырнагындамы?

— Син тырнакта түгел, ышанычлы кулда, Тотыш,— диде кыз, тыелгысыз елмаюын йомып.

— Мин кайда — ник әйтмисең? — диде Тотыш, соравын кабатлап.

— Син яралы, Тотыш. Терелгәнче син шушында ятачаксың.

— Син имчемени? — диде Тотыш, елмаеп.

Кыз матур иреннәрен тешләп тынып калды, күзләрен түбән иде.

— Мин яралы булсам, минем янга имче килсен,— диде Тотыш.

— Ярар, сау бул,— диде кыз, күңеле кырылып.— Синең янга Байтал имче килер.

Ул, күрәсең, теге чактагы кебек, Тотышның тагын үзен куалап чыгаруыннан курыкты. Шуңа күрә ул, ныклап торып бозылышканчы, тизрәк чыгып китү ягын карады. Ул инде ишек бавына да тотынган иде. Үзе яраткан, үзе тагын бер дә юктан күңелен кырган кыз Тотышка бик-бик кызганыч тоелды. Ул да, кыз кебек үк, теге чактагы күңелсезлек кабатланудан курыкты.

— Тукта, китмә! — диде ул.

Кыз туктады, яны белән борылды да, кызарынып, аның тагын берәр сүз әйтүен көтә башлады.
— Кил әле,— диде Тотыш.
Кыз күндәм генә урынынннан купты, сөрмәле күзләрен күтәреп карарга кыймыйча, яралы егеткә таба атлады.
Тотышның аңа: «Мин сине генә яратам. Сине генә яратам!» — дип әйтәсе килде. Тик ул тагын андый сүзне берничек тә әйтә алмаганлыгын, андый сүзне әйтү өчен кеше көченнән килми торган ниндидер бик зур батырлыкка, кыюлыкка ия булырга кирәклеген аңлады. Тел очына аның бөтенләй икенче сүзләр, җиңел сүзләр килде.
— Аппакка әйт... хан кызына... Мин аны яратмыйм! — диде ул, ашыгып, үртәлеп.
Ягымлы, юаш, күндәм кызны әйтерсең күз алдында алыштырып куйдылар. Кинәт ул башын калкытты, күкрәген киерде. Күз ачып йомганчы, ул билендәге хәнҗәрен тартып чыгарды. Көн яктысында очлы тимер ялтырап китте.
— Менә мин ул Аппак! Мин! — диде ул.
— Син?! — диде Тотыш, шаккатып.
— Мин! — диде кыз, башын югары чөеп.— Телим икән, «ә» дигәнче башың менә монда, аяк астында аунап ятачак!
— Кис! — диде Тотыш, башын иеп.
Ул моны чынлап әйттеме, шаяртып әйттеме — кыз берни аңлый алмады. Шулай да җегетнең бу сүзе, бу кыланышы, агулы ук булып, туп-туры аның йөрәгенә барып кадалды, аның болай да кимсетелгән мин-минлеген яралады. Ул моны Тотышның әлеге дә баягы кирелеге итеп, Алмыш хан кызын яратмавы итеп аңлады. Коры ку[1] сыман кинәт гөлт итеп кабынган ярсуы кинәт юкка чыкты. Баш бирмәс алып җегет алдында ул үзен иң беренче очрашудагы кебек көчсез итеп, кызганыч итеп тойды. Шулай да аның җиңеләсе дә килмәде.
— Ник яратмыйсың, ник?! — диде ул, янау катыш ялвару белән.— Мин шулай яратмаслыкмыни? Котсызмыни?
Тотыш ни дә булса әйтеп өлгергәнче, ул бөркәнчеген өстеннән салып ташлады.
Аның килмәгән бер генә җире дә юк иде. Аның үтә күренмәле ак ефәк аша беленеп торган нечкә биле камыш кебек сыгылмалы иде; иңбашлары, беләкләре, аяклары тулы, тыгыз иде. Аның яшь сылу тәненнән дәрт-ялкын бөркелеп тора иде.
— Әйт: кай җирем ямьсез? — диде ул, чын күңелдән пошынып, чак-чак кына масаю белән.
Тотыш инде чынлап та телдән калды. Иреннәре кипте. Күз алдын ялкын каплап алды.
— Син мине... алдадың...— диде ул, күпмедер тынып торганнан соң.
— Мин сине яратам! — диде кыз.
— Мин дә...— диде Тотыш, иреннәрен көчкә кыймылдатып.

## XVIII

Исән калган ир-атларын, олауларын, терлекләрен җыйнап, Тәкин углан кичекмәстән аръякка чыгара башлады. Үлгән ырудашларын болгарлар үзләре белән алдылар, казаяклар җирдә ятып калды.
Яшел болыннарга, оялчан күлләргә көндәгечә елмаеп кояш карады. Күктә мендәр кебек кабарынкы ак болытлар йөзеп йөрде. Яраларын шәрә ачып, җирдә үлеләр ятып калды. Якты көннең ямен җибәреп, ярым үле яралылар ыңгырашты. Яралылардан да уздырып, таза кешеләр җылашты. Бөтен Чулман буе җылау-сыктаудан дер калтырап торды. Терлекләргә, кешеләргә кушылып, әйтерсең бөтен туган җир ачы күз яшьләрен түкте.
Шулай итеп, җиңүчеләр, җиңелеп, таланып, көчкә үз якларына чыгып өлгәштеләр. Сал-күпер алынды, Чулман өсте бушап, иркенәеп калды. Болгар илен кара төн чатыры каплап алды.
Икенче көнне, бераз тын алгач, ял иткәч, кешеләр артларына борылып карадылар, югалган, юкка чыккан нәрсәләрен барладылар. Бары шуннан соң гына икенче бер кайгы — үзләренекеннән дә зуррак кайгы турында исләренә төшерделәр. Ханбалык нишләде икән? Алмыш ханның эшләре ничегрәк икән? Җиңә алганмы ул суарларны, әллә ул да шулай суга төшкән тавык кебек таланып-йолкынып калды микән?
Алмыш ханның исә эшләре мактанырлык түгел иде. Тулысынча агач өйләрдән, киез өйләрдән, чыбык-чабык куышлардан торган, агач коймалар белән әйләндереп алынган, агач күперләре, агач капкалары булган Болгар-каланы хан килеп җиткәндә инде ут-ялкын чорнаган иде. Суарлар берничә урында койма эченә бәреп кергәннәр иде. Ялкын ялмый алмаган урамнарда, ишегалларында, койма буйларында каты сугышлар бара иде. Коралсыз кешеләрнең күбесе, йорт-җирләрен, терлекләрен ташлап, болын, урман ягына качышып беткәннәр иде. Ханбалык янындагы юл буйларында, кырларда-басуларда үлгән, яраланган кешеләр аунап ята, кая барып бәрелергә белмичә, иясез терлекләр каңгырап йөри иде. Кара болыт булып күккә күтәрелгән кара төтен баганалары ягыннан, кызгылт ялкыннар, кара

күмергә әйләнгән каралты-куралар ягыннан каты чыртлап-шартлап янган агач тавышлары, шашынып кычкырулар, йөрәк өзгеч сыкранулар ишетелеп тора иде.

Шуларның барысын да күргәч, ишеткәч, Алмыш ханның күз аллары караңгыланып китте. Тиле кеше кебек ул кинәт:

— Яна-а! — дип кычкырып җибәрде.

Болгар ирләре тетрәнеп киттеләр. Боерык булганны да көтмәстән, буасын ерып киткән язгы су кебек, төп юлдан читкә бәреп чыктылар да, киң болынга тарала барып, сөрән салып, ут-ялкынга таба ыргылдылар.

Алмыш ханның кайтып төшүен суарлар да, ханбалык сакчылары да күреп алдылар. Суарлар, кара болыттай ябырылып килүче болгарлар белән очрашырга теләмичә, ашык-пошык чигенә башладылар. Иң беренче булып Килдеш би үзе табан ялтыратты. Кинәт купкан ыгы-зыгы, буталыш арасында аның качып китүен болгарлар түгел, суарлар үзләре дә күрми калдылар. Ерак юлдан кайтучы болгарларның иң өлгер ирләре Кыр капкага якынлашып килгәндә, Килдеш бине уртага яшереп качып барган суарлар төркеме инде Өчкүл ягындагы урман авызына барып җиткән иде. Беренче төркемнең үкчәсенә басып, суарларның икенче, өченче төркемнәре кузгалды. Алар да Өчкүл ягы урманына юл тоттылар.

Болгарларның болын тутырып килгән ир-атлары икегә бүленде. Берсе качучыларны эзәрлекли китте, икенчесе — янган калага ашыкты. Шул ук вакытта капкалардан, янган, ауган коймалардан калдык-постык болгар сакчылары бәреп чыкты. Капка алларында, киң болынның әле бер төшендә, әле икенче төшендә чигенүче суарлар белән болгарлар арасында сугышлар бәйләнеп китте. Өчкүл ягындагы урман буенда да ике арада яман сугыш башланды.

Төшкә сугыш бетте. Суарларның меңләгән ирләре мәңгегә күзләрен йомды. Болгарларның чыныккан, күпне күргән таза ирләре үз өйләренең капка төбендә аякларын суздылар.

Качып киткән Килдеш бине дә, башка суарларны да Алмыш хан эзәрлекләп тормады. Бу көтелмәгән яу, бу көтелмәгән җиңү-җиңелү аны шундый нык какшатып ташлады — кайгысыннан ул күзен дә күтәреп карый алмады. Атын әкрен генә атлатып, ул үзенең туздырылган оясына юнәлде.

Башта ул үз урдасына кайтып керде. Урдадан җилләр искән иде. Шулай да әле анда, әле монда кайбер нәрсәләр күренгәли иде. Текә яр буендагы ат абзарлары. Каравыл өйләре, җимерелә башлаган койма — барысы да исән иде. Шулай ук таш мәчеткә дә берни булмаган иде. Бары тик аның ишекләре генә каерылып ташланган иде дә, акташларына сыек ләпек, сыер тизәге үкәләгән иде... Җөфүтләр коткысына бирелгән суарлар эше...

Урда уртасындагы ак өй — Алмыш ханның агач сарае да, шул тирәдәге башка өйләр дә — барысы да кара  күмергә әйләнгән иде. Берничә кеше шунда кайнар көл, күмер арасыннан нидер эзләп маташа, икенче берәүләр, җылашып, янып бетмәгән кием-салымнарын коткарырга тырышалар иде.

Алмыш хан урдага читтән генә күз ташлап алды да, янып җир белән тигезләнгән Төн капка ягына юнәлде. Ул монда да озак тора алмады, тынычсызланган атын әйдәп, яңадан кузгалып китте. Кайгылы башын салындырып, ул ханбалыкны аркылы-торкылы йөреп чыкты: янган, җимерелгән коймалар буенда булды, капкаларга, каравыл өйләренә сугылды. Күл буена, зират янына барып әйләнде. Кая гына бармасын, теләсә кайда аңа пыскып-көйрәп яткан кара күмер, агач өемнәре, үлгән, янган кешеләр, көлгә-корымга буялган, шашынып әрле-бирле чабышкан ирләр, хатыннар, балалар очрады. Кая гына бармасын, аның колак төбендә җылау-сыктау, үксү тавышлары яңгырап торды.

Шунда  аның күз алдына икенче төрле янгыннар килде, җимерелгән, таланган авыллар, катаулар килде... Әйе, әле кайчан гына ул үзе талап, яндырып йөрде. Инде менә аның үзен талап-яндырып киттеләр. Барысы да юкка чыкты, барысы да көлгә очты! Күпме көч куеп, ничә еллар буе җыйган байлыгы суга акты. Йа Тәңрем, йа Алла, аның әле беркайчан да бу тикле талау, бу тикле кыран күргәне юк иде бугай! Беркайчан да әле болгарларның мондый зур оятка калганнары юк иде. Шундый күп көч түгеп, тырышып торгызган сарайлар, коймалар, капкалар — барысы да әнә аяк астында аунап ята. Менә сиңа бөек Болгар, менә сиңа җиңелмәс болгарлар! Болай булгач болгарлар түгел — хазарлар, Хазар каганы җиңелмәс булып чыкты. Боларның барысы да аның эше булмыйча, тагын кем эше булсын? Каган шымчылары күршеләрне туктаусыз котыртып тормасалар, болгарларга каршы туктаусыз корткычлык эшләмәсәләр, Килдеш бинең мондый эшкә йөрәге җитәр идемени? Юк, җитмәс иде. Димәк, тынгысыз күршеләрнең явызлыгыннан котылу өчен, иң элек Хазардан, каганнан котылырга кирәк. Үзеңне чыннан да бай итеп, иркле итеп тою өчен каган белән ике арадагы җепләрне өзеп ташларга кирәк! Шунсыз Болгар беркайчан да ныклап торып аякка баса алмаячак.

Алмыш ханның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Аны тик: ярый әле Чулман иле... Чулман байлыгы минем кулда, дигән бер уй гына бераз тынычландыргандай булды.

Менә яндырылган, таланган ханбалыкка... таланган, өтәләнгән Тәкин углан да кайтып төште. Алмыш хан, аны шулай ярым-йорты килеш күреп, аяктан егылды. Ике көн, ике төн ул баш калкытмый урынында ятты. Ашамады, эчмәде, беркем белән сөйләшмәде. Өченче көнне хан аягына басты, туган-тумачаларын яшерен киңәшкә җыйды.

## XIX

Үзенең биек түрендә калкып утырган килеш, берничә көн эчендә тартылып калган Алмыш хан сүзгә башлады:

— Моннан күп-күп җыллар элек бу якларга килеп, безнең борынгы ата-бабаларыбыз бу җирләрне яулап алганнар,— диде.— Күктә — кояш танык, җирдә — Итил танык: бабам, атам туган чакта Итилнең үрге агымы Ука суынача, түбән агымы — Кызлар тавынача, Чулманның Ала Бука катауга тикле барлык җир-сулары болгарныкы булган. Кояш танык, Итил танык — анам мине тапкан чакта шушы төбәктәге йорт-ил тулысынча болгарныкы булган. Көн дә иртән кояш монда безнең өчен чыга, көн-төн Итил, Чулман җир читеннән безгә таба агып тора. Күктә кояш сүнми торып, Болгар бетмәс, Итил-Чулман корымыйча торып, Болгар йорт бозылмас!

— Амин, шулай булсын! Сүзең изге! — диештеләр агай-эне, күңелле гөрелдәп.

— Күреп торасыз, белеп торасыз,— диде Алмыш хан, бераз тын алганнан соң,— безнең йортта тыныч түгел. Кайчакта мин үз йортымда үземне чит сизәм. Өч ел буена Чулман бездән аерылып торды. Инде аны яңадан яулап алгач, яңадан үземә тиешле каланны сугышып алып кайткач... Барысы да күз алдыгызда... Искә төшерәсе дә килми... Әйтегез, кайчангача суар, биләр, башка барлык дошман ырулар, хазарларга аркаланып, минем йортымны шулай талап-яндырып китәрләр?! Кайчан мин үз йортымда үзем баш булып, тынычлап яшәрмен?! Кайчан без, җөфүтләргә кол булудан туктап, үз башка, үз иркебезгә яши алырбыз?! Кайчан без бер-берсе белән талашып, ызгышып яшәгән таркау ил-көнне, ыруларны берләштереп, чын бөек Болгар йорт кора алырбыз?! Менә шулар турында уйладым мин соңгы көннәрдә. Менә шулар турында баш ваттым мин, агай-эне, туганнар... Барыгызның да күз алдында — Болгар йорт чак-чак кына аумый калды. Мин беләм: боларның барысы да каган этлеге. Суарларга, казаякларга Биләр дә кушылган булса, без инде күптән су төбендә булырыек. Безнең язмыш кыл өстендә калды — аңлыйсызмы шуны, агай-эне?! Киләчәктә дә без шулай яшәсәк, дошманнар үзара берләшеп, безне баш аркылы чөеп ташлаячаклар. Баш аркылы чөймәгәндә дә, белегез: безгә тынгы булмаячак. Без аларны барып таларбыз, алар безне килеп таларлар. Башкача болай яшәп булмый. Аңлыйсызмы — булмый!

Шулай дигәндә аның таштай авыр, салмак тавышы калтыранып китте, мыек чылгыйлары сикерешеп алды. Авыр йодрыкларын йомарлап, ул аягүрә басты да, тавышын көчәйтеп:

— Искечә яшәсәк, без юкка чыгачакбыз! — диде.— Менә шул турыда уйладым мин, агай-эне... Тыңлагыз сүземне. Элеккечә ил тотып булмый. Талау, яндыру белән ерак китеп булмый. Көтү көр булсын өчен терлекләр тынычлап утларга тиеш. Беләктә — көч, кесәдә — алтын тулып торсын өчен ил тыныч булырга, бердәм булырга тиеш. Безгә бердәмлек кирәк, иминлек кирәк, көч-байлык кирәк. Шуларны ничек булдырырга?

Ул, сүзеннән туктап, агай-энегә күз йөртеп чыкты. Аннары тагын салмак кына ялгап алып китте.

— Безгә барысын да өр-яңадан башларга кирәк булачак,— диде.— Без янган ханбалыкны торгызырга тиешбез, без катауны беркемнең теше үтмәслек таш койма белән уратып алырга тиешбез.

Кемдер түзмәде, исе китеп:

— Таш койма белән! — дип куйды.

— Әйе, таш койма белән! — диде Алмыш хан.— Таш койма эченә кереп бикләнмичә торып, безнең хатыннарга, балаларга, безнең караларга тынгы булмаячак. Шунсыз без усал, көнчел күршеләрдән котыла алмаячакбыз. Болгар җирендә таш җитәрлек.

— Таш җитәрлек тә, аш белән баш җитәрлек түгел шул! — диде шунда чәрелдек тавышлы бер картлач, урыныннан кузгалгандай итеп.— Таш койманы коры кул белән салып булмый. Ташчылар кая, түләргә акча кая?

— Әйе, әйе!

— Әйтүе генә җиңел — таш койма!

— Балта белән таш чабып булмый, ташчылар кирәк,— диештеләр башкалар да, телгә килеп.

— Ашыкмагыз, сүзем бетмәде,— диде хан.— Мин барысын да уйладым. Таш койма ул мине саклар өчен, сезне саклар өчен, безнең өйләрне, караларны, колларны саклар өчен кирәк.

— Бүредән курыккан урманга бармаган,— диде Корыч-Тимернең атасы Алып Тархан.— Син югында бүре килеп сарыкларыңны алып киткән икән, сарыкларны абзарга ябып асрамакчы буласыңмы?

— Ата-баба күршеләрдән куркып, таш коймага бикләнеп яшәмгән.

— Кулыңда кылыч барында, дошманнардан куркып яшәү — оят! — диештеләр кайберәүләр, шаулаша башлап.

Кашларын җыерып, йодрыкларын йомарлап, Алмыш хан яңадан урыныннан торды.

— Ата-баба дисезме?! — дип кычкырды ул, күкләрне күкрәтерлек итеп.— Ханбалык янганга сөенәсезме?! Койма да кирәкми, ханбалык та кирәкми дисезме?! Ничек телегез бара шундый сүзләр сөйләргә? Сезнең күзегез берни күрмимени, колакларыгыз берни ишетмимени? Көлгә очкан

байлыгыгызны күреп йөрәгегез янмыймыни? Юк, мин уйлаган уемнан кайтмаячакмын! Итил суын кире борып булмаган кебек, үткәнгә кире кайту юк. Ата-бабаларыбызны без олылыйбыз... урыннары оҗмахта булсын! Шулай да мин аларның шыр сөякләренә табынып кына яши алмыйм. Кулдагы кылычка гына да таянып яшәп булмый. Миңа кылычтан да, ук-җәядән дә, сөңгедән дә көчлерәк корал кирәк. Бармы шундый корал?

— Юк! — диде Алып-Тархан, үчекләшеп.

— Андый корал бар! — диде аңа каршы Алмыш хан.— Ул да булса — гарәпләр йоласы. Менә ул нинди корал!

Агай-эне, мондый сүз ишетеп, аптырап тынып калды. Барысы да, ханның аңлатыбрак сөйләвен теләгәндәй, аның авызына карап утыра бирделәр.

— Күрдегезме таш мәчетне? — диде Алмыш хан.— Тирә-якта барлык каралты-кура күмергә әйләнгәндә, таш мәчет берүзе утырып калган... Утка да, кылычка да бирешмәгән. Гарәп йоласы да менә шундый. Болгар, тауга үрләргә теләсә, ислам динен тотарга тиеш.

— Без болай да ислам динендә түгелме соң? — диде Алып-Тархан.

— Әйе, без — мосылманнар,— диде хан, аның мыскыллы соравына исе китмичә.— Нинди мосылманнар соң без? Без ата-баба йоласын да аяк астына салып таптадык, чын мосылман да була алмадык. Без беркемгә, бернигә инанмыйбыз. Без — урталыкта. Аннары без күпме — нибарысы биш йөз өй. Суар Аллага табынмый, биләр, бәрәнҗәр табынмый, Ямгырчы бине санамаганда, Чулман шулай ук табынмый. Безнең дә Аллага табынучылар — аксөякләр генә. Каралар гарәп йоласын ни дип тә белмиләр. Чирмешнең — үз йоласы, арның, мукшы, буртасның — үз йоласы. Юк, болай булмый! Болгар йортның ханы бер генә булган кебек, аның Алласы да бер генә булырга тиеш! Безгә тәҗикләрдән, гарәпләрдән, румнардан үрнәк алырга туры килә. Бөтен ил — аксөякләр, каралар, коллар, барлык ил-көн, бер генә йолага — мосылман йоласына табынырга тиеш! Менә шул турыда уйладым мин, агай-эне... туганнар...

Агай-эне, яшенле яңгыр алдыннан куркышып теләсә кая качып беткән кош-корт сыман, барысы да кинәт шып булдылар. Күңелләргә мең төрле сорау килде. Бөтен Болгар илен ислам диненә күндерергә! Булырмы бу? Бөтен йортны! Барлык ыруларны... ханбалыкны яндырудан тартынмаган, күзеңне йомдың исә, күзеңне чукырга, ялгыш бастың исә базга төртеп төшерергә генә торган ыруларны!.. Ничек итеп? Шул ук кылыч белән куркытыпмы? Үз ирекләре белән табынырга теләмәсәләр, чыннан да, аларны яңадан яулап алырга, яңадан кан коярга, таларга, яндырырга туры килмәячәкмени? Бер үк балык башы булып чыга түгелмени?

Өй эче бердәм гөрләргә, шауларга тотынды.

— Әйтеп кара — ничек ирешерсең икән моңа?

— Аңлатыбрак сөйлә! — диештеләр агай-эне.

— Мин болай итәргә уйлыйм,— диде хан, тавыш басыла төшкәч.— Әйткәнемчә, мин ханбалыкны ныгытам. Моның өчен таш койма салдырам. Шул ук вакытта мин үземә буйсынган барлык ыруларга яңа дингә күчәргә боерам. Буйсынмаган, баш бирмәгән ыруларны соңыннан әкренләп кылыч белән дә, дин белән дә яулап алам. Боерыгым буш сүз генә булмасын өчен, бөтен Болгар йорт, чыннан да, үзенең абакларын, сыннарын, сарыганнарын аяк астына салып таптасын, бары бер Аллага гына табына башласын өчен мин бер сугуда берәгәйле сукмакчы булам... мин, дин белгечләре — муллалар, мәзиннәр сорап, табындыручылар сорап, туры Багдадка, хәлифәнең үзенә илче җибәрәм![1]

Өй эчендә тантаналы, киеренке бер тынлык урнашты.

— Сез тагын сорарсыз: Багдадкача илче ничек барыр, каян барыр диярсез,— диде хан.— Мин анысын да уйладым. Хазар каганы безне Багдадка уздырмаячак. Шулай ук Хәрәзем дә безнең юлга аркылы төшәчәк. Шулай булгач без ачыктан-ачык мең кешелек илче җибәрә алмыйбыз. Безгә алдарга, ялганларга туры киләчәк. Безгә ничек дә Багдадка үтеп керергә, хәлифәнең үз кулына үтенечебезне тапшырырга кирәк. Моның өчен безнең илче илче булып түгел, сатучы булып, кирәк икән, теләнче булып, юлбасар булып барачак! Безнең өчен башка юл юк. Багдадка илче җибәреп, мин берьюлы ике куян гына түгел, өч куян атачакмын. Миңа хәлифәнең үз илчесе килсә, күршеләр арасында Болгарның даны бермә-бер күтәреләчәк. Болгар йорт башкалар арасына керә башлаячак, Болгар белән санлаша башлаячаклар. Икенчедән, үз кул астымдагы биләрне, ыруларны турыдан-туры хәлифә җибәргән илчеләр, табындыручылар булышлыгында яңа дингә инандыру миңа җиңелрәк булачак. Тагын шул, Хәрәземнән мосылман йоласы алганда, без алардан берни сорамадык. Таш мәчетләреннән башка алар безгә берни бирмәделәр. Бөтен йортымны яңа дингә күчергәндә мин ата-баба йоласыннан бушка гына аерылырга теләмим. Үз иркем белән мин хәлифәнең колы булам икән, үземнең коллыгым өчен мин түләү сораячакмын. Ул миңа ташчылар, йола белгечләре җибәрәчәк. Ул миңа, ким дигәндә, биш мең динар[2] акча бирергә тиеш булачак. Менә шул акчага мин таш койма корачакмын!

Хан тынып калды. Өй эче дә, каршы сүз әйтергә кыймыйча, тып-тын утырды. Агай-эненең эндәшмәвен килешү дип аңлап, Алмыш хан бераздан боеручан тавыш белән:

— Багдадка илче итеп мин Тәкин угланны җибәрәм. Аның белән Барыс углан да барыр,— диде.— Үзенә йөкләнгән бурычны Тәкин углан үтәп чыгарга тиеш. Шуның белән ул үзенең атасы-анасы алдындагы, барлык болгарлар алдындагы языгын җуя алыр.

**Дүртенче баб**

**I**

Элегрәк, тыныч елларда, Болгар ханы, язгы ташу кайтып, җирнең өсте кипшергәч тә, киң болыннар яшеллеккә күмелгәч тә, җәйләүгә чыга торган иде. Барлык өе, көтүләре белән, коллары, чирүе белән, үзенә буйсынган биләре, ырулары белән ул Итил болыннары буйлап көн ягына — кояшка, җылыга таба юнәлә иде. Җәй урталарында ул Болгар йортның көньяктагы чигенәчә барып җитә дә көнчыгышка таба борыла иде. Аннары Җаек суы буйлап, Урал-тау итәкләренә сугылып, үргә таба — төн ягына үрли башлый иде. Җәйнең җәй буена терлекләр яшел болыннарда утлыйлар — түл җыялар, мал җыялар иде. Көзге кырпак төшүгә, бөтен Болгар иле яңадан үзенең кышкы торак урынына — Чулман белән Чирмешән арасындагы болыннарга кайтып керә иде.

Элегрәк шулай иде. Соңгы елларда болай күченеп йөрүләр кыенлаша башлады. Иген игә торган, елга буйларында авыл корып, утрак тормыш белән яши торган ыруларны урыннарыннан кузгату елдан-ел авырлаша башлады. Алай гына да түгел, моңарчы гел күченеп йөргән ырулар да әкренләп-әкренләп үз җирләрендә төпләнә тордылар: агачтан өйләр салып, иген игеп яши башладылар. Шулай ук базарларда сатучылар да күбәйде. Үзара яулар да, ызгыш-талашлар да күченеп йөрүләрне тоткарлый торды.

Менә быел да шулай булып чыкты. Җәйләүгә чыгу турындагы уй быел ханның башына да килеп карамады. Үзенең күчмә урдасын ул янган, күмергә әйләнгән ханбалыкка якын җиргә — Өсән суының аръягына, Итил буе болынына — иңкү, тигез җиргә корды. Бу тирәдәге яхшы болыннар барысы да ханның үз көтүлекләре, үз җирләре санала иде. Хан үзе беркая  китмәгәч, аның биләре дә үз җирләрендә торып калдылар.

Алмыш хан Тәкин углан башлыгындагы яшерен илчелекне ерак юлга озатты да, җиң сызганып, эшкә тотынды. Каяндыр күктән төшкәнне көтеп, кул кушырып ятмыйча, кыш җиткәнче ул үз кайгысын үзе кайгыртырга булды. Ханбалыкка ул тагын тирә-яктагы балтачыларны чакыртып алды. Аларга ул үзенең яндырылган урдасын, коймаларны, күперләрне, капкаларны торгызырга боерык бирде. Кулына балта тота алмаган барлык ирләр урманга агач кисәргә, йә булмаса Ага-базарга —  сал сүтеп агач чыгарырга җибәрелде. Көрәк тота алганнар ханбалыкта җир казырга, койма, ур буйларын, урамнарны янган, кырылган агач-таштан әрчергә калдырылды. Ханның бу боерыгы бары каралты-куралары талау күргән кешеләргә генә кагылмады — үз каралты-кураларын алар үз көчләре белән торгызырга тиешләр иде. Алар инде болай да, кырмыскалар кебек, күптән эшкә тотынганнар иде: кайберәүләр, кыш торыр өчен генә дип, яр буена базлар казыйлар, кайберләре чыбык-чабыктан читән алачыклар үрәләр иде. Әзме-күпме байлыклары исән калган чүлмәкчеләр, тимерчеләр, тиречеләр, кисмәкчеләр — шуның ише кылачылар[1], кечкенә итеп булса да, бурап агач өйләр җиткерергә тырышалар иде.

Үзенең урдасыннан да, коймалардан, капка-күперләрдән дә элегрәк, Алмыш хан таш мәчетне төзәтергә кушты. Мәчетнең каерылган ишекләре яңартылды. Тышкы яктан ул агартылды, чылгыена алтыннан чүкеп эшләнгән ярым ай куелды. Җиргә, манара төбенә йөз кеше сыярлык итеп киң түбә ясатылды. Башына ак чалма ураган, озын кара чапан кигән Бохар мәзине, ханның боерыгы буенча, әледән-әле манара башына менеп, бар көченә азан кычкырды.

Яудан соң Алмыш ханның мосылман диненә кагылышлы бар нәрсәне артыграк күрүен, мулла-мәзиннәргә элеккегә караганда да ачыграк йөз күрсәтүен болгарлар сизми калмадылар. Багдадка илче җибәрү турында ханның иң якын кешеләреннән башка беркем белмәсә дә, ил башының нindider зур үзгәрешләр ясарга теләве турындагы имеш-мимешләр каралар арасына да үтеп керде. Кайгыдан, ачлык-ялангачлыктан башларын кая куярга белмәгән, бәгырьләре таштай каткан өйсез, җирсез кешеләр карт мәзиннең карлыккан тавышын котлары алынып тыңладылар. Янган, җимерелгән каралты-кура өстендә яңгыраган бу ят, ямьсез, аңлаешсыз тавыш аларга күктән килгән нindider усал кисәтү булып, янау-куркыту булып тоелды.

Алмыш ханның караларны да яңа дингә табындырырга, авылларда, калаларда мәчетләр, мәктәпләр салдырырга, читтән китерелгән муллалар куярга уйлавы турындагы яман сүзләр, имеш-мимешләр күптән инде йөри иде. Манара чылгыена алтын ай куелып, мәчет үзе төзәтелеп, мәзиннең кычкырулары ешая башлагач, бу имеш-мимешләр тагын да көчәя төште. Таш багана башына менеп, тар ярыктан муенын сузып килмешәк карт ишәк кебек бакыра башладымы, шул тирәдә көл-күмер арасында казынып яткан каралар шундук аңа — алтын айлы манарага аркалары белән борылдылар, кулларын күккә сузып, Тәңрегә ялвара башладылар. Уттан-яудан исән калган таш багана Алмыш хан

өчен изге тоелса, ата-баба йоласын бар нәрсәдән артыграк күрүчеләр өчен ул, киресенчә, явыз өрәк булып, алабсты булып тоелды. Илгә килгән зур талауны алар яудан түгел, менә шул исән калган таш мәчеттән күрделәр.

Болгарда җөфүт йоласын, рум йоласын тотучылар да бар иде. Алар, башлыча, читтән килеп, монда утракланып калган кешеләр иде. Ханның гарәп динен артыграк күрүенә эчләре пошканга, алар, үзара ызгышудан туктап, ата-баба йоласы яклы караларны якынрак күрә башладылар. Күп тә үтмәде, көннәрдән бер көнне Болгар-торада бөтен кешене шаккатырган бер сүз таралды. Нindидер кешеләр, каравылчыларны бәйләп ташлап, караңгы төндә таш мәчет төбен казыганнар, манараны аударырга, җимерергә маташканнар. Таң алдыннан мәзин килеп җитеп, тавыш куптармаса, чын-чынлап аударасылар икән!

Шул турыда ишеткәч тә, Алмыш хан, барлык эшен бер читкә куеп, таш мәчет янына китте. Чыннан да, таш манара төбе тирән итеп казылган иде, кызыл балчык өемнәре, таудай булып, ерактан ук күренеп тора иде. Шул тирәгә инде шактый кеше җыелып өлгергән иде. Таш манараның төбе казылган килеш тә аумый торуына күпчелекнең исе киткән иде. Кешеләр, чылгый очындагы ярым айга, озынча төннекләргә бармаклары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә пышылдашып, үзара гөр киләләр иде.

Ханның мәчеткә якынлашуы булды, кешеләр тынып калдылар, башларындагы бүрекләрен салып култык асларына кыстырдылар.

— Исәнме, ил-көн,— диде Алмыш хан, коры гына.

— Бик исән.

— Аманбыз,— диештеләр кешеләр, тыелып кына.

Алмыш хан атыннан төште, мәчет тирәсен әйләнеп чыкты, нигезнең кызыл балчык аралаш күренеп торган ак ташларына карады. Аннары җыелган кешеләргә борылды да:

— Менә күрдегезме Алланың көчен! — диде.— Бу — изге багана. Җир йөзендә аны аудара алырдай бернинди көч юк. Күрәсезме, Болгар җирендә ул нинди нык утыра! Бу җирдән аны кешеләр дә, Тәңре дә, албастылар да — беркем дә кузгата алмаячак. Бүген төнлә качып-посып шушы изге җирне казучылар Аллага каршы кул күтәргәннәр. Белексезләр, күтәргән кылычларының үзләре башына төшәчәге турында алар уйлый алмаганнар. Угрылар барыбер тотылачак. Аларга кызгут[1] ясалачак!

Кешеләр, «кызгут» сүзен ишетү белән, ахылдап җибәрделәр. Ирексездән күзләр күккә текәлде, куллар югары күтәрелде. Аларның күбесе, ханны да онытып, алтын айга аркалары белән борылдылар. Алмыш ханның йөзе бозылып китте.

— Тезләнегез! — диде ул, бар көченә кычкырып.

Кешеләр, кан калтырап, манара ягына борылдылар, чапкан үләндәй җиргә егылдылар, барысы да бер авыздан:

— Алла! — дип кычкырып җибәрделәр.

— Моннан ары сез яңа дин ялчылары,— диде хан.— Күккә, Тәңрегә, абакларга табынган кешеләрне яшен сугачак!

Тып-тын калган төркем арасында мышык-мышык җылаган, үксегән тавышлар ишетелде. Тигез итеп киселгән, шомартылган ак ташлардан өеп мендерелгән очлы багана, үз аяк астындагы җир кортларының кайгысына, җылау-сыктавына әз генә дә исе китмичә, канлы ярадан төртеп чыккан сөңге башыдай, казылган җир янында котны алып басып тик торды.

**II**

Мәчет яныннан Алмыш хан Ага-базарга китте. Янган каладан ераклашкач та, аның уйлары дин-йола, Тәңре, Алла кайгыларыннан арынып, базар кайгыларына, акча кайгыларына күчте. Бу арада базар, акча кайгылары аны дин-йола кайгыларыннан бер дә ким борчымады. Үз көче, үз кешеләре белән генә урданы, койманы яңадан торгыза алырмы ул? Барысын да яңабаштан корыргамы, элеккедән дә нык итеп, яхшы итеп корыргамы, әллә соң әлегә күп көч түкмәскәме? Тәкин угланның юлы уңып, уйланган уйлар тормышка ашырылса, соралган акча белән соралган кешеләр килеп җитсә, күпме байлык, күпме көч янга калачак!

Әйе. Тик шулай да хәлифә акчасы — күктәге торна шул! Ярый әле Чулман буеннан алып кайткан тиренең күбесе исән калган. Аны быел ук сатып җибәрергә туры киләчәк. Агач менә кыйбатланды. Икеләтә кыйбатланды. Яу килеп, яндырып киттеме, салчылар шундук комсызлана башлыйлар. Сычканга — үлем, мачыга — көлке. Болгар янса — арга-чирмешкә җылы. Ар-чирмеш янса — болгарга җылы.

«Ашлык та исән калган»,— дип уйлады Алмыш хан, яңадан базар кайгыларын исенә төшереп. Чокырлардагы богдай, тары, арпа шул көе. Озакламый яңа ашлык җитә. Шуңа чаклы сатып калганда яхшы булырые да, каян табасың аңа акчалы ач тамаклар? Үз ачларыңа таратудан файда юк.

«Тагын нәрсәне сатарга була соң?» — дип уйлады ул бераздан. Чүлмәк савыт-саба ватылып беткән. Бал аз. Байлык эзләп, суарларның үзләренә яу чабаргамыни? Әллә төн кешеләре ягына юл тотаргамы?

Мондый чакта анда ничек үтеп кермәк кирәк?! Ах, каян табарга күп, би-ик күп акча! Ходаем, ник юлыма чыгарып куймыйсың өй тәүмәлеге чүлмәк белән алтын-көмеш?!

Йөрергә чыкканда ханны беркем дә озатмый да, сакламый да иде. Үзенә кирәк җиргә ул үзе йөри, кирәк икән — көтүчеләр янына бара, кирәк икән — балыкчылар, игенчеләр янына бара, базарларга сугылып чыга иде. Көне буе диярлек өйдә кешеләр белән булып арыгач ул, атына атланып, тузанлы юлдан, йә булмаса яшел болыннардан үзалдына уйланып барырга ярата иде.

Менә ул, ачык, кояшлы җирне үтеп, тын, күләгәле нарат урманына килеп керде. «Әллә шушы наратларны гына кисеп аударыргамы соң?» — дип уйлады ул, биек, төз агач башларына караштырып. «Юк,— диде ул аннары, үз-үзенә каршы килеп.— Ханбалык янындагы урман — тере койма ул. Ярамый. Үзең утырган ботагыңны үзең чабу кебек булачак».

Шул чакны алда, куе агачлар артында, майланмаган арба шыгырдавы ишетелде. Комлы урман юлыннан үргә таба, тырышып тарта-тарта, мышный-мышный, атлар менеп килгәне күренде. Йөгертмәле арбаларга озын наратлар сузып салынган иде. Бүрәнәләр, күрәсең, әле яңарак кына судан чыгарылган — аларның кабыклары карайган, ләмгә, комга буялган, арба артларыннан исә пычрак су тамып бара иде.

Атларга юл бирү өчен Алмыш хан читкә чыкты, көтеп тора башлады. Йөкчеләр, аның турысына җиткәч, бүрекләрен салдылар, исәнлек-саулык сораштылар, туктамыйча, атларын куа-куа, югары менеп киттеләр. Алмыш хан унлап йөкнең барысын да уздырып җибәрде дә, иң арттан ашыгып атлаган урта яшьләрдәге бер аксак ирне туктатып:

— Каеклар белән кемнәр килгән анда? — диде.

— Урыслар килгән, хан,— диде аксак ир, башындагы бүрегенә тотынып.

— Урыслар дисеңме? Ниткән урыслар? Урыс-улакмы, сатучылармы? — диде хан, чиктән тыш бер кызыксыну белән.

— Сатучылар, хан. Тыныч күренәләр.

— Иртәгә ташып бетерерсезме? — диде хан, сүзне икенчегә борып.

— Бетмәс,— диде йөкче.— Арбалар җитми.

— Бар, юлыңда бул,— диде хан, кулын селтәп.— Анда арба җитми, монда кеше җитми.

— Хан, туктале,— диде йөкче, ханның кузгалып китүен күреп.— Мин — Сатылмыш балтачы булам.

— Беләм, ни йомыш? — диде хан, борылып.

— Без анда үзара сүз көрәштердек. Син шушы сулы агачлардан койма коярга, багана кагарга боергансың, имеш? — диде Сатылмыш балтачы.

— Боерса? Шуннан?

— Бу килеш багана утыртырга ярамас, хан. Багананың җиргә күмеләсе башын нәни генә җандырганда җакшы булырые. Алай ул череми. Сурыккан агач җакшы яна. Күрәсең ич — чи, сулы.

— Син әллә агач сурыкканчы көтәргә киңәш итәсеңме? — диде Алмыш хан.

— Юк,— диде Сатылмыш балтачы.— Син башта баганалар кагарга, койма коярга боергансың түгелме соң?

— Мин алай боермадым,— диде хан.— Мин койманы да, өйләрне дә кыш җиткәнче өлгертергә боердым. Башта койма коярга, баганалар утыртырга Чүти балтачы әйтте.

— Ә-ә! Шул шул! — диде Сатылмыш балтачы, куанып.— Чүти балтачы гел шулай үзенчә мәтәштерергә ярата.

— Син соң ни киңәш итәсең, Сатылмыш? — диде хан, кызыксына төшеп.

— Мин шуны киңәш итәм, хан,— диде Сатылмыш балтачы, үрне менеп җиткән атына карап алып.— Иң элек бурага тотынырга кирәк. Баганаларны да юна башларга була. Башын яндырмый утыртмаска — шул минем киңәш.

— Ярар, шулай эшләгез,— диде хан, килешеп.

«Димәк, урыслар килгән,— дип уйлады ул, Сатылмыштан аерылгач.— Биш-алты ел инде күренгәннәре юк. Карап карыйк, ни белән, нинди уйлар белән килделәр икән».

## III

Итил яры буена урнашкан Ага-базар яудан исән калган иде. Суарлар, ханбалыкны талау, яндыру белән булашып, куе урман артындагы базарга килеп җитә алмаганнар иде. Юкса талар, яндырыр өчен монда байлык та, каралты-кура да җитәрлек иде. Ага-базар бөтен Итил, Чулман буенда, Хазар йортның ханбалыгы Итил-торадагы базарлардан кала, иң зур базар санала иде. Бөек Итил, язгы боздан әрчелеп, яңадан боз белән капланганга тикле монда җир йөзенең барлык якларыннан, каекларга утырып, төрле ил сатучылары килә иде. Базар монда язын-җәен-көзен генә түгел, кыш көннәрендә дә тукталып тормый иде. Болгар йортның бу атаклы базарында күңелең ни тели — шуны алырга, күңелең ни тели — шуны сатарга була иде.

Күләгәле, талгын урманнан Алмыш хан кояш яктысы белән тулы яланга килеп чыкты. Калкулык итәгеннән үк, калын урман яныннан ук яшел болын башланды. Болын аша, ярты чакрым чамасы ераклыкта, Ага-базарның каралты-куралары калкып күренде. Алачыкларның, кибет, кураларның күбесе, бер-берсенә сыенып, йә булмаса бер-берсеннән бик нык читләшеп, оя-оя булып, төркем-төркем булып, Итил буена ук утырганнар иде. Болайрак исә, иркен болын ягында, киез өйләр, киндер чатырлар тезелеп киткән иде. Шунда ук, өйләр-чатырлар белән аралашып, агыллар[1], биек коймалар тырпаеп күренә иде.

Эреле-ваклы өйләр, куралар, чатырлар ягыннан, киртә-коймалар ягыннан күңелне җилкендергеч бер гөрелте — бары базарларда гына, кеше күп урыннарда гына була торган тынгысыз гөрелдек ишетелеп тора иде. Арырак, сул якта, урман буендагы агылларда җирне-күкне тетрәндереп бога үкерә; аннан да арырак, ярга якынрак төштә, сал чыгаручыларның күмәкләшеп, үзләренә көч биреп, өзек-өзек итеп кычкырулары ишетелә иде.

Алмыш хан, тузанлы тар тыкрыкларны узды да, базар уртасына кереп тормыйча, атын туры яр буена борды. Яр буенда, тамга өендә аны базар башы Бигеш каршылады. Симез, шадра битле, зур корсаклы Бигеш Алмыш ханның туганнан туганының углы иде. Төрле кеше белән эш итеп өйрәнгән, шомарган, каешланып беткән базар башы көчлеләр алдында төлкегә әйләнә, көчсезләр алдында бүрегә әйләнә белә торган астыртын, сак, комсыз бер кеше иде. Алмыш ханны күрү белән ул тиз генә бүреген салды, җиргә егылды.

— Урыслар килдемени? — диде Алмыш хан, яр астындагы ят каеклар ягына ымлап.

— Килде, ханым,— диде Бигеш, мышнап, аягына басмакчы булып.

— Тор,— диде хан. Аның интегүен күреп.— Ник килгәннәр? Кая юл тоталар?

— Туры безгә килгәннәр, ханым,— диде Бигеш, хан атының тезгенен тотып алып.

Алмыш хан атыннан төште, өстен-башын каккалап алды. Бигеш тезгенне үзенең бер кешесенә тоттырды да, иелә-бөгелә ашыгып, басмага таба атлады. Хан белән икәүләп алар яр астына төштеләр.

Ханның боерыгыннан башка ярга чыга алмаган, шуңа күрә аның килеп җитүен түземсезлек белән көтеп торган урыслар хан белән Бигешне күрделәр дә каек кырыйларына җыела башладылар.

Яр буена барлыгы егермеләп каек туктаган иде. Аларның барысы да күпер читенә үк килеп җиткәннәр, тик берсеннән дә ярга басма ташланмаган иде.

Алмыш хан белән Бигеш күпернең уртасына җитмичә туктап калдылар. Беренче каекның борын өлешендә басып торган урысларның берсе, бүреген салып, билен бөгеп, хан белән исәнләште дә аңа котлау сүзләре әйтте:

— Кенәз Родославның илчесе... бертуган инесе Святослав сатучы бөек Булгар юртның башы Алмыш ханга исәнлек-саулык, байлык тели, күп яшь тели! — диде урыс.— Иленә-юртыңа таңри кюч, байлык, тынычлык бирсен, хан!

— Синең туганыңа да, синең үзеңә дә шуны ук телим,— диде хан, урыс кенәзенең илчесен караштырып.

Ул яшь нарат кебек төз, таза буйлы, киң күкрәкле иде. Аның җил кискән кырыс битен җирән сакал-мыек баскан иде. Ул үзе генә түгел, аның артындарак басып торган юлдашлары да яшьләр, тазалар, озын буйлылар иде. Өсләренә алар тунга да, күлмәккә дә охшамаган ниндидер кыска кием кигәннәр иде. Җиңсез ул киемнәрнең озынрак булган сул як итәге ирләрнең сул як ботларын каплап тора иде. Киемнең уң як итәге исә кыскарак иде. Уң кулларына алар озын туры кылыч тотканнар, бил каешларына балта белән пычак такканнар иде. Таза беләкләренә, шәрә күкрәкләренә, ботларына аларның төрле чәчәк, ут-үлән, киек бизәкләре төшерелгән иде.

— Ни алып килдең? — диде хан.

— Илле баш кол, меңнән артык тире,— диде илче-сатучы Святослав.

— Төшер басмаңны,— диде Алмыш хан.

Каектан күпергә басма суздылар, аркан ташладылар. Хан белән Бигеш каекка менгәндә, басманың бер башыннан урыслар, икенче башыннан болгарлар тотып торды.

Кенәз Родославның бертуган энесе Алмыш ханга үзенең ярлыгын күрсәтте, битек бирде. Хан, җепне өзеп, битеккә күз төшереп алды да, яшь урыска борылып:

— Күрсәт таварыңны,— диде.

## IV

Беренче каектагы коллар кызлар иде. Озын буйлы, аксыл чәчле яшь кызлар барысы да таза, чибәр иде. Тик ерак юл килгәнгәме, әллә инде бик үк яхшы ашамаганга, алар шактый сулыкканнар иде. Аларның төпкә баткан күзләрендә, кипшергән яшь, сылу ирен читләрендә йончылганлык билгесе күренә иде. Өсләренә иске-москы гына киенгән, ярым шәрә дип әйтерлек бу кызлар каекның аскы катындагы утыргычларда тезелешеп утыралар иде.

Алмыш хан кызларны алай-болай тоткалап карады, арадан аеруча таза, ягымлы бер кызны сайлап алды да:

— Монысы яхшырак, миңа булыр,— диде хан.

— Булыр, хан,— диде сатучы, килешеп.

Әлеге таза кызга ул нидер әйтте. Кыз теләр-теләмәс кенә урыныннан торды, өстендәге сәләмәләрен селкетеп, баскычка таба атлады. Алмыш хан аның артыннан карап торды да, кулын селтәп:

— Юк! — диде.— Әллә чирле, әллә бетәшкән... Ач тоттыңмыни?

— Алар барысы да шундый, хан,— диде сатучы, уңайсыз елмаеп.— Үкенмәссең, мунысы якшы.

— Ач тоттыңмыни? — диде Алмыш хан, соравын кабатлап.

— Мин ач тутмадым,— диде сатучы, көрсенеп.— Урыста ачлык. Былтыр иген уңмады, андан суң юлбасарлар күбәйде. Ачлык илдә, ачлык, хан. Агам кенәз Родослав сиңа кюп бюлякләр җибәрде. Алары бер каек. Кая илтергә буерасың, хан?

— Урдага илтерсең,— диде Алмыш хан.

— Бюляк белән бергә агам кенәз сиңа зур үтенеч юллады,— диде урыс илчесе.— Муңарчы без синең белән тату яшядек, мундан соң да тату яшяргя язсын,— диде.

— Мин сезнең белән тату яшим — сезнең юлбасарлар гына миңа тынгы бирми,— диде Алмыш хан, шелтә белән.

— Муннан биш ел илек булган яуда кенәзнең языгы юк, буюк хан,— диде Святослав.— Алар юлбасар улакчылар. Алар безгә дә тынгы бирмиләр. Кенәз Родослав юлбасарлар белән туган түгел.

— Беләм, беләм! — диде Алмыш хан, кулын селтәп.— Ул юлбасарлар арасында өч меңе кенәз Родослав ирләре булганлыгын да беләм.

— Анысын мин белмим,— диде илче, тыйнак кына.

Алмыш хан усал гына көлеп куйды.

— Кирәк чакта сез берни белмисез,— диде ул.— Ник, алайса, биш-алты ел буена Урыстан Болгарга бер кәмә дә килмәде?

— Синең ачуыңнан куркып, хан,— диде илче-сатучы.— Иелгән башны кылыч чапмый.

— Сезнең белән без — күршеләр. Үз өеңә кайгы, кыран килгәндә генә түгел, башка вакытта да күршеләр үзара дус яшәргә, барышып-килешеп яшәргә тиеш. Кенәзнең уе изге булса, сезгә урын — түрдән!

— Без изге теләк белән килдек, хан,— диде илче.

— «Изге теләгегез» нindирәк шулай да? — диде Алмыш хан.

— Безгә ашлык кирәк. Ачтан кеше кырыла.

— Ашлык кирәк? — диде хан, сагаеп.

— Ашлык. Күп ашлык! Коткарсаң, безне син генә коткарасың, хан,— диде Святослав.

Мондый сүзләргә чиктән тыш куанса да, Алмыш хан эндәшмәскә кирәк тапты.

— Әйдәле, башка товарларыңны карыйк,— диде ул, җанланып.

Алар басмадан ярга төштеләр, икенче каекка менделәр. Бу каекта ир коллар иде. Алар да каекның аскы өлешендә тезелешеп утырганнар иде. Боларның аякларына тимер богау салынган иде. Ирләр дә, күрер күзгә яшь, таза күренсәләр дә, ачлар, йончылганнар иде. Хан бармак белән төртеп колларны санап чыкты да тазарак ике колны үзенә алды. Мондагылар белән эшне бетергәч, алар бүтән каекларга менделәр, колларны, тиреләрне берәм-берәм санап чыктылар. Ханның теркәүчеләре тамгалыкка алынган товарларны санап, язып, теркәп бардылар, теркәлгән берен алып китә тордылар, санау, язу, теркәү эшләре беткәч, урыс сатучысына Болгар җирендә сату итәргә ал тамгалы ярлык бирелде.

— Иртәгә урдага килерсең — шунда ныгытып сөйләшербез,— диде хан кенәз энесенә.— Кайгырма! Ашлык миндә җитәрлек. Унике батман бодай кенәзгә миннән кучтәнәч булыр. Тиреләреңне, колларыңны сатып алырмын. Шуның өчен каекларыңа төрлесеннән ашлык төятерсең.

— Бай бул, бөюк хан! — диде урыс кенәзенең энесе, сөенеп.

Алмыш хан, атына атланып, шау-шулы базардан салчылар янына китте. «Бирермен дигән колына, чыгарып куяр юлына!» — дип уйлады ул эчке бер куаныч белән. Чокырларда тулып-артылып яткан ике-өч еллык ашлыкларны кая куярга белмичә, әлерәк кенә пошынган иде түгелме соң? Менә, алучысы да табылды. Күктән төшкән кебек булды бу!

Салчылар янына барып җиткәнче ханның күңеле күтәренке булды. Салчылар аңа күңелсез хәбәр әйттеләр: балтачы Кабанны сал басты диделәр.

— Ничек... кайда басты — судамы, җирдәме? — диде Алмыш хан.

— Сал сүткәндә, суда,— диделәр салчылар.— Ярга чыгардык. Аяк сузды. Әнә анда ята.

— Өйләнгәнме, балалары бармы? — диде хан.

— Яшь җегет ирде, хан,— диделәр салчылар, кайгырышып.

— Урыны оҗмахта булыр,— диде хан, китәргә җыенып.

Өлкән яшьтәге бер салчы, күрәсең, әртил башлыгы, аның юлына аркылы төште.

— Йола кушканча күмәргә ирде җегетне,— диде ул.— Аны алай яткырып булмый — үзең беләсең, олуг хан.

— Ташлагыз суга — балыкларга җим булыр! — диде хан.

Өлкән яшьтәге салчының йөзе үзгәреп китте. Аларның сөйләшүен тыңлап торган ирләр башларын калкыттылар, билләрен турайттылар һәм ачулы, борчулы йөз белән ханга якынрак килделәр.

— Юк, алай ярамас, хан! — диде алыптай таза бер җегет.— Ул безнең иптәшебез. Без аны балыкларга ташлый алмыйбыз. Син безгә яхшылап күмәргә ирек бир.

— Эшне ташлапмы? — диде хан, үртәлә башлап.

— Ташланса ташлана инде. Эш дип монда күрәләтә языклы булып булмый,— диде җегет, карулашып.

— Болай да ал-ял белми эшлибез!

— Аякта көчкә басып торабыз!

— Бер көн ял бирсәң, күп булмас, хан! — диештеләр башкалар да, кычкырышып.

— Бу вакытта бер көн ял... беләсезме, нәрсә ул? — диде хан, ачуын тыярга тырышып.

— Беләбез! — дип кычкырдылар салчылар, барысы бердәм булып.

— Белсәгез, эшегездә булыгыз! — диде хан нык итеп. Сүзне беткәнгә санап ул янә дә кузгалып китмәкче булды.

— Юк! — диде алыптай җегет, тавышын күтәреп.— Без — ялланган кешеләр. Без синең колларың түгел. Кабанны күмәргә бер көн бирмәсәң, салыңны үзең чыгарырсың, хан!

Алмыш хан үзен төрле яктан әйләндереп алган таза, ачулы ирләргә җентекләбрәк карады. Ул аларның җил кискән тупас йөзләрендә, нык кысылган иреннәрендә, үзенә төбәлгән күз карашларында көч, ныклык, бердәмлек күрде.

— Ярар, сезнеңчә булыр,— диде ул, тыелып кына.— Иртәгә иптәшегезне күмәрсез. Бүтән көннәрдә артыграк эшләрсез.

Салчылар риза булдылар.

Алмыш хан кире ханбалыкка юнәлде. Юл буена ул үз-үзенә тынычлык таба алмады. Юл буена ул башбаштак, үзсүзле салчылар белән сүз көрәштереп барды.

Бер кешене кырыкка ярырга торган чагында... Кара син аларны! Башка вакыт булса, сөйләштерер идем мин сезне! Барыгызны Кабаныгыз белән бергә балыкларга...

Янган калада ул ташылган агачларны карады, ур төбен, янган койма, капка урыннарын тазартучы кешеләр янында булды. Шуннан соң ул тагын таш мәчет ягына борылды.

Мәчет янында ханны симерә башлаган яшь Бохар мулласы каршылады.

— Чокырны күмдерергә ирде, ханым... тиз кирәкте...— диде ул, ак симез кул аркаларын сыйпаштырып.

— Күмдерергә? — диде хан, исе китеп.— Син үзең көрәк тота белмисеңмени? Ир кешеме син, сабыймы?

— Мин... көрәк тотып? — диде мулла, аңлап җитмичә.

— Мәзин белән икегез...— диде хан.— Бер көрәкне ничек тә күтәрә алырсыз. Алай изгелеге күп булыр.

— Б-баш өсте, х-ханым,— диде мулла, ашыгып, баш иеп.

Болгар-тораның яндырылуы, талануы күп санлы ярлылар өчен мәңге төкәнмәс кайгы булса да, Алмыш хан өчен көтмәгәндә әйтерсең куанычка әйләнде. Урысларга ул ике йөз батман бодай сатты. Шуның өстенә Урыс җирендә биш ел буе тамгалыксыз ашлык сату өчен кенәзнең энесеннән ярлык алды. Соңгы елларда Болгар белән Урыс арасында сату-алу эшләре тукталып тора иде. Моннан соң инде болгар сатучылары бернинди тоткарлыксыз, бернинди тамгалык түләмичә, Урыс җиренең иң аргы төбәкләренә үтеп керә алачаклар. Сатучылар, Урыс җирендә кенәзгә тамгалык түләмәсәләр дә, ярлык өчен монда Алмыш ханга кулбау түләячәкләр! Димәк, ханның чокырына₁ өстәмә байлык агылачак! Берәр елдан, юлы уңып, Тәкин углан кайтып төшсә... алтын динарлар тутырылган капчыкларын чылтыратып, Багдад илчеләрен ияртеп... У-у, бүресе улаячак ул чагында Алмыш ханның!

Йорт башының Урыс илчесе белән килешүен Болгар сатучылары икенче көнне үк белеп алдылар. Белделәр дә, ашыгып, бер-берсен уздырырга тырышып, Алмыш хан өенә агыла башладылар. Ярлык өчен хан уннан бер өлеш кулбау сорады. Сатучылар аптырый калдылар, ык-мык иттеләр, кайберәүләр каршы да килеп карады — ник дигәндә, чит илләрдә сату-алуга ирек бирә торган хан ярлыгына беркайчан да алай күп түләнелми иде. Еш кына алар уннан ярты өлеш, күп булса, йөздән алты өлеш түлиләр иде.

— Мин сездән дә алмасам, янган ханбалыкны ничек торгызырмын? — диде хан аларга.— Йөкнең авырын болай да мин тартып барам. Сез дә тартышыгыз — җиңелгә туры килер.

Сатучылар хан белән артык сатулашып тормадылар. Күршеләрдә ачлык! Мондый җай гел булмый!

Сатучылар бер-бер артлы күнә тордылар, хан кулыннан ал тамгалы ярлыкны ала тордылар. Шулай итеп, ханның чокырына байлык агыла башлады. Шулай итеп, кайгы көтмәгәндә куанычка әйләнде.

Шушындый көннәрнең берсендә Алмыш ханның күңеленә юш килгән тагын бер яңалык булып алды. Таш мәчет төбен казучыларны эзләп табарга дип үзенең шымчыларына каты боерык биргән булса да, шымчылар, бик тырышып эзләүләренә дә карамастан, турыдан-туры языклы беркемне дә тота алмаганнар иде. Аның урынына көтмәгәндә икенче бер угры табылды. Аны Аллага, мәчеткә, Алмыш ханга тел тидерә, диделәр. Аның мәчет төбен казуда турыдан-туры катнашы бармы-юкмы икәнлеген беркем ачык кына әйтә алмады, шулай да аның тотылуы башка угрыларга булган ачуны басу өчен, яңа дингә каршы килүчеләрне куркыту өчен бик тә ярап куйды. Бу угры турында ханга Турай чәчән килеп әйтте.

— Аның коткы сүзләр сөйләгәнен мин үз колакларым белән ишеттем, ханым,— диде Турай чәчән.— Кирәк булса, мин таныкбула алам. Шулай да мине таныклыктан коткарсаң яхшы булырые. Мин башка таныклар табармын.

— Кем ул угры? — диде хан.

— Ул — Бәкәч чәчән,— диде Турай.— Җиңү туенда синең дошманыңны мактап җыру әйткән...

Алмыш ханның йөзе үзгәреп китте. Тотыш угланның батырлыгына чын күңелдән сокланган булса да, аның Койтым бикә углы икәнлеген белгән булса да, җиңелүчене мактап җыру әйткән белексез чәчәнне ул берничек тә оныта алмады. Аның күңеленә ул чәчән агулы ук булып, яман шырпы булып кадалып калды. Ул аны бөтен күңеле белән яратмады. Ул аны Тотышны мактаганы өчен түгел, бөтенләй икенче нәрсә өчен — аны — ханны олыламавы өчен, үзен шундый бәйсез, иркен тотуы өчен яратмады бугай.

Кызгут өчен ханга шундый кеше кирәк тә иде. Өй агасына ул Турай чәчәнгә бер яхшы тун бирергә боерды.

Шул ук көнне Бәкәч чәчәнне кулга алдылар, төрмәгә ябып куйдылар.

Өченче көнне төштән соң, хан урдасыннан бераз читтәрәк, киң языда кызгут булды. Языны бар яктан да коралл ы ирләр уратып алды. Кешеләрне уртага капка сыман итеп калдырылган ачыклыктан керттеләр. Кызгут буласы алдан билгеле булганга, кеше бик күп килде. Атларга атланып ерак болыннардан көтүчеләр килде, авыллардан игенчеләр, Ага-базардан сатучылар, базарчылар, чит ил кешеләре килде. Алмыш хан языга караларны бернинди тоткарлыксыз кертергә боерды. Кызгут, аксөякләрдән бигрәк, ярлы-ябагай өчен, каралар өчен эшләнелә иде.

Менә язы читенә хан чатыры да корылды. Шунда ук, чатыр каршысына, тәгәрәтеп имән бүкән китерделәр. Биленә күн алъяпкыч бәйләгән кара куллы, кара сакаллы тимерче үзенең учагына ут дөрләтеп җибәрде, шалтыр-шолтыр килеп, бик эшлекле кыланып, кыскычларын, чүкечләрен, өткеч безләрен бер урыннан икенче урынга күчергәләде.

Кешеләр җитәрлек җыелгач, чатырына Алмыш хан кереп утырды, аның хатыны, балалары, туганнары килде. Хан белән, ханның туганнары белән бер үк вакытта диярлек языга угрыны да алып керделәр.

Аның куллары, артка каратып, кыл-аркан белән бәйләнгән иде. Арканның бер очын арттан атлап килгән коралл ы ир тоткан иде. Башында бүреге булмаганга, аның озын кара чәчләре маңгаена, иңбашына таралып төшкән иде. Куркуыннан, төнне йокысыз уздырудан аның болай да ак йөзе тагын да ныграк агарып, төссезләнеп калган иде. Үз-үзен нык тотарга тырышса да, ул исерек кеше сыман алпан-тилпән атлый иде.

Кемгә кызгут буласын кешеләрнең күбесе белми иде әле. Алар бары мәчет манарасын аудармакчы булган, яңа дингә тел тидергән нииндидер угрыны тотканнар дип кенә ишеткәннәр иде. Куллары аркан белән бәйләнгән яшь кенә, бала сыман гына җегетне — Бәкәч чәчәнне күреп, барысы да таң калдылар. Шулмы угры? Шулмы таш мәчетне аудармакчы булган? Соң, аның думбырадан башка нәрсә тотып караганы да юктыр!

Кешеләргә күрсәтеп аны өч тапкыр түгәрәк әйләндерделәр. Шуннан соң аны хан каршысына — ачык җиргә алып килделәр, кулын чиштеләр. Языгы зур булганга, кызгутны яргучы[1] түгел, хан үзе алып барды.

— Әй, син, ярлы чәчән! — диде хан яшь җегеткә.— Атың кем, атаң-анаң, ыруың кем? Әйт кычкырып, ишетерлек булсын.

Бәкәч эндәшмәде, куркынган, котсызланып калган күзләрен әрле-бирле йөртеп, як-якка чайкалгалап тик торды. Ул, ахрысы, үзен монда ни өчен алып килүләрен дә аңлап җиткерми иде. Хан кычкырып соравын тагын кабатлады. Яшь җегет, кемнең дә булса үзенә булышуын, ханның сүзләрен аңлатып бирүен үтенгән сыман, артына борылып карады. Артта да, алда да, ян якта да меңләгән күзләр, очлы кораллар күреп, ул тагын да ныграк бөрешеп калды.

— Д-д-д...— диде ул, нидер аңлатмакчы булып.

Аның янына яргучы килде, аның ни әйтергә теләвен белмәкче булды. Бәкәч чәчән, бармакларын думбыра чирткәндәге кебек чиртеп, үзенең уен коралын сорады. Яргучы аңлап алды. Тиз арада яшь җегеткә аның думбырасын китереп бирделәр. Бәкәч чәчән күз алдында үзгәреп китте. Салынган башын югары күтәрде, тар күкрәгән киерде дә күзенә төшкән чәчләрен артка сыпырып куйды, думбырасын

җайлап торкан килеш, орышка җыенган алып сыман, Алмыш хан ягына тынгысыз бер күз карашы ташлап алды.

**VI**

— Атым минем Бәкәч булыр,
Атам — Ала-Серкәч булыр,
Туган ыру — Куян-Колак,
Туган урыным — Тирән Болак.
Туган илем — Бөек Болгар,
Әйтче, ханым, ни кирәк? —

диде чәчән, думбырасын чиертеп.

Аның карлыккан тавышы башта бик көчсез булып чыкты, аннары ныгыганнан-ныгый барды, бит алмаларына кызыллык йөгерде, тынгысыз күзләре, тере очкыннар чәчеп, як-якка йөгергәләп торды. Аның сүзләрен языдагы кешеләр тын да алмый тыңлап тордылар.

— Аңлашылды,— диде Алмыш хан.— Ала-Серкәч углы Бәкәч чәчән, синең языгың зур, син угрылыкта тотылдың. Сиңа менә кызгут ясала. Әйт кычкырып — якчыларың бармы, таныкларың бармы?

— Якчыларым — җыруларым,
Таныкларым — ыруларым,
Олуг Тәңре миңа юлдаш,
Әйтче, ханым, ни кирәк?

— Сине угрылыкта тоттылар,— диде Алмыш хан, яшь җегетнең кыюлана баруына үзенең үртәлүен сизеп.— Син, яңа дингә тел тидерә торган җырулар җырлап, илне-көнне котыртып йөрүең генә җитмәгән, Болгар йортның башы — хан табына торган таш мәчетне аудармакчы булып, аның төбен казыгансың. Син Аллага, ханга каршы кул күтәргәнсең! Шул синең языгың, Ала-Серкәч углы Бәкәч чәчән. Инде әйт — түрә буенча яргулыйммы, йола₁ буенчамы?

Бәкәч чәчән, ханның әйтеп бетерүен көтәр-көтмәс, кызып, җилкенеп такмакларга тотынды:

Алла дисең, мәчет дисең,
Баганага табынасың,
Читне уйлап юанасың,
Боздың Тәңрегә антыңны,
Пычраттың изге атыңны,
Кем син үзең, олуг ханым?!

— Булды! — диде хан, кулын күтәреп.

Яшь җегет аның сүзен әллә ишетте, әллә ишетмәде, әллә инде, күңелендә ташыган ярсуын тыя алмыйча, күзен дә йоммыйча, кайнарланып җыру әйтүендә булды:

— Тәңрегә син кул күтәрдең,
Йолага син лач төкердең,
Мин түгел языклы, ханым,
Син ул, син иң явыз угры!

— Җитте! — дип кычкырды хан, аягүрә басып.

Аның тавышыннан кешеләрнең йөрәкләре кинәт туктап калгандай булды, тамырларындагы каннар әйтерсең бозга әйләнде. Барысының да башлары ирексездән түбән иелде. Бары тик яшь чәчәннең генә башы бөгелмәде. Усал елтыраган куркусыз күзләрендә аның кыю очкыннар чәчрәде. Ул бары бераз тотлыккандай гына итеп торды, аннары, тиз арада исен җыеп, кем дә булса авызымны килеп томалаганчы дигәндәй, ашыгып, әле төркемгә, әле ханга карый-карый, ялкынлы җыруларын такмаклауда булды:

Төкерәмен баганаңа!
Төкерәмен сакалыңа!
Үкенмимен, кайгырмыймын
Астырсаң да, кистерсәң дә,
Тик яшәсен илем-көнем,
Тик яшәсен туган җирем.
Очармын Тәңре катына.
Сиңа тамуг — явыз угры!

Түземлеге төкәнгән Алмыш хан, «авызын томаларга!» дигәнне аңлатып, сакчыларга кул изәде. Сакчыларның берсе шундук зур көчле кулы белән җыручының авызын каплады. Бәкәч чәчән, нидер әйтмәкче булып, өзек-өзек өннәр чыгарды да, кулыннан думбырасын төшереп, кинәт тынып калды.

— Менә, тыгылдымы тамагың, пычрак каргасы! — диде Алмыш хан, усал кеткелдәп.

— Юк, сандугач! — дип кычкырды шунда кемдер төркем арасыннан.

Тораташтай катып калган кешеләр тетрәнеп киттеләр, барысы берьюлы диярлек әлеге тавыш килгән якка борылып карадылар. Тик беркем дә ул кыю кешене күрә алмады.

— Күктән килде! — дип кычкырды кемдер, көчәя барган гөрелдекне күмеп.

Барысы да — сакчылар да, каралар да, аксөякләр дә, борын-борыннан килгән, өйрәнелгән бер омтылыш белән, күз карашларын күккә юнәлттеләр. Алай гына да түгел, Алмыш хан үзе дә, башкалар кебек, билгесез бер көчкә буйсынып, ак болытлар йөзгән төпсез зәңгәр күккә карады. Ата-баба йоласы буенча, күккә карау ул Тәңрегә ялваруны аңлата иде.

— Тыңлагыз! — дип кычкырды Алмыш хан, бөтен языны яңгыратып.

Меңләгән күзләр яңадан түбән иелде, әле генә канатланып алган йөрәкләр яңадан уч төбенә йомылды. Күз алдында үткер сөңге башаклары, кылычлар ялтырап күренде.

— Инде әйтегез: Ала-Серкәч углы Бәкәч чәчән Аллага, ханга тел тидердеме? — диде Алмыш хан, төркемгә карап.

Беренче булып Турай чәчән кычкырды:

— Тидерде, ханым! — диде.

— Ул гына ишеткән, без ишетмәдек,— диде шунда төркем арасыннан бер усал теллесе.

— Мин дә ишеттем!

— Без дә...— диештеләр Турай чәчән янындагы ниндидер шома, сәләмә кешеләр.

— Тидерде, тидерде! — диделәр икенче яктан тук йөзле, яхшы киемлеләр.

— Син... Ала-Серкәч углы Бәкәч чәчән, Алла каршында, хан каршында языклысың,— дип кычкырды Алмыш хан, бераз тынып торганнан соң.— Синең телең озынайган. Түрә буенча, синең телең төбеннән үк кисеп ташланырга тиеш. Әй, болгарлар, белегез: кем дә кем тагын да йорт башы, аның якын кешеләре табынган ислам диненә тел тидерә... кул күтәрә... кем дә кем ханга, түрәгә, биләргә каршы тел озайта, кул күтәрә... аңа да менә шулай кызгут ясалыр. Минем боерыгым җиренә җиткерелергә тиеш!

Язы өстендә шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Бары тик зур кара куллы тимерченең тырышып-тырышып күрик басканы да, утлы күмергә озын саплы кыскыч күмгәне генә бу тынлыкны бозды. Кешеләрнең борыннарын ярып, тимерче учагы ягыннан көйгән ит исе килгәндәй булды.

**VII**

Яңа урында Тотыш өчен хан урдасының читендә аерым өй кордылар. Шунда ук, аның янына, кечерәк өйгә Торымтай урнашты. Торымтай аңа ашарга пешерде, аның вак-төяк йомышларын башкарды. Тотыш беркая чыкмады, беркем белән аралашмады. Ул әлегә үзен монда ничек тотарга да, нәрсә эшләргә, нәрсә эшләмәскә тиешлеген дә аңламады. Ул бары үзенең болгарларда ике ел тоткында яшәргә тиешлеген генә белде. Ике ел әле яңа гына башланган иде. Шуңа күрә көн үтсә дә, үтмәсә дә аның өчен барыбер иде. Ул берничек тә үзенең мондый тоткынлыгына күнегеп җитә алмады. Шулай ук аны ирекле тормыш та — Торымтайдан, ялгыз өйдән башка ниндидер бүтән тормыш та кызыксындырмады. Ул мәңгегә монда калу турында да уйламады, тизрәк атасы-анасы янына кайтып китәргә дә омтылмады. Атасына-анасына, туган ыруына, андагы йолаларга, карашларга үзен бәйләп тора торган ниндидер җеп аңа искәрмәстән өзелде шикелле тоелды. Ул монда — үзе дошман дип белгән болгарлар илендә ят җирләр, ят кешеләр күрде, аларның куанычларын, кайгыларын үз җилкәсендә татыды. Элекке җепләр урынына аны бу якка — Болгарга тартып тора торган икенче җепләр барлыкка килгәндәй булды. Менә шул икенче җепләр аны торган саен ныграк тарта, өстери шикелле тоелды.

Ул Аппакны... Алмыш ханның кызын ярата! Була торган эшме бу? Кемнең тоткыны соң ул — ханныкымы, әллә аның кызыныкымы?

Тик шулай да нинди татлы, нинди куанычлы бу тоткынлык!

Үзара аңлашкан теге кичтән соң әле алар бөтенләй очрашмадылар. Тотыш аны эзләп йөри алмады. Аппак исә, күрәсең, көпә-көндез аның өенә килергә шулай ук батырчылык итмәде. Аннары, бер-берсенә үзләренең күңелләрен ачып салгач, алар әле ныклап торып исләренә дә килә алмаганнар иде бугай. Аларның күңелендә әлегә, яратудан-сөюдән бигрәк, курку-өркү, бер-берсеннән оялу-тартыну өстенлек итә иде бугай.

Шулай да очрашмый тору озаккарак сузылды. Тотыш бүген аны көтә башлады. Күңеле сизенде: бүген алар очрашырга тиешләр иде.

Үзалдына уйланып утырганда, аның янына Алмыш ханнан кеше килде.

— Сине хан үзе янына чакыра, Тотыш,— диде йомышчы.

Тотыш каушап калды. Хан янына? Ник? Кызы белән очрашканны сизде микәнни? Чакырылган җиргә ул теләмичә генә барды, бик нык эче пошып, борчылып барды. Биек ак өйгә барып кергәч, бу борчылу тыелгысыз бер куркуга әйләнде.

Менә ул хан каршысына — күңеленнән иң явыз, иң кансыз дип уйлаган кеше каршына, үзе өчен дөньядагы барлык нәрсәдән, барлык үледән-тередән артыграк, сөеклерәк булган кызның атасы каршысына килеп басты.

— Синең боерыгыңны үтәп...— диде ул, авыз эчендә ботка кайнатып.

— Тезлән,— диде Алмыш хан, теш арасыннан сыгып.

Тотыш, йоланы исенә төшереп, бүреген салды, тезләнде.

Яшь җегет тирләп-пешеп идәндә тезләнеп торганда, Алмыш хан каш астыннан гына аны күзәтте. Аның күңелен, мачы булып, бер сорау тырнады: «Минекеме, түгелме?» — дип уйлады ул, батыр җегетнең таза иңбашларында, киң маңгаенда, борын-күзләрендә үз чалымын табарга тырышып. Төсе-бите белән ул анасына охшаган иде. Тик шулай да аның күз карашындамы, кара кашларының куелыгындамы... Алмыш ханның да төсмерләре бар иде шикелле. Әллә Күрән бинекеме соң? Киң яңаклар, кысыграк күзләр... үткен, очлы күзләр... Юк, шулай да Алмыш ханның каны кайный, ахрысы, моның күкрәгендә!

— Мин сине, Тотыш... угыл, сөйләшер өчен чакырдым,— диде хан, сүзгә башлап.— Моннан соң син минем урдада яшәячәксең.

— Мин инде айдан артык синең урдаңда яшим, хан,— диде Тотыш.

— Син миндә ике ел яшәячәксең,— диде хан, аны тыңламыйча.— Атаң синең урынга башка углын җибәргәч тә, туган җиреңә кайтып китәрсең. Шул булыр тотыклыгың... тоткынлыгың...

— Беләм,— диде Тотыш.— Ике ел буена мин шулай ялгыз өй саклап ятармын микәнни, хан? Ат бир, корал бир син миңа, хан!

— Ат, корал? Ни өчен? Миңа каршы берүзең яу чыкмакчы буласыңмы? Хе-хе...

— Мин яшь, таза. Беләктә көч ташып тора. Нишләп ятыйм мин анда? — диде Тотыш, ханның ягымлы сөйләшүеннән күңеле үсеп.

— Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый,— диде хан коры гына.— Синең сүзләреңдә миңа бүре авазы ишетелә, Тотыш углан!

Ханның кырыслыгы Тотышның курку-каушавын кинәт юкка чыгарды.

— Бүреләр янында бүречә уларга туры килә, хан! — диде ул, урыныннан кузгала язып.

Алмыш хан йөзен чытып куйды. Шулай да, Тотыш углан үзенә нинди генә каты сүз әйтсә дә, ул аңа чын-чынлап ачулана алмас иде, ахрысы. Тотыш аңа кирәк иде, бүгенгесе өчен генә түгел, киләчәге, бик ерак киләчәге өчен дә кирәк иде. Ныклап торып аны кулга ияләштерә алса, ул аны Акбүредә, бөтен Чулман илендә үзенең ышанычлы терәгенә, таянычына әйләндерә алачак. Ул чагында инде аңа төньяк җирләр өчен йокысыз төннәр уздырырга туры килмәс иде. Ул чагында инде аңа Акбүредән арырак җирләр турында да уйлаштыра башларга булыр иде.

— Син — тыйнаксыз,— диде ул береаздан, җиңелчә шелтә белән.— Сиңа өлкәннәр алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнергә кирәк. Син өеңдә генә ятмаячаксың. Болгар түрәсен, йоласын тотсаң, теләгән җиреңә барырсың, теләгән кешең белән очрашырсың, теләгән кешең белән аралашырсың. Тик алдан ук кисәтеп куям: качу турында башыңа да кертеп карама! Качасың икән, яңадан яу белән барып, өеңне, ыруыңны канга батырачакмын! Минем беләк синекеннән дә тазарак, Тотыш углан,— син анаң карынында ятканда минем инде кулда кылыч уйнады. Синең үз язмышың үз кулыңда. Атаңны-анаңны кайгыга салырга теләмәсәң...

— Син салган кайгыдан да зуррак кайгыга салып булмас, хан! — диде Тотыш, кызарынып.

— Бар, чыгып кит! — диде хан.

Тотыш аягына басты, ханга арты белән борылды да, иксез-чиксез тоелган озын йомшак келәмне таптап, ишеккә юнәлде. «Аяк атлавында да нидер бар»,— дип уйлады хан, аның артыннан күзәтеп. Тотыш инде чыгып китте дигәндә генә, ул аны кычкырып туктатты да кире үз янына чакырды.

— Сорарга онытканмын — синең анаң кем әле? — диде ул, тыныч кына.

— Койтым бикә.

— Ярар, китә бир,— диде хан.

«Шулай да ул миңа охшаган! Кыю, усал, таза! — дип уйлады Алмыш хан үзалдына.— Ничек итеп аны кулга ияләштерергә? Ничек итеп... куркытмыйча?..»

Хан тирәсеннән чыгып барышлый Тотыш та уйланды. «Ярый әле берни сизмәгән икән!» — диде ул үз-үзенә, сөенеп.

**VIII**

Торымтай янына Тотыш күтәренке күңел белән кайтты.

— Миңа нишләсәм дә, кая барсам да була! — диде ул.

— Нишләсәң дә микән? — диде Торымтай, шикләнеп.— Сиңа качарга ярамый — әйтмәдемени?

— Әйтте,— диде Тотыш.— Качсам, мине нишләтәчәкләр?

— Тотачаклар,— диде Торымтай, көлеп.— Качкын дип, аягыңны чабып өзәчәкләр дә агач башына элеп куячаклар.

— Алайса, баш исән калачак? — диде Тотыш.

— Кулларың да исән калачак,— диде Торымтай, әз генә дә шаяртырга уйламыйча.

— Тоттырмасам? — диде Тотыш.

— Тотачаклар,— диде Торымтай, тыныч кына.— Итилдә, Чулманда, базарларда, юлларда, авылларда, көтүләрдә Алмыш ханның шымчылары бар. Аларның күзе җиде төн уртасында күрә, аларның колагы җиде кат җир астында җылан күшәгәнне ишетә.

— Урманда да шымчылар бармы? — диде Тотыш бик үк ышанмыйча.

— Урманда — бүреләр. Син соң качарга җыенмыйсыңдыр ич? — диде Торымтай, эчке бер сагаю белән.— Тотыш, мин сине генә җибәрмим. Качсаң, миңа да әйт.

— Сиңа да? Син соң үзең дә хан шымчысы түгел микән?

Торымтайның кара-кучкыл йөзенә сизелер-сизелмәс кенә кызыллык йөгерде.

— Мин — ханның колы,— диде ул, ык-мык итеп.— Әйе, миңа шымчылык та йөкләнгән. Шулай да син миңа ышан, Тотыш! Син кайда — мин шунда. Син мине үлемнән алып калдың. Шуннан бирле мин синең мәңгелек колың, Тотыш! Колың булмасам, юлдашың, карындашың, Тотыш!

— Монысына мин килешәм! — диде Тотыш, Торымтайның кулын кысып.— Тыныч бул, мин беркая качмаячакмын. Ике елдан мин үз ыруыма кайтып китәчәкмен. Беләсеңме, Торымтай, шунда мин сиңа ирек бирермен. Син дә үз ягыңа — Кучәргә кайтып китә алырсың.

— Тотыш! — диде Торымтай, күңеле тулып.— Аяк астында тузан булыйм! Теләкләрең изге улсын!

— Чынлап та, ник качарга? Теләгән җиреңә барырга булгач...

— Синең кая барасың килә соң? — диде Торымтай.

«Синең кемне күрәсең килә соң? дип әйтмәде,— дип уйлады Тотыш үзалдына.— Нишләп соң әле ул бер дә Аппакны телгә алмый? Әллә ул берни белмиме, берни күрмиме? Белсә дә, күрсә дә, юри күрмәмешкә, белмәмешкә салынамы?»

— Минем суны күрәсем килә, Итилне...— диде Тотыш, көттеребрәк.

— Итил ерак. Әйдә Өсән буена гына,— диде Торымтай.

Алар өсләрендәге авыр киемнәрен, итекләрен салдылар да, җиңеләеп, киез, киндер өйләр, алачыклар арасындагы тар сукмактан Өсән ягына юл тоттылар. Хатын-кызларның суга йөри торган сукмагы башта калку җирдән барды, аннары түмгәкләр, тотам-тотам булып утырган куе яшел үләннәр белән капланган, кипкән тизәкләр белән чуарланган тар гына үзәнлек аша үтеп, шомырт, зелпе куаклары артындагы Өсән ярына барып чыкты.

Ханбалык урнашкан текә калкулык астыннан, яшел болыннар, куе урманнар арасыннан боргаланып аккан Өсән суы киң генә, тирән генә иде. Аның түбәнге өлешендә, Итилгә койган тамагында — Ага-базарга каршы якта, тамгалар, агач өйләр бар иде. Итил ярыннан алып ханбалыкка җиткәнче, бер-ике чакрым чамасы арада, әле анда, әле монда төрле зурлыктагы көймәләр, каеклар, улаклар туктап торуын, йә булмаса, аларның әкрен генә кыймылдавын күрергә була иде.

Тотыш белән Торымтай барган турыда елга сай иде, яр буйлары комлы иде. Балыкчы көймәләреннән башка бу тирәгә каеклар да менә алмый иде. Монда, елганың ике ягында да бала-чага су керә иде. Арада яшүсмерләр дә, буй җиткән кызлар да, җегетләр дә бар иде. Алар барысы да анадан тума шәрәләр иде, барысы да юешләр, барысы да никтер көләләр, кычкыралар, чыркылдыйлар иде. Су өстендә, яр буенда, зур яудагы кебек, колакларны тондыргыч бер тавыш, чыр-чу яңгырап тора иде.

Тотыш белән Торымтай су янына якынрак килделәр дә, тирә-яктагы үсмерләргә, бала-чагага карамыйча, өсләрен чишенә башладылар. Тотыш балаларның, үсмерләрнең кызыксынып үзенә карауларын сизеп торды. Ул, яланаяклары белән йомшак комга басып, эчке бер сөенеч тойгысы белән су читенә килде, елгада чагылган кояштан күзләрен йомыштырып, беравык тын гына карап торды, аяк очларын тидереп, суның җылымы, түгелме икәнлеген белде.

Шул чакны аның колак төбендә генә:

— Әй, син, килмешәк, кая тыкшынасың?! — дигән сүзләр ишетелеп китте.

Тотыш ялт кына артына борылып карады. Аннан берничә адым читтәрәк бер җегет басып тора иде. Ул Тотыштан калкурак иде. Беләкләре аның юан, күкрәге киң иде. Кылтаеп үрелгән озын чәчләрен арттан маңгай турысына китереп бәйләгән иде. Аның ачу китергеч чибәр йөзендә мыскыллы көлемсерәү бөркелеп тора иде. Бу теге Тотышны җиңгән Корыч-Тимер алып иде.

— Исеңдәме, син минем аяк астында аунап яттың?! Сине анда хан коткарып калды. Монда беркем коткармас — яхшы чакта үкчәңне күтәр! — диде Корыч-Тимер, бала-чага куркыткан сыман янап, көлеп.

Тотыш, аптырап, сыену эзләгәндәй, Торымтайга, якындагы үсмерләргә карап алды. «Бу ни була инде? Миңа кая барсам да ирек түгелмени?» — диде аның сораулы күз карашы.

Торымтай шундук аңа булышка ашыкты.

— Корыч-Тимер, тынычлан! — диде ул яшь җегеткә, үтенеп.— Тотыш — Алмыш ханның тотыгы, аңа Өсәндә су керү тыелмаган.

— Кит әле моннан! — диде Корыч-Тимер, колны җиңел генә читкә этәреп.— Килмешәккә монда урын юк. Күземә күренмәсен... мин аны!..

Янап, күзләрен чекерәйтеп ул Тотышка якын ук килде. Ул аны, күрәсең, суга төртеп җибәрмәкче булды.

Суга сикерергә укталган җиреннән Тотыш туктап калды. Аның күңелендә, давыл булып, үч, ярсу, оят — барысы берьюлы калкып чыкты. Корыч-Тимернең ташланганын көтеп тормастан, ул беренче булып үзе ыргылды. Масайган Корыч-Тимер исенә килергә дә өлгермәде, болан бугазлаган барыс кебек, Тотыш аның биленнән ике куллап кысып алды да, «ә» дигәнче баш аркылы атып та бәрде. Бу шундый тиз булды, шундый искәрмәстән булды — тынып калган яр буе кинәт чыркылдап җибәрде.

— Җәгез, кем тагын килмешәккә каршы килә? — диде Тотыш, усал елмаеп.

Аңа каршы чыгарга беркем дә батырчылык итмәде. Кемдер бары арттан гына таш ыргытты. Елга төбеннән алынган шома таш шап итеп аның калак сөягенә килеп тиде. Барлык тамырлары, сеңерләре киергедәй тартылган, күкрәгендәге утлы ярсуы уктай атылырга гына торган Тотыш үзенә таш ыргытучыны эзләп тормады — күзенә эләккән беренче угланны тотып алды да, аны да баш аркылы җиргә орды. Орды да, киртәсен ватып чыккан үгез сыман, шундук икенче якка ташланды — авызын ачып торган икенче берәүнең яңагына тондырды, өченчесенең корсагына төртеп алды.

Яр буе кинәт кузгалып куйды. Бала-чага куркып читкә йөгерде, өлкәнрәкләр бер тирәгә укмаштылар. Ул арада Корыч-Тимер дә аягына басты. Басты да, ярсып, үләрен белмичә, яңадан Тотышка таба килә башлады. Чын орыштагы кебек үзенең сизгерлеген, үткенлеген югалтмаган Тотыш искәрмәстән аның эченә тибеп җибәрде — Алмыш ханның макталган алыбы гөрс итеп арты белән җиргә барып төште.

Бер тирәгә җыелган җегетләр, Корыч-Тимернең тынсыз калуын күреп, шыпан-шыпан куаклар арасына шыла башладылар.

— Әй, болгар куркаклары, белегез, бу мин... бу мин — Тотыш булырмын! — дип кычкырды Акбүре батыры, качып баручыларны мыскыллап.— Минем белән очрашканда бер чакрымнан бүрегегезне салыгыз, юкса башыгызны култык астыгызга кыстырып җибәрермен!

— Юлбасар! Килмешәк!

— Ханга әйтеп, үзеңнең башыңны чаптырырбыз!

— Сиңа монда барыбер көн булмас! — диделәр яшь этәчләр, куак арасыннан йодрык янап.

Алтын-көмеш таraклары белән бер-берсенең чәчләрен тараган булып, бер читтәрәк сылу кызлар басып торды. Сокланып, исләре китеп, алар каш астыннан гына атаклы Тотышны — орышта ханның ике алыбын чәнчелдергән яшь батырны күзәттеләр. Пышын-пышын гына нидер сөйләнеп алдылар, тыелып кына көлешеп куйдылар. Тотыш аларның үзенә теләктәшлек белдергән ягымлы күз карашларын тотып алды. Күкрәгеп аның чиксез куаныч тойгысы, җиңү тойгысы биләде. Очынып, җиңеләеп, ул суга ташланды, колач салып йөзеп китте.

## IX

Яр буендагы ызгыштан соң күп тә үтмәде, хан өенә ачулы аталар килеп җитте. Аларның берсе Корыч-Тимернең атасы Алып-Тархан, икенчесе чүлмәкче Котылмыш, өченчесе бакырчы Юлай иде.

Корыч-Тимер атасының чын аты Болан иде, шулай да телдә аны Алып-Тархан дип кенә йөртәләр иде. Яше буенча алтмыштан узган бер карт булса да, көче, тазалыгы белән әле ул кайбер яшьләргә дә бирешерлек түгел иде. Яшь чагында ул тиңдәшсез алып булган, күп яуларда катнашкан, күп дошманның канын койган, алып булуы өстенә ул тархан[1] да иде. Шуңа күрә дә аны шулай Алып-Тархан дип атыйлар иде. Алмыш ханның ул иң якын, иң ышанычлы кешеләреннән санала иде. Үзенең тотнаксызлыгы, былагайлыгы, сугыш чукмарлыгы белән ул бөтен Болгар йортка билгеле иде. Берсеннән-берсе усалрак, берсеннән-берсе йөгәнсезрәк угыллары да аталарыннан бер дә калышмыйлар иде. Моңарчы хан катына җылап-сыктап Алып-Тархан өстеннән, аның угыллары өстеннән башкалар килә иде. Бүген әнә ул үзе килде.

Алмыш хан аның сүзләрен тыныч кына тыңлап утырды да, берни әйтмичә, «сөйлә» дигәнне аңлатып, Котылмышка баш кагып алды. Котылмыш сөйләп бетергәч, шулай ук авыз ачып бер өн чыгармыйча, бакырчы Юлайга ымлады. Юлай туктап калгач та, ул сүз әйтергә ашыкмады. Йомшак келәмдә тезләнеп торган кешеләргә күз кырые белән дә карамыйча, ул артына иелде, биек тәхет артыннан алтын комган тартып чыгарды. Комган авызына каплап куйган көмеш аякны бер кулына, комганның үзен икенче кулына тотып, бик бирелеп ачы бал агыза башлады. Теләр-теләмәс кенә аккан балны ирләр, күзләрен дә алмыйча, ымсынып карап тордылар, борыннарын тарттылар, төкерекләрен йоттылар. Ачы бал сузылып кына, нечкә генә булып акты да акты, аннары өзек-өзек тамчылары да туктап калды.

— Аякчы! — дип кычкырды хан.

Чыбылдык артыннан ашыгып аякчы килеп чыкты, идәндә аунап яткан комганны алып, агач чапчактан аңа бал агызмакчы булды. Хан түземсезләнеп, чапчакны култык астына кыстырды да, эчемлекне турыдан-туры шуннан гына агыза башлады. Тезләнгән ирләр, күзләрен уттай яндырып, бал тулы аякка текәлделәр. Алмыш хан, үзе эчкәч, башта Алып-Тарханны, аннары Котылмыш белән Юлайны сыйлады. Бары шуннан соң гына ул Алып-Тарханга күтәрелеп карады.

— Анда тагын кемнәр булган... таныклар? — диде.

Алып-Тархан үзе белгән унлап угланны санап чыкты. Котылмыш белән Юлай да шул ук угланнарны әйттеләр.

— Алайса, беренче булып Тотыш ташланган? — диде Алмыш хан.

— Беренче булып Тотыш ташланган, ханым,— диде Алып-Тархан.— Углым әнә билсез булып ята.

— Синеке ничек ята? — диде хан Котылмышка.

— Минекенең колак төбе канаган,— диде Котылмыш.

— Синеке ничек ята? — диде хан Юлайга.

— Аңын җуйган. Байтал имчене китердем,— диде Юлай.

— Үзегез ни киңәш итәсез? — диде хан, аталарның әле берсенә, әле икенчесенә карап.

— Кулын чабып өзәргә! — диде Юлай.

— Юк, башын чабарга! — диде Алып-Тархан, кызып, аягүрә басып.

Хан, кулын селтәп, аңа тезләнергә боерды.

— Син? — диде ул Котылмышка.

— Хан үзе ничек теләсә, шулай яргуласын1,— диде Котылмыш.

Алмыш хан, берни әйтмичә, яңадан артына иелде, комганын тартып чыгарды да, шаулатып, көмеш аякка тагын бал агыза башлады. Ачулы аталарны икенче аяк белән сыйлап чыккач, ул, күзләрен усал кысып, Алып-Тарханга борылды.

— Син, Алып-Тархан, минем урында булсаң, нишләриең икән! — диде.— Син әйтмәдең: ник Тотыш беренче булып синең углыңа ташланды икән? Күрәсең, углың үзе башлагандыр...

— Юк, юк, минем углым андый түгел! — диде Алып-Тархан, урыныннан тормакчы булып.

Алмыш хан, кулын селтәп, аны тагын идәнгә тезләндерде.

— Бүлдермә! — диде ул.— Син үзең дә, углың Корыч-Тимер дә төшеп калганнардан түгел. Юкка-барга кыерсыттырып тормассыз. Корыч-Тимер үзе бәйләнмәсә, Алмыш ханның атаклы алыбына... шундый таза иргә бәйләнергә кемнең йөрәге җитсен?!

— Үзе бәйләнгән, үзе! Корыч-Тимер башлаган, ханым! — диде Юлай, сүзгә катышып.

Алып-Тархан, ярсып, билендәге хәнҗәренә тотынды.

— Белеп сөйлә, бакырчы! — диде ул, Юлайга ташланмакчы булып.

Алмыш хан урыныннан торды, кулына кылычын алды.

— Үзара кыйнашкан, ызгышкан угланнарның башын чабарга дигән түрә юк! — диде ул.— Ханга ялган сөйләүченең башын кисәргә дигән түрә бар. Син кайсын яклыйсың, Алып-Тархан?

Эшнең болайга китүен күреп, Алып-Тархан өнсез калды, хәнҗәрен кынына тыкты да маңгаен идәнгә орды, кинәт кенә күз яшьләрен түгеп, ялынырга тотынды:

— Кичер, ханым! Углымны мин ялгыш аңлаганмын,— диде.

Аннан күрмәкче, Юлай белән Котылмыш та башларын җиргә ордылар.

Җиң очлары белән авыз читен сөртеп, бил каешын төзәткәләп, Алмыш хан урынына утырды.

— Күпме көч түгеп, күпме төн йокыларын калдырып... күпме кан коеп мин Чулман буен тез чүктереп кайттым,— диде ул, сүзгә башлап.— Анда йөргәндә минем күпме эшемә монда талау килде! Чулманны алдым — катаусыз калдым. Күпме алыпларым, бөркетләрем юкка чыкты! Оямны торыгызырга миңа бик күп акча кирәк! Син бирәсеңме үз акчаңны, үз байлыгыңны, Алып-Тархан? Сез бирәсезме, чүлмәкче Котылмыш, бакырчы Юлай? Мин әле сездән дә алырмын анысы... Җиде кат тирегезне тунармын әле мин сезнең! Тик миңа җиде кат тире генә дә аз. Миңа ун кат, йөз кат тире кирәк! Тотыш угланның башы елына ун мең тора. Сезнең угланнарыгызның башы күпмешәр тора?

— Минем углым — җиңүче! — диде Алып-Тархан, күкрәген киереп.

— Әйе, үтерелгән ике алыптан соң! — диде Алмыш хан.

— Кичер, ханым, ялгыш миндә,— диде Юлай, тагын баш орып.

— Кичер, ханым,— диде Котылмыш та, ашыгып.

Алып-Тархан да икенче кат шул ук сүзләрне кабатлады.

— Мин сезне кичерәм,— диде хан, тынычланып.— Колагыгызга киртеп куегыз: моннан соң минем тотыкларыма тел тидерәсе, кул күтәрәсе булмагыз. Тотыклар алар шул ук болгарлар. Болгар түрәсе алар өчен дә, сезнең өчен дә бер.

Аталар, оятлы йөзләрен яшереп, кызарынып, өйләренә кайтып киттеләр. Бик кыен, үкенечле булса да, аларга ханның әйткәне белән килешергә туры килде. Тик Корыч-Тимернең генә берни белән килешәсе килмәде. Алмыш ханны ул чын-чынлап Тотышның башын чаптырыр дип уйлаган иде. Атасы кайтып сөйләгәч, ул моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Аның күңелендә коточкыч бер көч

белән Тотыштан, булдыксыз атасыннан, Алмыш ханнан, барлык кешеләрдән үч алу теләге туды. Шул көннән соң ул бары шул теләге белән генә яши башлады.

## X

Тотышның өйгә кайтасы килмәде. Өйгә кайтты исә, анда аны кемдер сагалап, көтеп торадыр шикелле тоелды. Су кереп чыккач, алар Торымтай белән икәүләп Өсән буенда йөрделәр.

Төштән соң күк йөзен кара болытлар каплап алды. Көнне кисәк кенә караңгылатып җибәрде. Түбә өстендә Куар, ачулы мыгырданып, биек таулардан ташлар тәгәрәтте, явыз ияләрне куалап, утлы кылычы белән селтәнде. Шуннан соң коеп яңгыр яварга тотынды. Тотыш үзенең колы белән яңгыр туктаганчы агач төбендә көтеп утырды.

Аларның өйләре түгәрәкләнеп, балдак эчендә балдак булып утырган хан урдасының иң читенә — тышкы «балдакка», төн ягына урнашкан иде. Өйләренә алар болын ягыннан кайттылар, шуңа күрә аларга чатырлар арасыннан үтәргә туры килмәде. Алар кайтып җиткәндә, яңгыр инде туктаган иде, аның урынына, көн караңгылана башлаган иде.

Үзләре өенә бер йөз адым чамасы калгач, Торымтай барган җирендә туктап калды.

— Карале! — диде ул, каядыр алга күрсәтеп.

Тотыш та туктады, аптырап, үз күзенә үзе ышанмыйча, сыек караңгылык аша, үз өе ягына карап тора башлады. Анда, аныкы булырга тиешле түгәрәк өйдән, күккә шәбәеп төтен үрләп ята иде.

— Учак дөрләп китте микәнни? — диде ул Торымтайга.

— Безнең өй түгел бу,— диде Торымтай, икеләнеп.— Әллә яшен ташы төшкәнме соң, тфү, тфү!

— Сөйләнмә! — диде Тотыш.— Учакта утын калгандыр.

Ул тизрәк өенә ашыкты. Аның бу серле төтен чыганагын тизрәк үз күзләре белән күрәсе килде. «Яшен ташы... яшен ташы...» — дип уйлады ул, эсселе-суыклы булып. Булмас ла. Яшен сукса, иң элек Алмыш хан өен сугарга тиеш. Тәңредән, Куардан йөз чөергән башка кешеләрнекен сугарга тиеш. Аларны сукмаган. Әнә хан өе, күкне каплап, кукыраеп, масаеп урда уртасында утыра.

«Яшен башта Алмыш хан өен сугарга тиеш»,— дигән уй Тотышны бераз тынычландыра төште. Югыйсә яшен суккан булса, анда инде бөтен нәрсә юкка чыкты дигән сүз булачак! Хан урдасы, яшен суккан өйне, кешесе белән үзен генә калдырып, шундук күченеп китәчәк. Яшен суккан өйгә беркем якын килмәячәк, андагы кешегә беркем ашарга-эчәргә бирмәячәк. Барлык кеше аннан баш тартачак, шулай итеп, ул үзеннән-үзе кеше булудан, тотык булудан, Күрән би углы Тотыш булудан туктаячак. У-у, ул чагында... аның янына төнлә бары ач бүреләр генә киләчәк!..

Әйе, бу аның өе иде... Коты алынган Торымтайның үзен тотып калырга тырышуына да карамастан, Тотыш йөгереп диярлек ишек янына килде, тартып ишекне ачты.

Учак янында кемнедер күреп, ул чак-чак кына артына авып китмәде. Аның артыннан ук өйгә килеп кергән Торымтай да учак янындагы кешене күреп алды. Икесе дә, ачык ишектән алга узарга кыймыйча, чакырылмаган кунакка карап торуларында булдылар.

— Аппак ич! — диде кинәт Торымтай, кычкырып.

Шулай диде дә, телен тешләп, тынып калды, куркып як-ягына каранды. Өйләр бер-берсеннән ерак урнашкан иде, аннары, ярым караңгы булганга, якын-тирәдә беркем күренми иде.

— Әйттем исә кайттым! — диде Торымтай, пышылдап, кабаланып.— Минем күзем күрмәде, җирдә яткан таш күрде... Минем күзем күрмәде, агып яткан су күрде... Минем күзем күрмәде, исеп киткән җил күрде!

Үзалдына сөйләнә-сөйләнә ул, сак кына атлап, каядыр китеп барды. Аның бу сөйләнүләрен дә, кинәт тынып, юашланып калуын да Тотыш аңламады.

— Аппак шул! — диде ул, куанып, өенә кереп.

Ул учак янына килде, ишеккә арты беләнрәк торган кызны кочып алды, күзләренә карады. Кыз тыелып кына көлеп куйды, кайнар битен аның юеш, салкын битенә тидерде, аның озын чәчләреннән тамган яңгыр тамчыларын учына җыйды. Кинәт ул йомшап, авыраеп калгандай булды. Үзенең беләкләрендә, күкрәгендә Тотыш аның шул йомшаклыгын, исерткеч авырлыгын, кайнарлыгын тойды.

— Нинди куаныч! — диде ул.— Бу көннәрдә шундый сагындым мин сине, Аппагым! Син — минеке!

Кызның ярым йомык, сөрмәле күзләре ачылып китте. Ул аңа исе китеп, елмаеп карап торды да, шаяртып:

— Түгел,— диде.

Ул Тотышның кочагыннан балык кебек шома гына чыкты да, башын чайкап, битенә төшкән чәчләрен артка ташлады.

— Мин синеке түгел, син — минеке! — диде кыз, көлеп.

Аның болай сөйләнүе тотык җегетнең кирәкмәгәндә мин-минлеген кытыклап куйды.

— Нишләп алай? — диде ул.

Кыз берни әйтмичә, җегеткә бер өздереп карап алды да серле генә көлеп куйды, идәнгә төшкән бүреген алып киде. Шуннан соң куенындагы күнчегеннән кечкенә көзге алып, учактагы ут яктысына якын килде. Көзгегә карый-карый төзәнгән арада ул Тотыш ягына да күз төшергәләп алды.

— Әйт әле, нишләп син минеке түгел дә, нишләп мин — синеке? — диде беркатлы җегет, кашын җыерып.

Кыз аңа телен күрсәтте.

— Син Алмыш хан кызы булган өченме? — диде Тотыш.

— Әйтмим! — диде Аппак, үчекләшеп.

— Ник?

— Юри! Килмә, ярамый!

— Нәрсә ярамый? — диде Тотыш.

Тычканга ташланган мачы кебек, ул бер генә ыргылды да кызны яңадан эләктереп алды, кочагына кысты.

— Тотыш, үтерәсең! — диде кыз, чырылдап.

— Әйтәсеңме, юкмы? — диде Тотыш.

— Җибәрсәң, әйтәм,— диде кыз.

Тотыш аны ипләп кенә йомшак киезгә бастырды.

— Син — тиле,— диде кыз, яратып, үз итеп.— Син минеке булмасаң, өең дә минеке булмасые. Үзе югында чит кеше өенә керү ярамаганлыгын беләсеңдер? Сорамыйча керү — шул ук угрылык.

— Син болай да угры кебек,— диде Тотыш.

— «Кебек» белән «бугай» ат койрыгында гына була,— диде кыз, көлеп.

— Чын. Минем янга син бары караңгы төшкәч кенә... кеше күрмәгәндә генә киләсең,— диде Тотыш.— Беркайчан да без кеше алдында очраша алмабыз микәнни? Беркайчан да без бергә була алмабыз микәнни?

Кыз, йөзендәге елмаюын сүндереп, тынып калды.

— Әйдә ул турыда сөйләшмик! — диде ул бераздан уйчан гына.

## XI

Тотыш, юеш киемнәрен салып идәнгә ташлады да, шәрә килеш диярлек учак алдына килеп утырды.

— Киен,— диде кыз, үтенеп.— Торымтай килеп керер әллә.

— Керсә, ни булган? — диде Тотыш, исе китеп.

— Ярамый, киен,— диде кыз.

Тотыш, сүз тыңлап, өстенә коры киемнәрен киде. Ул әле генә Торымтайның: «Аппак!» — дип кычкырып җибәрүен, никтер куркып тизрәк чыгып китүен күз алдына китерде. Аңа монда ниндидер сер бардыр шикелле тоелды.

— Син... Торымтайдан курыкмыйсыңдыр ич? — диде ул кызга.— Әллә Торымтай синнән куркамы соң?

— Мин сиңа әйттем ич: мин гарәп динендәге кеше,— диде Аппак.

— Беләм,— диде җегет.

Менә шул, гарәп дине буенча, ир кеше алдында хатын-кыз битен каплап йөрергә тиеш, ди, үз ире булмаган ирләр белән очрашмаска тиеш, ди.

— Битен каплагач, аны ничек таныйлар соң? — диде Тотыш, шаккатып.— Очрашмыйча кешеләр ничек торалар соң?

— Мин аны үзем дә аңламыйм,— диде Аппак.— Мулла шулай куша. Әти соңгы көннәрдә мулладан да арттыра башлады. Мулла әйтә, ирләр белән хатын-кызлар бергәләп су керергә тиеш түгел, ди, шәрә килеш бер-берсенә күренергә тиеш түгел, ди. Анысы ярамый, монысы ярамый... Барысы да хатын-кызга ярамый! Көн дә мулла безне җыя да шундый нәрсәләр өйрәтә. Аннары гарәпчә укырга-язарга өйрәтә.

— Кызык. Авырмы?

— Җиңел. Мин бернәрсә дә аңламыйм,— диде Аппак, көлеп.— Мулланың юан корсагын, майлы күзләрен күрдемме, берни башка керми,— сине уйлап тик утырам.

— Мин муллага охшаганмынмыни?!

— Юк! — диде кыз, көләргә тотынып.— Син шундый булсаң, нинди ямьсез булырыең!

— Беләсеңме, син өйрән! Язарга да, укырга да өйрән. Миңа да өйрәтерсең,— диде Тотыш чын-чынлап кызыксыну белән.— Йолалары җайсыз булса да, алар үзләре бик башлы, ди. Минем ишеткәнем бар. Беләсеңме, аларча өйрәнсәң, Багдадка, Мисырга барырга була.

— Ник барасың анда? — диде кыз, күңелсезләнгәндәй итеп.

— Кызык итеп. Минем барлык җирләрне күрәсем килә: Румны, Самаркантны, Мисырны...

— Әй лә, кызык түгел,— диде кыз, балаларча киреләнеп.— Телләрен дә, язуларын да өйрәнәсем килми. Башта син өйрән, аннары миңа өйрәтерсең.
— Кемнән?
— Ага-базарда сатучылар бетмәгән, таныштырырмын,— диде Аппак.— Яратмыйм шул мулланы. Үзе, хатын-кыз ирләргә карамаска тиеш, ди, үзе гел миңа карый, башка кызларга карый.
— Сиңа карый? Нигә аны элегрәк әйтмәдең? — диде Тотыш.
— Нәрсә дип әйтергә? — диде Аппак, исе китеп.
— Мин аны! — диде Тотыш, мыгырданып.— Алар барысы да оятсызлар... көньяктан килгән ирләр... Беркайчан хатын-кыз күрмәгән кебек кыланалар.
— Шуның өчен дә көнләшәсеңме? — диде кыз.
— Юк, мин көнләшмим,— диде җегет.— Минем ачу килә. Юк, мин куркам, шикләнәм бугай.
— Нәрсәдән, кемнән куркасың — Корыч-Тимердәнме, аның атасыннанмы?
— Көлмә,— диде Тотыш, ачусыз гына.— Мин инде аны онытып та бетергәнием.
— Син онытсаң да, мин онытмадым,— диде Аппак, эчке бер борчылу белән.— Шуңа да ашыгып килдем менә. Нишләде... нишләдегез анда? Корыч-Тимернең кем икәнлеген... кем углы икәнлеген беләсеңме син?
— Беләм,— диде Тотыш, караңгы чырай белән.— Икенче бәйләнә калса, мин аны!.. Мин аны... нишләтеремне үзем дә белмим. Ни генә булмасын, мин аннан кыерсыттырып тормам. Мин аны чебен урынына, таракан урынына сытачакмын! Мин аны он итәчәкмен!
— Син нинди усал, Тотыш! — диде кыз, сокланып.— Шулай да саграк булырга кирәк. Син мондагы кешеләрне дә, йолаларны, түрәләрне дә белмисең.
— Йола... түрә! — диде Тотыш, ачудан йомарланган йодрыкларын селтәп.— Илгә яу килсә, яуга каршы сугышырга була. Өстеңә бүре ташлана икән, аның белән дә сугышырга була. «Килмешәк» дип сине берәрсе мыскыллый икән, аны җиргә күтәреп орырга була. Йола, түрә юлыңа аркылы төшсә, ул чагында нишләргә? Берни эшләп булмый. Башыңны иеп, килешергә тиеш буласың. Мин инде күптән уйланам ул турыда. Мин күктәге Тәңрегә иманам, җир, су, урман, ут-учак ияләренә... җил-давыл, яңгыр, яшен... җәй, кыш, яз, көз ияләренә... дөньяда була алган барлык ияләргә табынам!
— Мулла әйтә: җир, су, урман ияләре, өрәкләр, албастылар юк, ди, бары бер Алла гына бар, ди.
— Күрдеңме, әнә алар йоласы бөтенләй башкача! — диде Тотыш, никтер кыза башлап.— Гарәпләр дә безнең кебек кеше. Тәҗикләр дә, румнар, кытайлар... ар, чирмеш, урыс — барысы да ике аяклы, ике куллы кеше. Телләре башка да, йолалары башка. Менә шуны аңламыйм мин — барлык кеше өчен җир дә, күк тә, ай-йолдызлар да бер булгач, ник аларның йолалары гына төрлечә соң? Ник берәүгә яраган икенче берәүгә ярамый? Гарәпләр өчен әнә бер-береңә йөзне күрсәтү дә язык, безнең өчен — түгел. Ник болай бу? Кайсы моның чын? Бармы дөньяда чын йола? Әллә болар барысы да бер саташу гынамы?
— Мин белмим,— диде Аппак.— Син әллә нинди сүзләр сөйлисең, Тотыш. Мин куркам. Мин Тәңредән куркам, ияләрдән куркам.
— Син мулладан курык,— диде Тотыш, көлемсерәп.
— Мин барысыннан да куркам, Тотыш,— диде кыз.— Курку минем каныма сеңгән. Мулла әйткәннәр исемә төшсә, кайчакларда котларым алына: ияләр ни әйтер дим, ташлаган, оныткан өчен Тәңре таш белән бәреп үтермәсме дим. Күңелемнән минем беркайчан да ата-баба йоласыннан баш тартканым юк. Син алай Тәңрегә, йолага тел тидермә, Тотыш.
— Мин тел тидермим,— диде җегет.— Мин аңламыйм, мин аптырыйм. Минемчә, йолаларның яхшысы да, яманы да бар. Урлашырга, кеше үтерергә ярамый — яхшы йола. Ирләр белән хатын-кызлар бер-берсенә битләрен күрсәтмәскә дигәне — яман йола.
— Әйе шул,— диде Аппак, килешеп.— Мин синнән йөз яшермим ич. Аны мин дә яхшы йола димим.
— Шулай да син миңа киенергә кушасың!
— Торымтай күрмәсен дим...
— Минеме? — диде Тотыш.
— Безне,— диде кыз.
Тотыш, әйтергә сүз таба алмыйча, аптырап, күңелсезләнеп утырды. Нәрсә соң бу? Нинди серле, яшерен нәрсә бар соң монда?!
— Атаңнан... ханнан курыксаң, мин әле аңларыем,— диде ул, әкрен генә сүзгә башлап.— Билгеле, хан кызы теләсә кем белән йөрергә тиеш түгелдер инде ул. Билгеле, ата кеше... хан булган кеше үз кызының ниндидер тотык белән очрашуын, яратышып йөрүен теләмәс. Анысы аңлашыла кебек. Ник Торымтайдан да яшеренергә? Ник?! Менә монысы аңлашылмый. Ник син... гарәп йоласын яман дип уйлап та, үзең башка кешеләргә күренүдән куркасың? Нишләп син, кешеләрдән генә түгел, көннән, кояштан куркасың? Әлеге дә баягы... мин тотык булган өченме... «килмешәк» булган өченме?

— Юк, юк, Тотыш! — диде Аппак, куркып, аның муенынннан кочып.— Ни сөйлисең?! Ташка язмаганны!..

— Алайса, син мине кызганып... алдап йөрисең?

— Юк, Тотыш!

— Нәрсә, тагын «йола»мыни? — диде Тотыш, мыскыл белән.

— Әйе, йола,— диде кыз.

— Йола?! Чынмы? Алда да йола, артта да йола, уңда да, сулда да! Төкерәм мин йолаларга! Төкерәм! — дип кычкырды Тотыш.— Мине яратудан тыя торган, мине ашаудан-эчүдән, күрүдән, ишетүдән тыя торган... минем кулларымны, аякларымны богаулап ташлый торган барлык йолаларга, инануларга төкерәм мин!

— Тотыш, тукта! — диде кыз чыркылдап, коты алынып.

— Туктамыйм! — диде җегет.— Миңа тын җитми, миңа иркенлек җитми! Канатлар кирәк миңа — Тәңре катына күккә менәм, барысын да аңа аңлатып, сөйләп бирәм — болай яшәп булмый! Мин болай яши дә, ярата да алмыйм!

— Язык, язык! — диде кыз, дер-дер калтыранып.

Колакларын ике кулы белән томалап, ул ишеккә ташланды.

**XII**

Тотыш аның артыннан чыгып тормады. Эзләргә чыкса да, ул инде аны таба алмас иде. Тапканда да, ни файда? Үз кочагында чагында да ул аны үзенеке итеп тоя алмый. Аның өчен Аппак бар да, юк та. Ул аны — Тотышны — ярата да, яратмый да кебек. Ул буй җитмәслек агач башындагы матур алма шикелле. Аны алып булмый, кулга тотып булмый. Ике арада күзгә күренмәгән ниндидер киртә ята. Ул әйткәнчә, йола гынамы монда, әллә тагын бүтән нәрсә дә бармы?

Төптән уйлап караганда, монда әллә нинди аптырар нәрсә дә юк. Хан кызы була торып, нишләп әле ул аны... тотыкны... каяндыр урман арасыннан килгән бер томананы яратканлыгын башкаларга сиздерергә тиеш? Торымтай — шул ук озын колак. Сизсә, атасы аны шундук бирәр бигәме, чит илнең берәр ханынамы кияүгә тотып бирәчәк! Әйе, әйе! Чынлап та, сиздермәскә кирәк! Ничек тә кеше-карага сиздермәскә кирәк. Килсен генә, яратсын гына!

Үз-үзенә урын таба алмыйча, үкенеп, пошынып ул тышка чыкты. Теге чактагы кебек ул аны эзләп каядыр китеп бармады. Бик үк теләмичә генә ул Торымтай янына юнәлде.

— Аппакны күрмәдеңме? — диде ул аңа.

Торымтай, берни эндәшмичә, үзенең учагын дөрләтеп җибәрде, учак тирәсендәге чүлмәкләрен бер тирәгәрәк утыртып куйды.

— Аппакны күрмәдеңме? — диде Тотыш тагын, соравын кабатлап.

— Йокы да килми,— диде кол, чукрак кеше сыман, үзалдына сөйләнеп.

— Нәрсә мыгырдыйсың син? — диде Тотыш, аның кисек колагына күзе төшеп.— Ник әйтмисең — Аппакның чыгып киткәнен күрмәдеңме дим?

— Нинди Аппак? — диде Торымтай.— Мин бернинди Аппакны күрмәдем.

— Баягынак та күрмәдеңме? — диде Тотыш юри генә, сынап карау өчен генә.

— Күрмәдем,— диде кол.

— Син нәрсә, шаштыңмы әллә?! Әллә мине тилегә саныйсыңмы? — диде Тотыш, үз колагына үзе ышанмыйча.

— Юк, синең өйдә мин баягынак та, әле дә синнән башка беркемне күрмәдем,— диде Торымтай, кабатлап.

— Алайса, минем янга Аппак булып албасты килеп йөридер?

— Тфү, тфү! Минем колак ишетмәде, җирдә яткан таш ишетте...— диде Торымтай, такмакларга тотынып.

— Сез барыгыз да миннән нидер яшерәсез! — диде Тотыш, колның каршысына килеп.— Нәрсә? Әйтәсеңме, юкмы?

— Син юкка кызасың, Тотыш,— диде кол, ачусыз гына.— Синең өйдә минем синнән башка беркемне күргәнем юк.

— Син инде аны әйттең.

— Әйттем,— диде Торымтай, килешеп.— Син монда яңа кеше: йоланы, түрәне белмисең.

— Син дә шул ук сүзне сөйлисеңме?!

— Сөйләмичә! Балыксыз күл булмас, йоласыз ил булмас. Йолага, түрәгә, ханга буйсынмаган кешенең башын чабалар. Иртәгә кызгут була — онытмадыңмы?

— Онытмадым,— диде Тотыш, кинәт сүрелеп, төшенке генә.

Торымтай янынннан ул тагын да ныграк пошыну, борчылу белән чыкты. Адым саен түрә, йола, хан... Билгеле, Акбүредә дә йола, түрә бар иде, тик анда ул үзен андый нәрсәләрдән ничектер көчлерәк сизә

шикелле иде. Көчле үк сизмәгәндә дә, ул алардан курыкмый иде. Анда барысы да — урман, сулар да, ияләр дә якынрак, аңлаешлырак иде. Монда да шул ук җир, шул ук күк, тик монда, кая гына барсаң да, ни генә эшләсәң дә, күзгә күренмәгән ниндидер коймага барып төртеләсең.

«Тотык өчен шулай булырга тиештер дә инде»,— дип уйлады ул бераздан, тагын үз уйларына үзе каршы килеп. Моннан соң ул чыннан да саграк булырга тиеш, алдын-артын карап йөрергә тиеш.

Тик икенче көнне үк ул үз-үзенә биргән сүзен онытып ташлады. Ул тагын саксызлык эшләде. Кызгутта, бөтен кеше алдында, хан алдында яшь чәчәнне яклап, «Сандугач!» дип ул кычкырды. Шулай ук «Күктән килде!» дигән сүзләр дә аның авызыннан чыкты.

Якын-тирәдәге кешеләрнең барысы да диярлек ул икәнен күреп, ишетеп тордылар. Алай гына да түгел, Алмыш хан үзе дә, чатыр тирәсендәге башкалар да аның кычкыруын күреп-ишетеп калдылар. Тик беркемнең дә: «Тотыш кычкырды!» — дип әйтергә теле бармады.

Кызгуттан соң аны хан янына чакырдылар. «Үлемем шушыдыр»,— дип уйлады башсыз җегет, шүрли калып. Алмыш хан аңа, алтын аякка салып, агу урынына кымыз бирде, аннары, тыныч булырга тырышып, сүз башлады.

— Тотыш углан,— диде,— күреп торам, син чыннан да бүреләр токымыннан икәнсең. Шуңа күрә ошыйсың да син миңа!

— Шуңа?! — диде Тотыш, ышанмыйча.

— Шуңа,— диде Алмыш хан.— Миңа куйлар түгел, бүреләр кирәк. Аңлы бүреләр...

— Тешсез бүреләрме? — диде яшь җегет, сизелеп торган бер мыскыл белән.

— Юк, аңлы бүреләр,— диде хан нык итеп.— Күреп торам, син мине яратмыйсың, углан. Кызыл Яр катау янындагы орышта минем алыпларымны үтереп, син атаңны-анаңны, ыруыңны якладың. Моның өчен сине яманлап булмый. Анда син хаклы идең. Ләкин тормыш катлаулы, каршылыклы. Тормышта... хаклы кеше түгел, көчле кеше хаклырак. Минем ерак бабаларым да тегендә, җылы яктагы, диңгез буендагы туган җирләрен саклап, дошманнар белән сугышканнар. Алар хаклы булганнар. Ләкин дошман бар нәрсәдән көчлерәк булган. Болгарлар, көчлеләрнең кулы астына эләгеп кол булмас өчен, туган җирләрен ташлап, менә монда Итил-Чулман буена күченеп килгәннәр. Алар монда китәргә дип килмәгәннәр. Мин шулай ук китәргә җыенмыйм. Син углан, үзең турында гына, үз катавың турында гына уйлыйсың. Шуннан башка барлык кеше, барлык ырулар синең өчен — дошман. Шуңа күрә дә сез: акбүреләр, суарлар, казаяклар, бер-берегездән куркып, бер-берегез белән сугышып-ызгышып яши бирәсез. Шуңа күрә дә сез — таркау. Таркаулыктан миңа да, сезгә дә файда юк. Син менә шуны аңларга тиешсең, углан. Шуны аңласаң, син мине дә аңларсың, минем ягым түгел, минем якчым булырсың. Син инде уйлыйсыңдыр: ни өчен Акбүре Алмыш ханга, болгарларга буйсынып яшәргә тиеш дип, Акбүре иркле булырга тиеш дип. Ирекне мин дә яратам. Тик сезнең ирек белән минем ирек арасында бик зур аерма бар. Үз ирегегезне сез үзегез генә саклый алмыйсыз. Сезнең уч төбедәй ирегегез ахыр чиктә сезнең өчен ирексезлек булып кайта. Минем кул астындагы ирек сезне талаудан, кыраннан, кан-яшьтән коткарачак. Минем кул астындагы ирек, ныклы бер кулга тупланган ирек сезне дә, мине дә көчле итәчәк, теләсә нинди читләргә, ятларга каршы тора алырлык бердәм ил-көн итәчәк! Син, Тотыш углан, менә шулар турында уйлап кара. Кызыл Яр катауда торып кына түгел, менә монда — Итил белән Чулман кушылган төштә, барлык ыруларның, барлык ил-көннең кирәге бер тиенгә җыйналган шушы үзәктә торып уйлап кара. Итил-Чулманга йөзләгән, меңләгән елгалар, инешләр коя. Ул елгаларның, инешләрнең күбесе тавык атлап чыгарлык сай гына, тар гына. Аерым-аерым аксалар, беркайчан да алар диңгезгә барып җитә алмаячаклар — корып-кибеп бетәчәкләр. Бөек Итил аларның барысын бергә җыйган. Шуңа күрә дә ул көчле, куәтле. Аны җиңә алырлык бернинди көч юк дөньяда! Итил-Чулман буендагы вак ырулар да, бергә кушылып, Болгар тирәсенә тупланып, менә шундый көчкә ия булырга тиешләр. Син, Тотыш углан, үзең өчен генә түгел, башкалар өчен дә... киң итеп, зур итеп уйлап кара.

— Мин уйлармын, ханым,— диде Тотыш, бераз тынып торганнан соң.

— Мин сиңа ат бирергә, үзеңнең коралларыңны кайтарырга боердым, Тотыш углан,— диде Алмыш хан.— Корал сиңа кирәк булыр. Тик, кара аны, кеше арасында саграк бул!

— Ханым! Чынлапмы?! — диде Тотыш елмаеп, аягына басып.

— Минем көтүдән үзең теләгән атны сайлап алырсың,— диде хан.

— Бай бул, Тәңре сиңа күп яшь бирсен, ханым! — диде куанычыннан нишләргә белмәгән җегет.

## XIII

Таң атар-атмас борын Тотыш өе янына ханның баш көтүчесе Утамыш килеп туктады. Җәен-көзен, төнен-көнен кырда-болында үткәргәнгә, аның җил кискән җыерчыклы йөзе, корымланган чүлмәк төбе кебек, кара янып чыккан иде. Башына ул колакчынлы төлке бүрек, аякларына озын кунычлы күн итекләр кигән иде. Үзе атланган атның ике ягына да ул иярләнгән ике ат таккан иде.

Иң элек ул Торымтайны уятты.

— Тотыш углан кирәкте. Уят аны,— диде карлыккан тавыш белән пышылдап.— Көтүгә барабыз. Үзенә ат сайлар. Ханның боерыгы... Иртәнге чык күтәрелгәнче тотарга кирәкте.

Торымтай ханның боерыгын белә иде. Ул тиз генә Тотышны кереп уятты. Тотыш аны-моны аңлап өлгергәнче, өйгә Утамыш көтүче килеп керде.

— Тор, киен. Тиз бул, углым,— диде ул, сүзне кыска тотып.— Ат сайларга торабыз. Чык күтәрелгәнче...

Йокысы ачылып җитмәгән Тотышның күз аллары яктырып китте. Ул берни сорашып, карулашып тормады, тиз арада киенеп тә алды, көтүче карт артыннан ияреп тә чыкты. Утамыш аңа үзе белән алып килгән атның яшьрәген, көрән төстәгесен бирде. Торымтай киң янбашлы ала биягә атланды. Алар, чыклы үләндә яшькелт эзләр калдырып, кояш чыгышына таба юл тоттылар.

Иртәнге күренеш искиткеч иде. Иксез-чиксез болын өстендә, Итил аръягындагы сызылып кына күренгән күксел калку ярлар өстендә, уң яктагы урман буйларында йокымсырап иртәнге тынлык ята. Җирнең куе үлән белән, түмгәкләр белән капланган түбәнрәк урыннарында, ястык-ястык булып, аксыл томаннар кабарып күренә. Шулай ук кайбер урман ачыклыкларында да, куаклар арасында да төргәк-төргәк томан кисәкләре эләгеп калган. Чикерткәләр әле уянмаган. Аның урынына әле анда, әле монда сыздырып-сыздырып сандугачлар сайрый, бытбылдыклар кычкыра. Шулай да бөтен җирдә, бөтен дөньяда олы, серле бер тынлык саклана.

Күктән таралган бу иртәнге тынлык та, сандугачлар сайравы, бытбылдыклар кычкыруы да Тотышка бик-бик таныш иде. Чык күтәрелгәнче, кояш чыкканчы дип, шушылай ат өстендә тирбәлә-тирбәлә каядыр барулар да, йокымсыраган аяк-кулларның авырлыгы да, салкынча тын алудан күкрәктә әкренләп-әкренләп күтәрелә барган җиңеллек тойгысы да — барысы да, барысы да таныш иде. Шулай да монда — җирдә, күктә, бөтен тирә-якта нindidер яңа төрле киңлек-иркенлек бар, нindidер яңа төрле куаныч-сөенеч бар шикелле иде. Бер карасаң, монда бөтен нәрсә җырлап-көйләп тора сыман, икенче бер карасаң, нindidер әйтелмәгән моң-сагыш бар, гүзәллек, күркәмлек бар сыман иде. Чык тамчыларына күмелеп утырган үлән сабакларын, ак, сары, күк чәчәкләрне, сандугачларны кызганудан, яратудан нindidер, кайсыдыр бик якын кешеңне сагынудан, кайчандыр күңелеңне өтеп алган яшерен әрнү, кимсенү тойгыларын искә төшерүдән үзгәң өзгәләнеп җылыйсы да килә, шул ук мәлдә каядыр күккә, биеккә ашасы да килә шикелле иде.

Шулай моңланып, уйланып барганда, ул үзенең кичәгенәк «Сандугач!» дип кычкырган үз тавышын ишеткәндәй булды. Гүзәллек, серлелек югалды. Тирә-як көтмәгәндә салкынаеп, шыксызланып калды. Билгесез куанычлар, моң-сагышлар белән тибрәнгән күңелне, ачы таш булып, өткеч без булып, чын кызгану тойгысы көйдереп алды. Бозылган, канаты каерылган сандугач белән чагыштырганда, күзгә күренмәгән сандугачларның сайравы моңсыз, күңелсез булып тоелды.

Алар сөйләшмичә шактый ара киттеләр. Хан урдасы утырган болын да, болын читендәге таллыклар да артта калды. Алар сирәк-мирәк куаклар белән, язгы ташу алып килгән ботак-сатаклы, тамырлы агачлар белән чүпләнгән икенче бер болынга килеп чыктылар. Тирә-якта нindidер вак күлләр, камышлыклар күренеп калды. Алда җиз кыңгырау тавышлары ишетелде. Көтүгә барып җитәргә инде күп калмаган иде, ахрысы.

Менә Итил ягыннан беренче талгын җил исеп куйды. Шомырт, кара зелпе куаклары, бер-берсе белән исәнләшкән сыман, җиңелчә генә талпынышып алдылар. Каяндыр борыннарга әчкелтем төтен исе килеп бәрелде. Атларның аяклары астыннан, куе үлән арасыннан, ыргытылган таш сыман булып, чәчрәп кошлар очып чыкты. Шул ук мәлдә тәбәнәк калкулыклар, урманнар артыннан кояшның сөңге башаклары күренгәндәй булды. Утамыш, киек куалаган аучы сыман, ашыгып атын юрттыра бирде...

Күп тә үтмәде, тәбәнәк куаклар да, җир өстенә сузылып яткан тамырлы агачлар да артта калды. Алда искиткеч киңлек, иркенлек ачылды. Монда болынның иге-чиге юк иде. Ут-үлән монда куерак, йомшаграк иде. Шушы иксез-чиксез киң болынны тутырып җылкы көтүе утлап йөри иде. Куаклыктан бер ярты чакрым чамасы арырак, тирә-ягын яшел камышлар әйләндереп алган түгәрәк күл буенда, көтүчеләрнең киез өйләре күренә иде.

Куаклар арасыннан килеп чыккан җайдакларны иң элек этләр сизеп алды. Этләр өргән тавышка атлар да башларын калкытып карадылар, колакларын үрә торгызып, борын тишекләрен киереп, ят исләрне иснәделәр, кешнәп җибәрделәр. Тотышның Көрәне дә аларга каршы сузып кына кешнәп куйды.

— Исәнләшәләр,— диде Утамыш.— Этләр белән атлар кешедән белеклерәк. Алар әнә бер-берсен танып та алдылар, көтүчеләр әле күренми.

— Әнә берсе күренде,— диде Торымтай.

Чыннан да, алачыклар ягыннан болай таба бер атлы кеше килә иде. Бу яшь бер көтүче булып чыкты.

— Барыгыз да аманмы? — диде Утамыш, яшь көтүчегә якынайгач.

— Аманбыз, Утамыш баба,— диде яшь көтүче.

Шулай дигәндә ул кызыксынып Тотышка карап алды, ничектер үз итеп, ягымлы итеп елмайды да, кырт кына борылып, кире чапты. Өрә-өрә аның артыннан этләр иярде.

— Менә сезгә Тотыш углан,— диде Утамыш, көтүчеләр янына килеп җиткәч.— Кояш чыга, балалар. Чык күтәрелгәнче тотып бирергә кирәк берәр тулпарны. Арканга эләктергәнче бәкәлдә чык суы кибеп өлгермәсә, атланган ат чыктай җиңел, җилдәй җитез, арыслandай көчле була.

— Тотабыз, Утамыш баба!

— Була ул! — диештеләр көтүчеләр, ияр өстендә төз, нык утырган алып егетне караштырып.

— Мин үзем тотармын. Аркан бирегез дә...— диде Тотыш.

— Тотарсың, тотарсың, углан,— диде Утамыш.— Шулай да булышмый булмас.

— Минем булышчым бар,— диде Тотыш.— Каян икәнен күрсәтегез дә аркан бирегез.

— Күрсәтәсе юк,— диде Утамыш, яшь җегетнең үзсүзлелеген ошатмыйча.— Көтү — янында. Алмыш ханның иң яхшы атлары шушында. Чапкын өчен, яу өчен симертелә. Ияр күрмәгәннәре дә, күргәннәре дә бар. Кайсын сайлыйсың?

— Мин үзем белермен, Утамыш баба,— диде Тотыш.— Аркан бирәсезме миңа, юкмы?

Аның мондый кирелеген күреп, көтүче башының чын-чынлап йөзе җимерелде.

— Ай-йай! — диде ул, телен шартлатып.— Утамыш кебек көтүче бөтен Болгарда юк. Алмыш хан башта минем белән киңәшә. Син соң ханнан да белеклерәкмени, углан?

— Ат тоту өчен хан булуның кирәге юк, Утамыш баба,— диде Тотыш, тыныч кына.— Үзең әйттең: сайлап алырсың, дидең. Ханның да боерыгы шундый. Ник аяк чаласың?

— Аяк чалган кеше юк, Тотыш углан,— диде Утамыш, йомшарып.— Әйтәм генә. Бар, кайсын телисең, шунысын сайла. Шулай да тиз кыймылда. Бирегез аңа аркан!

Читтәрәк торган көтүчеләрнең берсе, Утамыш авызыннан «аркан» сүзе чыгар-чыкмас, искәрмәстән Тотыш кулына җыелган аркан ыргытты. Тотыш көтүченең селтәнүен, күрүдән бигрәк, тоеп алды. Ялт кына борылды да, кулын сузды, читкә очып барган аркан төргәген эләктереп тә алды. Чит җегетне сынарга чамалаган көтүченең, шулай ук аның янындагы башкаларның күз карашларында соклану билгесе чагылып китте. Торган саен ныграк үртәлә барган Утамыш та кинәт тынып калды.

— Ак юл сиңа, углан,— диде ул мыгырданып.

Торымтай белән Тотыш күлдән ераклашып өлгермәде, Утамыш тузына башлады.

— Карап карарбыз, нindиен тотарсың икән! — диде, төкеренеп.— Утамышны өйрәтүче табылган! Акбүре кергене! Урман арасыннан, аюлар яныннан килеп чыгалар да шулар, болгарлар алдында борын чөяргә тотыналар.

— Арканны нинди шәп тотты! — диде көтүчеләрнең берсе, телен шартлатып.

— Чәкән алпагытны шул чәнчелдергән ич инде! — диде икенчесе.

— Чәнчелдергән! — диде Утамыш, үртәлеп.— Алып-Тархан углы кебек бер селәгәйдер әле.

— Ә-ә! — диде шунда бер көтүче.— Корыч-Тимерне ул билсез калдырган.

— Орышта Корыч-Тимер үзен чак-чак кына чәнчеп үтермәгән! — диде Утамыш, ачу белән.

— Үчен кайтарган инде,— диде икенче көтүче.

— Барыгыз, читтән генә күзәтеп йөрегез — көтүне куркытып, таратып бетермәсеннәр анда,— диде Утамыш.

— Таратсалар, үзебез җыярбыз,— диде яшь көтүче.— Тотыш алыпны бөтен Болгар мактап сөйли — ул гына таныpга теләми, имеш!

— Ярар, телләшмә! — диде Утамыш, кырт кисеп.— Бар, эшегездә булыгыз.

Көтүчеләр, якында гына утлап йөргән иярле атларны тотып алдылар да, атланып, кайсы кая китеп бардылар.

## XIV

Көтү бик зур иде. Меңләгән яшь, таза атлар, күз күреме җитмәслек киң болынны иңләп, таралып, иркенләп йөриләр иде. Аларның кайберләре башларын калкытмыйча үлән умыралар; кайберләре, муеннарын сузып, каршы искән җилдә нindидер үзләренә генә таныш исләрне тоталар; кайберләре, койрыкларын селтәп, тынычсызланып, биеп, уйнаклап, башкалар арасында туктаусыз йөренеп торалар иде. Кайберләре, көтмәгәндә берәрсе белән очрашып, куркып-өркеп бер-берсен иснәштерәләр, икенче берәүләре, чиный-чиный, мышный-мышный, каты тоялары белән дөп-дөп бәреп, үзара чын-чынлап яу ясап яталар иде. Үзара тибешүчеләрдән арырак, икенче берәүләре, шаянраклары, матур башларын алга сузып, озын ялларын җилфердәтеп, койрыкларын күтәреп, бер-берсен узыша-узыша, «качышлы уйныйлар» иде.

Монда күк атлар да, акбүзләр дә, кара-туры, коба турылар да... җираннәр дә, колалар да, алалар да... кашкалар да — барысы да, барысы да бар иде. Кайбер атларның койрыклары юри озын көе калдырылган, кайберләренеке, киресенчә, кыска итеп киселгән иде. Күз тимәсен, урман иясе, саз иясе бозмасын өчен, кайсыбер атларның ялларына, койрыкларына төрле төстәге чүпрәкләр тагылган иде.

Күзләре уттай янып торган, яфрак селкенсә дә колаклары үрә торган сизгер яшь байталлар, яшь айгырлар, чит кешеләр якынлашу белән, шундук читкә китеп бардылар, йә булмаса, күптәнге танышларын күргән сыман, бернинди тартынусыз яннарына килделәр, атларын иснәштерделәр; әрсезрәкләре, арттан калмыйча, койрык булып тагылып йөрделәр.

Атлар күп иде, бик күп иде. Аларны җентекләп карау өчен бер көн түгел, биш көн кирәк булыр иде. Баш көтүче әнә биш көн түгел, бер күлем дә бирми — тизрәк, тизрәк, ди, чык күтәрелгәнче, ди... Кара, нинди белекле! Кем уйлап тапкандыр ул «чык күтәрелгәнче»не?!

Тотыш атын кызу атлатып барды. Аңа атларның берсе дә ныклап торып ошамады. Көр, чибәр атларның ул әле берсенең, әле икенчесенең кимчелеген тапты. Кайсының төсен, кайсының башын, аягын, кайсының билен яратмады. Күңеленнән ул үзенә коштай җиңел, корычтай чыдам, ялкындай җитез ат эзләде. Ни әйтсәң дә, ул аның үз аты булачак! Ике ел буена ул аның иң якын юлдашы булачак. Шулай булгач, ничек инде ул ашык-пошык сайласын аны!

Як-ягына карана-карана, күзәтә-күзәтә ул болынның әле бер җиренә, әле икенче җиренә барып чыкты. Юк, аңа ошаган ат очрамагач очрамады. Ул арада кояш күтәрелгәннән-күтәрелә барды, көн җылынды, чыклар кипте. Чәчәкләрдән татлы исләр бөркелә башлады. Итил ягыннан искән талгын җил белән бал исе, су исе килде. Меңләгән, ун меңләгән тояклар таптаган, шулай да таптап, тигезләп бетерә алмаган биек үләннәр арасында берөзлексез чикерткәләр чәкелдәде, кошлар сайрады. Җир уянды, чын-чынлап уянды.

Яшь җегетнең чырае бозылганнан-бозыла барды. Утамышның сүзләренә бик үк ышанмаса да, шулай да аның «чык күтәрелгәнче»се күңелен тырнап, эчен пошырып тик торды.

— Болай ашыгырга ярамый,— диде ул, атын туктатып.— Ашыйсы да килә. Әйдә кире борылабыз. Төштән соң яхшылап карарбыз.

Алар борылдылар да түгәрәк күл ягына карап киттеләр.

— Тапмадыгызмыни? — диде Утамыш, аларның буш кул белән килүен күреп.

— Тапмадык,— диде Тотыш.

— Иртәгә иртәрәк карап карарсың тагын,— диде Утамыш, ашыгып.— Әйдәгез, ашарга утырыгыз. Кояш югары — ашаган югале...

Тотыш кешәнләп атны утларга җибәрде. Торымтай белән алар күлдә битләрен, кулларын юдылар, учак янына, киез өстенә килеп утырдылар. Утамышның ише, озын киндер күлмәк итәген биленә кыстырып куйган шадра хатын, агач табакка салып, пешкән балык, ботка китерде, тулып, бүлтәеп торган турсык китерде.

— Без ашадык. Сез генә калдыгыз. Әйдәгез, җитешегез,— диде хатын Тотыш белән Торымтайга.

Кунаклар ашаган-эчкән арада, Утамыш, аякларын чирәм өстенә сузып җибәргән килеш, үзенең иярен төзәткәләде.

— Якын-тирәдә кан коелдымы, бүре җыела,— дип сөйләнде ул үзалдына.— Төннәрен көтүгә киләләр. Бүген төнә буе шулар белән сугышып чыктык. Бишесен үтердек. Бер байталны талаганнар.

Тотыш аның шулай әкрен генә сөйләнеп утыруына бөтенләй колак салмады. Шулай да бүреләр белән сугышу турындагы сүзләрне ул ишетеп калды. Шундук ул үзенең изге нарат янындагы төнге сугышын исенә төшерде. Нинди башсыз булган ул! Атасы булмаса, Утташ кам инде күптән аның башын ашаган булыр иде. Атай, анай!.. Кайда икән алар? Өйдә микән, исән микән алар? Уйлый микән алар үзләренең игелексез угылларын?

Шулай уйланып утырганда, аның күзенә бернәрсә чалынып калды. Күлмәк итәген биленә кыстырып куйган шадра хатын, кулына тоткан чүлмәген ничектер качыргандай кыланып, якындагы куаклыкка кереп чыкты.

— Булдымы, туйдыгызмы? — диде Утамыш, эшеннән аерылып, кунаклар ягына карап.— Бал куйганыек та, булуы җитмәгән, иртәгә авыз итәрсез инде.

«Тизрәк кайтарып җибәрмәкче була»,— дип уйлады Тотыш, яратмыйча.

Бераз тынып утыргач, алар яңадан атларына атландылар. «Тагын бер әйләнеп чыгарга кирәк»,— дип уйлады Тотыш, ныклы бер уйга килеп.

— Ярый алайса, углан,— диде Утамыш, саубуллашырга ашыгып.— Иртәгә иртәрәк үзегез килерсез, мин барып алганны көтеп ятмассыз.

— Сау бул, Утамыш баба,— диде Тотыш, кузгалып.

Ул, урда ягына китәсе урынга, көтү ягына юнәлде. Баш көтүче, моны күреп, тынычсызлана башлады. Авызын ачып нидер әйтергә дә итте, әйтә алмады. Куаклык буйлап китеп барган Тотыш кинәт сулга каерды, тар аралыктан андагы әрәмә эченә кереп китте. «Эх!» — диде Утамыш көтүче, ырылдауга охшаш бер өн чыгарып. Кулына күсәк алды да ашыгып Тотыш артыннан йөгерде.

Куаклык эчендәге кечкенә аланда утлап йөргән атны Тотыш бөтенләй искәрмәстән күреп алды. Ат тышаулы иде. Нукта тезгене тышауга тарттырып бәйләнгән иде. Шуңа күрә ат, теләсә дә, теләмәсә дә, башын калкытмыйча, шушы аланда гына утларга тиеш иде.

Тотыш якынрак килде, караштыра башлады. Тышаулы ат, чит кеше килүен сизеп, ашавыннан туктады, колакларын шомартты, башын калкытырга тырышып карады. Ул озын, нечкә торыклы, киң күкрәкле иде. Аның йомры нечкә биле, янбашлары сыгылып, уйнаклап тора иде. Ялы, койрыгы яхшылап киселгән, таралган иде. Бу тимеркүк искиткеч сылу иде!

— Кашка! — диде Тотыш, аның маңгаендагы ак йолдызын күреп.

Сикереп үк атыннан төште, Тимеркүкнең нуктасыннан эләктереп алды, тезген очын чишеп җибәрде дә, иплэп кенә, иркәләп кенә атның күкрәгеннән, муеныннан сыйпалый башлады. Маңгаендагы кашкасы белән генә түгел, үзенең буй-сыны белән, үз-үзен тотышы, күз карашлары белән ул угланның йолыкка чалынган Йолдыз-кашкасына охшаган иде!

Тотыш бар нәрсәсен онытып Тимеркүкне сыйпалаганда, агарынып аланга Утамыш көтүче килеп җитте.

— Бүре талаган! Бүре талаган! — дип кычкырды ул ерактан ук, тыны бетеп.

— Миңа бу ошый,— диде Тотыш, елмаеп.

— Бүре талаган диләр сиңа! — дип кычкырды Утамыш, күсәге белән кизәнеп.

— Кай җирен талаган? Берни күрмим,— диде Тотыш.

— Талаган, талаган! — диде Утамыш, атның нуктасыннан кысып тотып.— Ярамый! Булмый! Бирмим!

— Таласын. Мин шушы атны алам,— диде Тотыш, үзсүзләнеп.— Ярасын үзем төзәтермен.

— Кит! Якын килмә! — дип кычкырды Утамыш, күсәген яңадан күтәреп.

Тотыш атның бер ягында, Утамыш икенче ягында иде. Тотыш, теләсә, билгеле, атка сикереп атланган да булыр иде. Ул атланмады. Ул каушабрак калды. Утамыш эре сөякле, каты куллы иде. Анда тыелгысыз көч котырына иде.

— Ярар, бирмәсәң бирмә,— диде ул, кире чигенгәндәй итеп.— Ханга җиткерәм. Торымтай, таных бул: хан боерыгын үтәмәде.

— Таных! Таных! Хан боерыгын үтәмәде! — дип кычкырды Торымтай.

Тотыш, Тимеркүкнең нуктасын ычкындырды да, читкә китеп барган иярле аты янына ашыкты. Иярле ат аланның икенче башында ашанып тора иде. Тотыш, атына атланганда, куаклар арасында алачык сыман нәрсә күреп, тоткарланып калды. Аягын өзәңгедән кире алып, кызыксынып, ул әлеге яшерен куыш янына килде.

Агач ботакларыннан корыштырган алачыкта, яңа чабылган печәндә бер кеше ята иде. Ул, ахрысы, чирле иде. Өстенә аның юка тун ябып куйганнар, авызы турысына ак яулык каплаганнар иде. Ник шулай кеше күзеннән яшерделәр икән соң аны? Алачыгы тәбәнәк кенә — ерактан түгел, якыннан да күрерлек түгел.

Тотышның якынлашуын күреп, алачыктагы кеше ыңгырашып куйды, калкынгандай итте. Шунда аның авызын каплаган яулыгы бер читкә шуышты. Тотыш, куркуданмы, таң калуданмы, чак-чак кына кычкырып җибәрмәде: яшерен куышта Бәкәч чәчән ята иде! Аның иреннәре күпкән, авызы — ярым ачык иде.

— Сан-ду-га-ач! — диде Тотыш, исе китеп.— Менә кайда икән синең ояң!

Аның янына ашыгып тагын Утамыш көтүче килеп җитте.

— Кит моннан, кит, Тотыш углан! — диде ул, үтенеч сизелгән бер йомшаклык белән.— Ярамый. Савыксын. Ярамый, борчыма.

Бәкәч чәчән, күрәсең, янына кешеләр килүенә куанып, көчәнеп урыныннан торды, нииндидер кызганыч бер тавыш белән мөгердәп, ярым йомык күзләрен киереп ачты да Тотышка текәлде. Аның бу күз карашы — соклану да, нидер үтенү дә, әрнү дә белдергән моңлы күз карашы тотык җегетне тетрәндереп җибәрде.

— Кузгалма, балам, тыныч кына ят,— диде Утамыш, яралы «сандугачның» авыз тирәсендәге чебеннәрне куып.

Аңа каршы чәчән нииндидер өн чыгарды, Тотышка төртеп күрсәтә-күрсәтә, чандыр кулы белән селтәнеп-селтәнеп алды — аның бу селтәнүен кылыч белән чабу, сөңге белән кадау дип аңларга була иде. Шуннан соң ул Тотышка үзенең балаларныкы шикелле кечкенә кулын сузды. Тотыш иплэп кенә аның йомшак, көчсез кулын кысты.

— Тотыш углан була бу, балам,— диде Утамыш, никтер каушагандай итеп.

Бәкәч чәчән, белгәнлеген аңлатып, көтүчегә баш какты, күзләре белән елмаеп куйды.

— Шулаймыни? — диде Утамыш.— Сине каян белә ул, Тотыш углан?

— Белә инде,— диде Тотыш, чәчәннең үзен тануына аптырап.

— Кичер мине, углан,— диде Утамыш көтүче, читкә борылып, күз яшьләрен сөртеп.— Тимеркүкне мин аңа... үзебезнең сандугачка атаганыем. Сандугач түгел, бөркет иде ул! Ханнарның, биләрнең

күзләренә карап турысын әйтә алган бердәнбер кешебез бар иде — ул да менә телсез калды. Өч улым хан өчен яуда үлде, буй җиткән кызымны суарлар алып китте. Йөрәгемә кара кан укмашкан минем, Тотыш углан! Кая карама — кан-яшь, кая карама — кайгы-хәсрәт. Туктаусыз яулары-сугышлары гына җитмәгән, көчләп әнә изге йоланы ваталар, күңелеңне таптыйлар. Ничек түзә моңа Тәңре, минем менә шуңа башым җитми, Тотыш углан!.. Теләсәң, Тимеркүкне ал син, балам. Мин аңа — телсез бөркеткә икенчесен бирермен.

— Юк, Утамыш баба! — диде Тотыш, билен язып, эчке бер тойгы белән.— Болай булгач, мин Тимеркүктән баш тартам. Син миңа, булмаса, шул икенчесен бир.

**XVI**

Шулай да ул урдага Тимеркүккә атланып кайтты. Йолдыз кашкалы байталны аңа Утамыш түгел, Бәкәч чәчән бирде. Тотыш атны алса да алды, алмаса да алды. Бары тик Бәкәч чәчәннең, баш тартканны күреп, йөзе үзгәргәч кенә ул үзенең икеләнүен җиңә алды. Төрле ымлыклар, кул болгаулар белән Бәкәч аңа Тимеркүкне бүләк иткәнлеген аңлатты. Бүләктән баш тартмыйлар, диде, яхшы ат миннән бигрәк сиңа кирәгрәк, диде.

Юл буена Тотыш уйланып кайтты. Моңарчы ул бары үзе турында гына, үзенең язмышы турында гына уйланса, бүген ул башкалар турында — үзенең кордашы яшь чәчән турында, Утамышның яуда үлгән уллары турында, суарлар алып киткән кызы турында уйланды. Утамыш белеп сөйли: кая карама — кан-яшь, кая карама — яу-сугыш. Берәүләр җиңә, икенче берәүләр җиңелә. Чынлап торып уйлап карасаң, ник кирәк бу яулар-сугышлар? Ник?! Акбүрене болгарлар килеп басты, болгарларны — суарлар. Утамыш кына түгел, Алмыш хан да белеп сөйли, үзара яулар, сугышлар булмасын өчен, чыннан да бер йодрыкка тупланырга кирәк түгелме соң?!

Урдага кайтып җиту белән, аның каршысына каяндыр шар күзле юан гына бер кеше килеп чыкты. Ул үзен Алмыш ханның агычысы[1] дип белдерде.

— Сиңа, Тотыш алып, шаеңны кайтарып бирергә дигән боерык бар,— диде ул түбәнчелек белән.

Тотыш аның артыннан иярде. Алар хан өенә якын урнашкан бер зур гына өй янына килделәр. Агычы, билбавына тагылган ачкычларын бармаклары белән аралаштырып, арадан берсен тотты да, калын ишектәге зур йозакны ачты, эчкә кереп китте. Ул Тотышның сөңгесен, күбәсен, калканын чыгарып җиргә куйды, аннары җәясен, садагын, иярен алып чыкты. Үз коралларын күреп, Тотышның йөзе балкып китте. Ул шундук үзенең сөңгесен, калканын кулына алмакчы булды.

— Башта кулыңны куй,— диде агычы.— Яза беләсеңме? Менә бу тузга тамгаңны куй.

«Шаемны алдым. Тотыш» дип язып куйды яшь җегет үзенә бирелгән туз кисәгенә.

Агычы аның шома, җиңел язуына исе китеп карап торды.

— Син әле шулай язу таягы белән дә селтәнә беләсең икән! — диде ул.

— Беләм шул,— диде Тотыш.

— Беләге бар — берне җыгар, белеме бар — меңне җыгар! Сиңа битекче булыргае,— диде агычы.

— Битекче? Нигә? — диде Тотыш болай гына, артык сүз куертасы килмичә генә.

— Битекченең эше изгерәк. Сез, алыплар, кеше үтерәсез. Кеше үтерү — язык. Алмыш хан әнә болгар сүзләре язылган билге-ташларны юкка чыгармакчы була, ди.

Соңгы сүзләрен ул Тотышка якын ук килеп, пышылдап диярлек әйтте. Әйтте дә, сакчылар ягына кырын күз карашы ташлап алды, көрсенеп куйды.

— Син монда яңа кеше шул әле,— диде аннары, үз итеп.— Син әле күп нәрсәне аңламыйсың. Бозылды дөнья, бозылды тормыш. Ханның, бинең балаларын җыеп әнә гарәпчә укыталар, болгар иҗегенең көне төкәнде. Ничек түзә моңа Тәңре?! Уйласаң, башлар әйләнә. Кичә менә Бәкәчтән дә колак кактык. Бозылды ил-көн, бозылды ханнар...

Тотыш аның кайгылы сүзләрен бик үк тыңламады. Сөенеченнән нишләргә белмичә, ул үзенең киемнәрен киде, билен буды. Аннары ул атына атланды, алпаклы башын югары тотып, биек өйләр арасыннан үз өенә юл тотты.

Көне буена ул үзендә бер куанычлы җиңеллек тойды. Әйтерсең аңа инде бүтән берни дә кирәкми иде. Әйтерсең аның инде барлык теләкләре тормышка ашкан иде. Көне буена ул үзенең Тимеркүге белән булды: Өсән буена барып, ул аны су кертте, юды, кыргычлады, аның ялларын, койрыкларын тарады. Аты белән эшен бетергәч, үзенең коралларына тотынды — ышкыды, ялтыратты, кайрады...

Ул арада кояш та баеды. Җир өстенә кичке талгынлык саркый башлады. Ышкыйсы, тазартасы, төзәтәсе эшләре беткәч, Тотыш бушанып калгандай булды, өенә керде дә, тезләрен кочаклап кызу учак каршысына утырды.

— Корал тотып кая барырмын икән соң мин? — диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Миңа инде су буена барганда да кылыч күтәреп йөрергә туры килер микәнни?

Кинәт аңа күңелсез булып китте. Тимеркүк тә, кораллары да, киемнәре дә — бөтен нәрсә аңа кирәксез булып, чит, ят булып тоелды. Чыннан да, ник сөенде соң әле ул көне буена? Кемгә каршы

сугышачак, кем өчен сугышачак соң ул? «Сандугач»ның телен кистергән хан өченме, әллә аның кызы өченме?!

«Уйламаска кирәк моннан соң. Хан кызы белән тотык арасында беркайчан да чын яратышу булмаячак»,— дип уйлады ул. Учак янынынан торды да, Тимеркүкне күрәсе килеп, тышка чыкты. Торымтайның Җирәнкәе белән утлап йөргән тышаулы аты янына килде.

Бүген ул беркемне дә көтмәде. Ул, җиргә җәелгән иске киез өстенә сузылып ятты да, еракта янган йолдызларга текәлде. Тиздән аңа монда да күңелсез була башлады. Ул яңадан өйгә керде, йокларга ятты. Күзен йомып та өлгермәде, ишек тарткан тавышка ул сикереп урыныннан торды. Эчке бер сизенү белән ул аның Аппак булырга тиешлеген аңлап алды.

— Кер! — диде ул, эчтән ишек бавын чишеп.

Ишекне ачып җибәргән иде... тимерле киемнәрен чылтыратып, өй эченә караңгыдан ниндидер кораллы ир атылып килеп керде. Тотыш артка чигенде. Шул ук мәлдә ул, үзенең кылычын, калканын исенә төшереп, ятагы янына омтылды.

— Кузгалма! — диде кораллы ир, боерып.

Аның бу куркыныч тавышында көлемсерәү ишетелеп киткәндәй булды. Тотыш кинәт телсез калды. Сүрелеп барган учак яктысында ул кораллы ирнең буй-сынын күздән кичерде, карлыккан, йокылы тавыш белән:

— Син кем? — диде.

Кораллы ир, битлеген артка ташлап, көлеп җибәрде. Тотышка бик-бик кыен булып китте.

— Сиңа ни кирәк? — диде ул, каушавын яшерергә тырышып, ясалма бер усаллык белән.

— Син кирәк! — диде Аппак, көлә-көлә.

— Төн уртасында... кеше өенә басып керергә...— дип мыгырданган булды Тотыш.

— Үз өемә керү... басып керү түгел,— диде Аппак.

— Атаң өенә дип белсәң генә...— диде Тотыш, чеметтереп.

Аппак, башына суккан сыман, тынып калды, коралларын идәнгә куйды да алпагына тотынды.

— Авыр, үлә яздым,— дип сөйләнде ул.

Шуннан соң ул көйрәп яткан учак янына килде, учакка утын өстәде дә чәчләрен төзәткәләргә тотынды.

— Кичер мине, Тотыш,— диде.— Үзең «кер» дидең ич. Ник тагын авызыңны күптердең? Киен, әйдә, киттек.

— Кая?

— Кая булса да! Оялмыйча йоклап ятмакчы буласыңмы? Җәйге төн шундый матур! Синең инде атың, коралың бар... Теге көнне әллә нәрсәләр әйтеп минем күңелемне кырдың да, мин бик борчылдым. Әнә карар йөзем дә калмаган. Карале, мин бик ямьсезләнмәгәнмеме?

Ут яктысында ул Тотышка әле бер як битен, әле икенче як битен күрсәтте, ак тешләрен юри ыржайтып, ясалма бер елмаю белән елмаеп алды.

— Син — гүзәл! — диде Тотыш, күңелендәге бозны йотып.— Шулай да мин аңламыйм: ник киендең ул киемнәрне? Нишләп болай килдең? Кая бармакчы буласың?

— Баргач күрерсең,— диде Аппак, серле итеп. Ул алпагын яңадан башына киде.— Болай матурмы? Чын ир булдыммы?

— Булдың! — диде Тотыш.

— Коралларыңны ал, Тимеркүккә атлан,— диде кыз.

— Син күрдеңмени? Тимеркүккә атланып йөргәнне син күрдеңмени?! — диде Тотыш.

— Күрдем,— диде кыз.— Әйдә, киенәсеңме, юкмы?

— Киенәм! — диде Тотыш.

Бераздан алар, атларын әкрен генә атлатып, сөңгеләрен югары тотып, караңгылыкка кереп юк булдылар. Хан урдасын саклаучы төнге каравылчылар да шулай, сөңгеләрен югары күтәреп, икешәрләп йөриләр иде.

## XVII

Бүген алар яктыра башлаганны сизмичәрәк калдылар, ахрысы. Кайту ягына борылганда, җир өстендәге караңгылык инде таралган иде, болыннар, урманнар, күк йөзе таң алды йокысына чумып, тынып-изрәп ята иде.

Алар атларын кызулый төштеләр. Таныш әрәмәләрне, ауган карамаларны узып киттеләр дә куе таллыкка килеп керделәр. Таллыкны чыккач болын башланырга тиеш иде. Таллык урынында кайчандыр үтеп булмаслык сазлык булган. Инде ул кипкән. Көтү йөреп, арасыннан юл ясап бетергән. Алар куе таллар арасындагы тар гына ачыклыктан, көтү сукмагыннан киттеләр. Сукмак тар булганга, ике ат сыймады — Тотыш алдан барды, Аппак, бераз җир калышып, арттан килде.

Таллык авызына якынлашып килгәндә, Тимеркүк кинәт тынычсызлана башлады — як-ягына каранды, пошкырып-пошкырып алды. «Бүре микәнни?» — дип уйлады Тотыш, сөңгесен җайлабрак тотып. Аппакны көтеп, ул атын тыя төште.

— Нәрсә бар? — диде кыз.

Атта йөрүдән, иртәнге салкынлыктан аның бит очлары алсуланган иде, шаян күзләреннән, иртәнге кояш нурлары сыман тыелгысыз сөю, сөенеч чаткылары бөркелә иде. Тотыш аның чык тамчылары белән юылган болын чәчәгедәй алсу, гүзәл йөзенә елмаеп бер карады да, шауламаска, тыныч булырга кушып, кулын күтәргәндәй итте. Шуннан соң ул, тезгенне җыя төшеп, сак кына яңадан кызулап китте. Алда шылт иткән тавыш та ишетелмәде.

— Нәрсәгә исең китте соң? — дигән булды Тотыш, туктаусыз пошкырынган, тынычсызланган атына эндәшеп.— Беркем юк, котың алынмасын!

Ул моны, аттан бигрәк, Аппакны тынычландыру өчен әйтте бугай. Үзе ул уяулыгын аз гына да киметмәде. Ат, билгеле, тикмәгә генә пошкырынмый иде, алда ни дә булса булырга тиеш иде.

Шулай булып чыкты да. Таллык бетеп, тәбәнәк калкулыктан менеп килгәндә, алда, як-якта ниндидер атлылар күренде. Алар алты-җиде иде, барысы да кораллы, тимер киемле иде. Болар төнге каравылчылар булырга тиеш түгел иде.

Тотыш каршысына беренче булып килеп җиткән кораллы ир, әтәчләнеп, битлеген күтәрмичә:

— Ым? — дип кычкырды.

Тотыш каушап калды: ул ымны онытткан иде. Ул арада башкалар да килеп җиттеләр, сөңгеләрен җайлап, юлга аркылы төштеләр дә, көтә башладылар.

— Әһә, белмисез! — диде ым сораган ир, усал итеп, сөенеп.

Тотыш аның тавышыннан танып алды. Каушау, аптырау кыргый бер ярсу белән алышынды. Ул кизәнеп сөңгесен Корыч-Тимергә тондырыйм дигәндә генә, арттан Аппак килеп, аның беләгеннән тотып алды.

— Тотыш, ярамый! — диде ул, куркып, ялварып.

Тотыш аның үтенеченә буйсынып, сөңге башагын түбән иде.

— Кистән! — диде Аппак, ымны әйтеп.

Корыч-Тимер битлеген ачып җибәрде, Тотышка туры карап, шаркылдап көләргә тотынды.

— Тотышмы? Тотыш! Тотыш белән Аппак! Төнге каравылчылар! Җибәрегез, китсеннәр!

Аның сүзләреннән Тотыш берни аңламады. Ул бары үзенең көчкә тыелып торуын гына, Аппак ирек бирсә, бернигә карамый үзенең дошманына ташланачагын гына аңлады. Ник туктатты ул аны, ник тота ул аны? Кырын күзе белән генә ул Аппакка карап алды.

— Барыгыз, бар, ник туктадыгыз? — диде Корыч-Тимер, көлеп, атын читкә борып.

Җиңүче булып сөйләнсә дә, ул Тотыш кулындагы сөңгедән күзен алмады. Узып китәргә юл биргән булып, ул әкрен генә читкә каерды. Башкалар да аннан күрмәкче атларын бордылар, ике ара шактый ераклашкач кына: нишләр икән болар дигән сыман, читтән генә карап, көтеп тора башладылар.

— Тотыш... беттек! — диде Аппак пышылдап, алга узып.

— Бетмәдек! — диде Тотыш.— Ник туктаттың?!

— Беттек, беттек! — диде Аппак, дер-дер калтыранып.

— Йә алар, йә без! — диде Тотыш.

Күз ачып йомган арада ул ияреннән калыкты, ике аягы белән дә өзәңгегә ныгытып басты да, сөңгесен Корыч-Тимергә ыргытты. Сөңге тимәде. Корыч-Тимер, җирне-күкне калтыратып:

— Уйнаш! — дип кычкырып җибәрде.— Тотыш — Аппак — уйнаш!

Атын борып ул урда ягына чапты. Башкалар да: «Уйнаш!» — дип кычкыра-кычкыра, атларын куалап, урда ягына ашыктылар. Йоклап яткан җир күкрәген дер селкетеп, дөп-дөп бәргән ат тояклары да, куркып таллыктан очып чыккан кошлар да — барысы да:

— Уйнаш! Уйнаш! — дип кычкырдылар.

Тотыш куа китте. Арттарак калган бер ирне ул ук белән яралады, икенчесенең атын аксатты. Корыч-Тимерне ук та, Тимеркүк тә куып җитә алмады.

## XVIII

Болгар кешеләрен Тотыш җунләп белмәсә дә, болгарлар аның үзен яхшы ук беләләр иде. Аның даны Өсән буйларына, Ага-базар якларына үзеннән элегрәк килеп җитте. Кеше арасына чыкмыйча, көннәрен, төннәрен ялгыз башы киез өйдә үткәргән Тотыш үзе турында сөйләнелгән сүзләрнең берсен дә ишетмәде. Ишеткән булса, ул, билгеле, күп кенә яңалыклар белгән булыр иде.

Беркемгә күренмичә, яшеренеп йөрибез дип уйласалар да, аларның икәүләшеп, төнге каравыл булып йөрүләре күпләргә билгеле иде. Алай гына да түгел, хан кызының яралы тотык янына барып йөрүен инде теге чакта ук, Чулман буеннан кайтып килгәндә үк сизеп алганнар иде. Аларның бер-берсен яратышулары Алмыш хан белән Айкын хатыннан башка беркем өчен дә сер түгел иде, ахрысы.

Тик шулай да бу турыда — Аппак белән Тотышның бергә очрашулары турында да, икәүләшеп болыннарда, урманнарда йөрүләре турында да ачыктан-ачык әйтергә, йә булмаса ханга җиткерергә беркемнең дә башына килмәде. Ник дигәндә, Болгар йоласы буенча, кояш баеганнан алып кояш чыкканчыга тикле чит ир белән чит хатын-кыз бергә очрашса, уйнаш санала иде. Уйнаш өчен ирне дә, хатынны да — кем булуларына да карамастан! — аяк-кулларын чабып, тураклап үтерәләр иде. Болгарда әле моңарчы хан кызы гүзәл Аппакның да, атаклы яшь алып Тотышның да үлемен теләүче юк иде.

Андый кеше менә табылды. Корыч-Тимер аларны үзенең әшнәләре белән ике көн күзәтеп йөрде. Инде менә каптылар үзләре дә! Баш тартып карасыннар! Таныклар җитәрлек. Уяныгыз, кешеләр, күрегез уйнашчыларны! Баш кисүче, кайра балтаңны! Уяныгыз, кешеләр, җыелыгыз киң языга — уйнаш! Уйнаш!

Урдага карап чапканда Корыч-Тимернең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ак өйләр арасына килеп кергәч тә, ул чынлап та кешеләрне кычкырып йокыларыннан уятмакчы булды. Шулай да эчке бер тавыш аны бу тилелектән тыеп калды. Башкаларның чабылган кул-аяклары турында уйлаганда, ул үз башын да онытып җибәрмәде. Кояш чыкмыйча торып тиктомалга урданы, димәк, ханны да йокысыннан уяткан өчен аңа бик каты эләгәчәк иде. Ханны, урданы исә теләсә кайчан бары яу килгәндә генә, йортка-илгә талау, кыран килгәндә генә уятырга ярый иде, анда да әле чит кеше түгел — өй-агасы йә булмаса ханның үз кешеләре, сакчылары гына уята ала иде.

Аннары, нинди генә үчлекле, мин-минлекле булмасын, Корыч-Тимер дә Аппакның — хан кызы, Тотышның — хан тотыгы икәнлеген исеннән чыгара алмады. Ул, упкын аша сикерергә укталып та, сикерә алмыйча, упкын кырыенда тукталып калган кеше сыман, шып туктады. Кире борылды. «Көн тусын»,— дип уйлады ул, көтәргә булып.

Аппак белән Тотыш та шулайрак уйладылар. Аларга да тизрәк көн тууы, кешеләрнең, бигрәк тә ханның уянуы кирәк иде.

Аппак Тотышка барысын да сөйләп, аңлатып бирде. Җегетнең йөзен кайгы-сагыш биләп алды. Менә ни өчен Аппак бары төнлә генә килгән икән аның янына! Менә ни өчен Торымтай аларны бөтенләй күрмәмешкә салынган икән! Көндез хан кызына тотык белән очрашырга түрә кушмый, төнлә очрашырга йола кушмый! Хан кызы, хан балалары тотык белән бернинди бәйләнешкә кермәскә тиешләр. Ах, менә нинди кеше икән ул тотык!

— Ник башта ук әйтмәдең?! — диде ул, ачынып.

— Мин курыктым,— диде Аппак.— Белсәң, мине яратмассың дип, ташларсың дип курыктым.

— Инде менә бергәләп үләргә туры килә,— диде җегет, үкенү сиздереп.— Безне йола үтерә. Иң зур дошманым Корыч-Тимер дә түгел — йола! Мин менә тагын шуны аңладым. Мин... без нинди дер күзгә күренмәгән арканнар белән уратып алынганбыз, бәйләп ташланганбыз. Үз иркебез белән без тел дә кыймылдата алмыйбыз. Тәңрем, син бирдеңме андый йолаларны кешеләргә, әллә алар үзләре уйлап тапканмы?! Миңа күрергә ярамый — алайса, ник миңа күз бирдең? Миңа сөйләшергә ярамый — алайса, ник миңа тел бирдең? Миңа йөрергә ярамый — алайса, ник миңа аяк-кул бирдең?! Миңа сөяргә ярамый — алайса, ник син минем канымны кайнар иттең?! Юк, минем әле үләсем килми! Минем әле яшисем килә, сөеклем белән бергә куанасым килә, Тәңрем! Коткар безне, коткар языклы балаларыңны!

— Тизрәк, тизрәк! — диде Аппак, Тотышны ашыктырып.— Мин әле ышанам. Ничек тә әтине алданрак күрергә кирәк.

Алар ашыктылар. Үлемгә ашыгалар идеме алар, ирекккәме — беркем дә белмәде.

**XIX**

Болгар җирендә таң атып кояш чыгу белән, төрле яктан урдага кешеләр килә башлады. Берәүләр якындагы авыллардан, көтүлекләрдән килделәр, икенче берәүләр ерак илләрдән, сату итеп кайтып, хан янына йомышларын йомышларга ашыктылар. Өченчеләре, киресенчә, чит илләрдән, чит җирләрдән килеп монда нинди дә булса эш кырырга уйладылар — шуның өчен йорт башына күренергә кирәк таптылар. Ханда йомышы-табышы булган кайберәүләр, аның янына эләгә алмыйча, урда читендә өй корып, ничә көн инде төн куналар иде.

Каравылчылар кешеләрне урдага берәм-берәм карап, тикшереп керттеләр. Хан ашап-эчеп, үзенең зур өендәге биек түренә чыгып утыргач, хан-агасы аңа кемнәр килүен, нинди йомышлар белән килүен җиткереп торды.

Аппакның Тотыш белән бергәләп керергә теләвен ишеткәч, Алмыш хан, аңлап җитмәгәндәй:

— Минем каршыгамы? — диде.

— Әйе, ханым,— диде хан-агасы.— Анда тагын Алып-Тархан углы Корыч-Тимер алып та килгән. Никтер кызган, бик ашыгыч, ди, мине алданрак керт, ди.

— Корыч-Тимер сүрелә төшсен. Әйт, керсен, кызым,— диде хан.

Аппак үзе генә кермәде. Кулга-кул тотынышып, куркып-өркеп, кыюсыз гына алар икәүләп керделәр. Керделәр дә, ары барырга батырлыклары җитмичә, ишек төбендәге йомшак паласка тезләнделәр.

— Синең үзеңне генә керә дигәннәрие, кызым,— диде хан, мондый күренешне бик үк ошатмыйча.

— Мин икебезне дә әйттем, эти,— диде Аппак.

— Торыгыз. Килегез бире,— диде хан.

Алар тордылар, алгарак уздылар, тагын тезләнделәр. Хан, өйдәге барлык кешеләргә чыгып китәргә кушып, кулын селтәде. Хан-агасы, битекчеләр, сакчылар тавыш-тынсыз гына юк булдылар.

— Әти! — диде Аппак, эчке бер омтылыш белән, ялвару белән.— Без сиңа зур йомыш белән кердек — тыңлыйсыңмы безне?

— Сөйлә, тыңлыйм, кызым,— диде хан.

— Әти,— диде Аппак, барлык батырлыгын җыеп.— Әти! Мин Тотышны яратам, Тотыш... мине... Без өйләнешергә булдык — ирек бир безгә!

Ул атасының кырыс йөзенә бер генә күтәрелеп карады да тынып калды. Тотышның беләгенә тотынган көе, тынын кысып, бар нәрсәсен онытып ул көтә башлады. Уттай янган дүрт күз, тораташка, абакка, потка текәлгәндәй, куркып, ялварып, түрдә утырган ханга текәлде.

Болгар кешеләре генә түгел, хан үзе дә күп нәрсәне белә иде. Яшерен шымчылар аңа барысын да җиткереп торалар иде. Аппакның Тотыш белән бергә булуына ул ничектер бармак аша карады, хан кызына нишләсә дә килешә диебрәк карады. Аннары, андый нәрсәләр белән булашырга бу арада аның вакыты да булмады. Башка кайгылар да баштан ашкан иде! Нәрсә, көймәсе комга терәлде микәнни? Тотыш белән Аппак... Тотыш... Дөньядагы бар нәрсәдән артык Аппак әнә кемне сайлаган! Йа Тәңрем, йа Алла... кирәгеннән артык яратмый микән ул үзенең Аппагын? Кирәгеннән артык ирек бирмәде микән ул аңа?

— Өйләнергә? — диде ул кабатлап, төшенеп җитмәгән сыман.

— Әйе, эти,— диде Аппак.

— Син, кызым, үзеңнең кем икәнлегеңне онытып җибәргәнсең, ахрысы,— диде хан, авыр, салмак сүзләрен теш арасыннан кысып чыгарып.

— Юк, эти,— диде Аппак, тынгысыз бер кабалану белән.— Син бу сүзләрне миңа түгел, Тотышка әйтәсең. Тотыш мине үлемнән коткарды! Мине саклап унлап казаякны үтерде. Ул минем өчен, синең өчен сугышты. Ышанмасаң, күргән ирләр әйтер.

— Мин ышанам,— диде хан, коры гына.— Мин барысын да беләм.

— Беләсеңмени?! — диде Тотыш.

Хан, эндәшмәскә кушып, аңа кул гына селтәде.

— Беләм,— диде хан, кабатлап.— Тик шулай да син үзеңне үлемнән коткарган теләсә кемгә кияүгә чыга алмыйсың, кызым.

— Тотыш теләсә кем түгел, эти,— диде Аппак, тыйнак кына, юаш кына.— Тотыш — би углы.

— Тотыш — Алмыш ханның тотыгы,— диде хан.

— Мин аны яратам, эти! — диде кыз, учактагы ялкындай кызарынып.— Синең миңа әйткән сүзең бар: яраткан кешеңә генә бирермен, дидең. Исеңдәме?

— Исемдә,— диде хан, теләмичә генә.— Мин синең Тотышны яратуыңа каршы түгел. Өйләнешүгә килгәндә...

— Ханым! Атам! — диде Тотыш, түзмичә.— Күктәге Тәңре белән, җирдәге-судагы изге ияләр белән ант итеп әйтәм: аяк астыңда тузан булырмын, кая куйсаң, шунда торырмын, кая җибәрсәң, шунда барырмын! Ягылларыңны себереп түгәрмен, Хазар каганын юк итәрмен! Барлык абаклар белән, атам-анам белән, изге Чулман белән, изге Итил белән ант итәм! Күк кылычым белән ант итәм... бир миңа Аппакны!

— Миңа синең антларың да, тузан булуың да кирәкми, Тотыш углан,— диде хан, салкын гына.— Син беләсең булыр: Аппак, минем кебек үк, абакларга да, ияләргә дә табынмый. Ул бары бер Аллага табына. Мосылман түрәсе буенча, ул бары мосылман йоласы тоткан кешегә генә чыга ала.

— Син каршы килмәсәң, мин яңадан ата-баба йоласына кайтырыем, эти,— диде Аппак.

— Менә монысы инде үлгәндә дә булмас! — диде хан, тавышын көчәйтеп.— Үткәнгә кире кайту юк. Итил кирегә акмаган кебек, сиңа да, миңа да, бөтен Болгар йортка да кирегә кайту юк.

— Аппак кемгә табынса, мин дә шуңа табынырмын, ханым! — диде Тотыш, күп уйлап тормыйча.

— Шулаймы? — диде хан, үчекләшкән сыман, көлемсерәгәндәй итеп.— Атаң-анаң, ыруың ни әйтер икән соң?

— Кирәк икән, атамнан-анамнан, ыруымнан баш тартырмын, ханым! — диде күзе-башы акайган җегет.

— Хы,— дип куйды Алмыш хан, авызын кыйшайтып.— Нинди кызу канлы син, Тотыш углан! Атасыз-анасыз, ырусыз кем булырсың икән соң син? Ничек яшәрсең дөньяда? Кол булып, йолкыш булып?

— Аппак белән бергә булсам, кол булсам да, йолкыш булсам да, миңа барыбер!

— Сиңа барыбер булса да, миңа барыбер түгел,— диде хан.— Мин кызымны тотыкка да, колга да, йолкышка да бирә алмыйм. Сау булыгыз, угланнар.

Ул, соңгы сүзләрен әйтеп, урыныннан тормакчы булды. Аппак белән Тотыш, үз колакларына үзләре ышанмыйча, каттылар да калдылар.

— Әти! — диде кинәт Аппак чыркылдап, ап-ак агарынып.

Аягүрә баскан ата кеше, күңеле йомшап, кире урынына утырды.

— Нәрсә тагын? — диде ул, икеләнгәндәй итеп.— Әйтәсе сүзең калдымыни, кызым?

— Әйтәсе сүзем шул гына, әти,— диде Аппак, җыламсырап.— Бар ышаныч синдә, әти! Безне бергә күрделәр. Корыч-Тимер... тозак... Кызган мине, әти!

Алмыш ханның кара сакал-мыек баскан киң йөзен кара болыт каплап алды. Усал очкыннар бөркегән усал күзләре калын кашлары астында күмелеп кала язды. Киң, авыр күкрәге, тимерче күрегедәй гыж-гыж килеп, бер төште, бер күтәрелде. Баскан килеш, авыр йодрыкларын йомарлап, ул языклы яшьләргә карап торды. Кызына кычкырудан үз-үзен көчкә тыеп, ул кире урынына утырды. Шул чакны кара болыт арасыннан якты кояш нурлары балкып чыкты. «Өйләнешсеннәр»,— дип уйлады ата кеше. Тотыш менә дигән кияү булачак — кыюлыгы да, усаллыгы да бар, алып дигән аты да бар. Җебегән, булдыксыз Тәкин угланнар, Барыс угланнар түгел. Акбүре белән туганлашу... менә шулай кода-кодагый булып, кыз биреп туганлашу теләсә нинди килешүләрдән, теләсә нинди яулардан көчлерәк булачак.

— Тыңлагыз, сүзем шул,— диде ул, авыр гына сүзгә башлап,— Тотыш үзе, атасы-анасы, ыруы гарәп диненә күчсә... тиешле калымын түләгәч... ике елдан соң өйләнешерсез. Ак юл сезгә, балалар.

## Бишенче баб

### I

Ике ел искән җилдәй үтте дә китте. Баштарак шундый авыр булып, иксез-чиксез кара төн булып тоелган ике ел артта калды. Шулай бик тиз үтсә дә, Тотыш өчен бу ике ел бөтен бер тормыш булды. Монда, Болгар җирендә ул моңарчы төшендә дә күрмәгән нәрсәләр күрде, башына да китереп карамаган нәрсәләр белде. Монда аның күп нәрсәгә күзе ачылды, күп нәрсәгә карашы үзгәрде. Монда ул беркайда да ирешмәгән данга-атакка иреште.

Булачак киявенең иң ышанычлы, болгар ирләреннән дә ышанычлырак икәнлеген күреп, Алмыш хан аңа зур эшләр тапшырды. Тотыклыгының беренче елында, көзгә таба ул — Тотыш углан — ике мең кешелек чирү белән көтмәгәндә суарларны барып басты; калаларын камап алды, коймаларын яндырып, җимереп, катауларын пыр туздырды. Күп ирләрне кырып, күп байлык талап, Килдеш бинең үзен кулга төшерде. Шулай итеп, болгарлар тулысынча суарлардан үч алдылар. Алмыш хан, Килдеш бинең башын чаптырып, аның урынына бинең энесен утыртмакчы булды. Суар бие, Алмыш ханның итеген ялап, күз яшьләрен түгеп, үзен исән калдыруны үтенде. Шуның өчен ул бөтен ыруы белән гарәп диненә күчәргә, Суар-торада мәчет, мәктәп салдырырга сүз бирде. Алмыш хан бине ярлыкарга кирәк тапты.

Шулай итеп, Тотыш угланның җиңүе Болгар ханы өчен икеләтә җиңүгә әйләнде. Шушы җиңү уңае белән Алмыш хан зур туй ясады. Туйда Тотыш углан беренче тапкыр илнең батыр ирләре белән бергә ханның сул ягында утырды. Бөтен агай-эне алдында хан аңа мактау сүзләре әйтте, бөтен агай-эне алдында ул аңа үз кулы белән ачы бал бирде. Шунда ук ул үзенең сүзләрен кабатлады: бөтен ыруы, ата-анасы белән яңа йолага күчкәч, диде, тотыклыгы төкәнгәч, тиешле калымын түләгәч, диде, кызым Аппакны мин Тотыш алыпка бирәм, диде.

Бу инде үзара сөйләнгән сүзләр генә түгел иде, бу инде ил агалары алдында хан авызыннан әйтелгән сүзләр иде.

Шушы көннән башлап Тотышка булган караш күзгә күренеп үзгәрде. Инде аның Аппак белән бергәләп, атка атланып, көпә-көндез дә, кояш баегач та кеше күзе алдында йөрүенә беркемнең дә исе китмәде. Бергәләп алар яшьләрнең төрле уеннарында, бәйгеләрдә, җыеннарда катнаштылар. Алар кая гына бармасын, аларга кешеләр сокланып, яратып карадылар. Болгар илендә әле беркемнең дә беркайчан да болай ачыктан-ачык яратышып йөргәне юк иде бугай, Болгар илендә әле беркайчан да кыз белән егетнең шундый тиң килгәне юк иде бугай! Тотыш белән Аппак, кая гына бармасыннар, кем янына гына бармасыннар, үзләре белән әйтерсең яктылык, җылылык, байлык алып килделәр. Яшьләр арасындагы иң усал сугыш чукмарлары да, Тотышны күреп, юашланып калдылар. Иң караңгы чырайлы кешеләр дә, Аппакны күреп, аның сылулыгына исләре китеп, елмаеп җибәрделәр.

Бары бер генә кеше аларның яратышуын да, аларның батырлыгын да, матурлыгын да танырга теләмәде. Ул да булса Корыч-Тимер иде. Теге чакта ул, күпме генә тырышса да, Аппак белән Тотышка

«уйнашчы» дигән яманат тага алмады. «Мосылман динендәге Аппак өчен, димәк, Тотыш өчен дә ата-баба йоласының көче юк»,— диде аңа Алмыш хан.

Тотыш алыпның суарларны җиңеп кайтуы Корыч-Тимерне чын-чынлап тилертә язды. Оятыннан, көнчелегеннән ул инде болай да кеше арасында күренми башлаган иде. Көннәрдән бер көнне ул бөтенләй юкка чыкты. Соңыннан беленде: үзенең унлап сердәше белән ул караңгы бер төндә Урыска качкан. Анда ул урысларны Болгарга каршы яу белән барырга котыртып караган. Болгар икмәген ашап, ач үлемнән котылып калган урыслар аның коткысына бирелмәгәннәр. Сатлык Корыч-Тимер Урыстан да каядыр качып киткән. Бу турыда аннан аерылып Болгарга кайткан бер юлдашы сөйләде. Бераздан аның икенче бер юлдашы да туган якларына кайтып төште. Анысы тагын да көтелмәгәнрәк яңалыклар әйтте: Корыч-Тимер белән без мукшы авылларын талап, юлбасарлыкта йөрдек, диде. Корыч-Тимерне дә, башкаларны да мукшылар үтерде, мин генә исән калдым, диде. Аның әйткәннәре чын булды, ахрысы,— менә икенче ел инде Корыч-Тимер турында берни ишетелми. Атасы Алып-Тарханны кайгыдан кара чиргә сабышкан дип сөйләделәр.

Аның урынына, Тотышның эшләре майланган арба кебек тәгәрәп кенә барды. Суарларны җиңеп кайтканнан соң күп тә үтмәде, Алмыш хан аны башкыртларга каршы җибәрде. Тотыш башкыртлардан ике ел түләнмәгән каланны көч белән алып кайткач, йорт башы аны Болгардан аерылган мукшыларга каршы җибәрде. Мукшы ягыннан кайтып Тотыш алып тиешенчә баш-күз алырга да өлгермәде, Алмыш хан аңа тагын эш тапты. Ул көннәрдә Итилнең югары агымында юлбасарлар күренә башлаган иде. Алар болгар сатучыларына әледән-әле куркыныч тудыралар — товар төягән каекларны басып алалар, сатучыларның үзләрен үтерәләр, йә булмаса, каядыр коллыкка алып китәләр иде. Тотыш алып әлеге шул юлбасарларны да барып басты. Ояларын туздырып, күбесен кулга алды.

Шулай итеп, кайсы гына якка яу чапмасын, яшь алыпка язмыш алдан юл күрсәтеп, җиңү байрагы тотып барды. Киләчәк якты көннәрне якынайту өчен ул, Алмыш ханны, Болгар йортны яклап, үз-үзен аямыйча сугышты. Аның үткер кылычыннан туктаусыз кан акты. Кан белән бергә шулай ук алтын-көмеш тә акты. Тик ул алтын-көмеш аның үз кесәсенә түгел, хан чокырына коелды — йорт башы аңа бик аз телем чыгарды. Тотыш үзенең Аппагыннан да, үзенең сөеклесеннән дә зуррак байлыкка ия булу турында уйлап та карамады. Нинди генә җиңүгә ирешмәсен, күпме генә атаклы булмасын, беркайчан да ул үзенең тотык икәнлеген оныта алмады — хан үзе дә, аның якыннары да әледән-әле аңа шул турыда искәртеп тордылар.

Аннан соң ул икенче бер нәрсәне дә сизенеп алды: Алмыш хан сугышка аны тикмәгә генә җибәрми иде бугай. Ул ничек тә аның монда урдада, Болгар-торада азрак булуын тели иде бугай. Кем белә, әллә ул аны яудан кире кайтмас дип тә уйлагандыр! Әйе, әйе, соңгы көннәрдә, тотыклыкның ике елы тулар алдыннан Алмыш хан кинәт кенә үзгәрә башлады кебек, никтер пошына, борчыла башлады кебек.

Ни булса булды, ике ел узып китте. Алмыш хан аны бүген үз янына чакырып алды.

— Син ирекле, Тотыш углан... Тотыш алып,— диде ул.— Синең өчен Акбүредән икенче углан килеп җиткәнне көтеп тормастан, мин сиңа ирек бирергә булдым. Сиңа алмаш юлда булырга тиеш. Илеңә кайт, мин әйткәннәрне үтә, калым китер. Шунда киявем булырсың... Алла боерса!

## II

Тотыш юлга җыена башлады. Багдад ягыннан килеп, Болгарда төпләнеп калган Габид атлы тегүчегә ул моннан өч ай чамасы элек туй өчен үзенә кара төлкедән кышкы тун, кызыл атластан җәйге тун тектерергә биргән иде. Тотыш, хан өеннән чыккач та, туры тегүче янына юнәлде. Тегүче урдадан читтә, ханбалыкның яр буе бистәсендә тора иде. Аның өе агачтан иде, ишегалды зур, иркен иде. Ишегалдында корулы киез өйләр, араннар, абзарлар тезелеп киткән иде. Шунда ук атлар, кешеләр күренә иде. Тегүче Габид, Болгарның аксөякләренә яхшы тун, кием-салым тегү белән бергә, читтән бигрәк тә гарәп ягыннан килгән сатучыларга кунар өчен урын да биреп тора иде. Менә әле дә ул читтән килгән кунаклар белән мәш килеп ята иде.

— Өлгермәдем, Тотыш алып,— диде ул, кулларын җәеп.— Көтмәгәндә олы кунаклар килеп төште — шулар белән булаштым. Багдадтан! Хәлифә иленнән!

— Кем? — диде Тотыш.

— Фатих ибн Әхмәт! — диде Габид, авызын очлайтып.

Моның белән ул Фатих ибн Әхмәтнең бик зур кеше икәнлеген аңлатмакчы булды. Тотыш ул гарәп сатучысын ишетеп тә, күреп тә белә иде. Әйтүләренә караганда, ул монда ел да килә икән.

— Борчылма, Тотыш алып, иртәгә кичкә җитешер,— диде Габид, тынычландырып.

— Кара аны, иртәгә кичкә! — диде Тотыш.— Мин — иректә! Мин туган илемә кайтып китәм.

— Әйттем, әйттем! — диде Габид, Тотышны ишеккә тикле озатып.

Көн шундый җылы, якты иде. Тирә-як шундый ямьле иде — Тотыш тегелеп бетмәгән туннарын тышка чыккач ук онытты. Тегүчедән соң ул үз өенә кайтты. Торымтайны да алып, бераздан алар Аппак белән Ага-базарга киттеләр: атасы-анасы, туганнары өчен бүләкләр алырга кирәк иде.

Юл буена алар шаярып, юк-бар нәрсә сөйләнеп бардылар. Берәр кеше узып киткәч, йә аның киеменнән, йә атыннан берәр көлке нәрсә таптылар, ул да булмаса, юл читендәге берәр түмгәктән, агачтан, ялгыш әйтелгән берәр сүздән кызык табып, тыела алмыйча көлешеп бардылар. Тотышныкы кебек, Аппакның да күңеле күтәренке иде. Тик бу күңел күтәренкелегендә шулай да эчке сагыш, әйтелмәгән бер моң сизелә иде. Берничә айдан бергә кавышу турында уйлап сөенүгә караганда, ул озакламый аерылышырга тиешлекләре турында уйлап көяләнә иде, ахрысы. Көлешә-көлешә бара торгач, ул кинәт кенә сорап куйды:

— Син тиз килеп җитәрсең микән? — диде.

— Ким дигәндә, ике айдан,— диде Тотыш.

— Ике ай... Бик күп ич ул! Тизрәк булмыймы, Тотыш?

— Ике ай ике ел түгел. Ике елга түзгәнне ике айга гына түзәрбез инде, Аппагым,— диде Тотыш.

— Минем эчем поша, җылыйсым килә,— диде Аппак, читкә борылып, күз яшен күрсәтмәскә тырышып.— Күңелемне бер уй тырный, Тотыш: үз илеңә кайттың исә, атаң-анаң каршы килер дә, сине җибәрмәсләр кебек. Син килмәсәң, нишләрмен мин?

Тотыш аның бу сүзләреннән кычкырып көләргә тотынды. Тик аның көлүе бик ясалма килеп чыкты. Моны ул үзе дә сизде. Аппак аның үзенең дә күңелен борчыган, әйтергә кыюлыгы гына җитмәгән нәрсәне тел белән әйтеп бирде! Аның, билгеле, кызны юатасы, тынычландырасы килде. Тик аны юатып кына ул барыбер үз-үзен юата алмады. Ул, бернәрсәгә дә исе китми, аптырап калмый торган кеше кебек, җиңел генә:

— Уйлама юк-барны! — диде.— Алмыш хан белән туганлашырга кем каршы килсен?! Сөенә-сөенә килешәчәкләр.

— Әйе шул,— диде Аппак, күз яшьләре аралаш елмаеп.

Базарның иң кызган чагы иде. Итил ярыннан читкәрәк, калку җиргә урнашкан, тирә-ягын киез өйләр, киндер чатырлар, агач кибетләр сарып алган киң язы атлар, кешеләр белән шыгрым тулы иде. Сатучыларның күбесе үз товарларын туп-туры җиргә өеп ташлаганнар. Кайберләренең товарлары, киресенчә, биеккә — казык башларына, аркылы киштәләргә эленгән. Барысы да кычкыралар, шаулыйлар — үз товарларын мактыйлар, алучыларны яннарына чакыралар. Тирә-якта колак тондыргыч бер шау-шу, гүелдек яңгырап тора иде.

Базарның иң шау-шулы төшенә якын бер җирдә бөтенләй диярлек шәрә калган бер кеше зур көрән аю белән көрәшкән булып кылана. Аны бала-чага, яшь-җилкенчәк урап алган. Көләләр, кычкыралар, аюга көлчә, пешкән ит кисәкләре ыргыталар. Аю белән көрәшүчедән арырак, икенче бер җирдә тагын да кызыграк; тыгыз түгәрәк уртасында, сары ефәк чатыр янында яшь, шәрә бер кытай очлы пычаклар, утлы таяклар чөеп уйный.

Тотыш үзенең юлдашлары белән аю көрәшенә дә, кытай кәмитчесенә дә бераз гына карап торды да, ары китеп барды. Авыз ачып карап торсаң, Ага-базарда кызык нәрсәләр җитәрлек иде. Базарга, күрәсең, әле күптән түгел генә килеп туктаган дөяләр төркемен узып, алар яр буена ук килеп чыктылар. Язгы ташудан соң үз ярларына кайта башлаган, болганчык, салкынча Итил өсте төрле илләрдән килгән төрле зурлыктагы, төрле төстәге, төрлечә бизәлгән йөзләрчә каеклар, кәмәләр, улаклар белән чуарланган иде. Монда, яр буенда, кибетләр дә, товарлар да күбрәк, төрлерәк иде. Монда төрле төстәге кешеләр күренә, төрле телләрдә сөйләшкән, кычкырган тавышлар ишетелә иде. Кибетләр янына таудай итеп капчыклар өеп куелган, төрле зурлыктагы кисмәкләр, чапчаклар, чүлмәкләр тезелеп киткән иде. Берәүләр каеклардан ярга товар бушата, икенче берәүләр товар төйи иде. Әле анда, әле монда — башларын түбән иеп, куркытылган көтү сыман, бергә өелешеп, төркем-төркем коллар тора иде.

Аяк астындагы эреле-ваклы чүлмәкләргә, савыт-сабаларга орынмаска тырышып, тар аралыктан җайдаклар тагын да алгарак уздылар да таныш сыман тоелган зур гына бер ак чатыр алдында туктап калдылар. Якында гына кыздырылган балык, суган исе килә иде — бер-ике кеше, җиңнәрен сызганып җибәреп, аяк астына ук көйләнгән кызу учак өстендә, җиз табада балык кыздыралар иде. Тотыш балык кыздыручыларның йөзләренә карангалап торган арада, якында гына кемдер:

— Тотыш! — дип кычкырып җибәрде.— Исәнме! Әссәламегаләйкем!

Тотыш, эндәшүченең Фатих ибн Әхмәт икәнлеген аңлап, елмаеп, тавыш килгән якка борылып карады. Чыннан да, аның каршысында баягынак тегүче Габид әйткән гарәп базарганы басып тора иде. Ул кырык-кырык биш яшьләрдәге алыптай озын буйлы, киң җилкәле, таза бер кеше иде. Өстенә ул яшел ефәктән тегелгән озын итәкле юка җәйге чапан, башына кара бүрек сыман нәрсә кигән иде. Аның болай да кара янып чыккан, җил кискән кытыршы бите базардагы ак битле кешеләр арасында тагын да карарак булып, ерактан ук аерылып күренә иде. Аның кара сакал-мыек арасыннан елтырап-елтырап киткән тигез тешләре, киресенчә, ап-ак иде. Болгарның атаклы алыбын, үзенең әзме-күпме танышын күрүгә чиксез куаныч белдереп, ул елмаеп җибәрде, ике кулын да күкрәк турысынарак күтәрде дә, баш иеп, аны олылавын белдерде. Тотыш, атыннан төшеп, шулай ук аның алдында баш иде.

— Син әлерәк кенә тегүче Габидтан ирдең түгелме соң? — диде Тотыш, гарәп базарганы белән исәнләшкәч.

— Анда минем кешеләрем булыр. Минем моннан кузгалып киткәнем юк,— диде Фатих ибн Әхмәт, бер күзе белән Тотышка, икенче күзе белән Аппакка караштырып.— Бәрәкаллаһ! Монысы хан кызы Аппак түгелме соң?! — диде ул, күрәләтә соклану белән. Аннары, Торымтайны да күрми калдырасы килмичә, сүрән генә әйтеп куйды: — Монысы... теге... кем соң әле?

— Торымтай! — диде кол, аңа исенә төшерергә булышып.

— Ие, ие, Торымтай торур! — диде гарәп.— Әйдәгез, бире узың, түрдән узың! Ни телисез, миндә шул бар. Бөтен Ага-базарда Фатихтан бай сатучы булмас!

**III**

Гарәп сатучысы күз алдында үзгәрә барды. Ул, үзенең танышларын очратуына чиксез сөенгән сыман, кинәт кенә кабаланырга тотынды. Аннары бер дә юктан диярлек Болгарны, бу якның урман-суларын, кешеләрен, байлыкларын мактарга тотынды, «Багдадта да мин сезне сагындым»,— дигән булды. Яшьләр, мондый мактау сүзләренең бик үк чын күңелдән әйтелмәгәнлеген сизсәләр дә, шулай да бу аларның күңелен күтәрде. Хәйләкәр сатучы, болгар кешеләренең йомшаруларын күреп, тагын да арттырыбрак җибәрде. Шунда ук ул, күрәләтә соклану белән, комсызлык белән хан кызына карап-карап алды. Ахырда түзмәде, күңелендәгесен чыгарды салды.

— Сөбханалла! — диде, зур авызындагы ак тешләрен елтыратып.— Синең сылулыкны күреп мин телсез калдым, хур кызы! Унөч яшемнән башлап мин төрле илләр, җирләр гиздем, төрле кавемнәрне күрдем, ләкин синдәй гүзәлне очратканым булмады! Мин сине танымыйча торам! Быел син тулып пешкән җимеш кеби! Килешсез сүзләрем өчен мин белексезне гафу әйләңез. Сиңа, Аппак углан, бер соравым бар: син хак мосылман динендәсең. Шулай булгач, ничек итеп син шундый гүзәл йөзеңне теләсә кемгә, теләсә нинди ир кешегә күрсәтеп йөрүдән курыкмыйсың?

Аппак үзенә карата әйтелгән мактау сүзләрен оялчан гына тыңлап торды да гарәпнең соңгы сүзләреннән көлеп җибәрде. Чынында ул аның соравыннан да көлмәде, ул үзенең чибәр булуын аңлап, куанып көлде, барлык кешеләрнең үзенә карап соклануларын тоюдан, янында үзенең сөеклесе булуын аңлаудан куанып көлде. Әле кайчан гына күңелен борчыган ямьсез уйлар онытылды. Аңа ияреп Тотыш та, Торымтай да көләргә тотынды.

— Гарәпләрнең бар кайгысы шул — хатын-кызның йөзен күрсәтмәү,— диде Аппак, җиңелчә шелтә белән.— Тәңре яраткан матурлыкны кешеләргә дә күрсәтмәгәч, үзеңә үзең генә карап торыргамыни соң?

— Матурлык — байлык! Байлык ул саклап тотканны ярата,— диде Фатих ибн Әхмәт.— Ярар, сезнең байлыкны күрдек, инде минем байлыкны күрәек.

Шулай дип, ул үзенең чатыр ишеген күтәреп куйды. Яшьләр бөтен җире төргәк-төргәк, капчык-капчык товарлар белән тулган, төрле ят исләр аңкытып торган зур гына чатырга килеп керделәр. Фатих ибн Әхмәт иелеп җирдән бер тимерле сандыгын ачты да аннан бик сакланып кына нидер алды. Алган нәрсәсен учында гына тотып, ул аны Аппакка сузды.

— Менә... карале моны,— диде ул.

Бу сырлап, кырлап, чын ташлардан ясалган авыр гына муенса иде. Аппакның йөзе балкып китте. Үзе дә сизмәстән, ул җиңелчә генә: «Ах!» — дип кычкырып җибәрде, муенсаны иплән кенә кулына алды, күз алдына китерде дә муены турысына куеп карады.

— Матурмы? Килешәме? — диде ул, Тотышка борылып.

— Искиткеч! — диде гарәп, Тотыштан узып.— Мондый муенса Багдадта юк, Румда юк! Фатихта бар! Алың. Сиңа бүләк.

— Бүләк?! Ни өчен? — диде Аппак, аптырап.

— Синең гүзәллекне күргән өчен... Минем күзләремә куаныч биргән өчен! — диде гарәп сатучысы.

Аппак кызарынып, шаулатып көлеп җибәрде, муенсасын югары тоткан килеш, Тотышка ныграк борылып, кабатлап:

— Килешәме? Матурмы? — диде.

— Матур,— диде Тотыш, бик үк теләмичә. Аннары ул, куеныннан янчыгын чыгарып, сатучыга эндәште: — Күпме тора? Мин түлим,— диде.

— Бүләк өчен мин акча алмыйм,— диде сатучы.— Акчаны мин тавар өчен генә алам. Менә монда барысы да — тавар. Теләсәгез, алыңыз, тартынмаңыз.

— Ярар, без синең бүләкне алабыз,— диде Тотыш.— Ниең бар — күрсәт барысын да! Тик, кара аны, күргән бер матур нәрсә өчен мин сиңа бүләк бирмәячәкмен.

— Миңа акча да ярый,— диде сатучы, көлеп.— Әйдә, сайла! Барысы да бар: кием-салым, атлас, ефәк, палас, йөзем, өрек, хөрмә... Көзгеләр, беләзекләр, йөзекләр, ислемайлар... ут-үлән сулары, им сулары, ачыташлар... Йөзем сулары, каптырмалар, төймәләр... барысы да, барысы да! Итилдә бушатылмаган биш каек тора, менә монда чатыр тулы, тышта әнә таудай өелеп ята.

Сатучы, бик җитез кыланып, капчыкларын, төенчекләрен чиште, товарларын берәм-берәм күрсәтә башлады. Тотыш атасына-анасына, үги аналарына, өлкән туганнарына яхшы, ят туннар, киемсалымнар, төзәнү-бизәнү әйберләре сайларга тотынды. Атасының авыру икәнлеген исендә тотып, аңа күп кенә им-том үләннәре, им ташлары алды. Товар өчен ул кызганмыйча, сатулашмыйча түләде. Аның бу юмартлыгы гарәп сатучысына Аппакның гүзәллегеннән дә ныграк ошады.

Тотыш, кызып китеп, шактый күп бүләк алды. Барысын бергә җыйгач, аларны берьюлы алып китеп булмаганлыгы билгеле булды.

— Кайгырмаңыз! — диде шома сатучы, Тотышны тынычландырып.— Болай итәрбез: минем кешеләр өеңә илтеп куярлар. Курыкма, бер нәрсәң дә югалмас.

— Ярар, шулай итәрбез,— диде Тотыш, килешеп.

Инде сату-алу эшләре төкәнде дигәч, Фатих ибн Әхмәт яңадан тимерле сандыгын ачып җибәрде. Аннан ул энҗе кашлы алтын йөзек алды.

— Менә, онытканмын күрсәтергә,— диде ак тешләрен балкытып.— Бер генә, сиңа гына калган, Тотыш углан. Синд[1] ягыннан. Иң булдыклы алтынчылар эше. Төп-төгәл... йөз дирһәм[2]!

— У-у! — диде Тотыш, беренче тапкыр.

— Анаң Койтым бикәгә моннан да матур бүләкне табалмассың! — диде сатучы.

«Минем анамны да белә!» — дип уйлады Тотыш, исе китеп. Гарәп сатучысы авызыннан үз анасы турында ишетү аның иң нечкә күңел кылларын тибрәндереп җибәрде.

— Син... Фатих, каян беләсең минем анамны? — диде ул, тыела алмыйча.

— Беләм инде,— диде гарәп.— Аласыңмы?

— Ник башта ук күрсәтмәдең? — диде Тотыш, күрәләтә үкенү белән.— Кесә бушады.

— Тотыш, беләсеңме, мин түлим! Әниеңә миннән бүләк булыр,— диде шул чакны Аппак.

Алып егетнең йөзе яктырып китте.

— Әйе шул! — диде ул, беркатлы бер елмаю белән.— Синең бүләгеңә анам шундый сөенәчәк! Шуның өчен ул сиңа иң якын, иң сөекле нәрсәсен бүләк итәчәк.

— Тотыш! — диде кыз, чак-чак кына үпкәләп.— Мин аннан бернинди бүләк көтмим.

— Ул сиңа... мине бүләк итәчәк! — диде Тотыш, кызның колагына пышылдап.

## IV

Тотыш, бүләкләр алып, туган ягына кайтып китәргә җыенып йөргән арада, Ага-базарга унике каек белән акбүреләр килеп төште. Күзәмеш углан Алмыш ханга узган ике ел өчен калан алып килгән иде. Шуның белән бергә ул Тотыш урынына монда тотык булып калачак иде.

Үзенең туганын, ырудашларын күреп, Тотыш сөенеченнән җылап җибәрде. Бераз тынычлангандай иткәч, ул өйдә калган атасы-анасы турында, туганнары, ырудашлары турында сораштыра башлады. Әллә бик арып килгәнгә, әллә ике ел аерылышып торган арада Тотыштан суынып өлгергәнгә, Күзәмеш углан әллә ни ачылып китмәде. Авыз эченнән генә мыгырданып: «Исәннәр»,— дип куйды да, Тотышның үзеннән сораштырырга тотынды. Бераз иялән төшкәч, шулай да әйтеп куйды:

— Анаң сине бик сагынды. Тизрәк кайтырга кушты,— диде.

«Атам сагындымы соң?» — дип сорыйсы килде Тотышның. Нишләптер сорамады, Күзәмешнең Кызыл Ярдагыча монда да үзен эре, салкын тотуы өчен пошынды. Туганы Күзәмеш углан гына түгел, башка ырудашлары да аның белән никтер теләмичә генә сөйләшәләр кебек тоелды. Ике ел буена болгарлар арасында яшәгән Тотышка акбүреләрнең кырыслыгы, караңгы чырайлы булулары бөтенләй чит, ят күренде. Аннары аларның бу салкынлыгын ул элеккечә үзен санга сукмау дип юрады. «Аз гына да үзгәрмәгәннәр!» — дип уйлады ул, ырудашлары турында ачынып.

Шулай да аның күңеле чамадан тыш күтәренке иде — язгы көндә кинәт исеп киткән бозлы җил сыман, көтмәгәндә йөзенә бәрелгән бу кырыслыкка аның әллә ни исе китмәде. Ул инде алардан — үзенең көнчел туганнарыннан да, караңгы йөзле ырудашларыннан да өстен иде.

Каланга дип китерелгән байлыкны ханның агычыларына тапшыргач, Акбүре каекларына Тотыш үзенең бүләкләрен, кием-салымнарын, юллык азык-төлеген төятте. Юлга җыену эшләрен бетереп, ул үзенең таныш-белешләре белән саубуллашты да Аппак янына килде. Шунда аны Алмыш ханның йомышчысы эзләп тапты.

Башка көннәрдәгегә караганда хан өендә бүген аңа кеше күп күренде. Аннан да бигрәк, хан янында ниндидер ят, чит кунаклар бар иде бугай. Алмыш ханны күреп, Тотыш шаккатты. Хан, авыру кеше сыман, тартылып, агарынып калган иде. Башка чакта үзәккә үтеп керә торган көчле, усал күз карашы ничектер юашланып, моңсуланып калган иде. Ханның бик нык кайгылы икәнлеге әллә каян күренеп тора иде.

— Син китәсең икән, Тотыш алып,— диде ул, күтәрелеп карамыйча, әкрен генә.

— Әйе, җыенып беттем,— диде Тотыш.— Иртәгә таңнан юлга чыгам.

— Ак юл сиңа, углан. Анаңа, ыы... атаңа, туганнарыңа минем изге теләкләремне тапшыр.

— Тапшырырмын, ханым,— диде Тотыш.

— Син минем ышанычны акларсың дип уйлыйм,— диде хан.

— Аклармын, ханым,— диде Тотыш, ничектер кычкырыбрак.— Мин күп тормам, кош кебек очып кайтырмын, кош кебек очып килермен!

— Сау бул,— диде хан.

Тотышка чит-ят булып тоелган зур кунакларның берсе Башту улы Габдулла иде. Шушы көннәрдә генә ул түбәннән, Хазар йортның ханбалыгы Итил-торадан килеп төшкән иде. Бу укымышлы мулланы Алмыш хан яхшы белә иде. Көтмәгәндә ул Болгарга күңелсез яңалык алып килде. Башту улы Габдулла, пошынып, ачынып, каганның мосылманнарны эзәрлекләве, җөфүтләрнең узынуы турында сөйләде. Аның сөйләвенә караганда, Итил-торада җөфүтләр белән мосылманнар арасында еш кына бәрелешләр, үтерешләр була икән. Шундый бәрелешләрнең берсендә Габдулла үзе дә катнашкан булган. Алар, кызып китеп, җөфүтләрнең кәнәсәләрен1 яндырганнар. Каган бу эштә языклы кешеләрне тотып, кулларын, аякларын чабарга боерык биргән. Габдулла, үзен тотып алганчы Итил-торадан качып киткән дә, сыену урыны эзләп, менә монда Болгарга килгән.

Каганның мосылманнарны эзәрлекләвен дә, җөфүтләр белән алар арасында ызгышлар баргалавын да Алмыш хан белә иде. Башту улы Габдулланың монда сыену урыны эзләп килүендә дә әллә ни яңалык юк иде. Ни өчен дигәндә, җөфүтләрдән җык күргән мосылман хазарлар, туганнарыбыз, кан-кардәшләребез дип, әледән-әле Болгар җиренә күчә торалар иде. Итил, Чирмешән буйларында качак хазарлардан гына торган зур-зур авыллар барлыкка килгән иде. Болгар-торада, Ага-базарда хазарлар шактый күп иде.

Әйе, болары аның бер дә яңалык түгел иде. Башту улы Габдулланың икенче бер яңалыгы исә чыннан да яңалык иде! Габдулланың әйтүенә караганда, Корыч-Тимер хазарларга барып чыккан. Үзен аларга яхшы яктан күрсәтү өчен ул шундук җөфүт йоласына күчкән. Корыч-Тимер Итил-торага килеп җиткәндә, Тәкин углан әле Хазаранда булган. Шунда кышлап ул быел яз Багдадка юл тотарга уйлады. Корыч-Тимер боларны күргән дә, каган кешеләренә җиткергән: Тәкин углан сатучы түгел, Алмыш ханның хәлифәгә җибәрелгән яшерен илчесе, дигән. Каган кешеләре Тәкин угланны, Барыс угланны, аларның кешеләрен тотып алганнар, базга ябып сорау алганнар. Шулай да шикле берни тапмаганнар, күрәсең, хәлифәгә җибәрелгән битекне Тәкин углан юк итәргә өлгергәндер. Өч айга якын ябып яткырганнан соң, бәйләнерлек берни тапмагач, хазарлар боларны чыгарып җибәргәннәр.

Ныклап торып бәйләнәселәре килсә, бәйләнер нәрсә тапкан булырлар иде, билгеле. Тик шулай да каган кешеләре эшне зурга җибәрмәгәннәр: ул арада, болгарларның ябылуда ятуын белеп, Итил-торадагы барлык мосылманнар — болгарлар, хазарлар, тәҗикләр, гарәпләр, безнең дин кардәшләребезне җөфүтләр бер дә юкка ябып яткыралар, дип шаулаша башлаганнар. Әле анда, әле монда җөфүтләр белән үзара бәрелешләр башланган. Ябылган болгарларны каган бары шуннан соң гына иреккә чыгарырга боерган.

Болгарлар иреккә чыгуын чыкканнар, тик үзләре югында аларның барлык мал-мөлкәтен кемнәрдер талап, урлап бетергәннәр. Яшерен илчеләр белән киткән кешеләрнең кайсы тоткында ачтан үлгән, кайсы чыккач таралып беткән. Тәкин углан белән Барыс угланны Хазар мосылманнары, бераз акча җыеп биреп, угызларга качырганнар. Алар ничек тә Багдадка барып җитәргә сүз биргәннәр. Исәннәрме, юкмы, барып җиткәннәрме, юкмы — беркем белми икән.

Менә шуңа да күңелсез иде хан Тотыш белән саубуллашканда.

Үз кайгысы, яисә үз куанычы көчле булганга, ханның ни өчен шулай күңелсез, кайгылы булуы турында Тотыш углан баш ватып тормады. Бу кайгының кайсыдыр ягы белән үзенә дә кагылганлыгын, үзенең киләчәк язмышына йогынты ясаячагын ул, билгеле, башына да китереп карый алмады.

Ул ярдан кузгалып киткән иртә искиткеч матур, аяз булды. Үзе белән ул Торымтайны да, Бәкәч чәчәнне дә алды. Алар киң Итил өстеннән, иксез-чиксез су киңлеге артыннан сызылып кына, елмаеп кына чыгып килгән кояшка карап кузгалып киттеләр. Артта, яр буенда, йокысыннан ныклап уянмаган Ага-базар — каралҗым, моңсу каралтылар, коймалар, өйләр торып калды, яр буенда бер төркем атлы кызлар: Аппак белән сердәшләре озатып калды. Тотыш, артына борылып утырган килеш, бик озак аларга карап, кул болгап барды. Кызлар шулай ук аңа кул болгадылар, баш киемнәрен болгадылар.

Борылыш артында кызлар да, Ага-базар да күренмәс булгач кына, Тотыш алдына карап утырды да, янындагы ишкәкченең ишкәкләрен алып, каерып-каерып ишәргә тотынды. Тыгыз, тирән суны тою анда әйтеп бетермәслек куаныч тудырды. Янындагы кешеләрне онытып, бирелеп, ул иште дә иште. Күзләре аның еракка, алсу кояш ягына текәлде, күңеле аның яр өстендә торып калган җайдак кызларга омтылды. Ул арыганчы, арттагы моңсу карачкылар онытылганчы иште. Шуннан соң чатыр эченә керде дә, йомшак киезгә сузылып, татлы йокыга талды.

Байракларын күтәрмичә генә йөзгән унике каек, кыр казлары сыман бер-бер артлы тезелеп, су өстеннән әкрен генә югарыга үрләделәр.

Ага-базар тамагыннан кузгалып китүгә уналты көн тулды дигәндә, бер матур иртәдә каеклар Акбүре яруы биләмәләренең көньяк чигенә килеп җиттеләр. Үз туган җирләренә исән-сау кайтып җитүләренә чиксез куанган кешеләр шаулашып ярга чыктылар, җирнең үзләренекеме, түгелме икәнлеген тикшереп карагандай, сабый балаларча сикергәләп алдылар, йомшак үләндә аунадылар. Шуннан соң пычак очлары белән кечкенә чокыр казып, чокырга ашамлык калдыклары, сөякләр, төймә, каптырма кебек нәрсәләр күмеп куйдылар. Үз улларын көтеп торган туган җиргә бу аларның бүләкләре-күчтәнәчләре булды:

— Менә бу безнең як, безнең җир! — диде Тотыш Торымтай белән Бәкәчкә, Чулман аръягындагы болыннарга, ерактагы күксел калкулыкларга күрсәтеп.

— Сездә матуррак,— диде Торымтай. Бәкәч, думбырасын чиертеп, шулай ук үзенең соклануын белдерде.

Ишкәкчеләрнең бер-икесе, коры-сары җыеп, учак ягып җибәрделәр, таган ясап, казан астылар. Каекларда әлерәк кенә тоткан балыклар бар иде — берничә кеше балык әрчергә тотынды. Тотыш, өч-дүрт юлдашын алып, якындагы урманга ауга китте. Анда, урман эчендә, Тоба-күл дип аталган сазлыкта кыр үрдәкләре күп була торган иде. Чыннан да, алар монда тиз арада унлап үрдәк атып алдылар. Иртәнге аш өчен шул да җиткән иде — алар артык мавыкмадылар, кире борылдылар да, учак янына килеп, үрдәк йолкырга тотындылар.

Шулай учак тирәсендә мәш килеп. Аш-су белән булашып ятканда, каяндыр бер атлы кеше килеп чыкты. Ул бик озын буйлы иде. Күрәсең, шуңадыр, ул атланган ат чамадан тыш кечкенә булып күренә иде.

— Әй, Баганай түгелме соң? — диде Тотыш, озын кешене танып.

Баганай урман артындагы унбиш өйлек Тоба-күл авылының агасы иде. Тоба-күл кешеләре Акбүредә иң яхшы аучылар, балыкчылар саналалар иде.

— Би углы Тотыш ич! — диде Баганай.

— Мин бу, мин! — диде Тотыш, ырудашына таба атлап.

Баганай, тәбәнәк киртәдән атлап чыккан сыман, озын аягын җиңел генә күтәреп аттан төште дә бүреген салды, башын иде, аннары аталарча яратып, читтә йөреп кайткан җегетне күкрәгенә кысты. Ул аның бала чакларын, балыкчылар белән бергә балык тотарга йөрүләрен яхшы белә иде. Әнә ул нинди үскән, тазарган! Яшьләр үсә, картлар картая...

Баганай, үзалдына сөйләнгәләп, никтер балавыз сыгып алды. Тотыш аның бер дә юктан шулай йомшап китүен дә, сабый баладай итеп үзен кочаклап, иркәләп торуын да аңлый алмады.

— Кемнәр монда учак ягып яталар дисәм, бу сез икәнсез,— диде Баганай.— Алайса, кайтып җиттең, углым? Иртәгә атаңның соңгы көне — беләсеңдер ич?

— Ничек — соңгы көне? — диде Тотыш, төшенмичә.

— Соңгы көне, углан,— диде Баганай, үз-үзенә ышанып.— Мин бүген юлга чыгам. Иртәгә соңгы көн. Иртәгә кайгы туе.

— Ни сөйлисең, Баганай?! Нинди кайгы туе?! — диде Тотыш, коты алынып.

— Ммм...— диде Баганай, мыгырданып.— Син әллә белмисең? Ыы... Күрән би... ыы...

Кинәт ул кычкырып җылап җибәрде. Бөтен болынны, Чулманны, урманнарны тетрәндереп, кайгыга салып, тыела алмыйча җылап җибәрде.

Тотышның кулындагы үрдәге төшеп китте, куллары, аяк буыннары көчсезләнеп калды. Туры гына басып торган Баганай да, баганадай Баганай да нишләптер як-якка чайкала башлады. Тотыш барысын да аңлап алды, шулай да ул әле бернәрсә дә аңларга теләмәде. Баганайның куркыныч сүзләре дә, кычкырып җылавы да никтер ялган булып тоелды.

— Баганай... Баганай...— диде ул, нидер әйтергә теләп тә, әйтәсе килгән сүзен сыгып чыгара алмыйча.

— Күрән би үлде! Ике ел инде... үлде! — дип кычкырды Баганай, бертуктамый күз яшьләре түгеп.

Тотышның кайгысын уртаклашып, Баганайдан күрмәкче, ишкәкчеләр дә, Торымтай да кычкырып җыларга, такмакларга тотындылар. Барысы да җыладылар, бары Тотыш кына җылый алмады. Аңа әллә ни булды. Аның күз яшь юллары да, тын юллары да кинәт кенә томаланып калгандай булды. Аяк-кулларын әйтерсең кемнәрдер авыр чылбырлар белән богаулап ташладылар. «Моннан ике ел элек үлгән»,— диде ул үз-үзенә, бөтенләй чит кеше турында уйлаган кебек. Димәк, Күзәмеш углан аңа әйтмәгән. Башка ырудашлары да әйтмәгәннәр. Үзләре әнә беренче тапкыр ишеткәндәй, бик нык кайгырган булып, акырып-акырып җылаган булалар. Ялган! Ялган! Баганайның җылавы да, ишкәкчеләрнең җылавы да ялган! Шулай булгач, аның атасы үлгән дигән сүз дә ялган! Ялган бу, ялган!

## VI

Имгәк аяк астында, дип белми әйтмәгәннәрдер, күрәсең,— Күрән би үзенең үлемен аяк астыннан тапты. Алмыш хан Акбүре җиреннән кузгалып киткәч тә, көннәрдән бер көнне Күрән би үзалдына

уйланып, онытылып манара башыннан төшеп килгәндә, аның аяк астындагы басма сынып китте. Авыр, авыру би эһ дигәнче баштүбән аска мәтәлде. Аста, койма буенда, кырлы чуерташлар өеме бар иде. Ни булганын аңларга да өлгермәгән би бернәрсәгә дә тотынып кала алмады — анда бәрелеп, монда бәрелеп, туры шул ташлар өеменә барып төште. Күгәреп, яшәреп беткән ташларга берни булмады, бинең башы исә чүлмәк кебек челпәрәмә килде. Акбүре ыруының башы, атаклы Күрән би күз ачып йомганчы аяк сузды.

Бинең үлеме ыру өчен кайгы өстенә кайгы булды. Бине күмгәндә, ырудашлары чын күңелдән җыладылар, кычкырып-кычкырып, чәчләрен-башларын тырнап җыладылар. Күрән бинең өенә — капкаларына, ишек яннарына кайгы байраклары куелды. Күмүнең беренче көннәрендә — бинең хатыннары, туганнары, балалары, соңга табарак — коллар, чуралар, үлгән ыру башының ишек төбендә үзләренең шәрә тәннәрен каеш чыбыркылар белән камчылый-камчылый җыладылар. Ике ел буена берөзлексез диярлек би өе ягыннан ирләрнең шулай ямьсез, кыргый тавышлары ишетелеп торды. Бөтен катау тизрәк соңгы көн, соңгы кайгы көне тууын, кайгы байракларының алынуын, йөрәк өзгеч иләмсез тавышларның тынып калуын көтте. Аннан да бигрәк, кешеләр Күрән бинең тол хатыны Койтым бикә ясаячак кайгы туенда — аш-суда бер туйганчы ашап-эчеп калу көнен көттеләр.

Ул соңгы көн якынлашканнан-якынлашты. Ишек төпләрендә үз-үзләрен кыйнап җылаучы коллар тагын да ямьсезрәк итеп, көчлерәк итеп кычкыра башладылар. Ерактагы ырудашларга — авыл агаларына, аксакалларга, үлгән бинең барлык туган-тумачаларына билгеләнгән көнгә — кайгы туена килергә белдерү ясалды.

Күрән би үлгәч, аның туганы, ыруда иң атаклы кешеләрдән саналган Утташ кам, йола буенча, ыру башы булып калган иде. Кайгы туеннан соң бер көн тормыйча, җыен җыелырга, шунда аны би итеп, яңадан ыру башы итеп куярга тиешләр иде. Шуннан соң ул, шулай ук йола, түрә буенча, Күрән бинең барлык байлыгына, хатыннарына, балаларына, йорт-җиренә, терлек-туарына, колларына, чураларына баш булып калачак иде. Әлегә исә, ыру башы саналса да, Күрән бинең байлыгына ул түгел, Койтым бикә баш иде. Ыру эшләрен башкарганда да әле Утташ кам Койтым бикә белән, Котан, Акбога, Майчан аксакаллар белән киңәшмичә берни дә эшли алмый иде.

Шулай итеп, барысы да соңгы көнне көтте.

Кайгы туе төштән соң башланды — би иртәнге күлемдә үлгән иде. Җылау-сыктау тавышлары бердәй тынып калды, җилдә-яңгырда, карда-буранда уңып, теткәләнеп беткән байраклар, буяулары купкан агач сыннар алып куелды. Кешеләр бер тотам чәчләрен кисеп җиргә күмделәр. Шуннан соң Койтым бикә өйдән, көмеш табакка салып, бер кисәк ит, ботка, ачы бал алып чыкты. Күрән бинең бөтен өй эче белән ул, әлеге азыкларны күтәреп, зыяратка юнәлде. Анда алар кечкенә чокыр казыдылар, үзләре белән алып килгән ашамлык-эчемлекләрне шул чокырга куйдылар.

— Күрән! Син үлдең. Соңгы тапкыр без сиңа ашарга, эчәргә алып килдек. Без барысын да йола кушканча эшләдек,— диде Койтым бикә, чокырга карап.— Барлык ыру синең белән саубуллашырга килде. Бары синең улың, минем колынкаем Тотыш кына кайтып җитмәде, аннары синең углың Күзәмеш тә монда юк. Явыз Алмыш ханга ул тотык булып китте. Тәңре катына баргач, син безнең турыда әйтергә онытма, Күрән! Үзеңнең ыруыңны, сәвекле хатыннарыңны, балаларыңны онытма. Без синең өчен изге теләктә булырбыз, син дә Тәңредән безнең язмышларыбызны кичерүен үтен. Тыныч бул, яткан җирең мамык булсын, Күрән! Син мине кеше иттең, син миңа йомшак, ягымлы булдың, син мине барлык хатыннарыңнан ныграк ярattың. Мин сине мәңге онытмам, сәвекле ирем!.. Алайса, без туйны башлыйбыз, Күрән?

Әледән-әле борынын тарткалап, күз яшьләрен түгеп, ул шулай үзенең үлгән ире белән сөйләште. Бераздан башын калкытып, көндәшләренә, балаларына, туганнарына карады да:

— Ул мине ишетте! Тиздән ул монда килеп җитәр! — диде, кулларын күкрәк турысында кушырган килеш, күккә карап.

Әкрен генә атлап, кайгылы башларын салындырып, алар өйгә кайтып киттеләр. Беравык көтеп торганнан соң, үлгән бинең хатыннары, балалары, туганнары зыяратка яңадан килделәр. Алар калдырган ашамлык-эчемлек тә, табак-савыт та юк иде. Монда күп тормыйча алар ашыгып кайтып киттеләр.

— Би килгән! Итен, боткасын ашаган, балын эчкән. Бар нәрсәсен үзе белән алып киткән,— диде Койтым бикә, кунакларга елмаеп.

Ире үлгәннән соң бу аның беренче елмаюы иде.

Күрән бинең туйга килеп җитүе, пешкән азыкларны, эчемлекне беренче булып авыз итүе билгеле булгач та, кунакларны сыйлау башланды. Бинең хатыннары, балалары, туганнары, шулай ук барлык зур кунаклар йөз кешене сыйдыра ала торган киез өйдә сыйландылар. Башка кунакларга, чураларга, колларга, бала-чагага туп-туры җир өстенә күп итеп киезләр җәйделәр дә, ашамлык-эчемлекне шунда тараттылар.

Туйны Койтым бикә үзе алып барды. Кунакларны сыйлый башлаганда гына ул түрдә утырды да, ашау-эчү җайга салынгач, киез өйдән чыгып китте. Пешекчеләрне, аякчыларны күрде, тегесен тегеләй

итәргә, монысын болай итәргә кушты; җир өстенә тезелеп утырган кунаклары арасында йөрде — кемгә нәрсә биргәннәр, күпме биргәннәр, берәрсен онытып калдырмаганнармы — барысын да карап күздән кичерде. Урын тапмыйча аптырабрак торган хатыннарны, ирләрне, бала-чагаларны, үзе белән ияртеп, иркенрәк җиргә алып китте; узышлый берәрсенең иңбашына орынып алды, кайберсенә берәр сүз кушты, йә булмаса, исәнлек-саулык сорашты.

Койтым бикәнең кайгылы, боек йөзе әле анда, әле монда күренеп калды. Чынында ул инде иренең үлемен күптән онытып бетергән иде. Бикәнең күңелен, бинең үлеменнән бигрәк, бөтенләй икенче нәрсәләр борчый иде. Бүген соңгы көн. Бүгеннән соң ул менә шулай шаулатып, бөтен ыруны җыеп туйлар ясый алмас. Бүгеннән соң инде шулай якын итеп кешеләрнең иңбашларына орынып китә алмас. Озакламый аның кулыннан байлык та, көч тә китәчәк. Озакламыйча... бүгенге төн көнгә авышкач та, ул үзенең явыз дошманы Утташның... Утташ бинең хатыны булып санала башлаячак. Беренче төнне яңа би аның өендә куначак. Ул инде алдан ук әйтеп куйды. Кемне куяр ул үзенең өлкән хатыны итеп? Тотышка ничек карар ул? Тотыш турында ишетү белән аның чырае сытыла. Элеккечә ул аны каргарга батырчылык итми, шулай да ул аны яратмый да. Тотыш үзе ничек карар бу эшкә? Ул инде үскәндер, көчледер. Үги атасына каршы бер-бер яманлык эшләмәсме ул? Үз атасы булмагач, аны инде элеккечә яклаучылар табылмас. Бер анасының гына яклавы аны үги атаның кырын күзеннән, яманлыгыннан саклап кала алырмы?

Бикәнең күңелен менә шундый уйлар борчыды. Ул инде күптән, бик күптәннән бирле киләчәктә ниндидер зур үзгәрешләр буласын сизенеп яшәде. Соңгы көннәрдә куркыныч төшләр дә күрде. Ниләр генә булыр инде, ниләр генә күрер инде аның кайгылы башы?

Койтым бикә бүген саранланып тормады — чокырларда саклап тотылган барлык кисмәкләрне диярлек кунакларга таратырга боерды: аяктан егылганчы эчсеннәр, диде. Үзе ул ачы балны бары авыз итеп кенә карады. Аякчылар, бикәнең боерыгын үтәп, бик юмарт кыландылар. Күп тә үтмәде, әле анда, әле монда кычкырып җырлаган, көлешкән тавышлар ишетелде. Көлү, җыр тавышларына җир селкетеп биегән, думбыра чиерткән тавышлар кушылды. Кайгы туе сиздермичә генә куаныч туена әйләнде.

Ашау-эчүнең, уен-көлкенең кызган чагында Койтым бикә, арып-алҗып, үз өенә кереп китте. Ак өйдә дә, тышта да аның инде кирәге юк иде. Аның бераз ятып ял итеп аласы килде.

Бусага янында аның каршысына кинәт бер кеше килеп басты. Ул исерек иде, сыңар күзе аның кара тире белән бәйләнгән иде.

— Бикәгә минем бер сүзем бар,— диде ул, телен көчкә әйләндереп.

— Нинди сүз? — диде бикә.

— Синең үзеңә генә. Аулакта гына,— диде исерек ир кеше, бик тә серле итеп.

«Кем соң әле бу?» — дип уйлады Койтым бикә, тиз генә таный алмыйча. Күзен бәйләгән... Туктале, Талут ич бу! Тотыш чыбыркы белән сугып күзен чыгарган Талут. Моннан ике ел элек шул сытылган күзе өчен акча сорап килгән иде. Шуннан соң бөтенләй күзгә-башка күренмәде. Урман арасында яшәде бугай. Нинди яшерен сүзе булыр аның? Тагын шул күзе өчен акча сорамакчы була микәнни? Кайчагында бик бәйләнчек була бу каралар.

— Әйдә, керик алайса,— диде ул Талутка.

Өйгә кергәч, ул ишекне эчтән бикләп куйды. Түргә, йомшак урынга барып утырды да, бер сүз әйтмичә, көтә башлады. Талут, өйгә керү белән, бикә алдына тезләнде, сыңар күзеннән яшьләр коеп, җыларга кереште.

— Шулмы сүзең? — диде Койтым бикә.

— Бикә, кичер мине, кичер,— диде Талут, такмаклап, башын бәргәләп.

— Ни өчен кичерергә? — диде бикә.— Теге чакта акча алган өченме? Тотышны яманлавың өченме? Булган — беткән, онът.

— Тәңре каршында языклы мин, бикә! — диде Талут.

— Мин сиңа Тәңре түгел!.. Әйттем исә кайттым! — диде бикә, үртәлә башлап.— Чыккан күзең өчен тагын акча кирәкме?

Ул, кабаланып, кулын күлмәк изүенә тыкты да акча янчыгын тартып чыгарды. Аның тизрәк бу исеректән котыласы килде. Алтын-көмеш тәңкәләр күреп, Талут җылавыннан туктап калды, сыңар күзен елтыратып, бикәнең ак кулына карап тора башлады.

— Юк, бикә, миңа акча кирәкми! — диде ул кинәт бөтенләй айнык бер тавыш белән.

Койтым бикә, иелеп, аның йөзенә җентеклăбрәк карады. Талут исерек түгел иде.

— Әйтеп кара алайса сүзеңне,— диде бикә, янчыгын кире яшереп.

— Бикә! Кичерәсеңме мине? — диде Талут.

— Ник? Тотыш өченме? — диде бикә тагын да.— Эш миннән тормас. Тәңре кичерсен.

— Әйт, кичерәсеңме?! — диде Талут исәр кеше сыман, аягына басып.

— Мин сине кичерәм, Талут,— диде Койтым бикә, йомшак кына итеп.

Аны чын-чынлап кызыксыну биләп алды: ни булган моңа? Әллә чыннан да тилергәнме бу?

— Нинди языгым булса да кичерәсеңме? — диде Талут, бәйләнчекләнеп.

— Минем алда синең бернинди языгың юк, Талут,— диде бикә.
— Әйт — кичерәсеңме?! — диде кычкырып күзен бәйләгән кеше, ярсып.
— Нинди языгың булса да, мин сине кичерәм, Талут,— диде бикә, никтер курка башлап.
— Сүзеңнән танма, бикә! — дип кычкырды ялган исерек, сыңар күзен акайтып.
— Танмам,— диде бикә.
Талут, каты буза эчәр алдыннан тынып торган эчкече кебек, беравык тынын кысып торды да, йөзен чалшайтып, көрсенеп куйды, аннары, башын түбән иеп:
— Иреңне... Күрән бине... мин үтердем, бикә,— диде.
Аның ябык, саргылт йөзе үлекнеке төсле булып, тагын да ныграк агарынып калды, башы тагын да ныграк салынып төште. Искәрмәстән ул гөрселдәп идәнгә ауды.
Койтым бикә, урынында ничек утырган булса, шул көе катты да калды. Шулай күпмедер онытылып, шаккатып, аптырап утырганнан соң, ул борын сыртын кашып куйды, изүен чишеп җибәрде. Кисәк кенә аны нидер калтырата башлагандай булды. Шул ук мәлдә күкрәгенең сул ягында, эчтә, тирәндә, авырттырып-ачыттырып нидер кузгалып куйды.
— Әйе, мин үтердем, бикә,— диде Талут озак кына ятканнан соң, башын калкытып.— Ике ел буена кара кан йотып яшәдем. Корыдым-киптем, саргайдым. Күрән бинең каны тота мине. Өрәге көн дә төшемә кереп котымны ала, буа, өстемә каплана... үз янына тарта... Мин куркам, бикә! Кешеләрдән, синнән, синең балаларыңнан куркам. Минем кешегә бармак белән чирткәнем дә булмады. Күрән бигә минем тамчы да ачуым югые. Шулай да мин аны үтердем.
— Ни өчен?! — диде бикә пышылдап, тетрәндергеч итеп.
— Менә шуның өчен үтердем,— диде Талут, күзендәге тире кисәген капшап.— Тотыш минем күземне чыгарды, бер дә юкка. Күңелдә углыңа, сиңа, бикә, ачу саклап йөрдем. Шунда мине Утташ кам котыртты, аңымны томалады.
— Шуннан, шуннан? — диде бикә.
— Шуннан шул... Күрән би менеп йөри торган баскычның бер басмасын алыштырып куярга ул әйтте. Башыма да килмәгәние. Сагалап кына тордым да беркем күрмәгәндә... би манара башына менеп киткәч... таза басманы черекка алыштырдым да куйдым. Мин аны үләр дип белмәдем. Аягы гына имгәнер, шуның белән үчемне кайтарырмын дип уйладым. Ул әнә алай булып чыкмады. Би булгач, мин сине унбашы[1] ясармын, диде.
— Кем?
— Кем булсын — Утташ!
— Димәк, минем ирем сез казыган базга барып төшкән булып чыга?
— Шулай булып чыга, бикә,— диде Талут.— Миңа унбашы булу да, йөзбашы булу да кирәкми. Күрән би үлгәч, мин дә үләргә тиеш, бикә! Күрән би янына китеп, мин аның аягына җыгылырга, аның ярлыкавын үтенергә тиешмен. Сиңа үтенечем шул: минем хатынымны, балаларымны ташлама, кыерсытма. Кызым чирле... өч яшьлек... сабыем, балакаем! Аягы йөрми. Шуны уйласам, йөрәкләрем өзелә. Терелт, им ит. Күрәсең, аны да Күрән бинең каны тотадыр. Мин үлсәм, җибәрер. Тотышка бер үпкәм дә юк инде. Яшь кеше... кызып киткәндер. Шундый зур языгым булмаса, бер күз белән дә яшәгән булырыем. Инде булмый, бикә. Тагын шул: Утташ кам... ни... миңа Тотышны да...
— Тотышны да?! — диде бикә, аягүрә басып.
— Әйе. Мин баш тарттым.
— Бу турыда тагын берәрсе беләме? — диде бикә, үз-үзен тиз арада кулга алып, эчке бер ныклык белән.
— Утташ та мин.
— Мин сине тулысынча... бөтенләйгә... мәңгегә кичерәм, Талут! — диде бикә, дулкынланып.— Син минем күземне ачтың. Турысын сөйләвең өчен мин генә түгел, Тәңре дә ярлыкар сине, Талут. Тынычлап яшә. Хатыныңны, балаларыңны кайгыртырмын — ул турыда борчылма. Мин кичергәч, Күрән би дә йомшар... йолык бирербез.
— Юк, бикә! — диде Талут.— Мин инде уйладым: мин Тәңре катына бармыйча, җирдә тынгы таба алмаячакмын. Күрән бинең ярлыкавын мин үзем сорарга тиешмен.
— Бел аны: бу турыда беркемгә тишмә! — диде бикә.— Монда син түгел, Утташ кам языклы. Иң элек без аннан үч алырга тиешбез! Шунсыз Күрән безне кичермәс.
— Колың булыйм, бикә! — диде Талут, чибәр хатынның күлмәк итәген үбеп.

## VIII

Талут чыгып күп тә үтмәде, бикә янына өлкән аякчы килеп керде.
— Таратырга бал бетте, бикә,— диде ул.— Теге өч чиләк керешле тамгалы чапчакларны ачаргамы?
— Ачарга,— диде бикә, аның сүзләрен бик үк тыңламыйча.

— Утташ әйтә, Койтым бикә нишләп күренми, ди. Исерде. Үзе җырлый, үзе җылый, үзе тагын бал сорый.

— Минем башым авырта, күңелем болгана — бара алмыйм,— диде бикә.— Әйт: исермәсен, туйны үзе алып барсын, күз-колак булсын.

— Кая ул! — диде өлкән аякчы, кулын селтәп.— Аның үзенә күз-колак булырга кирәк.

Ул, шулай сөйләнеп, өйдән чыгып китте. Койтым бикә аның соңгы сүзләрен бөтенләй ишетмәде. Ул күзләрен йомды. Ул үзендә коточкыч авырлык тойды. Аның өчен тормыш әйтерсең туктап калды — аның ни дә булса уйлыйсы да, кайгыртасы да килмәде. Шулай да күңеленең бер кырыенда гына энә очы чаклы гына булып, әрнетеп, авырттырып, Тотыш эленеп торды. Ул кайтып җитмәде. Алмыш хан җибәрмәгәнме, Күзәмеш углан барып җитә алмаганмы? Исәнме, түгелме?

Туктале, аңа тозак корырга да өлгермәгәннәрме? Кайтып җитмәс борын... юлда... берәр ничек юкка чыгармаганнармы? А, Тәңрем?

Бикәнең авыр кайгыдан бастырылып ойый, тына барган йөрәге, оясыннан атылып чыккан кош кебек, ыргылып куйды, камырга әйләнә башлаган кан тамырлары буенча, йокымсыраган миен, тойгыларын камчылап, кайнар кан йөгереп узды, «Тәңрем, көч бир, кыюлык бир!» — диде бикә, ишекле-түрле йөренеп, нидер эшләргә, нидер кырырга-җимерергә чамалап.

Ул тышка чыкты, йолдызлар белән тишкәләнгән кара төн чыбылдыгына карап алды — әле төн уртасына ерак иде. Кунаклар инде таралыша башлаганнар, анда-санда гына исерек тавышлар, җырлар ишетелә иде.

Бикә кире өйгә керде, пыскып янган учакка утын өстәде, өстен-башын төзәткәләде, көзгегә каранды, агарынган йөзенә кызыллык йөгерсен өчен бераз бал эчте. Шуннан соң гына ул яңадан тышка чыкты, ак өйләргә таба юнәлде. Аңа кичекмәстән берәрсен күрергә, сөйләшергә, ни дә булса эшләргә кирәк иде. Юкса ул соңга калачак, бик нык соңга калачак! Кемне күрергә, кем белән киңәшергә соң? Майчан аксакал белән берни барып чыкмас. Була-калса — Котан, Акбога... Бөтен ыруда, бөтен туган-тумачалары арасында алардан башка бернинди ышанычлы кеше юк. Котан... Котан би... Әллә Акбогамы? Аның үги уллары... Күрәсең, язмыш шулайдыр. Башкача булмый.

Исерешеп беткән, баш-аяк килгән кешеләр арасында Котанны ул бик тиз тапты. Шыпырт кына аңа үзе артыннан барырга кушты.

— Кеше күрмәсен. Ашыгыч сүзем бар,— диде ул аңа.

Котан күз карашы белән генә аңа төшенгәнлеген белдерде. Бикә, елмаеп, кызмача кеше сыман, як-якка чайкалган булып, Утташ кам янына барып әйләнде, үз кулы белән аңа буза салып бирде. Аннары, аның колагына пышылдап:

— Беренче әтәч кычкыргач килерсең. Әле төннең чирек дә юк,— диде.

Шулай сөйләнгәләп, ислемай исләре аңкыткан күлмәк итәкләрен җилфердәтеп бикә шул тирәдә бераз буталды да юкка да чыкты. Ул үз өенә кайтып кергәндә, Котан анда иде инде. Субашы Котан шактый кызмача иде, шулай да аягында нык басып тора иде. Койтым бикә аңа йомшак урындыкка утырырга кушты, Котан сирәк сакалын сыйпаштырып, елмаештырып бикәнең аяк астына идәнгә тезләнде.

— Анам өендә миңа идәндә дә йомшак,— диде ул.

— Бүгеннән башлап син миңа угыл түгел, мин сиңа  ана түгел,— диде бикә.

— Төн уртасы узмаган ич әле, анам... бикә...— диде субашы бер дә юктан кеткелдәп.

Койтым бикә күлмәк иткәләрен җыештыргалагандай итте, алтын беләзекләренә, ялт-йолт килгән муенсаларына кагылгалап алды, елмайды, учактагы утка яны беләнрәк торган Котанның күзләренә туры карады да:

— Мин сиңа ошыйммы, углым? — диде.

Беркатлы Котан авызын ерып, ышанып җитмәгән шикелле, тын гына карап торды. Аннары кызмача бер кыюлык белән, омтылыш белән, бикәнең тез өстеннән салынып төшкән ак, матур кулына үрелде, тотып алды, җылый-җылый, көлә-көлә үбәргә тотынды.

— Анам! Бикә! — диде.— Чынмы? Ялганламыйсыңмы? Бикә! Анам! Тагын әйт: чынмы?

Котан тынычлана төшкәч, бикә кулын тартып алды да кырыс бер ныклык белән.

— Ошасам, шул: синнән башка мин беркемгә кияүгә чыкмаячакмын! — диде.

Субашы Котан авызын ачып, исе китеп тик торды.

— Утташ кам...— диде ул шулай да, үзалдына мыгырданып.

Булачак иренең җебегәнлегенә ачуы килеп, бикә чыраен сытып куйды.

— Тик син шуны аңларга тиешсең,— диде ул боеручан тавыш белән,— мин өлкән хатын гына булмаячакмын. Би урынын да, ыру башын да мин үзем тотачакмын! Ишетәсеңме, мин ыру башы булачакмын! Шуңа килешсәң, иртәгәдән мин — синең хатының!

Котан, шашынып, яңадан бикәнең ак кулын үбәргә тотынды. Нидер исенә килеп, ул кинәт аягына басты, беренче тапкыр күргән сыман, сокланып үзенең үги анасына карап тора башлады.

— Утташ кам ничек соң... әллә ничек була түгелме? — диде ул тагын да.— Аңлатып бир: ничек?

Койтым бикәгә чыннан да аңлатып бирергә туры килде. Бары шуннан соң гына булачак кияү җиңел сулап куйды. Үзенең зур, көчле кулына бикәнең ак кулын алып кысты да, чын күңелдән соклану белән — инде икенче төрле соклану белән:

— Синнән дә башлырак, кыюрак кеше калмады ыруда, анам! — диде.— Билек[1] — сиңа, ыру башы — сиңа! Тулысынча мин сиңа буйсынам. Үз урынымда калсам, миңа шул җиткән.

— Антмы? — диде бикә.

— Ант! — диде Котан, бикә биргән эчемлекне алып.

— Тагын бер сүзем бар,— диде бикә, ант эчкәч.— Тотыш кайткач, аңа бернинди усаллык кылмаска! Мин барысын да үземчә эшләячәкмен. Син минем бер эшемә дә кысылмассың.

— Мин сиңа сүз бирәм! — диде Котан.— Тотышка усаллык кылмам, синең сүзеңнән чыкмам!

— Килештек,— диде бикә.— Төн уртасы җитәдер. Кирәкле кешеләреңне күреп, кисәтеп куй. Акбогага белдер, соңыннан үпкәләп йөрерлек булмасын. Юк. Аңа мин үзем әйтермен. Утташ килгәнче өлгерергә кирәк.

— Булды, киттем! — диде Котан, ишеккә борылып.

Шул чакны кемнеңдер бәрелә-сугыла өйалдына килеп кергәне ишетелде.

— Килә! Түзмәгән,— диде бикә, пышылдап.— Бар, кач!

## IX

Койтым бикә ишекне ачып җибәргән иде, каршысында Утташ кам урынына Тотышны — үскән, үзгәргән Тотышны күреп, артына авып китә язды. Курку-каушау тиз арада чиксез куаныч белән алышынды.

— Улым, Тотыш! — диде ул, кочагын җәеп.

Борынын тартып, шыңшыгандай итеп ул аның күкрәгенә сыенды.

— Кайтты! Исән, исән! Колынкаем, бавыр итем, йөрәк маем. Исән, исән! — диде ул, улының киемнәрен, битен, кулын кайнар күз яшьләре белән чылатып.— Кайчан кайттың? Ничек кайттың? Ник соңгардың, углым?

— Менә, кайттым инде, анай,— диде Тотыш, елмаеп.— Капкадан кергәндә беркем күрмәде — сакчылар исерек.

— Син әле дә үз капкаңнан качып-посып керәсеңмени, углым? — диде ана.

— Мин инде якты күздә кайтып төштем,— диде Тотыш.— Керергә юри караңгыга калдым.

— Ник? — диде бикә.— Әллә берәр нәрсә булдымы?

— Булды, анай,— диде Тотыш, өстендәге киемнәрен чишенә башлап.— Талкысыктан аста, Ауган карама янындарак юлбасарлар юлыма аркылы төште. Арлар. Бик каты сугыштык. Өч кешем үлде. Шуларның берсе — якын дустым Бәкәч чәчән. Урыны оҗмахта булсын! Аннары Баганай...

— Баганай? — диде Койтым бикә.— Әйтәм, туйда күренмәде!

— Аларның сүзеннән шуны аңладым: алар минем кайтканны сагалап торганнар. Аларны котыртканнар, анай! Шуңа күрә монда качып-посып кердем. Кичер мине, анам! Күңелем яман нәрсә сизенде. Шулай да мин чигенмәскә булдым. Миңа тозак коручы кем генә булмасын, мин аннан курыкмыйм. Үз өемә, үз анам янына кайтып җитеп, кире чигенсәм, атым Тотыш алып булмасын! Бүләкләремне талап алып калдылар, әзәрлекләп булмады. Бары бер йөзек кенә исән калды... Булачак киленеңнең сиңа бүләге — ал шуны, изге анам!

Ул куенындагы янчыгыннан алтын йөзекне алды да анасының урта бармагына кидерде.

— У-у! — диде Койтым бикә, кояштай балкып, йөзектән күзен алмыйча.— Булачак киленемнән? Кем икән ул минем булачак киленем? Бай булсын, сау булсын икән ул юмарт килен!

— Соңыннан сөйләшербез ул турыда,— диде Тотыш, киемнәрен, коралларын салып.— Иң элек син әйт: шулай ук эшләр яманмыни монда?

Койтым бикә, авыз ачып нидер әйтмәкче булган иде, шул чакны көтмәгәндә өй ишеге тагын ачылып китте — Тотыш кергәндә, күрәсең, өйалды ишегенең биген элдерергә онытkan иде. Ана да, угыл да, сүзләреннән бүленеп, керүчегә текәлделәр. Тотыш ялт кына урыныннан кубып, чөйдәге кылычын алды. Елмаерга, туры басарга тырышып, ишек яңакларына тотынгалап, Утташ кам кереп килә иде.

— Ярты төн узды, бикә! — диде ул, артта калган сул аягын бусага аша күтәреп алырга тырышып.— Кияү килә. Каршы да алмыйсың, бикә!

Тырыша торгач, ул бусагадан аркылы атлады да борылып ишекне япты, бавын элдерде, аннары билен турайтып, тамак кыргалап, түргә узгандай итте. Каршысында, ут яктысында Тотышны күреп ул чайкалып китте, күзләрен челт-мелт йомгалады, әллә төшләнәмме дигәндәй, сакалын тарткалап карады. Юк, төш түгел иде, ахрысы, бу. Тотыштан бер читтәрәк, усал елмаеп, бикә басып тора иде. Аның шул усал елмаюлы йөзен күргәч тә, Утташ кам барысын да аңлап алды. Аны кинәт очкылык тота башлады.

— Ке... ке... кем бу? Н... н... ни эш бу? — диде ул, кемгәдер ачуланасы килеп.
Аңа беркем берни әйтмәде.
— Ә-ә... Тотыш икән! — дигән булды Утташ кам, «танып» алып. Тотыш... ничек итеп... ни... ыы?..
Кинәт ул биленнән хәнҗәрен тартып алды да, ярсытылган аю сыман Тотышка ташланды. Ул аның кулындагы кылычын күрмәде бугай. Ут яктысында озын тимер ялтырап китте.
— Углым, ярамый! — дип кычкырды Койтым бикә, Утташ камны каплап.
Шул чакны качкан җиреннән — чыбылдык артыннан Котан килеп чыкты. Тотыш белән икәүләп алар тиз арада Утташ камны тотып алдылар, аяк-кулларын бәйләп ташладылар, авызына чүпрәк тутырдылар.
— Исәнме-саумы, Тотыш,— диде Котан, Утташ белән эшләре беткәч, энесенең кулын кысып.
Котан белән Тотыш тыелып кына исәнләште. Нәрсә бу? Нишләп монда дүртенче кеше килеп чыкты әле? Ул анасына сораулы караш ташлап алды.
— Утташ кам сиңа тозак корган, без аңа капкын кордык, углым,— диде Койтым бикә.— Син бу кешене яхшы беләсең. Бу кеше сиңа, миңа көн күрсәтмәскә тырышты. Бу кешенең эче яманлык белән тулы.
— Беләм, барысын да беләм,— диде Тотыш.— Шулай да, төшенмим — нишләтмәкче буласың син аны?
— Мин дә үч алмакчы булам, углым,— диде Койтым бикә.— Синең өчен, үзем өчен, атаң өчен үч алмакчы булам.
— Атам өчен? — дид Тотыш.— Минем ул турыда уйлаганым булмады. Минем атама аның теше үтмәде сыман.
— Ул аны үтергән, углым! — диде бикә.— Соңгы сүзне иртәгә ыру әйтер. Болай гына эшен бетерсәк, без кеше үтерүче булачакбыз. Моның өчен ыру безне кичермәс. Үзенең өлкән камын, үзенең биен, ыру башын ыру гына үтерә ала. Ырудан, ил-көннән көчле берни юк дөньяда, углым!

**X**

Җыен үзенең соңгы сүзен әйтте: ыру башы Күрән бине үтергән өчен Утташ камны Тәңре катына озаттылар. Урман эчендәге киң алан читендә, бер-берсеннән бер ун адым аеры утырган ике яшь каенның башларын бергә китереп иделәр дә, Утташ камның бер аягын бер агач башына, икенче аягын икенче агач башына бәйләделәр. Шуннан соң каеннарны ычкындырып җибәрделәр. Кешеләр, өсләренә кара кан тамудан куркып, тиз генә як-якка сибелделәр.
Талутны Койтым бикә җыенда яклап чыкты. Шуңа күрә аны исән калдырдылар. Бары Талут үзе генә моңа каршы килде. Ул, бер үк сүзне кабатлап, үзенең Күрән бидән ярлыкау үтенергә тиешлеген әйтте. Аның теләгенә каршы килмәделәр.
Шулай итеп, Койтым бикә җиңеп чыкты. Җыен аны ыру башы итеп куйды. Билекне ыру башы үзенең углы Тотышка бирде. Субашы Котан белән каравыл башы Акбога гына моңа артык куаныч белдермәделәр. Шулай да аларның да почмагы түгәрәкләнде: Койтым бикә, биргән сүзен үтәп, Котанны үзенә ир итеп алды — үги улының икенче хатыны булды. Акбогага бүләк итеп Койтым бикә үзенең яшь, күркәм бер кол кызын бирде.
Кызыл Яр катауда кайгы туена ялганып, яңа туй башланып китте. Таралышып өлгермәгән кунакларга яңадан ачы баллар, бузалар, кымызлар куелды, сарыклар, җылкылар суелды.
Туй ыгы-зыгылары үткәч, берничә көннән Тотыш анасына үзенең эч серләрен ачты. Койтым бикә, елмаеп, сөрмәле күзләрен кысыштырып, углын озак кына карап утырды.
Аның углы Тотыш Тәңкәсен оныткан. Ул әнә хан кызын ярата! Тотыш — Алмыш хан кияве! Алмыш хан белән алар — Койтым бикә — кода-кодагый булачаклар! Нәрсә бу — язмыш шуклыгымы, әллә соң Болгар ханының бик еракка ташланган җәтмәсеме? Ун мең тиен калым түләргә, бөтен ыруың белән гарәп диненә күчәргә... Бу аз түгел. Хан кызы Аппакка торырлык түләү бу. Моның иң авыры кайсы булыр — ата-баба йоласыннан баш тартумы, әллә ун мең тиен калыммы? Күрәсең, ханның чыннан да үз уйлары бардыр. Акбүрене ныклап торып үз кулына алса, бөтен Чулман буе аныкы булачак. Тулысынча аныкы булачак. Акбүредән Биарга да ерак түгел. Биардан әнә таланган кешеләр килә. Биарны төн ягыннан, диңгездән килгән явыз юлбасарлар талаган. Биар тузган, юкка чыккан. Күрәсең, язмыштыр. Биар ханының җитен чәчле сылу кызын алып булмады. Таланган, көчсезләнгән биар белән туганлашуга караганда, үргә менеп барган Болгар ханы белән туганлашу, билгеле, йөз кат, мең кат артыграк. Шулай да... кемнәр алар бер-берсенә — туганнармы, әллә ятлармы? Ах, шулай да, Тәңрем, синең серле эшләреңне кем генә белә соң?!
Ярар, алар яшьләр. Бер-берсенә алар чит тә, ят та булсыннар ди... кавышсыннар, куанышсыннар, оя корсыннар ди... Ул үзе — Койтым бикә — моңа ничек карарга тиеш соң? Аның да күңеле бар ич әле, аның да үткәне, яшьлеге бар ич әле! Күләгәдәй арттан калмый торган, онытылмый торган канлы-яшьле, куркыныч яшьлеге... Ничек карарга, кайсы яктан килеп карарга тиеш ул үзенең үткәненә...

Алмыш ханга... аның белән туганлашуга? Була торган эшме бу? Барысы өчен ул алардан, аннан үч алырга тиеш түгелмени?!

Ничек итеп, нәрсә белән?

Менә бу сорау — караңгы яшьлектән дә, куркыныч төшләрдән дә мәңгерәк, авыррак менә бу сорау искәрмәстән аның уй агышын кире борып җибәрде. Элеккеләр, күпме генә аның күңел күзен томалап тормасын, күпме генә аның йөрәген яралап, ярасыннан кара кан саркытып тормасын, шулай да ул инде алардан күптән, бик күптән ераклашкан иде, ахрысы. Ни генә булмасын, ул бүгенге көн, иртәгәге көн белән яши иде. Яшәргә тиеш иде. Шуның өстәвенә ул монда Акбүредә илсез-көнсез кол булып, кырнак булып түгел, бикә булып, баш булып яши. Шулай булгач, ул инде үзеннән, үзенең үткәненнән бигрәк, ил-көн турында, аның бүгенгесе, иртәгәсе турында кайгыртырга тиеш түгелмени?!

Менә шушы кайгы — олы, изге бер кайгы аның барлык теләкләреннән, уй-хыялларыннан өстен чыкты. Күрән би үлгән белән башкалар да үләргә тиеш дигән сүз юк, бечәнәкләр таркалган белән Акбүре дә таркалырга тиеш дигән сүз юк! Акбүре яшәргә тиеш. Тынычта, иркендә яшәргә тиеш. Алмыш хан белән туганлашу ул — мәңге иминлек дигән сүз. Болгарлар канаты астына сыену ул — моннан соң Акбүре җирендә беркайчан да олы яу, сугыш булмаячак дигән сүз. Инде шулай да болгарлардан башка берәрсенең Акбүрегә каршы кылыч күтәрергә кыюлыгы җитә икән, ул чагында кода... кодалар кыерсытырга ирек бирмәячәкләр.

— Мин, улым, синең бер генә теләгеңә дә каршы килмәячәкмен,— диде бикә, озак кына сүзсез утырганнан соң.— Син минем бердәнбер куанычым. Син инде үзең би. Үз башың белән уйлап кара: бүгеннән тотып без ата-баба йоласыннан баш тартсак, ыру безгә ни дияр? Безне тыңлап та тормаслар — кулдан тотарлар да, артка тибәрләр дә, чыгарырлар да җибәрерләр: әнә бара юлыгыз! Теләсә кая барыгыз, теләсә кемгә би булыгыз! — диярләр.

— Нишләргә соң, алайса? — диде Тотыш, караңгы чырай белән.

— Ашыкмаска кирәк,— диде ана кеше.— Көтәргә, ыруны тулысынча үз кулыбызга алырга, киреләрне үз ягыбызга аударырга кирәк. Утташ кам үлде. Аның яклылар үлмәде. Шуны да онытма, гарәп йоласына күчсәк, без урталыкта калачакбыз: уңда да, сулда да ата-баба йоласындагы ырулар булачак. Алар безгә кырын күз белән караячаклар. Шулай булгач, безгә үз ыруыбызны гына түгел, күршеләрне дә үз ягыбызга аударырга туры киләчәк. Ике айдан түгел, дүрт-биш айдан...

— Дүрт-биш ай! — диде Тотыш, көрсенеп.— Дүрт-биш айда мин саргаеп үләрмен, анам.

— Үлмәссең,— диде Койтым бикә.— Яңа иген җитмичә торып, мең тиен түгел, мин йөз тиен дә арттыра алмыйм. Калымга гына түгел, әле бүләккә дә дүрт мең, биш мең кирәк булачак. Безнең базлар, чокырлар бу көннәрдә бушап, такыраеп калды, углым. Би буларак, син үзең карап, тикшереп чык. Шуннан соң күрерсең үз күзләрең белән.

Тотыш би, анасының сүзен тыңлап, чыннан да карап чыгарга булды. Үзенең базларын, чокырларын, амбарларын тикшереп карагач, ул әллә ни байлык юклыгын таныргa тиеш булды. Мең тиенлек калым җыю өчен дүрт-биш ай булмаса да, кимендә бер өч ай көтәргә, тир түгеп эшләргә кирәк булачак иде. Калымнан да бигрәк, Койтым бикәнең йола турындагы сүзләре чынга чыкты. Аксакалларның, ил агаларының берсенең дә тора салып күнеккән, ияләшкән үз йолаларыннан баш тартасылары килмәде. Каршы торучыларны үз ягына аудару өчен Койтым бикәгә бик нык тырышырга туры килде.

Яңа дингә каршы торучыларның иң көчлесе Майчан аксакал иде. Койтым бикә ныклап торып сөйләшүне иң элек аннан башлады.

— Син, Майчан аксакал, бөтен ыруда иң өлкән, иң белекле кеше. Шулай да син күп нәрсәне уйлап җиткермисең,— диде ул аңа.— Ямгырчы би килде — аннан йөз чөердек. Үз җиребездә үзебез генә яшибез, дидек. Яши алдыкмы? Юк! Болгарлар яңадан яу белән килсәләр, монысында инде безне беркем дә коткара алмаячак — Тәңре дә, калан да! Аның шартын үтәсәк, Акбүре җирендә мәңге тынычлык урнашачак. Сиңа, миңа, караларга тынычлыктан башка тагын ни кирәк?

— Шулай ук микән? — диде Майчан аксакал, икеләнә башлап.

— Шулай, Майчан баба! — диде Койтым бикә.— Итил-Чулман илендә Алмыш ханнан көчле беркем юк. Алмыш хан белән туганлашып Акбүре отачак кына. Моннан соң игенчеләр курыкмыйча иген игәчәк, терлекчеләр терлек асраячак. Моннан соң Акбүредә беркайчан да ятим балалар да, тол хатыннар да булмаячак!

— Кхм...— диде Майчан аксакал, тынычлыгын җуеп.— Ышандырдың, бикә. Яңа дигәч тә, Тотышның Алмыш хан кызына өйләнүенә дә миннән каршылык юк... Ул кызны бик күркәм, диләр. Төкле аягы белән килсен, куаныч алып килсен Акбүрегә. Миннән теләк шул.

Бары шушы сөйләшүдән соң гына ыруның аксакаллары, агай-эне, икеле-микеле уйларын, кирелекләрен җиңеп, Койтым бикә ягына авыштылар. Шуның белән бергә Тотыш бинең Алмыш хан кызы Аппакка өйләнүенә килешү дә белдерелде. Боларның барысы да коры сүз генә булып калмасын өчен, Болгар ханына битек язылды, битекне тапшыру өчен Алмыш ханга ырудан ун кеше илче итеп билгеләнде. Шул ук кешеләр хан катына кода булып та керергә тиешләр иде. Яңа йолага күчүдә Тотыш

би баш илче булса, аңа Аппакны ярәшүдә Майчан аксакал баш кода булды. Илчеләр-кодалар арасына Койтым бикәнең ире Котанны да керттеләр.

## XI

Кырларда-басуларда игеннәр өлгереп, урманнарда яфраклар саргая башлагач, көннәрдән бер көнне Тотыш би ерак юлга җыена башлады. Каекларны яхшылап төзәттерде, буятты, бизәтте. Ишкәкчеләр итеп ул үзенә бары яшь, таза җегетләрне генә алды. Шундый эшләрен бетергәч, ул калымга, бүләккә алып барасы товарларын каекларга төятә башлады. Болгар илендә өйләнгән барлык кешеләр ханга иярләнгән бер яхшы ат бирергә тиешләр иде. Шуның өчен дип көтүдән өч яшьлек җирән айгыр кайтарттылар. Айгыр өчен аерым каек җайланды. Калымга, бүләккә дип Тотыш би бер батман яңа бал алды, ун батман яңа богдай, тары алды. Төрлесеннән өч йөз тире, иллеләп чүлмәк, савыт-саба, дүрт төн[1] суккан юка киндер, бер кисмәк балык мае, ярты батман кипкән балык алды. Шуның өстенә төрле төзәнү-бизәнү яраклары: ырудашлары ясаган төрле беләзекләр, йөзекләр, алкалар, чулпы ише нәрсәләр, эш, сугыш кораллары алды. Акбүре җирендә нәрсә бар, акбүреләр ниләр ясый алалар — барысын да ул Болгар ханына күрсәтмәкче булды.

Җылы, изге бер таңда, Чулман аръягыннан алтын кояш чыгып килгәндә, Тотыш бинең байраклар белән, төрле төстәге ефәкләр, ат койрыклары белән бизәлгән, төрле төсләргә буялган унике каегы Кызыл Яр катау тамгасыннан кузгалып китте. Яр буендагы кешеләр, куллар болгап аны изге теләкләр белән озатып калдылар. Акбүре биләмәләрен узып киткәнче, Чулманның әле бер ягында, әле икенче ягында яр башларында җыелып торган төркемнәр күренде, байраклар җилфердәде, күңелле быргы тавышлары ишетелде.

Үз җирләрен узып киткәч, ят кешеләрнең кызыксынуын арттырмас  өчен, Тотыш би каеклардагы байракларны, төрле бизәкләрне алып куярга боерды. Уртасында аты, араны булган каекка ул чатыр корырга кушты. Чит ярлар арасыннан алар, утлар яндырмыйча, бары төнлә генә бардылар, көндезләрен исә берәр аулак елга тамагында, йә булмаса таллыкта, камышлыкта уздырдылар.

Шулай сакланып бара торгач, алар күп кенә авылларны, катауларны узып киттеләр. Иң куркынычы алда иде. Ул да булса, Шуран катау иде. Ямгырчы би иде. Болгардан Кызыл Ярга кайтканда Тотыш Шуран катау турысыннан төн уртасында гына, бик сакланып кына узып китте. Бу юлы да ул ничек тә шул турыдан ипләп кенә, тавыш-тынсыз гына ычкынырга уйлады.

Алар Шуранга капма-каршы яктан — Чулманның сул як яры буйлап китәргә булдылар. Куркыныч урынга җитәрәк, көндез алар яхшылап ял иттеләр, сугышырга туры килсә дип, коралларын җайлап куйдылар.

Күзгә төртсәң күренмәслек кара төндә тавыш-тынсыз гына яр читеннән йөзеп барганда, су өстендә әле анда, әле монда утлар кабынып китте, якында гына ниндидер куркыныч тавышлар ишетелде. Тирә-якта утлар торган саен күбәя барды. Алар ничектер бик җитез кыймылдадылар, чайкалдылар-тирбәлделәр, артка төштеләр дә, акбүреләрнең каекларын бар яктан да уратып алдылар.

Үзенең чолганышта калуын күреп, Тотыш бинең эче жу итеп китте. Ул үз каекларына бер тирәгәрәк тупланырга боерды.

— Ничек үләбез — сугышыпмы, сугышмыйча гынамы? — диде ул үзенең юлдашларына.

— Нишләп әле син үләргә ашыгасың, яшь би? — диде Майчан аксакал.

— Ямгырчы би — безнең кеше. Ул бездә кунакта булды,— диде Котан.— Безгә дә кунак булырга тырышып карарга кирәк.

— Тырышып карагыз, атай,— диде Тотыш би.— Мин инде кунак булдым анда... икенче тапкыр кунак булырга теләмим.

— Аларның көче күбрәк,— диде Торымтай.— Бу караңгыда без берни эшли алмаячакбыз.

Алар шулай киңәшкән арада, төрле яктан утлар белән ерткаланган төн бөркәнчеге астыннан сиздермичә генә утсыз каек килеп чыкты. Килеп чыкты да, ниндидер зур, көчле балык сыман җитез генә Тотыш би каегына таба килә башлады; сумалалы биек кырые белән акбүреләр каегының кызылга буялган борынына ышкылып алды. Аягүрә баскан Ямгырчы бинең куркыныч карачкысы караңгыдан чыгып, акбүреләрнең күз алдында ук күренеп китте.

— Исәнлек-саулык та сорашып тормыйча, кем китеп бара ул минем катау турысыннан? — дип кычкырды Ямгырчы би.

Шулай сөйләнгәләп, шәрә кылычына таякка таянган сыман таянып, ул җиңел генә акбүреләр каегына сикерде. Тотыш би кешеләре, нишләргә белмичә, аптырабрак калдылар. Ул да булмады, Ямгырчы би шакылдатып кылычын каек идәненә ташлады, кулларын җәеп, башта Тотыш бине кочаклады, аннары Котан белән Майчан аксакалга үрелде. Ул, ахрысы, кызмача иде. Акбүреләр, сөенергә дә, көенергә дә белмичә, берни эндәшмичә, баскан урыннарында катып тик тордылар. Беренче булып кылыч күтәрергә Тотыш бинең кыюлыгы җитмәде. Ямгырчы би белән булган ызгыш-талашка,

орышка инде күп вакыт үткән иде, тойгылар ничектер көчсезләнә төшкән иде. Кем белә аны, әллә Ямгырчы би элеккеләрне онытып та бетергәндер...

Биләре артыннан каекка тагын берничә кораллы казаяк сикереп керде. Алар да, бу төнге очрашуга бик тә куанган сыман, шаулашып, кычкырып исәнлек-саулык сорашырга тотындылар.

— Нинди эш бу? Оят кирәк азрак! Юк, юк, кунак итми җибәрмим,— диде Ямгырчы би, барысыннан да ныграк шаулап.

— Без ашыгабыз, би,— диде Тотыш, телгә килеп, эчке бер киеренкелек белән.— Без сине борчымаска уйлаганыек. Алмыш ханга калан илтә барабыз.

— Калан? Ха-ха! — диде Ямгырчы би, бөтен Чулманга шаркылдап.— Алмыш ханга калан түләргә атлыгып торучылар да булыр икән! Кайгырмагыз — ханга да, каланга да берни булмас. Әйдәгез, борылыгыз. Олы кунагым булырсыз, түрдә утырырсыз... Өйләр корылган, казан асылган, мунча ягылган. Юк, юк, беркая җибәрмим! Бал, кымыз җитәрлек, ит-май җитәрлек — түрдән узыгыз, кунаклар!

— Борылырга кирәк! — диде Майчан аксакал, Тотыш бинең эндәшмәвен күреп.

— Борылырбыз,— диде Тотыш би, теләр-теләмәс кенә.

**XII**

Каеклар уңга — Шуран катауга борылдылар. Ямгырчы би үз каегына чыгып тормады, кунаклар белән бергә китте. Озын колга башларында чытырдап янган утларын югары тотып, казаяклар алдан бардылар. Алар артыннан караңгы чырайлы кунаклар шуышты.

Иң алдан килгән каек яр буендагы субайларга килеп төртелү белән, ярдан шундук элмәкле аркан ташладылар. Басмадан беренче булып Ямгырчы би үзе төште, тешен кысып, аның артыннан Тотыш би атлады. Ярда алар, янәшә баскан килеш, сүзсез генә башка каекларның килеп җитүен көтеп тордылар.

Ул арада, олы кунакларга дип, каяндыр атлар китерделәр. Тотыш би үзе белән бары кодаларны-илчеләрне генә алды. Торымтай башлыгындагы кырык кеше яр буенда каекларда калды.

Кызыл Яр катау кебек Шуран катау да текә яр өстенә урнашкан иде, тик бу турыда яр өсте ергаланып бетмәгән, бәлки, ындыр табагы кебек тип-тигез иде. Шуңа күрә, капкага керү өчен ерактан әйләнеп йөрисе юк иде. Катау капкасы янында гына, яр буенда гына иде.

Ташлы сөзәк юлдан югарыга менеп җиткәч, Тотыш би түзмәде, артына борылып аска карады. Төн уртасы узган иде инде. Аста тып-тын булып, агарып Чулман җәелеп ята иде. Ах, шулай да ялгышты бугай ул! Күбрәк көч белән төшәсе калган, бөтен бер чиру белән! Үз язмышыңа кирәгеннән артык ышанмыйсың микән, Тотыш углан... Тотыш би?

Менә арттагылар да менеп җитте. Төркемләшеп, күпер агачларын дөпелдәтеп, алар койма буендагы тирән урлар аша чыктылар, тешсез авызын зур ачып утырган капкадан да үттеләр. Ямгырчы би үзенең кунакларын тар гына урамнан алып китте. Бер ярты чакрым чамасы баргач, алар икенче күпер алдына килеп җиттеләр.

— Менә монысы минем урдам,— диде Ямгырчы би.

Борчулы, сак, тынычсыз юлчылар соңгы күпер белән соңгы капкадан керделәр. Керделәр дә иркен, тигез ишегалдына тарала бардылар. Каршыда, ишегалдының яр ягындагы почмагында, караеп биек агач өй күренде. Агач өйдән сул яктарак, шулай ук караеп, төркемләшеп очлы башлы киез өйләр кабарып утыра иде.

— Нишлисез, кунаклар, башта мунча кереп аласызмы, әллә ашап-эчеп аласызмы? — диде Ямгырчы би.

— Йокыдан да яхшысы булмас безгә,— диде Тотыш би.

— Сез теләгәнчә булыр! — диде Ямгырчы би, бик тиз килешеп.

«Ашы да, мунчасы да юк. Юри сөйләнә»,— дип уйлады Тотыш, эче пошып. Чыннан да, урда каты йокыга талган иде, бер яктан да аш-су исе, төтен исе килми иде. Бары тик көзге коры салкында аерата кискен булып, борыннарны ярып, тирләгән ат, җылы тизәк исе аңкый иде.

Ямгырчы би кунакларның барысын да аерым-аерым өйләргә урнаштырды. Акбүреләр караңгы, ят өйләргә керсәләр дә керделәр, кермәсәләр дә керделәр. Шулай да, башлары мендәргә тию белән, шундук йокыга киттеләр. Алар төш җиткәнче йокладылар.

Тотыш би кисәк кенә уянды, өйдә үз янында нииндидер чит кеше барлыгын тоеп, сискәнеп, куркып уянды. Күзләрен ачып җибәргән иде, үзенең аяк очында, үз ятагында елмаеп утырган Тәңкәне күреп, тынсыз калды.

Тәңкә аңа картайган, ямьсезләнгән шикелле күренде. Шул ук озынча ак бит, атасыныкы төсле калын кашлар, тынгысыз коңгырт күзләр, шул ук чандырлык, юкалык.

— Исәнме, Тотыш,— диде Тәңкә, балкып.— Бу мин — Тәңкә. Әллә танымыйсың?

— Таныйм,— диде Тотыш би, башын калкыткандай итеп.

— Торма,— диде Тәңкә.

Кискен генә кыланып, кабаланып, ул өстендәге киемен салып ташлады, ябу-тунның читен тартып җибәрде. Салкыннан туңган сыман калтырана-калтырана, көлештергәләп, песи кебек ул Тотыш янына кереп ятты. Ятты да, очлы терсәкләре, тез башлары белән кунакның әле бер җиренә, әле икенче җиренә орынгалап, аякларын сузды, аның биленә, аркасына үрелде. Ояда утырган каз кебек, бертуктаусыз урынын ипләде — әле ябу тунын калкытты, әле итәген җыештырды. Тотыш, аның шулай анадан тума шәрәлегенә дә, өтеп алырдай кайнарлыгына да, песи баласыдай мыр-мыр килүенә дә әз генә дә исе китмәгән сыман, сагаеп, үлек кебек кымшанмыйча ята бирде.

— Тотыш, ник берни эндәшмисең? — диде Тәңкә, аның борынына кайнар тынын өреп.— Йокың туймадымыни?

— Туймады бугай шул,— диде Тотыш.

— Син мине исеңнән чыгармадыңмы? — диде Тәңкә, иркәләнгәндәй итенеп.

— Юк,— диде Тотыш.

— Мин сине көттем. Ике ел буе көттем, Тотыш,— диде Тәңкә, калтыранып.— Таң аттымы, күзем Чулманда булды. Кайтканда кермәгәнсең. Бик үпкәләдем сиңа, Тотыш. Җыладым, көн-төн җыладым. Артыңнан куа китмәкче булдым — атай җибәрмәде. Ник кермәдең шунда?

— Менә... кердем ич.

— Кердең? Син мине алырга килмәдеңмени?

Тотыш урыныннан кузгалып куйды, нидер әйтмәкче булды. Теле әйтерсең аңкавына ябышып калды — әйләнмәс булды. Кылыч белән чабып төшерелгәндәй булып, авыр башы кире ятагына ауды. Ташка, бозга әйләнгән йөрәгендә бары бер генә тамыр тыпырчынды. Тимер кебек авыр кулын көчкә күтәреп ул Тәңкәнең биленә салды. Моның белән нәрсә аңлатырга теләгәнлеген ул үзе дә төшенеп җитмәде. Күңелендә аның, ахрысы, кызгану тойгысы баш калкытты. Ул, ахрысы, аны юатмакчы булды. Ул аны, билгеле, яратмый иде. Юк, ул аны тамчы да яратмый икән. Шулай да ул аны болай гына, җиңел генә читкә дә сыпырып ташлый алмый иде, ахрысы. Кайсыдыр ягы белән, кайсыдыр саны белән ул — Тәңкә — аның күңеленә бик нык сеңеп калган иде. Ул аның яшьлеге иде, тиле, татлы... кайгылы үткәне иде. Шул үткәннең бер китеге, бер кечкенә истәлеге иде. Ничек соң аның күңелен кырмыйча гына, ипләп кенә аңа шул турыда әйтеп бирергә икән?

— Мин Алмыш ханга калан илтә барам,— диде ул, әкрен генә сүзгә башлап.

Яшь хатынның көләч йөзе сүрелеп калды, уттай кайнарлыгы, өреп сүндергәндәй, юкка чыкты. Чандыр беләген Тотышның биленнән алды да, арты белән борылып, йомарланып, читкә шуышты. Битен куллары белән каплаган көе, бөтен аркасын, иңбашларын калтыратып, бөтен ятакны селкетеп, җыларга тотынды. Тотыш, өстенә таш бастырып куйгандай, кымшана да алмыйча, үзалдына сызланып, пошынып, тып-тын гына ятты да ятты.

Бозга әйләнгән күңел бик озак яткач кына эри башлады. Өстендәге авыр ташны читкә этәреп, Тотыш аның ягына әйләнде, аның нечкә биленнән кочып, юатып:

— Җылама, мин сине дә алырмын,— диде.

— Мине дә?! — диде Тәңкә, җылавыннан туктап.

— Сине дә...— диде Тотыш, кыюсыз гына.— Мин би булдым. Миңа үлгән атамның хатыннары калды.

— Шул гынамы? — диде Тәңкә.

— Шул гына,— диде Тотыш, тотлыгып.

— Каектагы атны кемгә алып барасың? — диде Тәңкә, күз яшьләре аша аңа карап.

— Калан өчен... Алмыш ханга,— диде Тотыш, ялганлап.

Тәңкә кинәт өстендәге ябынгычын атып бәрде. Сикереп урыныннан торды, күлмәкләрен, читекләрен киде, чулпыларын төзәткәләп куйды.

— Мин барысын да беләм! — диде ул коры, усал итеп.— Мин сине ике ел көттем. Суар Килдеш бинең кече углыннан баш тарттым, угыз ябгуыннан[1] баш тарттым. Мин сине көттем. Син — икейөзле!

Корт чаккандай, Тотыш та кинәт сикереп торды.

— Минме икейөзле?! — диде.

— Син! Син! — диде Тәңкә.— Балыкчы куышында кайгылы төннәреңне уртаклашканда Тәңкә кирәгие, инде би булгач Алмыш хан кызы Аппак кирәк булган! Канечкеч... килмешәк... капкорсак ханның юха җыланы кирәк булган!

Тотыш агарынып китте, әйтерсең искәрмәстән кемдер яңагына китереп сукты, әйтерсең искәрмәстән кемдер битенә төкерде... әйтерсең кемдер аны ләпеккә, пычракка төртеп екты! Кинәт ул ыргактай куллары белән чандыр хатынны эләктереп алды да чүлмәк кебек итеп, агач кебек итеп ятакка орды.

— Икенче телеңә аласы булма! — диде ул, ярсуына буылып.

Тәңкә сырты белән төште. Ятак дөп итеп китте. Ни булганын аңлый алмаган яшь хатын: «Ай!» — диде дә өнсез калды. Исенә килә алмыйча ул бик озак ятты. Аннары ыңгырашып куйды, чыраен сытты. Авырлык белән генә урыныннан торды, арты белән шуышып идәнгә басты, билен турайтты.

— Ярар, икенче әйтмәм,— диде салкын гына.

Башын югары тотып ул өйдән чыгып китте.

## XIII

Кичкә Ямгырчы би кунакларга аш-су ясады. Нараттан салынган биек өйнең искиткеч итеп бизәлгән иркен, биек бүлмәсендә карамайлы пыскыйлар түгел, көмеш шәмдәлле балавыз шәмнәр янды. Эстинәләрдән, киң түшәмне тоттырып торган терәкләрдән, төрле төстәге ефәкләр, атласлар асылынып торды. Тигез идәндә, төрле бизәкләре белән елмаеп, җемелдәп, бай келәмнәр сузылып ятты. Кунакларга утырырга чигүле йомшак мендәрләр куйдылар. Кыздырылган итне сырлап ясалган авыр алтын табакларга салып китерделәр, ачы балны, кымызны бары алтын аякларда гына бирделәр. Би үзе дә, хатыннары, балалары, туганнары да, алай гына түгел — аш-су ташучы кешеләре дә — барысы да бай, ят киемнәр кигәннәр иде. Аларның үз-үзләрен тотышында да, сүзләрендә дә ят кыланышлар, ят сүзләр чалынып кала иде. Кунаклар моны бик тиз күреп, сизеп алдылар. Ямгырчы бинең бар нәрсәдә мосылманнарга охшарга тырышуын аңлавы бер дә читен түгел иде.

Ни генә булмасын, Ямгырчы би ярлы яшәми иде! Моннан ике ел элек кичү янында болгарлар белән бәрелештә җиңелеп, күп талау күрсә дә, тиз арада ул аякка басты. Үзенең бик каты оттырганлыгын аңлап, Алмыш хан алдында аклану өчен, ул аның казаяклар талаган, теләсә кайда таралган байлыгын үзенә җыйдырды. Чулманны боз токкач, баш иеп, хан катына китте. «Ялгышлык белән булды, кичер, ханым»,— диде. Үз кешеләре талаган күп кенә байлыкны ул Алмыш ханга кире кайтарып бирде. Чынында бу — таланган байлыкны кире кайтарып бирү түгел, җиңелгән өчен өстәмә калан булды. Алмыш ханның да Ямгырчы бидән колак кагасы килми иде. Ник дигәндә, Чулманның йозагы — кичү аның кулында иде. Аннары, ул инде күптән мосылман диненә күчкән иде. Би китергән каланның яртысын ул аңа түләнмәгән кулбау өчен дип бирде. Алмыш хан янына үләмме, каламмы дип барган Ямгырчы би баеп кайтты. Аның әле болгарлардан таланган байлыкның үзендә яшереп калдырганы да җитәрлек иде. Шулай итеп, тоттырмас, шома би берьюлы аякка басты куйды.

Казаяк ыруының башы ничек тә кунакларының күңелен табарга тырышты. Ашаган-эчкән арада көйчеләр төрле көйләр уйнадылар. Аштан соң ул үзенең чит илләрдән китертелгән ят җырчыларын, биючеләрен чыгарды. Алар мондагы кешеләргә аңлашылмаган телдә, җылаган сыман сузып, кычкырып, ниндидер җырлар җырладылар, күңелләрне тетрәндереп, шашкын биюләр биеделәр.

Төн урталары якынлашыр алдыннан, ашап-эчеп, күңел ачып туйгач, би үзенең кунакларын мунча керергә алып китте. Мунчада кунаклар ят нәрсәләрне тагын да күбрәк күрделәр.

Мунча нык итеп, иркен итеп таштан салынган иде. Башта акбүреләр җыйнаулашып чарачага[1] керделәр, шуннан соң шәмнәр белән яктыртылган икенче бер бүлмәгә уздылар. Мунчачы ирләр аларга чишенергә булыштылар. Чишенү, утырып ял итү өчен билгеләнгән бу салкынча бүлмәдән ирләр чабыну, юыну бүлмәсенә керделәр.

Әллә болыт булып түшәмгә эссе бу күтәрелгәнгә, әллә почмаклардагы шәмнәр көчсез янганга, монда шулай да караңгырак иде. Үз мунчасын яхшы белгән Ямгырчы би алдан атлады, кунакларга кайда юынырга, кайда чабынырга кирәклеген аңлатты. Күзләре иялңнә төшкәч акбүреләр үзләре дә күрделәр: сулда, идән уртасындарак, эре ташлардан өелгән учак калкып тора иде: учак янында чабыну өчен баскычлап биек сике корылган иде. Уң якта, эстинә буенча, озын утыргыч сузылган иде.

Ямгырчы би кунакларны кычкырып үз янына чакырды. Учакның икенче ягында имән бүкән калкып тора иде. Ямгырчы би кулындагы агач табакны шапылдатып бүкән өстенә куйды, югарыдан сузылып торган җиз көпшәнең бөкесенә тотынды да:

— Күрәсезме менә моны? — диде.

Шулай дип әйтүгә, ул агач бөкене тартып та җибәрде — көпшәдән шаулап кайнар су ага башлады. Агач табак яртылаш тулгач, би икенче яктан сузылган икенче көпшәнең бөкесен ачты — монысыннан салкын су агарга тотынды. Кунаклар, таң калып, телләрен шартлаттылар, көпшәгә бармакларын тидереп-тидереп карадылар.

— Күрдегезме! — диде Ямгырчы би, мактанып.— Мондый мунча Алмыш ханда да, Суарда да, Биләрдә дә юк. Итил-торада үзем күреп кайттым, үзем ясаттым. Үз бакырчым ясады барысын да. Суны күрше бүлмәдә казанда кайнатып торалар. Салкын су да шуннан килә. Инде карагыз монда!

Кунаклар, тагын ни белән шаккатырыр инде бу, дисәләр, би аларга идәнгә карарга кушты. Анда, идәннең урта бер җирендәрәк, чокырланып торган бер төшендә, әрлән төннегә сыман тишек күренде.

— Юынты сулары шуннан агып китә,— диде Ямгырчы би, аңлатып.— Чүлмәк көпшәләр буенча җир астыннан Чулманга коела. Чишмә суы да җир астыннан көпшә буенча килә.

— Бар икән баш үзеңдә дә! — диде Майчан аксакал, бине мактап.

— Юк түгел алай,— дигән булды Ямгырчы би кеткелдәп, күңеле булып.

— Чабынырга миллегең бармы соң? — диде Котан, кашынып.

— Булыр,— диде би.

Үрелеп ул ниндидер бауны тартты — арткы салкынча бүлмәдә тонык кына булып кыңгырау тавышы ишетелде. Ишектән баягы мунчачы ирләр килеп керде. Алар, ни дә булса әйткәнне көтеп тормастан, учак янына килделәр. Берсе, кайнар ташларга җиз чүмеч белән су сибеп, каен миллеге пешерде, икенчесе, кулына сабын, мунчала тотып, кунакларның аркасын ышкырга җыенды.

— Башта син чабын,— диде үги ата Тотыш бигә.

— Бар әйдә, чабын,— диде Тотыш.

**XIV**

Мунчадан кайтуга, түрдә елмаеп утырган Тәңкәне күреп, Тотыш бераз гына аптырап калды. Ул аны көтмәгән иде. Ул аны бик нык ачулангандыр дип, шуңа күрә чынлап та инде беркайчан да килмәс дип уйлаган иде.

Берни эндәшмичә, ашыкмыйча, ул киемнәрен алыштырды, нидер эзләгән сыман, анда сугылды, монда сугылды.

— Утыр, арыгансыңдыр,— диде Тәңкә, көлеп, үз яныннан урын күрсәтеп.

Тотыш бернинди каршылыксыз йомшак урынга килеп утырды.

— Син инде беләсең, шулай булгач...— диде ул, сүз башларга тырышып.

Тәңкә, елмаеп, аңа якынрак күченде, ике куллап аның муеныннан кочып алды да түбән иелгән күзләренә карады.

— Нәрсә «шулай булгач»? — диде ул, үчекләшкән сыман.— Тагын күтәреп ормакчы буласыңмы? Ор! Мин синең хатының. Мин сине барыбер бирмим. Бирмим!

Көлеп, кабаланып, ул аңа ныграк елыша барды. Озын толымнары белән юри аның муенын уратып алды, кечкенә бармаклары белән аның бармак очларын тоткалады; думбыра кыллары чиерткән сыман, аның турсайган иреннәренә кагылгалап алды.

— Ник килдең? — диде Тотыш, ачуланган сыман итенеп.

— Сөйләшер өчен,— диде Тәңкә.

Ялт кына ул аягына басты, озын толымнарын салындырып, ишеккә таба атлады. Тышта беравык югалып торганнан соң, ул яңадан өйгә керде, кире үз урынына килеп утырды.

Шуннан соң күп тә үтмәде, өйгә өлкән яшьтәге бер хатын килеп керде. Кулына ул яшь бала тоткан иде. Баланы иркәләп сөя-сөя, нидер сөйләнә-сөйләнә, ул яшьләр янына килде. Тотышка ничектер кырын күзе белән генә карап алды да баланы Тәңкәгә тоттырды.

— Әннә! Әннә! — диде бала, яшь хатынның борыныннан эләктереп.

Батыр гына кыланып, ул әннәсенең тезенә менеп утырды, ике куллап аның күкрәген тотып алды. Идәндә нидер күреп, көлеп җибәрде, җитез генә кире идәнгә төште дә аннан бер чүп кисәге табып алды.

— Кәкәй, ташла! — диде әннәсе.

— Ы, кәкә? — диде бала, аның күзенә карап, бик нык аптырап.

Тотыш, берни эндәшмичә, аның кыланышларын күзәтеп утырды. Ул эндәшә алмады. Аптырауның, таң калуның ул соңгы чигенә җитте. Имеш, аның улы бар. Тотыш бинең беренче углы. Бөтен дөньяда йөзләгән, меңләгән, төмән кешеләр арасында яңа бер кеше... ике аяклы, ике куллы, күзле, борынлы чын кеше!

— Без сине икәүләп көттек, әттә! — диде Тәңкә юаш кына, углы булып.

— Ни... ыы, ни атлы? — диде ата кеше.

— Атым минем — Күке! — диде әннә углы өчен.

— Күке? Шундый ямьсез ат кушалармыни?

— Атайга карап куштык,— диде әннә, елмаеп.— Телисең икән, без аңа Куаныч-Бога кушабыз. Мәле, мине тотып кала, әттә! Нинди таза, нинди көчле мин! Белеп тол, әннәне кыелсытсаң, үскәч мин синең якаңнан алылмын! Алып булыл бу! Куаныч-Бога алып!

Тотыш, баланың берәр җирен имгәтүдән куркып, иплән кенә, сакланып кына аны кулына алды, тезенә бастырды. Күке-Куаныч-Бога, шыңшып, киреләнеп, анасы ягына тартылды. Аның нәни көчен тоеп, аның йомшак тәпиләрен, кулларын тоеп, Тотыш көлеп җибәрде. Ныграк ачуландыру өчен ул аны юри күкрәгенә кысты, аның уймактай борынын, алсу колакларын тоткалады. Кәкре аякларын атасының тезенә терәп, бала бар көченә карышты, ачуланып, үртәлеп кычкыра ук башлады.

— Хи-хи! Нинди батыр! — диде ата кеше, кеткелдәп.

— Атаң ич,— дигән булды Тәңкә, углына эндәшеп.— Ул әннәне оныткан, син дә аны оныттыңмы әллә?

— Мин «әннә»не онытмадым,— диде Тотыш.— Әннәсе дә, углы да... үземнеке!

— Тотыш?! — диде Тәңкә, аның күзләренә карап, аның чынмы, юриме әйткәнен белергә тырышып.

— Әйе,— диде Тотыш.— Сүзем сүз: сине дә, углымны да беркайчан ташламам!

— Тотыш! — диде тагын да Тәңкә, шашынып, куанып.

Бер кулы белән углын, икенче кулы белән ирен кочаклады да, җылый-җылый, көлә-көлә, алмаш-тилмәш икесен дә үбәргә тотынды.

**XV**

Шулай итеп, бер яшьлек тә берничә айлык Күке... Куаныч-Бога беркемгә дә баш бирмәгән кырыс атасын аяк астына салды да куйды. Тотыш бинең Болгарга, Аппак янына ашкынган какшамас күңелендә нидер кинәт кителеп төшкәндәй булды. Нык тартылган керештәге укны ул әйтерсең кире алды. Йөрәгендә дөрләп янган сөю ялкынын ул әйтерсең туны белән каплап куйды.

Кызы белән Тотыш би арасындагы татулашуны белеп, Ямгырчы би күз алдында үзгәрде. Ясалма куанычы, ясалма кунакчыллыгы шундук юкка чыкты. Кунаклар өчен яңадан симез сарыклар суйдырды, базларыннан, чокырларыннан чит илләрдән килгән иң яхшы эчемлекләрен — йөзем суларын чыгартты, көн-төн мунчасын җылы тотты. Өч көн буена кунаклар балда-майда йөзделәр, өч көн буена Тотыш би Тәңкә белән татлы бал эчте.

Дүртенче көнне аның өенә — Тәңкә югында — Майчан аксакал белән субашы Котан килеп керде. Йокысы туймаган, бите җилсенә башлаган Тотыш би алар кергәндә йомшак урында ята иде.

— Углым, Тотыш би, без сиңа киңәшкә килдек,— диде Майчан аксакал, сүзгә башлап.

— Нинди киңәш тагын? — диде Тотыш, теләмичә генә.

— Киңәш дип... үзара сөйләшергә,— диде Котан.— Синең безне тыңлар җаең бардыр ич?

— Сөйләшик,— диде Тотыш, урыныннан торып.

— Тотыш би, углым,— диде Майчан аксакал, өч бөртек сакалын сыйпаштырып.— Безгә нидер эшләргә кирәк.

— Нишләргә? Берни аңламыйм,— җүнләп сөйләгез, Майчан аксакал,— диде Тотыш би.

— Без менә үзара киңәштек тә сиңа әйтмәкче булдык,— диде үги ата.— Моннан ары икеле-микеле яту ярамас безгә. Без менә киңәштек тә... Тәңкәдә синең углың бар, атабыз Күрән бинең — урыны оҗмахта булсын! — Ямгырчы бигә биргән сүзе бар. Инде менә уйларың да үзгәрде кебек. Ямгырчы бигә кода булып керик тә, калымны түлик тә, кайтыйк та китик! Алмыш ханга никтер аяк тартмый. Яңа йоланы көчләп тагуы да эчне пошыра. Майчан аксакал әнә яман төшләр дә күргән.

— Шулмы сүзегез? — диде Тотыш би.

— Шул, Тотыш углан, би,— диде Майчан аксакал.— Инде болай-болай булган икән, татулык белән... кхм... элеккеләрне онытып...

— Ярар,— диде Тотыш би, килешкән сыман...— Тәңкә — минем хатыным, Куаныч-Бога — минем углым. Сүземне әйткәнмен икән, мин аларны алып кайтырмын. Тик минем Аппакка да, Алмыш ханга да биргән сүзем бар! Анам Койтым бикәгә, туган ыруыма биргән сүзем бар! Әйтегез — нишләргә?

— Алмыш ханга да, Ямгырчы бигә дә түләргә безнең калым җитәрлек түгел,— диде үги ата.— Безгә икенең берсен сайларга кала. Без сайладык. Безгә Ямгырчы би белән аның кызы кулай.

— Акбүре ыруы да, анам Койтым бикә дә Ямгырчы бине түгел, Алмыш ханны сайлады! — диде Тотыш би.— Аннары мин Аппакны яратам!

Майчан аксакал белән Котан бер-берсенә карашып алдылар.

— Яратасың? — диде Котан.— Нинди ярату ул? Алмыш хан сине алыштырып җибәрмәгәндер ич?

— Алмыш хан алыштырмады, менә монда сез алыштырмакчы буласыз,— диде Тотыш би, чыраен сытып.

— Бер дә алыштырмакчы булмыйбыз, улым,— диде Майчан аксакал.— Күрән би сине Ямгырчы би кызына өйләндерергә тиешие.

— Юк, иң элек ул мине Биар ханының кызына өйләндермәкче булганые,— диде Тотыш би.— Атам үлгәнгә инде өченче ел. Шулай да сез аның Ямгырчы бигә биргән сүзенә тотынып калмакчы буласыз. Сез минем сүзгә, анам сүзенә, туган ыруым сүзенә түгел, үлгән атай сүзенә колак саласыз. Мин — би! Әле булса сез миңа ышанмыйсыз, әле булса минем иркемне кысасыз, сүземне, теләгемне санга сукмыйсыз. Ыру җыены алдында, анам алдында биргән сүзегезне онытып, бүгеннән үк сез миңа тышау салмакчы буласыз. Ник?! Минем үземнең өйләнәсем килә... Үзем яраткан кызга өйләнәсем килә! Атам кушканга да түгел, сез кушканга да түгел — үзем теләгәнгә! Ярамыймыни? Йола кушмыймыни? Атам сүзе тотармы? Минем Аппакка, Алмыш ханга, анама, ыруыма биргән сүзем тотса? Кайсы яманрак — атам сүзен тотмаумы, әллә үз сүземне тотмаумы? Үз сүземә үзем баш була белмәгәч, нинди би булырмын соң мин? Төшендереп бирегез миңа!

— Алай булгач, ник җебеп төштең соң монда? — диде үги ата.— Алмыш ханга биргән сүзеңнән курыккач, Ямгырчы бидә кунак булып ятасы да юк!

— Нинди белекле! — диде Тотыш би.— Төн уртасында Чулманда каекларымны чолгап алырга әллә мин куштыммы Ямгырчы бигә?! Үземне төрлечә алдарга-юлдарга әллә мин куштыммы?!

— Тәңкәне алып качарга әллә мин куштыммы?! — диде Котан, мыскыл белән.

— Нәрсә?! — диде Тотыш, агарынып.

Котан да бер дә юктан кабынып, шундук коралына ябышты.

— Урыныңнан кузгалып кына кара! — диде Тотыш әкрен генә, үтемле итеп.— Мин сиңа Тотыш углан түгел; Тотыш би булырмын, атай!

Үги ата, кулын кылычыннан алып, кире чигенде.

— Без сиңа әйттек, Тотыш би,— диде Майчан аксакал, тамагын кыргалап.— Калганын үзеңчә эшлә. Кхм... Бездә ирек.

— Үземчә эшләрмен! — диде Тотыш.— Иң элек Аппакны алып кайтам, Тәңкә белән улымны — соңыннан. Өлгерсәм — быел, өлгермәсәм — җәрингә.

Шул ук сүзләрне ул Тәңкәгә дә әйтте.

— Син әле дә онытмадыңмыни аны? — диде Тәңкә, арты белән борылып, төшенке генә.

— Көн дә җир өстенә чыга торган кояшны онытып буламы? — диде Тотыш.

— Ул, алайса, синең өчен — кояш? — диде Тәңкә, никтер тыныч кына.

— Кояш!

— Мин кем?

— Син... син — ай!

— Минем... ай буласым килми,— диде Тәңкә, шул ук салкын бер төшенкелек белән.— Минем сиңа кояш буласым килә, Тотыш!

— Күктә ике кояш булмый,— диде Тотыш, көлгән булып.

— Әйе, күктә бер генә кояш була,— диде Тәңкә, әкрен генә.

— Мине ыру җибәрде. Мин ыруга, анама каршы килә алмыйм,— диде Тотыш.

Шулай дигәндә ул үзенең никтер кызарынуын, уңайсызлануын тойды.

Тәңкә эндәшмәде, кырт кына читкә борылды да, яшьле күзләрен күрсәтмәскә тырышып, иреннәрен тешләп, урыныннан торды һәм ашыгып-кабаланып өйдән үк чыгып китте. Шул китүдән ул бүтән килмәде. Тотыш би, беркая чыкмыйча, беркемне күрмичә, төне буе, көне буе үз өендә аунап ятты. Икенче көнне кич, караңгы төшкәч, аны Ямгырчы би янына чакырдылар.

## XVI

«Үгетләмәкче була микәнни?» — дип уйлады Тотыш Ямгырчы би турында. Алдан ук ул аның белән буласы сөйләшүен күз алдына китерде. Кунак булып яткан дүрт-биш көн эчендә ул инде Казаяк ыруы башы белән үз арасында булган элекке ызгышларны, сугышларны — барысын да онытып өлгергән иде. Соңгы көннәрдә аның уенда бары тик ул үзе дә, Тәңкә белән улы гына иде. Аныңча ата кеше — Ямгырчы би — кияү кешене якларга тиеш иде. Тәңкәне генә яратамы, Аппакны да яратамы аның кияве — аның өчен барыбер булырга тиеш кебек иде. Тик Тәңкәнең атасы бөтенләй ул уйлаганча булып чыкмады.

— Ха-ха! — дип кычкырды ул, Тотышны күрү белән.— Бу синмени әле, Тотыш би? Бик сагынып көттем мин сине, ике ел буена көттем шушы очрашуны. Кызым Тәңкә кебек саргаеп көттем, Тотыш алып. Син инде тынычландыңмы, онытты бу барысын да, дип уйладыңмы? Онытмыйча! Шундый олылап каршыладылар, көне-төне сыйладылар. Җитмәсә, күңел ачарга дип, Ямгырчы би аңа үзенең кызын биреп торды. Үз кызын, үзеннән туган бердәнбер кызын биреп торды! Ха-ха! Алмыш ханга калан илтә баручы сылу җегетнең күңеле кырылмасын, каны бозылмасын... Шулай булмыйча, гүзәл Аппакны алырга бара ла ул!

— Туктале, би,— диде Тотыш, мыгырданып, кашларын җыерып.

— Туктарга?! — дип кычкырды Ямгырчы би, төкерекләрен чәчеп.— Мин инде күп тукталып тордым. Яз көне мин синең кайчан узып китәсеңне яхшы белдем, шулай да тукталып калдым. Калым белән, байлык белән төшүеңне көттем. Инде менә монысында эләктереп алдым. Шулай да әле утлы табада кыздырып ашамадым — тукталып калдым. Кызымның сүзен тыңладым. Аның өчен түздем. Бары аның өчен генә! Инде түземлегем төкәнде. Кызым миңа барысын да сөйләде. Кызым минем кулларымны чиште. Ха-ха! Тотыш алып! Кияү! Телим икән — кыздырып ашыйм, телим икән — итеңне каклап куям, телим икән — балыкларга, кош-кортларга җим итеп сибәм!

— Син шашкансың, би,— диде Тотыш, ачусыз күренергә тырышып.

— Ха-ха! — диде Ямгырчы би, йодрыкларын селтәп.— Шашмый торсын! Син әллә чынлап та үзеңне Алмыш ханга җибәрерләр дип уйлыйсыңмы? Акбүре белән туганлашып Алмыш ханның тагын да көчәюенә юл куярлар дип уйлыйсыңмы? Юк, булмас! Юл ябык. Синең антыңны бозганыңны да онытканнардыр дип уйлыйсыңмы?

— Син үзең боздың, би! — диде Тотыш би, кылычына тотынып.

— ...Казаякларны чебеш урынына кырганыңны онытканнардыр дип уйлыйсыңмы?! — дип кычкырды Ямгырчы би аның сүзләрен ишетмичә.— Алар барысы да менә монда — йөрәк түрендә! Кызымны инде мин әйтмим дә. Моңарчы сине ул яклап килде. Инде син аның табанын ялап ярлыкау

үтенсәң дә, сине якларга аның да көченнән килмәячәк. Ул соңгы сүзен әйтте. Сине этләр җыячак, Көчек би!

Тотыш белән Ямгырчы би арасында өч-дүрт адымлык буш урын бар иде. Шул өч-дүрт адымлык буш урында, уртада, кып-кызыл булып, дүрткел палас җәелеп ята иде. Ямгырчы би авызыннан утлар чәчеп тузынганда Тотыш ничек тә аннан читтәрәк булырга тырышты. Аннары уртадагы әлеге палас та ике араны бүлеп тора шикелле тоелды. Ямгырчы бинең мыскыллы янаулары соңгы чиккә җиткәч, Тотыш түзмәде, кылычын суырып чыгарды да...

— Ха-ха! — дип шаркылдады явыз би, баш очындагы ниндидер җепкә үрелеп.

Тотыш аның шул соңгы «ха-ха»сын гына ишетте дә, коточкыч булып кыйшайган усал йөзен, акайган күзләрен генә күреп калды. Аяк астындагы палас кинәт убылып китте. Ямгырчы бигә җитәргә бер-ике адым калды дигәндә, кылычын күтәргән Тотыш каядыр аска, караңгыга ычкынды. Кинәт ачылып киткән баз капкачы шундук кире ябылды. Яктылык сүнде. Ул әйтерсең мәңгегә, бөтенләйгә юкка чыкты.

Тотыш бинең үз өендә юклыгын күреп, акбүреләр пошына башладылар. Алар, катау иясе янына барып, аңа шул турыда сөйләмәкче булдылар. Тик алар бу теләкләрен үти алмадылар: Ямгырчы би кешеләре килеп, берни әйтмичә, аларның коралларын җыеп алдылар, өйдән беркая чыкмаска боерып, китеп тә бардылар. Ямгырчы би шулай ук яр астындагы акбүреләрне дә коралсызландырды, каекларны, кешеләрне сак астына алды. Бинең мондый яманлыгын акбүреләр ничек дип аңларга да белмәделәр. Алар шауладылар, янадылар, соңыннан ялына башладылар.

— Ха-ха! — диде Ямгырчы би.

Шулай итеп, каптылар... тәбегә төшкән сычканнар кебек каптылар!

## XVII

Каптылар... Ләкин Тәңкә үзенә бернинди ямь, кызык тапмады. Эче пошып, Күкесен күтәреп ул койма өстенә менде, Чулманга карап тора башлады. Ул аны менә шулай көтте. Көн дә таң ату белән, баласын кочты да койма өстендәге үзенең җайлы урынына менеп утырды. Үзенең Күкесенә ул башта «әттә» сүзен өйрәтте, аннары «әттә»нең кем булуы турында сөйләде, аның батырлыгын, матурлыгын мактады. Шулай сөйләнгән, юанган арада, ул әледән-әле су өстенә карап алды.

Элек әле ышаныч бар иде. Менә-менә еракта караеп зур, ят каек күренер дә, зур-зур атлап, елмаеп каектан «әттә» чыгар төсле иде, биек коймага үрелеп, үзенең улын, нәни Күкесен тотып алыр төсле иде. Күз алдына татлы күренешләр килә иде, күңел, очар коштай, канат җилпи иде.

Инде алар барысы да юкка чыкты. Чулман өстендә ят каек та күренмәячәк, аннан зур-зур атлап батыр «әттә» дә чыкмаячак. Аның бик нык эче пошты. Үз-үзенә урын таба алмыйча, ул өенә кайтып китте. Өендә дә аны салкын бушлык, эч пошу, сыкрау каршы алды. Аңа тик нәни улы гына, улының йөрәк җылысын, тынын, күз карашын тою гына күпмедер тереклек көче биреп торды. «Әттә? Әттә?» — диде бала, кечкенә кулы белән әнкәсенең борыныннан тотып. Яшь ананың күзләреннән чишмә булып яшьләр акты.

Ике тәүлек буена ул шулай үз-үзе белән, үзенең теләкләре, тойгылары белән тарткалашты. Ике төн буена ул йокы күрмәде, ике көн буена тынгы белмәде. Өченче көнне барысы да баш-аяк килде. Ул үзенең янында гына булган, шундый көтеп алынган, сагынып алынган иреннән аерым яши алмаганлыгын аңлады. Ул, барысын артка ташлап, эченә йотып караңгы төшү белән иренең ялгыз өенә китте.

Өй буш иде. Ул аны көтеп торды. Тотыш кайтмады. Шунда ул барысын да аңлап алды. Кызып китеп, атасына әләкләгәндә, ул аны аз гына да кызганмаган иде. Инде аның юклыгын күргәч, ул куркудан шашар чиккә җитте. Ул коелды да төште. Ул буш, куркыныч өйдән шундук чыгып китте, үзенең ышанычлы кешеләрен эзләп тапты. Алар аңа барысын да түкми-чәчми сөйләп бирделәр. Кинәт аның йөрәге бөтенләй икенче төрле тибә башлады, буталган, суынган каны бөтенләй икенче юнәлештә ага башлады. Үзендә ул искиткеч җиңеллек, күңел аеклыгы, күңел бөеклеге тойды. Бөтенесен ул ап-ачык итеп күз алдына китерде, бөтенесен җентекләп уйлап карады. Тирән баз ишегенең ачкычы атасының тимерле тартмасында саклана иде. Тартма үзе бинең йокы бүлмәсендә яшерен ояга утыртып куелган иде. Кирәкле ачкычны алу өчен иң элек ишек төбендәге сакчылар яныннан узарга, аннары ата кешенең йоклаган җиренә керергә, аның мендәр астыннан озын бауга бәйләнгән кечкенә бакыр ачкычны алырга кирәк иде. Бу теге әкиятләрдә сөйләнә торган алтын ачкыч эзләү кебегрәк иде. Әкияттә ул җиңел эшләнелә. Менә монда нишләргә? Сакчыларны инде алдарга да, сатып алырга да булыр. Үз атаңны, атаң янындагы үги ананңымы... карабашнымы... нишләтергә? Үтерергә? Бәйләп ташларга?.. Алдарга? Ничек итеп?!

Ул әлегә берни уйлап таба алмады. Шулай да ул, башта өенә кайтып, үзенең барлык алтын-көмешләрен янчыгына тутырды да тиз генә атасы өенә килде. Берни әйтмичә, аңлатып тормыйча, ул

тышкы ишек төбендәге сакчыга бер уч көмеш акчалар бирде. Өлкән яшьләрдәге сакчы учын күзенә якынрак китерде. «О-у!» — диде. Күзләрен елтыратып, Тәңкәдән:

— Ни йомыш, кызым? — дип сорады.

Тәңкә аңа яшермичә әйтеп бирде. Сакчы, сыңар күзен кысып, бик нык уйлангандай итеп, күккә, йолдызларга карады.

— Би бүген үзе генә йоклый,— диде ул, бераздан.— Аны үтерү берни түгел. Кызгансаң йокы уты иснәтергә була. Миндә бар.

— Шулаймы?!

— Синең өчен берни кызганыч түгел, углан... кызым,— диде сакчы, тыныч кына.— Иң яманы шул — минем яннан ничек үтәргә сиңа? Монысы иң кыены. Калганы чүп кенә. Син мине бәйли алмыйсың — көчең җитмәс. Үтерергә киңәш итмим. Сиңа берәр таза ир кеше табарга кирәк. Минем кулларны, аякларны бәйләргә дә, авызга чүпрәк тыгарга да... кара аны, борынны томалый күрмәгез! Эчтәге сакчыны да шулай итәрсез. Миңа тагын бер уч бир дә, углан... кызым, бераз көтеп тор. Ул көмешләрне берәр җиргә яшерәсе дә бар әле — бик кыен эш шул ул, кызым.

— Кемне табарга? Кемгә әйтергә? — диде Тәңкә, үз-үзе белән сөйләнгән сыман.— Үзебезнең кешеләргә ярамый. Кунаклар янына барырга туры килә.

— Алар сак астында,— диде сакчы, күңеле сүрелеп.— Кемне үтерергә соң анда? Ай-һай, бик кыен эш шул бу, углан. Яр астында ничек икән? Анда да сак! Булмаса, син миңа тагын бераз арттыр да, кызым, мин тиз генә аска төшеп, андагы үзебезнекеләр белән сөйләшеп, берәр тазарагын алып миним. Шунсыз булмый. Мондагылардан булмас — барысы да карт-коры. Аннары,— диде ул, пышылдауга күчеп,— болары... кодалар... берсе би янына килеп йөрде. Аларга ышаныч юк. Син монда торып тор. Мин тиз килермен.

Күпмедер вакыттан соң караңгыдан ике карачкы килеп чыкты. Аларның берсе — әлеге өлкән яшьләрдәге ишек сакчысы, икенчесе Торымтай иде.

**XVIII**

Торымтай аны иңбашына күтәрде. Ул бик авыр иде. Тәңкә, Торымтайның сыгылып төшүен күреп, аңа булышмакчы булды.

— Үзем... әйдә тизрәк! — диде Торымтай, пышылдап.

Алар караңгы, тар баскычтан өскә үрмәли башладылар. Төшкәндә дә бик озын тоелган баскыч менгәндә тагын да озынрак тоелды.

Менә алар тар ишек авызына килеп җиттеләр, кысылышып тышка чыктылар. Тышта инде баздагы кебек үк караңгы түгел иде. Торымтай иплән кенә Тотышны аягына бастырды, ике куллап тотып торган килеш, аның йөзенә карады, ничек тын алуын тыңлап торды.

— Исән! — диде ул, куанып.

— Исән, исән! — диде Тәңкә дә.— Әйдә тизрәк, Торымтай! Исән!

«Тәңкә!» — дип уйлады әкренләп аңына килә барган Тотыш, колак төбендә генә аның тавышын ишетеп.— Сөеклем, Тәңкә! Беркайчан ташламам сине!»

Аның күзенә яшьләр килде, тик шулай да ул җылый алмады — аны яңадан Торымтай күтәреп алды. Алар яңадан кузгалып киттеләр. Кая киттеләр алар? Тотыш берни аңламады. Аңа алар тагын да нindидер тар, текә баскычтан төшәләр шикелле тоелды.

Әйе, алар чыннан да тар баскычтан төшеп баралар иде.  Монысы инде Ямгырчы бинең өй асты базыннан менә торган баскыч түгел, монысы катаудан туры яр буена чыга торган яшерен юл иде.

Көтмәгәндә алда тагын көчсез генә яктылык күренде, салкынча су исе — таза, җиңел ис килеп бәрелде. Алар өчәүләшеп тагын җир өстенә — Чулман яры буена килеп чыктылар, туктап калдылар. Тотыш, үзенең кайдалыгын аңлап, күзләрен зуррак ачты, бер кулы белән Торымтайга, икенче кулы белән Тәңкәгә тотынган көе, аяклары белән каты җирне тойды.

— Менә без иректә! — диде Торымтай, җиңел сулап.

— Иректә! — диде Тотыш, ыңгырашып.

— Ашыгырга кирәк! — диде Тәңкә.— Атам йокыдан уянганчы, сезгә тизрәк кузгалып китәргә кирәк. Сакчыларның барысы да бәйләнгән, аларга тимәгез. Урдада калган кешеләрегезне коткарырга да коралларыгызны алырга кирәк. Алмасагыз да була, сакчыларныкын алыгыз да... Торымтай, син аны үз каегыңа кертеп яткыр,— диде ул, кем турында сүз барганлыгын аңлатып, Тотыш ягына ымлап.— Мин өскә менәм, сезнекеләрне алып төшәм.

— Мин дә синең белән барам, үзең генә булдыра алмассың,— диде Торымтай.

— Юк, синең белән булдыралмам,— диде Тәңкә, кырт кисеп.— Бар... ыгыз, тизрәк булыгыз.

Ул, кирәгеннән артык ашыгып-кабаланып, яңадан яшерен юл авызына кереп юк булды. Торымтай, Тотышны иңбашына салып, нindидер чытыр-чатыр арасыннан, нindидер кәҗә сукмагыннан иплән кенә, сакланып кына су янына ук төште.

Яр буенда анда-санда бәйләп ташланган казаяклар күренде. Йокыларыннан уятылган, боерык булу белән кузгалып китәргә генә торган акбүреләр Тотыш белән Торымтайны куанычлы гүелдәп каршы алдылар. Тотыш би, үз кешеләрен, каекларын күреп, ыңгырашып аягына басты.

Аны яр буенда калдырып, Торымтай берничә ир белән тиз генә җир тишегенә таба йөгерде. Күп тә үтмәде, ташлы тар сукмактан бер-бер артлы тезелеп төшеп килгән кешеләр — акбүреләр күренде. Алар, агач ботакларына тотынгалап, яр астына төштеләр, каеклары янына килделәр.

Тотыш би, яр читендә басып торган килеш, үзенең тозактан котылган юлдашларын күздән кичерде. Аларның барысының да исән-сау икәнлеген күреп, ул каекларга утырырга, кузгала торырга боерды.

Каеклар бер-бер артлы китә башладылар. Бераздан яр буенда акбүреләрнең ике-өч каегы гына торып калды. Андагылар Тотыш бинең утыруын көттеләр. Би исә Торымтай белән киткән ирләрне, алардан да бигрәк Тәңкәне көтте.

Менә алар, чыбык-чабык күтәргән сыман, корал күтәреп, җир тишегеннән килеп чыктылар.

Кораллар төялде, кешеләр урнашып беттеләр. Ташлы ярда Тотыш би генә торып калды. Ул Тәңкә белән саубуллашырга, йә булмаса, аны үзе белән алып китәргә тиеш иде.

Бәйләп ташланган ырудашлары арасында нидер эшләп булашкан Тәңкә, Тотышның көтеп торуын күреп, башын калкытты, әкрен генә аңа таба килә башлады. Анда әлерәк кенә күзгә бәрелеп торган ашыгу-кабалану да, бизгәк тоткандагы сыман ялкынланып яну да юк иде. Бит алмалары аның бушанып, сулыгып калган иде. Йөзендә, күз карашында, үз-үзен тотышында моңарчы булмаган бер нәрсә — читләшүме, салкынлыкмы бөркелеп тора иде. Андагы бу салкынлык, андагы ныклык Тотышны өркетеп җибәрде. Ул, аның күзләренә туры карый алмыйча, башын түбән иде.

Тәңкә аңа якын ук килеп басты, шул ук өркеткеч бер караш белән, тавыш-тынсыз гына аңа карап тора башлады. Тотыш та сүзсез генә аңа күз ташлап алды. Аларга исә каеклардан ишкәкчеләр карады, җирдәге бәйләп ташланган казаяклар карады.

Тотыш, ике кулын күтәреп, ипләп кенә аның беләкләреннән тотып алмакчы булды.

— Юк! — диде Тәңкә, кулларын тартып алып.— Бар, кит. Син иректә.

Тотыш би авыр гына көрсенеп куйды.

— Мин килермен. Көт,— диде ул ипләп кенә, йомшак кына.— Улымны сакла.

— Ак юл сиңа, Тотыш би,— диде Тәңкә.

— Мин барыбер килермен,— диде Тотыш, батыр өчен башка бер сүз дә тапмыйча.

— Килмә,— диде Тәңкә.— Сиңа, ыруыңа мин авыр йөк булачакмын. Мине оныт. Бәхетле бул.

— Ачуланма миңа. Бай бул, сау бул,— диде Тотыш би.

— Җитте! Кит, кит! — дип кычкырды кинәт Тәңкә, йөрәк түреннән чыккан бер ачыну белән.

Аның бу чатнап-кителеп чыккан йөрәк өзгеч тавышы Тотышны әллә нишләтеп җибәрде. Аны кызгану тойгысы биләп алды. Ул тагын аңа таба тартылып куйды. Ул аны кочмакчы, юатмакчы булды. Тәңкә, куркып, шашынып, артка чигенде. Шул ук мәлдә ул хәнҗәр тартып чыгарды. Тотыш би ап-ак булды. Ул, күрәсең, аны кадый дип уйлады. Тәңкәнең нык кысылган ирен читендә мыскыллы елмаю чагылып китте. Ул, хәнҗәр сабын Тотышка сузып:

— Соңгы үтенечем: када миңа, Тотыш! — диде, ярым пышылдап.

Тотышның үзеннән-үзе сузылган кулы кире тартылды. Хәнҗәр төшеп китте. Тәңкә Тотыштан да ныграк агарынып китте.

— Куркак! — диде ул, җирәнеп.

Ышану буенча, очлы тимерне кулдан төшереп җибәрү яманга юрала иде. Тәңкә хәнҗәрен алып тормады, коты алынып читкә сикерде, йөгерә башлады.

— Тотыш, тизрәк, тизрәк! — дип кычкырды Торымтай каектан.

**XIX**

«Шушы микәнни инде аерылышу?» — дип уйлады Тотыш, авыр, кыен бер тойгы кичереп. Ул Тәңкә җиңел генә, кыр кәҗәсе кебек кенә йөгергәләп менеп киткән текә яр башына шактый озак карап барды. Ул анда беркемне дә күрә алмады. «Кыр кәҗәсе» әллә шунда куе куаклар арасында яшеренеп калды, әллә шулай тиз арада өскә менеп, өенә кайтып китте.

Әле генә алар янәшә басып торган яр чите, киң күпер, җирдә аунап яткан сакчылар — барысы да артта кала барды. Куркытылган-өркетелгән ишкәкчеләр, котылуларына чиксез сөенеп, аякларын нык терәп иштеләр дә иштеләр.

— Кызурак, кызурак! — диде әледән-әле каек башы, ишкәкчеләрне ашыктырып.

Би утырган каек алданрак кузгалган каекларны куып җитәргә, алга чыгарга тиеш иде. Шулай кызулап бара торгач, чыннан да алар куып та җиттеләр, узып та киттеләр. Агым уңаена каеклар бик шәп бардылар. Арттан куа чыкканчы, ничек тә бу куркыныч төштән узып китәргә кирәк иде.

Шулай ашыгып, кызулап барганда, ишкәкчеләр ярда нindидер нәрсә күреп алдылар.  Тотыш та алар караган якка әйләнеп карады. Текә яр читенә чыгып торган таш кисәгендә ниндидер кеше сыман

карачкы күреп, ул тынсыз калды. Шундый куркыныч ташта, шундый тирән упкын өстендә басып торырга ничек йөрәге җитә аның?! Таш ычкынып китсә, кителеп төшсә? Йә булмаса башы әйләнеп...

Туктале, кем соң бу? Тәңкә... түгелме соң?!

— Тот-ты-ы-ыш! — дип кычкырды шул чакны күк читендә басып торган кеше.

Тотыш аягына басты, ике кулын авызына куеп:

— Тәңкә-әәә! — дип кычкырды.

— То-ты-ы-ыш! — дип кычкырды тагын кыя өстендәге Тәңкә, Чулман өстен яңгыратып.

Каектагы кешеләр, тын алырга куркып, текә ярга карап бардылар. Кешеләр генә түгел, киң Чулман да, исе китеп, тып-тын калды. Каралҗым яр буйлары, биек наратлар, су өстендә очкан акчарлаклар, керәшәләр — барысы да, пошынып, борчылып, уркын кырыена барып баскан тынгысыз йөрәкне күзәттеләр. Ник баскан ул анда куркыныч таш өстенә, ник шулай йөрәк өзгеч итеп кычкыра ул каектагы кешеләргә? Күпне күргән чал елга да, биек наратлар да, кыялар да берни аңлый алмадылар. Ник баскан ул анда?!

Кулларын бутап, тун чабуларын җилфердәтеп, баштүбән ул суга сикергәч, бөтен җирнең-күкнең асты өскә килде. Чулман туктады, керәшәләр, акчарлаклар күктә очалмыйча катып калдылар. Биек наратлар, кара ярлар, киресенчә, суга иелделәр. Ах, ниләр булды аңа, ни булды?! Таш сындымы, җил өрдеме, әллә юкса су тарттымы аны? Ник төште ул шундый биектән?!

Адәм баласының егылуын күрмәс өчен, керәшәләр, акчарлаклар куркып читкә ташландылар; кайгысыннан Чулман кара янып чыкты; сызланып, сыкранып колак төбеннән салкын җил исеп үтте.

Бу ничектер төштә күргән кебек кенә булды. Шулай да бу өндә — барысының күз алдында булды. Куллардан ишкәкләр төште, йөрәкләр, атылып чыгардай булып, бушлыктагы кешегә омтылды. Барысы да, авызларын ачып, торараштай каттылар да калдылар. Монда инде карап торудан башка берни эшләп булмый иде.

Шулай да Торымтай исенә килә алды. Күз ачып йомганчы ул, өстендәге авыр тунын салып, суга ташланды.

Тәңкә, күрәсең, Тотыш каегына чамалап сикерде. Баш каектан ул бераз гына алдарак, уң яккарак килеп төште.

...Өстеннән су аккан, төсе качкан, күзләре йомылган ярым үлек Тәңкәне Торымтай белән бер-ике ишкәкче каекка менгерделәр.

— Су эчкән! Суын чыгарырга кирәк! — диде каек башы.

Бер ишкәкче Тәңкәне аягыннан югары күтәрде, бер-икесе аның иңбашыннан, башыннан тотып торды. Торымтай ипләп кенә аның кулларын кыймылдатты. Чулман төбеннән, үлем тырнагыннан тартып алынган Тәңкәнең бераздан тын алганы ишетелде.

— Тәңрем, ярлыка,— диде каек башы, ике кулын күккә күтәреп.— Ул суга ялгыш егылып төште. Ул үзе сикермәде. Без күреп тордык — аның аягы ычкынып китте. Үзең ярлыка, Тәңрем!

Әле генә үлгән кебек тоелган кешенең терелүен күреп ул, куркып, шундук читкә китеп барды. Шулай ук яшь ишкәкчеләр дә тизрәк үз урыннарына утырырга ашыктылар. Тәңкә янында Тотыш белән Торымтай гына торып калды. Салкын тимәсен өчен алар аны тунга төрделәр дә, авызын ачып, ачы бал эчерделәр. Тәңкә күзләрен беразга гына ачты да яңадан йомды. Ул, ахрысы, йокыга китте. Аның тын алуы тигез иде.

Тотыш би, Торымтайның җиңеннән тотып, аны читкә әйдәде.

— Карале, юлдаш,— диде ул аңа, пышылдап.— Минем сиңа бер үтенечем бар. Аны мин үзем белән алып бара алмыйм,— диде ул, Тәңкә ягына ымлап.— Әнә анда — яр буенда ниндидер куыш күренә. Бу әле Ямгырчы би җире булырга тиеш. Син аның белән шунда калмассыңмы? Суга төшкәнен әйтмә, чирләде, бизгәк тота, диген, өстенә салкын су койдык, диген. Савыккач атасына илтеп куй. Йә булмаса минем кире борылып кайтканны көтеп торыгыз. Юк, ул алай теләмәс. Савыккач үзе әйтер тагын. Мин кайтканда Алмыш ханнан көчле алай сораячакмын, юкса безне Шуранда тагын кунак итүләре бар. Шуннан мин сезне дә алып китәрмен... җайларбыз әле!

— Тотыш! — диде Торымтай, дулкынланып.— Синең изгелегең аркасында мин яңадан үземне кеше итеп сизәм. Син миңа ирек бирдең, үлгәнче сиңа турылыклы булырга мин үз-үземә сүз бирдем. Кайгырма, барысы да син дигәнчә булыр. Без сине көтәрбез!

— Кара аны: сакла! Алай-болай тагын үзенә үзе кул сала күрмәсен! Улымны ятим калдырса, мәңге кичермәм. Шулай дип әйтте диген!

— Тыныч бул,— диде Торымтай.

Тотыш би нык итеп аның кулын кысты.

Ярдагы куыш турысына җиткәч, баш каек ярга якын килде, туктады. Торымтай, тунга, киезгә төрелгән Тәңкәне күтәреп, ярга төште. Тотыш би үзенең ышанычлы юлдашына ике йөз тиен акча бирде, ашарларына бер-ике көнлек азык-төлек калдырды.

— Тыныч бул, Тотыш би,— диде Торымтай, кабатлап, кул болгап.

**Алтынчы баб**

**I**

Төштән соң каеклар Итилгә килеп керделәр. Кызгылт-болганчык сулы Чулман, ургылып, усалланып, бераз җир үзенчә эз салып барды да, үзеннән икеләтә диярлек киңрәк, көчлерәк Итилгә кушылып, мәңге юкка чыкты. Ярлар үзгәрде, ерагайды. Яр өстендә калкып утырган авыллар, ялгыз өйләр, алачыклар — барысы да кеп-кечкенә булып күренделәр.

Тотыш, су буенда үссә дә, моннан ике ел элек беренче тапкыр Итилне күргәч, үз алдында җәелеп яткан шундый күп суга, шундый зур киңлеккә чын-чынлап таң калган иде. Менә әле дә ул, озак кына аны күрми торгач, үзендә искиткеч бер күтәренкелек тойгысы калка барганлыгын сизде. Ямьсез, күңелсез нәрсәләр онытылды. Бөек көчкә, тере, серле көчкә табыну тойгысы көчәйгәннән-көчәя барды. Очарга җыенган кош сыман, ул кулларын күтәрде, аннары иелеп су төбенә карады.

— Олуг Итил! — диде Тотыш би, туган җиренең бөек суына эндәшеп.— Исән-имин илтеп тапшыр мине сөйгәнемә! Юлымда ак җәймә бул, изге Итил! Мин, Тотыш би, синең биләмәңә кердем, синең тигез юлыңнан барам. Ачуланма миңа, усалланма, каекларымны каплама, кешеләремне суырма. Менә сиңа калан итеп көмеш йөзегемне бирәм, уналты бөртек көмеш акча бирәм, гүзәл Итил!

Сул кулындагы йөзеген салып ул суга ташлады. Көмештәй су чыңлап китте, көмеш йөзек, бөтерелеп, ялт-йолт килеп, төпкә чумды. Шуннан соң Тотыш би, санап, берәмлекләп көмеш акчалар ташлады. Итилгә калан түләнгәч, кешеләр бауга бәйләп чиләк төшерделәр, су алдылар. Итил суы белән битләрен, кулларын юдылар.

Көн кичегеп барганда, еракта, калкулык өстендә, Болгар-тораның очлы мәчет манаралары, биек койма эчендә бер-берсенә сыенып утырган өй түбәләре караеп күренде.

Болгарга, үзенең сөеклесенә якыная барган саен, Тотыш бине капма-каршы уйлар, теләкләр биләп алды. Аның күз алдына әле күңелле, гүзәл күренешләр килде, әле куаныч күгендә кара болытлар кабарып чыкты да күңел кылларын ниндидер курку-өркүләр тынгысызлый башлады. Ниләр көтә икән инде аны анда? Илләр тыныч микән? Ике айдан киләм дип киткән кешенең соңга калуына үпкәләп ятмыйлар микән?

Менә алар кояш баер алдыннан Ага-базарга да килеп җиттеләр. Төн ягыннан яңа каеклар килеп туктавын күреп, кунакларны каршыларга базар башы Бигеш килеп җитте — монда аларны, күрәсең, ерактан ук көтеп торганнар иде. Тотыш би, басмадан төшеп, туры аның янына атлады, елмаеп баш иде.

— Илдә иминлекме, базар башы? — диде.

— Иминлек,— диде Бигеш.

Ул моны ничектер теләр-теләмәс кенә әйткән сыман күренде. Шулай да Тотышка берьюлы җиңел булып китте. Күкрәген кысып, тынгысызлап торган билгесезлек, өркү тойгысы юкка чыкты. Иминлек булгач, башкасы турында инде борчылып та торасы юк. Бигешкә ул бүләк итеп бер тәпән яңа бал бирде, бер тунлык иләнгән тире, хатынына дип пыяла муенса бирде. Бары шуннан соң гына базар башының симез йөзендә ягымлылык чаткылары күренә башлады. Алай гына да түгел, ерактан килгән юлчыларга кунакчыллык күрсәтеп ул бераз гына кабаланып та алды: каекларның кайсын кая туктатырга, ярга чыгарылган капчыкларны, төргәкләрне кайда, ничек урнаштырырга кирәклеген әйтте. Акбүре аксакаллары белән исәнләшкәндәй итенеп, баш та иеп алды.

— Кунак өендә буш урын бармы? — диде Тотыш би.

— Синең өчен табарбыз,— диде Бигеш, шадра төрткеләр арасында күмелеп калган кечкенә күзләрен елтыратып.— Миндә кеше күп, шулай да сезнең өчен табарбыз. Тотыш алып...

— Тотыш би,— диде кунак, төзәтеп.

— Тотыш би?! — диде Бигеш, тычкан күзләрен чекерәйтеп.— У-у, болай булгач, җир тишегеннән булса да табарбыз. Баш өсте, Тотыш би!

Акбүреләргә, билгеле, буш җирдә урда корырга да булыр иде. Тик Тотышның алай итәсе килмәде: би кешегә, кияү буласы кешегә, теләсә нинди сатучы кебек, ярлы-ябагай кебек, кая туры килә шунда өй кору килешми иде.

Бигеш тиз арада юлчыларга иярле атлар китертте. Иярле атлар белән бергә җигүле атлар да килде. Арбаларга капчыкларны, төргәкләрне, тәпәннәрне төяделәр. Каеклар янына тиешле каравыл калдырылды. Шуннан соң, акбүреләр калымга биреләсе атын җитәкләп, югары күтәрелгән байраклар белән, төркемләшеп, ашыкмыйча гына Бигеш утарына таба кузгалып киттеләр.

Ике ягында да тәбәнәк өйләр, алачыклар утырган тар гына аралыкны үтеп, алар киң языга — төп базарга килеп керделәр. Базар әле бетмәгән иде. Шулай да кибетләрнең күбесе ябык иде, анда-монда төркемләшеп торган, үзара нидер кызып сөйләшкән, сатулашкан кешеләр күренә иде.

Базар кешеләре Тотыш бине ерактан ук күреп алдылар. Товар сатулашучылар сату-алудан туктадылар, болай гына сөйләшеп торучылар сүзләреннән бүленеп калдылар — барысы да,

кызыксынып, йончылган, шулай да күтәренке күңелле юлчыларга карап тора башладылар, үзара пышылдап:

— Тотыш килгән!

— Кодалар белән!

— Кыз алырга килә! — диделәр.

Акбүреләр узып киткәч, пышылдаудан кычкырып сөйләүгә күчтеләр, аз гына да тартынмыйча, арттан төртеп күрсәтә-күрсәтә:

— Әнә шул инде Тотыш алып!

— Кияү булып килә.

— Соңгарак калган шул! — диештеләр.

Үзе турында әйтелгән сүзләрнең барысын да Тотыш ишетә алмады. Ул, кияү буласы кеше буларак, эре генә, кукыраеп кына, иярендә төз генә утырып барды. Шулай да базар кешеләренең арттан чыш-пыш килүе, тыелып көлгән сыман тавышлары аның эчен борып-борып алды. Нидер булган монда. Яхшыга гына булса ярар иде!

Байраклы ир-атлар төркеме, базар яныннан үтеп, яңадан тар тыкрыклар арасыннан бардылар-бардылар да, урман буендагы, калкулык өстендәге зур гына капка алдында туктап калдылар. Монда базар башы Бигешнең утары урнашкан иде.

Базар башының торган җире бер дә хан урдасыннан ким түгел иде. Якында гына биек наратлар шаулап утырган тәбәнәк калкулык әллә каян биек койма белән уратып алынган. Зур, авыр капка янында кораллы сакчылар тора. Капкага илтә торган тар юлга таш түшәлгән, капка алдына, тирән үр аша күтәрмәле күпер салынган.

Иркен ишегалды, калкулык өстендә Бигешнең эре нарат бүрәнәләрдән салынган биек өе калкып утыра иде. Калкулык астында кечерәк өйләр, каралты-куралар, абзарлар тезелеп киткән иде. Тагын да арырак, Итил буе болыннары ягына табарак, төркем-төркем булып утырган ак чатырлар, өйләр күренә иде. Ул төркем-төркем чатырларда, өйләрдә төрле җирдән килгән сатучылар яши иде. Базар башы Бигешнең бу «кунак өе» үзе бер авыл кебек иде. Монда кечкенә урамнар да, үз өйләре, үз каралтылары тирәсендә үзләренең көндәлек эшләре белән булашкан — аш пешергән, кер юган, бала имезгән хатын-кызлар да, җыйнаулашып, үзара сөйләшеп торган ирләр дә бар иде. Шулай ук монда көч сынашкан, шаулашкан яшьләр дә күренә иде. Өйләр арасында, урамда, юлда кояшта янган синдләр дә, озын буйлы кара гарәпләр дә, зур борынлы әрмәннәр, тәҗикләр, румнар да бар иде. Болар барысы да Бигешнең кунаклары иде. Ул аларның товарларын саклый, җылкы кайтарта — шуның өчен алардан акча ала иде. Базар башы Бигеш бөтен Болгар йортта иң бай кешеләрнең берсе санала иде.

Акбүреләргә ул ишегалдының иң кырыйдагы, болын ягындагы бер төшендә буш урын бирде. Шунда аларга ул киез өйләр кордырды. Бигешнең кешеләре акбүреләр «урда»сын тиз арада киртәләп алдылар, «урда» киртәсе янына тагын бер киртә кордылар. Монда алар кечерәк бер көтү сарык куалап керттеләр.

Арыган юлчылар туйганчы яңа ит ашадылар, яңа җирдә, яңа өйләрдә тынычлап йокыга талдылар. Тотыш би йоклый алмады. Бер дә юктан аның күңеленә әллә нинди ямьсез, куркыныч уйлар килде. Базар яныннан үткәндә кешеләрнең кинәт тынып калулары, чыш-пыш килүләре, Бигешнең башта ук ачу китергеч кыланышы — барысы да аның эчен пошырды. «Аппак, исәнме син, көтәсеңме мине?» — дип уйлады ул сагышланып.

**II**

Җәй башында, Тотыш углан ирек алып үзенең туган җиренә кайтып киткәннән соң бер ун-унбиш көн үткәч, Хазар каганыннан Алмыш ханга илче килеп төште. Егерме биш хатыны, алтмыш кырнагы булган кырык җиде яшьлек җөфүт каган Алмыш ханның кызы Аппакны — угыз ябгусының сеңелесе Айкын хатыннан туган гүзәл Аппакны үзенә егерме алтынчы хатынлыкка сораган иде. Болгар ханына язган битегендә ул, янап: «Үзең теләп бирмәсәң, көч белән тартып алырмын»,— дип тә әйткән иде.

Хазар каганының кул астыннан ычкыну, көчле, бай, бердәм Болгар йорт кору турында көн-төн баш ваткан Алмыш хан өчен бу аяз көнне яшен суккан кебек булды. Хазар каганында аның инде бер углы тотык булып ята иде. Ни генә булмасын, ул моны көтмәгән иде. Аппакны ул хазарларга түгел, Акбүрегә бирергә тиеш иде ләбаса! Акбүрегә, Тотышка биреп ул үзенә көч өстәмәкче иде. Инде аны илчегә биреп җибәрсә, ул яңадан Хазар каганына кулы-аягы белән бәйле булып калачак. Үлгәнче, мәңгегә! Шулай итеп, беркайчан да ул авыр богаудан котыла алмаячакмыни, Тәңрем?

«Минем кызым мосылман динендә, кияүгә мин аны мосылманга гына бирәм»,— диде Алмыш хан каган илчесенә. Илче карулашып тормады, шундук килгән җиренә кайтып китте.

Алмыш хан җиңел сулап куйды. «Котылдым!» — дип уйлады ул сөенеп. Тик аның сөенече озакка бармады. Көннәрдән бер көнне, Тотыш яңадан Ага-базарга килеп җитәргә өч-дүрт көн кала, каган илчесенең килеп китүе инде бөтенләй онытылып беткәч, Болгар җиренә каган чирүе басып керде.

Алмыш хан шундый күп көч түгеп яңадан торгызган Болгар-тораны хазарлар төрле яктан уратып алдылар. Субашы Каплан, Алмыш ханның борын төбендә кылыч уйнатып: «Инде бирәсеңме гүзәл кызыңны?» — диде.

Каган чирүе урман кебек иде. Хан уфтанды, көрсенде, кайгысыннан каралай көйде. Кылычка каршы кылыч күтәрергә аның кыюлыгы җитмәде. Агач коймалар, агач капкалар, агач өйләр аны берничек тә дошманнан саклап алып калырлык түгел иде.

Шулай итеп, язмышка буйсынырга туры килде. Иң кыен чагында Алмыш ханга Тәңре дә, Алла да булышка килмәде. Җөфүт каган тагын өстен чыкты. Җөфүт каган тагын аны аяк астына салды. Итил-Чулман күрке, бөтен Болгар йортның күрке... ата-ана мактанычы... гүзәл Аппак, кан-яшь түгеп, чит җирләргә, чит кулларга озатылды.

Аппак китте. Кояш сүнде. Болгар күген кара болыт басты. Көлгән, җырлаган тавышлар тынып калды. Биюләр, күңел ачулар бетте. Өйләрдә кот калмады, туган җирдә ямь калмады. Язгы ташу булып, бөек Итилгә көндәш булып, болгарларның күзләреннән кайнар яшьләр акты.

Аппак китте. Болгар илен кара кайгы басты...

Кайгысыннан Айкын хатын аяктан егылды. Ата кеше нишләргә дә белмәде.

Каган чирүе Болгардан китү белән, Алмыш хан янына Башту углы Габдулла килеп керде. Ул ышанычлы кешеләрнең Итил-торадан яңалык алып килүләре турында әйтте. Бу этлекләрнең барысы да сатлык Корыч-Тимер эше икәнлеге ачыкланды, диде. Синең гүзәл кызың барлыгы турында каган-биккә ул әйткән, каган-бик исә каганга җиткергән, диде. Аппакның Тотыш угланга бирелергә тиешлеген белгәнгә күрә, Корыч-Тимер сине, ханым, каганга кызыңны бирүдән баш тартырсың дип, ике арада сугыш булыр, хазарлар болгарларны канга батырырлар дип уйлаган, диде.

Боларның барысын да ишетеп, Алмыш хан, йөрәгенә чыдый алмыйча, урыныннан сикереп торды да... Габдулланың изүеннән эләктереп алды.

— Чынмы? — диде ул, авыр гыжылдап.

— Чын, ханым,— диде Габдулла, курка калып.

Алмыш хан, үзенең тилелеген күреп, аңына килде, изүне ычкындырды да, авыз эченнән мыгырданып:

— Кичер...— диде.

Тынычлана алмыйча ул әрле-бирле йөренде, тешләрен шыгырдатты, йодрыкларын йомарлады, янау сүзләре кычкырды. Шулай үзалдына тузынган арада, ул тезләнеп торган Габдулланы күреп алды да:

— Тагын сүзең бармыни? — диде.

— Бар,— диде Габдулла.— Әл-Моктадирга...— Багдад хәлифәсенә мине илче итеп җибәр, ханым. Мин юлны беләм, мин ничек тә барып җитәрмен дип ышанам.

Кайгысыннан нишләргә, нәрсә уйларга белмәгән Алмыш хан кинәт кенә юашланып, ипләнеп калгандай булды. Аның томаланган күз алдында әйтерсең яшен чаткысы ялтырап китте. Багдадка илче булып?! Нинди кыю кеше бу? Юри генә сөйләнәме, тынычландырмакчы булып кына?..

— Алаймы? — диде ул, кыска буйлы, кырыс, таза Габдулланы күздән кичереп.— Илче дисең алайса? Яра-ар... Тәкин белән Барыс угланны юкка чыкты дибезмени инде алайса? Алар булдыра алмаганны син ничек булдырырсың икән — сөйләп карале!

— Мин инде күптән уйлыйм бу турыда,— диде Габдулла.— Сиңа әйтергә кыюлыгым гына җитми торды, күнмәссең дип курыктым.

— Әйе шул,— дип куйды хан, аның сүзен җөпләп.— Син минем углым да, туганым да түгел. Син — сатучы да, мулла да... алдарга-юлдарга күнеккән... Миннән кеше, байлык алып, син дә Тәкин углан белән Барыс углан кебек юкка чыкмассың микән соң? Ул чагында мин сине ничек юллармын?

— Алай дип уйласаң, җибәрмәссең,— диде Габдулла, тынычлыгын аз гына да югалтмыйча.— Син, ханым, беләсең: синең янга мин байлык эзләп килмәдем. Булган байлыгымны, хатынымны, балаларымны ташлап килдем. Мин төрле кысудан, кысынкылыктан, үлемнән качып килдем. Бу нәрсәгә син көч, байлык күзеннән карыйсың. Син бары байлык белән көчкә генә табынасың, шуннан гына куркасың. Шуңа да көн-төн исерткеч эчәсең, үзең, җитмәсә, мосылманмын, дисең.

— Туктале, тукта — син кем мине... өйрәтергә?! — диде хан, кисәк кенә кабынып китеп.

— Мин — беркем түгел,— диде Башту углы Габдулла, тыйнак кына.— Мин сиңа бары шуны гына әйтәм: сиңа, кайгым бар дип, көн-төн эчү килешми, ханым. Караларга син яман үрнәк күрсәтәсең. Йортың-илең таза, нык, бай булсын дисәң, син, йорт башы, иң элек үзең айнык булырга, нык, таза булырга тиешсең.

— Ярар, ярар... Кызык, сөйли бир. Мин укымышлылар сүзен тыңларга яратам. Сүзең туры — миңа киңәш бирүче дә кирәк кайчагында,— диде хан, урынында җайлап утырып.

— Тыңласаң, минем сиңа сүзләрем күп, ханым! — диде Габдулла, күңеле күтәрелеп.— Минем йөрәгем яна, ханым! Минем кайгымның чиге-чамасы юк! Җөфүтләр Хазар илен коры таякка терәделәр инде. Каган берни эшли алмый — көн-төн хатыннары белән күңел ача. Каган-бик[1] булдыксыз. Акыллы сүзне тыңлаучы юк. Илдә таркаулык, ярлылык, томаналык...

— Кызык, кызык,— диде Алмыш хан, бармаклары белән кылыч сабына шакылдаткалап.— Укымышлылар сүзен тыңларга бик тә яратам мин. Сөйлә әйдә, сөйлә. Тик син шуны да онытма: Хазарның көчәюе ул Болгарның үлеме дигән сүз!

— Әйе, шулай,— диде Габдулла, килешеп.— Болгарның көчәюе — Хазарның үлеме дигән сүз! Менә нәрсә телим мин, ханым! Хазарга үчлекләшеп түгел, җөфүткә үчлекләшеп тә түгел. Юк! Үз илемне-көнемне, үз телемне алдынгы итәсем килә минем. Таркау ыруларны, кабиләләрне синең кебек тынгысыз кеше генә берләштерә ала. Синең өчен иң җайлы чак хәзер. Сиңа мондый җайны кулдан ычкындырырга ярамый, ханым.

— Аңлашылды,— диде хан.— Күреп торам: син минемчә улыйсың. Ярар, мин сине дә җибәреп карыйм. Берьюлы шунда Тәкин углан белән Барыс угланны да эзләп табарсың, төп йомышыңны да үтәрсең. Шулай да күңелемдә бер төен бар: Хазар аша ничек узарсың?

— Кайгырма, ханым,— диде Габдулла.— Анысы минем эш. Мин Итил-тораны, хазарларны Тәкин угланнардан яхшырак беләм. Мин аннан күз йомып та уза алам. Мин алар кебек бер көтү булып бармаячакмын. Мин бернинди кешесез... үзем генә китәчәкмен! Беркемгә берни сиздермичә... Синең үзеңнән башка беркемгә!

— Үзең генә? — диде хан, ышанып җитмичә.— Сакчысыз, юлдашсыз?

— Әйе, сакчысыз, юлдашсыз. Мин сатучы булып түгел, сатучылар белән китәрмен, аларның бер кешесе булып. Монда ышанычлы бер гарәп бар. Ул мине алып барачак...

— Кем ул?

— Фатих ибн Әхмәт,— диде Габдулла.— Аның булмаган җире, кермәгән тишеге юк. Бөтен Багдадта аннан булдыклы, аннан бай, аннан шома сатучы юк.

— Беләм мин аны,— диде хан.— Тапшырдык алайса, Башту углы Габдулла! Бүгеннән җыена башла.

**III**

Коточкыч яңалыкны иң элек кодалар белде.

Кайгылы хан, эндәшмичә, кешеләргә күтәрелеп карамыйча, бик озак утырды.

— Аппак юк...— диде ул ниндидер чит кеше тавышы белән.— Юк. Китте... бетте...

Аның ике як бите буйлап кайнар яшь тамчылары тәгәрәп төште.

Акбүре ыруыннан килгән кодаларга хан Аппакның кайчан, ничек, нишләп «юк» булуын аңлатып тормады. Анысын башкалар аңлатты.

Тотыш би кодаларны берүзе бер өйдә көтеп утыра иде. Аңа турысын гына әйтергә беркемнең дә батырлыгы җитмәде.

Шулай да ул барыбер белде. Белде, тик ышанмады, ышана да алмады. Үзе исән чакта, үзенең күзләре кешеләрне, күкне, кояшны күргән чакта... Өйләр, агачлар аумыйча-авышмыйча торган чакта... Дөньядагы барлык нәрсә элеккечә исән-сау калган чакта ул аның гына... бары Аппакның гына шушы мәңгелек күк, кояш астында булмавына, шушы өйләр, каралтылар арасында булмавына ышана алмады. Капка төбендәге сакчылар, беркемгә кирәксез ниндидер хатыннар, балалар, усалланып безелдәгән чебеннәр, этләр, терлекләр шушында... шушы җирдә, шушы илдә иркенләп яшәп ятканда аның гына... бары бер Аппакның гына монда була алмавына ул берничек тә ышана алмады.

Тәңрем! Туган җирем, туган күгем! Олуг кояш! Әйтегезче, күрдегезме сез дә аның юк булуын? Күрдегезме җөфүт каган кешеләре аны көчләп, тартып алып киткәннәрен? Өйләр, капкалар, тузанлы юл, сез ул чакта монда булгансыз. Күрдегезме аның кан-яшь түгеп чит якларга, чит җирләргә олакканын?

Әй, болгарлар, кешеләр! Шуны күреп ничек сезнең йөрәгегез ярылмады, ничек сезнең ярсуыгыз кузгалмады?! Ник сез шуңа юл куйдыгыз?! Ник сез шуны тыныч кына карап калдыгыз?

Үзенең йөрәк түреннән чыккан иң усал сүзләрен ул, сөңге аткан кебек, хан йөзенә атты.

— Син — ялганчы! — диде.

Башка вакыт булса, башка кеше булса, мондый сүзгә Алмыш хан чыдап тормас иде. Меңбатманлы авыр башын, кайгылы зур башын көчкә күтәреп утырган ата кеше урыныннан да кузгала алмады. Ул бары күз кабакларын гына калкытты да ачусыз гына:

— Мин ялганчы түгел, Тотыш... углан,— диде.— Язык миндә түгел.

Ул үзе янындагы хан-агасына ым какты. Хан-агасы каядыр китеп барды. Күп тә үтмәде, кулыннан җитәкләп ул хан катына яшь кенә бер кызны алып килде. Аңа, күп булса, ундүрт-унбиш яшьләр булыр иде. Оялудан аның сылу бит очлары пешкән чиядәй алсуланып тора иде. Аның елтыр кара күзләре тынгысыз иде.

— Менә минем кызым Айтулды... Аппакның бертуган сеңелесе,— диде Алмыш хан, авыр гыжылдап.— Мин аны сиңа хатынлыкка бирәм, Тотыш би.

— Мин ат түгел, бога түгел,— диде Тотыш би, усалланып.— Мин синең бу кызыңны яратмыйм, тегесен яратам... Аппакны! Шуны бир син миңа, Алмыш хан!

Мондый сүзләр ишетеп, хан көлемсерәгәндәй итеп куйды.

— Иң элек син миңа аны алып кайтып бир... каганны җиңеп...

— Җиңәрмен! — диде Тотыш би, тиле кеше сыман, тыела алмыйча.— Каганның астын өскә китерермен, Аппагымны тартып алырмын!

Хан янындагылар, бу кеше чыннан да тилергән, ахрысы, дигән сыман, сүзсез генә бер-берсенә карашып алдылар, тамак кыргалап куйдылар.

— Сиңа кыен булган кебек, миңа да кыен, би,— диде ата кеше, авыр гына.— Мин сүземне әйттем: Айтулды синеке. Теләмисең икән, көчләмим. Уйла, тынычлан, ике көннән килерсең. Син, Тотыш би, миңа үз улым кебек якынсың. Мин сине яраттым. Күңел яраңны төзәтү өчен мин сиңа тагын бер изгелек эшләмәкче булам.

Алмыш хан шома йөзле, тук, таза битекчегә кул изәде. Битекче алгарак чыкты, таяк сыман итеп төрелгән юка күнне сүтте дә калын, матур тавыш белән кычкырып укый башлады:

«Мин, изгү Болгар йортның башы Шилке углы Алмыш хан ошбу ярлыкны Акбүренең Күрән би углы Тотыш бигә иректе тархан булсын дип бирдем. Миңа буйсынган биләр, ыру башлары, субашлары, тарханнар, угланнар, туган-тумачалар, ил агалары, илчеләр, каравыл башлары, базар башлары, тамга башлары, агычылар, ясакчылар, салымчылар, авыл агалары, Болгар йортның барлык аксөякләре, каралары белсеннәр: чибәрлеге тиңсез кызым Аппакны явыз җөфүт каган тартып алганга, Аппакның кияве буласы Тотыш бинең кайгысын уртаклашып, күз яшьләре түгеп, мин Алмыш хан, Күрән би углы Тотыш бине, аның угылларын, угылларының угылларын, барлык тамырын киләчәктә миңа, миннән соң утырачак ханнарга калан түләмәсен, дидем. Көчләп аннан яу өчен ир-ат алмасыннар, караларын тартып алмасыннар. Ясак, салым, түләү салмасыннар. Ыругына, катавына, авылларына, байлыгына, терлек-туарына талау китермәсеннәр. Җиренә-суына, урманнарына, болыннарына басып кермәсеннәр. Тыңламаучыларга аларның каргышы, ханның ачуы төшәр. Тотыш би үзе, иле-көне, ырудашлары, тамырдашлары Болгар ханнарының якыны, ышанычлы таянычы булсын, мине дошманнардан көч белән, байлык белән якласын, Алладан миңа, минем йортыма, илемә-көнемә, ыруларыма тәлим байлык, иминлек, озын яшь теләп, изгелектә булсын...»

Ханның якыннары, Акбүре илчеләре — өйдәге барлык кешеләр тын да алмый тыңлап тордылар. Укып бетергәч, битекче ярлыкны ханга бирде, хан Тотыш бигә сузды.

Тотыш би кузгалды, ашыкмыйча, нык-нык басып, хан катына килде. Бер сүз әйтмичә, ярлыкны алды да, учында йомарлап... идәнгә ыргытты.

— Мин синең ярлыгыңа өйләнергә килмәдем, хан! — диде усал итеп. Кешеләр тетрәнеп киттеләр, куркынган тавышлар, аһылдаулар ишетелде. Кайберәүләр, исән чакта чыгып таярга кирәк дигән сыман, ишек ягына караштырып алдылар. Котлары алынып, ыңгырашып Акбүре илчеләре-кодалары Алмыш ханның аягы астына егылдылар.

Кешеләр генә түгел, хан үзе дә, сулуы кабып, агарынып, өнсез калды. Нәрсә бу?! Шулай аның йөзенә төкерергә... аңа каршы кул күтәрергә... кем ул? Кем!

Аның ярым йомык күз кабаклары киерелеп ачылды. Күкрәгендә котырынган ярсуын тотып тора алмыйча ул, йодрыкларын нык кысып, бөтен тәне белән калтыранырга тотынды. Шулай да ул нишләптер утырган урыныннан тора алмады.

— Моның өчен сине агач башына асып куярга тиешләр,— диде ул бераздан, авыр тын алып.— Буйсынмавың, белексезлегең аркасында, күзең сукыраю... кайгы-сагыш аркасында, кызым Аппакны яратуың аркасында булганга, мин сине кичердем, Тотыш би. Мин Акбүре белән татулыкта яшәргә телим, Акбүренең Чулман буенда минем терәгем, уң кулым булуын телим. Әйткән сүзем көчендә: ике көннән килерсең.

**IV**

Кодалар-илчеләр, аякларына таш таккан кебек авыр атлап, әкрен генә кире борылдылар. Байраклар түбән иелде, башлар салынып төште. Килгәндә шундый куанып кычкырган быргылар, күк күкрәтеп дөпелдәгән дөңгерләр мыштым гына тынып калдылар. Урамда, юлда очраган кешеләр, Тотыш бинең, Тотыш алыпның кайгылы йөзен күрмәскә тырышып, күзләрен читкә бордылар. Ага-базар шулай ук аларны тавыш-тынсыз каршы алды. Чыр-чу килеп арттан балалар да иярмәде, капка төпләрендә авызларын ачып карап торучылар да күренмәде. Кешеләр, шулай булачагын алдан ук белгәнгә күрә, тараканнар кебек каядыр качышып беттеләр.

Әллә качмаганнар иде микән соң? Әллә тирә-якта шаулап, ыгы-зыгы килеп тордылар микән соң алар? Тотыш күрмәде, ишетмәде. Ул берни тоймады. Ул, алтынлы, бизәкле ияр өстендә утырган килеш, иксез-чиксез Итил дулкыннарында тирбәлеп барган кебек, әкрен генә тирбәлеп барды да барды.

Ул бик озак барды. Ханбалык белән Ага-базар арасындагы ике-өч чакрымлык юлны ул әйтерсең айлар, еллар барды.

Бигеш аларга күп итеп ит суйдырды, күп итеп кымыз, бал куйды. Ачыккан акбүреләр ашау ягын кайгырттылар. Тотыш ашарга утырмады. Шулай ук ул ятып та, басып та тормады. Ул ничектер барлык кешеләрдән, тормыштан, дөньядан аерылып калган кебек булды. Ул әйтерсең әле дә атына атланган килеш, җир белән күк арасында әкрен генә тирбәлеп барды.

Яшь бинең, белексез, тиле бинең кыланышына ачулары килгән кодаларның, ашап-эчеп алгач, телләре чишелде. Беренче булып Майчан аксакал телгә килде.

— Синең аркада, кем... Тотыш углан, кхм... кхм... без дә башсыз кала яздык. Инде син би булгансың икән, Акбүренең баш кешесе икәнсең, уйлап эшләргә... адымыңны уйлап атларга кирәк.

— Балаларча булды!

— Шундый ярлык биргәндә, алырга да ычкынырга е! Кызы үзенә булсын!

— Әйтмә! Нинди сөю, нинди ярату ул? Кыз беткәндер би кешегә!

— Кочакларга, төн кунарга кем дә ярый,— диештеләр кодалар, берсеннән-берсе уздырып.

— Сеңелесе соң, сеңелесе! — диде үги ата Котан, кычкырып.— Тагын ни кирәк? Алмыш ханның кызын алам дидең — ал! Шуңа килдек түгелмени? Шуның өчен йолабыздан, ата-бабалардан баш тарттык түгелмени? Бу, Тотыш би... углан, энем... синең эш кенә түгел, бөтен ыру эше. Менә без, Акбүренең аксакаллары, җыелдык та сиңа әйтәбез: Айтулдыдан син баш тартырга тиеш түгел. Калымны бирәбез дә, кызны алабыз да, кайтып китәбез.

— Әйе, әйе, шулай!

— Әле берсеннән баш тарт, әле икенчесеннән! Ни дигән сүз бу?

— Ямгырчы би кебек Алмыш хан да барыбызны да тотып япканчы, эшне тизрәк җайларга кирәк,— диештеләр башкалар да, шаулашып.

Тотыш би, телдән язган кеше сыман, беркем белән карулашмады. Күрмәс күзләре белән ул ырудашларының әле берсенә, әле икенчесенә карап алды. Күңеле белән ул барысын да сизеп, тоеп торды: аксакаллар ничек тә аның йөрәгендәге ялкынны сүндерергә, ничек тә аның уйларын, теләкләрен үзгәртергә, кирегә — үзләре теләгән якка борып җибәрергә тырыштылар. Сөю юк, ярату юк... Кем дә ярый... Каланны түлик тә кире борылыйк... Ямгырчы бигә барып эләккәч тә шуны сөйләделәр түгелме соң алар?

Аларга нәрсә! Тамаклары тук булсын да кочаклашып төн кунарга, бала табарга, кием-салым юарга-ямарга, аш пешерергә хатыннары булсын.  Күңелләре теләгән сөекле, күрекле кызмы ул, карабашмы — алар өчен барыбер. Төннәрен аларның ялт-йолт килеп янган якты йолдызларга караганнары бар микән? Уйланып, таң калып аларның төпсез, киң Итилгә — бертуктаусыз агып яткан бөек көч чыганагына карап утырганнары бар микән? Тирә-якта ут-үләннәр шау чәчәккә күмелгәндә, чикерткәләр сайраганда, бал кортлары бал җыйганда аларның болын уртасына сузылып ятып, баш очында эленеп торган ак болытларны күзәткәннәре бар микән? Сөекле кызлары турында уйлап, төннәрен йокысыз уздырган чаклары булды микән аларның?

Сөю юк, ярату юк, имеш! Шуннан башка тагын ни бар соң дөньяда, Тәңрем?!

Әллә соң туганда ук алар шулай бөкшәйгән, ямьшәйгән, уршыган картлар булып, чытык йөзле, черек тешле, сирәк-мирәк кәҗә сакаллы картлар булып туганнармы?

Сөю юк, ярату юк... Кочакларга кем дә ярый, имеш! Киекләр дә, ерткычлар да... барлык кошлар, кортлар яратыша белә. Адәм генә шундый түбәнмени, Тәңрем?!

— Сез миннән көләсез, минем яратуымнан, минем кайгымнан көләсез, аксакаллар,— диде ул эчке бер ачыну белән.— Туганымнан бирле, аягыма басып йөри башлаганнан бирле сез, сезнең балаларыгыз миңа ят итеп карадылар. Минем кыюлык, минем батырлык сезгә кыргыйлык булып, йолага каршы килү булып тоелды. Мин кылычым белән, сөңгем белән... каным белән ыруымны яудан, үлемнән саклап калдым. Мин бары ыруның иреген, бәйсезлеген генә саклый алмадым. Минем аңа көчем җитмәде. Алмыш ханның алыплары белән орышып мин бер дә алай кыргый түгеллегемне, туган җиремә, туган ыруым, атам-анам өчен утка-суга керә алуымны күрсәттем. Минем батырлыкка сокланып, сез минем «явызлыкларны», «кыргыйлыкны», «башбаштаклыкны» онытып тордыгыз. Инде килеп ханның кызын яратканмын икән, чынлап торып... йөрәгемә Тәңре салган барлык ут-ялкыным белән, бөтен күңелем белән яратканмын икән, бу тагын да сезгә тилелек булып, балалык, кыргыйлык булып тоела. Сез тагын да миңа ышанмыйсыз, ырудашлар. Минем яшьлегемә, минем сөя алуыма ышанмыйсыз! Күкрәгемдә утлы куздай дөрләп янган йөрәгем булуына, башымда — уем, кулымда көчем барлыгына ышанмыйсыз! Тәңре мине яратканда матурлыкны, гүзәллекне күрә торган күзләр биргән, тәмлене, татлыны аерырга сизгер тойгы биргән. Үзем теләгәнчә сөяргә миңа канатлы күңел биргән. Сез, ырудашлар, шуңа ышанмыйсыз. Барлык кешеләр, барлык тереклек ияләре сезгә үзегез кебек картайган-муртайган булып, телсез-күзсез бүкән булып тоела. Әйе, ырудашлар, мин бары Аппакны гына яратам! Тәңре алдында, бөек Итил, Чулман алдында, изге ияләр алдында мин ант итәм: мин Айтулдыга өйләнмәячәкмен!

— А-а! — диделәр аксакаллар беравыздан, котлары алынып.

— Курыкмагыз, ырудашлар,— диде Тотыш би.— Сез исән калырсыз. Минем бу антым өчен... Айтулдыга өйләнмәгән өчен Алмыш хан сезгә бармак белән дә чиертмәс. Акбүре ыруына бернинди талау килмәс. Мин, ырудашлар... аксакаллар... үз теләгем белән билекне үги атам Котанга тапшырам.

— А-а! — диделәр тагын да аксакаллар, утырган урыннарында кузгалышып.

— Айтулдыга Котан би өйләнеп, тарханлык ярлыгын да ул алыр... хан бирсә, билгеле. Бу минем боерыгым... соңгы боерыгым.

Ул, башка берни әйтмичә, Багдад тегүчесе теккән бай тунын, алтын-көмешле киң билбавын, башындагы биек, очлы бүреген салып, үги атасына тоттырды. Шуннан соң үзенең билен таррак, төссезрәк икенче бер каеш белән буды да, кылычын, хәнҗәрен җайлады да яланбаш көе ырудашлары яныннан чыгып китте.

## V

Алмыш хан каршындагы Тотыш би тарханлык ярлыгын йомарлап ыргыткач, ал тамгалы күн кисәге Котанның аяк астына туры килде. Зур ирек, байлык бирә торган әлеге күн кисәген Котан, киек тоткан җырткыч кебек, шундук эләктереп алды, шундук тун җиңе эченә яшерде. Ыгы-зыгы арасында аны беркем күрмәде. Инде менә аның кулына бай кием-салым, билбау, бүрек тоттырып чыгып киттеләр. Ыруның аксакаллары алдында аны... субашы Котанны би ясадылар!

Аның күз аллары әлҗе-мөлҗе килде, буыннары камыр кебек йомшап калды. Аның авызы үзеннән-үзе ерыла башлады. Ул, тыела алмыйча, көлеп үк җибәрде, кулындагы алтын-көмешле бай киемнәргә — билек билгеләренә исе китеп карап торды да аннары ырудашларына күтәрелеп карады, бала-чага сыман:

— Киим микәнни? — дип куйды.

— Ки, ки! — диде аксакалларның берсе.— Үзе салгач, ки!

— Башкача булмас, ахрысы,— диде Майчан аксакал да, пошынып.

Майчан аксакал ыруда белекле, турылыклы карт санала иде. Яшь егетнең сүзләре аның күңелен шактый яралады, шулай да ул аңа ачулана алмады. Киресенчә, ул үзен бераз гына аның алдында уңайсыз сизә иде, ахрысы.

— Үзе теләмәгәч, кхм... Эшләр шулай булып чыккач, берни эшләп булмый,— диде ул, Котанга туры карамыйча.— Яшь шул, яшь. Яраткач, берни эшләп булмый. Яратудан да зур көч юк дөньяда, оланнар. Без дә уйламыйчарак сөйләндек, кхм... Бераз тынычлансын, ашыкмыйк әле булмаса.

— Юк, юк, билекне Котанга тапшырабыз!

— Котанга, Котанга!

— Тотышның авызыннан ана сөте кипмәгән. Би андый булмый! — диделәр аксакалларның күпчелеге, ачулы шаулашып.

Котан үзенең киемнәрен салып ташлады да, берәрсе тартып ала күрмәсен, дигән сыман, кабаланып-калтыранып, би киемнәрен кияргә тотынды. Ырудашлары сүзсез генә аны күзәтеп тордылар. Киемнәр яңа бигә бераз гына киңрәк, иркенрәк иде, шулай да бик килешле иде. Субашы Котан күз алдында үзгәреп китте.

— Котан — би! Сез мине... чынлапмы? Беравызданмы? Антмы? — дип сөйләнде каушап калган Котан би, як-ягына каранып.

— Чынлап, чынлап! Ант, ант! — диделәр ырудашлары, аны тынычландырып.

— Хи-хи... ышанычыгызны аклармын. Бай булыгыз, сау булыгыз. Тәңре сезгә мең яшь бирсен! Хи-хи!

Куанычыннан тынычлыгын җуйган би ул көнне үзен исерек кебек тойды. Аның үзен чыннан да би итеп, көчле итеп күрсәтәсе килде, бу турыда аның барлык кешеләргә, барлык Болгар йортка белдерәсе килде. Шул ук мәлдә аның күңеленә: «Тотыш углан сүзен кире алса?» — дигән бер куркыныч уй да килде. Бу аны бик каты кайгыга салды. Тыелгысыз куаныч каядыр юк булды. Билектән чын-чынлап колак каккан кебек, яңа бинең чын-чынлап йөрәге яна башлады. Аксакаллар ант итү белән генә чын би түгел ич әле ул! Би итеп аны ыру башы таныргa, җыен таныргa тиеш. Аннары Алмыш хан да аңа Айтулдыны бирәме, юкмы әле, ярлыгын таныймы, юкмы әле. Әйе... нишләргә уйлый Тотыш билектән баш тартып? Кире ыруга кайтачакмы, монда торып калачакмы ул? Ыруга кайтса, аның белән беркемгә тынгы булмаячак, анасы Койтым бикә барыбер аның яклы булачак. Шулай булгач, димәк... шулай булгач...

Шулай! Монда Утташ кам кебек эшләргә ярамый. Монда уйлап, киңәшеп эшләргә кирәк.

Котан би үзенең уйларын башкаларга да сөйләп бирде: «Без аннан беркайчан да игелек күрмәдек, моннан соң да күрмәбез,— диде.— Аны нидер эшләтергә кирәк. Нишләтергә — үземнең генә башым җитми — сез ни әйтсәгез, мин шуңа килешермен»,— диде.

Аксакалларга яңа бинең сүзләре төпле тоелды. Әйе, Тотышны ырудан куарга, йә булмаса, бөтенләй юкка чыгарырга кирәк. Тик менә шунысы куркыта: ыру башының углын юкка чыгару алай бик җиңел эш түгел шул. Углы белән икесен бергә йолкып атар идең, кемне куярга ыру башы итеп? Шул ук Котан бине, Акбоганымы? Монысы инде бөтенләй ярамаган нәрсә булачак. Ана корт көчле булса, корт күче дә көчле була. Ыруның анасы көчле. Аңа тияргә ярамый. Тисәң, ыру таркалачак. Шулай ук Тотышны да исән калдырырга ярамый — алай да ыру таркалачак. Таркалмаса да, яңадан башбаштак китәчәк.

Акбүренең илчеләре, аксакаллары шулайрак уй йөрттеләр. Шулай да беркемнең дә тотып кына: аны шулай итәргә, болай итәргә кирәк, дип әйтергә теле бармады. Би киемнәрен кисә дә, билек тә, көч тә Котанда түгел, Тотышта иде.

— Ике көн үтсен, ханга үзенең соңгы сүзен әйтсен,— диде Майчан аксакал аптырашкан ырудашларына.

— Юк! — диде Котан би, каршы төшеп.— Ике көн узгач соң була. Сез миңа ант иттегез, инде кирегә чабасызмы? Тотыш ике тәүлек эчендә юк булырга тиеш. Хан катына ул түгел, мин барачакмын!

Котан би беренче тапкыр ныклык күрсәтте. Ырудашлар яңа бинең яңача сөйләшүен сизми калмадылар. Бу аларга ошады да, ошамады да. Алар күнделәр. Тотыш угланны юк итүне ырудашлар үги атаның үзенә тапшырдылар.

Үги ата үзе берни уйлап таба алмады. Караңгы төшкәч ул базар башы Бигеш янына китте. Аңа ул үзенең үтенечен сөйләп бирде. Төрле кеше белән эш итеп шомарып беткән Бигеш, эре тешләрен ыржайтып, ат кешнәгәндәй көлеп куйды.

— Аннан да җиңел эш юк,— диде.— Калымга алып килгән байлыгыңның яртысын бирсәң...

Котан би ык-мык итте.

— Алайса, бөтенләй бирерсең! — диде Бигеш, зур корсагын тотып, көлә-көлә.

— Күбрәк. Аның башы аңа тормый,— диде үги ата.

— Аның башы синеке ишеләрнең меңенә тора! — диде Бигеш, күрәләтә мыскыл белән.

Кеше киеме киеп кенә би булган субашы Котан, агарынып, хәнҗәренә тотынды.

— Тсс! — диде Бигеш, бармак янап, бала-чаганы тыйган сыман.— Юкса менә моннан типкәләп чыгарырмын да ханга барып әйтермен, барлык байлыгыңны басып калырмын. Тотыштан котылмакчы булалар! Кара син аларны! Тотышны бөтен Болгар белә, Тотышны бөтен Болгар ярата. Тотыш углан Алмыш ханның иң көчле, иң күркәм алыбы, беләсең килсә. Суарларны Тотыш тез чүктерде, барлык дошманнарның котын алды. Алмыш ханга ул әйткән сүзләрне син әйткән булсаң, бүген сине каргалар чукыган булырые. Синең ише тавык башларның меңе түгел, ун меңе дә Тотыш алып башына тормый!

Котан би тирләп чыкты. Бу куркыныч, юан кешегә күтәрелеп карарга да батырчылыгы җитмичә, ул урынында таптанып тик торды. Куркудан озак кына аның авызы ачылмады.

— Калым миңа кирәк булачак,— диде ул бераздан, исенә килә башлап.— Калымны мин ханга бирәчәкмен.

— Хан сиңа ни бирер? — диде Бигеш, тычкан күзен кысып.

— Айтулдыны...

— Айтулдыны?! — дип кычкырды Бигеш.— Айтулдыны ул сиңа түгел, Тотышка бирмәкче була! Син соң кем — танымый тораммыни соң әле мин сине?

— Җитте! — диде би, барлык батырлыгын җыеп.

— Җә, килештекме? — диде Бигеш, Котан бинең изүеннән эләктереп алып.

— Килештек,— диде үги ата.— Калымның яртысы... Тик анда бүләккә дигәннәр дә бар.

— Нәрсә? — диде Бигеш, Котан бине кабып йотардай булып.— Мин берни белмим. Минем амбардагы байлыгыңның яртысы — минеке. Калыммы, бүләкме, минем өчен барыбер.

Котан би, авызын ачып, лып итеп артына утырды. Нинди кеше бу?! Нинди оятсыз бу?!

Шундый көчсез, таркау күренгән юан, симез кеше Котан бине кинәт якасыннан эләктереп алды да, ишеккә таба төрткәләп:

— Әнә бара юлың! — диде.— Кеше үтерүчеләр! Иртәгә байлыгыңнан гына түгел, башыңнан да колак кагарсың әле!

— Ярар, килештек. Барлык байлыкның яртысы сиңа,— диде Котан би, маңгай тирләрен сөртеп.

## VI

Караңгыда, песи кебек сак кына атлап, Бигеш акбүреләр «урда»сына килде. Тотышның өе аерым утыра иде. Бигеш әкрен генә тамак кырды да, эчтән тавыш килгәч, ишекне ачты. Өйдә бөтенләй дип әйтерлек караңгы иде. Учактагы кузлар сүнә язып, көл белән капланган иде. Шулай да көл катламы аша кызгылт ут җемелди иде. Шуңа күрә өй эчен әзме-күпме шәйләргә дә була иде.

— Тотыш, йоклыйсыңмы? — диде Бигеш, тамак кырып.

— Йокламыйм,— диде урында яткан кеше ачык бер тавыш белән.— Бу кем? Бигешме? Әйдә, түрдән уз.

Ул урыныннан торды, учактагы утны күрәтеп җибәрде. Бигеш тә учак янынарак килде. Икесе дә, аякларын бөкләп, киез өстенә утырдылар.

— Төнлә борчуым өчен ачуланма,— диде Бигеш, кайгылы йөз белән сүзгә башлап.— Мин барысын да ишеттем. Менә кайгыңны уртаклашырга килдем.

— Бүген генә ишеттеңмени? — диде Тотыш, базар башының җирәнгеч-ягымлы йөзенә карап алып.

— Соңгысын — бүген генә,— диде Бигеш, авызын очлайтып.— Мин аны әйтмим... Хан янында булган күңелсезлекне әйтәм.

— Һы,— дип куйды Тотыш коры гына.— Аның өчен мин кайгырмыйм. Үкенмим дә. Мин бернәрсәгә үкенмим. Төн уртасында килгәнсең икән монда, юкка түгелдер. Турысын гына әйтә алмассыңмы?

Аның күз карашы очлы, үткен иде. Ул чамадан тыш тыныч иде. Үз-үзен ул чамадан тыш иркен, ышанычлы тота иде. Аның тавышы корыч тимер чыңыдай чыңлап, яңгырап чыга иде. Элеккедән дә кырысрак, ныграк, усалрак алыпны күреп, Бигеш, кирәкле сүзен башлый алмыйча, чак-чак кына төртелгәндәй итеп торды.

— Турысын гына әйткәндә,— диде ул, иреннәрен бөрештереп,— мин сиңа изгелек эшләмәкче булып килдем, сине коткармакчы булып...

— Кемнән, нәрсәдән?

— Үлемнән, Тотыш алып,— диде Бигеш, көрсенеп.— Хан ярлыгын ташлап ике ялгышкансың. Ике ялгышың өчен дә сине үлем көтә. Менә мин сине шул ике үлемнән коткармакчы булып килдем дә!

Бигеш, нидер көткән сыман, тынып калды. Тотыш аның сөйләвен көтте. Базар башы, тычкан күзен челт-мелт йомгалап, аның йөзенә карап утыруында булды. Тотыш аңлап алды, куеныннан янчыгын чыгарды да, юан, комсыз кеше алдына ташлады. Янчыктагы көмеш акчалар, шыңшыган сыман, тонык кына чыңлап куйдылар. Бигеш берьюлы ачылып китте.

— Мин сине бик яхшы беләм, Тотыш алып,— диде ул, шундук сүзгә башлап.— Мин сиңа булышмакчы булам. Син инде би түгел. Хан, теләсә дә, теләмәсә дә, сиңа инде Айтулдыны бирә алмаячак. Шулай булгач, ике тәүлектән, юк, тәүлек ярымнан ул сине тотып алып ябып куячак. Билегеңнән баш тартып син үги атаңны көчәйттең. Ул сине бүген таңда...

— Бүген таңда?! — диде Тотыш, чак-чак кына кашларын җыерып.— Мин аның үзен таң атканчы!..

— Юк, юк! — диде Бигеш, кулын селтәп.— Алай булмый! Берүк аны уйлама. Үз утарымда, үз җиремдә мин кеше каны коелуны теләмим. Миңа читтән кеше күп килә. Яманатың чыкса, аннан соң борылып та карамаячаклар. Алай-болай син ялгышлык эшләсәң, ул чагында мин үзем сине ханга тотып бирергә тиеш булачакмын. Синең ырудашларыңа да мин шулай дидем: минем җиремдә кеше каны коярга ярамый, дидем. Алар сине, Тотыш алып...— диде ул, тавышын әкренәйтеп,— алар сине яргуламакчы булалар. Аксакаллар барысы бер сүздә. Син аларның да кытыгына кагылгансың, яман сүзләр әйткәнсең.

Тотыш, йөрәгенә чыдый алмыйча, сикереп урыныннан торды, киенә башлады. Бигеш тә аягына басты.

— Син кая барасың? — диде ул, Тотышның юлына аркылы төшеп.

— Мин аларны!..— диде Тотыш, тешләрен шыгырдатып.

— Син тагын өченче ялгыш ясамакчы буласыңмы? — диде Бигеш, кызу канлы җегетнең беләгеннән тотып алып.— Мин барында син ул ялгышны эшләмәячәксең! Сиңа котылу юлы бер генә — син качарга тиеш!

— Ничек итеп? — диде Тотыш.

— Үзем булышырмын,— диде Бигеш.— Шуның өчен дә килдем... булышырга, коткарырга...

— Койма аша чыгу угрылык санала,— диде Тотыш.— Димәк, син мине капкадан чыгарачаксың? Таң атмыйча капка ачылырга тиеш түгел. Шулай булгач...

— Син капкадан да чыкмассың, койма аша да чыкмассың,— диде базар башы.— Мин синең янга үземнең кешене җибәрермен. Каян чыгарга икәнен ул сиңа күрсәтер. Онытма: мин берни белмәдем, күрмәдем! Син койма артына чыккач та мин берни белмим, берни күрмим! Кая китәсең килә, шунда китәрсең — анда синең ирек.

Бигеш, үз сүзен әйткәч тә, тизрәк чыгып китү ягын карады. Үз өендә Тотыш берүзе генә торып калды. Бик азга гына кабынып киткән ярсу шундук юкка чыкты. Аны тагын да нindider торгынлык, ис китмәүчәнлек биләп алды. Ул әле үзенең иң зур кайгысыннан арына алмаган иде, арыну түгел — ул әле үзенең буталган уйларын-теләкләрен җайга да сала алмаган иде. Ул әле үзенең киләчәктә нишләргә тиешлеген бөтенләй белми иде. Бигеш килеп аның күзен ачты.

Чыннан да, нишләргә, ни кылырга, кая барырга тиеш соң ул? Алмыш ханнан ярлыкау үтенергәме? Ул ярлыкаган очракта да, кем булыр иде икән соң ул? Ул инде би дә түгел, тотык та түгел. Кем соң ул? Йолкыш, сукбай? Алмыш хан ап-ачык итеп әйтте түгелмени: йолкышка мин кызымны бирмим дип? Билекне кире сорап алыргамы? Кулдан очкан кошны инде ничек тотып алмак кирәк! Әйе, аның инде берние юк: киеме дә, янчыгы да, калымы да... ярлыгы да! Кылычыннан башка, хәнҗәреннән башка

аның кулында берние юк. Аңа инде беркем буйсынмый, аны инде беркем тыңламый. Шулай ук хан да тыңламас. Үзенә күпме җирләр-сулар яулап алган, үзенә күпме байлык алып кайткан Тотыш алыпны инде ул да тыңламас. Атлас тун, ак бүрек, алтынлы киң билбау дөньядагы бар нәрсәдән көчлерәк. Менә ул йола!

Күрәсең, җирәнгеч Бигеш ялганламыйдыр. Шулай булгач, тагын качаргамыни? Кая? Ырудашлар сине читкә типкәч, кая булса да барыбер түгелмени? Шулай итеп, үги ата, үги агай үч алмакчы була... Булыр. Базар башы ялганламый, ахрысы. Көч — анда, үги агайда. Көчсез кеше көчкә ия булса, иң беренче эше — үч алу.

Димәк, барысы да бетте. Бетсен. Аппак булмагач, сөю, ярату булмагач, бетсен. Шулай да үләсе килми. Үләргә әле иртә!

Бигешнең кешесе озак көттермәде. Нишләптер үсми калган, кыска гына буйлы, аксак, өтәләнгән кеше артыннан Тотыш, кылычын җайлап тоткан килеш, сак кына атлап тышка чыкты.

Тышта караңгы иде. Күктә берән-сәрән йолдызлар җемелдәшә, капка ягында кызгылт яктылык чайкала — учак яна. Өйдән чыккач та Тотыш, күзе ияләшсен өчен, беравык туктап торды, ырудашлары йоклый торган өй ягына карап алды. Анда шылт иткән тавыш та ишетелми иде. Анда гына түгел, бөтен утарда, бөтен тирә-якта тирән, караңгы тынлык саклана иде.

Шулай күпмедер тыңлап, карангалап торгач, ул кечкенә кешенең иңбашына орынып алды. Кеше еракта караеп күренгән коймага таба кузгалып китте. Койма янына килеп җиткәч, Тотышның нишләптер күңеле тырнала башлады. Әллә ничек кисәк кенә булды бу. Ныклап уйламыйча... «Нәрсәсен уйлыйсың инде?!» — диде ул шундук, үз-үзенә каршы килеп.

— Менә бу яркак кузгала. Читкә этәсең дә... Тышта — урман...— дип пышылдады кечкенә кеше.

— Башта син үзең! — диде Тотыш аңа.

Кеше карышмады, кузгала торган яркакны көчәнеп читкә этәрде дә кысылыштырып икенче якка чыкты. Аның артыннан Тотыш та чыкты. Койма тышында ул тиз генә як-ягына каранып алды. Кесәсендә торып калган ике бакыр акчаның берсен кылавызның[1] учына салды:

— Бай бул,— диде.

— Бай бул, Тотыш,— диде кеше, этенеп.

Ул бизгәк тоткандагы кебек калтырана башлады. Тотыш аны-моны абайлап өлгергәнче, ул кире утар ягына карап китте. Шул чакны аның койма артында, яркакны үз урынына җайлап куймакчы булып, нидер эшләгәне ишетелде. Агачка агач тиеп шакылдаган тавыш төнге тынлыкта куркыныч булып яңгырады. Шул ук мәлдә, Тотышның колак төбендә генә диярлек, койма өстеннән калкып торган биек манара башыннан төнге каравылчының:

— Кем ул анда? — дигән йокылы тавышы ишетелеп китте.

Бөтен койма өсте, бөтен тирә-як берьюлы кыймылдашып куйды. Әле анда, әле монда: «Тотыгыз, тот!» — дигән сүзләр яңгырады. Ул да булмады, баш очыннан гына нидер сызгырып үтте, шык итеп каты җиргә ук килеп төште. Сызгырып үткән, шык та шык иткән тавышлар күбәйгәннән-күбәя барды. Шул ук мәлдә дип әйтерлек, ур артында, караңгыда ашыгып, ябырылып килүче җәяүле карачкылар күренде.

**VII**

Димәк, барысы да алдан уйланылган булган! Үз утарында кеше үтерүдән курыкса да, утар тышында ул, симез үләксә, теләсә кемнең канын коячак. Ул аны юри качарга котырткан. Качакны үтергән өчен аңа да, башка беркемгә дә берни булмаячак.

Тотыш өчен билгесезлек, торгынлык юкка чыкты. Бөтен нәрсә, ачыкланып, үз урынына утырды. Алда — дошман. Димәк, орышырга кирәк, үз-үзеңне сакларга кирәк!

Ул койма буйлап йөгерә башлады. Койма өстендәге каравыл өйләренең ничек корылганын ул бик яхшы белә иде — өстән аткан уклар аңа тимәячәк. Аның өчен иң куркынычы — каршыга килүче җәяүле каравылчылар иде. Янында гына ышанычлы калкан — биек койма булуы аны тынычландыра төште. Ул аек баш белән бөтенесен күз алдыннан кичереп алды.

Төнге сакчылар, ашык-пошык кыланып, койманың әлерәк кенә Тотыш чыкка турысына атуларында булдылар. Урман ягыннан килеп чыккан карачкылар да, шаулап, ук ата-ата, шул турыга якынлаштылар. Караңгы коймага сыена-сыена болын ягына, Итил ягына йөгергән кешене алар абайламыйчарак калдылар, ахрысы.

Тотыш койма яныннан йөгерүендә булды. Тавышларның артта кала баруы аның күңелен тынычландыра төште. Шулай ук котылды микәнни? Шулай җиңел генә... Туктале, бу урны ничек чыгарга соң? Алда тагын сакчылар юк микән?

Ул шулай дип уйларга да өлгермәде, койма почмагында, ачыграк җирдә төркемләшеп торган өч-дүрт сакчы өстенә килеп чыкты.

Койма почмагында тирән ур аша тар гына күпер салынган иде. Сакчылар әлеге шул тар гына күпердә басып торалар иде. Аларның берсе — сөңге белән, икенчесе — кылыч, өченчесе ук-җәя белән коралланган иде. Әйе, монда барысы да алдан уйлап эшләнелгән иде. Бу инде сиңа Ямгырчы би тәбесе түгел — монда сине коткарырга Тәңкә юк!

Тотыш эсселе-суыклы булып китте. Арттан да, алдан да, уңнан да, сулдан да аңа бернинди котылу юлы юк. Берәр ничек кош булып күккә очса да, барыбер аны ук белән атып төшерерләр иде. Бары җир убылса гына...

Ярның якасына килеп җиткән Тотыш ярсып кинәт бар көченә кычкырып җибәрде. Кычкырып җибәрде дә, котырынган барыс кебек, карачкылар өстенә ташланды.

Алар да, ахрысы, аның коймага ышыклана-ышыклана килүен сизмичәрәк калдылар. Алар да, ахрысы, аны әле булса шау-шу ишетелгән төштә, дип уйладылар. Әллә соң алар аның ныклап торып якынлашуын көттеләр микән, йә булмаса, аны тере килеш алмакчы булдылар микән?

Ни генә булмасын, алар өчен бу тамак ярып кычкыру бөтенләй көтелмәгән чакта яңгырап китте. Базар башы Бигешнең яу күрмәгән, орыш күрмәгән тук, симез сакчылары каушап калдылар. Шулай да берсе сөңгесен ыргытты — сөңге коймага кадалды. Укчы ук атты — угы каядыр ур төбенә барып төште. Сакчылар яңадан коралларына тотынганчы, Тотыш аларның каршысына барып та басты, каты селтәнеп, кылычы белән берсенең аякларын чабып өзде, икенчесен күпердән төртеп төшерде дә, качып киткән өченчесен куа-куа, болын ягына ыргылды.

Аның артыннан уклар очты, куркынган өзек-өзек тавышлар ишетелде. Өченче сакчы да ерак кача алмады — урталай чабылган килеш җирдә ятып калды. Тотыш, алдын-артын карамыйча, тигез җирдән ерактагы ниндидер киртәләргә, караltыларга карап йөгерде. Аны инде берни дә куып җитәрлек түгел иде.

Ул, ниндидер каралтыларга сыенып, кача-поса, бертуктамый чабуында булды. Менә каралтылар, киртәләр дә артта калды, ул тагын иркен, буш җиргә килеп чыкты. Монда кипкән сазлык иде, ахрысы — аяк астында ниндидер түмгәкләр, агач кисәкләре калкып чыкты. Бер-ике тапкыр ул егылып алды. Егылганда ул артына карарга да өлгерде. Сыеклана башлаган караңгылыкта Бигеш утары ягында ул болын өстенә сибелгән бик күп карачкылар күрде. Алар, ахрысы, аны куа киләләр иде.

Ул уңга — Ага-базарның ярга якынрак урнашкан өйләре, алачыклары арасына борылды. Монда аңа беркем очрамады. Бөтен яр буе таң алды йокысына чумган иде.

Таң беленә башлаганда ул, Ага-базарны артта калдырып, Итилнең буш, аулак яры буена килеп җитте. Бу тирәдә аста да, өстә дә беркем күренми иде. Монда тыныч, искиткеч тыныч иде. Ул бөтенләй туктап калды, курыкмыйча артына борылып карады: куа килүчеләр инде күренми иде.

Ул текә ярдан шуышып аска төште, чабыш аты кебек тиз генә туктый алмыйча, яр буеннан җиңелчә генә йөгереп барды да барды. Ул берничек тә туктый алмады. Ул туктарга тиеш түгел иде. Ул ничек тә бу төштән, бу җирдән ераграк китәргә тиеш иде. Ул ничек тә котылырга, исән калырга тиеш иде.

Әле комлыктан, әле ташлыктан сикереп атлый-атлый, ул шулай туктаусыз йөгерүендә булды. Аның яныннан гына, аның аяк астында гына пышылдап, тирбәлеп-чайкалып Итил йөгерде. Алар әйтерсең бер-берсен узарга тырыштылар.

Юк, алар узышмадылар. Бөек, тирән, көчле Итилне ничек узмак кирәк?! Ул бары Итилдән калышмаска гына тырышты. Ул аңа иярергә, аның җаена ятарга гына тырышты.

Итил исә акты да акты. Менә шулай ул көн-төн ага, еллар, йөз еллар, мең еллар ага. Кешеләрнең орышында, үлемендә, кайгысында аның уе да юк. Сөяләрме алар, сөймиләрме, җылыйлармы, көләләрме — уйламый да, үз көенчә ага да ага. Ул шундый тыныч, ул шундый олы!

Бөек Итил, туган Итил, күрдеңме син бүген мине? Мин тагын да бер үлемнән... мең үлемнән исән калдым. Аңлыйсыңмы, беләсеңме шуны: сөеклемнән аерылып калдым... Мин кайгылы, мин сагышлы... Мин тагын да мең үлемнән исән калдым. Җиткер шуны минем сөйгәнемә, тиңсез Итил, бөек елга! Җиткер аңа минем уйларымны, җиткер аңа кайнар каным катыш аккан тозлы яшьләремне!

Туган Итилгә кайгыларын, әрнүләрен сөйләп, ул яр читеннән барды да барды.

**VIII**

Якында, яр өстендә тояк тавышлары ишетеп, ул кисәк кенә туктап калды, башын калкытты. Артта, текә яр читендә, сындай катып, атлы җайдак тора иде. Ул, ахрысы, Итил өстен, яр буйларын күзәтә иде. Ул, билгеле, аны күрмәкче булып карана иде!

Әйе, әйе, кораллы ир-атлар бөтен Итил буен бетереп аны эзлиләр иде! Әнә якында гына ачулы ирләр тавышы ишетелде, ат авызлыгы чыңлады...

Ул ачыккан иде, арыган, йончылган иде. Аның инде беркем белән орышасы да, сугышасы да килми иде. Аның бары менә шулай дәү Итил белән җитәкләшеп, серләшеп-сөйләшеп бертуктаусыз барасы да барасы килә иде.

— Үлеме, тереме — табарга! — диде баш өстендәге ачулы кеше, кемгәдер аңлатып.— Боерык шундый!

Каландырук! Алмыш ханның бурзае...

— Тирә-якны айкап чыктык,— диде чәрелдәп яшь бер ир.— Юк булгач, юк! Тамгалы каекларны карадык, Ага-базарның астын өскә китердек.

— Ул Итил ягына киткән. Күреп торганнар,— диде Каландырук.— Теге якка гына таймаса, ул бу якта булырга тиеш. Тагын бер карап чыгыгыз. Алай да табылмаса, яр буена ут төртәбез! Мин аны табарга тиешмен, мин аның канлы башынмы, янган сөякләренме Алмыш ханга илтеп тоттырырга тиешмен. Боерык шундый. Андый качаклар Болгарга талау китерә. Корыч-Тимер өчен эләгә язды инде. Монысын да ычкындырсак, эләкми калмас.

Шулай кычкырынып, алар китеп бардылар.

Ул кар-яңгыр сулары ерган ниндидер тар гына чокыр турысында туктап тора иде. Чокырның тирә-ягын чикләвек, юкә куаклары каплап алган иде. Әйе, алар аны күрми китеп бардылар.

Агач ботакларын селкетмәскә, кыштырдатмаска тырышып, сакланып кына ул яңадан кузгалып китте, комлы яр читенә төште. Коткарса, аны бары Итил генә коткара алыр, ахрысы. Төпсез Итил, иксез-чиксез, тынгысыз Итил... Тәңредән дә бөегрәк Итил генә коткара алыр, ахрысы, аны.

Яр буе шәп-шәрә, ап-ачык иде. Тотынып йөзәрдәй берни күренми иде.

Ул, бер кулына йөрәген, икенче кулына кылычын кысып тоткан килеш, яңадан Итил белән, дулкыннар белән янәшә атлап китте.

Яр буйлап бер чакрым чамасы баргач, ул көтмәгәндә ауган агач өстенә барып чыкты. Су буенча агып килә-килә, бәрелә-сугыла шомарып, муртаеп беткән үле агач дулкыннар өстендә тирбәлеп аның юлына аркылы төшеп ята иде. Колач җитмәслек юан, озын бер тирәк иде бу. Коткарса аны Итил дә шушы үле, юан тирәк кенә коткара ала иде.

Каландырук чакырткан ике йөз кешелек яңа алай Ага-базар ягындагы болынга таралып, барлык чокыр-чакырларны, куакларны, камыш-түмгәк араларын тоташтан айкап килә башлаганда, еракта, яр өстендә киек аулаучы сунарчылар сыман һай-һулап кычкырган куркыныч тавышлар яңадан ишетелә башлаганда, Тотыш юан тирәкне тирән җиргә этеп чыгарды. Тирәкнең нечкә башына, киселгән ботак янына ул үзенең киемнәрен, коралларын бәйләде. Ике кулы белән дә агачка тотынып, кыйгачлый-кыйгачлый ул агым белән түбән таба йөзеп китте.

Көзге су инде суынган иде. Балалар да, өлкәннәр дә бу көннәрдә су керүдән туктаганнар иде. Тотыш суның суыклыгын бөтенләй диярлек сизмәде. Ул әйтерсең суны тоймады да. Ул бары үзенең ярдан тизрәк читләшергә, елга уртасына чыгарга, аннары каядыр ераккa, икенче якка барып җитәргә тиешлеген генә аңлады. Инде ул үзе калдырып киткән ярга да борылып карамады, ул яктагы тавышларга да колак салмады. Якында гына аларның каеклары да, көймәләре дә юк. Яр буйлап куа ки-лүләре дә ишетелми. Алар әле булса өстә, болында — куаклар, чокыр-чакырлар арасында кычкырыналар иде бугай.

Туган Итил! Олуг Итил! Агыз тизрәк. Коткар мине дошманнардан! Исеңдәме, күптән түгел калан бирдем мин сиңарга? Ачуланма миңа, үпкәләмә миңа. Алып чык син мине дулкыныңда ирек ярына.

Тәңрем! Синнән баш тартып мин бик языклы булдым. Акбүренең изге ияләре, сезне онытып мин игелексез булдым. Туган җирем, туган ыру! Изге анам Койтым бикә! Кичерегез, ярлыкагыз мине. Миңа сезнең каргыш төште. Ана кендегеннән аерылган бала кебек, мин дә аерылдым сездән. Кичерегез, ярлыкагыз мине! Мин сезнеке түгел инде. Мин берьялгыз. Мин — йорт-җирсез, мин — ырусыз, мин — Тәңресез. Беркемем юк минем... Мине Итил алып китте, аерып китте. Сау булыгыз, бай булыгыз, туган җирем, туган илем!

Тик шулай да минем кендек өзелмәгән сездән. Минем күңел аерылмаган сездән. Ерагая барган саен, минем арттан сез киләсез, туган җирем, олуг Чулман, изге анам Койтым бикә!

Кичерегез, ярлыкагыз мине!

Тиңсез Итил! Илт син мине каган каласына, илт син мине сөйгәнемнең канлы-яшьле эзе буйлап.

Каландырукның кешеләре ал-ял белми аны эзләделәр. Яр буйларын, якындагы урманнарны, чокыр-чакыр араларын — барлык шикле урыннарны тентеп, актарып йөрделәр. Алмыш ханга ярарга теләп, Каландыруктан бигрәк Котан би тырышты. Ул үзенең барлык ирләрен үги угылын, үги энесен эзләргә җибәрде. Базар башы Бигеш кайгысыннан кара күмер кебек янды. Тотыш аны утыртты төп башына! Бөлдерде, акыртып талады! Өч сакчысы юкка чыкты. Чит ил сатучылары, куркышып, юлга җыена башладылар. Ага-базарда сату-алу бозылды. Шуның өстәвенә, аның якасыннан алып, хан әйтте: «Тотыш алып табылмаса, мин синең барлык байлыгыңны тартып алам, үзеңне утлы табага бастырам»,— диде.

Каландырукка хан әйтте: «Тапсаң, мин сине субашы ясыйм»,— диде.

Котан бигә хан әйтте: «Тапсаң, мин сине киявем итәм»,— диде.

Шуңа күрә дә алар, кара тиргә батып, телләрен салындырып, бөтен җирдән аны эзләделәр.

Ул, юан, кара агачка тотынып, агымга кыйгачлый-кыйгачлый, елга уртасына таба йөзде дә йөзде. Итил уртасыннан агып барган ташландык агачны күрмәделәр түгел — күрделәр. Тик шул агачка тотынып, муеныннан көзге салкын суга чумып, Тотыш йөзеп барадыр дип уйларга беркемнең дә башына килмәде. Әз мени суда агып барган ялгыз агач!

Ул түбәнгә таба акты да акты. Туган Итил, көчле Итил, иркәләп, тирбәлдереп, яман күзләргә күрсәтмичә аны алып китте. Ага-базар, Каландырук, кораллы ирләр — барысы да бик еракта, артта калды. Инде шактый ара үтелде. Инде икенче якка да чыгарга булыр иде. Тик әлегә аның чыгасы килмәде. Бу тирәдә уң якта да аны ханга тотып бирүләре бар иде.

Ул арада көн дә кичегә башлады. Су өстеннән салкынча җил исәргә тотынды. Тотыш агачка йөзтүбән капланып бара иде. Ул туңа башлады. «Ярга чыкмый булмас»,— дип уйлады ул. Текә яр башындагы кечкенә авылдан, таш кыя астында посып утырган ялгыз алачыктан башка бу тирәдә кеше-кара булуы турында сөйли торган берни күренми иде. Ул кечкенә авылны да, ялгыз куышны да узып китәргә булды.

Җил арттан исә иде, шуңа күрә агачны ярга таба алып баруы аңа бик үк авыр булмады. Шулай да ул күңеленнән чамалаган төштән шактый еракка барып чыкты. Су эчкән, муртайган авыр агач, яр читендәге вак ташларга килеп төртелү белән, ул су төбенә басты, коры җиргә чыкты. Шуннан соң ул агачка бәйләнгән киемнәрен чишеп алды, тирәкнең нечкәрәк башын коры җиргә тартып куйды. Агачның әле кирәге булуы бар иде, аны әле кулдан ычкындырырга ярамый иде.

Ул коры киемнәрен киде, күнчегендәге ку белән чакма ташын, тун якасына эләктерелгән кармагын капшап карады. Барысы да үз урынында иде. Болай булгач, яшәргә була! Тик ул бүгенгә балык каптыру белән булашмаска булды: аяк астындагы коры-сарыларны җыештырды да беренче эше итеп ут ягып җибәрде. Ут янында аның күңеле күтәрелеп китте.

Утка ул әле бер ягын, әле икенче ягын куйды, җылынды, кибенде. Яр астында ышыкланыр өчен җайлы урын юк иде. Ул куыш ясап тормады. Ул инде бик нык арыган иде. Баш астына корыган үлән йолыккалап салды да, кылычын, хәнҗәрен тун астына яшерде дә җайлап җир өстенә сузылып ятты.

**IX**

Бермәлне ул йокы аралаш үзенең янбашы бик нык җылынганлыгын тоеп, кабаланып аягына торып басты. «Ут капкан, ахрысы»,— дип уйлады ул, куркып. Күзен ныклап торып ачып җибәргән иде, су өстенә балкып кояш чыккан, көн яктырган... учак сүнгән... якында гына, яр буенда, караеп, ямьле көннең ямен җибәреп, очлы борынлы бик зур каек калкып тора! Арттарак, яр буенда тагын берничә каек күренә...

Якында гына, аның колак төбендә генә тыелып көлгән тавыш ишетелеп китте. Тотыш сискәнеп артына борылды. Аның каршысында, биленә таянып, ят бер кара кеше басып тора иде. Ят кешенең ике ягында берничә кораллы кеше бар иде.

— Фатих! — диде Тотыш, кара кешене танып алып.

— Тотыш! — диде Фатих, ак тешләрен елтыратып.— Сине анда эзлиләр. Минем арттан куа киләләр. Әйдә, утыр тизрәк. Кунагым булырсың.

— Син... нишләп монда? — диде Тотыш, кораллы ирләргә каранып.

— Мин илемә кайтып барам,— диде гарәп сатучысы.— Синең җирдә — мин кунак, минем каекта — син кунак. Кайда телисең, шунда төшереп калдырам.

Тотыш утырды. Ул утырмыйча булдыра алмады. Ул моңа сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәде. Чит каекка атлаганда аның йөрәге өзелеп төшкән кебек булды. Ул, нәрсәсендер калдырган сыман, үзе яккан учак ягына соңгы кат күз төшереп алды.

Аңа ашарга, эчәргә китерделәр. Ул бар нәрсәсен онытып ашаган-эчкән арада, Фатих ибн Әхмәтнең яр буена туктаган каеклары берәм-берәм кузгалып киттеләр дә Итил уртасына каердылар. Алар түбәнгә, көн ягына карап бардылар.

Гарәп сатучысы Фатих ибн Әхмәт, көн-төн байлык артыннан куса да, алай бик үк ашыгырга да яратмый иде. Ул барысын да уйлап, белеп, үлчәп эшләргә күнеккән иде. Ел тәүлегенең күбрәк өлешен юлда, читтә үткәрергә туры килгәнгә, ул кайда да үзен өендәге кебек тотуны яхшы дип саный иде. Намаз укырга кирәкме — кырык эше кырылып ятса да, кичекмичә ул үзенең намазын укый, ашар чак җиттеме, шулай ук, бернигә карамыйча, тамак ялгау ягын карый иде. Бары тик Болгар җирендә генә, көньякның кайнар кояшы, ком-бураннары белән чагыштырганда, кеше яши алмаслык салкынлык иле булып та, тоташ яшеллеккә күмелгән оҗмах булып та тоелган бу искиткеч бай җирдә ул, үзе дә сизмәстән, иркенләп, туарылып китә торган иде. Монда тормыш талгын гына, ашыкмыйча гына ага. Шау-шулы, кызу канлы Багдадлар, Бохара, Сәмаркандлар, Кустантиннар, Итил-торалар янында Ага-базар, Болгар-тора... Биләр, Суар, Шураннар яңа гына туган балалар сыман тоела. Монда инде туарылырга теләмәсәң дә туарылырга туры килә! Кайчакларда, үзенең мондый ялкаулыгына эче пошса

да, беркатлы сабый балалар, беркатлы сабый кешеләр аңа ныграк ошый иде — аларны... алдавы җиңелрәк иде...

«Сабый» Болгарда гарәп сатучысы бигрәк тә җирне-суны, аеруча — шушы Итилне ярата иде. Үзенең ташкынлыгы белән, ярларының гүзәллеге, суының арыклыгы1 белән Итил җир йөзендәге Фатих ибн Әхмәт белгән бер генә елгага да охшамаган иде. Анда, Болгар ирләрендәге сыман, сокландыргыч батырлык та, тыелгысыз кыргыйлык та, болгар кызларындагы сыман күреп туймаслык күркәмлек тә, тыйнак юашлык та бар иде. Гарәп базаргany, су өстеннән искән салкынча җилгә битен куеп, яр читләрендәге кыяларга, күгелҗем урманнарга, яшел болыннарга карый-карый, көннәр буена үзенең - каегында, борындагы йомшак урынында тын гына утырып барырга ярата иде. Шулай таң калып, исе китеп күпме генә карап бармасын, беркайчан да ул үзендә ялыгу, йончылу шикелле нәрсә тоймый иде. Көнозын талгын гына тирбәлеп йөзгәннән соң, ул кичкә таба яр буенда берәр җайлы, матур урын сайлап туктый да төнен шунда куна — ашый-эчә, күңел ача иде. Итил буйлап кайтканда ул бөтен бер ел өчен, киләчәк өчен үзендә яңа көч туплый иде.

Башка елларны шулай иде. Тик бу юлы Фатих ибн Әхмәт ашыгырга кирәк тапты. Каеклар бик кызу бардылар. Алар, караңгы төшү белән, элеккечә ярга борылмадылар, очлы борыннары белән дулкыннарны ярып, туктаусыз алга баруларында булдылар.

Гарәп сатучысы Тотышка юри генә, куркыту өчен генә: сине куа киләләр дип әйтсә дә, бу юри әйтелгән сүз аның үзенә бераздан чын булып тоела башлады. Кем белә аларны, чыннан да берәр нәрсә сизенеп, Каландырук арттан кешеләр җибәрсә! Сизенмәсә дә, болай гына да ул яр буйларын тикшерү өчен каеклар җибәрә ала ич. Аннары яр буендагы сакчыларны алдан кисәтеп куюлары да бар.

Менә шуңа күрә дә гарәп сатучысы бу юлы, тукталып тормыйча, барды да барды. Хан кешеләренә тоттырмаган качакның җиңел генә, бөтенләй көтмәгәндә үз кулына төшүенә ул чиксез куанса да, соңга таба бу куаныч тойгысына борчылу-курку тойгысы кушылды. Ул, качакның үзендә икәнлеген белгертмичә, ничек итеп болгарлар җиреннән ычкынырга икән, дип борчылды. Болгарларның яшерен илчесе Башту углы Габдулланы Багдадка илтеп җиткерү бурычына караганда, Тотышны Болгардан алып чыгу бурычы аңа кыенрак тоелды. Алмыш ханга ул берьюлы изгелек тә, явызлык та эшли иде. Тик, тузандай явызлык та тубалдай изгелектән яманрак саналганга, Фатих ибн Әхмәт, эшләгән изгелегем өчен хан минем явызлыгымны кичерер, дип, үз-үзен юата алмады. Ни генә булмасын, Алмыш хан күзе алдында аның яманатлы булып каласы килмәде, аннан да бигрәк, аның атаклы Болгар тиреләреннән, бал-балавыздан, ак тәнле коллардан — үз илендә унар тапкыр кыйбатрак сатыла торган товарлардан колак кагасы килмәде.

Тотылган очракта ул Тотышны болгарлар кулына бирә ала иде, билгеле. Тик аның алай итәсе килмәде. Аның өчен Тотыш элекке таныш-белеш кенә түгел, аның өчен Тотыш — байлык та иде.

Тотышка ул гарәп ишкәкчеләренең киемен бирде, аны ишкәк төбенә утыртты. Качак, бернинди каршылык күрсәтмичә, берни сорашмыйча, ишәргә тотынды. Ул каекларның тизрәк Болгар җиреннән чыгып китәргә тиешлекләрен дә, үзенең гарәп сатучысына көченнән килгәнчә булышырга тиешлеген дә бик яхшы аңлады. Шуңа күрә дә ул берни эндәшмәде.

Шулай да телсез кеше кебек, чылбырга бәйләп куелган кол кебек, бер урыннан кузгалмыйча, тукталмыйча ишеп бару аны озакламый ялыктыра башлады. Фатих ибн Әхмәт нишләптер аның янына килеп тә әйләнмәде. Ишкәкчеләр сөйләшмәделәр. Бу кара кешеләр арасында ул үзен чит, ят итеп тойды. Бу аның саруын кайнатты. Ник сөйләшми гарәп сатучысы? Кая алып бармакчы була ул аны? Кунак булган кешене шулай көн-төн ишкәк төбендә утырталармыни?

Менә алар, биш тәүлек буена туктаусыз барганнан соң, болгарларның калку яр башына урнашкан чик буе катаулары яныннан узып киттеләр. Аларны туктатып тикшерүче булмады. Бары катаудагы манаралардан озын кулын болгап, ак юл теләп, сыек зәңгәр төтен генә озатып калды.

Фатихның караңгы йөзе яктырып китте, ишкәкчеләр үзара шаулашып алдылар, болгар сүзләрен вата-җимерә, саргая башлаган тал куаклары белән капланган яр буена күрсәтә-күрсәтә, Тотышка тиздән ярга туктау, ял итү турында аңлатырга тотындылар.

Чик буендагы катауны узып, бер дүрт-биш чакрым түбән төшкәч тә, каеклар сул як ярга борылдылар.

## X

Тирә-ягын таллыклар, камышлыклар, вак-вак күлләр әйләндереп алган бу утрау сыман җирне гарәпләр электән үк беләләр иде, ахрысы. Ярга төшү белән алар беренче адымнарыннан ук үзләрен үз җирләрендәге, үз өйләрендәге кебек тота башладылар: шундук чатырлар кордылар, учаклар яктылар, кичке ашка суярга дип, каеклардан куйлар төшерделәр, азык-төлек, эчемлек, савыт-саба ташыдылар. Берничә кеше таллар, камышлар арасына ауга китте: бу тирәдә, күрәсең, җәйрәннәр, сайгаклар бар иде.

Чатырлар корылып, казаннар асылгач, утрауга агарынган, куркынган кол кызларны төшерә башладылар. Гарәп сатучысы аларны Ага-базарда алган иде. Алар барысы да яшьләр, оялчаннар иде.

Кызларның күбесе болгарлар иде, арада ерактан китерелгән урыслар, уйсулар, ар, чирмеш, мукшылар да бар иде. Кара сакал-мыек баскан кара гарәпләр янында алар үзләренең ак киемнәре, ак битләре, ак кул-аяклары белән әллә каян аерылып торалар иде.

Озын басмадан тезелеп ярга кызлар чыга башлагач та, утраудагы шау-шу кинәт тынып калды. Учаклар, чатырлар тирәсендә булашкан ишкәкчеләр тынып, эшләрен ташлап, кызларга карап тордылар. Телсез-өнсез калып соклану шулай да озакка бармады — оятсызраклары кызларга якынрак килделәр, авызларын ерып, телләрен шартлатып, үзләренчә берәр сүз әйтеп куйдылар. Аларга башкалар кушылды. Богадай таза, яшь ирләр, кыргый бер куаныч белән, тыелгысыз бер шашыну белән шауларга, гөрелдәргә тотындылар. Кайберәүләр, чамадан тыш батыраеп, кызларның беләкләренә, түшләренә үрелделәр. Печтерелгән ирләр — сакал-мыеклы ишкәкчеләрдән дә тазарак, озынрак сакчылар, бәйләнчек чебеннәрне куган сыман, аларга юан таяклары белән селтәнеп-селтәнеп алдылар.

Печтерелгән сакчылар кызларны утрауның аргы башынарак алып киттеләр. Үзләренә карап торган аттай ирләр өереннән тартынып, качып-посып, кызлар үз йомышларын йомышладылар. Шуннан соң аларны яңадан су янына, яр буена алып килделәр. Казлар кебек каңгылдашып кызлар су керделәр, юындылар, керле киемнәрен юдылар.

Тотыш, айгыр кебек кешнәгән, шаркылдашкан гарәпләргә катнашмыйча, аптырап, тынын кысып, бер читтәрәк басып торды. Аның инде шәрә кол кызларны гына күргәне бар иде. Тик аның беркайчан да, беркайчан да мондый кыргыйлыкны, мондый оятсызлыкны күргәне юк иде. Аның ыруында, аның илендә хатын-кызга — колмы, иреклеме ул — кайчан да кеше итеп карыйлар иде. Кыргый урманнар арасында, аюлар, бүреләр янында яшәгән «сабый» кешеләр өчен хатын-кызның кешелек тойгыларын кимсетү, аны түбәнсетү үзе иң зур кыргыйлык саналыр иде. Телсез-өнсез, үксез яшь кызларны кызганудан аның йөрәге кысылып-кысылып куйды. Чит, ят ыру, чит, ят тел ирләре арасында калган үз туганнары, үзенең кан-кардәшләре аңа бүреләр өере арасындагы куйлар булып тоелды. Кайсыдыр ягы белән аның үз язмышы да, Аппак язмышы да шушы кол кызлар язмышы белән бер тоелды. Сакаллы айгырларның бөтенләй кирәкмәгәнгә, авыз күтәреп, оялчан, тыйнак кызлардан көлүләре аңа үзеннән көлү булып, үзенең күңелендәге иң нечкә кылларны аяк астына салып таптау булып тоелды.

Кемдер арттан килеп аның иңбашына кулын салды. Ул тиз генә артына борылып карады.

— Чибәрләрме? — диде гарәп сатучысы, су коенучы кызларга ымлап.

Ул, күрәсең, Тотышны кызларга ымсынып карый дип уйлаган иде. Ул, күзгә бәрелеп торган эре, ак тешләрен елтыратып, зур эш башкарганнан соң гына була торган бер куаныч белән, тыелып кына кеткелди иде.

— Чибәрләр,— диде Тотыш, аның кара йөзеннән тизрәк күзен читкә борып.— Болгар кызлары ямьсез булмас.

— Кайтканда мин гел шушында туктыйм,— диде гарәп сатучысы.— Ике-өч көн туй ясап, күңел ачып алам. Кешеләргә дә ял бирәм. Гүзәлләрнең тәмен иң элек шушында татып карыймыз. Шуңа Кызлар утравы димез бу җирне. Болгарда түрә каты — гарәп ишкәкчесе кызларга якын бара алмый. Сатып алырга аның акчасы юк. Монда мин аларга тулы ирек бирәм. Моннан ары юлда кызлар да, ирләр дә үзләрен тынычрак тотачаклар. Юкса, кыен мондый товар белән. Сакчылар гына тыя алмый. Былтыр шулай Муса атлы яһүдинең ишкәкчеләре, сакчыларны кырып, Мусаның үзен таш белән суга бәйләп ташлаганнар. Кызларны алып качканнар. Тот син аннан соң аларны! Мин алай итмим. Этне озак бәйдә тотсаң, тилерә башлый. Бүген туй ясыймыз. Син минем кунагым. Башта син сайла. Кайсы ошый... Үзеңә бер чатыр бирәм. Оҗмах менә шушында инде, Тотыш алып, хе-хе!..

— Миңа барысы да ошый,— диде Тотыш, караңгы чырай белән.

— Барысы да ярамый,— диде гарәп, шаркылдап.— Барысы да! Ха-ха! Ха-ха! Берне генә, Тотыш алып, берне генә! Ирләр күп. Кызлар болай да җитәрлек түгел.

— Алайса, миңа бөтенләй кирәкми,— диде Тотыш.

— Кирәкми?!

— Кирәкми.

— А-а! Аңлыйм! Йөрәк яна? Хан кызын онытмаган? Аппакны? Гүзәл кыз. Тиңсез йолдыз. Сокланам да, аптырыйм да мин сезгә, болгарлар. Сез... артта калган... кыргый... Шулай да сезнең күңелегез бөек! Хан кызын син оныт, Тотыш алып. Хан кызы юк! Ул инде каган куенында, хе-хе... Ир кешегә төн кунарга кыз булсын, гыйшык, ярату ир кеше эше түгел. Ир кешенең эше — байлык җыю.

— Фатих! — диде Тотыш, калтыранып.— Мин синең кунагың. Мыскыллама! Кызларың миңа кирәкми.

— Туктале, кызмале,— диде гарәп сатучысы, аның беләгеннән тотмакчы булып.— Миндә әле иң сылулары бар. Мин аларны бик нык саклыйм. Алары беркемгә бирелми. Мин аларны сатам гына. Синең өчен, Тотыш алып...

— Юк! — диде Тотыш, кискен итеп.

Борылды да, гарәп сатучысын аптыраšта калдырып, читкә китеп барды.

**XI**

Ул утрауның иң аулак урынына, каеклардан читкә, яр буена килеп утырды. Аның беркемне дә күрәсе килмәде. Аңа бөтенесе җирәнгеч, әшәке булып тоелды. Монда, үзен коткаручылар арасында, ул үзен теле, ыруы белән генә түгел, үзенең күңеле, үзенең уйлары-теләкләре белән дә чит-ят итеп тойды. Аппакны искә төшереп гарәп сатучысы аның күңел яраларына әйтерсең учлап тоз сипте, әйтерсең аның йөрәген очлы пычак тыгып айкады. Аның җылыйсы килде, җиргә ятып ауныйсы, йә булмаса, бар нәрсәне кырып-җимереп бетерәсе килде.

Ул, күтәреп булмаслык авыр төшенкелеккә бирелеп, шактый озак утырды. Түбә өстен инде караңгылык каплап алды, ашаучы-эчүче ирләр ямьсез итеп җырлар җырладылар, яр буендагы талларны калтыратырлык итеп, ямьсез тавышлар белән шаркылдап көлделәр. Аяк астында исә, яр читләренә кагылып, пышылдап су акты да акты... Шул ук Итил. Нинди зур ул, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз ул Итил!..

Ул ачыга башлады. Аны беркем ашарга да чакырмады, эзләп тә килмәде. «Мин кем? Мин нишләргә тиеш, ничек яшәргә тиеш киләчәктә?» — дип уйлады ул тирән борчылу белән. Кая бара соң ул? Ник аңа ачык кына беркем дә берни әйтми? Колмы ул, ишкәкчеме, әллә кунак кынамы? Исән-имин барып җитә алырмы ул Итил-торага?

Аның исерек ишкәкчеләр янына барасы килмәде. Ул утырды да утырды. Көтмәгәндә артта ниндидер аяк тавышы ишетелде. Ул сагаеп көтә башлады. «Фатих микәнни?» — дип уйлады, иренеп кенә. Ул инде тынычланган, юашланган иде. Күңелендә ташыган ярсу уйлар-сораулар инде онытылган, төссезләнгән иде. «Сак булырга кирәк аның белән»,— дип уйлады ул гарәп сатучысы турында.

— Тотыш, син мондамы? — диде арттан килгән кемдер, аның янында гына туктап.

Ул моны ап-ачык итеп Тотышның туган телендә әйтте. Тотыш аягына басты. Бу — Фатих түгел иде. Бу ниндидер үз кеше иде!

— Син кем? — диде Тотыш, дулкынланып, карачкының йөзен күрергә тырышып.

Бу — Алмыш ханның яшерен илчесе Габдулла иде. Ул үзенең кем икәнлеген әйтмәде, бары:

— Мин синең юлдашың,— дип кенә куйды.

— Син безнеңчә яхшы сөйләшәсең,— диде Тотыш.

— Синең телең — минем туган телем,— диде Габдулла.

— Син кем? — диде тагын да Тотыш, кызыксынып.— Ничек бу болай? Кол түгелсеңдер ич син??

— Түгел,— диде Габдулла, Тотышның кулыннан алып.— Мин сине ашарга чакыра килдем, Тотыш. Болай үпкәләп утыру килешми. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың. Берни эшләп булмый. Фатих миңа әйтте. Аның ачуы килгән.

Тотыш берни эндәшмәде. Шулай ук ул аңа карышып та тормады. Алар икәүләп учак янына бардылар. Ул анда ашады, эчте. Шуннан соң алар яңадан икәүләп яр буена килделәр дә, төнге Итилгә — елк-елк килеп аккан каралҗым су өстенә карап, сүзсез генә утырдылар.

— Минем инде күптән синең белән сөйләшәсем килә, Тотыш,— дип, әкрен генә сүзгә башлады Габдулла.— Минем туган җирем — Итил-тора. Синең кебек мин дә туган илемнән качып киттем. Минем барлык байлыгым, өем, терлек-туарым Итилдә торып калды. Синең кайгыңны мин аңлыйм. Шуңа да менә сөйләшәсем килде.

— Син ник качтың? — диде Тотыш.

— Сөйләсәң, күп инде,— диде Габдулла, көттеребрәк.— Мин — мосылман. Җөфүтләр белән килешә алмадым. Кыскасы, шул. Мин үземнең йолам-динем аркасында талау күрдем.

— Син мулламы әллә? — диде Тотыш.

Габдулла эндәшмәде.

— Мин менә сөюем, яратуым аркасында качак булып йөрим,— диде Тотыш, көлгәндәй итеп.— Синең сөйгәнең, алайса, йола... гарәпләр йоласы булып чыга?

— Шулай дисәң дә ярый,— диде Габдулла, килешеп.— Тик монда эш коры йолада гына түгел, эш монда тирәнрәк.

— Минем өчен барыбер: йола булгач йола! — диде Тотыш.— Минем дә менә берәр белгән кеше белән сөйләшәсем киләдерие. Аңлатып бир әле миңа... нишләп шулай табына кеше йолага? Ата-баба йоласына да түгел — гарәпләр йоласына табына! Ник кирәк ул сиңа? Әнә шулай безнең кызларны тире кебек, агач, терлек кебек итеп сатып алып китсеннәр өченме, теләсә кайда теләсә ничек мыскылласыннар өченме?! Шулар арасында синең сөйгәнең булса... сеңелең, кызың, апаң, анаң булса, нишләриең син?! Ничек карарыең, ничек түзәриең шуңа?! Әнә алар, яхшы йолалы, алдынгы, белекле кешеләр минем сеңелләрне... Йола! Шул турыда ишеттемме, минем каным кайный башлый, кемнеңдер бугазын чәйнәп өзәсем килә! Мин туганнан бирле ата-баба йоласын тоттым. Сөйгәнемә өйләнү өчен мин бернигә карамый гарәп йоласына күчтем. Мулла әйтте: Алладан көчле беркем, берни юк, диде. Җөфүт каган минем сөйгәнемне тартып алып киткән. Инде әйтеп кара: кем көчлерәк?

— Син языклы сүзләр сөйлисең, Тотыш! — диде Габдулла, куркып, төкеренеп.— Сине иблис буташтырган!

— Мине беркем буташтырмады,— диде Тотыш.— Мин сиңа туры сорау бирәм, син шуңа туры җавап бир. Кемгә, нәрсәгә инанырга?

— Бер Аллага инанырга! — диде Габдулла, нык итеп.— Минем дә йөрәгем әрни, минем дә каным бозга әйләнә. Ел саен күпме безнең кызлар, безнең ирләр чит илләргә озатыла! Ата-аналар, терлек саткан кебек, комсыз сартларга, татларга үз балаларын сатып җибәрәләр. Ата-баба йоласы моңа каршы килми. Ханнар, биләр моңа чик куя алмыйлар. Кайчан безнең олуг Итилгә кардәшләребезнең каняшьләре акмый башлар?! Мин дә уйлыйм, мин дә янам, Тотыш! Бу оятлы, түбән эштән безне Тәңре коткармады. Алла коткарачак! Мосылман йоласы мосылманны товар итеп, кол итеп сатуны тыя. Безнең илләр мосылман булса, безнең туганнарны беркем сата да, сатып та ала алмаячак. Котылу юлы менә шунда, Тотыш.

— Алай икән,— дип куйды Тотыш, килешкән сыман итеп.— Шулай да мин аңлап җитмәдем әле: ата-баба йоласында булганда да ник бу эшкә чик куеп булмый? Ата-баба йоласындагы кеше кеше түгел, мосылман йоласындагы кеше генә кешемени? Алла шуңа юл куямыни? Нишләп соң гарәп ишкәкчесе ата-баба йоласындагы кол кызга бүген терлеккә караган кебек карый да, ни өчен иртәгә... кол кыз мосылманга әйләнсә, аңа кеше итеп карый башларга тиеш? Гарәп йоласына кучү белән мин... син... ул кызлар әллә икенче төрле кешегә әйләнәләрме? Ни өчен гарәпләр чын кеше дә, башкалар чын кеше түгел?!

— Алла каршында бары аның коллары гына... чын кешеләр, изге кешеләр,— диде Габдулла.

— Юк, барыбер аңламыйм! — диде Тотыш.— Мин моны беркайчан да аңламадым. Үз ыруымнан Болгарга килеп яши башлагач та аңламадым. Мин анда төрле йоладагы кешеләрне күрдем. Юк, мин аңлыйм да аны. Тик үземчә аңлыйм. Барлык йолалар да бертөсле. Алар бары төрлечә атала гына. Минем үзем өчен инде барыбер. Кем йоласына табынсам да — барыбер. Мин — йортсыз, җирсез, ырусыз...

— Менә шул турыда сөйләшмәкче булганыем да мин синең белән,— диде Габдулла.— Мин сиңа әйтмәдем... Мин... Багдадка барам. Җөфүтләрдән качып. Миңа ышанычлы юлдаш кирәк. Синең кебек таза, яшь... Мине синең язмышың да борчый. Күрмәгән-белмәгән булып мин болай гына синең яннан узып китә алмыйм. Кире Болгарга кайтсаң, сине анда үлем көтә. Фатих белән китсәң, сине анда нәрсә көтәдер, анысын әйтүе кыен. Ул ачык кына берни әйтми. Син үзең ничек уйлыйсың? Нишләмәкче буласың син?

— Белмим,— диде Тотыш, төшенкелек белән.— Минем әлегә юлым билгеле түгел. Барлык уйларым-теләкләрем юкка чыкты. Мин әлегә берни уйлый алмыйм. Сөйгәнемнән башка миңа кызык та, ямь дә юк. Миндә бары үч тойгысы гына ялкын булып дөрли. Туң ташны да эретердәй үч, ярсу гына бар миндә. Бирегез миңа мең кешелек чиру — бүгеннән барып каганның йортын туздырам, сөйгәнемне йолып алам! Бармы синдә андый чирү? Булса, бүгеннән мин синең колың, юлдашың.

— Күреп торасың — миндә чиру юк,— диде Габдулла, тавышын әкренәйтеп.— Мин менә шундый чиру, көч эзләп барам. Багдадта бар андый көч! Мосылманнарның баш кешесендә. Мин менә шунда барам. Безгә ничек тә шунда барып җитәргә кирәк! Синнән дә яхшы юлдашны мин эзләсәм дә табалмам. Ашыкма, уйла. Иртәгә әйтерсең.

## XII

Габдулла, саубуллашып, урыннан торды. Тик ул кузгалып китә алмады, җир астыннан чыккан кебек, аның каршысында Фатих ибн Әхмәт калкып чыкты.

— Тукта! — диде ул, яшерен илченең күкрәгенә хәнҗәр терәп.— Алла белән ант итәм: мин барысын да ишетеп тордым! Икәүләп сез яманлык уйладыгыз.

Тотыш, гарәпнең ачулы сүзләрен ишетеп, тиз генә урыныннан сикереп торды.

— Кузгалма! — диде сатучы аңа да.

Таллар арасында кыштырдык ишетеп, Тотыш як-ягына каранып алды. Аларны төрле яктан кораллы ирләр уратып алган иде. Бары су ягында гына беркем юк иде. Әнә анда да ирләр тулы көймә шуышып чыкты!

Гарәп базаргány үз телендә кораллы ирләргә нидер әйтте. Тотыш исенә килеп өлгергәнче, ике яктан ике таза ир аның беләкләреннән тотып та алдылар, каердылар, кыл аркан белән бәйләп тә ташладылар.

— Карышма, курыкма, Тотыш алып,— диде Фатих ибн Әхмәт.— Сиңа берни булмас — син минем кулда.

— Сиңа ни булды, Алла колы? — диде Габдулла, аптырап, шаккатып.— Ни эшең бу?

— Миңа булмады — сезгә булган! — диде гарәп.

Ул исерек иде, аның сүзләрендә ниндидер кыргый куаныч бар иде, сычкан эләктергән мачы мырлавына охшаш бер куаныч бар иде.

— Исерек башыңа... языксыз мосылманга кул күтәрергә ничек батырчылык итәсең? — диде Габдулла, кычкырына башлап.
— Хе-хе,— дип көлемсерәде гарәп сатучысы, биленә таянып.— Сез, болгарлар, барыгыз да ярым мөселманнар. Бозык мөселманнар. Аллага тел тидерәсез. Мин ишеттем. Сез миңа яманлык кыласыз. Икегезне дә сатлык дип ханга озатсам?!
— Хәмер синең акылыңны алган! — диде Габдулла.
— Алла белән ант итеп әйтәм, юк! — диде Фатих ибн Әхмәт.— Әйдә минем чатырга, шунда сөйләшербез.
Алар җилләнеп китеп бардылар.
— Башту ибн Габдулла,— диде гарәп, үз чатырына кереп, зур сандыгы өстенә утыргач.— Мин синең белән турысын сөйләшмәкче булам. Мине юлбасар дип уйласаң, син языклы булырсың. Мин сине тиешле җиргә илтеп җиткерергә ханга сүз бирдем — сүземне үтәрмен. Син минем эшемә кысылма. Тотыш белән нәрсә сөйләштең яшерен?
— Анда синең эшең юк! — диде Габдулла, кискен генә.
— Мин ишеттем. Син минем колымны...
— Колыңны?! — диде Габдулла, күзләрен зур ачып.
— Минем колым Тотышны...— дип төзәтте гарәп сатучысы. Тотышны мин таптым. Шулай булгач, ул минем колым, ул минем товар.
— Син аны кунак итеп алдың,— диде Габдулла.— Юлбасар булдыңмыни?! Ханбалыкка җиткәч мин сине...
— Барып җитә алсаң! — диде сатучы, янап.— Сез икегез дә минем кулда. Нишләмәкче буласыз сез?
— Син нишләмәкче буласың? — диде Габдулла, ярсуына буылып.— Берәр нәрсә эшләп кенә кара! Минем сиңа утырып юлга чыкканны Итил-торадагы мосылманнар белеп, көтеп торалар. Миннән башка барып керсәң, ни диярсең аларга?
Гарәп сатучысының елтыр-ак тешләре шундук эчкә йомылды. Бу турыда ул, күрәсең, уйлап җиткермәгән иде.
— Колымны мин сиңа бушлай бирмәячәкмен,— диде ул, йомшый төшеп.— Син котыртып аны үзеңә алмакчысың.
— Син аны миңа сатып бирмәкче буласыңмыни?! — диде Габдулла, шаккатып.
— Әйе! — диде сатучы.— Йөз динар[1]! Алмыш хан миңа биш йөзне бирәчәк.
— Йа Алла! — диде Габдулла, күкрәгенә тотынып.
Ул куеныннан янчыгын чыгарды, йөз динар санады да, акчаларны гарәпнең сузылган учына салды. Бу аның юлга дип алып чыккан акчасының чиреге чамасы иде. Әле балта сабыдай җир китмәделәр, болай булса, ничек барып җитәр ул барасы җиренә, ничек эзләп табар ул Тәкин углан белән Барыс угланны? Йа Алла, үз мосылманың терелэй тотып тунагач, башкалар ничек тунамасын? Чыннан да, кемгә ышанырга, кемгә таянырга бу дөньяда? Нишләп соң, Аллам, кешеләр сүздә сине олылыйлар, чынында исә сиңа түгел — көчкә, алтынга табыналар?!
Кара гарәпнең кара йөзе акча күргәч яктырып китте.
— Моннан соң Тотыш тулысынча минеке,— диде Габдулла.
— Синеке,— диде сатучы елмаеп, ялагайланып.
Икәүләп алар яңадан тышка чыктылар. Төн уртасы инде узган, җир өсте яктыра башлаган иде. Куллары артка каерып бәйләнгән Тотыш җирдә утырып тора иде. Үз кешеләренә гарәп сатучысы аны чишәргә кушты.
— Син тагын иректә,— диде Габдулла моңсу гына, аның кулын кысып.
— Түләдеңмени? — диде Тотыш.
— Түләдем,— диде Габдулла, көрсенеп.
— Алайса, мин синең... колың? — диде Тотыш.
— Син минем кардәшем, юлдашым,— диде Габдулла.
...Ике төн, ике көн күңел ачканнан соң, гарәпләр ярдан кузгалып киттеләр. Ишкәкчеләр баш калкытмый иштеләр. Каеклар агым уңаена бик тиз бардылар.
Текә ярлар, калын урманнар күптән инде артта калды. Ярлар тәбәнәкләнде, ерагайды. Итил тагын да ныграк киңәеп, җәелеп китте. Күрер күзгә шундый күңелле булган яшеллек кайдадыр артта калды. Тирә-якта ат кылыдай каты, коры үләннәр генә тырпаеп утырган иксез-чиксез далалар, тигез, шәрә далалар башланды. Аның урынына монда кояш агымлырак карый башлады. Яр өстендә анда-санда ак киез өйләр күренде, берәр яшел уйсулыкта утлап йөргән куй, җылкы, сыер көтүләре күренде. Йә булмаса, кайнар рәшә дулкыны тирбәлгән берәр тәбәнәк калкулык артыннан, озын муеннарын сузып, әкрен генә кыймылдап барган озын торыклы дөяләр тезмәсе килеп чыкты.
Каеклар ханбалыкка — Хазар йортның изге каганы яши торган Итил-торага якынлашып киләләр иде.

Менә шул чагында, үзенең туган якларыннан инде бөтенләй аерылгач, үзенең каядыр читкә китеп баруы, каядыр икенче илләргә баруы ачыклана төшкәч, Тотышның күңелендә кискен бер үзгәреш барлыкка килде. Моңарчы әле тулысынча ачыкланып җитмәгән бер уй, яман чир кебек, аны тынычсызлый башлады. Шул ук мәлдә аның өчен бөтен нәрсә ап-ачык булып, кояшлы көндәй яп-якты булып калды. Барлык сораулар, барлык кайгы-борчулар, каршылыклы уй-тойгылар аның күңелен балкытып җибәргән әлеге яктылыкта кинәт юкка чыктылар.

— Юлдаш! — диде ул беркөнне Габдуллага.— Син миңа ачулана күрмә. Мин синең акчаңны тулысы белән кайтарырмын.

Габдулла күңелсез иде, уйчан иде. Тотыш аны, суга салынган йөз динары өчен кайгыра, дип уйлады. Габдулла исә бөтенләй икенче нәрсә турында: гарәп сатучысының ышанычсыз булуы, Итил-торада, күрәсең, аннан аерылып калырга кирәк булачагы турында уйлана иде.

— Мин аны оныттым. Икенче ул турыда минем исемә төшермә, Тотыш алып,— диде Габдулла, үзенең юлдашын тынычландырып.

— Мин сиңа шуны әйтмәкче булам,— диде Тотыш Габдуллага.— Мин синең белән китәм! Кая алып барсаң да, нишләтсәң дә, мин синең юлдашың булырмын. Тик минем бер үтенечем бар. Бер генә үтенечем!

Ул, иелеп, аның колагына:

— Мин... Аппакны коткарырга тиешмен! — дип пышылдады.

Габдулла, ярым ачылган авызын күтәреп, саңгырау кеше сыман аңа карап тик торды.

— Әйе! — диде Тотыш, елмаеп, чиксез бер күтәренкелек белән.— Шунсыз миңа тормыш юк. Бу минем сиңа, язмышка... Аллага... Тәңрегә бердәнбер үтенечем. Ирек бир миңа, булыш миңа... чын юлдаш булсаң, кардәш булсаң!

Габдулланың ярым ачык авызыннан бер сүз дә чыкмады.

**XIII**

Ханбалыкка җитәбез дигән көннең салкынча таңында гарәп базарганы Фатих ибн Әхмәт каеклары Итилнең төп юлыннан аерылган бер тармакка килеп керделәр. Тармак буйлап бер чакрым чамасы түбән төшкәч, биек, куе камышлар арасында баш каек туктап калды. Каекның борынына баскан килеш тирә-якны күзәтеп барган Габдулла бармакларын авызына куйды да ачы итеп сызгырып җибәрде. Йокымсырап утырган камышлар калтыранып киттеләр, камышлар арасыннан, куркып, пырылдап, авыр чүрәкәйләр очышып чыкты. Күз алдында гына очкан үрдәкләрне күреп беркемнең дә исе китмәде. Барысы да, тып-тын калып, камышлар аша еракка карап, нидер көтеп тордылар. Габдулла, колакларны ярырлык итеп, тагын бер сызгырып җибәрде. Күпмедер көтеп торганнан соң, камышлар артында, бераз сулдарак, күккә ай койрыклы ук атылды. Күп тә үтмәде, шул турыдан камыш ерып көймә килгәне күренде.

Көймәгә яшь кенә бер җегет утырган иде. Аның дала кояшында кара янган киң яңаклы бите, су өсте сыман шоп-шома булып, ялт итеп тора иде. Аның шулай ук кыска туны да, энҗе ташлар белән бизәлгән сыман, иртәнге кояшта елкылдап күренә иде. Тик аның шомарып, каешланып беткән киеменә энҗеләр түгел, балык тәңкәләре ябышкан иде. Кыска ишкәге белән ул бик җиңел генә, иркен генә ишә иде. Ачык күкрәкле, кыскарак муенлы бу таза җегетнең су буенда туган, су буенда үскән кеше икәнлеге әллә каян сизелеп тора иде.

— Хода юлыгызны уң кылсын, юлчылар! — диде ул, каектагыларга сынаулы күз карашы ташлап.

— Шулай булсын, амин! — диде Габдулла, эчке бер дулкынлану белән.

Бу аларның ымнары — алдан үзара килешеп куйган сүзләре иде. Бу — тирә-якта тыныч, имин, ярга чыгарга була, дигәнне аңлата иде. Габдулла ашыгып койрыкка таба атлады. Көймәгә аның зур гына ике төргәген төшерделәр. Шуннан соң Габдулла Тотышка төшәргә кушты. Бары шуннан соң гына ул көймәгә үзе дә аяк басты. Аннары ул баш очында, каек читендә бөеренә таянып торган гарәп сатучысына күтәрелеп карады.

— Сау бул. Алла сиңа исән-имин кайтып җитәргә язсын,— диде ул гарәп сатучысына.

— Мин сине алдан килешенгән җирдә ун көнгәчә көтәм,— диде караңгы чырайлы сатучы.

— Ярый, ярый,— диде Габдулла, кузгалып китәргә ашыгып.— Ун көннән килеп җитмәсәм, сау бул. Мин башкаларны белешермен.

Көймә, куе камышлыкта тар гына эз калдырып, ярга таба шуышты. Ике юлчысыннан арынган каек та, су өстендә зур дулкыннар ясап, әкрен генә кузгалып китте.

Куе камыш арасыннан көймә авырлык белән барды. Комлы калку яр буена барып чыкканчы беркем берни сөйләшмәде. Көймәне яр читендә калдырып, комлы сукмактан югары менгәндә дә шулай ук эндәшүче булмады.

Яр өстендә искиткеч күренеш ачылды: кая карама — киңлек-иркенлек... Ерактагы соргылт далалар арасында аеруча күркәм булып тоелган яшел камышлы ярлар. Ярлар арасында Итил тармаклары. Шул

тармаклар арасында — яшел камыш урманнары уртасында — соргылт таучыклар, калкулыклар... Утрауларның кайберсендә камыштан корылган ниндидер куралар, киез өйләр күренә, пәрәвездәй булып, кибәргә эленгән балык аулары челтәрләнеп тора; кешеләр, терлекләр кыймылдаша. Иртәнге чалт аяз тынлыкны бозып, әле уңда, әле сулда ниндидер тавышлар ишетелеп китә.

Камыш белән кызыл балчык катыштырып ясалган ялгыз куыш янында аларны чәчләре агарган, урта яшьләрдән өлкәнрәк бер ир кеше каршылады. Көймәче җегет кебек, ул да кыскарак муенлы, киң яңаклы иде. Сирәк сакал-мыегы аның кыска итеп, түгәрәкләп алынган иде. Аның да өсте-башы, гел балык белән булышканга, шомарып, каешланып беткән иде. Аларның икесеннән дә балык исе аңкып тора иде. Алардан гына түгел, мондагы куыштан, камышлардан, җирдән, көймәдән — барлык нәрсәдән балык исе килә иде.

Туган җиренә аяк басу белән, Габдулла, өстендәге тунын җиргә җәеп, намаз укырга кереште. Башкалар, изге бер тынлык саклап, читтән генә карап тордылар. Габдулла, намаз укыганда үз-үзен күпме генә тыныч тотарга тырышмасын, булдыра алмады — үзе белгән берничә китап сүзен авыз эченнән генә мыгырданды да, кызарынган, яшьләнгән күзләрен көн чыгышка текәп, елмаеп, туган җиренә, Тәңрегә, чыгып килгән кояшка изге теләүләрен юллады. Тотыш аны шаккатып тыңлап торды. «Әллә гарәп йоласыннан баш тартканмы?» — дип уйлады ул, үзалдына. Габдулла, ахрысы, аны бөтенләй исеннән чыгарып ташлаган иде.

— Иминлекме, Мәмәт? — диде ул, өлкән ир кешегә карап.

— Иминлек,— диде Мәмәт, Тотыштан күзен алмыйча.

— Хатыным, балаларым? — диде Габдулла, тынын кысып, сагаеп.

— Алар да исән-имин,— диде Мәмәт, ашыкмыйча гына.— Бары да исән.

Габдулла, җиңеләеп, шаулатып бер тын алды, елмайгандай итте, юешләнгән борынын тарткалады.

— Шулай да сиңа күзегергә ярамас,— диде Мәмәт, көттеребрәк.— Кирәк кешеләрне үзебез табарбыз, алып килербез.

— Без әле сезне көтмәгәниек,— диде яшь җегет, сүзгә катышып.— Каган яучылары Болгардан кичә генә кайтып төштеләр.

— Кичә генә?! Болгардан?! — диде Тотыш.

Ул моны шундый кычкырып, шундый куркыныч итеп әйтте — барысы да, ни булды дигән сыман, аптырашып, тынып калдылар, бер-берсенә карашып алдылар.

— Бүген каганның туе була,— диде балыкчы җегет, Тотышның соравыннан берни аңламыйча.

Ул боларны Тотыш өчен түгел, Габдулла өчен — Итил-тора яңалыкларыннан бик нык артта калган якын кешесе өчен сөйләде. Тик Габдулладан бигрәк аның сүзләре иң элек Тотышка барып җитте. Аның йөзе тартышып куйды. Ул, балта белән чабылган агач кебек, кинәт җиргә ауды, йөзтүбән капланды да үксеп-үксеп җыларга тотынды.

**XIV**

— Тор! — диде кинәт Габдулла, боерып.— Болай җебегән булсаң, берни эшли алмассың. Тор, тыңла сүземне.

Тотыш башын калкытты, торып утырды.

— Минем әле сиңа үз сүземне әйткәнем юк,— диде Габдулла.— Инде тыңла. Сез дә тыңлагыз,— диде ул, балыкчыларга эндәшеп.— Мин сезне таныштырмадым да бугай? Бу — Болгардан, Тотыш алып. Җөфүт каганга аның сөйгән кызын алып килделәр. Болары — Мәмәт ага белән аның углы Әмин. Минем иң ышанычлы кешеләрем. Монда без барыбыз да өлешсезләр, барыбыз да бер теләк белән янучы кешеләр. Без болай итәрбез... Фатих ибн Әхмәткә... юлбасарга ышанып мин ерак юлга чыга алмыйм. Бер ярты ай чамасы миңа монда булырга туры килә. Миңа әле кайбер кешеләрне күрергә, үз эшләремне җайларга кирәк. Хатынымны, балаларымны мин Болгарга күчерәм. Мин алардан башка яши алмыйм. Барысы да сөйләшенгән-килешенгән — аларны юлда болгарлар каршы алачаклар. Тик моннан исән-имин алып чыгарга гына кирәк. Бу эштә безгә Мәмәт ага булышыр. Аннары шул: Багдадка без су юлы белән түгел, коры юлдан Хәрәзем аша китәрбез. Итилдән аркышлар йөреп тора. Миңа иң элек Тәкин углан белән Барыс угланны эзләп табарга кирәк. Болары аның болай гына. Инде сиңа килгәндә, Тотыш... Мин үз эшләремне кайгырткан арада, син дә үз эшеңне кайгыртырсың. Сиңа Әмин булышыр.

— Бай бул, Габдулла ага! — диде Тотыш, күз яшьләре аша елмаеп.

— Мин үз хатынымнан, балаларымнан башка тора алмаган кебек, син дә үзеңнең сөйгәнеңнән башка тора алмыйсың,— диде Габдулла.— Монда бер дә искитәрлек нәрсә юк. Аллаһе Тәгалә үзенең колларын сөю, сөелү өчен яраткан. Каган синең сөйгәнеңне көч белән тартып алган. Син шуны үзеңә кайтарасың. Монда угрылык юк. Монда язык юк. Түрә безнең якта, Алла безнең якта!

Габдулла үзенең якташларына карап алды. Мәмәт төсе уңган күзләрен читкә борды, яшь Әмин, башын иеп, аяк очы белән комлы җирне тырнаштырды. Аларның мондый нәрсәне яклыйсылары килмәве әллә каян күренеп тора иде.

— Ник эндәшмисез, Мәмәт ага, Әмин? — диде Габдулла.— Куркып калдыгызмы?
— Куркуын курыкмадык та,— диде Мәмәт, башын кашып.— Кызны ничек алырга? Барып сорасак, бирмәс ич ул аны!
— Көлмә, Мәмәт ага,— диде Габдулла.— Каганда — көч, бездә — кыюлык. Кызны синең белән мин түгел, менә яшьләр коткарырга тиеш. Ничек итеп коткарырга кирәген башта алар үзләре бергәләп киңәшерләр. Кирәк икән, без дә әйтербез.
— Шулаен шулай да,— диде Мәмәт ага.— Хазар каганына... изге каганга, бөек каганга кул күтәрергә! Белмим, кемнең генә йөрәге җитәр икән моңа?
— Каганның безгә каршы кул күтәрергә йөрәге җитә ич! — диде Габдулла.— Мосылманнарны кысарга, күршеләрне таларга йөрәге җитә ич!
— Мин үзем кул күтәрермен! — диде Тотыш.— Сез миңа әйтегез генә. Барысын да мин үзем башкарырмын. Үлсәм дә, калсам да, нишләсәм дә — үзем языклы. Мин бернәрсәдән курыкмыйм.
— Син бик батыр күренәсең, углан,— диде Мәмәт Тотышка, яратмыйча.— Каган — изге. Ул җөфүт кенә түгел. Бер көнне ул җөфүт кәнәсәсенә барса, икенче көнне мәчеткә бара, өченче көнне ата-баба келәүлегенә, дүртенче көнне рум чиркәвенә бара. Аның каргышы төшсә, бик каты төшәр. Аның сараен, урдасын дүрт меңлек чиру саклый. Аның хатыннары, кырнаклары яши торган җир биек таш койма белән уратып алынган. Хатыннары — аерым-аерым өйләрдә, өйләрнең ишек төпләрендә — печтерелгән сакчылар. Ничек үтәрсең коймалар, сакчылар аша?
— Кирәк икән, кош булып очармын, җылан булып шуышырмын, йомран булып җирне тишеп керермен! — диде Тотыш.
— Иң кыены — таш койма,— диде Әмин, Тотыш ягына авышканлыгын сиздереп.— Эчкә кергәч, анда — бакчалар, агач өйләр... Анда җиңелрәк.
— Карале, син дә батыр икәнсең! — диде ата кеше үзенең улына.— Сез үләрсез дә котылырсыз. Каганның каргышы безгә — Итил мосылманнарына төшәр.
— Кызны кем урлаганын каян белерләр соң? — диде Әмин.
— Тотылсагыз? — диде ата кеше.
— Тотылсам, мине монда беркем белми,— диде Тотыш.
— Мин каршы,— диде Мәмәт, беркемгә карамыйча.— Каган — изге. Каганга кул күтәрергә... Юк! Теләсәгез нишләгез — мин каршы.
— Син безне сатмассың ич, Мәмәт ага? — диде Габдулла.
— Минем әле беркемне дә сатканым юк,— диде Мәмәт ага, үпкәләп.
— Болай булгач, без үзебез генә эшләрбез,— диде Габдулла, яшьләргә карап.— Сез бүген үк ханбалыкка барырсыз, карарсыз, күрерсез. Безгә барысын да уйлап, җайлап эшләргә кирәк. Ашыгырга, кабаланырга ярамый. Аппакны коткарсак, Хәрәземгә без бергәләп китәрбез. Изге ияләр, фәрештәләр юлдашыбыз булсын. Без әле каганның яңагына шундый иттереп бирербез — күзеннән утлар күренер!

## XV

Алар көймәгә сайлап эре балыклар салдылар. Кояшта бозылмасын өчен балыкны камыш белән капладылар да, өлкәннәр белән саубуллаштылар да, ярдан кузгалып киттеләр. Көймәне Әмин башта яр буйлап, камыш үсмәгән тар аралыктан алып барды. Шуннан соң алар, сирәк камышлыкларны үтеп, ачык су өстенә килеп чыктылар. Күз алдында икенче төрле күренешләр ачылды. Алар бара торган тармакка каяндыр икенче тармак килеп кушылды. Биек камышлар читкә тайпылды, тирә-як тагын да яктырып китте. Арттан көтмәгәндә аларны нindидер җитез көймә куып җитте. Көймәгә әрдәнәләп утын төягәннәр иде. Утынлы көймә узып киткәннән соң, арттан тагын бер көймә күренде. Монысына капчыклап ашлык төялгән иде.
Алар, ахрысы, зур юлга килеп чыктылар. Монда аларга әле алдан, әле арттан килүче көймәләр, каеклар очрап кына торды. Агым белән алга барган саен, як-якта нindидер ят тавышлар, нindидер басынкы гына шау-шу, гөрелдек ишетелә башлады. Яр өсләрендә өйләр, алачыклар күбәйде. Ул да булмады, еракта, күк белән җир-су өсте бергә тоташкан турыда, караеп, урман кебек булып, бик күп өйләр, каралты-куралар калкып чыкты. Озын казыклар кебек күккә сузылып, тырпаеп утырган сырганнар, манаралар күренде.
Тотыш исе китеп, күз алдында җәелгән иксез-чиксез ханбалыкка карап барды.
Бөек Хазар йортның баш каласы Итил тамагыннан алтмыш-җитмеш чакрым чамасы югары урнашкан иде. Ханбалык «Итил» дигән бер генә сүз белән аталып йөртелсә дә, чынында ул өчкә бүленгән яисә өч кисәктән тора иде. Ханбалыкның «Хазаран» дип аталган иң зур кисәге Итил суының сул ягына урнашкан иде. Ун меңнән артыграк кеше яшәгән Хазаранда күпчелек мосылманнар иде. Хазар болгарларыннан, тәҗик, гарәпләрдән тыш монда төрле яклардан килеп утракланган күп төрле башка ыру, башка тел кешеләре дә җитәрлек иде. Хазаран ул бөтен Хазар йортның үзәк базары иде. Сату-алу, алыш-биреш монда беркайчан тукталып тормый иде. Монда күбесенчә сатучылар яши иде.

Алардан тыш монда балыкчылар, терлекчеләр, шулай ук төрле кылачылар — чүлмәкче-тимерчеләр, тимерче-бакырчылар, җимешчеләр яши. Хазаран — агач, камыш, балчык һәм киез өйләрдән торган сатучылар, кылачылар, каралар торасы иде.

Итил-тораның уң як ярга урнашкан кисәген «Хан-балык» дип йөртәләр иде. Монда инде тулысынча аксөякләр — каган-бик үзе, каганның, каган-бикнең туганнары, якыннары, биләр, субашлары, җавышгарлар[1], дин башлыклары, билгәләр, битекчеләр яши иде. Шунда ук, дүрткел биек койма белән әйләндереп алынган иркен бер җирдә бөек каганның хатыннары, кырнаклары да көн күреп яталар иде.

Итил уртасындагы зур утрауда, Хазаран белән ханбалык арасында Итил-тораның өченче кисәге урнашкан иде. Монда таудай биек итеп, сырлап-бизәп, кызыл кирпечтән салынган гүзәл сарайда, таш коймалар эчендә, җимеш бакчалары, карт тирәкләр арасында Хазар йортның башы бөек каган... изге каган яши иде. Бу утрау «Урда» дип атала иде.

Каган, күктәге Алла кебек, Тәңре кебек, теос[2] кебек, аденой[3] кебек, берни эшләми, бернигә катышмый иде. Бөек Хазар йортны исә каган түгел, аның урынбасары каган-бик үз кулында тота иде. Каган-бик йорттагы эчке-тышкы эшләрне алып бара, сайлап алынган унике меңлек чиргә башлык итә иде. Каган исә Хазар йортындагы барлык илләрне, ыруларны, барлык кешеләрне бары үзенең бөеклеге, изгелеге белән генә куркытып, буйсындырып тора иде. Аннары ул, күктәге аденойдан, теостан, Тәңредән, Алладан аермалы буларак, ике аяклы, ике куллы кешеләрнең барысы кебек, ашый-эчә, уйный-көлә иде. Аннан да бигрәк, ир кеше булганга, ул үз илендәге теләсә кайсы гүзәл кызны коча ала иде. Монда инде ул чынлап та бөек иде. Бу эштә җир йөзендә аның белән бик аз кешеләр тиңләшә ала иде.

Җәйләүдә булмаганда каган үзенең урдасыннан кеше арасына бары дүрт айга бер генә чыга иде. Аннары ул үзенең утравыннан илгә яу килгәндә, йә булмаса, Итил-торада зур ызгыш булганда да чыга иде. Изге каганның Урдадан чыгуын ишетеп, дошманнар шундук куркып качалар, талашучы-ызгышучылар шундук татулашалар иде. Менә шундый көчле, менә шундый бөек, изге иде Хазар йортның башы каган!

Бүген илгә яу да килмәгән иде, берәрсенең кем белән булса да талашканы-ызгышканы да ишетелми иде. Шулай ук бүген дүртенче айның соңгы көне дә түгел иде. Шулай да каган бүген утраудан чыгачак, үзенең иленә-көненә күренәчәк. Ни өчен дигәндә, бүген бөек каган Болгар йортының башы Алмыш ханның гүзәл кызы Аппакка өйләнә. Төш уртасында, күктәге кояш түбә өстендә асылынып торганда, җирдәге кояш үзенең яңа кәләше белән ханбалыкның үзәк урамыннан узып китәчәк!

Бу турыда инде ханбалык кешеләренә белдерелгән иде. Шуңа күрә бүген Хазаранда торучы каралар да, сатучылар да, якындагы далаларда күченеп йөрүче күчмәләр дә, Итил буе авыллары кешеләре дә, Итил-торадагы күп санлы кунаклар да — барысы да, барысы да таң атмас борын ханбалык ягына агыла башладылар. Елга аша бер яктан икенче якка туктаусыз каеклар йөреп торды. Каекчылар уң як ярга төзәнгән, бизәнгән ирләрне, хатын-кызларны, бала-чагаларны ташып тордылар. Бүген базарлар ябылды, кибетләр эшләмәде. Каекларга төялгән кешеләр җырлар җырладылар, төрле уен коралларында күңелле көйләр уйнадылар. Кешеләрнең күңеле күтәренке, йөзләре көләч иде. Бүген алар, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, көләргә-елмаерга тиешләр иде.

Үзләренең юлларын аркылы кисеп, әледән-әле уң якка ашыккан каекларга, чыр-чу килгән кешеләргә Тотыш аптырабрак карады. Аның беркайчан да су өстендә берьюлы бу тикле күп каеклар да, күп кешеләр дә күргәне юк иде. Ул аларның нигә шулай бары бер якка гына ашыгуларын да, нилектән шулай күңелләре чамадан тыш күтәренке булуын да аңламады. Ул алай бик үк аңларга да тырышмады. Аның күңеле бөтенләй икенче нәрсәдә иде. Ул үзенең Аппагын уйлады. Юк, ул аны уйламады да, ул аны кайдадыр якында гына итеп тойды. Аңа үзе белән аның арасында ниндидер күзгә күренмәгән койма бар шикелле булып, тагын бераз бардың исә, яр читендә күренгән серле корылмалар, коймалар, манаралар янына ук барып җиттең исә, шул күзгә күренмәгән койманы үтеп чыгарга, аны күрергә, аның белән кавышырга булыр кебек тоелды. Ул ике арада яткан чын киртә-коймаларны әлегә берничек тә күз алдына китерә алмады.

**XVI**

Алар бераз соңгарак калдылар: яр буенда инде көймә туктар урын да калмаган иде. Ханбалыкның биек коймасы ягыннан ук бөтен яр буен — тамгаларны, басмаларны, күперләрне, комлыкларны кәмәләр, каеклар, улаклар сарып алган иде, әйтерсең Хазаранның барлык кешеләре бу якка күченеп беткән иде. Кәмә-каекларның барысы да кешесез иде, бары тик зуррак каекларда гына берән-сәрән сакчылар күренгәли иде.

Әмин, каеклар арасыннан буш урын карый-карый, үргә ишә башлады. Алар бер ярты чакрым чамасы кире менделәр дә комлы ярга туктадылар. Кәмәне алар яртылаш ком өстенә тартып чыгардылар, киемнәрен, коралларын караштырдылар да, тар сукмактан яр өстенә менеп, барлык кешеләр юнәлгән якка — ханбалыкның Киң урам дип аталган үзәк урамына карап киттеләр. Әмин

Тотышны башта каган карарга алып барырга, аннан соң, кешеләр төркеме таралгач, урамнар, тыкрыклар бушап калгач, ханбалык белән, дүрткел койма белән таныштырырга булды. Юлда ук ул аны, кеше арасында юк-бар сөйләшмәскә, кычкырып теләсә нинди сорау бирмәскә, дип кисәтеп куйган иде. Шуңа күрә алар юлда бөтенләй диярлек сөйләшмәделәр. Тотыш тулысынча Әмингә ышанды.

Ханбалык җиренә аяк баскач, беренче булып Әмин үзе сүз башлады.

— Әнә каган өе! — диде ул, сул якта, утрау уртасында калкып күренгән кызыл кирпеч сарайга күрсәтеп.

Тотыш барган җиреннән туктап калды, авызын ачып, -
каушап, таң калып каган сараена карарга тотынды. Ул аны баштарак утраудагы ниндидер таш кыя дип уйлаган иде.

— Ул да... андамы? — диде ул, пышылдап.

— Белмим,— диде Әмин, аның кем турында соравын аңлап.— Кашыңны җыерма! Әнә юл буенда чавышлар[1] карап тора!

— Белмисең?! — дип пышылдады Тотыш, аның кисәтүен аңламыйча.— Белмәгәч... ничек соң... без аны каян табарбыз?

— Бүген тапмасак, иртәгә... Иртәгә тапмасак, берсекөнгә,— диде Әмин, шулай ук пышылдап, елмаеп.

Тотышка ул ничектер үз-үзенә ышанмыйчамы, теләмичәме сөйләшә шикелле тоелды.

— Син ялганламыйсыңмы? — диде ул, балыкчының күзләренә карап.— Үзең булышмакчы булдың, үзең койрык болгыйсың түгелме?

— Юк, болгамыйм,— диде Әмин, чавышларга арты белән борылып.— Менә бу мәлдә аның кайда икәнлеген беркем белми. Күрәсең, шул кызыл сарайдадыр.

— Алайса, кая барабыз соң без? Ник шул утрау ягына бармыйбыз? — диде Тотыш, тагын да ныграк аптырап.

— Син ычкынгансың, ахрысы, юлдаш! — диде Әмин, усал пышылдап.— Миңа бер генә сорау да бирмә. Үзем аңлатырмын соңыннан. Көл, елмай!

— Ярар, синеңчә булсын...— диде Тотыш, юаш кына.

Алар каган үтеп китәчәк Киң урам башына килеп җиттеләр. Тик монда да алар соңга калган булып чыктылар: урамның ике ягын да, тыгызлап тутыргандай, кешеләр сарып алган иде. Алар, ерып-ерып уртадагы ачыграк урынга үтмәкче булдылар. Тик аларны беркем дә үз алдына уздырмады. Аларның тыкшынуын, ыгы-зыгы тудыруын күреп, шундук атлы чавыш килеп җитте. Җегетләргә ул артка, буш урынга барып басарга боерды.

Күпмедер көтеп торганнан соң, Урда ягында быргы тавышлары ишетелеп китте. Киң, тигез урамның ике ягын да тутырып торган, түземсез гөрләшкән кешеләр, быргы тавышына колак салып, тып-тын калдылар. Урамның Төньяк капкага — каган чыгачак капкага якынрак башында басып торган кешеләр, киселгән камыш кебек, барысы берьюлы җиргә аудылар. Бары тик урам читләрендә бер-берсеннән билгеле ара калдырып торган атлы чавышлар гына урыннарыннан кузгалмадылар да, аргы баштагы кешеләр генә баскан килеш тора бирделәр.

Төньяк капка ягыннан ишетелгән быргы тавышы якынайганнан-якыная барды. Җиргә йөзтүбән капланып яткан кешеләрнең барысы кебек, Тотыш белән Әмин дә, кызыксынуларын җиңә алмыйча, башларын калкытып, тавыш килгән якка карадылар. Болай карау бик уңайсыз иде, болай күбесенчә алдагы кешеләрнең арт саннары, янбашлары гына күренә иде. Тотышка бу аеруча кыен булды. Ул, терсәкләренә таянып, калкынгандай итте дә көтә башлады.

Менә уртадагы ачыклыкта ашыкмыйча гына атлап килгән яхшы ат күренде. Атны матур итеп бизәгәннәр, өстенә ефәк бөркәнчекләр япканнар. Атка атланган кораллы яшь ирнең дә өсте-башы ялт итеп тора. Ике куллап ул озын сапка беркетелгән ал байрак тоткан. Озын койрыклы байрак, җилсез көндә әлсерәп, яшь ирнең иңбашына салынып төшкән. Беренче байракчы узып китү белән, аның артыннан тагын унлап байракчы күренде. Алар барысы да яшьләр, тазалар иде.

Байракчылардан бераз калышып, быргычылар, дөңгерчеләр килеп чыкты. Алар якыная барган саен, быргы кычкырткан, дөпелдәгән тавышлар да көчәя барды. Тотыш, онытылып, шау-шу арасында башын тагын да ныграк күтәрмәкче булды. Шул чакны искәрмәстән аның аркасына авыр, тупас нәрсә килеп төште. Авыртудан ул чак-чак кына кычкырып җибәрмәде — Әмин ачу белән кулыннан тотып алмаса, күрәсең, кычкырып та җибәргән булыр иде.

— Билсез каласың киләмени?! — дип пышылдады Әмин аның колак төбендә генә.

Тотыш исенә килеп күзләрен ачып җибәргәндә, урам уртасын инде җайдаклар каплап алган иде. Алар, быргы, дөңгер тавышларына җайлашып, тигез, нык адымнар белән киләләр иде. Тотыш каганны никтер менә шул атлар арасындадыр дип уйлады — алар шундый бай, матур киенгәннәр, шундый тазалар, кырыслар иде! Быргы тавышлары аның йөрәген телеп-телеп алды. Атларның таш җәелгән урамга дөп-дөп басулары аның күкрәген таптаган кебек тоелды. Менә шулай, башын да калкыта

алмыйча, тузан иснәп, күршеләренең табаннарын иснәп, җиргә капланып ятарга тиеш булуы, шул ук вакытта якыннан гына Аппак узып китәргә тиешлеге турында уйлап ул нишләргә дә белмәде.

Шул чакны җиргә ауган кешеләр өстеннән, күктәге кояш яктысыннан да көчлерәк булып, ниндидер яктылык шуып үтте. Тотыш, аңлаешсыз бер курку белән, каушап кинәт күзләрен йомды. Яңадан күзләрен ачып караса, урамнан, атлы ирләр барган яктан ниндидер зур, түгәрәк нәрсәнең кояшта чагылып-чагылып китүен күреп алды. Нәрсәнең шулай бик көчле булып чагылуын ул тиз генә төшенә дә алмады. Алпак дисәң алпак түгел, калкан дисәң, калкан түгел... Үзе, ахрысы, алтыннан — сап-сары. Баш очына күтәргәннәр. Күктән кояш төшкән дә, шуны шулай күтәреп баралар дип торырсың!

Кинәт Әмин каты гына итеп аның иңбашына төртеп алды.

— Әнә! — диде ул, пышылдап.

Тотыш, күзләрен зур ачып, бөтен күңеле белән алга омтылып, урам якка текәлде. Әле генә кораллы ир-атлар тулып килгән урам уртасы бушап калган иде. Алтын «кояш» тоткан кеше дә алгарак узып киткән иде. Бушап калган урам уртасыннан, таза атларга атланып, кечкенә төркем булып, ниндидер ирләр килә иде. Аларның икесе, алтын төсендәге сары байрак күтәреп, башкалардан берничә адым алдарак баралар иде. Байрак күтәргән ирләр артыннан тагын дүрт ир килә иде. Кулларына алар ниндидер озын колгалар күтәргәннәр иде. Колга башларына күк төстәге ефәк чыбылдык беркетелгән иде. Менә шул чыбылдык астында, акбүз атка атланып, ниндидер кеше килә иде. Җиргә ятып караганда да аның йөзен бик үк аерырлык түгел иде. Бары тик дүрт колга башындагы чыбылдык итәкләре чайкалып, ачылып киткәндә генә ул кешенең башындагы алтын алпагы, сирәк сакалы, озынча чандыр йөзе күренеп-күренеп кала иде.

— Каган! — диде Әмин, пышылдап.

Тотышның никтер моңа әз генә дә исе китмәде. Әллә аның күзен будылар, әллә анда ниндидер эчке үзгәреш барлыкка килде — үз-үзен ул бик тыныч тотты. Күтәрмә чатыр астында, акбүз атта барган чандыр кешегә карата ул ачу да, көнләшү дә, курку да, олылау да тоймады. Аның турында шултикле күп сүзләр, куркыныч сүзләр ишетеп тә, үзен шундый якыннан күргәч, Тотышны күңел кайту сыман бер нәрсә биләп алды. «Нәрсәсе изге икән соң аның?» — дип уйлады ул үзалдына. Бу исә аның бердән-бер теләген — үзенең Аппагын коткару теләген тагын да ныграк көчәйтә төште.

Чыбылдык астындагы каган узып күп тә үтмәде, шундый ук колгаларга беркетелгән ак чыбылдык-чатыр күтәргән башка ирләр төркеме күренде. Чатыр астында, баштанаяк ефәк киемнәргә киенгән, алтын-көмешләрен, чын ташларын елкылдатып, атка атланган хатын-кыз килә иде. Аның да аты акбүз иде. Атның ике ягыннан да, иярдәге кыз егылып китә күрмәсен дигән сыман, җәяүле яшь ирләр атлый иде.

Бу — ул иде, Аппак иде. Аның башы түбән иелгән, куллары салынып төшкән иде.

## XVII

Каган белән яшь кәләштән бер чакрым чамасы артка калып, урам уртасыннан кораллы ир-атлар узды. Алар бик күп иде. Алар узганда урамда җиңелчә тузан болыты күтәрелде, тавыш күтәрелде.

Хазар каганының унике меңлек атлы чирүе узып киткәч, йөзтүбән капланып яткан кешеләр кузгалыша башладылар.

Тотышны Әмин тарткалап торгызды. Ул исерек кеше кебек иде. Әмин аны култыклап каядыр читкә алып китте. Бераздан алар яр буена, үзләренең көймәләре янына килеп чыктылар.

— Инде ашап алсак та ярый — ачыктырды,— диде Әмин, көймә төбеннән ниндидер төенчек алып.

Шул ук мәлдә ул, коры камыш, тизәк җыеп, яр буенда ут тергезеп җибәрде. Монда аулак иде. Кешеләр барысы да диярлек, көймәләренә утырып, китеп беттеләр. Бөтен су буенда алар икесе дә, тагын берән-сәрән балыкчылар гына торып калды.

Әмин көймәдә алып килгән балыкларны кыздырды, бертуктаусыз ут-учак белән булашты. Тотыш, әлерәк кенә урамда яткан сыман, ком өстенә сузылып ятып, суны күзәтте. Беркем берни сөйләшмәде. Сөйләшмәсәң дә, барысы да аңлашыла иде, барысы да көн кебек ачык иде.

Аппак монда. Ул кайдадыр якында гына. Өстенә ул ят киемнәр кигән, аның янында — ят ирләр. Алар аның белән янәшә генә атлыйлар, алар аның киемнәренә орыналар, курыкмыйча, тартынмыйча, алар аның йөзенә-күзенә карыйлар! Бары тик ул гына — Тотыш кына тотарга тиеш булган кулларын тоталар, бары тик ул гына сыйпарга тиеш булган чәчләрен сыйпыйлар! Чит ирләр. Белмәгән-күрмәгән ирләр. Гарәп ишкәкчеләре болгар кызларын мыскыллаган кебек, алар, тартынмыйча, курыкмыйча, аны мыскыллыйлар! Синең күз алдыңда... Тегендә, Кызлар утравында, ул кардәшләрен яклап берни эшли алмаган кебек, монда да ул үзенең сөйгәнен яклап берни эшли алмады. Шуннан да зур оят, шуннан да зур көчсезлек бармы, Тәңрем, җирдә?!

Туган Итил, олуг Итил, кеше баласына үзен, үз якынын яклый алмаудан да зуррак оят бармы, булганмы?! Күпме күргәнсең син, күпме ишеткәнсең, изге елга! Нигә эндәшмисең син дә, батыр Итил! Әллә син дә куркасыңмы, әллә син дә качасыңмы аннан, бөек каганнан?

Итил ага да ага. Еракта, Кызыл Яр турысында Чулман ничек аккан булса, ул да шулай ага да ага. Кыймылдап, ухылдап, нидер пышылдап ага... яр читләрен ялап, көймә төпләрен сыйпап ага да ага...

Чулман ярында аның изге анасы Койтым бикә дә менә шулай игелексез улы кебек карап сагышлана микән шушы мәлдә? Аппак өчен аның йөрәге ничек өзгәләнсә, аның да йөрәге шулай өзгәләнә микән үзенең югалган улы өчен?

Шуран катаудагы Тәңкә уйлый микән аны шушы мәлдә? Көтә микән аны Күке улы белән бергә яр башына чыгып?

Әйтче, Итил, күрдеңме син минем анамны, күрдеңме син минем Тәңкәмне? Күрдеңме син минем каным нәни улымны? Уйлыйлармы алар мине, көтәләрме алар мине, туганым Итил?

Итил ага да ага... Алар монда икәү. Итилнең яртысы — Чулман. Алар кавышканнар, алар табышканнар. Башкаларда аларның эше юк. Анасы да, Тәңкәсе дә, улы да аның турында берни белмиләр булыр. Юкса Итил ни дә булса әйтер иде, сөйләр иде. Алайса, син, Итил, аларга әйт минем турыда. Ярга ташланган балык кебек, кирәксез бер агач кебек комда аунап ята, диген... Якында гына, берничә адым читтә генә аның сөеклесе кан-яшь түгә, үзен беркем йолып ала алмаганга үпкәсеннән, ачуыннан өзгәләнә, диген...

Юк шул, Итил кире акмый, Итил бары бер генә якка ага.

Ичмасам, җил дә исми бу якларда. Нинди бөркү, нинди авыр монда! Нинди кысан, нинди кыен монда! Үзе шундый якты, шундый аяз, тик шулай да берни күреп булмый монда. Ничек кеше яши монда?!

Ашагач Әмин аны ханбалыкта йөртте. Ул аны ниндидер тар гына тыкрыклардан алып китте, ниндидер киң языларга, җимеш бакчалары янына алып чыкты. Ул аңа үзе белгән бөтенесен сөйләде, үзе белгән бөтенесен күрсәтте. Алар икәүләп читтән генә койманы карап йөрделәр. Койманың бер төше тәбәнәк иде, ярым җимерек иде. Тотыш берни сорашмады. Ул бары тыңлады да, үз уйларын уйлады, барысын да исендә калдырды. Кич була башлагач, алар яңадан көймәләре янына килделәр.

— Бүгенгә җитәр,— диде Әмин, көймәне суга тартып.— Әйдә, утыр, киттек.

— Кая? — диде Тотыш.

— Кая булсын — үзебезгә, утрауга. Безне инде болай да югалтып яталардыр,— диде Әмин.

— Мин беркая китмим,— диде Тотыш, искиткеч бер тынычлык белән.

Яшь балыкчы, аның мондый сүзләрен ишетеп, каушый калды.

— Карале, юлдаш, син чынлап сөйлисеңме? — диде ул, пошынып.

— Чынлап,— диде Тотыш.

— Безне Габдулла ага югалтып ятадыр, борчылып...

— Борчылсын. Мин аңа кайтырга дип сүз бирмәдем.

— Мин китәм! Кал үзең генә! — диде Әмин, ачуланасы килеп, кулын селтәп.

— Сау бул. Изгелегеңне онытмам,— диде Тотыш.

— Туктале, нишләмәкче буласың соң син? — диде Әмин.— Монда калып нишләмәкче буласың? Без соң барысын да уйлап, җайлап эшләргә дип сөйләшмәдекмени?

— Мин беркая китмим! — диде Тотыш, нык итеп, кабатлап.— Теләгемә ирешмичә, мин моннан аяк та атламаячакмын! Мин инде барысын да уйладым да, җайладым да. Яр буенда көймәләр җитәрлек. Итил кая да булса алып чыгар әле.

— Мин сине беркая җибәрмим! Син болай бөтен эшне бозачаксың! — диде Әмин, чын-чынлап куркуга төшеп.

— Синнән сорап тормаслар! — диде Тотыш.

Әмин, әйтер сүз таба алмыйча, тынып калды. Көймәсен кире ярга чыгарды да, тезләрен кочаклап, комлы яр читенә утырды.

— Болай булгач, мин дә беркая китмим,— диде ул, үзалдына сөйләнеп.

Алар, бер-берсенә карамыйча, бер-берсенә якынлашмыйча, ком өстендә шулай утырдылар да утырдылар. Яр буенда якында гына беркем калмаган иде. Алар, нидер көткән кебек, Итилгә карап утырдылар да утырдылар...

Сиздермичә генә көн сүрелде. Су өстеннән салкынча җил исә башлады. Әмин, юлдашын кайтырга күндерә алмавына ышангач, яңадан учак ягып җибәрде, балык кыздыра башлады.

Тотыш бернигә катнашмады, бернигә борчылмады, кайгырмады — таштан уеп ясалган сын кебек, тезләренә таянып утырды да утырды. Ул караңгы төшүен, койма эчендәге ялгыз өйләр ягында утлар кабынуын көтте. Көн яктысында ул аныкы булырга тиешле өйне күреп, күңеленә беркетеп куйды. Анда, ул өй тирәсендә, озын колгаларда байраклар җилферди иде. Койманың ярым җимерек төшеннән ул ерак түгел. Барысы да күңелдә, барысы да күз алдында. Караңгы төшкәч ул турыда утлар яктырак янса, Әмин ялганламаган булыр.

Итил ага да ага... Әле кайчан гына аксыл-яшькелт иде, инде әнә кара төскә керде. Елкылдап, тере кебек кыймылдап, ыңгырашып ага да ага. Кайчаннан бирле агасың син шулай, Итил? Моннан йөз ел

элек, мең ел элек әлегәчә туктамыйча шулай актыңмы син? Күптән, бик күптәннән синең яр буенда әлегедәй берәр җегет утырдымы шулай сагышланып?

Нинди көч бу, нинди иксез-чиксез көч, тереклек синдә, Итил? Каян килә бу тикле көч, бу тикле су, Итил? Мин очармын... тузан булып, томан, төтен булып мин очармын күккә, Итил! Уйларсыңмы мине шунда, сагынырсыңмы моңсу бер тамчыңны, бер тузанны, чиксез Итил?!

Ах, нинди тереклек бу синдә, олуг елга! Көч бир миңа, ныклык-корычлык бир миңа, бер улыңа... бер тамчыңа, атам Итил! Йөрәк түзми. Мин кузгалдым, сау бул, Итил!

Әйе, Әмин алдамаган. Әнә шул турыда бик күп булып утлар янды... Бик күп утлар, якты, куркыныч утлар...

Ул изге суда битен юды, кулын юды. Тун чабуы астындагы хәнҗәрен изге суга манчып алды. Ул кузгалды. Ут күбәләге утсыз торалмаган кебек, ул да ут-ялкынга карап китте.

**Соңгы баб**

**I**

Менә тагын яз җитте. Кышкы озын төннәрдән соң, каты салкыннардан, ачы бураннардан соң тагын яз килде... Тагын Чулманда боз кузгалды, җылы яктан кояш белән бергә кошлар килде. Балыкчылар ауга чыктылар. Бозын ватып, шаулап-җәелеп аккан елга кебек, тормыш тагын ярларына сыеша алмыйча гөрләп ага башлады.

Тәңкә быел бернәрсәгә дә катнашмады — башка еллардагы кебек, җир ачылу белән, тау кашына кызлар уенына да йөрмәде, балыкчылар белән ауга да чыкмады, шулай ук өй эчендәге эшләргә дә күз салмады. Ул үзенең койма өстендәге җылы, аулак урынына чыгып утырды да суны күзәтте. Моннан берничә ел электәге кебек, ул әле булса аны көтте. Алмыш ханның Аппагын каган алып киткән. Айтулдыдан ул баш тарткан. Шулай булгач, ул барыбер кайтырга тиеш түгелмени? Ул әйтте: мин сезне ташламам, көтеп торыгыз, диде. Шул ук сүзләрне ул Торымтайга да әйткән: кайтырмын, алып китәрмен, дигән. Шулай булгач, үз сүзен ул үтәми калмас. Шундый сагынып-саргаеп, шундый өзелеп көтеп торучылар булганда, ул берничек тә кайтмый кала алмаячак!

Язгы салкын җилдән бөрешеп, әле шулай моңаеп, әле үткәннәрне күз алдына китереп утырганда, артта кемнеңдер аяк тавышлары ишетелде. Тәңкә артына борылып карады. «Атаммы әллә?» — дип уйлады ул. Ярый әле ул түгел икән! Ул булса, куалап төшерер иде. Аның белән ара бөтенләй бозылды. Ул аңа үз кызы булган өчен генә, кайчандыр яраткан кызы булган өчен генә түзеп тора. Аннары ул Күкене дә ярата бугай.

— Безнең әннә монда икән! — диде Торымтай, Тәңкә янына килеп.— Без сине эзлибез дә эзлибез. Салкын түгелме сиңа, әннә? Монда җил. Без сиңа менә җылы толып китердек. Төренеп кенә утыр әле шуңа.

Бер кулына Торымтай зур толып тоткан, икенче кулы белән Күкене җитәкләгән иде.

— Әннә, мин балыкка балам! — диде Күке, Торымтай кулыннан ычкынмакчы булып.— Толымтай җибәлми. Мин балыкка балам!

— Атаң кебек зу-ур булгач барырсың,— диде Тәңкә, урыныннан торып, Күкене кулына алып.

Торымтай ул утырган аркылы агачка толыбын җайлап җәеп куйды.

— Бүген җиллерәк, әллә аска төшәбезме? — диде ул.— Төсең качкан. Терелеп тә җитмәгәнсең. Төшик булмаса.

— Утырыйк әле бераз,— диде Тәңкә.

Улын ул үзенең тезенә утыртты, тезләрен дә, улын да толыпка төрде дә, күрми калдым, ахрысы, дигән сыман, яңадан су өстенә текәлде. Кинәт ул йөткерә башлады. Ул инде былтырдан бирле йөткерә. Кыш көне бераз тынып торгандай итте дә, яз җитү белән әнә тагын көчәеп китте.

— Әйдә, төшәбез! Монда җил,— диде Торымтай тагын да.

— Утырыйк әле,— диде Тәңкә йөткерүдән туктаган арада.— Баланы ал. Аңа салкын.

— Миңа салкын түгел, әннә! — диде Күке.— Мин балыкка балам.

Анасы кулыннан ычкындыргач та, ул шуышып аның тезеннән төште, йөгереп китмәкче булды. Торымтай аны шундук эләктереп алды.

— Сез төшегез, сез...— диде Тәңкә, учы белән авызын каплап, йөткерә-йөткерә.

— Ярамый, төшәбез. Үзем менәрмен карарга,— диде Торымтай, иреккә куймыйча.

Ул Күкене кулыннан ычкындырды да Тәңкәне көчләп диярлек урыннан торгызды, әле генә җайлап куйган толыбын кире алды.

— Ул миңа сине карап, саклап торырга кушты. Ныклап торып аяктан егылсаң, ни диярмен мин аңа? — диде Торымтай, бала-чаганы юаткан сыман сөйләнеп.

Тәңкә килешкәндәй булды. Әкрен генә атлап, өчәүләп алар баскычтан төштеләр. Күке, үскән углан буларак, барысыннан да алданрак төште, йөгергәләп каяндыр китеп тә барды. Ялгыз өенә кайтып учакка ягып җибәргәч кенә Тәңкә аның юклыгын күреп алды.

— Яшь гөлекәй кебек. Атасына охшаган,— диде ул, елмаеп.

Соңгы көннәрдә ул шундый сүзләрне бик еш әйтә башлады. Ул беркайчан да «Тотыш» димәде, аны сагынып көтүе турында да беркайчан да кычкырып әйтмәде. Ул бары үзенең Күкесен мактады да, бары аның «атасын» гына исенә төшерде. Торымтай белән алар бер-берсен бик яхшы аңладылар. Торымтай да беркайчан да үзенең элекке хуҗасын кычкырып телгә алмады. Ул бары көрсенеп кенә куйды. Ул инде, Тотыш өчен көрсенүдән бигрәк, Тәңкә өчен көрсенә иде. Тәңкә аның күз алдында сыза барды, юкка чыга барды. Торымтай, кулыннан килгәнчә, ничек тә аңа булышырга тырышты — үзе белгән имнәр белән имнәде, белекле имчеләр белән киңәште, кирәкле им сулары, им тамырлары алып кайту өчен, берничә тапкыр Ага-базарга барды. Тәңкә үзе әйтерсең берни сизмәде. Ул, ахрысы, әле булса үзен элеккечә таза-сау дип белә иде.

Учак янында алар сүзсез генә җылынып утырдылар. Утыра торгач, Тәңкә кинәт әйтеп куйды:

— Торымтай... ул кайтканчы үлмәм микән мин? — диде.

— Ни сөйлисең син? — диде Торымтай, тыныч булырга тырышып.— Авызыңнан җил алсын!

— Тын җитми. Әйдә ирекка, әйдә койма өстенә,— диде Тәңкә, ялынып.

— Әйдә, алайса,— диде Торымтай, көрсенеп, теләмичә генә.

Ул аны яңадан толыбына төрде, сабый бала кебек күтәрде дә тышка чыкты.

— Сизгер син, Торымтай,— диде авыру хатын.— Аякның көче юк. Әллә нәрсә булды.

— Ашамыйсың. Ашарга кирәк,— диде Торымтай, шелтәләп. Аннары йомшак кына өстәп куйды: — Көннәр җылынсын әле менә — җүнәрсең,— диде.

**II**

Алар койма өстенә менеп җайлап утырырга да өлгермәделәр, яр астында нииндидер ыгы-зыгы ишетелде. Тәңкә үрелеп аска карады. Кинәт аның йөзе балкып китте: яр буена Акбүре каеклары килеп туктаган иде.

Тамга сакчылары исә акбүреләрне бик үк теләмичә генә каршыладылар. Моннан ике-өч ел элек килеп киткән Акбүре кунакларын алар әле онытып бетермәгәннәр иде. Шул игелексезләр, шул башкисәрләр аркасында күпме талау килде аларга! Шулар аркасында, шуларның Тотыш атлы юлбасарлары аркасында, би кызы әнә чиргә сабышты, атасы белән икесенең арасына кара мачы ятты. Би тыныч булмаса, каралар да тыныч түгел. Барысы да шул акбүреләр аркасында!

Акбүреләр турында ишетеп, Ямгырчы бинең дә йөзе бозылды.

— Башлары кем? — диде би яр астыннан менгән сакчыга.

— Хатын кеше. Койтым бикә,— диде сакчы.

Мондый сүз ишетеп, Ямгырчы би җиңел сулап куйды. Койтым бикә! Ул да исән икән. Юк инде, акбүре булмагае, әллә кем булсын, Койтым бикәгә караңгы йөз күрсәтү килешмәс.

Ул яхшы киемнәрен киде, яхшы атын иярләргә кушты. Акбүреләрне каршыларга аның яшь хатыны да, Тәңкә белән Торымтай да, туган-тумачалары да төште. Койтым бикәне Ямгырчы би элеккечә яшь, чибәр итеп күрермен дип уйлаган иде. Күргәч исе китте. Аның каршысында ул белгән, ул күңелендә йөрткән Койтым бикә түгел, бөтенләй икенче Койтым бикә басып тора иде. Өч-дүрт ел эчендә ул танымаслык булып үзгәргән иде. Баштанаяк ул ирләрчә киенгән. Көмеш алпагы астыннан иртә көмешләнгән чәчләре күренеп тора. Күз төпләренә нечкә генә булып җыерчыклар сузылып яткан. Кайчандыр тулы, сусыл иреннәре кысылган, кипшереп калган. Күз карашында ныклык, кырыслык, аннан да бигрәк — эчкә, тирәнгә яшерелгән кайгы-сагыш күренә иде.

— Язмыш мине синең җиреңә китерде, Ямгырчы би,— диде Койтым бикә, исәнлек-саулык сорашканнан соң.— Углым Тотышка күрсәткән явызлыкларыңны уйлаганда, синең җиреңә кунак булып аяк басу түгел, синең ягыңа әйләнеп тә карый торган кеше түгел мин. Тик шулай да күктән Тәңре күреп тора, синең кебек мин эчкерле, үчлекле түгел, Ямгырчы би! Минем кайгым зур. Минем кайгым сине күрәлмәүдән дә, үчтән дә, кеше эшли ала торган барлык явызлыклардан да зуррак, көчлерәк, би. Син Кызыл Ярга килеп киткәннән бирле мин ике иремне югалттым. Ишеткәнсеңдер: Күрән би егылып үлде, Котанны Алмыш хан үтертте. Мин, Ямгырчы би, Күрәннән дә, Котаннан да сөеклерәк өченче кешемне югалттым. Мин углымны... Тотышымны югалттым, би! Мин колынын бүре ашаган бия кебек, мин бозавын аю капкан болан кебек. Мин бәрәне тирән ярга төшкән куй кебек. Минем йөрәк маем, бавыр итем... бердәнберем... Тотыш углым юк булды, би! Синдә минем углымның улы бар, киленем бар. Мин синең барлык явызлыкларыңны оныттым, Ямгырчы би! Мин яңадан синең белән татулашырга килдем... Углымның улы Күке, киленем Тәңкә янына килдем. Җиреңә аяк бастырасыңмы, Ямгырчы би?

Ул, башын югары тотып, Ямгырчы бинең күзенә туры карап сөйләде, бераз гына үртәлеп, бераз гына өстен торып сөйләде:

— Мин сине җиремнән, катавымнан кире борып җибәрә алмыйм, Койтым бикә,— диде Ямгырчы би.— Сүзең чын: миндә синең углыңның улы бар, киленең бар. Ант итеп әйтәм: мин дә синең белән татулашуга каршы түгел. Түрдән уз минем изге җиремә, Койтым бикә! Түрдән узыгыз, Акбүренең кыю ирләре!

— Бай бул, Ямгырчы би,— диде Койтым бикә.— Җирең-суың тыныч булсын, илең-көнең имин булсын. Минем әле сүзем бетмәде. Синең җиреңә аяк басканчы мин шуны да әйтергә тиешмен: мин синдә күп тормам. Мин Алмыш ханга юл тотам. Мин аннан улымны таптырырга барам. Уең үзгәрмәдеме, сүзеңне бозмассыңмы, би?

— Юк, үзгәрмәде, Койтым бикә,— диде Ямгырчы би.— Мин синең юлыңа киртә булмам. Түрдән уз, кайгылы ана.

Ямгырчы би сүзен бозмады. Ничек тә ул бикәнең күңелен күрергә тырышты: шундук казаннар асылды, сарыклар суелды, базлардан ачы бал тулы чапчаклар, кисмәкләр чыгарылды. Тик Койтым бикәнең ашау-эчүдә аз гына да кайгысы булмады. Ул күбрәк килене Тәңкә белән, Күке белән юанды.

Төнне Койтым бикә килене белән бер өйдә кунарга теләвен белдерде. Була алмаган биана белән була алмаган килен төне буе сөйләшеп, серләшеп чыктылар. Бер-берсенә карата алар моңарчы булмаган бер туганлык, якынлык тойгысы кичерделәр.

— Үле булса, ишетелерие,— диде Койтым бикә, югалган углы турында.— Кем белә аны, әллә хан берәр җиргә озаткандыр, йә булмаса ябып тотадыр, кол итеп саткандыр... Кайда гына булмасын, мин аны барыбер табарга тиешмен!

Мондый сүзләрдән соң Тәңкә бөтенләй үзгәреп китте, терелеп, яшәреп китте. Ул инде аны чынлап торып, ышанып көтә башлады...

**III**

Шуран катауда ике кич кунганнан соң, акбүреләр Болгар-торага юл тоттылар.

Алар китеп күп тә үтмәде, Ямгырчы бигә Алмыш ханнан тартык килеп төште. Тартык Ямгырчы бигә ханның кичекмичә бөтен ыруы белән Өчкүл янына килеп җитәргә дигән боерыгын тапшырды.

— Ни булды? — диде би, сагая калып.

— Болгарга җырактан, Багдадтан илчеләр килә! — диде тартык, кутәренкелек белән.— Барлык мосылманнарның башы Әл-Моктадир Алмыш ханга үзенең ышанычлы кешеләрен җибәргән. Ханга буйсынган барлык ил-көн, барлык ырулар, ислам диненә кучкәнлекләрен танып, хәлифә илчесе алдында ант бирәчәкләр. Кем дә кем каршы килә, аларга хәлифәнең каргышы төшәчәк. Алар Алла колы Алмыш ханның үткер кылычын татыячаклар. Ханның боерыгы шундый.

Ямгырчы би карышып тормады. Ул үзенең бөтен ыруына Чулман аръягына чыгарга, Өчкүл ягына юнәлергә боерды. Казаяк ыруы тиз арада аякка басты. Булган барлык каекларга, көймәләргә утырып кешеләр Болгар ягына агылдылар.

Алмыш хан урдасына, Өчкүл янындагы болыннарга башка яклардан да төркем-төркем булып кешеләр килделәр. Оя-оя булып өйләр корылды. Барлык болыннарны, басу-кырларны, урман буйларын, аланнарны атлар, кешеләр каплап алды. Кеше күплектән атлап йөрер урын да калмады.

Дүрт көн, дүрт төн буена кешеләр шулай килә тордылар, бер тирәгә җыела тордылар. Якын-тирәдәге барлык ырулар, ыру башлары, биләр, тарханнар җыелып беткәч, кояшлы бер иртәдә кешеләр Өчкүл янындагы иң зур болынны бал кортыдай сарып алдылар.

Менә кешеләрне тын калырга өндәп быргылар кычкырды. Чит илдән килгән илчеләр хәлифә җибәргән ике кара байракны югары күтәрделәр, Алмыш ханның өстенә — кара чапан, башына ак чалма кидерделәр. Хәлифә илчесе Сүсән әр-Рассиның битекчесе Әхмәт ибн Фадлан — озын борынлы, җирән сакал-мыеклы таза гына бер гарәп җиң очыннан бөтәрләнгән битекне алды да укырга җыенды. Шунда ул үзе янында торган Башту углы Габдуллага үз телендә нидер әйтте, Габдулла Алмыш ханга борылды, аңа битекченең сүзләрен җиткерде. Әхмәт ибн Фадлан: хәлифәнең битеген укыганда аяк өсте басып тыңларга кирәк, дигән икән. Берничә ел эчендә картаеп, юанаеп калган Алмыш хан аягүрә басты. Аннан күрмәкче башкалар да аякларына бастылар.

Бер-берсенә сыенып торган кешеләр урманы тынып калгач, калку урынга менеп баскан, шуңа күрә барлык тирә-якка күренеп торган битекче көр-ягымлы тавыш белән кычкырып укырга кереште. Башту углы Габдулла шундук аның сүзләрен болгар теленә әйләндереп барды. Габдулланың сүзләрен башка тылмачлар үзләре янындагы кешеләргә җиткерделәр. Йөз меңләгән кеше урманы өстеннән төрле якка, дулкын-дулкын булып, бер үк сүзләр тарала торды.

Хәлифә битеген укып бетергәч, бөтен киң болынны тутырган кешеләр, җирне-күкне дер селкетеп, бер авыздан: «Алла!» — дип кычкырдылар. Казаяклар да, Койтым бикә белән юлдашлары да, биләрләр, суарлар да, бәрәнҗәрләр дә — барысы да, барысы да төп болгарлар белән шул ук сүзне кабатладылар.

Алмыш хан үзенең атына атланды, уртадагы түгәрәк ачыклыкны бер әйләнеп чыкты. Ул үзенә буйсынган кешеләргә — ирләргә, хатыннарга, бала-чагаларга карап алды. Аларның башы өстеннән ул еракка — Итил буе киңлекләренә, Чулман буйларына, Урал итәкләренә, Җаек далаларына күңеленнән күз йөртеп чыкты. Күз алдына килгән шул биләмәләрен, җир-суларын бергә туплаган сыман, ул зур авыр йодрыгын йомарлады да кулын күтәрде.

— Болгарлар! Болгар җиренең барлык иле-көне, ырулары! — дип кычкырды Алмыш хан, көчле, күтәренке бер тавыш белән.— Моңарчы таркау булган, бер-берсе белән ызгышып, бер-берсенең канын коеп яшәгән... миңа калан түләгән ил-көн бүген бер байрак астына берләште.

Моннан соң безнең барыбызның да Тәңребез бер генә. Ул да булса — Алла! Алладан бөек беркем юк. Барлык каралар, аксөякләр — Алланың коллары. Аллага табынган, аны бер дип белгән барлык мосылманнар — тигез!.. Шушы язгы кояшлы көндә, барлык үләннәр, агачлар... барлык тереклек иясе куанып башларын калкытканда, бөек Итил, Чулман җирендә безнең изге йортыбыз — Болгар йорт та яңадан туды! Болгар, яшь булса да, өлкән алыплар тезмәсенә басты. Безне изге хәлифә үзе таный, безгә үзенең изге теләкләрен юллый. Бүгеннән башлап мин, Алмыш хан, Болгар йортның башы, үземнең Хазар каганына бәйсез икәнлегемне белдерәм. Бүгеннән башлап Болгар йорт җирдә үзенә ирек даулаячак, үз көнен үзе күрәчәк, үз язмышын үзе сайлаячак. Күктә кояш сүнми торып, Болгар йорт сүнмәячәк. Итил суы корымый торып, Болгар йортның тамыры корымаячак!

**IV**

Шулай итеп, Алмыш хан теләгенә иреште: Багдадтан биш мең кеше белән илчеләр килде, изге хәлифә аны үз канаты астына алды. Моннан соң инде ул барлык эшендә аңа таяначак. Моннан соң инде аның теләсә нинди яуларга, давылларга каршы корыч калканы булачак.

Әйе, илчеләр килде. Алар аңа хәлифәнең байракларын алып килделәр, бүләкләр, күчтәнәчләр, имтом үләннәре алып килделәр. Илчеләр белән бергә аның угыллары, ышанычлы кешесе Габдулла исәнимин әйләнеп кайтты. Шулай да барысы да ул уйлаганча ук барып чыкмады. Ислам диненә өйрәтергә тиеш булган укытучылар — мөгаллимнәр, суыктан, ераклыктан, авыр юлдан куркып, Хәрәземдә үк илчеләрдән аерылып калдылар — илчеләр исә таныш су юлы белән түгел, адым саен куркыныч сагалап торган коры җирдән килгәннәр иде. Болгарга шулай ук соратылган ташчылар да килеп җитмәде. Алмыш ханга элеккечә үз көенчә, үзе корган агач коймага гына сыенырга калды.

Шулай итеп, илчеләр аңа сөенечләр дә, көенечләр дә алып килделәр. Тик алар алып килгән көенеч Хәрәземдә торып калган мөгаллимнәр дә, ташчылар да түгел иде. Алар алып килгән көенеч-кайгы Аппакның үлеме һәм Тотышның юкка чыгуы иде. Боларның барысы турында да ханга Габдулла сөйләде. Бу турыда ишеткәч, Алмыш хан Габдуллага берни әйтмәде — сорау да бирмәде, ышанyышанмау да белдермәде. Ул әлегә моны ничек итеп аңларга да, моның белән үз-үзен ничек итеп килештерергә дә белмәде. Айкын хатынның тазалыгы болай да яхшы түгел иде. Кызының үлеме турында ишетсә, аның бөтенләй аяктан егылуы бар иде. Шуңа күрә ул Габдуллага бары бу турыда беркемгә дә сөйләмәскә генә кушты.

Шундый көннәрнең берсендә Алмыш хан янына Койтым бикәнең керергә теләвен белдерделәр. Алмыш ханның йөрәге кузгалып куйды. Койтым бикә... Тотыш... Алар турында ул беркайчан да тыныч кына уйлый алмады.

— Минем углымны кая куйдың? — диде аңа Койтым бикә, сорау алган яргучы сыман.

— Ул качты. Син ул турыда беләсең булыр,— диде хан.

— Мин ышанмыйм,— диде Койтым бикә.

— Шуннан башка мин берни белмим,— диде хан.

Койтым бикә икенче көнне дә килде. Ул аңа шул ук соравын бирде:

— Кая куйдың минем углымны? — диде.

Чәчләре агара башлаган, кырысланган, усалланган бу хатынга ханның ачуы килде. Шулай да ул аны җиңел генә куалап чыгара алмады.

— Алайса тыңла,— диде ул, йомшарып.

Ул үзе бер сүз дә әйтмәде. Койтым бикәгә барысын да Габдулла сөйләде. Үзе белгән, үзе ишеткәннең барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде.

Габдулланың белгәне-ишеткәне исә шул иде: теге истәлекле көнне көймәгә утырып киткәннән соң, Тотыш та, Әмин дә кире кайтмаганнар. Шул төнне ханбалыкта, дүрткел койма эчендә ут чыккан. Койма эченә, имеш, ниндидер угрылар үтеп кергәннәр. Алар анда нәрсә урламакчы булганнардыр — беркем берни белми икән. Утны да, имеш, шулар төрткәннәр. Угрылар белән сугышканда әллә бишалты, әллә унлап-унбишләп сакчы үтерелгән. Угрыларны сакчыларга булышка килгән короллы ирләр генә җиңә алган. Кайберәүләр әйтә, имеш, аларны шунда үтергәннәр, ди, икенче берәүләр әйтә: үтермәгәннәр, тотып алганнар, ди. Өченчеләре әйтә, имеш, ул угрылар качып котылганнар икән, ди. Телдән телгә сөйләнелгән ул «угрылар»ның Тотыш белән Әмин булуына аз гына да шикләнмәсә дә, Габдулла шулай да аларның язмышы турында башка берни белә алмады. Итил-торадагы иң ышанычлы

кешеләр дә ачык кына итеп берни дә әйтә алмадылар. Бары Аппак турындагы сүзләр генә бернинди имеш-мимешкә урын калдырмый иде. Каган хатыны булуына бер ай булды дигәндә Аппак сагыштан корып-кибеп үлгән. Бу турыда каган кешеләре үзләре әйткәннәр.

Алмыш хан, мондый сүзләрне ишеткәч Койтым бикә аңын җуяр, егылыр, йә булмаса, тилереп, чәчен-башын тырнап җыларга тотыныр, дип уйлаган иде. Кайгы күреп йөрәге ташка әйләнгән ананың, ичмасам, ыңгырашкан тавышы да ишетелмәде, күзләренә бер бөртек яшь тә килмәде. Аның болай да нык кысылган иреннәре генә кысыла төште дә, авыз читләрендәге, күз төпләрендәге җыерчыклары гына кызганыч булып тартышып-тартышып алды.

Габдуллага Алмыш хан чыгарга кушты. Койтым бикә белән генә калгач, ул, авыр көрсенеп:

— Язмыш...— дип куйды.— Язмыштан узмыш юк. Син — углыңны, мин кызымны югалттым.

— Әйе, язмыштан узмыш юк, ханым,— диде Койтым бикә, каядыр читкә, еракка карап.— Син минем туган ыруымны тар-мар иттең, иремне үтерттең... ата-баба йоласын аяк астына салып таптадың. Барысы өчен сиңа Тәңренең авыр каргышы төшкән, Алмыш хан... көч, байлык иясе... хәлифә ялчысы!

Кызыл Ярга кайтканда Койтым бикә тагын Шуран катауга туктады.

Ямгырчы би белән аның арасында зур гына сөйләшү булды. Койтым бикә Тотыштан туган Күкене үзенә биреп җибәрүне сорады. Тотыш инде юк, диде, аның кайдалыгын беркем белми, диде. Күке минем бердәнбер юанычым, диде. Ямгырчы би ике арада мондый сөйләшү буласын, күрәсең, алдан ук көтеп торган иде.

— Күкенең анасы бар,— диде ул.— Мин дә, син дә яңа йоладагы кешеләр. Ислам дине яшь баланы ата-анадан аерырга кушмый. Күке сиңа юаныч булган кебек, анасына да юаныч. Кая куярмын мин аның баласыз анасын?

— Чакырт кызыңны! — диде Койтым бикә.

Тотышның инде бөтенләйгә, мәңгегә юкка чыгуын белгәч, Тәңкә тынычланып калгандай булды. Койтым бикә, киленен кызганып, аңа углының кайда, ничек югалуын әйтмәде. Ул аңа, Тотыш Итил аръягында юлбасарлар белән сугышта үлгән, ахрысы, дип ялганлады.

— Нишлисең, бирәсеңме балаңны? — диде ата кеше үзенең кызына.

— Мин улымны беркемгә бирмим,— диде Тәңкә, каны качкан иреннәрен чәйнәп.— Анам каршы килмәсә, мин аның белән китәрием... улымны алып.

— Мин синнән шуны гына көттем дә, кызым! — диде Койтым бикә, елмаеп, Тәңкәне кочагына алып.— Берегез дә артык түгел, икегезне дә алып китәм. Икегез дә балаларым булырсыз.

— Минем тагын бер кешем бар,— диде Тәңкә, оялчан гына. Аның бит очларына көчсез генә кызыллык йөгерде.— Торымтайны да... каршы килмәссеңме, анам?

— Торымтай? — диде Койтым бикә, аңлап җитмичә.— Ә-ә, Торымтай! Аңа да каршылыгым юк. Тагын кемнәрең бар — әйдәгез барыгыз да. Кайгылы ана күңеле өч кешене түгел, йөз кешене, мең кешене сыйдыра ала! Баласын югалткан ана өчен барлык үксезләр — бала! Күкем мине... Куаныч-Бога, атла алдан. Барлык йортым — сиңа, җир-суым — сиңа... бар байлыгым, көчем — сиңа! Атла, улым... Күке балам!

*1969 ел, Казан*

## Сүзлек

### А

*Абак* — пот, табыну сыны.
*Агыл* — терлек-туар ябу, бергә туплау өчен киртәләп алынган җир.
*Агылык* — хәзинә (алтын-көмеш һәм, гомумән, кыйммәтле әйберләр) саклана торган урын.
*Агычы* — хәзинәче.
*Аденой* — яһүдиләр алласы.
*Алай* — гаскәри төркем, отряд.
*Алас* — монда: изге ияләрне олылап эндәшкәндә әйтелә торган өндәү сүзе.
*Албалап җигү* — атларны, озын аркан сузып, бер-бер артлы тезеп җигү.
*Алпагыт* — батыр, көчле кеше.
*Алпак* — сугышчының металлдан (мәс. тимердән) ясалган баш киеме.
*Алыс* — ерак.
*Аман* — исән-сау.
*Аркыш* — кәрван.
*Арык* — таза, саф. Хәзерге телдә ябык (симез түгел) мәгънәсендә йөри.
*Ассу* — файда, табыш. Хәзерге телдәге «аслам», «асламчы» шуннан калган.
*Атак* — дан, шөһрәт. Хәзерге телдә «атаклы» формасында кулланыла.
*Аяк* — касә. Эчемлек эчә торган савыт.
*Аякчы* — эчемлек таратучы.

### Б

*Базарган* — чит ил сатучысы.

*Батман* — авырлык үлчәве. Хәзерге үлчәү системасы буенча күпме булуы төгәл генә билгеле түгел. Төрле заманда төрлечә йөргән. Мәсәлән, бер батманда 12 пот, 8 пот, 4 пот булуы билгеле. Хәзерге телдә халык иҗатында сакланып калган.

*Би* — эре хуҗа, җир-су, байлык иясе; баш кеше.

*Билге-таш* — һәйкәл.

*Битек* — язу, хат.

*Битекче* — язу-сызу эшләрен башкаручы, секретарь.

*Бога* — гомумән, үгез һәм нәсел үгезе.

*Болаңгыр* — болытлы, күңелсез көн.

*Борнай* — масая, борын чөя торган кеше.

*Буза* — тары ярмасыннан яисә арпадан ачытылган эчемлек. Хәзерге телдә «буза чиләге» дигән сүздә сакланып калган.

*Бурдак* — кымыз яисә су ише сыекчалар саклана торган тире капчык.

## Д

*Динар* — алтын акча берәмлеге.

*Дирһәм* — көмеш акча берәмлеге.

*Дөңгер* — барабан.

## И

*Им суы* — сыек дару.

*Им уты* — дару үләне.

*Ир* — кораллы сугышчы.

*Иравыл* — хәрәкәттәге армия алдыннан баручы гаскәри берләшмә. Авангард.

*Йолык* — корбан чалу.

*Йорт* — берничә ыруның территориаль берәмлеге, дәүләт.

*Йөгертмә* — арбаның аерым рәвештә җигелгән алгы күчәре. Озын агачлар ташуда кулланыла.

## К

*Каган* — Хазар йортның патшасы.

*Каган-бик* — каганның урынбасары, хәзергечә әйткәндә, «премьер-министр».

*Кайсар* — Рум (Византия) ханы, патшасы, императоры.

*Кайраккан* — изге ияләргә олылап эндәшә торган сүз.

*Калан* — сугышта җиңелүче җиңүчегә түли торган еллык салым, ясак.

*Кам* — ыруның дин башлыгы.

*Капуг* — капка.

*Кара. Каралар* — гади халык, кара халык. Буйсынган кешеләр.

*Карабаш* — кол кыз, җария.

*Карамай* — нефть.

*Карачы* — ханның дәүләт белән идарә итүдә ярдәмчесе (министр). Болгар ханының һәм соңыннан шулай ук Казан ханының дүрт карачысы була.

*Катау* — коймалар, урлар белән нығытылган, кораллы гаскәр тарафыннан сакланыла торган торак урын. Катауларда гадәттә биләр, ханнар яшәгән.

*Керген* — килмешәк.

*Кирмән* — хәрби лагерь.

*Котычык* — кечкенә сандык, шкатулка.

*Ку* — чакмадан ут кабызу өчен кулланыла торган коры мәшкә.

*Куар* — яшен алласы.

*Кул* — хәрби термин. Гаскәри берләшмәләрнең бер-берсенә карата позиция тәртибе:

а) уң кул — уң фланг;

б) сул кул — сул фланг;

в) урта кул — үзәк.

*Кулагы* — бер бөтеннең күпмедер өлеше. Процент.

*Кулбау* — шул ук «кулагы».

*Кызгут* — күргәзмә хөкем; халык алдында ясала торган суд процессы.

*Кылавыз* — юл күрсәтүче.

*Кылачы* — һөнәрче.

*Кыран* — зур бәла-каза, үләт, ваба.

*Кырнак* — кол кыз, җария.

*Кәнәсә* — яһүдиләрнең гыйбадәтханәсе. Синагога.

*Күбә* — кечкенә тимер боҗралардан җыйнап ясалган «күлмәк», сугышчы киеме.

*Күбәтә* — аш савыты, кечкенә табак.

*Күнчек* — кесә.

*Күтәрмә* — күченеп йөргәндә кулланылган җиңелчә чатыр.

## О

*Оран* — сугышчан аваз.

## П

*Пот* — сын. Хәзерге телдә һәртөрле сынга, табыну әйберенә карата кулланыла.

## Р

*Рум йоласы* — христиан дине.
*Рум кешесе* — Византия кешесе, грек.

### С

*Сарт* — сәүдәгәр, Урта Азия кешесе.
*Субашы* — гаскәр башлыгы.
*Сукман* — батыр.
*Сычук* — ачы бал.
*Сыя* — язгы ташу вакытында елгада ага торган эре кар кисәге.
*Сөлтәр* — скелет.

### Т

Тамга:
а) билге, мөһер, печать;
б) елгада каеклар, көймәләр туктый торган урын, пристань.
*Тамгалык* — читтән кертелгән товар өчен алына торган бәя, пошлина.
*Тартык* — ханга, бигә буйсынган кешеләрне ашыгыч рәвештә хан, би янына чакыртып (тарттырып) алу өчен җибәрелгән махсус кеше.
*Тархан* — үзенә буйсынган биләргә хан тарафыннан бирелә торган дәрәҗәле исем. Тархан төрле өстенлектән файдаланган һәм салымнар түләүдән азат ителгән.
*Телем* — сугышта яулап алынган байлыктан сугышта катнашучыларга бирелә торган өлеш.
*Теос* — греклар алласы.
*Тора* — шәһәр.
*Тотык* — берәр таләпнең үтәлүен тәэмин итү өчен дошман якларның берсе тарафыннан кулга алынган каршы як кешесе, заложник.
*Тәлим* — күп.
*Төмән* — ун мең яисә: «бик күп».
*Төң* — тукыма төргәге, тюк.
*Түрә* — билгеле бер кагыйдәләр җыелмасы, закон. Хәзерге телдә мәгънәсе үзгәргән килеш кулланыла.

### У

*Углан* — хан яисә би баласы.
*Угры* — карак.
*Укталу* — ни дә булса эшләмәкче булып омтылыш ясау.
*Улак* — кечерәк каек.
*Улакчы* — ашыгыч хәбәр китерүче.
*Ур* — катау тирәсен әйләндереп алган тирән чокыр, канау.
*Урда* — бинең, ханның ныгытылган яисә сак белән әйләндереп алынган торак урыны.
*Урыс-улак* — елгалар буенча каекларга утырып төшкән һәм яр буйларындагы авыл-шәһәрләрне талау белән шөгыльләнгән юлбасарлар.

### Х

*Хан-агасы* — ханның, каганның беренче ярдәмчесе, вәзир.
*Ханбалык* — башкала.
*Хәлифә* — барлык мөселманнарның башы, рухи «атасы».

### Ч

*Чавыш* — гаскәрдә тәртип саклаучы.
*Чагдавыл* — хәрәкәттәге армия артыннан баручы гаскәри берләшмә, арьергард.
*Чарача* — мунчаның салкын бүлмәсе.
*Чирү* — гаскәр. Хәзерге телдә «кыр чирүе», «Кырым чирүе» (бик күп) кебек сүз тезмәләрендә сакланып калган.
*Чук-чук* — бик күп.
*Чура* — бигә, ханга буйсынган кеше, «кара». Эш кешесе.

### Ш

*Шай* — сугышчының сугыш кирәк-ярагы (кием-салым, корал).

### Ы

*Ым* — сугышчыларның очрашканда бер-берсен тану өчен алдан билгеләп куйган сүзе, пароль.

### Э

*Эчкәре* — өй эче хезмәтчесе.

### Я

*Ябгу* — угызларның баш кешесе.
*Ягы* — дошман.
*Язы* — ялан, буш җир, мәйдан.
*Язык* — гаеп, ярамаган эш.

*Яргулау* — хөкем итү.
*Яргучы* — хөкем итүче.
*Яркак* — такта.
*Ярлыкау* — гафу итү, кичерү.

## Ө

*Өй-агасы* — ханның, каганның өй эшләрен алып баручы ярдәмчесе.

## Җ

*Җавышгар* — Хазарда хөкем итүче, яргучы.
*Җайдак* — атка атланган кеше.
*Җөфүт* — яһүд динендәге кеше, яһүд.

## Искәрмәләр

*(Географик атамалар, ил, халык, кеше исемнәре)*

*Азак тиңгезе* — Азов диңгезе.

*Алмыш хан* — Шилке ханның улы. Туган, үлгән еллары билгесез. 913 елда (Болгарга ибн Рустә килгәндә) һәм шулай ук 922 елда (ибн Фадлан килгәч), димәк, кимендә, шушы ара эчендә Болгар ханы булуы мәгълүм. Алмыш хан вакытында Болгарга Багдад хәлифәсеннән илчелек килә. Болгар рәсми рәвештә ислам дине кабул итә. Алмыш ханның мөселманча исеме — Җәгъфәр.

*Андалус* — Испания.

*Ар* — удмуртларның элекке исеме. «Ар» сүзе хәзер дә кулланыла, тик бүгенге көндә «ар» удмуртларны беркадәр кимсетү белән әйтелә. Шуңа күрә бу сүз рәсми телдән төшеп калды. Элек исә «ар» сүзендә бернинди кимсетү булмаган.

*Башкырт* — бу вакытта, ягъни 922 елларда башкыртлар Җаек (Урал) һәм Кондырча елгалары арасындагы далаларда яшәгәннәр. Ибн Фадланның язуына караганда, башкыртларның унике алласы (иясе) булган (мәс., кыш иясе, җәй иясе, яңгыр, җил, агач, кеше, ут, су, төн, көн, үлем, җир ияләре). Аларның бер төрлесе җыланнарга, икенче төрлесе балыкларга, өченче төрлесе торналарга табынганнар.

*Биар* — Скандинавия халыклары телендә «Биармия» дип, русча «Пермь» дип аталган. Хәзерге Пермь өлкәсенең төньяк, Коми АССРның көньяк өлешендәге бер ил. Башкаласы — Чардын. Болгардан төньяктагы тире, мех сәүдәсенең әһәмиятле үзәге. Биар борынгы заманнарда ук Скандинавия халыклары белән бәйләнешкә кергән. Норманнар Биар белән сәүдә иткәннәр һәм еш кына, яу белән килеп, аны талап та киткәннәр. Мәсәлән, 920 елны, ягъни романда сурәтләнгән елларда Норвегия короле Эрих, Биарны бик нык талап, туздырып китә. 1236 елда монгол яулары тарафыннан тар-мар ителә һәм шуннан соң аякка баса алмый.

*Болгар* — «Болгар» сүзенең өч төрле мәгънәсе бар: а) болгарлар, болгар халкы; б) Болгар дәүләте; в) Болгар исемендәге шәһәр. Болгар шәһәре Идел буендагы Болгар дәүләтенең башкаласы булган һәм анда болгарлар яшәгән. Тарихта өч төрле Болгар дәүләте билгеле: 1. Бөек Болгар. 2. Идел-Чулман Болгары. 3. Дунай буе Болгары (хәзерге көндәге «Болгария» дәүләте).

Болгарлар Европада IV гасырдан ук билгеле булганнар. Алар Төньяк Кавказда, Кара диңгез, Азов диңгезе буйларында яшәгәннәр. 630 елда Азов диңгезе буенда «Бөек Болгар» дип аталган дәүләт барлыкка килә. Бу «Бөек Болгар» озак яши алмый, дәүләтне оештыручы Кубрат үлгәннән соң таркала башлый. Болгарларның бер өлеше Идел буенча төньякка күченә һәм Идел-Чулман бассейнында IX—X гасырларда яңа дәүләт булып оеша. Шул ук вакытта Дунай буенда да Болгар дәүләте барлыкка килә. Бу дәүләт башта йөз ел чамасы төрки була, соңыннан славянлаша.

Идел буена болгарлар IX—X гасырларда гына түгел, аннан элегрәк тә үтеп кергәннәр. Алар монда җирле халыкларны, шул исәптән, үзләреннән элегрәк килеп утракланган төрки кабиләләрне буйсындыралар. Болгар дәүләте Европа белән Азия арасындагы иң әһәмиятле сәүдә үзәгенә әверелә. Урта Идел, Чулман һәм Урал буе халыкларының экономик, культура үсешендә Болгар дәүләтенең прогрессив роле чиксез зур. Биш йөз елдан артык яшәү дәверендә Болгар күп кенә күтәрелеш һәм түбәнәю чорлары кичерә. 1236 елда аны монголлар яулап ала, соңыннан аңа урыс-улаклар (ушкуйниклар) тынгы бирми башлый, ә 1431 елда князь Федор Пестрый Болгарны тәмам тар-мар итә. Шуннан соң Болгар дәүләте бөтенләй таркала, башкала җимерелә. Политик үзәк Казанга күчә.

*Буртас* — Иделнең уң ягында, Болгардан көньяктарак яшәгән халык. Буртаслар турында фәндә мәгълүматлар бик аз. X гасырда буртаслар халык буларак яшәүдән туктаган булалар.

*Бәрәнҗәр* — X гасыр Болгар дәүләтендәге өч төп кабиләнең берсе.

*Бежәнәк* — төрки телдә сөйләшкән күчмә халык. X гасырда бежәнәкләрнең күпчелеге инде көнбатышка күченеп киткән була. Алар көньяк Днепр буйларына барып чыгалар. XII гасырда Византия белән сугышта бежәнәкләр тулысынча диярлек тар-мар ителәләр. X гасырда Арал диңгезе буйларында бежәнәкләрнең бик аз өлеше генә калган була.

*Биләр* — Болгар дәүләтендәге иң көчле феодал үзәкләрнең берсе. Болгар шәһәре белән Биләр шәһәре арасында өстенлек өчен каты көрәш барган. Болгар йортның башкаласы беренче чорда Болгар шәһәре булса да, соңга таба Биләр шәһәре өстен чыккан һәм Бөек Болгар исеме белән аталып йөртелгән.

*Итил-тора* — 723 елдан башлап Хазар йортның башкаласы (аңа кадәр Хазарның башкаласы Төньяк Кавказда, Хазар диңгезе буенда була). Итил-тора хәзерге Әчтерхан шәһәреннән түбәндәрәк булган. 965 елда рус кнәзе Святослав тарафыннан җимерелгән, юкка чыгарылган. Шуннан соң беркайчан торгызылмаган һәм Идел комнары астында күмелеп калган, ахрысы.

*Йура* — Печора елгасы белән Төньяк Урал арасында яшәгән халык. Хантларның (остякларның) һәм мансиларның борынгы бабалары. Шул халык яшәгән җирне дә Йура дип атаганнар.

*Кустантин* — Византия дәүләтенең башкаласы Константинополь.

*Куябы* — Борынгы рус дәүләте Киев кнәзлегенең башкаласы, Киев шәһәре.

*Кыпчак* — X гасыр башларында Иртыш буенда, Көнбатыш Себердә яшәгән, соңга таба Дунайгача, Карпаткача киң территорияне яулап алган күпсанлы, көчле төрки халык. Монгол яуларыннан соң барлыкка килгән Алтын Урда дәүләтенең төп халкы кыпчаклар була. Бүгенге көндәге татар халкының, шулай ук башкорт, казакъ, каракалпак, нугай, кумык һ.б. халыкларның этногенезында (формалашуында) кыпчакларның өлеше гаять зур.

*Лангабар* — Италия.

*Мукшы* — мордва. Болгар чорында, романда сурәтләнгән заманнан соңрак, мордваларның бер өлеше болгарларга, икенче бер өлеше русларга буйсынган була.

*Әл-Моктадир* — Габбасилар династиясеннән хәлифә. 907—932 елларда тәхеттә була.

*Рум* — Көнчыгыш Рим, ягъни Византия империясе. Византиянең башкаласы Константин да еш кына Рум дип аталган.

*Синд* — Һиндстан.

*Суар* — Болгар дәүләтендәге шәһәр. Политик үзәкләрнең берсе.

*Тәҗик* — Урта Азиянең төрки булмаган халыкларын элек шулай дип атаганнар.

*Угыз* — Түбән Иделнең сул ягында, Каспий буе далаларында яшәгән күчмә төрки кабиләләр.

*Уйсу* (Вису) — Ладога күле белән Ак күл (Белое озеро) арасында яшәгән борынгы халык һәм шул халык яшәгән җир. Хәзерге вакыттагы кечкенә вепс халкын шул вису-уйсу халыкның калдыгы дип уйлыйлар.

*Урыс* — рус кабиләләре Болгардан төньяк, көнбатыш җирләрдә яшәгәннәр. Елгалар буенча түбән төшеп көньяк илләр белән сәүдә иткәннәр, ерактагы Хазар (Каспий) диңгезенә чаклы барып чыкканнар. Еш кына руслар елга, диңгез буендагы авылларны, шәһәрләрне басып алганнар, талаганнар, яндырганнар.

X гасырдагы «рус» юлбасарлары мәсьәләсендә уртак фикер юк. Кайбер галимнәр әлеге «рус»ларны Скандинавия илләреннән чыккан норманнар яисә викинглар дип исәплиләр.

*Франк* — Франция. Монда, гомумән, Көнбатыш Европа илләре.

*Хазар* — Көнбатыш төркиләр империясе таркалганнан соң, VII гасырда, Иделнең түбән агымында, Каспий, Азов буйларында барлыкка килгән дәүләт. Заманында Хазар бик көчле була һәм бик зур территория биләп тора. Хазарлар, үз бәйсезлекләрен саклап, гарәпләр һәм Византия белән гасырлар буена көчле сугышлар алып баралар. X гасырда Хазар аксөякләре, күрәсең, мөселман динендәге гарәпләр һәм христиан динендәге Византия тәэсиренә биреләселәре килмичә, яһүд дине кабул итәләр. Хазарда сәүдә һәм шәһәр тормышы алга киткән була. Хазар империясенең (Идел буе Болгарын исәпләмичә дә) төп халкы хазарлар һәм болгарлар була. 965 елда рус князе Святослав Хазарның башкаласы Итилне тар-мар иткәч, дәүләт таркала һәм Хазарның Идел буендагы күп кенә биләмәләре соңыннан Болгар кулына күчә.

*Хазар диңгезе* — Каспий диңгезен Хазар чорында шулай дип атаганнар. XII гасырда Болгар диңгезе дип аталган.

*Хәрәзем* — Аму-Дәрьяның түбән агымындагы дәүләт, борынгы культура үзәге. Хазар, Болгар һәм башка төрки дәүләтләр белән Хәрәзем арасында борын-борыннан экономик һәм культура мөнәсәбәтләре яшәп килгән. Хәзерге вакыттагы Үзбәкстан, Төркмәнстан һәм Каракалпак АССР территорияләренә карый.

*Чирмеш* — мари.

*Чулман* — Кама елгасы.

*Шилке* — Алмыш ханның атасы. Туган, үлгән һәм хан булып торган еллары билгесез. Үлгәч бирелгән мөселманча исеме — Габдулла.

# КОЛ ГАЛИ

*Өч пәрдәле трагедия*

## Катнашалар:

Гали — болгар шагыйре.
Ураз бәк — кыпчакларның Бурлы ыруы башы.
Чәчәк— Ураз бәк кызы.
Энҗе бикә.
Хаҗи бәк — Галинең агасы.
Актай — баш карачы (вәзир).
Инәл кам — Бурлы ыруында дин-йола башлыгы (шаман).
Беренче юлчы (Шәмсетдин).
Икенче юлчы.
Өченче юлчы.
Ярмыш — Болгар илчесе.
Тукаш — сәүдәгәр.
Күгеш — Хаҗи бәкнең өй-агасы.
Бикә — Ураз бәкнең хатыны.

Аксакаллар, илчеләр, сакчылар, кораллы ирләр, хезмәтче хатыннар, хан кешесе, улагчы (ашыгыч хәбәр китерүче).

Вакыйганың урыны — урта гасырдагы Болгар дәүләте һәм Кыпчак далалары, вакыты — монгол яулары чоры, ягъни 1220—1230 еллар.

### БАШЛАУ

Гали шигырь укый:
Без — тузан бөртеге Мәңгелек юлында.
Тузанның гомере — Газраил кулында.

Әйтегез, ни мәгънә дөньяга туудан,
Билгесез бер тузан бөртеге булудан?!

Кайгырма, Кол Гали, зарланма язмыштан —
Тузаннар мең төрле матдәдән яралган:

Берәүләр тусалар агачтан йә таштан.
Башкалар ялкыннан бүленеп таралган.

Кайгырма, туганым, зарланма язмыштан,
Бик кыска гомерле булсаң да тумыштан.
Кызганмый үзеңне балкып ян һәм яндыр,
Гасырлар күгендә ялкынлы эз калдыр!

Буыннан буынга нәселең таралсын,
Үтердем аны дип Газраил алдансын.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Киез өй эче. Өй уртасында, җир идәндә учак яна. Учак янында Гали утыра. Ул нидер яза. Бер арада эшеннән туктый да тышкы якка колак
салып тыңлап тора.

Гали *(тора, йөренә, үзалдына сөйләнә).*
Тышта төн. Тавышлар тынган.
Канат җәйгән йокы һәр якка.
Тик мин генә уяу, байгыш сыман,—
Йокы качты миннән еракка.
Тышта төн. Учаклар сүнгән.
Караңгылык хаким бу җирдә.
Тик бер учак яна ялкынланып
Минем өйдә... ярлы бер өйдә.

Җирдә төн. Йолдызлар ерак.
Томаналык, кыргый торгынлык.
Тик яралы күңелемдә дөрли
Уй-хыяллар белми тынгылык.

*(Көрсенә.)*

Кемгә кирәк бу далада, Гали,
Ялгыз учак, яралы күңел?

*(Түшәмдәге төннек аша күккә карый.)* Кешеләр дә, йолдызлар да күрми сине, белми сине, шагыйрь Гали. Йолдызлар — ерак, кешеләр — йокыда. *(Яңадан йөренә.)* Юк, ялгышма, Гали! Башлаган эшеңне син тәмамларга тиеш! *(Учак янына утыра, яза, сыза.)*

Чәчәк керә. Кыюсыз гына атлап, елмаеп учакка якынлаша. Арттан Галинең күзләрен буа.

Гали. Кем бу? Кем бу?! Энҗе, синме?
Саташаммы әллә югыйсә?!

Чәчәк *(корт чаккандай кулын тартып ала. Төшенке).* Мин Энҗе түгел, мин — Чәчәк.

Гали. Чәчәк? Син? Бу вакытта?!

Чәчәк. Син миңа икенче тапкыр «Энҗе» дип эндәштең. Кем ул Энҗе?

Гали. Чәчәк... Алсу чәчәк, тиңсез чәчәк!
Нидер булган сиңа. Ни булды?

Чәчәк. Ни булганын мин үзем дә белмим. Күзгә йокы керми. Син безнең Бурлы ыруына килеп кушылганнан бирле көннең яме качты, төннең тынычлыгы качты. Инәл кам сине бозучы, күз буучы, ди.

Гали. Инәл кам?

Чәчәк. Мөселманнар алар барысы да бозучылар, күз буучылар, ди. Кешеләрне, терлекләрне бозу өчен төне буе учак ягып, өендә ниндидер яман эшләр эшли, ди синең турыда.

Гали *(аягүрә баса)*. Син шуңа ышандыңмы?

Чәчәк. Белмим. Минем үз күзләрем белән күрәсем килде.

Гали. Минем күз буганнымы?

Чәчәк. Синең учак ягып, нидер эшләгәнеңне.

Гали *(кәгазь-каләмен Чәчәккә күрсәтә)*. Менә күр — мин язам.

Чәчәк. Ни язасың?

Гали. Кыйсса... җыру.

Чәчәк *(ак кәгазьне караштырып)*. Алай икән. Нәрсә турында соң ул синең җыруың? Батырлар турындамы, бер-берсен яратышкан кыз белән егет турындамы?

Гали. Минем жыру Йосыф атлы җегет белән Зөләйха атлы кыз турында.

Чәчәк. Алар яратышаларммы?

Гали. Яратышалар.

Чәчәк. Кызы Зөләйхамы? Энҗе кем соң, алайса?

Гали. Энҗе... Энҗе ул... сиңа охшаган бер болгар кызы.

Чәчәк. Син аны яратасыңмы?

Гали. Мин аны яраттым, Чәчәк!

Чәчәк. Кайда соң ул болгар кызы?

Гали. Ул еракта, моннан бик еракта!
Упкын ята безнең арада.

Чәчәк. Син аны яратасыңмы?

Гали. Карале, әйдәле ул турыда сөйләшмик, Чәчәк.

Тышта, якында гына күк күкри, яшен яшьнәп китә. Чәчәк, куркып, ирексездән Галигә сыена. Икесе дә төннек аша күккә карыйлар.

Чәчәк. Мин куркам. Яшен иясенең кемгәдер ачуы бар. Сине генә сукмаса ярар иде, Гали! Төннегеңне дә япмагансың, ичмасам.

Гали. Нишләп мине генә сугар икән соң ул? Сукса, икебезне дә...

Чәчәк *(коты алынып).* Ни сөйлисең, Гали?! Тәңре каршында минем бер языгым да юк.

Гали. Нишләп минеке бар дип уйлыйсың?

Чәчәк. Мин уйламыйм, Инәл кам әйтә.

Гали. Ул шулай гел мине яманлыймыни?

Чәчәк. Ул сине яратмый, Гали. Ул сиңа каршы атамны да котырта.

Гали. Атаң... Ураз бәк нәрсә ди?

Чәчәк. Ул да сине өнәп бетерми. Хәрәзем ханы Мөхәммәт солтан кыпчакларны җиңгәч, Сугнакны туздыргач, ул бигрәк тә ачулы сезгә.

Гали. Мөхәммәт солтанның Сугнакны туздыруына минем яисә башка болгарларның ни катнашы бар?

Чәчәк. Мин анысын белмим. Мин бернәрсә дә белмим, Гали! Алар сине мөселманнарның яшерен шымчысы дип уйлыйлар.

Гали. Менә сиңа кирәк булса!

Чәчәк. Кач син, Гали, моннан! Кач тизрәк!

Гали. Кыпчакларга каршы, Ураз бәккә каршы мин берninди яшерен эш алып бармыйм. Шикләнәләр икән, тикшерсеннәр, сорашсыннар.

Чәчәк. Тикшерә башлагач, соң булыр. Инәл камга беркем каршы килә алмый. Ул сиңа күптән теш кайрый, Гали!

Гали. Беләм. Очрашканда ул мине күрми узып китә.

Чәчәк. Гали, качыйк икәүләп! Ишетәсеңме, Гали, мин синең мәңгелек юлдашың булырмын!

Гали *(яратып, иркәләп).*

Карлыгачның канатыдай кашларың бар,
Сәйлән сыман тезлеп торур тешләрең бар,
Ефәк сыман йомшак дәхи чәчләрең бар,—
Сине күрсә тотлыгадыр телем имди!
Балкыр иде бәхет нуры, булсак бергә,
Мәхәббәтнең сарайларын корсак бергә!
Ләкин язмыш аяк чала һәрчак безгә,
Нихәл итим — вөҗдан кушмый андый эшкә!

Чәчәк *(читкә тайпыла).* Сез, болгарлар, барыгыз да белекле, укымышлы. Яратышу турында сез әнә нинди җырулар чыгарасыз — үзегезнең күңелегез таш кебек!

Гали *(юатмакчы була).* Туктале, тукта, Чәчәк...

Чәчәк *(кырыс).* Туктыйсы юк! Кара аны, иртәгә соң була күрмәсен! Сау бул, җыручы. *(Ишеккә ташлана, туктый, кинәт җылап җибәрә. Бик каты итеп күк күкри. Җылаудан туктап, Галигә борылып карый.)* Мине Инәл камга кияүгә бирмә келиләр! *(Җылый-җылый чыгып китә.)*

Гали. Чәчәк! *(Артыннан ташлана, туктый, кире борыла. Каты итеп тагын күк күкри.)*

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Гали.

Килде, керде. Тынычлыкны бозды.
Котны алды, татлы шом салды!
Бар нәрсәнең өсте аска килде,
Күңелемне биләде-алды.

*(Йөренә.)*

Иртә таңнан көтү куасың бар,—
Җитәр, Гали, ташла эшеңне.

*(Кәгазь-каләмен җыештыра, урын-җир әзерли башлый.)*

Кинәт тышта эт өргән тавышлар ишетелә. Кемнәрдер ишеккә якынлаша. Гали сагаеп тыңлый.

Тыштан тавыш. Өйдәләрме? Адашкан юлчыларны төн кунарга кертсәңезче?

Гали ишек янына килә, тыңлый.

Гали *(үзалдына).* Килеп тә җиттеләрмени?! Кемнәр? Кемнәр генә булмасын, сак булырга кирәк, Гали. *(Идәндәге төргәкләр арасыннан кылычын ала, биленә тага, озын чапан итәге белән каплап куя.)*

Тыштан тавыш. Без — юлаучылар. Барлыгы өч кеше. Арыдык, ачыктык, юлны югалттык.

Гали *(ишек артындагы кешеләргә).* Ишек ачык — түрдән узыгыз, юлаучылар. Өем тар, күңелем иркен. Яхшы кешеләргә учагым ягулы, казаным асулы. Яман кешеләргә ут та юк, ит тә юк. Яман кешенең юлы читтән узсын.

Ишектән бер-бер артлы өч ир кеше керә. Өсләрендә озын киемнәр, билләрендә янчык, кынлы пычак ише нәрсәләр. Буйсыну белдереп,
кулларын кушыралар. Гали алдында баш ияләр.

Беренче юлчы. Без — мөселманнармыз. Безнең уемызда яманлык имәс.

Гали. Түрдән узыгыз, яхшы кунаклар.

Беренче юлчы. Илегез имин улсын, терлек-туарыңыз чук улсын, тук улсын. Безгә монда Бурлы ыруы җәйләүләре булырга тиеш дигәннәр ирде. Без инде өч көн, өч төн киләмез. Икенче көн

авызымызга бер тәгам ризык алганымыз юк. Атларымыз арыды, үземез үләр чиктә. Караңгыда ут күрдек тә килдек. Кемнең җәйләве, кемнең ялгыз өе бу, мәрхәмәтле хуҗа?

Гали. Сез эзләгән Бурлы ыруының җәйләве бу, юлаучы. Мин Бурлы ыруының башы Ураз бәкнең карасы Гали торырмын.

Беренче юлчы. Гали дисеңме? Син дә мөселманмыни?

Икенче юлчы. Менә куаныч!

Гали. Әйе, мөселманмын. Ләкин минем мөселманлыгымнан кемгә — куаныч, кемгә — юаныч.

Беренче юлчы. Мөселман кешенең динсез, кыргый кыпчакның карасы булуы — күңелсез хәлдер.

Гали. Миңа чыннан да күңелсез иде. Сез килгәч, күңелле булып китте. Әйдәгез, утырыгыз, сөйләгез — каян киләсез, кая барасыз? Ниләр күрдегез, ниләр ишеттегез? *(Тиз-тиз генә казан аса, учак янына табын әзерли, вак-төяк савыт-сабалар китереп куя. Ул арада юлчылар учак тирәсенә утырышалар.)*

Беренче юлчы. Без күргәнде сөйләргә сүз җитмәс, Гали туган.

Икенче юлчы. Без сөйләгәннәрне тыңларга түземлелегең җитмәс, Гали туган.

Өченче юлчы. Без сөйләгәндәрде тыңласаң, күңелең күтәрелер, дип әйтеп булмайды.

Гали турсыктан, ягъни тире капчыктан агач касәләргә кымыз агыза.

Гали. Ярый, кунаклар, сезнең белән очрашу хөрмәтенә кечкенә туй ясап алыйк. Өемдә ни бар — барысы да сезнең алда. Сез сөйләячәк сүзләр күңелсез булганлыктан, казанда ит пешкәнче, күңелләрне кымыз белән күтәрә торыйк. *(Кымызны эчәр алдыннан беразын учакка тамыза, эчә, касәне Беренче юлчыга бирә.)*

Беренче юлчы *(касәне ала, кымызның беразын учак тамыза, эчә, касәне Икенче юлчыга бирә)*. Тәмле телең, яхшы сыең өчен рәхмәт, хуҗа!

Икенче юлчы *(касәне ала, кымызның беразын учакка тамыза, авыз итә, касәне Өченче юлчыга бирә).* Җакшы! Булуы җиткән!

Өченче юлчы *(касәне ала, кымызның беразын учакка тамыза, эчеп бетерә, касәне Галигә бирә)*. Ай-йай, күз алдары яктырып кетде!

Гали *(касәгә яңадан кымыз агыза, эчә дә Беренче юлчыга бирә)*. Берне авыз иткәч, күз алларыгыз яктырды, икенчене авыз иткәч, телләрегез чишелсен.

Беренче юлчы *(эчә, иптәшенә бирә).* Син, Гали туган, безнең телләрне чишәргә ашыкма. Тыныч сәгатьләрең озаккарак сузылсын.

Гали. Сез, юлаучылар, бик серле сөйләшәсез. Шулай да кемнәр сез — инде әйтсәгез дә ярыйдыр?

Беренче юлчы *(Галигә текәлеп карый)*. Гали! Син үзең кем?

Гали *(сискәнеп китә, нидер сизенеп, шулай ук Беренче юлчыга текәлеп карый)*. Мин әйттем: мин Ураз бәкнең карасы Гали торырмын, дидем.

Беренче юлчы. Анысын ишеттек. Минем уйлавымча, син — Ураз бәкнең карасы Гали — Болгар ханының Мәликә хатыннан туган төпчек улы торырсың!

Икенче юлчы. Болгар ханының дисеңме?

Өченче юлчы. Ой-бой! Теге батыр Галиде әйтәсеңбе?

Гали *(кулыннан әйбере төшеп китә)*. Тс-с, кычкырып сөйләшмәгез! Каяле, ишек артында берәрсе юк микән... *(Тора, кунаклардан читләшә, чапан итәге астыннан кылычын тартып чыгара, серле юлчылар каршына килеп баса.)* Әйе, мин — Ураз бәкнең карасы — Болгар ханының төпчек углы торырмын. Агам Хаҗи бәкнең мәкере аркасында миңа яла яктылар, атама каршы баш күтәрергә ниятләүдә гаепләп, мине туган илемнән качарга мәҗбүр иттеләр. Минем кемлегемне монда беркем белми. Белмәскә тиеш. Төшендегезме? Инде әйтегез: өчегезне берьюлы чабып ташлыйммы, әллә берәм-берәм чапсам да ярармы?

Беренче юлчы. Гали! Гали углан! Чынмы бу? Ышанмыйм, ышанасы килми. Йа Алла, йә Тәңрем, нинди кыямәт көннәре килде безгә? Аксөякләрнең кадере калмады, бар дөньяга коллар, кыргыйлар баш булды. Мин дә синең кебек үк туган иленнән... Болгардан качып киткән бәхетсез бәндәмен... казначы Сәйфетдин углы Шәмсетдин торырмын. Таныйсыңмы, Гали?

Гали. Туктале, тукта... Шәмсетдин? *(Ныгытып карый.)* Әйе шул, Шәмсетдин!

Шәмсетдин. Казна байлыгын үзләштергән дип, минем атама да ялган гаеп тактылар. Атамны яргуламакı булдылар. Котылу юлы калмагач, караңгы бер төндә каекларга төялдек тә...

Гали. Беләм! Барысы да истә. Моннан биш-алты ел чамасы элек булды бу хәлләр.

Шәмсетдин. Дөрес, Гали углан!

Гали. Сез качып киткәннән соң ике-өч ел үткәч, хан сезне аклады бугай.

Шәмсетдин. Безне?! Барыбызны дамы?!

Гали. Сине дә ике энеңне, ахрысы. Атаңны акламадылар.

Шәмсетдин. Йа Алла, йә Тәңрем! Шундый зур куанычтан кинәт йөрәгем тукталгандай булды. Мин әле ишетмәгән идем. Атам инде күптән җир куенында. Акласа, аны бары Тәңре генә аклар. Ике энем шулай ук теге дөньяда. Бу дөньяда бары мин генә калдым — куанычымның чиге-чамасы юк, Гали!

Гали. Болай булгач, әйдәгез әле туйны яңадан башлап җибәрик.

Учак янына утырышалар, яңадан чиратлашып кымыз эчәләр.

Гали. Син, Шәмсетдин, кая юл тотасың?

Шәмсетдин. Әлегә тикле кая барырымны үзем дә белми идем, хәзер — туп-туры Болгарга! Бары Болгарга гына!

Гали *(хыялланып)*. Болгар... Син нинди бәхетле, Шәмсетдин!

Шәмсетдин. Карале, Гали туган, безнең Чирмешен яры буендагы ике катлы таш өебез әле дә исән микән? Кире бирерләр микән?

Гали. Аклагач, мөгаен, бирерләр.

Шәмсетдин. Бирмәсәләр дә кайгырмыйм. Баш кына исән булсын! Баш исән булу кирәк, Гали туган, баш! Кешегә бу дөньяда шуннан башка берни кирәкми. Менә мин шуны аңладым. Байлык, дәрәҗә, сарайлар, хатын-кызлар, бала-чага, кием-салым...— барысы да чүп-чар, көл-тузан. Алар бер көн эчендә юкка чыгарга мөмкин. Ничек тә үзеңне сакларга кирәк. Мин — галим. Үргәнечтә шәкертләргә дин гыйлеме үгрәттем. Болгарга, ханбалыкка[1] кайткач, мәдрәсә ачам, балалар укытам.

Икенче юлчы. Укыта алырсың микән?

Өченче юлчы. Булмас инде ул мәдрәсәләр ачып балалар укыту. Дөньяның рәте кетде. Яэҗүҗ-мәэҗүҗ кузгалды.

Шәмсетдин *(кинәт сүрелеп кала, төшенкелеккә бирелә)*. Болар — минем юлдашлар, Гали. Без бергә... качтык.

Гали. Каян? Ник? Моннан качтыгыз, аннан качтыгыз. Сез качтыгыз, мин качтым. Кем генә качмыйча, курыкмыйча яши соң бу дөньяда?

Шәмсетдин. Гомере буена кеше үлемнән качып яши. Синең сыман без дә үлемнән качтык, Гали.

Икенче юлчы. Без дәһшәттән качтык, Гали! Чин-Кытай ягыннан Чыңгыз атлы илбасар калыкты.

Өченче юлчы. Бохара, Сәмәрканд, Үргәнеч...— барлык шәһәрләр, авыллар җир белән тигезләнде. Кеше сөякләреннән таглар өелде, Гали!

Шәмсетдин. Җир йөзендә Чыңгыз ханга каршы торырлык көч юк, Гали. Хәрәзем ханы Мөхәммәт солтан, илен-көнен ташлап, чирүен[1], хатыннарын, балаларын ташлап, каядыр көньякка качып китте. Углы Җәләлетдин Чыңгызга каршы торырга тырышып карады,— булдыралмады.

Гали. Монда ишетелгәләгән имеш-мимешләр, алайса, чын?

Шәмсетдин. Кая ул чын булмаган! Үргәнечне җиде ай камап тордылар. Алдылар, таладылар, җимерделәр. Карт анамны, өлкән хатынымны күз алдымда кылыч белән чаптылар, яшь хатынымны, буй җиткән кызымны күз алдымда мәсхәрә иттеләр, Гали! Биш яшьлек углымны сөңге башына кадап, янган утка ыргыттылар, Гали! Анысы да күз алдымда булды. Чытырдап янды... кара күмергә, көлгә калганчы, Гали! Төнлә төшләремә керә, саташып кычкырып уянам. Кемдер минем яшерелгән бик күп алтыным бар дип әйткән — шуны таптырдылар. Ябып тоттылар. Төнлә сакчыларны алдап качтым. Колак төбемдә туктаусыз җылаган, ялварган тавышлар ишетелә. Кайчакларда акылдан шашардай булам!

Гали. Аларны син безнең якларга да килеп җитәрләр, дип уйлыйсыңмыни, Шәмсетдин?

Шәмсетдин. Кая ул җитмәгән! Алар кояш чыгыштан кояш батышка тикле барлык илләрне-йортларны басып алмакчылар, барлык халыкларны үзләренә буйсындырмакчылар. Каршылык күрсәткәннәрне бернинди кызганусыз юк итәләр, бары үзләре теләп буйсынганнарны гына исән калдыралар.

Гали. Аңлашыла. Барча дошман шулай итә: каршылык күрсәткәннәрне үтерә, каршылык күрсәтмәгәнне исән калдыра. Мөхәммәт солтан сыман, бар нәрсәңне ташлап, бары үз башыңны коткару өчен генә качып йөрсәң, дошман тагын да ныграк кыюлана, оятсызлана.

Шәмсетдин. Алар дошман гына түгел, алар — динсезләр, кыргыйлар! Алар яшен ташы кебек, алар — Наҗагай[2] кебек!

Икенче юлчы. Алар җил-давыл кебек, язгы ташу кебек!

Өченче юлчы. Аларга каршы торырдай көч юк дөньяда!

Гали *(аягүрә баса, ике куллап кылычына таяна)*. Барлык кешеләрнең котын алу өчен яу алдыннан сезнең кебек коткычыларны җибәрәләр. Менә шулай сөйләнеп, сез Кыпчак даласында коткы таратасыз. Хәзер Болгарга кайтып, сез анда да шушы ук сүзләрне сөйләячәксез...

Шәмсетдин. Ниткән коткы булсын? Без күргәнне сөйлибез!

Гали. Күргәнне төрлечә сөйләргә була. Туктаган бер җирдә әлегечә шомлы итеп сөйләсәгез, дошманга сез алдан ук җиңү яулыйсыз. Моның өчен сезнең башыгызны чаптырырга кирәк!

Шәмсетдин кинәт билендәге пычагына тотына. Ике юлчы да аякларына басалар, коралларына тотыналар.

Шәмсетдин *(калтыранып)*. Минем башны... син... чабарга җыенмыйсыңдыр ич, көтүче Гали?

Гали *(үз-үзен көчкә тыеп)*. Юк, мин синең башыңны чабарга җыенмыйм, казна талап качкан Сәйфетдин углы Шәмсетдин. Чүбек тутырган кабак башың үзеңә булсын. Яудан синең котың алынган, ихтыярың сынган. Мин сине аңлыйм, шунлыктан синең тупаслыгыңны кичерим. Ләкин син шуны да онытма: җир йөзендә Сәмәрканд, Бохара, Үргәнечләр генә түгел, синең туган шәһәрең Бөек Бүләр бар, Суар, Ашлы бар, Җүкәтаулар, Ташкирмәннәр бар. Безнең уртак йортыбыз изге Болгар бар, иксез-чиксез далаларны биләгән кыпчаклар бар. Тагын да арырак китсәң, Урыс бар, Кафтау, Франк бар. Җимерелгән, таланган Хәрәзем шәһәрләре турында тыңлаганда, мин менә шуларны уйладым, Шәмсетдин!

Шәмсетдин *(мыскыл белән)*. Уйласаң да, уйламасаң да, син инде берни дә кыра алмассың, көтүче Гали. Синең эшең беткән. Болгар турында атаң кайгыртсын.

Гали. Шәмсетдин! Ничек телең бара?!

Шәмсетдин. Үз башың турында уйласаң, синең өчен тагын да яхшырак булыр, көтүче Гали.

Гали *(ярсып)*. Гөнаһлы итмә — сыпыр яхшы чакта!

Шәмсетдин *(ишеккә таба чигенеп)*. Син нәрсә? Ярар, кыздык, бетте. Әйттем исә кайттым.

Гали *(Шәмсетдиннең юлдашларына карап)*. Сез дә! Өчегез дә! Исән чакта...

Шәмсетдин *(йомшап, ялагайланып)*. Мондый вакытта яхшы адәм этен дә куалап чыгармас.

Икенче юлчы *(ишеккә таба чигенә)*. Синең әле чын яуны күргәнең юктыр, Гали.

Өченче юлчы *(ишеккә таба чигенә)*. Күрергә язмасын, Ходай!

Гали *(кылычын җайлап тотып)*. Саныйм: бер, ике...

Өченче юлчы *(учак өстендәге казанга карый)*. Ит кенә әрәм кала.

Икенче юлчы *(кымыз тулы турсыкка карый)*. Кымызы да.

Гали. Ит пешкән. Алыгыз. Турсыкны да алыгыз.

Юлчылар итне, турсыкны алалар.

Шәмсетдин *(ишек төбендә)*. Кызып киттем. Кичер, Гали.

Гали *(коры)*. Сау бул, Шәмсетдин.

Шәмсетдин. Сау бул, Гали.

Гали *(йомшап)*. Бүләргә кайтып җитә алсаң... зиратка барып... анам каберенә сөйлә минем хакта.

Шәмсетдин. Сөйләрмен, Гали.

Чыгалар. Тышта ерагая барган тояк тавышлары ишетелә. Күк күкри, яшен яшьни.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Гали ялгыз.

Гали.

Яшен яшьнәп, күк күкрәтеп болыт килә,  
Үз юлында бар нәрсәне кырып килә.  
Бозмы, ташмы — нәрсә явар яңгыр илә?  
Ни яуса да, кан-яшь килә, үлем килә!  
Дала ачык җил-давылга. Чыпчык кача.  
Башын саклап посар өчен тыныч җирдә.  
Алып-батыр кошлар гына кыю оча —  
Һич куркытмас кара болыт бөркетләрне!

*(Көрсенә, йөренә.)* Ә син үзең бөркетме соң, әллә чыпчыкмы? Шәмсетдинме, Гали угланмы?! Ах, Гали! Үкенечле синең язмыш! Кул-аягың бәйле, телең — богауда! Чыпчык булмый, кем син тагын, мескен, Гали?! *(Туктый, кискен үзгәреп.)* Булмый! Ярамый! Күктән кан исе килә, көек исе килә! Мөхәммәт солтанны җиңгән дошман Кыпчак даласында гына туктап калмас Кыпчактан соң — Болгар!

Болгар... Синең туган йортың. Анаң кабере. Карт атаң, туганнарың, туган халкың... Менә мондый хәтәр чакта Болгарга син кирәк, Гали! Синең кебек сугышчылар кирәк.

Ләкин... ничек кайтырга үз йортыңа, үз атаң янына?! Кул-аяклар бәйле, юллар ябылган. Бердәнбер өмет — кыйсса. Атамның аяк астына егылырмын да: ханга, Болгарга турылыклы икәнлегемне исбатлау өчен, мин сиңа багышлап гүзәл кыйсса иҗат иттем, бөек ханым, диярмен. Һәм ул мине гафу итәр.

Тизрәк, тизрәк язып бетерергә кирәк. *(Гали ашыгып язарга тотына.)*

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ураз бәкнең киез өе. Идән уртасында учак, учакта — ут. Түгәрәк өйнең стенасына төрле бизәкләр, ау күренешләре, җәнлек сурәтләре төшерелгән тукымалар эленгән. Идәндә бай келәмнәр, җәнлек тиреләре. Түрдә бай җиһазлы биек урын. Өйнең ишеге сәхнәнең сул ягында. Түрдәге биек урында, тамашачыга йөзе белән, Ураз бәк утыра. Сул ягында — бикә. Уң якта, түбәндәрәк ике аксакал. Бәкнең сул ягында, шулай ук түбәндәрәк — ике аксакал. Ураз бәкнең башында чын ташлар белән бизәлгән очлы бүрек. Бәктән кала барысы да яланбаш.
Озын чәчләре үрелгән.
Пәрдә ачылганда Инәл кам бәкнең өен арыклый, ягъни явыз рухларны куалый: барабан кага, кычкырып-кычкырып җибәрә. Иң ахырда өй эчендәге «җеннәрне» ачык төннектән тышка куалап чыгара.
Инәл кам аеруча игътибарга лаек. Кам (шаман)— борынгы төрки халыкларда дин-йола башлыгы. Камның өстендә йоны тышка калдырып, ат тиресеннән тегелгән тун. Берничә үремгә үрелгән озын чәчләре җилкәсенә төшеп тора. Кулында иләк сыман бер яклы барабан. Барабан кысасындагы аркылы тимергә шөлдерләр тагылган. Колакларында — алка, кулында — кечкенә тукмак. Һәрбер хәрәкәтеннән шалтыр-шолтыр тавышлар чыга. Кам кызу канлы, җитез, кискен. Бик тиз кызып китеп, шашу дәрәҗәсенә җитәргә мөмкин.

Инәл кам *(такмаклый)*.

Чыгың, чык! Чыгың, чык!
Сезнең урын монда түгел,
Сезгә монда кулай түгел.
Чыгың, чык! Чыгың, чык!
Сикереп чык, йөгереп чык,
Үлә-казала очып чык!

Учак янына килә. Аксакалларның берсе касә белән аңа кымыз бирә. Кымызны кам аз-азлап кына утка сибә — утка йолык (корбан) бирү
йоласын башкара. Такмаклый:

Илгә тереклек биргән,
Өйгә җылылык биргән,
Иярне сөйдергән,
Күрмәсләрне[1] көйдергән
Кырык уллы Ут-ана,
Кырык күзле Ут-ана,
Кырык телле Ут-ана,
Кырык җирдә Ут-ана!
Илдән — йолык!
Миннән — йолык!
Бәктән — йолык!

Ураз бәк *(ишек ягына карап кычкыра)*. Керсен!

Гали керә. Ике ягында ике сакчы.

Гали *(баш орып)*. Йорт-илең имин булсын, өең, караларың сау булсын, терлекләрең көр булсын, бәк. Олуг Тәңре үзеңә, бикәңә чиксез күп яшь бирсен.

Ураз бәк. Шулай булсын. Исеңдәдер, көтүче Гали, моннан биш-алты ай элек, ач-ялангач килеш, өтәләнгән килеш син минем бусагама килеп егылдың.

Гали. Барысы да исемдә, бәк.

Ураз бәк. Син әйттең: мин Болгардан, дидең. Агам белән тыныша алмадым. Атамнан калган байлыгымны тартып алмакчы булып үтермә келәделәр, шуның өчен илемнән качып киттем, дидең.

Гали. Барысы да дөрес, бәк!

Ураз бәк. Мин сиңа ышандым, тамагыңны туйдырдым. Кияреңә кием бирдем, торырыңа өй бирдем.

Гали. Сүзең дөрес, бәк!

Ураз бәк. Минем алда, бикә белән аксакаллар алдында сүзеңне кабатла.

Гали. Сүземне кабатлыйм: син мине ач үлемнән коткардың, син мине өйле, атлы, киемле иттең. Син мине үз канатың астына алдың, Ураз бәк.

Ураз бәк. Шулай булгач, көтүче Гали, инде тагын әйт: яхшылыкка яхшылык тиешме, әллә яхшылыкка яманлык тиешме?

Гали. Яхшылыкка яхшылык тиеш, Ураз бәк.

Аксакаллар, хуплау белдереп, җиңелчә гөрелдәп алалар.

Инәл кам *(кискен)*. Син ялган сөйлисең, Болгар мөселманы!

Гали. Ни уйласам, мин шуны сөйлим, изге кам. Мин әйтәм: яхшылыкка яхшылык тиеш, димен. Син шуны ялган дисеңмени?

Инәл кам. Сүзең чын, эшләгән эшләрең — яманлык!

Гали. Мин Ураз бәкнең көтүләрен көтәм. Бу эшне мин яман эш, дип әйтмәс ирдем, изге кам.

Аксакаллар, теләктәшлек белдереп, ирексездән янә гөрләшеп алалар.

Инәл кам. Синең яман эшләрең дә җитәрлек, Болгар мөселманы!

Ураз бәк. Шулай, синең яман эшләрең дә бар, көтүче Гали. Монда без сине шуның өчен яргуларга чакырдык.

Гали. Төшендереп бирсәгезче, бәк.

Ураз бәк. Син, көтүче Гали, төне буе учак ягып, качып-посып, өеңдә ниндидер шикле эшләр эшлисең. Нишлисең син төне буе?

Инәл кам. Нишләсен! Мөселман китапларына карап, бозу, күз буу эшләре эшли!

Аксакаллар.

— Кешеләргә, терлекләргә талау китерә!

— Моның өчен утта яндырырга кирәк — эзе калмасын безнең далада!

Инәл кам. Кырыкка тураклап, үләксәсен кырык җиргә күмәргә!

Тынлык.

Аксакаллар.

— Инәл кам белеп әйтә!

— Кырыкка тураклап, кырык җиргә күмәргә!

Ураз бәк. Син ни диярсең шуңа, көтүче Гали?

Гали *(киеренке)*. Мин шуны әйтермен, Ураз бәк: төннәр буе мин үз өемдә учак ягып, качып-посып, мөселман китапларына карап, бозу, күз буяу эшләре белән шөгыльләнмим. Ни өчен дигәндә мин үзем... китап язам!

Гомуми аптыраш. «Кит аннан!»
«Булмасны!» дигән сүзләр ишетелә.

Ураз бәк. Кабатлап әйт: нишлисең?

Гали. Кабатлап әйтәм: мин китап язам. Көндез минем вакытым юк, мин бары төнлә генә үз иркемдә.

Бикә. Китапны кешеләр язамыни?

Инәл кам. Китапны мөселманнар күктән иңдерелгән диләр!

Гали. Дөрес, кайбер мөселманнар, барлык китапларны да изге санап, күктән иңдерелгән дип уйлыйлар. Син дә, изге кам, мөселман китапларын күктән иңдерелгән дип, изге дип уйлыйсыңмыни?

Инәл кам. Тфү-тфү! Телеңә — тилчә!

Ураз бәк. Яра-ар, көтүче Гали. Син кызык итеп сөйлисең. Мин сине белмәгәнмен. Синең тынычлыгың, кыюлыгың миңа ошый. Инде әйтеп бир: ни язасың ул китапка?

Гали. Җыру язам, Ураз бәк.

Аксакаллар көлешә башлыйлар.

Бикә. Җыруны китапка язалармыни? Беренче тапкыр ишетәм.

Аксакаллар.

— Җыруны телдән әйтәләр!

— Җыруны думбырада чиртәләр!

Ураз бәк. Әйтеп, чиртеп күрсәт безгә, көтүче Гали. Бирегез аңа думбыра!

Галигә думбыра бирәләр.

Гали *(думбыра чиртә, такмаклый)*.

Җырулардан, кыйссалардан
иң затлысын.
Ялыкмастан тыңлау өчен иң татлысын
Китап эчрә тезә барам иң аклысын,—
Моны белү тиеш сезгә, и наданнар!

Инәл кам. Тукта!

Ураз бәк *(ачулы)*. Синең нинди җыручы булуың аңлашылды, көтүче Гали.

Аксакаллар.

— Җыруы үз башына!

— Син языклы, көтүче Гали!

Ураз бәк. Беренче языгыңны кире кага алмадың. Синең тагын ике языгың бар. Аларын да кире кага алмасаң, сине үлем көтә, җыручы Гали!

Гали. Әйт, Ураз бәк — минем тагын нинди языкларым бар?!

Ураз бәк. Икенче языгың шул: төннәрен синең янга ниндидер шикле кешеләр килә. Кемнәр алар? Ник киләләр алар синең янга?

Инәл кам. Кемнәр булсын — Хәрәзем мөселманнарыннан шымчылар килә!

Аксакаллар.

— Кыпчакларга каршы тагын яу чапмакчы була микәнни аты коргыры Мөхәммәт солтан?
— Үләксәсен этләр җыйгыры, Бурлы ыруын да канга батырмакчы буладыр!
Ураз бәк. Дөресме шул, көтүче Гали?
Гали. Дөрес түгел, Ураз бәк.
Инәл кам. Караңгы төшкәч, сиңа ят кешеләр килгәнен мин үзем күрдем!
Аксакаллар.
— Мин дә күрдем!
— Күрдек, үз күзебез белән күрдек!
Гали.

Ярлы өем, ялгыз өем — юл буенда.
Ишек ачык көн буена, төн буена.
Миңа керми, кемгә керсен соңга калган,
Ачыккан һәм дәхи анда юлдан язган?!
Юлаучыны кире бору юк уемда.
Ләкин алар шымчы түгел — моны белең!

Инәл кам. Шымчы!
Ураз бәк. Ник шымчы түгел, көтүче Гали?
Гали.

Солтан иле Хәрәземне яу баскан, бәк!
Кыпчак кайгысы юк анда. Ул качкан, бәк.
Ташлап барын — илен-көнен, чирүләрен,
Чыңгыз ханга көнбатышка юл ачкан, бәк!

Аксакаллар.
— Авызыңа бал да май, көтүче Гали!
— Мөхәммәт солтанның башы аягы астына килсен!
— Килгән инде!
Ураз бәк *(тынычсыз)*. Бу сүзләрең чынмы, көтүче Гали?
Гали.

Чын, Ураз бәк! Аксакаллар, һәммәсе чын!
Ләкин нигә сөенергә моның өчен?!
Бүген солтан, иртәгә — без: Кыпчак,
Болгар
Татып карарга бик мөмкин дошман көчен!
Чыңгыз ханны явыз, диләр, кансыз, диләр,
Ул җимерткән шәһәрләрне сансыз, диләр,
Ул магулны фиргавендәй комсыз, диләр.
Андый катил әлегәчә булмас имди!
— Сез, кыпчаклар, таралгансыз киң далага,
Буйсынмыйсыз берегез дә уртак ханга.
Сезне җиңү берни тормас дошманнарга —
Берләшергә кирәк безгә яу алдында!

Инәл кам. Болгар беләнме?!
Гали. Болгар белән дә, башка кыпчак ырулары белән дә, изге кам!
Ураз бәк. Хәрәзем җиңелгән өчен башыма кайгы аласым юк! Минем үз кайгым үземә җиткән.
Аксакаллар.
— Шулай, кайгы баштан ашкан!
— Хәрәземне җир йотса да, ис китмәс!
— Үз далабыз исән булса, безгә шул җиткән!
Ураз бәк. Көтүче Гали, синең икенче языгың кире кагылды.
Аксакаллар.
— Языгы юк!
— Икенче языгын кире какты!
Инәл кам *(сикереп торып)*. Аның өченче языгы бар!
Ураз бәк. Әйе, синең өченче языгың бар, көтүче Гали.
Гали. Анысы ни?
Ураз бәк. Кызым Чәчәк көтмәгәндә чиргә сабышты, йокы аралаш саташып, «Гали» дип кычкыра. Бу — бозу чире. Монда син гаепле булырга тиеш.
Гали *(каушап)*.

Чәчәгем чиргә сабышкан,
Чәчәгем сулганмы әллә?!

Ураз бәк. Өченче языгыңны танийсыңмы, көтүче Гали?
Гали. Кызыңны күрәсем килә, Ураз бәк!
Бикә. Керсен, әллә чире китәр.
Бер аксакал. Теләген үтәргә кирәк.
Ураз бәк *(ишек ягына кычкыра)*. Әйтегез, кызым Чәчәк керсен.

Чәчәк керә. Кайгылы. Түргә уза, кулын кушырып, атасы-анасы алдында баш ия. Галигә каршы якта туктап кала.

Гали *(үзалдына)*.

Сылуымның нурлы йөзен кайгы баскан!
Күрсәңезче! Мәхәббәте баштан ашкан!
Ни кылаем аның өчен мин саташкан?
Сөенечтән күңелем хуш булыр имди!

Чәчәк. Нигә кирәк булдым мин монда, атам-анам, аксакаллар?

Ураз бәк. Без монда көтүче Галине яргулыйбыз. Синең чиргә сабышуыңда ул гаепледер дигән шигебез бар. Атаң-анаң алдында, аксакаллар алдында турысын әйт: бозу, чиргә сабыштыру теләге белән ул сиңа каршы берәр төрле яманлык эшләмәдеме?

Чәчәк. Әйе, бу кеше... көтүче Гали аркасында мин чиргә сабыштым, саргайдым, аяктан егылдым. Шулай да аның монда бер языгы да юк.

Инәл кам. Юк?!

Чәчәк. Әйе, юк. Көтүче Гали миңа каршы бернинди яманлык эшләмәде. Мин аны үзем... яраттым!

Бикә. Яраттым дисеңме?

Инәл кам. Ярату юк! Күз буу, сихер генә бар!

Чәчәк. Ярату булмаса, синдә юктыр, изге кам. Миндә — бар! Атам-анам алдында, Бурлы ыруының аксакаллары алдында, олуг Тәңре каршында ант итеп әйтәм: мин Галине генә яратам!

Гали *(Чәчәккә омтыла)*. Чәчәгем! Кабатлачы тагын шул сүзне!

Бикә. Атасы, бу ни эш бу?!

Аксакаллар аптырашта. Чәчәк, Галинең омтылышын күреп, күз алдында үзгәрә: башын калкыта, Галигә елмаеп карый.

Ураз бәк *(аягүрә баса)*. Мин, Бурлы ыруының башы Ураз бәк, бикә белән, аксакаллар белән берлектә көтүче, җыручы Галине яргуладым... Гали! Сиңа соңгы сүзем бар: мине мактап җыру әйт!

Гали *(башын калкыта, думбырасын алып аягүрә баса, көттереп)*. Син миңа авыр эш куштың. Армый-талмый мактарга сине, Ураз бәк, телем бармый. Изгелегең өчен рәхмәт. Көчләмә гел. Хәкимнәрне җырда мактау миннән булмый.

Ураз бәк *(ачулы)*. Син үзеңә-үзең баз казыдың, җыручы Гали. Боерам: болгар качагы Галине утта да яндырмаска, кырыкка турап, кырык җиргә дә күммәскә. Җыручы Галине, иреген алып, мәңгелек кол ясарга!

Гали *(коты алынып)*. Мәңгелек кол ясарга?! Юк, Ураз бәк! Утта яндыр, кырыкка турап кырык җиргә күм — бары тик кол гына ясама! Шагыйрь кол булмый, кол шагыйрь булмый!

Ураз бәк. Була, шаир Гали!

Инәл кам. Кол син, кол!

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Болгар башкаласы Бүләр. Хаҗи бәк сарае. Кайдадыр артта басынкы гына музыка уйный, җырлаган, тыелып кына көлгән тавышлар ишетелә. Биек терәкләр тезелеп киткән залда күләгәләр сыман хезмәтчеләр узып китә.
Эшсезлектән арыган, йончыган кыяфәттә, әкрен генә атлап, Энҗе бикә килеп керә. Аның ике ягында ике хезмәтче хатын.

Энҗе бикә *(бер кечкенә бүлмәгә керә)*. Бөтен сарайда шушы бүлмәдән дә тын, аулак урын юк. Тәрәзәдән карасаң, Чирмешән буйлары, яшел болыннар күренә. Дөнья кайгылары онтыла, очар коштай булып күңел талпына башлый. Никтер җылыйсы килә, кемгәдер сыенасы килә. *(Хезмәтче хатыннарга.)* Чыгып торыгыз — минем уйланып утырасым килә. Көйчеләргә әйтегез — уйнамасыннар. Юк — уйнасыннар! Тик әкренрәк.

Хезмәтче хатыннар шыпырт кына чыгып китәләр. Энҗе бикә ялгыз.

Энҗе бикә. Бертуктаусыз эчем поша, күңелемне сагыш кимерә. Байлык дисәң — байлык җитәрлек, дан вә шөһрәт бары да баштан ашкан. Тик шулай да миңа нидер җитми. Бүген тагын мин Галине төштә күрдем. Боек, күңелсез. Үзе кылыч кайрый. Куркуымнан котым алынды. Нәрсә булыр икән?

Хезмәтче хатын керә.

Хезмәтче хатын. Кичер, бикә. Өй агасы Күгеш сине эзли.
Энҗе бикә. Аз гына да котылып торып булмый. Күгешләрдән, борчулардан!
Хезмәтче хатын. Бик тә кирәк ди, бикә.
Энҗе бикә. Керсен.

Хезмәтче хатын чыга, Күгеш керә.

Күгеш. Хаҗи бәкне сорап, кешеләр килгән, бикә. Көтсеннәрме, кайтып китсеннәрме?
Энҗе бикә. Мин үзем дә Хаҗи бәкне көтәм.
Күгеш. Алайса көтмәсеннәрмени?
Энҗе бикә. Кемнәр килгән? Нинди эш белән?
Күгеш. Башкыртлар калан китергәннәр.
Энҗе бикә. Тагын кемнәр?
Күгеш. Чирмеш бие Актанай, аннары Җүкәтаудан Ибраһим бәк, аннары урыслар...
Энҗе бикә. Урыслар ни йомыш белән?
Күгеш. Иделдә Ашлыдан түбән балык тотарга рөхсәт сорыйлар.
Энҗе бикә. Тагын кемнәр?
Күгеш. Күп инде анда. Олысы да, кечесе дә Хаҗи бәккә килә. Хаҗи бәк сарае хан сараена әйләнде, бикә.
Энҗе бикә. Юкны сөйләмә, Күгеш. Хаҗи бәк сараеның хан сараена әйләнгәне юк әле. Хан үз урынында, Хаҗи бәк үз урынында.
Күгеш. Алайса кайтып китсеннәрмени, бикә?
Энҗе бикә. Чит ил сатучыларыннан беркем дә юкмыни?
Күгеш. Нишләп булмасын, бар. Кырымнан, Мисырдан, Румнан, Куябыдан...
Энҗе бикә. Ник башта ук шуларны әйтмисең? Кемнәр килгән? Нәрсәләр алып килгәннәр? Бүләккә ятрак, затлырак әйберләр юк микән?
Күгеш. Бик бай киенгәннәре дә бар. Таныш йөзләр дә күренгәли. Аннары качаклар, бикә... Үргәнеч, Бохара якларыннан. Анда каты яу бара ди, бикә.
Энҗе бикә. Әйтмәле шул качакларны! Бу арада күбәеп киттеләр әле алар.
Күгеш. Әйе, бикә, ул яклардан көн дә шомлы хәбәрләр килә.
Энҗе бикә. Күгеш, ул турыда берни әйтмә! Шомлы хәбәрләр, Аллага шөкер, үзебездә дә җитәрлек.
Күгеш. Алайса, бикә?..
Энҗе бикә. Тагын кемнәр?
Күгеш. Каралардан берничә кеше, галим-голәмә, шагыйрьләр.

Хезмәтче хатын керә.

Хезмәтче хатын. Хаҗи бәктән кеше кайтты, бикә. Хаҗи бәк әйткән, бүгенгә кайталмыйм, Сараландагы утарга китәм, анда ашыгыч эшем бар, дип әйткән.
Энҗе бикә. Менә ни өчен эчем пошкан икән көне буена! Ярар, ул анда типтерсә, без монда типтерербез. *(Хезмәтче хатынга.)* Андагыларга әйт: бүген кич аш-су ясыйбыз. Табынны көндәгедән илле кешегә артыграк әзерләсеннәр.
Хезмәтче хатын. Әйтермен, бикә. *(Чыга.)*
Күгеш. Алайса?..
Энҗе бикә. Әйе, «алайса», Күгеш! Каралар, качаклар кайтып китсеннәр. Чит ил сатучылары, болгар сатучылары, галим-голәмә, шагыйрьләр бүген миңа аш-суга килсеннәр. Башкыртларга, чирмеш бие Актанайга, Җүкәтау Ибраһимга, урысларга әйт: Болгарда беренче — хан, икенче — Хаҗи бәк, диген. Хаҗи бәктән узып, беркем берни эшли алмый, диген. Бүгенге аш-суга киләсе кунакларны яхшырак кара. Юк-бар бүләк бирердәйләрнең, шомлы хәбәр сөйли торганнарның берсен дә якын җибәрмә.
Күгеш. Шулай итәрмен, бикә. *(Чыга.)*
Энҗе бикә *(ялгыз).* Беләм мин синең Сараландагы ашыгыч эшләреңне! Мин — читлектәге кош кебек. Ул әнә өенә кайтып керсә керә, кермәсә юк. Хәер, аның кайтып кермәве яхшырак та.

Актай керә, тамак кыра.

Актай. Кызым, исәнме
Энҗе бикә. Әти! Әтием! Нинди акыллы син — кирәк чакта гына килдең дә кердең!
Актай. Әти кешеләр кирәк чакта гына акыллы булалар да, кызым.
Энҗе бикә. Бүген иртәдән бирле мин сине уйладым, әти.

Актай. Минем сине исемнән чыгарганым да юк, кызым!
Энҗе бикә. Минем сиңа гына әйтәсе сүзләрем бар, әти.
Актай. Минем дә сиңа гына әйтәсе сүзләрем бар, кызым.
Энҗе бикә. Башта син сөйлә, әти.
Актай. Кияү кайтмадымыни? Бүген ул атасы хан янында булды.
Энҗе бикә. Беләм, әти.
Актай. Синең, кызым, дөньяда белмәгән нәрсәң юк икән. Сабыр ит, белмәгәнеңне дә ишетерсең.
Энҗе бикә. Сөйлә әти, сөйлә.
Актай. Менә шул, кызым, хан белән Хаҗи бәк арасында бик каты сөйләшү булды. Бер ел эчендә Гали табылмаса, мин сине үземнең варисым итеп билгеләячәкмен, дигән иде хан үзенең өлкән углына. Хаҗи бәк бүген варислык сорап килде.
Энҗе бикә. Шуннан, шуннан, әти?
Актай. Хан һаман Галине таптыра.
Энҗе бикә. Үле Галинеме?! Акылдан шашканмы әллә ул?
Актай. Юк, кызым, хан акылдан шашмаган, ханның күзе ачыла башлаган. Хаҗи бәк артыгын кылана, тупас, кансыз. Ул инде күптән үзен варис итеп, хәтта... хан итеп тота!
Энҗе бикә. Кызык. Киявең турында син элегрәк бер дә андый сүзләр әйтми идең.
Актай. Астыңа су йөгерсә, әллә ниләр әйтерсең, кызым!
Энҗе бикә. Шулай укмыни, әти? Күңелсез сүзләрне әллә бүгенгә сөйләшмибезме?
Актай. Юк, кызым, бүген башлаган сүземне мин иртәгәгә калдырырга күнекмәгән. Хаҗи бәкне хан үзенең варисы итмәячәк. Менә шул минем сүзем.
Энҗе бикә. Менә ни өчен эчем пошкан икән көне буена! Хаҗи бәк хан була алмаса, мин кем генә булырмын икән соң? Үз киявеңне тәхеткә дә утырта алмагач, ник бирдең соң мине аңа?
Актай. Кияүгә бирү-бирмәү, кызым, кайчагында, бирүгә карамый, бирелүгә дә карый. Тора-бара син миңа: ник мин хан кызы булмаганмын, дия башларсың!
Энҗе бикә. Шулай да... Хан әллә мәңге яшәмәкче була?
Актай. Тәүгилде яклылар Фатыйма бикәнең Алтынташ углын варис итәргә кирәк, дип сөйләнәләр.
Энҗе бикә. Хан кинәт үлеп-нитеп китсә, шул тиле-миле дигәндәй... шул җебегән Алтынташ тәхеткә утырырмы? Ул чагында без: син, мин, Хаҗи бәк... Фатыйма бикәнең табанын яларбызмы?
Актай. Ул чагында безгә кем табанын яларга туры килер — анысын әлегә әйтеп булмый. Әлегә шуны гына әйтергә була, ул чагында беркем дә безнең табаныбызны яламаячак, кызым.
Энҗе бикә. Андый эш беркайчан да булмас!
Актай. Алай җиңел уйлама, сәвекле кызым Энҗе бикә. Язмышның төбе — мәкер. Бер көнне ул сине күккә чөя, икенче көнне аяк астына салып таптый. Кешеләр ханнан җылырак урын, майлырак калҗа эләктерү өчен бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер торалар.
Энҗе бикә. Фатыйма бикә углы турында хан үзе нәрсә уйлый икән?
Актай. Хан Галине таптыра. Үлеме, тереме — Галине табып китерегез, ди, шунсыз мин аның үлеменә дә, гаепле булуына да ышанмаячакмын, ди. Миннән соң Болгар тәхетенә утыру өчен аннан да төплерәк беркемне дә күрмим, ди.
Энҗе бикә. Нишләп ул аны элегрәк — Гали исән чакта әйтмәде икән соң?
Актай. Менә анысын сорарга башыма килмәгән, кызым! Хан әйтеп бирмәсә дә, Галинең нинди ир икәнлеген син үзең дә белергә тиеш идең.
Энҗе бикә. Син ялгышасың, әтием: мин аның кемлеген бик яхшы белдем. Ләкин ул чагында хан Галине түгел, Хаҗи бәкне якынрак күрде түгелме соң? Тәхеткә бернинди хокукы булмаган, үлгәнче «кара» дип йөртелгән надан анадан туган Галине син үзең дә бик үк мактамый идең. Нишләп алай фикерең үзгәрде?
Актай. Минекен генә түгел, бик күпләрнең фикерен үзгәртте Гали углан. Буш вакытын күбрәк каралар белән уздыра торган Галигә баштарак беркем дә ышанып карамады. Инде сугышчы Гали уңда да, сулда да дошманнарны җиңеп кайткач, бик күпләр аның булдыклы ир икәнлеген танырга мәҗбүр булдылар. Күпчелек аның ягына авышты куйды. Синең белән без менә шул үзгәрешне сизми калдык. Әйе, байлыгы аның юк дәрәҗәсендә иде, хан катында да ул түбәнрәк утыра иде. Хан үзе дә, мин дә Болгар йорт өчен, тәхет өчен аның алыштыргысыз кеше булуын бары ул юкка чыккач кына аңлый алдык.
Энҗе бикә. Кирәк чагында үзең аңлый алмаган өчен син мине аңсызлыкта гаепләргә җыенмыйсыңдыр ич, әтием?
Актай. Юк, кызым, мин бары шуны гына әйтмәкче булам: үзең өчен кемнең файдалырак булырын син миннән башка да аңлый алдың. Син бит туганнарның икесен дә «яраттың»! — Гали читтә кан койганда, мыштым гына Хаҗи бәк белән шаярдың.
Энҗе бикә. Җитәр, әти!
Актай. Җитмәс, кызым. Моңарчы әйтмәдем — бүген әйтәм.

Энҗе бикә. Әйт, әйт — барысын да әйт!

Актай. Әлегә барысын да әйтмәм, шулай да бер нәрсәне әйтми булдыра алмыйм: ханга гына түгел, безгә дә Гали кирәк!

Энҗе бикә. Болай булгач, син — минем туган атам, хан алдында Хаҗи бәкне якламаячаксыңмыни?

Актай. Мин алай димәдем.

Энҗе бикә. Син әле генә мине тотнаксызлыкта, хыянәттә гаепләдең. Син үзең дә шундыйрак түгелме соң, атам?

Актай. Ярый әле, кызым, исемә төшердең — минем сиңа бик тә яшерен сүзем бар икән. *(Як-ягына карана.)*

Энҗе бикә. Куркытырмын дип уйлама, эти. Хаҗи бәк турында, Гали турында нәрсә генә әйтсәң дә, минем инде әз генә дә исем китми. Хаҗи бәк, бернәрсәгә карамыйча варис булырга, тәхетне яулап алырга тиеш. Син аңа булышачаксың, эти! Син баш тартсаң, мин үзем тотыначакмын!

Актай. Синең булдыклы бала булуыңа мин шикләнмим, кызым. Шулай да исеңнән чыгарма: хан инде карт, килененең серле елмаюларына гына эреп төшмәячәк. Шуны да борыныңа киртеп куй: Хаҗи бәккә җиңү яуласаң, син үзеңә баз казыячаксың.

Энҗе бикә. Кызык.

Актай. Иң кызыгы шул, кызым: Хаҗи бәк белән син менә бер ел торасың, шулай да синең балаң юк.

Энҗе бикә. Әти, кагылма минем авырткан җиремә!

Актай. Синең авырткан җирең — минем дә авырткан җирем.

Энҗе бикә. Күренмәгән имчем калмады. Барысы да: булыр, диләр, тагын бер-ике ел көтәргә кушалар.

Актай. Без бер ел да, ике ел да көтәрбез, тик Хаҗи бәк кенә көтәргә теләми.

Энҗе бикә. Тагын Хаҗи бәк!

Актай. Хаҗи бәк булмыйча, кем булсын? Ул синең балаң юклыгына пошына.

Энҗе бикә *(үртәлеп)*. Әти, казынма минем күңелемдә! Әйтәсе сүзеңне әйт тә...

Актай. Әйтер сүзем шул: синең ирең Хаҗи бәк Тәүгилделәр белән астыртын эш йөртә.

Энҗе бикә. Юк! Тәүгилде тархан Хаҗи бәкнең явыз дошманы. Син үзең әле генә әйттең: Тәүгилде яклылар Фатыйма бикәнең Алтынташ углын варис итмәкче булалар, дидең.

Актай. Әйттем, кызым. Тик мин сиңа Тәүгилде тарханның Көнсылу атлы гүзәл кызы барлыгын әйтмәдем бугай?

Энҗе бикә. Көнсылу?!

Актай. Көнсылу, кызым, Көнсылу. Яшьрәк тә, чибәррәк тә.

Энҗе бикә *(җылау катыш)*. Әти!

Актай *(тыңламыйча)*. Синең ирең Хаҗи бәк, менә шул гүзәл Көнсылуга өйләнеп, берьюлы ике куян атмак була. Хаҗи бәк Тәүгилде тархан кияве була калса, ул чакта Алтынташ турында беркем авыз ачмаячак. Әйе, кызым, Хаҗи бәк Болгар тәхетенә утырса, ул чагында синең дә, минем дә кояшыбыз сүнәчәк. Син сөйкемсез икенче хатынга әйләнерсең, минем урынга баш карачы булып Тәүгилде тархан менеп утырыр.

Энҗе бикә. Рәхмәт, эти, үтердең! Мин инде күптән сизенәм аны. *(Җылый.)* Менә ни өчен эчем пошкан икән көне буена!

Актай. Шулай итеп, коткарса безне Гали генә коткарачак.

Энҗе бикә. Кайда соң ул, кайда? Үлеме, тереме?

Күгеш керә, тамак кыра.

Актай *(Күгешне күреп)*. Кем кирәк, ни булды, Күгеш?

Күгеш. Бикәне күрергә телиләр.

Энҗе бикә. Кемнәр?

Күгеш. Караларның, качакларның барысын да кайтарып җибәрдем. Берсе — Үргәнеч качагы...

Энҗе бикә. Качакларны күрергә теләмим, дип әйттем түгелме соң мин сиңа?!

Күгеш. Ул качакның сиңа гына әйтәсе сүзе бар, имеш. Куанычлы сүз, ди.

Актай. Керсен.

Күгеш *(Энҗе бикәгә)*. Алайса?..

Энҗе бикә. Әйе, «алайса»!

Күгеш чыга, Шәмсетдин керә, Энҗе бикәнең аяк астына егыла.

Шәмсетдин. Илеңез имин улсын, терлек-туарыңыз чук улсын. Мән ярлы качакның үтенеченә колак салып, бер ягы ай, бер ягы кояш тик балкыган гүзәл йөзеңездә күрсәткән чөн, улуг бикә, Аллаһе Тәгалә, бу дөньяда барлык теләкләреңә ирештерсен, теге дөньяда йете кат оҗмах ишекләрен ачып, урыныгызды түрдә әйләсен!

Энҗе бикә. Минем теге дөньядагы урыным турында кайгыртуыңны куеп тор. Сүзеңне кыскарак тот: йомышың ни?

Шәмсетдин. Бик кыска тотсам, аңлашылып йетмәс, дип куркамын. Шул сәбәптин бераз тарих сүзләргә рөхсәт итсәңезче, бикә.

Актай. Тарихыңның баш өлешен мин сөйли алам: син — Үргәнеч качагы. Болгарда казна талап качкан Сәйфетдин углы Шәмсетдин торырсың. Үргәнечтә дә син, атаң сыман, берәрсен талагансыңдыр да качып киткәнсеңдер. Инде менә сыеныр урын эзләп, телеңне бозган булып, яңадан Болгарга кайткансың. Шулаймы, качак Шәмсетдин?

Шәмсетдин *(аягүрә баса, кинәт үзгәреп)*. Яртысы шулай, яртысы шулай түгел, баш карачы Актай! Мин Сәйфетдин казначы углы Шәмсетдин торырмын. Тик мин Үргәнечтән кеше талап качмадым. Анда минем үземне таладылар. Угрылар анда башка. Анда кан-яшь, үлем, Актай!

Энҗе бикә. Миңа әйтәсе куанычлы сүзең шулмы?

Шәмсетдин. Кичер, бикә. Анысына да җитәрмен. Дөрес, мин монда — үземнең туган җиремә сыену урыны эзләп кайттым. Ханның безне ярлыкавын, атам Сәйфетдин казначының ике катлы таш сараен кире үзебезгә бирүен ишеттем дә...

Актай. Син ялган сөйлисең, Шәмсетдин. Атаң-казначының барлык байлыгы — таш, агач өйләре, көтүләре, көтүлекләре, коллары, чуралары — барысы да тартып алынды. Синең агач өең...

Шәмсетдин. Минем агач өйдән җилләр искән, Актай!

Энҗе бикә. Хаҗи бәк аша син шул агач өеңне дауламак буласыңмы?

Шәмсетдин. Юк, бикә, мин атамның ике катлы таш өен кайтарып алмакчы булам!

Актай *(мыскыл белән)*. Ничек итеп?

Шәмсетдин. Мин аны сатып алмакчы булам, баш карачы Актай. Минем ике катлы таш сарайга гына торырлык байлыгым бар.

Актай *(көлеп)*. Әйттем ич кемнедер талап качкан дип!

Шәмсетдин. Мин Болгар ханының Бүләрдән качып киткән кече углы Галинең кайдалыгын беләм. Менә шул минем байлыгым.

Энҗе бикә. Гали дисеңме?!

Актай *(исе китмәгән булып)*. Гали, имеш! Син тагын ялган сүз сөйләргә тотындың, качак Шәмсетдин. Гали углан, атасы ханга каршы эш алып баруда, ханны үтереп, аның урынына тәхеткә утырырга тырышуда гаепләнде. Аның яклылар төнлә Гали өендә кулга алындылар. Барысының да башлары чабылды. Гали углан үзе качты, Чирмешән аша чыкканда, аркасына ук тиеп, суга батып үлде. Аның үлгәнен үз күзләре белән күргән кешеләр бар.

Шәмсетдин. Мин дә аны үз күзләрем белән күрдем... тере килеш.

Энҗе бикә. Тере килеш?!

Шәмсетдин. Тере килеш, бикә. Сез миңа атамның ике катлы таш сараен кире кайтарып алырга булышсагыз...

Актай. Угры Сәйфетдин казначының ике катлы таш сарае, хан боерыгы белән, миңа бирелде.

Шәмсетдин. Ә?! А-а!.. *(Актайның аяк астына егыла.)* Актай, үтермә!

Актай. Шулай, Шәмсетдин, атаңның таш сараен сиңа Энҗе бикәдән дә түгел, Хаҗи бәктән дә түгел,— миннән ялынып сорарга туры киләчәк. Ләкин синең Гали турындагы ялган хәбәрең минем өчен сукыр бер тиен дә тормый.

Энҗе бикә. Әти! Ул дөресен сөйли!

Шәмсетдин. Коръән белән, атам-анам белән, барлык изгеләр белән ант итәм — ялган түгел!

Энҗе бикә түшәмнән асылынып торган бауны тарта. Хезмәтче
хатын керә.

Энҗе бикә. Кара, кадим, кәгазь кертегез.

Хезмәтче хатын чыга. Икенче бер хезмәтче, тәбәнәк өстәлгә куеп, кара, каләм, кәгазь кертә. Актай сүзсез генә кәгазьгә нидер яза. Хезмәтче
өстәлне алып чыга.

Актай *(Шәмсетдингә)*. Менә сиңа язу. Сүзең чын булып чыкса, үзеңнең агач өеңә, каралтыларыңа — юкка чыккан барлык байлыгыңа торырлык җир-су, өй, каралты-кура алырсың.

Шәмсетдин *(язуны ала, укый. Көрсенеп)*. Азрак шул, Актай.

Актай. Атаңның таш сараен оныт. Яңа өй өчен урынны ханбалыкның үзең теләгән төшеннән бирермен. Теләсәң, таш сарай салырсың. Булышырмын. Хәзергә менә шуны алып тор. *(Куеныннан акча тулы янчык алып бирә.)*

Шәмсетдин *(янчыкны ала)*. Бай бул, Актай! Болай булгач, әйтәм. Болгар ханының Мәликә хатыннан туган кече углы Гали углан кыпчакларның Бурлы ыруында, Ураз бәк урдасында булыр. Мин аны

шунда күрдем. Минем тагын ике юлдашым бар, капка төбендә минем чыкканны көтеп торалар. Ышанмасагыз, алардан сорый аласыз.

Энҗе бикә. Йа Алла, Гали исән! Гали исән!

Шәмсетдин. Исән, бикә, исән! Мин сезнең бер-берегезне үлеп яратуыгызны белдем. Белмичә, бөтен ханбалык сөйли. Шуңа да куанычлы хәбәремне иң элек сиңа әйтмәкче булдым. Менә ул бәхет, Шәмсетдин! *(Кулындагы акчалы янчыкны югары чөя.)* Чирмешән яры буена атам нигезенә яңәшә яңа сарай салдырам. Җир астыннан су кертәм. Таш мунча салам, бакча үстерәм. Берәр яшь, чибәр кызга өйләнеп җибәрәм. Баш исән булсын, Шәмсетдин, баш!

Актай бауны тарта, Күгеш керә.

Актай *(Күгешкә)*. Сакчылар керсен.

Күгеш чыга, коралло сакчылар керә.

Энҗе бикә. Әти, ни булды?

Актай *(сакчыларга Шәмсетдинне күрсәтеп)*. Менә бу кешене хәзер үк зинданга илтеп ябыгыз. Капка төбендә тагын ике йолкыш булыр — аларын да шунда озатыгыз. Бу — бикәнең боерыгы.

Энҗе бикә *(Актайга карый, икеләнеп)*. Әйе... минем дә боерык. Әти!

Шәмсетдин. Ә?! Э-э...

Бер сакчы *(бикәгә баш иеп)*. Баш өсте, бикә.

Актай. Зиндан башлыгына әйтегез: минем яисә бикәнең боерыгыннан башка беркая чыгармаска, беркемне янына җибәрмәскә. Теге икене бергә япсалар да ярый.

Шәмсетдин. Э-е... Бу ни бу?! Син мине алдадың. Мин кычкырам!

Актай. Башың исән калуын теләсәң, кычкырмассың.

Шәмсетдин. Сез мине алдадыгыз. Сез — ялганчылар.

Актай *(сакчыларга)*. Тагын берәр сүз әйтсә, авызын томалагыз.

Сакчылар Шәмсетдинне алып чыгып китәләр. Күгеш керә.

Күгеш. Хан сараеннан кеше килгән.

Актай. Керсен.

Күгеш чыга, хан кешесе керә.

Хан кешесе. Актай, мин сине алырга килдем. Хан сине тиз арада үз янына чакыра.

Актай *(каушап)*. Ни булды? Ханның хәле начарландымы әллә?

Хан кешесе. Ханның түгел, Болгарның хәле начар. Яңа хәбәр алынды: Җаек буена магуллар басып кергәннәр. Болгарга яу килә, Актай!

Энҗе бикә

Актай

Хан кешесе. Хаҗи бәккә дә хан сараена килергә боерык бар.

Энҗе бикә. Ул өйдә юк. Хәзер чакыртып кеше җибәрәм. Яу килә! Шул гына калган иде. Менә ни өчен эчем пошкан икән көне буена!

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Кыпчак даласы. Бурлы ыруында Галинең ярлы өе. Төн. Уртада сүнәр-сүнмәс учак яна. Учак тирәсендә түгәрәкләнеп дүрт кеше утырган. Берсе — Гали, калганнары — Болгар илчеләре. Бер-берсенә якын килеп, алар үзара яшерен сүз алып баралар.

Ярмыш. Бөтен Бүләр корт күчедәй мыжгып тора, Гали! Чыңгыз ханның Җаек буена басып керүе бик күпләрнең йокысын ачты. Ар, чирмеш, мукшы, башкырт якларыннан ханбалыкка коралло көчләр килә. Көч күп, ләкин... таркау.

Гали. Ах, шул таркаулык! Болгарны какшаткан, агач корты кебек туктаусыз кимергән нәрсә — һәрвакыт шул таркаулык булды!

Ярмыш. Атаң картайды. Дәүләт эшләре белән бөтенләй диярлек кызыксынмый. Бар эшне Хаҗи бәк үз кулына алды.

Гали. Тәүгилде тархан кем яклы? Җукәтау Ибраһим кем яклы?

Ярмыш. Тәүгилде тархан Хаҗи бәк белән тартышырга чамалый. Җукәтау Ибраһим, беркемгә катышмыйча, үзенә аерым көч туплый.

Гали. Гаскәр башы кем?

Ярмыш. Әйтеп торам лабаса — таркаулык! Гаскәр башы юк. Билгеләнмәгән.

Гали. Ах, Болгар! Ах, ятим, бичара Болгар! Беләм, аңлыйм. Ерактан ук барысын да күреп торам! Берәүләр чын күңелдән янып йөри, икенче берәүләр, ыгы-зыгыдан файдаланып, үз ишләрен җайларга маташа. Шушы көнгә тикле гаскәр башы билгеләнмәгән! Атам нәрсә уйлый, Ярмыш? Кемгә таянмакчы була?

Ярмыш. Хан кемгә таянырга да белми. Ул сине көтә, Гали!

Гали *(аягүрә баса)*. Мине көтә? Ник? Башымны чаптырыргамы?

Ярмыш. Ул сине гаепле дип уйламый, Гали.

Гали *(тынычлыгын җуеп)*. Шулай ук микән? Әгәр ул мине гаепсез дип уйлаган булса, минем яклы кешеләрнең башын чаптырмаган булыр иде!

Ярмыш *(аягүрә баса, башкалар да торалар)*. Боларның барысы да — агаң Хаҗи бәк эше, Гали.

Гали. Хаҗи бәк... Таркаулыкның башы — Хаҗи бәктә. Күп нәрсәне ул аңлый алмый. Хан булу белән ул барлык теләкләремә ирешермен, барлык дошманнарны җиңәрмен дип уйлый. Халык белән, гаскәр белән түгел, берүзем җиңәрмен дип уйлый!

Ярмыш. Шуңа күрә дә аны халык яратмый, гаскәр яратмый.

Гали *(йөренә)*. Ярмыш! Болгарлар! Без барыбыз да чиктән тыш хәтәр көннәрдә яшибез. Магуллар без белгән башка бер дошманга да охшамаган. Әгәр дә мәгәр Чыңгыз хан чирүләре Идел-Чулман буйларына килеп җитә калсалар, Хәрәзем шәһәрләре кебек, безнең шәһәрләрне дә җир белән тигезләячәкләр, безнең халыкны да чебен урынына кырачаклар. Изге йортыбызны, туган халкыбызны саклап калу өчен безгә кичекмәстән берләшергә кирәк! Аңлыйсыңмы, Ярмыш?! Аңлыйсызмы, болгарлар?! Берләшергә кирәк. Болгарның үз ырулары гына түгел, күршеләр белән дә — кыпчаклар белән, урыслар, төн халыклары белән берләшергә кирәк!

Ярмыш. Сүзләрең алтын, Гали!

Илчеләр. Дөрес, Гали!

Ярмыш. Актай да, Энҗе бикә дә шундый ук фикердә.

Гали *(йөрүеннән туктап)*. Энҗе бикә?! Ул инде «бикә»мени?

Ярмыш. Ул сине дүрт күз белән көтә, Гали!

Гали. Энҗе бикә... Хаҗи бәк хатыны! Ә мин аны һаман элеккечә дип хыялланам!

Ярмыш. Гали, мин сиңа ялганлый алмыйм. Сиңа яла ягу да, синең өеңә басып керү дә — барысында да Хаҗи бәк кулы уйнаганын син инде аңлыйсыңдыр. Хаҗи бәк сиңа тиешле тәхетне генә түгел, Энҗене дә тартып алмакчы булган.

Гали. Һәм ул аны алган да! *(Туктый, кискен үзгәреш белән.)* Шулай булгач... туктале, шулай булгач... мин кем янына кайтырмын соң?

Ярмыш. Туп-туры Энҗе белән Актай янына! Хан белән очрашуны-көрәшүне — барысын да Актай үзе җайлаячак. Синең кайтуыңны ишетү белән, бөтен ханбалык синең якка чыгачак, Гали! Барлык гаскәрне, бернинди икеләнүсез атаң синең кулга тапшырачак, Гали!

Гали *(үзалдына сөйләнгән сыман, әкрен, тантаналы)*.

Болгар миңа кирәк, мин — Болгарга.
(Ана белән бала кебек без.)
Тагын кемгә кирәк Гали? Ханга?
Агам Хаҗи бәккәме соң әллә?!

Туктый, дәһшәтле итеп.

Кем җибәрде сезне минем янга?
Яшермичә әйтеп бирегез!

Ярмыш. Син безгә ышанмыйсыңмыни, Гали?! Актайның, Энҗенең йөзек тамгасы сугылган менә бу битеккә ышанмыйсыңмыни?! *(Кулындагы битекне селкеп күрсәтә.)*

Гали *(төшенке)*. Юк, ышанмыйм.

Ярмыш *(хәтере калып)*. Мин сине сугышчы вә шагыйрь дип белә идем. Син монда икенче кешегә әйләнгәнсең, Гали. Хуш, без киттек! *(Ишеккә юнәлә.)*

Башка илчеләр дә кузгалалар.

Гали *(беравык артларыннан карап тора, икеләнүен җиңеп, газаплы)*. Туктагыз. Монда мин, әйе, икенче кешегә — Шәмсетдингә әйләнә башлаганмын бугай... үз башымны бар нәрсәдән кадерлерәк күрә башлаганмын бугай...

Ярмыш *(кире борылып)*. Гали!

Гали. Мин китәм сезнең белән. Үзем кайтам. Ни генә булмасын, мин Болгарга — атам янына, халкым янына кайтырга тиешмен!

Ярмыш *(Галине кочаклый)*. Гали!

Илчеләр.

— Тиздән төн уртасы җитә!

— Таң атканчы безгә Бурлы ыруыннан чыгып китәргә кирәк.

Гали. Мин әзер. Минем үзем белән аласы бер генә әйберем бар, ул да булса — кыйсса китабым! *(Төргәкләр арасыннан китабын актарып ала. Учакка бер күз ташлый да ишеккә юнәлә.)* Әйдәгез, кузгалыйк!

Ярмыш. Хәерле сәгатьтә!

Тышта ниндидер кыштырдау ишетелә. Барысы да тынып калалар.

Гали *(ишек янына ук килеп)*. Кем бар анда?

Кинәт ишек ачылып китә. Өй эченә берьюлы дүрт-биш кораллы ир килеп керә. Иң алда Инәл кам. Кулында артыш таягы. Гали артка
чигенә.

Инәл кам. Менә каптың, кол Гали! Инде ычкына алмассың. Мин сине көн-төн күзәттем. Менә өстеңә бастым — хәзер инде сине беркем дә коткара алмас. *(Илчеләргә.)* Кузгалмаска! Коралларыгызны салырга!

Гали. Бу ни эш бу, изге кам? Болар минем кунакларым.

Инәл кам. Колның кунагы булмый! *(Галигә таягы белән кизәнә.)*

Гали. Юк, изге кам, колның да кунагы була! *(Инәл камның югары күтәрелгән кулын тотып ала, каера. Камның таягы төшеп китә, кам егыла.)*

Инәл кам. А-а-ы-ы!..

Кораллы ирләр ярдәмгә ташланалар, болгарлар коралларына тотыналар.

Гали *(болгарларга, тыныч)*. Ярамый. Коралларыгызны ташлагыз! *(Инәл камга.)* Тор, изге кам. Моннан соң коллар белән ягымлырак сөйләшергә тырыш.

Инәл кам тора, таягын ала. Болгарлар коралларын ташлыйлар.

Инәл кам *(ярсуына буылып)*. Туктале, моның өчен мин сине!..

Гали *(кораллы ирләргә)*. Без буйсынабыз. Илтегез безне бәк янына.

Кораллы ирләр Галине, болгарларны алып чыгалар.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ураз бәк өе. Түрдә — Ураз бәк, аның янында бикә, Аксакаллар,
Инәл кам, Гали һәм болгар илчеләре.

Ураз бәк *(Галигә)*. Шулай итеп, болар синең кунакларың булып чыга инде?

Гали. Әйе, бәк, минем кунакларым.

Ураз бәк. Каян килгәннәр, нишләп йөриләр алар минем җиремдә?

Гали. Болар — болгарлар. Адашканнар.

Ураз бәк. Таллыкта яшеренеп яткан иллеләп кеше дә адашканмы?

Ярмыш. Без барыбыз да адаштык, бәк. Ут күрдек тә, кемнәр икән, дип, җәяүләп кенә килдек.

Ураз бәк. Кемнәр сез, кая юл тотасыз?

Ярмыш. Хан йомышы белән без Кырым ягына юл тотабыз.

Ураз бәк. Нишләп юлыгыз турыдан түгел, кыектан китте?

Гали *(дулкынланып)*. Ураз бәк! Мин — синең колың. Мин сиңа беркайчан да ялган сөйләмәдем. Хәзер дә мин сиңа бары дөресен генә сөйләргә телим.

Ураз бәк. Тыңлыйм — сөйлә, кол.

Гали. Болар — чыннан да минем кунакларым! Көтелмәгән кунакларым. Алар ханбалыктан — Бүләрдән килгәннәр. Алар мине... эзләп килгәннәр, бәк!

Ураз бәк. Эзләгәннәр, тапканнар, урлап китмәк булганнар. Минем колымны. Син миңа агаң белән ызгышуың турында әйткән идең. Агаң синең үлгән, яки үтергәннәр, йә ул синең белән татулашырга тели. Бүләрдә сине байлык көтә, карт анаң, хатының, балаларың көтә. Шулай булмаса, шултикле җирдән сине эзләп килмәгән булырлар иде.

Гали. Мине Бүләрдә карт анам да, хатыным, балаларым да көтми, байлык та көтми. Анда нәрсә көткәнен мин әлегә үзем дә белмим, ханбалыкта мине йә балта, йә... тәхет көтә, бәк.

Ураз бәк. Йә балта, йә тәхет?!

Гали. Болгар тәхете көтә, ханлык көтә, Ураз бәк!

Ураз бәк, таңга калып, аягүрә баса. Башкалар да аягүрә басалар. Бары
Инәл кам гына урынында утырып кала.

Инәл кам. Алданма, Ураз бәк! Үлемнән котылмак булып, ялган сөйли оятсыз колың!

Ураз бәк. Ялган түгел, изге кам Җаекның уң ягыннан кыпчакларны кысрыклап чыгарган Гали углан турында далада белмәгән-ишетмәгән кеше юк.

Гали. Дөрес, син ишетеп белгән Гали углан мин булам, Ураз бәк. Инде яшеренеп торуның кирәге калмады Болгарга, Кыпчак далаларына куркыныч килә. Дусларым, якыннарым мине ханбалыкка чакыралар. Ирек бир миңа, Ураз бәк!

Ураз бәк үз урынына утыра, башкалар да утыралар.

Ураз бәк *(яңадан коры, рәсми кыяфәткә керә)*. Һы, ирек... Син, тәхеткә утырасы кеше, колга ирекнең алай җиңел генә бирелмәгәнен беләсең булыр. Болгар бай, көчле. Аның җир-суы иксез-чиксез. Сине тәхеткә утыртырга җыенган дусларың, шундый ерак җирдән килгәннәр икән, буш кул белән генә килмәгәннәрдер. Шулай ук алар сине, хан буласы кешене, бик аз бәягә бәяләргә дә җыенмыйлардыр.

Ярмыш. Без аны коллыкта дип белмәдек, бәк.

Ураз бәк. Шулай да сез аның кайдалыгын белгәнсез!

Гали *(тынычсыз)*. Әйт, Ураз бәк, күпме сорыйсың?

Ураз бәк. Синең өчен мин алтын белән... бер мең сорыйм, кол Гали.

Ярмыш. Бер мең?!

Илчеләр.

— Күп, бик күп!

— Бездә андый акча юк!

Гали *(үзалдына)*. Менә нинди кыйбат синең башың, Гали!

Ураз бәк *(илчеләргә)*. Чыгарыгыз акча янчыкларыгызны!

Илчеләр теләр-теләмәс кенә куеннарына тыгылалар, акча янчыкларын чыгарып, Ураз бәккә бирәләр.

Ярмыш. Менә йөз сум.

Илчеләр.

— Минеке кырык сумга өч тиен тулмаган булыр.

— Барысы шунда.

Ураз бәк *(янчыкларның авырлыгын чамалап карый)*. Аз. Бу җитми. Сине шушы ике йөз сум чамасы акчага биреп җибәрсәм, бу синең өчен бик зур түбәнлек булачак, Гали углан!

Ярмыш. Минем сиңа бер киңәшем бар, Ураз бәк. Син безнең берәребезне тотык[1] итеп алып каласың, бер-ике айдан без сиңа...

Ураз бәк. Миңа чылтырап торган мең акча кирәк. Кая ул акча? Мәгез теләнче тиеннәрегезне! *(Ачу белән янчыкларны хуҗаларына ыргыта.)*

Авыр тынлык.

Гали. Ураз бәк! Син сораган акча булыр. Тулысынча булыр! Тик акчаны түләр алдыннан минем сиңа бер шартым бар. Тыңлыйсыңмы?

Ураз бәк. Тура[2] буенча, син — минем колым. Сату-алу йоласы буенча, син миңа бернинди шарт куя алмыйсың. Шулай да мин сине тыңлыйм, Гали углан.

Гали. Мең алтын акча түләнгәч, Болгарга озатып кую өчен миңа син мең кешелек чиру бирерсең.

Ярмыш сискәнеп китә, искәрмәстән: «Мең кешелек чиру!» — дип ычкындыра, башка илчеләрнең колаклары үрә тора. Аксакаллар, үзара пышылдашып, ымлашып алалар. Ураз бәк, дәрәҗәсен саклап, тып-тын утыра. Барысы да аның авызына карап калалар.

Ураз бәк *(әкрен, уйланып)*. Шартың авыр, Гали. Шартың... урынлы, Гали! Сине озатып кую өчен мең кешелек чиру бирермен. Тик син миңа акчаңны чыгарып салмадың әле? Миңа акча кирәк, Гали!

Гали. Ураз бәк! Кичә таңда синең урдаңа Тукаш атлы сәүдәгәр туктады. Ул Болгарга юл тота булыр. Чакыр аны монда.

Ураз бәк. Ярар, карап карыйк. *(Ишек ягына кычкыра.)* Әйтегез, Тукаш сәүдәгәр керсен!

Тукаш керә.

Тукаш *(Ураз бәккә баш ия)*. Олуг Тәңре илеңә-көнеңә — иминлек, үзеңә байлык бирсен, бәк.

Ураз бәк. Шулай булсын, Тукаш. Минем сиңа сүзем бар.

Тукаш. Сүзеңне тыңлыйм, бәк.

Ураз бәк. Син, Тукаш сәүдәгәр, каян кая юл тотасың? Байлыгың ни, күпме?

Тукаш. Мин Бөек Болгар йортының ханбалыгы изге Бүләргә юл тотам, бәк. Мин күп илләрдә булдым: Мисырда, Румда, Кырымда... Юлым уңмады, дип әйтә алмыйм. Тик менә дөньялар бозылып тора. Син миннән бурычка тавар алмакчы буласыңмы?

Ураз бәк. Миңа тавар түгел, акча кирәк, Тукаш. *(Галигә күрсәтеп.)* Менә бу минем колым торыр. Ул синең белән сөйләшмәк була. Сөйләш аның белән.

Тукаш *(Гали ягына борыла)*. Тыңлыйм. Сөйләп кара сүзеңне, кол.

Гали. Тукаш! Күзеңне ачыбрак карале — каршыңда кем тора?

Тукаш *(җентеклəп карый)*. Кем дип əйтим?.. Кара, Гали углан түгелме соң? Булмас!

Гали. Булган инде, Тукаш! Син ялгышмадың, мин — элекке Гали углан. Хəзер мин — кол. Тукаш! Коллык богавымны өзеп, мин Болгарга кайтырга тиешмен. Ураз бəк минем өчен мең алтын сорый. Ишетəсеңме, мең алтын! Бир син аңа мең алтынны — мин сиңа үземне үзем сатам, Тукаш!

Тынлык.

Тукаш *(каушап)*. Ни сөйлисең, Гали?! Көлəргə җыенасызмы əллə миннəн?

Гали. Язмыш миннəн көлə, Тукаш! Əйт, күпмегə бəялисең минем башны?

Тукаш. Туктагыз əле, нишлəп болай соң əле бу?

Гали. Кабатлап əйтəм: Ураз бəк минем баш өчен мең акча сорый. Алтын белəн.

Ураз бəк. Əйе, алтын белəн. Мең акча.

Тукаш эндəшми.

Гали. Ник тынып калдың, Тукаш? Мең алтынга тормас дип уйлыйсыңмыни? Атам кулына тапшырсаң, ул сиңа ике меңне бирер, Тукаш! Бүлəргə генə алып кайт мине. Болгарга! Яу килə, яу! Ашыгырга кирəк, Тукаш! Ник дəшмисең, кансыз сəүдəгəр?!

Тукаш. Мин синең нинди язмыш аркасында бу хəлгə төшүеңне белмим, Гали углан. Төпченеп тə тормыйм. Сине бу коллыктан йолып алу минем өчен зур бəхет булачак...

Гали. А-а, Тəңрем!

Тукаш *(куеныннан бер-бер артлы ике акча янчыгы чыгара, берəм-берəм Ураз бəккə бирə)*. Менə сиңа биш йөз, менə сиңа биш йөз, Ураз бəк. Алтын белəн. *(Галигə.)* Син, кол Гали, моннан соң ирекле!

Гали. Ирекле?! Тукаш, əйт тагын!

Тукаш. Миннəн ирек сиңа, Гали.

Гали *(Тукашны кочып ала, күз яшьлəре белəн)*. Тукаш! Коткаручым!

Тукаш. Мин — сəүдəгəр. Мин тире-яры, күн белəн, кием-салым, бал, корал белəн сату итəм. Белем күп җирлəрдəн мин Болгарга гыйлем китаплары алып кайтам, белем аз җирлəргə Болгарның үзеннəн алып китəм. Лəкин минем беркайчан да кеше башы белəн — кол галимнəр, кол шагыйрьлəр башы белəн сату иткəнем юк. Кеше белəн сату итү минем барлык уй-телəклəремə каршы килə. Болгарның олуг бер шагыйрен, алып ирен шундый хурлыктан коткаруны Аллаһе Тəгалə изге эшем итеп кабул итсə, миңа шул җиткəн. Мин, Гали углан, синнəн бурыч язуы алып тормыйм. Мин синең сүзлəреңə ышанам — Бүлəргə кайткач, син бурычыңны миңа ике мең итеп түлəрсең.

Гали. Ике мең итеп түлəрмен, Тукаш. Менə болар — болгар таныклары. Алар безнең килешүне раслаудан баш тартмаслар.

Ярмыш. Баш тартмабыз, Гали углан.

Ураз бəк *(акчаларның авырлыгын чамалый, янчыкларны чишеп-чишеп карый. Ярмышка, Галигə эндəшеп)*. Безнең сату-алу эше шуның белəн төгəнде. Хəзер сез барыгыз да — минем кунакларым. Хəзер олы туй ясыйбыз. *(Ишек ягына кычкыра.)* Əйтегез, кызым Чəчəк керсен!

Чəчəк керə, атасы-анасы каршына килə, кулларын кушырып, тезлəнгəндəй итə.

Чəчəк. Ни сүзең бар, атам?

Ураз бəк. Теге көнне син, кызым, минем алда, анаң белəн аксакаллар алдында Галине яратуың турында əйтеп, безне таң калдырган идең. Мин баштагы уемнан кире кайттым: мин сине Инəл камга бирмəскə булдым.

Инəл кам. Бəк! Миңа биргəн сүзеңне бозсаң, тамырың корыр!

Ураз бəк *(камны тыңламыйча)*. Мин сине Гали угланга бирергə булдым, кызым.

Аксакаллар аптырашта. Инəл кам урынга егыла.

Бикə. Минем белəн киңəшү юк, сөйлəшү юк!

Чəчəк. Бай бул, атам!

Ураз бəк *(Галигə)*. Гали углан, минем белəн туганлашуга син каршы түгелсеңдер ич?

Гали. Каршы түгел, Ураз бəк!

Чəчəк. Гали! Өнемме, төшемме?! *(Галинең күкрəгенə каплана.)*

Гали.

Язмыш мине кызганмады — утка салды.
Яндым-көйдем. Миннəн бары тузан калды.
Мин терелдем! — Язмыш көлде, суга салды.
Утта янмас, суда батмас мин, Чəчəгем!
Менə безгə елмайды ул — кавыштырды!
Кайгыбызны сəвенечкə алыштырды!

Рәхмәт аңа — икебезне табыштырды.
Өнме, төшме — үзем дә белмим, Чәчәгем!

Ишектән сакчы керә, ашыгып, Ураз бәк янына килә, нидер әйтә. Ураз бәк үзгәреп китә, сакчыга нидер әйтә, сакчы ашыгып ишеккә юнәлә. Тыны бетеп улагчы, ягъни ашыгыч хәбәр китерүче килеп керә. Ураз бәкнең аяк астына егыла.

Улагчы. Бәк! Аксакаллар! Кунаклар! Яу килә! Көнчыгыштан көткән яу көнбатыштан килә. Магуллар, Болгар диңгезе[1] артыннан үтеп, Каф-тау аша Кыпчак далаларына үтеп керделәр. Кыпчакларның урыслар белән берләшкән көчләре Калка суы буенда тар-мар ителде. Дошманның Җебе, Субутай атлы батырлары күп көч белән Иделгә якынлашып киләләр.

Гомуми каушау, ыгы-зыгы.

Ярмыш *(Ураз бәккә)*. Без хәзер үк юлга чыгабыз, бәк. Безнең кулга алынган кешеләрне, атларны кире кайтарып бирүеңне үтенәм.

Ураз бәк *(бик нык каушаган, куркынган)*. Нәрсә ул сезнең атлар, кешеләр! Сез китәрсез дә котылырсыз. Ялан-япа далада ун мең, йөз мең атлар, кешеләр белән, көтүләр белән мин нишләрмен?!

Тукаш. Син, Ураз бәк, үз илеңдә. Синең җитәрлек кораллы ирләрең бар. Тавар төялгән дөяләрем белән, утыз-кырык кешем белән шыр далада мин нишләрмен дә, кем канаты астына сыенырмын?!

Ярмыш. Минем сездә эшем юк. Ураз бәк, безне тоткарламавыңны үтенәм. Син, Тукаш, кайгырма. Син — бай. Яу килеп басса, алтын бирерсең дә котылырсың. Биреп котылырга безнең менә берниебез дә юк.

Улагчы. Дошман кылычыннан алтын биреп кенә котылып булмаячак Алар үткән җирдә кеше сөякләре генә өелеп кала, көл-күмер генә кала!

Гали *(тыныч, киеренке)*. Улагчы! Синең кебек коткы таратучыларны мин инде бер тапкыр очраткан идем. Ул чакта мин аларны чак-чак кына кылыч белән чабып ташламадым. Мин сиңа моннан соң беркайчан да андый куркыныч сүзләр сөйләмәскә киңәш итәм. *(Ураз бәккә, аксакалларга.)* Син, Ураз бәк! Сез, аксакаллар! Мине тыңлагыз — безгә хәзер үк сугышка әзерләнергә кирәк!

Ураз бәк. Ничек итеп, Гали? Йөрәгемә капты. Кулларым калтырый. Мин берни дә уйлый алмыйм, Гали.

Инәл кам *(явыз тантана белән)*. Мин ни әйттем сиңа, Ураз бәк? Шул кирәк сиңа, шул! Аха-ха! Тамырың корысын, аха-ха!

Барысы да сәерсенеп, котлары алынып, Инәл камга борылып карыйлар.

Ураз бәк *(тәмам коты алынып)*. Сүзең хак, изге кам.

Гали. Күреп торам, сезнең кулларыгыз калтырый, йөрәкләрегез сикерә. Мин сиңа, Ураз бәк, элегрәк тә сугышка әзерләнергә, башка ырулар белән, Болгар белән берләшергә кирәк дип караган идем. Ул чагында син мине тыңламадың.

Ураз бәк. Гали углан, мин сине тыңлыйм!

Гали *(күтәренкелек белән)*. Ураз бәк! Кыпчаклар! Болгарлар! Моннан соң кыпчаклар белән болгарлар үзара дус-тату булырбыз, дип теләсә нинди дошманга каршы бергәләп сугышырбыз, дип ант эчик!

Ураз бәк. Ант эчик!

Кулларына касәләр, турсыклар тотып, хезмәтчеләр керә. Һәркемгә кымыз агызып бирәләр, һәркем үзенең кымызын беркадәр эчә дә, күршесенә, ягъни болгар — кыпчакка, кыпчак болгарга бирә. Галигә яхшы киемнәр кидерәләр.

Барысы да. Ант! Ант!

Гали. Антыбызны кыпчак йоласы буенча, кылыч белән беркетеп куйыйк. *(Кылыч йөзен үбә.)* Биргән антымны бозсам, бу күк керсен, кызыл чыксын!

Ураз бәк *(кылыч йөзен үбә)*. Биргән антымны бозсам, бу күк керсен, кызыл чыксын!

Гали. Инде барыгыз да минем сүзләрне тыңлагыз. Мин, Гали углан, илгә килгән яу куркынычы алдында бөтен эшне үз кулыма алам. Сез — аксакаллар, син, Ураз бәк, сез — болгар илчеләре, каршы түгелме?

Барысы да. Түгел! Түгел!

Гали. Алайса тыңлагыз... Ураз бәк! Мине озатып куярга тиешле мең кешелек чирүдән тыш, корал тота алган барлык ирләреңне минем карамакка бирәсең.

Ураз бәк. Бирәм, Гали углан! Нәрсә кирәк — барын да бирәм. Менә бер мең алтынны да бирәм! *(Акча янчыкларын Гали алдына ташлый.)*

Гали. Көч сорап, берләшергә өндәп, күрше ыруларга хәзер үк кешеләр җибәрәсең.

Ураз бәк. Җибәрәм, Гали углан!

Гали. Кораллы ирләрдән башка бөтен ыру халкына, терлек-туарларын куалап, киез өйләрен арбаларга төяп, тиз арада төньякка — Болгар ягына күченергә боерасың.

Ураз бәк. Боерам, Гали углан!

Гали. Ныгытылган шәһәрләрдә, авылларда алар болгар туганнары янында сыену урыны табарлар. Яу үткәнче качып калу өчен Болгарда урманнар, тау-ташлар җитәрлек. *(Ярмышка.)* Син, Ярмыш, юлдашларың белән хәзер үк Бүләр ягына юл тотасың. Сәүдәгәр Тукаш та сезнең белән бергә китәр.

Ярмыш. Миңа шундый боерык кына кирәк тә!

Гали. Мин сезгә өстәмә сакчы көч бирермен.

Тукаш. Менә монысы дөрес булыр, Гали углан!

Гали. Мин үзем, Ураз бәк белән берлектә, кул астындагы барлык көчне бергә туплап, дошманның юлына аркылы төшәчәкмен. Идел буенда берәр уңайлы урында яшеренеп, без аңа тозак корырбыз. Шунда без аларны тар-мар итәрбез! Ярмыш! Ханга, Актайга, сезне монда җибәргән башка кешеләргә минем теләкне ирештер: Болгар йортның бусага төбенә килеп җиткән явыз дошманны җиңәргә кирәк, дип уйласалар, миңа булышка иң яхшы чирүләрен җибәрсеннәр. Бу эшкә агам Хаҗи бәк каршы килергә мөмкин. Бу кара көннәрдә, элеккеләрне онытып, мин аңа дуслык, туганлык кулы сузам. Әгәр Хаҗи бәк гаскәр бирүгә каршы килмәсә, мин аны үземнән өстен санап, Болгар тәхетенә варислыктан баш тартачакмын!

Ярмыш. Син әйткәннәрнең барысын да түкми-чәчми җиткерербез, Гали углан.

Илчеләр.

— Тыныч бул, теләгең үтәлер, Гали углан!

— Болгар сине ташламас, Гали углан!

Чәчәк *(чак-чак кына күңелсезләнеп)*. Болай булгач, безнең туй бозылды инде, Гали.

Гали *(Чәчәкне юатып, иркәләп)*. Чәчәгем — сылуым! Туйны без җиңүдән соң ясарбыз, менә дигән иттереп ясарбыз! Хәзер сиңа, Бурлы ыруының барлык хатын-кызлары, бала-чагалары белән Болгар ягына китәргә туры киләчәк. Җиңүдән соң без синең белән Бүләрдә, хан урдасының Олы капуы янында очрашырбыз. Мине шунда көтеп торырсың.

Чәчәк. Мин ул капуның кайда икәнлеген дә белмим ич, Гали!

Гали. Мин сиңа белгән кешеләр бирермен, сылуым. *(Куеныннан язма китап чыгара, Чәчәккә бирә.)* Оныта язганмын! Менә бу минем кыйссам. Мин аны язып бетердем. Син аны сакла... бик сакла! Мин алай-болай булып... үлеп калсам...

Чәчәк. Уеңа да китермә!

Гали. Яңадан күрешә алмасак, бу китапны атама — Болгар ханына тапшыр.

Чәчәк. Мин аны саклармын, Гали. Күз карасы кебек саклармын! *(Кочаклашалар.)*

Пәрдә төшә

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ханбалык. Хаҗи бәк сарае. Бай җиһазлы иркен бүлмә.
Бүлмә уртасында мәрмәр фонтан, кечкенә бассейн. Бассейнның як-ягында озынча утыргычлар. Гүрдә — калку урын. Яхшы келәмнәр, җәнлек тиреләре. Ат, үгез сурәтләре төшерелгән тукымалар. Зур чүлмәкләрдә гөлләр. Стенадагы чөйләргә, болан мөгезләренә сугыш
кораллары элеп куелган.
Сәхнә ачылганда, Энҗе бикә, тәрәзәгә капланып, тышкы якны күзәтә. Янында ике хезмәтче хатын. Шулай ук тәрәзәгә капланганнар.
Урам яктан туктаусыз шау-шу, күңелле гөрелдек ишетелеп тора.
Бераздан борчылган, үртәлгән кыяфәттә Хаҗи бәк килеп керә. Өстендә җиңелчә өй киеме: ефәк халат, ефәк ыштан, билендә гади
билбау, аягында — каюлы йомшак итек. Башы яланбаш.

Хаҗи бәк. Кайтып та җиткәннәрмени, бикә?

Хатын-кызлар кинәт артларына борылып карыйлар. Барысы да көләч. Хаҗи бәкне күрү белән, йөзләре сүрелеп кала. Хезмәтче хатыннар
шыпырт кына чыгып китәләр.

Энҗе бикә *(акламыйча)*. Кемнәр кайтып житкән, Хаҗи?

Хаҗи бәк. Син соң кемне күзәтәсең, бикә?

Энҗе бикә. Урам тулы халык. Барысы да олы капка ягына ашыгалар.

Хаҗи бәк. Синең дә аларга ияәсең килә, ахрысы?

Энҗе бикә. Кайчагында килә, кайчагында минем дә, өстемдәге бай киемнәремне салып ташлап, каралар сыман киндер, тире киемнәргә киенеп, базарда, халык арасында... Чирмешән буйларында йөрисем килә!

Хаҗи бәк. Теләсәң, син бүген үк, хәзер үк китә аласың... җиңүчеләрне каршыларга!

Энҗе бикә. Ник, җиңүчеләрне каршылау миңа тыелганмыни, Хаҗи?

Хаҗи бәк. Алай дип әйтсәм, телем корысын, бикә!

Энҗе бикә. Шулай да синең шулай дип әйтәсең килә, Хаҗи!

Хаҗи бәк. Юк, минем бары: Галине көтәсеңме, Энҗе бикә, дип әйтәсем генә килә.

Энҗе бикә *(үзгәреп)*. Мин тагын сезне татулаштыгыз, дип уйлаган идем.

Хаҗи бәк. Без татулаштык. Ләкин татулашу шатлыгыннан минем йокым качты, җиңү шатлыгыннан йөземне кара кайгы басты.

Энҗе бикә. Нишләп аны элегрәк әйтмәдең? Тәрәзәдән карамаган булыр идем.

Хажи бәк *(кискен, тупас)*. Мин синең атаң — Карт Бүрене көтәм. Бу тирәдә күренмәдеме ул?

Энҗе бикә. Ул синең сарык тиресе ябынган яшь бүре икәнлегеңне сизенгәндер дә килмәскә булгандыр.

Күгеш керә.

Күгеш. Актай килде. Сине сорый, бәк.

Хаҗи бәк. Монда керсен. *(Энже бикәгә.)* Ул әле берни сизенмәгән, бикә. Ул мине һаман да сарык дип уйлый.

Күгеш чыга. Энҗе бикә дә чыгып китмәкче була.

Энҗе бикә. Сезнең үзара чәйнәшүегезне карап торсам, эчем поша башлый.

Хаҗи бәк. Чыкма. Сиңа күңелсез булмасын өчен, бу юлы без өчәүләшеп чәйнәшербез.

Ашыгып, Актай керә.

Актай. Исәнмесез, кияү, кызым! Бөтен ханбалык кырмыска оясыдай мыж килеп тора. Барча кеше урамда: төзәнгәннәр, ясанганнар. Капкаларга байраклар элгәннәр. Җиңүчеләрне сыйларга әле анда, әле монда казаннар асканнар. Олы туй бүген, балалар! Бүләр шәһәрендә мондый куанычны гомеремдә күргәнем юк. Сезнең... ник йөзегез чытык?

Энҗе бикә. Исәнме, эти.

Хаҗи бәк. Исәнме, бабакай. Без әле генә синең кызың белән сугыштык. Яңакка берне шундый иттереп кундырды — күземнән утлар күренде! Үзенә дә берне тондырмакчы булган идем, син килеп кердең.

Актай. Синең, кияү, җиңү көннәрең алда икән әле!

Хаҗи бәк. Минем җиңелгәнем дә юк, бабакай.

Актай. Синең миндә йомышың бар бугай, кияү?

Хаҗи бәк. Йомышым түгел, сүзем бар, бабакай!

Актай *(түрдәге йомшак урынга аякларын бөкләп утыра, дога кыла)*. Болай булгач, дога кылып алыйк, балалар. Зур сөйләшү алдыннан китап дога кылырга куша.

Хаҗи бәк *(көлеп)*. Доганы зур сөйләшүдән соң кылу тагын да яхшырак була торган иде, бабакай. Синең кебек мин качышлы уйнамаячакмын. Бүген мин сиңа турысын ярып салачакмын, бабакай!

Актай. Мин сине кыек яра дип уйламыйм да, кияү.

Хаҗи бәк. Мин зур эшләр кырмакчы булам, бабакай. «Эш кыра» башлаганчы, шулай да синең белән киңәшмәкче булдым. Билгеле, мин синнән башка да «кыра» алган булыр идем. Ни өчен дигәндә, ханбалыктагы чирү минем яклы. Ташкирмәдә, Тубылгытауда, Суарда, Иске Болгарда — якын тирәдәге барлык шәһәрләрдәге кораллы көчләр шулай ук минем яклы. Болгар аксөякләренең күбесе минем яклы. Шулай да, бабакай, синең белән киңәшмичә, мин әлегә кыл да кыймылдата алмыйм. Теләсәк тә, теләмәсәк тә, безнең кендек бергә ябышкан.

Актай. Син, кияү, миңа береккән кендегеңне тартып алмакчы буласың, ахрысы. Ләкин, авыртыр, дип куркып, миннән киңәш сорамакчысың. Синеке авырткач, минеке дә авыртмас микәнни?

Хаҗи бәк. Син минем сүзләремне ялгыш аңладың, бабакай. Бүгенге көндә мин, кендектән бигрәк, баш турында кайгыртам. Бер казанга ике тәкә башы сыймаганын беләсеңдер. Ә без — өч тәкә башы.

Актай. Тәкә башы, кияү, бер генә. Ул да булса — син!

Хаҗи бәк *(көлемсерәп)*. Син, бабакай, Карт Бүре, һаман тешле күренәсең. Шулай да син юкка хәйләләп маташасың. Бүген булмаса, иртәгә үләргә тиешле атам — карт тәкә башын санга тыкмаганда, ике баш кала. Ике баш! Йә ул, йә мин!

Энҗе бикә. Ни сөйлисең, Хаҗи?! Гали синең өлешкә керергә уйламый да!

Хаҗи бәк. Анысы дөрес — Галинең уйларын син миннән яхшырак беләсең.

Энҗе бикә. Юк, Хаҗи бәк, аның уйларын син дә яхшы беләсең! Ул безгә ап-ачык итеп белдерде: мин агамны үземнән өстен саныйм, тәхеттән баш тартам, диде. Галинең сүзләренә ышанганга күрә дә син бернинди каршылыксыз аңа утыз меңлек чирү бирдең. Әллә шулай түгел димәкче буласың?

Хаҗи бәк. Шулай, бикә, барысы да шулай. Алай гына да түгел, әнә ул — Гали углан — мин җибәргән утыз мең болгар белән, биш-алты мең кыпчак белән явыз дошманны җиңеп, ханбалыкка кайтып килә. Бөтен халык Олы капкага Галине каршыларга ашыга. Гали үзе ханбалыкка кайткач шәп итеп туй ясамакчы, ди, Ураз бәкнең кызы Чәчәккә өйләнмәкче, ди.

Энҗе бикә. Нинди Ураз бәк ул тагын?

Хаҗи бәк *(мыскыл белән)*. Нинди Чәчәк ул тагын, диген.

Энҗе бикә *(үртәлеп)*. Син бүген кире ягың белән торгансың, Хаҗи бәк!

Хаҗи бәк. Минем уңай ягым белән торганым да юк, Энҗе бикә.

Энҗе бикә *(үпкәләп, хәтере калып чыгып китмәкче була)*. Миннән башка гына талашыгыз.

Актай. Ашыкма, кызым. Бүген монда Болгар язмышы гына түгел, безнең язмыш та хәл кылына. Син, кияү, турыдан ярыла торган сүзеңне әйтеп бетермәдең.

Хаҗи бәк. Мин аның бераз өлешен әйттем. Гали исән чакта бу дөньяда миңа тынгы булмаячак, бабакай. Мин кем генә булсам да — ханмы, варисмы анда — кайдадыр якында гына Гали барлыгын белә торып, беркайчан да күңел тынычлыгы тапмаячакмын. Мин сездән бернәрсә дә яшермим: мин аннан көнләшәм, мин аннан куркам! Мин аның яхшылыгыннан, батырлыгыннан куркам, аның бөеклегеннән куркам! Бертуктаусыз ул минем канымны агулый, күңелемне ярсыта! Гомер буе шулай газапланып яшәргәме?

Актай. Синең газапланып яшәвеңә Галидән бигрәк син үзең гаепле түгелме, кияү?

Хаҗи бик *(кискен)*. Юк-бар сүзләреңне куеп тор бабакай! Мин Галине юк итәргә тиешмен — менә шул минем туры сүзем.

Актай. Миннән ни сорала?

Хаҗи бәк. Киңәш.

Актай. Минем киңәшнең сиңа инде кирәге калмаган. Шулай да мин сиңа үз фикеремне әйтеп карыйм, кияү. Бу куркыныч, хәтәр көннәрдә күңел газапларыңны бер читкә куеп, ил кайгысын кайгыртсаң, яхшы булмас микән? Бер җиңелү белән генә магулларны кире чигенерләр, дип әйтеп булмый. Яу куркынычы бетмәгән. Мондый чакта Галине юк итү бик зур акылсызлык булачак. Галидән файдалана белергә кирәк. Аның кебек булдыклы, нык куллы ирләр хәзер бу дөньяда бик аз калды. Сиңа ничек тә тәхетне, Болгарны саклау турында уйларга кирәк. Тәхетне яулавы җиңел булыр, саклап кала алырсыңмы, юкмы — анысын бер Ходa белә.

Хаҗи бәк. Анысын мин да беләм, бабакай.

Актай. Шулай булгач?

Хаҗи бәк. Мин синнән бары шуны гына сорамакчымын: Галине ничек юк итәргә?..

Энҗе бикә. Хаҗи, син чынлап та?!

Хаҗи бәк *(тупас)*. Чынлап та, бикә. Юри генә сөйләнәдер бу, дип ялгыша күрмәгез. Мин инде кайбер эшләр эшләдем дә. Чыңгызга каршы көрәштә ярдәм сорап, мин урысларга илче җибәрдем. Аннары мин, бабакай, җиңүчеләргә шәһәр капкаларын ачмаска боердым.

Актай. Шулай укмыни?!

Хаҗи бәк. Шулай ук, бабакай! Мин ханбалыкка Гали яклы кыпчакларның кереп тулуын теләмим.

Актай. Менә монысы ялгыш. Кыпчак — синең кан-кардәшең, кияү!

Хаҗи бәк *(тыңламыйча)*. Аннары мин, бабакай, хан сараен камап алырга боердым. Инде камап та алганнардыр.

Энҗе бикә *(Актайга сыенып)*. Әти! Бу ни бу?! Безне дә.

Актай *(киеренке)*. Тыныч бул, кызым. Ул әле ханбалыкны камап алырга боерык бирмәгәндер.

Хаҗи бәк *(көлемсерәп)*. Шулай, бабакай, син уйлаганча, булдыклы, нык куллы ирләр Болгарда бөтенләй үк бетеп җитмәгәннәр әле.

Актай. Син хаклы, кияү. Ләкин мин ник кирәк сиңа?

Хаҗи бәк. Безнең кендекләр бергә ябышкан дип, мин сиңа тиккә генә әйтмәдем, бабакай. Тәхеткә утыргач, миңа синең акылың, хәйләкәрлегең, осталыгың кирәк булачак. Әйт миңа турысын гына: син кем яклы — минем яклымы, әллә?..

Актай *(киеренке тынлыктан соң)*. Барысы да ачыкланды дисәм, бернәрсә калган икән. Тәхеткә утыргач, Тәүгилде тарханны кая куярсың?

Хаҗи бәк *(үртәлеп)*. Тәхет тирәсендә аңа урын булмаячак.

Энҗе бикә *(сөенеп)*. Әти!

Актай *(йомшап, куаныч белән)*. Мин, кияү, синең атаң белән утыз елга якын бер табактан ашадым. Утыз ел эчендә мин бер генә тапкыр да аның теләгенә каршы килмәдем, бер генә тапкыр да аңа ялгыш киңәш бирмәдем, бер генә тапкыр да хыянәт итмәдем. Минем тырышлык аркасында изге Болгар

илендә һәрвакыт тынычлык, иминлек булды. Эшне белеп башкаруым нәтиҗәсендә Болгарның байлыгы, көче артты, җире-суы киңәйде. Соңгы елларда хан бик картайды, акылы зәгыйфьләнде...

Хаҗи бәк. Бабакай, сузма!

Актай. Кияү... Хаҗи бәк, мин синең яклы! *(Хаҗи бәкнең аяк астына егыла, итеген үбә.)*

Энҗе бикә *(хурланып)*. Әти! Тор!

Актай *(тора, Хаҗи бәкнең кулын үбә)*. Шаулама, кызым. Үз киявемнең кай җирен үпсәм дә, үпкәләмәс. Аягы астында ятсам да, язык булмас. Тик табаны астында гына ятмаска!

Хаҗи бәк үз-үзеннән канәгать кыяфәттә кеткелдәп тора. Актай үпкәләгән баланы иркәләгәндәй, кызы Энҗе бикәне иркәли. Барысы
да шат. Хаҗи бәк белән Энҗе бикә чыга.

Актай *(ялгыз)*. Карап карарбыз, иң ахырда кем кемнең аяк астында ятар бит әле!

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Кирмән, ягъни хәрби лагерь. Зур, иркен чатыр. Уртада учак. Учак янындарак — багана. Баганага калканнар, ук-җәя ише кораллар элengән. Түрдә калку урын. Анда яралы Ураз бәк ята. Сәхнә
ачылганда, Гали, тирән уйга чумып, әрле-бирле йөренеп тора.

Ураз бәк *(хәлсез. Үзалдына сөйләнә)*. Олы җиңүне күрдем, олы туйны күрә алмадым. Инде күрмәм дә. Өметем киселде. Хәлем бетә бара, күз алларым караңгылана.

Гали (*йөрүеннән туктап*). Имче чакыртыйммы?

Ураз бәк. Мине инде имче генә терелтә алмас. Озакламый мин Тәңре катына китәм. Сизеп ятам — күп калмады. Үзе өчен борчыла икән, дип уйлый күрмә...

Гали. Чәчәк турында да борчылма. Мин аны ташламам, кыерсытмам. Мин исән чакта аңа бернинди кыенлык килмәс.

Ураз бәк. Мин сиңа ышанам, Гали. Ләкин синең үз хәлең яман.

Гали. Алай ук яман түгел. Безнең хәл озакламый ачыкланырга тиеш. Болгарда бер Хаҗи бәк кенә түгел, Болгарда әле хан бар, Актай бар. Гаскәр бар, халык бар. Мин атама, Актайга яшерен кешеләр җибәрдем. Алар тиздән кайтып җитәрләр дип уйлыйм. Кем кертми безне ханбалыкка — Хаҗи бәк кенәме, әллә атам дамы? Безгә менә шуны белергә кирәк.

Ураз бәк. Беләсе юк. Барысы да билгеле. Хаҗи бәктә — көч. Ул сине ханбалыкка якын да җибәрмәячәк. Таярга кирәк моннан исән чагында, Гали! Китик далага. Магул качты, дала үзебезгә калды. Алып кайт син мине үз далама — мин шундук аякка басармын. *(Башын калкыта, торып утырмакчы була.)* Гали! Тыңла сүземне — кайтыйк далага!

Гали. Сине дала тарта — мине ханбалык тарта.

Ураз бәк *(яңадан торып утырмакчы була)*. Гали! Кил әле, тыңлале!

Гали *(Ураз бәк алдына тезләнә)*. Бәк... бабам, син яралы, сиңа борчылырга ярамый.

Ураз бәк. Син шулай да тыңла. Аннары уйлап кара.

Гали. Ярар, уйлап карармын.

Ураз бәк. Мин үлгәч... юк, далага кайту белән үк! — син минем урынга калырсың. Бәк булып! Ыру башы булып! Күз алдыңа китер — кыпчак даласы иксез-чиксез! Анда утыз-кырык ыру. Берләштер шуларны! Бер йодрыкка тупла, Кыпчак-йорт яса! Син булдырырсың аны, Гали! Ул чагында... Хаҗи бәк тә... Чыңгыз хан да... О-у, ул чагында!

Гали *(уйчан)*. Уең изге, Ураз бәк. Шулай да бераз көтик инде, көтик! Кыпчак даласына китү беркайчан да соң түгел. Көтик, бабам: ачыклансын, барысын да тыныч юл белән хәл итик. Без әле керербез ханбалыкка, ясарбыз олы туйны!

Ураз бәк *(төшенке)*. Менә монысына инде ышанмыйм, Гали. Чәчәкне табып китерергә дигән кешеләрең дә кайтып җитмәде.

Гали. Аларын да көтик. Чәчәк әле безнең нинди көлке хәлгә таруыбызны белми дәдер.

Ураз бәк *(башын калкыта, үртәлеп)*. Көлке хәл дисеңме? Аяныч хәл, кызганыч хәл, Гали! Монда, үз илеңә кайткач, сиңа әллә ни булды. Балалар сыман җебеп төштең дип әйтимме... уяулыгыңны югалттыңмы...

Гали. Дөрес, миңа чынлап та әллә нәрсә булды. Күңелем йомшарды. Бернинди усаллык турында уйлыйсым килми. Мин хәтта Хаҗи бәкнең мәкеренә дә ышанмыйм. Боларның барысы да кемнеңдер ялгышыдыр кебек кенә. Алар шулай безнең тиз кайтып җитүебезне абайламый калганнардыр да, капкаларны ачарга боерык булмаганлыктан, безне тоткарларга мәҗбүрләрдер сыман. Кайгырма, бабам! Менә тиздән каерылып капкалар ачылыр, байраклар күтәрелер, бөтен ханбалык, шау-гөр килеп, безне каршыларга чыгар!

Ураз бәк. Ах, башым авырта! Кайтыйк далага! Тыңла сүземне, Гали!
Сакчы керә.

Сакчы. Ханбалыктан илчеләр килде.

Гали *(чиксез куанып)*. Илчеләр! Яшибез, бабам, яшибез, Ураз бәк!

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Караңгы. Уртада беленер-беленмәс кенә учак яна. Югарыда чатырның түгәрәк төннегеннән йолдызлар күренә. Гали ялгыз.

Гали *(үзалдына сөйләнә).*

Тышта төн. Тавышлар тынган.
Канат җәйгән йокы һәр якка.
Тик мин генә уяу, байгыш сыман.
Йокы качты миннән еракка!

*(Югарыга карый.)* Кыпчак даласында да шундый ук төн иде, күктә йолдызлар яна иде. Монда да шундый ук төн, шундый ук йолдызлар. *(Йөренә.)* Юк, монда йолдызлар яктырак яна, Гали, монда йолдызлар якынрак. Берсе бүген җиргә төшкән. Төшкән дә үзе синең янга килгән. Кая соң әле ул, күренми? *(Карана. Ярым караңгыда Энҗе бикә күренә. Өстендә озын кием, башында — бөркәнчек.)* Әнә йолдыз! Шашма, йөрәгем!

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Энҗе бикә ялгыз.

Энҗе бикә. Никтер эчем поша, күңелем шомлана. Мин ут белән су арасында. Үзем куркам, аякларым һаман монда тарта. Тәңрем-Аллам, изге юлдаш бул! Кая килеп кердем соң мин — оҗмахкамы, әллә тәмугкамы? *(Нәрсәгәдер абынып китә, җиңелчә генә кычкырып җибәрә.)* Ай!

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гали һәм Энҗе бикә.

Гали *(ашыгып Энҗе бикәгә таба атлый)*. Энҗе, синме?
Энҗе бикә. Гали!

Кочаклашалар.

Гали. Энҗем-йолдызым!
Энҗе бикә. Гали, бәгърем! Син — исән!
Гали. Без тагын бергә!
Энҗе бикә. Йә Тәңрем, нинди куаныч! Син — исән! Син бөтенләй үзгәрмәгәнсең, Гали.
Гали. Син дә. Элеккечә синнән татлы ис килә. Тавышың да шул ук... күзләрең, чәчләрең...
Энҗе бикә. Юк, син үзгәргәнсең: элеккедән бераз гына кырысрак, усалрак... чибәррәк!
Гали. Анысы дөрес түгел. Мин — ямьсез. Хаҗи бәк менә чибәр!
Энҗе бикә *(каушап)*. Ник?.. Нигә... Юк, юк, әйтмә аны, исемен дә телгә алма!
Гали. Кичер, уйламыйча әйтелде. Минем дә аны телгә аласым килми. Ләкин онытып та булмый.
Энҗе бикә. Онытыйк без аны, Гали?
Гали *(тынычсызланып йөренә башлый)*.

Исемен әйтү белән туганымның,
Нидер сынды, нидер ватылды...

*(Энҗе бикә каршында туктап кала. Беркадәр читләшү, кырыслану белән.)* Онытыйк дисеңме? Аны оныткач, сине дә... синең Энҗе бикә булуыңны да онытыргамы?
Энҗе бикә. Алай... әйтмә миңа, Гали!
Гали *(яңадан йөренә башлый)*. Ярар, әйтмәм. Онытырбыз. Шулай да ничек дип әйтергә соң сиңа? Кем дип эндәшергә? Тегендә, читтә, иң авыр, иң кыен чакларымда мин сине уйлап юандым, йөрәк ярсуымны басар өчен озын төннәремдә мин кыйсса язып уздырдым. Шунда мин сине тиңсез Зөләйха итеп сурәтләдем.
Энҗе бикә. Бәгърем! Бөтен Болгарда син — ни, атаклы шагыйрь.
Гали *(тыңламыйча)*. Әлегәчә мин сине шул гүзәл Зөләйха итеп күз алдына китердем. Минем өчен Зөләйха да, Энҗе дә бер кеше булып тоелды.
Энҗе бикә. Гали, син әллә ничек аңлаешсыз итеп сөйли башладың.
Гали *(читләшеп)*. Юк, инде аңлаешлы кебек. Кинәт күз алларым яктырып китте. Барысы да аңлашылды хәзер!

Энҗе бикә. Гали, сөйләнмә алай!

Гали *(туктый. Кызу-кайнар)*. Зөләйханы Энҗе белән бутап, мин бик каты ялгышканмын. Зөләйха — башка! Зөләйха — саф, тугрылыклы.

Энҗе бикә *(үпкәләп)*. Минем ниндидер Зөләйха буласым да килми. Минем бары Энҗе генә буласым килә.

Гали. Син инде Энҗе генә дә була алмыйсың! Син — бикә, ишетәсеңме, Энҗе бикә! Ха-ха! Хаҗи бәк... хатыны... *(Йөзен каплый, үкси.)*

Энҗе бикә *(юатмакчы була)*. Гали, бәгърем! Синең өчен мин һәрвакыт — Энҗе!

Гали *(башын калкыта. Тыныч, салкын)*. Ник килдең монда?

Энҗе бикә. Синең янга мин... илче булып килдем, Гали.

Гали. Сөйләп кара. Ник кертмиләр безне ханбалыкка?

Энҗе бикә. Агаң кертми. Кыпчаклардан курка. Керсәләр, таларга, көчләргә тотынырлар, ди.

Гали. Кыпчаклар миңа буйсына. Мин бернинди талауга, көчләүгә юл куймаячакмын. Беләме шуны Хаҗи бәк?

Энҗе бикә *(яңадан ягымлы, серле итеп)*. Гали! Шулай ук син мине... аз гына булса да яратмыйсыңмыни?

Гали эндәшми, йөренә башлый.

Гали *(туктый)*. Син — илче. Сүзеңне сөйләп бетер, Энҗе.

Энҗе бикә. Мин сине... коткарырга килдем, Гали!

Гали. Кемнән, нәрсәдән?

Энҗе бикә. Үлемнән.

Гали. Үлемнән? Нинди үлемнән?

Энҗе бикә. Хаҗи бәк сине юк итмәкче була.

Гали *(кызу-кызу йөренә)*. Ул мине бер тапкыр юк итмәкче булды инде. Ул чакта минем нибарысы ун-унбиш кешем бар иде. Хәзер минем кырык меңгә якын чирүем бар. Юк итеп карасын ул мине!

Энҗе бикә. Сиңа хәзер үк нидер эшләргә кирәк, Гали!

Гали. Әйтеп кара, нишләргә икән?

Энҗе бикә. Хаҗи бәк өлгергәнче, аның үзен юк итәргә кирәк. Теләсәң, хәзер үк, таң атканчы ханбалыкка бәреп керә аласың. Мин капка каравылын сатып алдым — алар минем яклы. Тәхеткә юл ачык. Йоклап кала күрмә, Гали!

Гали. Димәк, син миңа тәхет ачкычы алып килдең?

Энҗе бикә. Мин синең белән, Гали!

Гали *(авыр, киеренке)*. Мин ханның, Болгарның җирен-суын, иминлеген саклап, юлбасарларга, илбасарларга каршы яу чаптым. Мин ханның, Болгарның җирен-суын арттыру өчен чит халыклар белән сугыштым. Ләкин мин беркайчан да болгарларны болгарларга каршы алып бармадым. Агамның, атамның, меңләгән болгар туганнарымның канлы мәетләре аша тәхеткә утырсам, исән калганнар — мин үтерткән болгарларның ата-аналары, туганнары — бөтен ил халкы миңа нинди күз белән карар?

Энҗе бикә. Намус, вөҗдан дигәндә, син һәрвакыт талымчан булдың. Хәзер сайланып, талымлап торыр чак түгел. Йә син,— йә ул! Миңа, тәхеткә син кирәк, Гали, син!

Гали. Канга буялачак тәхеттән мин баш тартам, Энҗе бикә! Тынлык.

Энҗе бикә *(Галигә бик якын килә, усал пышылдап)*. Син чынлап та миннән... Энҗедән баш тартасыңмыни?!

Гали. Мин бары Зөләйхадан гына... *(Сүзен әйтеп бетерә алмый — Энҗе бикә итәк астыннан хәнҗәрен чыгара, кадый.)*

Энҗе бикә. Тәхет тә, Энҗе дә агаңа булыр! Хуш, шагыйрь! *(Ашыгып чыгып китә.)*

Гали. А-а! Хыянәт! *(Егыла.)*

Йөгереп Сакчылар керә. Гали янына киләләр.

Сакчылар.

— Кая, кем кычкырды?

— Ни булды?

— Гали! Галине үтергәннәр!

— Тотыгыз, тот! Монда теге бөркәнчекле хатын гына булды.

Сакчыларның берсе ашыгып чыгып китә, икесе Гали янында кала.

Гали *(хәлсез)*. Кирәкми. Инде соң. Тимәгез аңа... Чәчәк... кыйссам... Кайда син?.. *(Үлә.)*

**СОҢГЫ КҮРЕНЕШ**

Әкренләп таң ата бара. Анда-санда янгын утлары күренә. Ыңгырашкан тавышлар ишетелә. Бу — яудан соңгы Бүләр. Җимерелгән йортлар, манаралар. Янган, кара күмергә әйләнгән агач калдыклары. Мәетләр, киселгән кул-аяклар. Сынган сөңгеләр, ватылган калканнар. Еракта күккә ашкан кара төтен — анда һаман нидер яна. Авыр, кайгылы музыка.

Агач-таш арасыннан Шәмсетдин килеп чыга. Ярым ялангач. Өтәләнгән. Чәчләре тузгыган, битен сакал-мыек баскан. Әледән-әле артына карый, як-ягына карана, абына-сөртенә, каядыр ашыга. Туктый, утыра, бер башы янган ниндидер бүрәнәгә сөялеп хәл җыя.

Шәмсетдин *(ерактагы янгыннарга карап)*. Дөмекте ханбалык. Дөмекте Болгар. Актайлар, ханнар. Энҗе бикәләр — барысы да дөмекте. Тәңрегә тиң Чыңгыз ханның изге кулы монда да килеп җитте. Ха-ха, беттеме башыгыз! Мин — исән! *(Башын тотып карый.)* Баш исән, Шәмсетдин, баш! Ха-ха, мин тагын качтым! *(Кузгалып китә, икенче яктан килеп чыккан Чәчәккә барып бәрелә яза, туктый.)* А! Син кем? *(Кача башлый, егыла.)*

Чәчәкнең йөзендә чиксез кайгы. Култык астына нидер төреп тоткан. Иелеп-иелеп мәетләрнең йөзен карап йөри. Үлекләр арасыннан кемнедер эзли, үзалдына: «Юк, түгел»,— кебек сүзләр әйтеп куя. Шәмсетдинне күреп, кире чигенә.

Чәчәк. Син... тере кеше түгелме соң?

Шәмсетдин. Юк, юк, мин тере кеше түгел! *(Кача башлый.)*

Чәчәк *(Шәмсетдингә якын килә, йөзенә карый)*. Юк, син түгел.

Шәмсетдин. Юк, юк, мин түгел! Сиңа кем кирәк? Син үзең кем?

Чәчәк. Күрәсең ич, бер тол хатын.

Шәмсетдин *(качарга азаплана)*. Юк, юк, мин ир түгел! Мин — Шәмсетдин. Мин — галим. *(Чәчәкнең култык астындагы төргәкне күреп ала.)* Бу ни? Икмәкме? Бир монда! *(Тартып алмакчы була.)*

Чәчәк. Бу — китап.

Шәмсетдин. Китап! Ха-ха, китап! Утка як, чүплеккә ташла! Болгар бетте, китап бетте. Кирәге юк, бетсен, дөмексен!

Чәчәк *(Шәмсетдиннең кулыннан тотып ала)*. Син, галим, укый белмисеңме? Өйрәт мине укырга!

Шәмсетдин *(Чәчәктән ычкынмакчы була)*. Юк, юк, мин укый белмим. Кит моннан, кит!

Чәчәк *(Шәмсетдинне ычкындыра, үзалдына сөйләнә)*. Бичара... җир корты... тирес корты. *(Үз юлы белән китә, мәетләрнең йөзләренә карый. Үтеп китешли Шәмсетдингә.)* Курыкма, тимәм. Миңа синең ише тере мәетләр кирәкми, миңа батыр үлеләр кирәк.

Шәмсетдин. Батыр үлеләр кирәк дисеңме? Ха-ха, батыр үлеләр! Туктале, бу минем баш микән соң? *(Башын тотып карый.)* А-а! Әллә кем башы бу! А-а! *(Җиргә ятып үрле-кырлы килә, шуышып, каядыр китеп бара.)* Юк, юк, тоталмассыз! Мин качарга өйрәнгән инде...

Чәчәк *(китабын күз алдына китерә, ача, актара, караштыра)*. Бөек кыйсса, мәңгелек истәлек. Мин саклармын, Гали, синең китабыңны. Мин өйрәнермен, мин укырмын, Кол Гали, синең Йосыф атлы батыр ир белән Зөләйха атлы гүзәл кыз турындагы тиңсез җыруыңны!

Пәрдә төшә.

*1972 ел. Казан*

# САРМАТ КЫЗЫ СӘРИНӘ

*Тарихи драма*

### Катнашалар:

Сәринә.
Байсар би — сарматларның Сарайгыр ыруы агасы.
Бигәнәй бикә — Байсар бинең хатыны.
Котас би — сарматларның Алас ыруы агасы.
Юлдаш баба — аксакал.
Танай.
Филеб.
Җәликә.
Мамиха.
Бикә — Котас би хатыны.
Карт.
Кортка.
Малай.
Ир сугышчылар, кыз сугышчылар, ирләр, хатын-кызлар.

Вакыйганың урыны — Кара диңгез буе далалары, вакыты — безнең
эрага кадәр III гасыр, ягъни моннан 2200 еллар элек.
Сарматлар — борынгы күчмә кабиләләр. Баспурлар — Керчь ярым атавында һәм Кара диңгезнең көнчыгыш яры буенда урнашкан
борынгы Боспор патшалыгы греклары.
Ага-ыру башы (ир кеше), амага — ыру башы (хатын-кыз).

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Таң ата, кояш чыгып килә.
Якындагы өйдән Кортка чыга.

Кортка *(кире борылып, ишек ягына кычкыра)*. Сиңайтәм, тордыңмы?

Өйдән Карт чыга.

Карт. Ә? Нәрсә?
Кортка. Әнә кояш чыгып килә. Нинди матур, илаһым.
Карт *(кояш ягына карап)*. Тагын бер көн яшисебез бар икән әле бу якты дөньяда.
Кортка *(тезләнә, адарынып, кулларын югары күтәрә)*. Тәңрем-Аллам, изгелегеңнән ташлама без гөнаһлы бәндәләреңне!
Карт *(тезләнә, адарынып, кулларын югары күтәрә)*. Бар ышаныч синдә, Ходаем. Илгә иминлек бир, бигә — акыл, үземә көч-куәт бир!
Кортка. Җыясы ризыкларыбыз, эчәсе суларыбыз бетмәсен, илаһым!
Икесе бергә *(дога кылып)*. Амин! Шулай булсын!

Аягүрә басалар, күтәрелеп килгән кояшка карап, сокланып торалар да, ашыкмыйча гына өйләренә кире кереп китәләр. Җиһанда балкып
кояш чыга.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Уң якта — Сарайгыр ыруы агасы Байсар би өе. Киез өй итәгендә сурәтләр: чабып баручы боланнар,
киек бугазлаучы ерткычлар.
Пәрдә ачылып бераз вакыт үткәч, еракта сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы ишетелә. Таяк атка атланып, «Атын» чыбык белән
кыйный-кыйный, сәхнә аша Малай йөгереп үтә.

Малай. Кайталар! Киләләр! Сөенече!

Өй ишеге ачыла, ялт-йолт каранып, Җәликә чыга.

Җәликә. Кем булды ул?

Бигәнәй бикә чыга.

Бигәнәй. Кем бар анда?
Җәликә. Әле генә кемдер кычкырды, бикә.

Бигәнәй. Йөрсен әле ул кызларны борчып. Мин әле аны менә!..
«Атын» кыйный-кыйный Малай керә.

Малай. Кайталар! Сөенче!

Бигәнәй *(еракка карый)*. Берни күрмим. Йөрисез шунда кычытынып.

Җәликә *(Малайга күрсәтеп)*. Менә бу ут күз ич!

Малай. Ут күз түгел, ут колак!

Тынлык. Еракта сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы ишетелә.

Җәликә. Әнә!

Малай. Ишеттегезме инде?

Бигәнәй. Ишеттек, балам. Биебез кайта!

Җәликә. Нишләп ул яктан кайтыр икән соң ул, бикә?

Бигәнәй. Кайсы яктан кайтса да барыбер түгелмени синең өчен?

Малай. Сөенче! Би кайта! Сөенче! *(Чыга.)*

Мамиха керә.

Мамиха. Бикә! Котас би килә. Әле генә кешесен очраттым.

Бигәнәй. Нинди Котас би?

Мамиха. Алас ыруыннан Котас би килә, бикә.

Бигәнәй. Ник килә, ничек килә?

Мамиха. Кешесе әйтте: кода булып килә, диде.

Бигәнәй. Котымны алдың! Ник аны башта ук шулай димисең?

Мамиха. Кешесе әйтте... монда килсеннәрме, шунда туктап калсыннармы?

Бигәнәй. Менә сиңа кирәк булса! Беркем дә өйдә юк чагында...

Мамиха. Урдага аяк басарга рөхсәт юк дип әйтеп әйттеләр дип әйтиммени, бикә?

Җәликә. Бар, бар, шулай дип әйтеп әйтте диген. Йөрмәсен анда юлбасар башына кода булган булып!

Бигәнәй *(Җәликәгә)*. Кирәкмәгән җирдә кысылсаң, менә моннан мин сине! *(Мамихага)*. Изге ният белән... кода булып килгән кешене кире борып җибәрү йоласы юк. Әйт: туктаган җирләрендә өй корсыннар.

Мамиха. Шулай дип әйтермен, бикә. *(Чыга.)*

Икенче яктан икенче төрлерәк кычкырткан быргы тавышы ишетелә.

Җәликә. Менә монысы — алар!

Бигәнәй. Алар, балам, алар!

Малай керә.

Малай. Кайталар! Кайталар! Сөенче!

Бигәнәй *(Малайга)*. Бар, улым, йөгер каршыларына!

Малай. Сөенче! Байсар би кайта! *(Чыга.)*

Быргы тавышы якыная. Әкренләп халык җыела. Юлдаш баба керә.

Юлдаш. Биебез кайта дип ишеттек — дөресме, кем, килен?

Бигәнәй. Дөрес булырга охшый, Юлдаш баба.

Танай керә. Ул сугышчы киемендә.

Танай. Исәнме, инәй!

Бигәнәй. Улым, Танай! *(Кочаклашалар.)*

Танай. Исәнме, Юлдаш баба!

Юлдаш. Исәнме, кем, улым Танай.

Бигәнәй. Барыгыз да исән-саумы? Атаң?

Танай *(тотлыгып)*. Ы-ы-ы... ни... Әтәй дә исән.

Бигәнәй. Атаңа ни булды?

Танай. Әтәй яралы.

Бигәнәй. Һай Аллам!

Танай. Куркыныч түгел... әз генә, нәни генә...

Бигәнәй. Котымны алдың!

Байсар би керә. Үзенең яралы икәнлеген күрсәтмәскә тырышып, әкрен генә атлый. Аның янында кораллы ирләр.

Байсар. Менә мин кайттым, бикә.

Бигәнәй. Бием! Атасы! *(Байсар алдында бил бөгә.)*

Байсар. Үзегез ни хәлләрдә ятасыз! Иминлекме?

Бигәнәй. Иминлек, атасы. Син киткәннән бирле ут йоттым — ашаганым аш булмады, йокым йокы булмады.

Күңелле ыгы-зыгы. Өйдән кызлар тире савытлар белән кымыз алып чыгалар. Кымызны алтын касәгә салып, иң элек Байсар бигә бирәләр. Бераз эчкәч, Байсар би бикәгә бирә, бикә — Танайга, Танай — Юлдаш бабага бирә. Кымызлы касә түгәрәк буенча кулдан кулга китә. Җыр,
бию, музыка.

Байсар *(халыкка)*. Исәнме, ил-көн! *(Юлдаш бабага.)* Исәнме, Юлдаш баба!

Халык.

— Амин!

— Бик исәнбез, би!

Юлдаш. Үзең ничек йөреп кайттың, би? Юлың уңдымы?

Байсар *(сул кулы белән эчен тоткалый, авыртынып чыраен сыта. Танайга)*. Улым, Танай, әйт әле — кертсеннәр теге сандыкларны.

Танай. Хәзер, әтәй! *(Чыга.)*

Бигәнәй *(Байсарның авыртынуын күреп)*. Әллә өйгә керәбезме, атасы?

Бер-ике ир белән Танай авыр сандык күтәреп керә.

Байсар *(халыкка)*. Туганнар, ил-көн! Хәзер бүләкләр өләшербез.

Халык.

— Биебез баеп кайткан.

— Биебез чит ил бүләкләре алып кайткан.

Байсар би авыртынып сандык өстенә утыра. Халык аптырабрак кала.
Танай өйдән аркалы урындык — тәхет алып чыга.

Танай. Әтәй! Каяле, утыр әле менә монда.

Бигәнәй. Бигрәк төсең киткән. Өзлекмәсәң ярар иде, атасы.

Байсар *(җайлабрак утыра, сандыкны ачып җибәрә. Әле бер әйберне, әле икенче әйберне алып карый. Эре таш төймәләр тезеп ясалган затлы муенса чыгара. Бигәнәйгә)*. Беренче бүләгем сиңа, бикә.

Бигәнәй *(муенсаны ала)*. Бай бул, бием. Бигрәкләр матур икән!

Байсар. Ерактан, диңгез аръягыннан кайтарылган. Мондый муенсаларны Мисыр патшаларының хатыннары гына тагып йөри. *(Авыртынып эченә тотына.)* Танай! Улым Танай!

Танай. Әтәй, ни булды?

Бигәнәй. Бүләкләр өләшүеңне хәзергә калдырып торасыңмы әллә.

Байсар. Бетте, бетте. Юлдаш баба, кил әле бирерәк.

Юлдаш. Мине дә исеңдә тоттыңмыни, кем, Байсар улым?

Байсар. Беркайчан исемнән чыкмадың, Юлдаш баба. *(Сандыктан чапан ала.)* Менә сиңа — чапан. Баспур осталары теккән.

Юлдаш *(бүләкне ала, караштыра)*. Бай бул, кем, улым Байсар. Үземә ашлап теккән кебек.

Байсар *(сандыктан асыл ташлар куеп тегелгән затлы мех бүрек ала)*. Монысы — Сәринәгә! Кияүгә чыгасы кызыма дип, бөтен калаларының астын өскә китертеп эзләттем. *(Як-ягына карана.)* Кызым, Сәринә! Каяле, кил әле монда.

Тынлык.

Бигәнәй. Өйдә юк әле ул, атасы.

Байсар. Әйтәм күренми. Кайда соң ул?

Танай. Ул, әтәй, әйтми-нитми яуга китеп барган.

Байсар. Нинди яу ул тагын?

Бигәнәй *(Танайга)*. Кем әйтте, каян ишеттең әле син аны?

Танай. Ишеттем инде. Үзебезнең урдага кайтып җиткәнче барысын да сөйләп бирделәр очраган кешеләр.

Байсар. Нишләп миңа берни дә әйтмәдең, улым?

Танай. Сине борчыйсым килмәде, әтәй.

Байсар *(Бигәнәйгә)*. Шулай да ни булды?

Бигәнәй. Кичәгенәк төнлә ниндидер угрылар барымтага килгәннәр.

Танай. Кичә төнлә түгел, инәй, өченче көн таң алдыннан!

Бигәнәй. Кай арада барысын да белеп өлгердең әле син, Танай улым?

Танай. Башбаштак Сәринәне далада белмәгән кеше юк.
Байсар *(сандыкны ябып куя)*. Арыдым. Эчем!.. *(Эчен тота.)* Бүләкләрне... үзең... таратырсың...
Танай. Әтәй, әйдәле ятып тор.
Бигәнәй. Бием, атасы, ниләр булды — ник әйтмисең?
Байсар. Очлы тау янында... төнлә юлбасарлар чыкты. Сугыштык.
Бигәнәй *(Танайга, ирләргә)*. Биебезне өйгә алып керегез. Карагыз аны — ипләп!
Байсар. Кертмәсеннәр. Монда рәхәт. Туган даламны... көтүләремне карап утырыйм әле... шушында гына...
Бигәнәй *(халыкка)*. Хәзергә таралып торыгыз, туганнар.

Халык тарала.

Байсар *(Танайга)*. Бар, улым, син дә ял ит. Ирләр дә ял итсеннәр.
Танай. Ярар, әтәй. *(Чыга.)*
Бигәнәй. Нәрсә булган бу Танайга? Синең алда тыз да быз килә, кирле-мырлы сөйләнә.
Байсар. Сәринәдән көнләшәдер.
Бигәнәй. Башлы-күзле итәргә кирәк аны да. Өйләндерсәк, көнләшмәс.
Байсар. Карарбыз әле.

Танай керә.

Танай. Анда кодалар килгән икән — әйттеләрме әле, инәй?
Байсар. Нинди кодалар ул тагын?
Танай. Котас би, әтәй.
Бигәнәй *(Танайга ачуланып)*. Һай, улым! Ниеңә кирәк булды әле ул кодалар сиңа? Күрәсең ич, атаңның хәле болай да начар.
Байсар. Котас би... Котас би... Ничек оялмаган ул?!
Танай. Уртанчы улы Баракка безнең Сәринәне сорап килгән ди.
Байсар *(ярсып)*. Ничек аяк баскан ул минем җиремә?! Кем керткән аны минем урдама?!
Танай. Мин дә шулай димен шул, әтәй.
Бигәнәй. Кызмале, атасы. Илчегә үлем юк. Котас би илче булып, кода булып килгән. *(Танайга ачуланып)*. Нәрсә катып торасың — атаңны өйгә кертергә кирәк!

Танай кабаланып Байсарга килеп тотына.

Байсар *(усалланып аягына баса)*. Юк! Мин әле, мин... Котас би алдында күтәрәмгә каламмы соң?!
Танай. Әтәй, тынычлан. Әйдәле, әйдә. *(Байсарны бер яктан култыклап ала.)*
Бигәнәй *(Байсарны икенче яктан култыклап ала)*. Күрше хакы — Алла хакы. Күршеләр белән татулыкка ни җитә!
Байсар *(Танай белән Бигәнәйдән ычкынып китә, ачуланып йөренә)*. Өченче ел бер көтү куйларымны куалап киттеләр, дүрт кешемне үтерделәр. Былтыр илле баш җылкымны алып качтылар. Барысы да Котас би эше!
Бигәнәй. Тотмагач, алай дип тә булмый инде, атасы.
Байсар. Тоткан булсаммы... тоткан булсаммы мин аны! Юлбасар ул яктыдан курка — гел төнлә йөри. Аткан уклары менә монда тиде *(күрсәтә)*. Угы агулы булды, ахрысы, бикә.
Бигәнәй *(куркып)*. Агулы дисеңме?
Байсар *(эчен тота, утыра)*. Үзе болай сыдыртып кына китте. Шулай да менә авырта.
Бигәнәй *(каушап-кабаланып)*. Нигәләр генә искә төшердең шул ко... ко... кодаларны, улым Танай? Җәликә! Мамиха! Кая олагып беттегез барыгыз да?

Өйдән Җәликә белән Мамиха чыга.

Җәликә. Син чакырдыңмы, бикә?
Мамиха. Без монда, бикә.
Бигәнәй. Барыгыз әле тиз генә яңа сауган җирән бия сөте алып килегез.
Танай *(ашыгып)*. Үзем, инәй! *(Чыга.)*
Җәликә
Мамиха
Бигәнәй. Яңа сауган җирән бия сөте эчеп җибәрсәң, агуы да чыгар, ярасы да төзәлер, боерса.
Байсар. Укның агуы чыгар, тик менә йөрәккә кара кан булып укмашкан ачу чыгып бетәр микән?
Бигәнәй *(Байсарны култыклап урыннан алып китмәкче була)*. Анысы да чыгар. Әйдәле, мамык түшәкләргә ятып бер тынычланып йоклап ал. Торуыңа таш кыздырып, мунча әзерләргә кушармын, имчеләр чакыртырбыз.

Байсар *(битараф)*. Урдаңда Котас би булганда мамык түшәкләрдә йоклап яту килешмәс, бикә. Борын төбендәге айгырыңны, куеныңдагы хатыныңны алып кача торган кешеләр алар... Котас биләр, Барак угланнар.

Бигәнәй. Барак углан?

Байсар. Әйе, әйе, Котас биләр, Барак угланнар!

Ике кулына ике тире савыт тотып Танай керә. Аннан бераз калышып, Җәликә белән Мамиха керә.

Танай. Менә, әтәй, берсе яңа сауган җирән бия сөте, икенчесе яңа сауган кара сыер сөте.

Бигәнәй. Яңа сауган кара сыер сөте әлегә кирәкми.

Җәликә. Без дә шулай дидек аңа, бикә.

Мамиха. Кеше сүзенә колак та салмый ул, бикә.

Бигәнәй *(Байсарга касә белән сөт бирә)*. Менә эчеп җибәр әле, атасы.

Байсар *(эчә)*. Тыннарым озаеп китте!

Бигәнәй. Хәлләнерсең, Алла боерса.

Байсар. Яралангач... ике көнгә Йөкәнәс җәйләвендә тоткарландык.

Танай. Анда да имче карчык яңа сауган җирән бия сөте эчерде, иеме, әтәй.

Байсар *(яратмыйча)*. Улым, мин бит сиңа ял ит дигән идем.

Танай. Син авырганда мин ни җаным белән ял итеп ятыйм, әтәй?

Бигәнәй *(Танай белән асрауларны куалап)*. Барыгыз әле, бар! Кирәк булгач, үзем чакырырмын.

Танай белән асраулар чыга.

Байсар. Имче карчык тагын бер-ике көн ятып торырга кушкан иде — йөрәгем түзмәде. Сине, Сәринәмне сагындым.

Бигәнәй. Ул да озаклады. Кодаларга җавап бирәсе дә бар.

Байсар *(кискен)*. Кодаларга җавап бер генә: юлбасарга бирә торган кызым юк минем!

Бигәнәй. Тоткан җирдән өзү дөрес булыр микән?

Байсар. Мин әйткәч, булыр!

Бигәнәй. Алай димәле син, атасы. Кызың турында да уйла, Танаеңны да онытырга ярамый.

Байсар. Алар турында баш ватам да инде мин. Кинәт үлеп-нитеп китсәм...

Бигәнәй. Әйттем исә кайттым диген!

Байсар. Беребез дә мәңгегә килмәгән, бикә. Миннән соң Сарайгырда ыру башы булып кем калыр — менә нәрсә борчый мине.

Бигәнәй. Юк белән башыңны катырма әле. Син әле үзең!..

Байсар *(тавышын әкренәйтеп)*. Миңа агулы ук тигәнен белгәч тә... Бар әле карап кил — тыңлап тормыйлармы?

Бигәнәй торып як-ягына караштыра, өйгә кереп чыга, яңадан үз урынына килеп утыра.

Бигәнәй. Ул-бу сизелми.

Байсар. Агулы ук тигәнен белгәч тә, безнең улыбыз Танай күз алдында үзгәрде, бикә. Мин хәтта курка башладым.

Бигәнәй. Алай ук түгелдер лә инде, атасы!

Байсар. Алай ук шул, Бигәнәй бикә.

Бигәнәй. Сине кызганыптыр ул.

Байсар. Кеше кызгана торган кеше түгел ул синең Танай улың.

Бигәнәй. Анысы шулай.

Байсар. Мин бернәрсә уйладым әле, бикә.

Бигәнәй. Нәрсә икән ул?

Байсар. Су төбенә салынган теге серне чишеп... Сәринә белән Танайны кавыштырсак, ничек булыр икән димен.

Бигәнәй. Менә сиңа кирәк булса! Иске авыздан яңа сүз. Үзең әйтеп торасың... кансыз дисең, үзгәрде дисең.

Байсар. Сарайгырны таратмас өчен шулай эшләргә кирәк, бикә.

Бигәнәй. Гомер буена агалы-сеңелле булып йөрсеннәр дә, кинәт кенә ирле-хатынлы булып китсеннәр, имеш! Ил-көн алдында ни диярбез дә, күршеләр күзенә ничек күренербез?

Байсар. Кысыр хәсрәт менә шул була инде, бикә.

Бигәнәй. Әйтмәм дигән идем... Болай булгач, әйтмичә булмас, ахрысы.

Байсар *(сагаеп)*. Тыңлыйм, бикә, сүзеңне.

Бигәнәй. Өченче көн, угрыларны куа китәр алдыннан, Сәринә әйтте: мин югында кодалар килсә, борып җибәрмәгез, мин кайтканчы көтеп торыгыз, диде.

Байсар. Кемнән кодалар килсә дигән иде соң ул?

Бигәнәй. Шул инде, шу... теге... ни.. Ко... Котас бинең уртанчы углы Бaрактан дигән иде.

Байсар *(тора, йөренә, үртәлеп)*. Башсыз булып чыкты синең ул Сәринә дигән кызың, Бигәнәй бикә. Минем кан дошманым белән, юлбасар белән... Кара син аны!

Бигәнәй. Яратышалардыр, Байсар би. Яратуның түрәсе дә, йоласы да — бер.

Байсар *(тупас)*. Юк, бер түгел!

Бигәнәй. Син, бәлки, үзеңнең дә яшь чакларыңны исеңә төшерерсең, Байсар би? Шүнәк ыруының бердән-бер мактанычы булган Бигәнәйне өзелеп яраткан өчен... син дә шүнәкләрне юлбасарларча барып басмадыңмыни?!

Байсар *(караңгы чырай белән)*. Искегә тисәң исең китәр. Искене актарырга булдыңмыни, Бигәнәй бикә?

Бигәнәй. Шүнәкләр белән сугышкан чакта син дә Котас биләрдән, Барак угланнардан ким кыланмаган идең.

Байсар *(эченә тотына)*. Тагын шулар!

Бигәнәй. Котас би улы Барак углан да Сәринәне өзелеп яратадыр димәкче генә булам мин сиңа, Байсар би.

Байсар *(утыра, йомшарып)*. Яратадыр, яратадыр. Кил әле янымарак. Сәринәдән бигрәк мин сине сагынып кайттым, Бигәнәем-Бергенәем.

Бигәнәй *(утыра)*. Сәринәне сагынсаң да бер дә сүзем юк.

Байсар. Шәп идең син яшь чагында, Бигәнәй!

Бигәнәй *(балавыз сыгып ала)*. Бар карап торганым шул Сәринә.

Байсар. Минем дә бар карап торганым — Сәринә. Шулай да иң якыны — син. Моңарчы мин сиңа карата тупас булдым бугай. Хәзер менә сине гел мактыйсым килә.

Бигәнәй. Ярар инде...

Байсар. Тегендә — диңгез, таулар. Өйләре гел таштан, балчыктан. Суларга тын җитми анда. Даладагы кебек җил юк, иркенлек юк.

Бигәнәй. Безнең дала оҗмах ул, оҗмах!

Байсар. Анда мин гел сине уйладым. Яратып, сагынып уйладым.

Бигәнәй. Үз илебезгә, үз җиребезгә ни җитә! Утырыйк әле бер иркенләп.

Байсар *(беравык тынып утырганнан соң)*. Угрылар кайсы яктан килделәр икән — белмәдеңме?

Бигәнәй. Төньяктан диделәр.

Байсар. Димәк, Очлы тау ягыннан!

Бигәнәй. Даланың киртәсе юк — кайсы яктан килсә дә ирек.

Байсар *(көрсенеп)*. Бозылды дөньялар. Үз илеңдә, үз җиреңдә тынычлап яшәве елдан-ел авырлаша бара.

Бигәнәй. Шуңа күрә дә күршеләр белән тату булырга кирәк безгә.

Байсар. Юлбасарлар мине өченче көн кич караңгы төшәр алдыннан яраладылар. Сугыш ярты сәгать чамасы барды. Без аларны куып җибәрдек.

Бигәнәй. Качтылармы?

Байсар. Качтылар. Шуннан соң алар әнә минем җәйләвемә килеп чыкканнар, көтүемне куып киткәннәр.

Бигәнәй. Син инде андагы юлбасарларны да, мондагы угрыларны да бер үк кешеләр булган димәкче буласыңмы?

Байсар. Шулай димәкче булам. Шуларның берсе, беләсеңме, кем булган?

Бигәнәй *(сизенеп)*. Юк, булмас!

Байсар. Буласы булган инде, Бигәнәем-Бергенәем. Юлбасарларның берсе... атаманы... Котас бинең уртанчы улы Барак углан булган!

Бигәнәй. Ай-һай, ялгышмадың микән, Байсар би?

Танай керә.

Танай. Кодаларның сине күрәселәре килә, әтәй.

Байсар белән Бигәнәй сүзсез генә бер-берсенә карашып алалар.

Байсар. Син, Танай улым, Котас бинең йомышчысына әйләнмәгәнсеңдер ич?

Танай. Ул синнән бераз шүрли бугай — минем аша эш йөртмәкче була.

Байсар. Кем аша эш йөртергә кирәклеген белә ул, ата юлбасар.

Танай. Нәрсә дип әйтим соң, әтәй?

Бигәнәй. Байсар бинең хәле юк, арыган, әлегә беркемне күрәсе килми дип әйттеләр диген.

Байсар. Менә монысы инде булмас! Котас би алдында сер сынатаммы соң?! Авызымда кара кан булса да... *(Кискен.)* Әйт, килсеннәр! *(Тора, йөренә, эченә тотына.)* Ах, эчем!

Кодалар керә. Алар өч кеше. Берсе Котас би. Кодалардан соң Танай белән Юлдаш керә.

Котас *(түргә уза, Байсар би алдында бил бөгә)*. Илең имин булсын, терлек-туарың көр булсын, Байсар би.

Байсар. Амин, шулай булсын.

Котас. Үзеңә, бикәңә, илеңә-көнеңә озын гомер, байлык, тазалык бирсен Хода.

Байсар. Әйткән сүзләрең изгегә юралсын, Котас би.

Бигәнәй. Теләгән теләкләрең үзеңә яхшылык булып кайтсын, Котас би.

Байсар. Әйдәгез, утырышыгыз, кодалар.

Кодаларга урын бирәләр. Алар Байсар би һәм башка сарайгырлар каршысына утыралар.

Котас. Сарайгырлар белән без — аласлар, күрше генә булсак та, үзара йөрешмибез, белешмибез. Моннан соң алай булмасын дип, ике арада дуслык, татулык сукмагы салынсын дип, мин сиңа зур йомыш белән килдем, Байсар би.

Байсар. Мин болай үзем күршеләр белән аралашып яшим. Кеше малына кул сузмыйм. Җирем-суым җитәрлек. Өстем бөтен, тамагым тук дигәндәй... Инде сиңа килгәндә, Котас би...

Котас *(бүлдереп)*. Диңгез буенда, баспурларда сәүдә эше белән йөреп кайткан диләр сине. Дөресме шул, Байсар би?

Байсар. Баспурга сатарга терлек куалап бардым. Юлым уңды, Котас би. Сатир патшада кунакта булдым. Бик күп бүләкләр биреп, далага чаклы озатып куйды.

Котас. Сатир патшаны мәкерле, икейөзле, диләр.

Байсар. Сизмәдем. Минем белән эчкерсез булды. Моннан соң да йөрешергә, сату-алу итәргә сүз куештык. Аларның җирләре аз.

Котас. Беләм, Баспурларның күптән безнең далага күзләре кыза.

Байсар. Мал-туарлары бөтенләй диярлек юк. Иген игәләр дә, чүлмәк ясыйлар, балык тоталар.

Котас. Беләм. Көтү-көтү терлек-туарың булмаса, ничек җан асрамак кирәк бу дөньяда?

Байсар. Калалары ике кат койма белән әйләндереп алынган.

Котас. Көче, гаскәре күпме Сатир патшаның?

Байсар. Менә анысын сорарга оныткамнмын, Котас би.

Котас. Сатир патшаны әледән-әле күршеләренә яу чаба, диләр.

Байсар. Күршеләренә яу чаба торган юлбасарлар үзебезнең сармат даласында да җитәрлек, Котас би.

Котас. Әйе, далада тәртип бетте. Барысы да үзара талаша, сугыша.

Байсар. Андыйларга мине кыстыра күрмә, Котас би.

Котас. Аннары — йола! Йола харап итә безне, Байсар би. Безнең Алас ыруында шулай: яшь җегет, барымтага барып, күршеләреннән бер көтү мал куып кайтмаса, аны иргә дә санамыйлар, аңа кыз да бирмиләр.

Байсар *(тынычсыз)*. Беләм мин сезнең юлбасарлар йоласын.

Бигәнәй. Андый гына йолалар без дә бар инде, атасы. Ирләр кебек кулына корал тотып яу чаба алмаган, кимендә бер дошман башы алып кайта алмаган кызга бездә кияүгә чыгу тыела. Шунлыктан менә Сарайгыр кызларының күбесе утырып кала.

Байсар. Безнеке — изге йола!

Котас. Алайса, Байсар би, сез дә күршеләр белән сугышмыйча тора алмыйсыз икән?

Бигәнәй. Әллә хәзергә яу-сугыш турындагы сүзләрне онытып торабызмы?

Байсар. Котас би безгә үзенең йомышын әйтмәде. Тыңлап карыйк аны.

Котас. Мин, Байсар би, Бигәнәй бикә, уртанчы улым Баракка сезнең кызыгыз Сәринәне сорап килдем. Йомышым минем шул.

Байсар. Кызым Сәринә үзе өйдә юк. Аның үзеннән башка мин бер сүз дә әйтә алмыйм, Котас би.

Бигәнәй. Сәринә үзе кайтсын инде. Килешербез, боерса.

Юлдаш. Кем, Байсар би, Бигәнәй бикә... Сәринәне кияүгә бирү-бирмәү ул сезнең эшегез генә түгел — бөтен ил-көн эше. Сәринәнең язмышы ул бөтен Сарайгыр язмышы. Шуңа күрә сез мине дә тыңлап карагыз әле, кем, Байсар би, Бигәнәй бикә.

Байсар. Тыңлыйбыз, Юлдаш баба.

Ерактан сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы ишетелә. Барысы да тынып калалар.

Бигәнәй. Әнә үзе дә кайта!

Малай керә.

Малай. Сөенче! Кайталар! Кайталар!

Җилләнеп Сәринә керә. Аның янында бер-ике кыз сугышчы.

Сәринә *(әтисе алдына килә, тезләнә)*. Исәнме, әтием!
Байсар. Кызым, Сәринәм! *(Кочаклый.)*
Бигәнәй. Кайтты. Сәринәм дә кайтты! *(Кочаклашалар.)*
Сәринә. Кайттым, әнием. Миңа ни булсын — мин җил кебек. Мине сөңге алмый, кылыч чапмый.
Бигәнәй. Тәүбә диген!
Котас *(үзалдына)*. Карап туйгысыз. Ут кебек, җылан кебек!
Танай. Сәринә! Сеңлем!
Сәринә. Абыем! Барыгыз да исән-саулар. Нинди куаныч!
Бигәнәй. Почмагыбыз түгәрәкләнде, кызым.
Сәринә. Арыдым. Үтереп йокы килә.
Байсар. Сөйлә, кызым, кайларда булдың, ниләр күрдең?
Сәринә. Без аларны куып бардык...
Байсар. Кемнәрне, кызым?
Сәринә. Угрыларны. Өченче көн таң алдыннан безнең көтүләрне куып киткәннәр. Кораллы кызларымны җыйдым да, киттем артларыннан.
Бигәнәй. Куып җиттегезме?
Сәринә. Икенче көнне без аларны Очлы тау ягында очраттык.
Байсар. Очлы таудамыни?..
Сәринә. Очлы тауга җитәрәк. Күрделәр дә безне, әрәмәләр арасына кереп качмакчы булдылар. *(Тыела алмыйча көләргә тотына. Ул әле Котас бине дә, аның юлдашларын да күрми. Күрмәмешкә салына.)* Өч йөз баш җылкыны куып киткәннәр дә, җиңел генә безне алдамакчы булганнар. Өч йөз баш! Берсен дә бирмәдек. Барысын да куып алып кайттык.
Байсар. Менә ул минем батыр кызым!
Котас *(шомланып)*. Тегеләр... угрылар качтылармы?
Сәринә *(көлә-көлә Котас би ягына борыла)*. Юк, берсе дә качып котыла алмады, Котас би. Утызын да кырып салдык. Сарайгырның утыз кызы яудан утыз дошман башы алып кайтты.
Котас *(ыңгырашып)*. Йә Тәңрем!
Сәринә. Сарайгырның утыз кызы бүгеннән башлап үзенә кияү сайлый ала.
Байсар. Син дә алып кайттыңмы, кызым?
Сәринә *(тыела алмыйча көлә дә көлә. Көлүендә газап сизелә)*. Яудан мин бүген өченче баш алып кайттым. *(Сугышчы кызларга.)* Күрсәтегез мин алып кайткан дошман башын!

Сугышчы кызлар күн капчыктан баш алып күрсәтәләр.

Котас *(якынрак килеп карый, коты алынып кычкырып җибәрә)*. Улым! Барак! *(Егыла.)*
Бигәнәй. Ай Алла, харап булдык!
Танай *(үзалдына)*. Менә кызык!

Өй эчендә ыгы-зыгы башлана. Котас бине кодалар аягына бастыралар.

Байсар *(чыраен сытып эченә тотына)*. Күңелем сизенгән иде аны.
Сәринә. Без аларны сиздермичә генә уратып алдык, йоклаганда өсләренә барып бастык.
Котас *(кыныдан хәнҗәрен тартып чыгара, Сәринәгә ташлана)*. Сез йоклап яткан кешеләрне үтергәнсез. Сез үзегез — угрылар!
Сәринә *(читенә, хәнҗәрен чыгара. Арага кораллы кызлар баса, атылып Танай килеп җитә)*. Син, Котас би, ялгышасың: үтерер алдыннан без аларны уяттык.
Котас *(читенә)*. Улым, балам!
Бигәнәй. Бәхетсез бала.
Котас. Соңгы сулышында берәр сүз әйттеме, ичмасам?
Сәринә. Әйтте. Сиңа миннән кодалар килер, диде. Мин аны кызгандым. Бар, кач, без бит вәгъдәләшкән кешеләр, безнең туебыз булырга тиеш ләбаса, дидем.
Котас. Ул ни диде?
Сәринә. Син — җиңүче. Җиңүченең колы буласым килми — үтер мине, диде.
Котас *(җылый)*. Улым, балам... Бир ул башны миңа, Сәринә?
Сәринә. Юк, Котас би!
Котас. Байсар би! Бигәнәй бикә! Сез дә ата кеше, ана кеше...

Байсар. Кызым, Сәринә! Синең яудан өченче баш алып кайтуыңны барыбыз да күрдек.
Юлдаш. Күрдек, кызым.
Бигәнәй. Бир син аны, кызым, бир аңа.
Байсар *(аягүрә баса)*. Котас би! Бигәнәй бикә! Кызым Сәринә! Ил-көн! Бу күңелсез хәл безгә мәңге сабак булсын. Элекке дошманлыкны онытып, безгә — сарайгырлар белән аласларга — киләчәктә мәңге дус-тату булырга кирәк.
Сәринә. Әтием Байсар би! Әнием Бигәнәй бикә! Ил-көн! Аласлар белән дуслашырга теләгән өчен дә мин үзем теләп Баракка кияүгә чыгарга ризалык биргән идем. Биргән сүзне мин түгел, ул бозды. Шуның өчен менә башы белән җавап бирде.
Байсар. Шулай да бир син ул бәхетсез башны аның атасына, кызым.
Сәринә. Бу бәхетсез башны мин яраттым, әтием. Бу баш бары минем үз башым белән бергә генә биреләчәк.
Котас *(үзгәреп)*. Сәринә! Батырларның батыры, гүзәлләрнең гүзәле! Син мине... улым Баракны хур иттең. Син безне — аласларны аяк астына салып таптадың. Аласлар өчен дә бу күңелсез хәл мәңге сабак булыр. Моннан соң алар беркайчан күрше малына кул сузмаслар!
Кодалар. Моннан соң аласлар Сарайгыр белән мәңге дус булырлар.
Байсар. Амин, шулай булсын.
Бигәнәй. Теләгең изге, Котас би.
Юлдаш. Татулыкка ни җитә, балалар!
Котас. Байсар би! Бигәнәй бикә! Сарайгырлар! Уртанчы улым Барак үтерелгән өчен генә мин сезнең белән туганлашудан баш тарта алмыйм. *(Сәринәгә.)* Сәринә! Мин Барак улым кебек тәкәббер түгел. Мин синең колың булырмын. *(Тезләнә.)* Чык миңа кияүгә!

Тынлык.

Сәринә. Яудан өч дошман башы алып кайткан кыз буларак, мин үзем яраткан теләсә кемгә кияүгә чыга алам. Бу безнең сарайгырларның борынгы йоласы. Кияүгә чыгарга дисең инде син, алайса, Котас би?
Котас. Аласта, бөтен далада беренче бикә булырсың, Сәринә.
Сәринә *(икеләнеп)*. Сиңа... кияүгә...
Байсар. Үзең бел, кызым.
Бигәнәй. Без каршы түгел, кызым.
Сәринә. Юк, Котас би, юк! *(Көлә.)* Мин сине түгел, улың Баракны яраттым. Син... бераз гына картрак, бераз гына ямьсезрәк, Котас би. Юк, юк! *(Укси.)*
Котас *(ялварып)*. Байсар би! Бигәнәй бикә! Ник якламыйсыз мине?
Байсар *(эченә тотына)*. Мин... кызымның теләгенә каршы... килә алмыйм...
Бигәнәй. Сәринә үзе риза булса, без риза, Котас би.
Юлдаш. Уйлашырга кирәк, балалар.
Котас *(Сәринәгә)*. Икеләнмә, Сәринә!
Байсар *(бик нык авыртынып)*. Кызым... Сәринә...
Сәринә. Әти, ни булды?
Бигәнәй. Бием! Атасы!
Танай. Әтәй!
Байсар *(хәлсез)*. Миңа аткан угы... чыннан да... агулы булган... Барак угланның. Имче карчык әйтте... өч көнгә түзсәң... исән калырсың, диде.
Бигәнәй. Түз, атасы, түз.
Байсар *(бик нык авырлык белән)*. Минем урынга... амага булып... син каласың...
Танай *(Байсарның янына ук килеп)*. Кычкырып әйт — кем кала, кем, әтәй?!
Байсар. Сәринә... син каласың...
Танай. Әтәй! Кабатла!
Бигәнәй. Күчте.
Танай *(шашып, Байсар янындагы кешеләргә)*. Сез ишеттегезме: ул кем диде?
Юлдаш. Сәринә, диде, кем, Танай улым.
Танай *(үле Байсарның якасыннан эләктереп ала)*. Карт алдакчы! Тамуг кисәве!
Сәринә *(Танайны этеп җибәрә)*. Син үзең тамуг кисәве!
Бигәнәй *(Танайга)*. Нишләвең бу?! Кулың корыр!
Танай. Йола буенча, Сарайгырда ага булып мин калырга тиешмен. Байсар бинең өлкән улы, бердәнбер улы — мин... Танай!
Юлдаш. Кем, Танай улым, ямьсезләнмә. Байсар би үз авызы белән әйтте: Сәринә кала, диде.
Танай. Сез барыгыз да бер сүздә, барыгыз да дошман миңа. Чәнчелеп китегез! *(Тузынып чыгып китә.)*

Юлдаш. Әл-лә-лә! Менә нинди икән әле ул безнең Танай улыбыз!
Бигәнәй. Бары да язмыш кулында.
Сәринә. Язмыш кулында гына түгел, әнием.
Бигәнәй. Язмыштан узмыш юк, кызым.
Котас. Язмышны аны сугышып җиңәргә кирәк! *(Чыга. Кодалар да чыгалар.)*
Юлдаш. Менә шулай кеше кайгыра, даулаша — бар дөньяны яулап алмак була. *(Үле Байсарга күрсәтеп.)* Аңа инде берни кирәкми.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Өй эче. Сәринә түрдә. Аның тирәсендә кызлар бөтерелә. Алар аны киендерәләр, төзәндерәләр.
Бигәнәй керә.

Бигәнәй. Кызым, Сәринә! *(Сәринә ишетми.)* Сәринә дим! Тамактан калдың, инде колактан да калдыңмыни?
Сәринә. Әү? Әни, синмени?
Бигәнәй. Үлгән артыннан үлеп булмый — шулкадәр бетеренмә.
Сәринә. Мин уйланам, әнием.
Бигәнәй. Бүген менә ил-көн сине Сарайгырның амагасы итеп күтәрәчәк. Каршы килүчеләр булмасмы, үзара тавыш-гауга чыкмасмы?
Сәринә. Борчылма, әнием, берни булмас.
Бигәнәй. Үз-үзеңә артыграк ышанмыйсың микән, кызым?
Сәринә. Үземнән бигрәк мин халкыма, ыруыма ышанам.
Бигәнәй. Җан сердәшең булса, үзеңә җиңелрәк булыр иде димен шул.
Сәринә. Иң ышанычлы сердәшем син — әнием... Бигәнәй бикә.
Бигәнәй *(җиңелчә ачуланып)*. Башыңны җүләргә салып утырган булма. Сиңа хәзер үк кияү турында уйларга кирәк.
Сәринә *(таркау)*. Кияү. Кияү алырга. Кияүгә барырга...
Бигәнәй. Шундый яшьлегең белән, шундый чибәрлегең белән... кайгыга сабышып утырырга монда!
Сәринә. Кемгә чыгарга соң, әни?
Бигәнәй. Үзең теләгәнне сайла.
Сәринә. Сайлыйсым килми.
Бигәнәй. Синең урында булсаммы мин!
Сәринә *(көлеп)*. Утыр минем урынга.
Бигәнәй. Яшьлекне алай гына кайтарып булса иде ул, кызым! Минем яшьлек инде узды... күренмичә, сизелмичә узды. Синеке әле башлана гына. Сөекле ирең булсын, итәгең тулы балаларың булсын — миннән теләк шул сиңа.
Сәринә. Кайгым бар, әни.
Бигәнәй. Нинди бетмәгән кайгы инде ул?
Сәринә. Мин үземә ир дә табармын, бәхетле дә булырмын...
Бигәнәй. Бирсен Хода!
Сәринә. Мин бәхетле булган белән генә Сарайгырның барлык кызлары да бәхетле булыр микән соң?
Бигәнәй. Кайсы кызларны әйтәсең?
Сәринә. Кияүгә чыгарга хокукы булмаган кызларны.
Бигәнәй. Бәрәч! Синең белән бергә аласларны җиңеп кайткан егерме тугыз кызның барысы да кияүгә чыгып бетте ләбаса инде. Син генә калдың.
Сәринә. Мин — булачак ыру башы, үзем белән аласларны җиңеп кайткан кызлар турында гына түгел, барлык ил-көн турында кайгыртырга тиешмен.
Бигәнәй. Анысы аның ярый инде ул, кызым. Шулай да син Сарайгырның барлык кызлары кияүгә чыгып беткәнче дуадак каз кебек утырырга җыенмыйсыңдыр ич?
Сәринә. Җыенам, әнием.
Бигәнәй. Андый сүзне кеше-кара ишетә күрмәсен — яманатың бөтен далага таралыр, йөзеңә карап көләрләр.
Сәринә. Үз уемнан мин кире кайтмаячакмын... йөземә карап көлсәләр дә, яманатым бөтен далага таралса да!
Бигәнәй. Карале, шуны әйтим дигән идем... Мәрхүм әтиеңнең бер теләге бар иде. Бүген... кырыгы тулган көнне...
Сәринә. Мин аның теләген беләм, әнием.

Бигәнәй. Үзең белгәч, бигрәк тә яхшы.
Сәринә. Мәрхүм Байсар бинең теләгән һәркем белә: үзе урынына ул мине...
Бигәнәй. Белмисең! Сарайгыр таркалмасын өчен, ул сине...

Юлдаш керә.

Юлдаш. Исәнме-саумы, кем, кызым Сәринә. Исәнме, килен.
Сәринә. Түрдән уз, юлдаш баба.
Юлдаш. Ярый әле икегез дә бергә туры килдегез. *(Сәринәгә.)* Минем сиңа әйтәсе бик кирәкле сүзем бар иде, кем, кызым Сәринә.
Сәринә. Әйтеп кара, Юлдаш баба.
Юлдаш. Үзең яшьсең, үзең чибәрсең. Батырлыгың да ярыйсы. Бүген менә үзеңне амага итеп күтәрәчәкбез. Тормышың түгәрәкләнсен дисәң, кызым, сиңа кияүгә чыгарга кирәк.
Бигәнәй. Мин дә шуны сөйләп торам әле, Юлдаш баба.
Сәринә. Бик акыллы киңәш бу, Юлдаш баба. Синең әллә димләр кешең дә бар?
Юлдаш. Менә дигән кешем бар, кызым.
Сәринә. Кем икән соң ул, Юлдаш баба?
Юлдаш *(чыга, шундук Танай белән бергә керә)*. Менә бу чибәр угланны беләсеңдер.
Сәринә *(аңламаган булып)*. Танайны әйтәсеңме, Юлдаш баба?
Бигәнәй *(җиңелчә ачуланып)*. Кыланып утырган булма! Юлдаш бабаң, олы башын кече итеп, синең белән сөйләшә икән, тыңлап кына тор.
Юлдаш. Шул инде, шул... бәхете булгыры... абыең Танайны әйтәм.
Сәринә *(көлеп)*. Син мине абыем Танайга димләргә җыенасыңмыни?
Юлдаш. Юк ла, ниткән абыең булсын ул синең? Атаң мәрхүм — урыны оҗмахта булсын! — яудан, шүнәкләрдән алып кайтты аны.
Танай. Мәрхүм әтәй... Сарайгырның элекке агасы Байсар би — яткан җире мамык булсын — моннан бик күп еллар элек шүнәкләргә каршы яу чапкан. Шунда ул мине янган өй янынннан табып алган, минем ырудашлар... шүнәкләр, арбаларын, өйләрен яндырып, минем кул-аякларны бәйләп... мине шунда утыртып калдырган булганнар. Миңа бары ике-өч яшь булган.
Юлдаш. Әниең Бигәнәй бикәне дә Байсар би шуннан алып кайтты.
Сәринә. Каян алып кайтты?
Юлдаш. Шуннан инде, шуннан — Шүнәктән.
Сәринә. Кичә үлгән булсам, бүген ишетмәгән булыр идем! Дөньяда мин белмәгән серләр җитәрлек икән әле.
Юлдаш. Кем, кызым, Сәринә, дөньяның син белмәгән серләре күп. Ул серләрне бары берничә кеше генә белә. Хәзер менә син дә белә башларсың.
Сәринә. Белмәгән булсам, нинди яхшы буласы икән!
Юлдаш. Амага кеше чынын да, ялганын да белергә тиеш. Шүнәкләрне җиңеп кайткач, Байсар би әйтте халыкка: яшь баласы белән яшь хатын алып кайттым, диде. Танайны... ырудашын әниең Бигәнәй бикә, җил-яңгыр тидермичә, үз баласы кебек карап үстерде.
Сәринә. Нишләп мин берни дә сизмәдем икән соң?
Бигәнәй. Танай улым үзенең ятимлеген белмәсен, күңеле китек булмасын дип тырыштык инде, кызым. Шуңа күрә сиңа берни сиздермәдек.
Сәринә. Ул үзе каян белгән соң?
Танай. Былтыр монда Шүнәктән бер теләнче килеп чыкты — шул сөйләде.
Сәринә. Дөрес, Шүнәктән бер теләнче булды бездә!
Юлдаш *(бер кулы белән Танайны, икенче кулы белән Сәринәне тотып, икесен дә бер-берсенә якын китермәкче була)*. Дөньяның бер сере чишелде. Бәхетле булыгыз, балалар.
Бигәнәй. Бәхетле булсыннар, тигез гомер итсеннәр.
Сәринә *(карышып)*. Ләкин мин Танайга чыга алмыйм!
Юлдаш. Нишләп алай?
Сәринә. Мин аны... яратмыйм, Юлдаш баба, әнием Бигәнәй бикә!
Танай. Мин сине... яратам, Сәринә!
Сәринә *(көлеп)*. Син мине... яратасың?! Нишләптер моңарчы сизелмәде. Миңа карата син һәрвакыт көнчел, үпкәчел һәм кансыз булдың сыман.
Танай. Моннан соң алай булмас, Сәринә.
Сәринә. Шулай бик тиз үзгәрерсең микәнни, Танай?
Танай. Үзгәрәм! Утка керергә кушсаң, утка керәм, суга керергә кушсаң, суга керәм!
Сәринә *(чит, салкын)*. Әгәр мин сине белмәгән булсам, бәлки әле ышанган да булыр идем. Ләкин мин сине биш бармагым кебек беләм. Беркайчан да син мине яратмадың... туганың-сеңлең буларак та, хатын-кыз буларак та. Син бары үзеңне генә яратасың, Танай.

Танай *(хурланып)*. Үзең әллә кем инде!
Сәринә. Юк, яратмыйм мин сине, яратмыйм!
Танай. Барак калдыгы! Исеңә төшәр дә, соң булыр! *(Тузынып чыгып китә.)*
Сәринә. Менә монысы Танайча!

Барысы да аптырап Танай артыннан карап калалар.

Бигәнәй *(Сәринәгә)*. Кешенең йөзенә бәреп «яратмыйм» дип әйтергә теге... кем булдың шулкадәр? Син дә күктән төшмәгән!
Юлдаш *(Сәринәгә)*. Хәзер инде мине тыңлап кара, кызым Сәринә. Ярату кемгә дә кирәк. Яратудан бигрәк сиңа ир кирәк. Ирең, терәгең булмаса, Сарайгырда сине беркем санламаячак. Үләр алдыннан Байсар би сине ыру башы итеп калдырган икән, димәк, ул барысын да ныклап уйлаган.
Бигәнәй. Уйлады, Юлдаш баба, бик нык уйлады.
Юлдаш. Син, кызым, алай-болай чит ыруга кияүгә чыксаң, Сарайгыр бик кыен хәлдә калыр иде. Синең бирнәң булып, Сарайгыр чит ыруга кушылыр иде. Син чит ыру кешесенә чыкмасын өчен мәрхүм Байсар би сине Танайга бирергә исәпләгән.
Бигәнәй. Исәпләде, Юлдаш баба! Икәү бергәләп исәпләдек.
Юлдаш. Шулай булгач Сарайгырның бәйсезлеген саклап калыйм дисәң, сиңа бары Танайга гына чыгарга туры килә, Сәринә кызым.
Сәринә *(көрсенеп)*. Нинди авыр икән амага булу!
Юлдаш. Сиңа тагын шуны да әйтим, кызым Сәринә: безнең сүзгә колак салмыйча киреләнә башласаң, без сине амага итеп күтәрмәячәкбез.
Сәринә. Куркытма, Юлдаш баба! Мәрхүм Байсар бинең ыру башы булырлык баласы бер генә. Ул да булса, мин — Сәринә!
Юлдаш. Син әле берни белмисең икән, кызым, мәрхүм Байсар бинең ыру башы булырлык ир баласы бер генә. Ул да булса — Танай.
Сәринә *(нәфрәтләнеп)*. Син Юлдаш баба, ни сөйләгәнеңне белеп сөйлисеңме?!
Юлдаш. Бик белеп сөйлим, кызым. Мәрхүм Байсар бинең варисы — Танай.
Сәринә *(тыела алмыйча)*. Бар чыгып кит моннан, ялганчы карт!
Бигәнәй. Кызым, тукта хәзер үк!
Сәринә *(Бигәнәйгә)*. Әллә син дә аның яклы, Бигәнәй бикә?
Бигәнәй. Үлсәм дә, калсам да — бергә. Ил-көн белән, халкым белән.
Юлдаш *(чигенә, ишекне ача. Ишек артында җиңелчә гүелдек ишетелә. Анда — халык)*. Ашыкма, кызым, куарга. Сиңа соңгы сүзем шул: халык алдында мин Танайны яклаячакмын!
Сәринә *(атылып ишек янына килә)*. Син әле шулаймыни?!
Юлдаш. Шулай, кем, кызым, Сәринә.
Бигәнәй *(Сәринәгә каршы якка, Юлдаш янына баса)*. Мин дә «шулай», кызым.
Сәринә *(ярсып ары-бире йөренә дә, туктап кала. Дәртсез)*. Мәрхүм әтием Байсар бинең теләген үтәп... Сарайгырның бәйсезлеген саклап калу өчен... мин риза Танайга кияүгә чыгарга.
Юлдаш. Менә монысы акыллы сүз, кызым!
Бигәнәй. Уф! Авызыннан тартып алгандай алдык акыллы сүзне. Тагын бер кабатла әле.
Сәринә *(дәртсез)*. Кабатлыйм: мин Танайга кияүгә чыгарга риза, Бигәнәй бикә, Юлдаш баба. *(Кискен рәвештә башын калкыта.)* Хәзер мине тыңлагыз!
Юлдаш. Тыңлыйбыз. Әйтәсе сүзләреңне әйтеп бетер, кызым.
Бигәнәй. Тыңламаган кая ул, тыңлыйбыз!
Сәринә. Мин Танайга кияүгә чыксам, мине амага итеп күтәрәчәксез. Булды бер.
Юлдаш. Күтәрәбез.
Бигәнәй. Күтәрәбез, кызым.
Сәринә. Мин амага булгач, ил-көн алдында мине якларсыз. Булды ике.
Юлдаш. Якларбыз.
Бигәнәй. Үз кызымны да якламагач, тагын кемне якларга?!
Сәринә. Карагыз аны, әйткән сүзегездән кайтасы булмагыз!
Юлдаш. Әйткән сүздән кайтмабыз.
Бигәнәй. Сүзебездә торырбыз, кызым.

Тышта тавышлар ишетелә.

Юлдаш. Халык җыелды. Ил-көнгә күренергә вакыт.
Сәринә. Мин әзер. Керсеннәр.

Бигәнәй бикә ишекне ача, халыкка керергә куша. Халык керә.

Сәринә *(түргә утырып, халыкка эндәшә)*. Мәрхүм Байсар бинең хатыны... сөекле әнием Бигәнәй бикә мондамы?

Җавап. Монда.

Сәринә. Сарайгырның акыл иясе, атаклы аксакал Юлдаш баба мондамы?

Җавап. Монда.

Сәринә. Минем батыр ир туганнарым мондамы?

Җавап. Монда.

Сәринә. Минем батыр кыз туганнарым мондамы?

Җавап. Монда.

Сәринә *(аягүрә баса)*. Сөекле әнием Бигәнәй бикә! Атаклы аксакал Юлдаш баба! Туганнар! Моннан кырык көн элек Сарайгыр ыруының курку белмәс олуг агасы... әнием Бигәнәй бикәнең яраткан ире... минем сөекле әтием кара җир астына керде.

Халык *(авыр ыңгырашып)*. Кара җир астына керде.

Сәринә. Курку белмәс батыр Байсар бине дошман угы үтермәде — үзара дошманлык, явызлык, кыргыйлык үтерде. Моны беркайчан онытмыйк, сарайгырлар.

Халык *(авыр ыңгырашып)*. Мәңге онытмабыз.

Сәринә. Үләр алдыннан мәрхүм әтием үзенең теләген әйтеп калдырды. Ул миңа Сарайгырның амагасы булырга боерды. Син — әнием Бигәнәй бикә! Син — атаклы аксакал Юлдаш баба! Мәрхүм Байсар бинең боерыгын яклыйсызмы?

Бигәнәй. Яклыйбыз, кызым.

Юлдаш. Яклыйбыз, кызым, Сәринә.

Сәринә. Сез — минем батыр ир туганнарым, сез — минем кыю кыз туганнарым... сез — ырудашлар... мәрхүм Байсар бинең боерыгын яклыйсызмы?

Бераз вакытка тынлык.

Тавышлар. Яклыйбыз, Сәринә! Мең яшә, амага!

Гомуми күтәренкелек, шау-шу. Сәринәне ак киезгә утырталар. Киезнең ике ягыннан ике ир кеше, ике ягыннан ике хатын-кыз тота. Тотучылар арасында Бигәнәй бикә белән Юлдаш баба да бар. Киезне югары
күтәреп түбән төшерәләр. Сәринә тәхеткә утыра.

Сәринә. Рәхмәт сиңа, әнием Бигәнәй бикә! Рәхмәт сиңа, Юлдаш баба! Рәхмәт сезгә, ырудашлар. Сарматларның Сарайгыр ыруы амагасы Сәринә сөйли. Мине тыңлагыз. Сезнең күбегезнең аталары, ирләре, уллары, кызлары ел саен, көн саен диярлек булып торган төрле яуларда башларын салдылар. Мин белгәндә генә дә Сармат даласында күпме сугыш булды! Күпме хатыннар тол калдылар, күпме балалар ятим калды! Безнең җиребез батыр ирләрнең, гүзәл кызларның кайнар каны белән сугарылган.

Халык *(авыр ыңгырашып)*. Дөрес, Сәринә.

Сәринә. Далада гомер-гомергә килә торган дошманлык, кыргыйлык сезнең ирләрегез, сезнең туганнарыгыз белән бергә... мәрхүм әтием Байсар би белән бергә минем сөйгәнем Барак угланны да гүргә салды. Дөрес, Барак угланны мин үзем үтердем. Безне туктаусыз үзара сугыштыра торган әшәке йола минем акылымны томалаган. Моны мин бик соңлап аңладым. Тагын мин шуны аңладым, сарайгырлар — җирдә беркайчан да толлар, ятимнәр, гарипләр булмасын дисәк, иң элек безгә үзара дошманлыкны бетерергә кирәк. Дошманлыкны бетерү өчен... яман йолаларны юкка чыгарырга кирәк!

Авыр тынлык.

Юлдаш *(ачулы, тыелып)*. Йола безгә ата-бабадан калган. Йола безнең какшамас терәгебез!

Тавышлар. Йола — изге! Йоланың яманы юк!

Сәринә. Йоланың яманы да бар, сарайгырлар! Яшь кызларны корал тотып яу чабарга мәҗбүр итә торган йола — яман йола! Хатын-кызны Тәңре җирдә нәсел калдыру өчен яраткан.

Хатын-кызлар. Дөрес, Сәринә! Дөрес, амага!

Сәринә. Сарайгырның бик күп яшь кызлары яуда катнаша алмыйлар. Шунлыктан аларның иргә чыгарга хаклары юк. Бу — кансыз йола!

Хатын-кызлар. Кансыз йола! Яман йола!

Сәринә. Бу йола күршеләр белән туктаусыз сугышып торуны таләп итә. Сугыш берәүләргә байлык китерсә, икенче берәүләргә үлем, хурлык китерә. Бүген без җиңсәк, иртәгә күршеләр җиңәчәк.

Халык. Дөрес, амага!

Юлдаш. Дөрес түгел, амага!

Сәринә. Ни дөрес түгел, Юлдаш баба?

Юлдаш. Күршеләр белән чагыштырганда, Сарайгырның халкы азрак. Шулай да бик күпләр бездән шүрләп торалар. Ник? Чөнки сарайгырларның ирләре генә түгел, кызлары да яу чаба. Шуңа да Сарайгыр, беркемгә буйсынмыйча, үз көнен үзе күрә. Инде килеп син, кызым Сәринә, әлеге йоланы юкка чыгарасың икән, ул чагында Сарайгыр көчсезләнәчәк.

Аксакаллар.

— Усал күршеләр безне таптап китәчәкләр!

— Сарайгыр юкка чыгачак!

Сәринә. Сарайгыр юкка чыкмаячак!

Юлдаш. Амин, шулай булсын. Шулай да син аңлатып бир. Кызларыбыз корал ташласалар, Сарайгыр гаскәре бермә-бер кимиячәк. Ничек итеп каршы торырбыз соң дошман явы килсә?

Сәринә. Моннан соң беркем Сарайгырга каршы корал күтәрмәячәк, Юлдаш баба!

Юлдаш. Син аны каян беләсең?

Сәринә. Мин үзем башлап беркайчан күршеләргә каршы яу чапмаячакмын.

Юлдаш. Шулай да булсын.

Бигәнәй. Ниятең изге, кызым.

Сәринә. Мин үзем беренче булып корал күтәрмәгәч, башкалар да безгә каршы яу чапмаячаклар.

Юлдаш. Шулай да чабарга теләсәләр?

Сәринә. Мин ничек тә эшне зурга җибәрмәскә тырышачакмын. Мин ничек тә дошманлыкны дуслыкка әйләндерергә тырышачакмын. Мин далада мәңге иминлек урнаштырачакмын!

Юлдаш. Көнеңне хатын-кызга калдырмасын икән Хода.

Бигәнәй. Хатын-кызга тел тидермә, Юлдаш баба. Ни күрсәк тә бергә күрербез. Мин кызым яклы.

Хатын-кызлар. Яклыйбыз, амага! Яклыйбыз!

Сәринә *(аксакалларга)*. Сез — аксакаллар?

Аксакаллар. Без... үзең беләсең... уйларга кирәк.

Сәринә *(Юлдашка)*. Син — Юлдаш баба?

Юлдаш *(төшенке)*. Мин инде карт кеше, балалар.

Сәринә. Син, Юлдаш баба, бер дә курыкма. Күршеләр безне көчле дип уйлыйлар. Уйласыннар! Без аларга берни сиздермәбез. Берничә елдан Сарайгыр даласын шат балалар тавышы күмеп китәр. Күршеләр аны-моны сизеп өлгергәнче, ир балалар үсеп җитәрләр, әниләре урынына сакка басарлар.

Юлдаш. Теләгең изге, кызым, амага. Тик менә...

Сәринә. Тик менә... Син миңа сүз бирдең, Юлдаш баба.

Юлдаш *(авырлык белән)*. Мин сине яклыйм, амага.

Аксакаллар *(җанланып)*. Яклыйбыз, амага! Бетсен яман йола!

Сәринә. Шулай итеп, Сарайгырның яшь кызларын корал тотып яуда катнашырга мәҗбүр итә торган йоласын юкка чыкты дип исәплибез.

Аксакаллар. Амин, шулай булсын.

Бигәнәй *(Сәринәгә)*. Без синең теләкне үтәдек, инде син безнең теләкне үтә.

Юлдаш. Барысы да ишетсен — әйт кычкырып безнең теләкне.

Сәринә. Сөекле әнием Бигәнәй бикә! Атаклы аксакал Юлдаш баба! Сарайгырлар! Мин — Сарайгырның амагасы Сәринә... моннан унсигез ел элек мәрхүм әтием Байсар би шүнәкләрдән яулап алып кайткан... үз баласы кебек итеп тәрбияләп үстергән Танайга кияүгә чыгарга риза.

Бигәнәй. Атаң мәрхүмне искә алган бу изге көндә... Исән булса, ул да сөенер иде. *(Күз яшьләрен сөртә.)*

Юлдаш. Инде күңелем тыныч — Сарайгыр исән калыр. Ата-баба рухы мәңге онытылмас.

Аксакаллар. Изге эш — яклыйбыз! Сарайгыр таркалмас!

Сәринә *(Танайны эзләп як-ягына карана. Күренмәгәч, халык ягына карап)*. Танай, син мондамы?

Барысы да, Танайны эзләп, як-якларына каранالар. «Танай кая?» «Танай юк!» дигән тавышлар ишетелә. Сәер тынлык, гомуми аптыраш.

Бигәнәй *(ашыгып)*. Җәликә! Мамиха! Барыгыз тиз генә Танайны эзләп табыгыз. Әйтегез — хәзер үк килеп җитсен!

Пәрдә ябыла.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Бигәнәй бикә ялгыз. Ул еракка карап уйга калган. Еракта күңелле шау-шу, күтәренкелек.

Бигәнәй. Кемнәр килеп кемнәр китми бу дөньядан... Кичә — бар, бүген — юк.

Юлдаш керә.

Юлдаш. Исәнме, кем, килен.

Бигәнәй. Исән әлегә, Юлдаш баба.
Юлдаш. Моңаясыңмы, килен?
Бигәнәй. Моңаям. Менә шушы вакытта, кояш кичкә авышканда моңаям. Никтер мәрхүм Байсарның миңа үпкәсе бардыр кебек. Сезгә, исәннәргә рәхәт, безгә — үлеләргә бик кыен дип әйтәдер кебек.
Юлдаш. Исәннәргә дә бик үк җиңел түгел, килен.
Бигәнәй. Түгел, Юлдаш баба. Кайда рәхәттер — белгән юк.
Юлдаш. Минем дә менә тынычлыгым качты. Сарайгырда хәзер көн дә бәйрәм, көн дә туй.
Бигәнәй. Бу арада туйлар күбәеп китте шул.

Юлдаш белән Бигәнәй, тын калып, ерактагы күңелле шау-шуны тыңлап торалар.

Юлдаш. Яшьләрнең күңел ачуларын күрдемме, эчем поша башлый.
Бигәнәй. Картаябыз, яшьләрне яратмыйбыз, Юлдаш баба.
Юлдаш. Юк, килен, картлыктан гына түгел — яшьләрнең гамьсезлегенә, аңсызлыгына эчем поша. Бүген күңелле булса, аларга шул җиткән. Гел менә ниндидер бәла-каза булыр кебек.
Бигәнәй. Бәла аяк астында.
Юлдаш. Ниме соң, андый-мондый хәбәр юкмы?
Бигәнәй. Танайны әйтәсеңме?
Юлдаш. Шуны инде, шуны.
Бигәнәй. Юкка чыкты безнең Танаебыз. Нәрсә уйларга да белгән юк. Эзләргә җибәргән кешеләребез дә кайтып җитмәде.

Таяк «ат»ын кыйный-кыйный Малай керә.

Малай. Сөенче! Киләләр! Кайталар!
Бигәнәй *(өйгә кереп барган җиреннән туктап кала).* Кем кайта, балам?
Юлдаш. Бу вакытта кем генә булыр икән ул?
Малай. Әнә тыңлагыз әле.
Тыңлыйлар. Еракта сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы ишетелә.
Юлдаш. Берни ишетмим.
Малай. Һи, шуны да ишетмәгәч!
Бигәнәй. Югалган Танай улым кайтамы соң әллә?
Малай. Кайталар! Киләләр! Сөенче! *(Чыга.)*

Мамиха керә.

Мамиха. Бикә! Юлдаш баба! Илчеләр килә!

Өйдән Сәринә чыга.

Сәринә *(Мамихага)*. Кемнәр килә дисең?
Мамиха. Илчеләр килә, амага.
Сәринә. Белмәдеңме — каян, кемнән икән?

Җәликә керә.

Җәликә. Амага! Сәринә! Баспурдан илчеләр килгән.
Бигәнәй. Сатир патшаданмыни?
Юлдаш. Баспурлардан безгә илчеләр килгәне юк иде — хәерлегә булсын, балалар.
Сәринә *(Җәликә белән Мамихага)*. Барыгыз, каршы алыгыз.

Мамиха белән Җәликә чыга. Сәринә шунда калку урынга утыра. Бераздан Җәликә белән Мамиха һәм Филеб керә. Филеб янында бер-
ике баспур кешесе.

Филеб *(Сәринәгә якынрак килә, бил бөгә)*. Баспур патшасы Сатирның өлкән улы Филеб синең алда баш ия, бөек амага.
Сәринә. Исән-имин минем җиремә, урдама килеп җитүең белән котлыйм сине, Сатир патшаның өлкән улы Филеб.
Филеб. Илең имин булсын, терлек-туарың көр булсын, халкың бай булсын, бөек амага.
Сәринә. Амин, шулай булсын.
Бигәнәй. Яхшы сүзләрең үзеңә изгелек булып кайтсын.
Юлдаш. Шулай булсын, балалар.
Сәринә. Бик ерактан килгәнсең, Сатир патша улы. Нинди җилләр ташлады сине безнең бу дала якларына?

Филеб. Сармат сарайгырларының бөек агасы Байсар бинең үлеме турындагы күңелсез хәбәр безнең Баспур җирләренә дә барып җитте. Байсар бинең үлеме Сатир патшаның күңеленә кара кайгы булып ятты. Үзенең кайгысын белдерү өчен әтием Сатир патша мине сиңа илче итеп җибәрде, бөек амага.

Сәринә. Әтиебез олуг Байсар бинең үлеме безнең үзебезгә дә аяз көнне яшен суккан кебек булды. Сарайгырларның кайгысын уртаклашкан өчен Сатир патшага миннән рәхмәт әйтерсең, илче.

Филеб. Тагын шул, бөек амага: Сатир патша сине Сарайгыр тәхетенә утыруың белән котларга кушты, синең үзеңә озын гомер, байлык, көч-куәт теләде.

Сәринә. Сатир патшаның изге теләкләре өчен миннән аңа шулай ук рәхмәт әйтерсең, илче.

Бигәнәй. Рәхмәт инде Сатир патшага — бигрәк олылаган безне.

Юлдаш. Бай булсын Сатир патша.

Филеб. Байсар би исән чакта, без, баспурлар, сарайгырлар үзара дус-тату яшәдек. Сатир патша киләчәктә дә сарайгырлар белән туганнарча дус яшәргә дигән теләк белдерде.

Сәринә. Сарайгырлар да баспурлар белән элеккечә дус-тату яшәргә телиләр.

Бигәнәй. Баспурлар белән барышып-килешеп яшәргә язсын, Тәңрем.

Филеб. Мәрхүм Байсар би миңа сау-сәламәт, таза булып күренгән иде. Аның үлеменә без бик аптыраштык.

Сәринә. Баспурдан кайтканда аларга юлбасарлар чыккан. Шунда әтиемә агулы ук тигән.

Филеб. Нинди зур кайгы! Юлбасарлардан беркайда да качып котылып булмый бу дөньяда.

Сәринә *(көлеп)*. Сүзең дөрес, илче. Син миңа бик таныш бер юлбасарны хәтерләттең.

Филеб *(куркып битен каплый)*. О, Зевс! Мин... юлбасарга охшаганмынмы?!

Сәринә. Нәкъ үзе. Суйган да каплаган!

Бигәнәй. Кызым, Сәринә, олы кунакның йөзен ерту килешмәс.

Сәринә. Ул чыннан да мәрхүм Баракка охшаган, әнием.

Бигәнәй. Авыр юлдан соң илчеләрнең ял итәселәре, ашыйсылары-эчәселәре киләдер.

Сәринә. Шулай шул, әнием. Син анда зурлап аш-су әзерләргә куш әле.

Бигәнәй. Ярар, кушармын. *(Кузгала.)*

Юлдаш. Мин дә китим әле.

Чыгалар.

Сәринә. Мин синең хәтереңне калдырдым, ахрысы, илче?

Филеб. Хәтер калырга мөмкинме соң сиңа, бөек амага?!

Сәринә. Ялгыш әйтелгән сүздән генә түгел, кырын күз карашыннан да хәтер кала кайчагында.

Филеб. Минем сиңа хәтерем калмады, Сәринә. Минем күзем томаланды! Мин сине болай уктыр дип уйламаган идем.

Сәринә *(көлеп)*. Нишләп әле син минем турыда уйладың, илче?

Филеб. Синең турыда ишеткәннән бирле... гел сине уйладым.

Сәринә. Баспурда мине күргән-белгән кеше юк. Кем әйтте сиңа минем хакта?

Филеб. Син ул кешене беләсең. Ул миңа үзенең уңышсыз мәхәббәте турында сөйләде.

Сәринә. Танаймыни?!

Филеб. Танай. Без аның белән дуслашып киттек. Байсар бинең үлеме турында да ул әйтте. Шуннан соң менә җыендым да, илче булып синең катыңа килдем.

Сәринә. Сине монда Сатир патша җибәрмәдемени алайса?

Филеб. Мин теләдем, ул җибәрде. Синең чибәрлегең, батырлыгың турында күбрәк белгән саен, миндә сине күрәсе килү теләге туа барды.

Сәринә. Шулай да син кем: илчеме, Сатир патшаның улы гынамы?

Филеб. Илче дә, гашыйк та.

Сәринә. Син бик кыю күренәсең, Сатир патша улы.

Филеб. Безнең нәселдә кыюсызлар юк, бөек амага. Син әле генә мине үзең белгән ниндидер юлбасарга охшаттың. Син хаклы, ахрысы — бик ерак бабаларым минем диңгез юлбасарлары булган.

Сәринә. Син бераз гына мактанчык та бугай, диңгез юлбасары.

Филеб. Бераз гына түгел, бик зур мактанчык мин, Сәринә!

Сәринә *(көлә)*. Нинди күңелле кеше икәнсең син, илче!

Филеб. Ләкин минем башка мактанчыкларга охшамаган бер ягым бар. Башка мактанчыклар бары үзләрен генә мактасалар, мин йә ата-бабамны, йә хатын-кызны мактыйм.

Сәринә. Һөнәрләрең күп икән синең, мактанчык Филеб. Ата-бабаңны мактап син бер һөнәреңне күрсәттең, башка һөнәреңне әлегә күрмәдек.

Филеб *(күтәренке).* Тудыручы бөек Ана сиңа Афродита гүзәллеген, Афинаның батырлыгын биргән. Искитмәле күркәмлегең белән безнең кебек ир кешенең зиһенен буташтыру өчен изге Зевс сине алтын түргә утыртып куйган.

Сәринә. Синең чыннан да зиһенең буталган, ахрысы, илче Филеб. Түргә мине баспурлар Алласы Зевс утыртмады. Тәңренең боерыгын, мәрхүм әтиемнең теләген үтәп, мине монда ил-көн утыртты.

Филеб. Сарайгырның сылу амагасы! Синең урының дәрәҗәле, ләкин белүемчә, син әле дә ялгыз.

Сәринә. Минеке кебек дәрәҗәле урында ялгыз утыру хәерлерәк, илче Филеб.

Филеб. Бөек амага! Мин сиңа моннан да дәрәҗәлерәк урын тәкъдим итмәкче булам.

Сәринә. Минем өчен Сарайгыр тәхетеннән дә дәрәҗәлерәк урынның булуы мөмкин түгел.

Филеб. Сарайларымны, бүлмә тулы алтын-көмешләремне — барлык байлыгымны таудай итеп синең аяк астына өеп куярга әзермен, Сәринә!

Сәринә. Мин — дала кызы. Аяк астының тигез булганын яратам.

Филеб. Көннәрдән бер көнне... озакламый Баспур тәхетенә Филеб патша утырачак. Филеб патша Баспур җирләрен Сарайгыр җирләренә кушса, Сәринәнең байлыгына кызыкмаган кеше калмаячак. Ал мине үзеңә кияү итеп, Сәринә!

Сәринә *(тора, йөренә, тынычсыз)*. Синең кебек сораучылар булмады түгел, булды. Ялындылар, янадылар. Синең кебек тау-тау алтыннар, көтү-көтү маллар вәгъдә иттеләр. Берсе ялынмады да, янамады да, байлык та вәгъдә итмәде. Мин аны үзем яраттым. Ләкин ул мине алдамакчы булды, шуның өчен мин аның... башын чаптым. *(Тәхеткә утыра, кискен.)* Юк, Филеб патша, син миңа кияү була алмыйсың.

Филеб. Ник, Сәринә?

Сәринә. Син яшь, чибәр. Ләкин син — чит халыктан. Син — баспур, мин — сармат, син — су, мин — ут. Минем кендегем Сарайгырга береккән... халкыма, ыруыма. Мине моннан ...бу биек урыннан беркем, берни кузгата алмый.

Филеб. Алай икән шул...

Бигәнәй керә.

Бигәнәй. Олы кунакны ялыктырма, кызым. Табын әзер.

Сәринә. Әни?! Күңелле сүз ишетәсең киләме?

Бигәнәй. Күңелле сүзләрне безгә сирәк ишетергә туры килә.

Сәринә. Танай исән икән бит, әни!

Бигәнәй. Танай?! Кайда ул минем Танай улым?

Сәринә *(Филебкә)*. Илче Филеб, Танайны син кайда, ничек күрдең?

Филеб. Байсар би Баспурга терлек-туар алып килгәч, беренче мәртәбә мин аны шунда күрдем, бөек амага.

Сәринә. Икенче мәртәбә кайда күрдең?

Филеб. Икенче мәртәбә ул Баспурга качып килгәч күрдем. Очрашкач әйтте: Сарайгырдан киттем, диде, анда мине чит күрәләр, диде.

Бигәнәй. И бала, бала.

Филеб. Ул тагын шуны да әйтте: исән чагында Байсар би мине үзенең варисы дип белде, үләр алдыннан баш тартты, диде.

Сәринә. Монысы дөрес түгел.

Бигәнәй. Бигрәкләр хурланган икән шул, балакаем.

Филеб. Мин аны кызгандым, кораллы сакчы итеп, үз яныма сарайга алдым.

Сәринә. Ул хәзер кайда?

Филеб. Ул минем белән килде, бөек амага.

Бигәнәй. Бу сөенечле хәбәрне Юлдаш бабаңа да әйтергә иде. Кая булды соң әле ул?

Юлдаш керә.

Сәринә. Гомере озын булыр әле — менә ул үзе!

Юлдаш *(шомлы, каушап-калтыранып)*. Кызым, Сәринә! Кем, килен, Бигәнәй бикә!

Бигәнәй. Без монда сиңа сөенечле хәбәр әйтмәкче булып торабыз,— синең анда нишләптер төсең качкан әле, Юлдаш баба.

Сәринә. Нәрсә булды, Юлдаш баба?

Юлдаш *(Сәринәгә, таләпчән)*. Кая безнең батыр ирләр, кая безнең сугышчан кызлар, амага?

Сәринә *(каушап)*. Туктале, сорау алмале син миннән, Юлдаш баба.

Юлдаш. Синнән сорау алыр вакыт җитте, амага! Котас би көчле, Котас бине син мыскыл иттең.

Бигәнәй. Котас бигә нәрсә булган тагын?

Юлдаш. Котас бигә берни булмаган. Безгә булыр. Анысы менә көн кебек ачык. Бетте Сарайгыр, бетте, балалар!

Сәринә. Кода булып безгә тагын Котас би киләмени, Юлдаш баба?

Юлдаш. Кода булып түгел, яу булып килә!

Сәринә. Яу булып?!

Бигәнәй. Башы аягы астына гына килгере икән!

Сәринә *(аягүрә баса, тәвәккәл)*. Бетмәс Сарайгыр, Юлдаш баба! Яуга каршы — яу! Кызларымны коралландырып, барлык ирләремне алып, Котас бигә каршы мин яуга чыгам.

Юлдаш. Күпме генә кызларыңны, ирләреңне җыя алырсың икән, амага?

Бигәнәй. Яшьләр күңел ача. Аларда яу кайгысы юк.

Юлдаш. Котас би Сәринә өчен килә. Безгә хәзер икенең берсен сайларга кала: син, кызым, Сәринә, яхшылык белән Котас бигә кияүгә чыгарга ризалык бирәсең яисә сугышып аны җиңәсең.

Сәринә *(Филебкә)*. Илче Филеб!

Филеб. Мин сине тыңлыйм, бөек амага.

Сәринә. Үзең белән синең күпме гаскәрең бар?

Филеб. Барлыгы биш йөз.

Сәринә. Сарайгырга каршы Котас би килә. Син кем яклы, Баспур патшасының улы?

Филеб *(уйланып)*. Син беләсең: мин монда сугышыр өчен килмәдем, бөек амага. Ләкин мин сине кыен хәлдә калдыра алмыйм. Мин... Сарайгыр яклы.

Бигәнәй *(җиңел сулап)*. Йа Аллам! Җыясы ризыкларыбыз, эчәсе суларыбыз бетмәгән икән әле.

Филеб. Ләкин минем сезгә бер үтенечем бар.

Сәринә. Нинди үтенеч?

Филеб. Әгәр мин Котас бигә каршы сугышсам... әгәр без аласларны җиңсәк... син миңа кияүгә чыгасың, бөек амага.

Бигәнәй. Баспурга, чит халыкка!

Сәринә. Мин риза.

Бигәнәй. Авызыңнан җил алгыры!

Юлдаш. Син Танайга ярәшелгән! Танайдан башкага чыксаң, сине җир йотачак, амага!

Сәринә. «Талак» әйтеп, Танай миннән баш тартса, мине җир йотмаячак, Юлдаш баба.

Юлдаш *(мыскыл белән)*. Кая соң ул сиңа «талак» бирәчәк Танай?

Филеб. Танай монда. Керсенме?

Сәринә. Керсен.

Филеб *(үз кешесенә)*. Танайны чакыр.

Филебнең юлдашы чыга һәм бераздан Танай белән керә. Танай баспур сугышчысы киемендә.

Танай. Исәнмесез, әнием Бигәнәй бикә, Юлдаш баба. Исәнме, Сәринә.

Бигәнәй *(Танайга таба омтылып)*. Танай, улым!

Юлдаш *(исе китеп)*. Нәрсә соң бу? Өнме, төшме? Танай улым түгелме соң чынлап та?!

Сәринә. Танай! Илгә яу килә, Котас би килә. Ул үзенең үтерелгән Барагы өчен миннән канлы үч алмакчы була. Сарайгырның киләчәге синең кулда. «Талак» бир миңа, Танай!

Бигәнәй. «Талак» бир, улым!

Юлдаш. Коткар Сарайгырны!

Танай *(тәкәббер)*. Сез мине бик нык рәнҗеттегез, сез мине читкә тибәрдегез. Үзегезгә кыенлык килгәч, хәзер миннән «талак» сорыйсызмы?

Юлдаш. Элеккеләрне оныт, Танай улым. Илеңне, халкыңны уйла. Баспурлар белән бергәләп Котас бине җиңсәк, без сине Сарайгырның агасы итеп күтәрербез.

Бигәнәй. Танай улым ага булыр.

Сәринә. Котас бине җиңгәнне көтәсе дә юк. Ул мине үзеннән азат итсә, без аны хәзер үк ага итеп күтәрәбез, баспурлар белән бергәләп, Котас бигә каршы яуга ташланабыз. *(Филебкә.)* Син кире уйламадыңмы, Филеб?

Филеб. Мин әйткән сүземнән кире кайтмадым, сөеклем Сәринә.

Танай. Болай булгач мин каршы түгел Сарайгырның агасы булуга. Тыңлагыз: Сәринәгә миннән талак, талак, талак!

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Бигәнәй бикә ялгыз. Ул еракка карап уйга калган. Каяндыр җиңелчә шау-шу, җыр авазлары ишетелеп китә.

Юлдаш керә.

Юлдаш. Исәнме, кем, килен.

Бигәнәй. Исән әлегә, Юлдаш баба.

Юлдаш. Моңаясыңмы, килен?

Бигәнәй. Моңаям да, уйланам да. Менә шушы вакытта, кояш кичкә авышканда моңаям. Шуны әйтәм әле, Юлдаш баба, Байсар бинең күңеле нишләптер гел шул якка тартты. Баспур ягына. Шулар белән аралашып йөргән булды. Әнә, Сарайгырны хәзер баспур каплап алды.

Юлдаш. Каплап алды, килен.

Бигәнәй. Болай булыр дип күз алдына да китермәгәндер, мәрхүм.

Юлдаш. Китермәгәндер, килен.

Бигәнәй. Үзе менә кара җир астында ята.

Юлдаш. Барыбызның да төп йорты — кара җир астында.

Бигәнәй. Шулаен шулай да, кызым Сәринә дә шул якта бит әле, Юлдаш баба.

Юлдаш. Сәринә китте — дала котсызланып калды.

Бигәнәй. Бар терәгем Сәринә булган икән...

Юлдаш. Синең генә түгел, безнең барыбызның да терәге Сәринә булган. Соңлап булса да, менә шуны аңладым мин, килен.

Бигәнәй. Аңлавын аңладык та, аңлаудан ни файда?

Юлдаш. Башта ук безгә барлык баспурларны кире борып, үз илләренә кайтарып җибәрергә кирәк булган.

Бигәнәй. Танай нык торды бит, калдырабыз, диде. Котас би яңадан яу белән килә-нитә калса, кирәк булырлар, диде.

Юлдаш. Шулай диде шул.

Бигәнәй. Без каршы килмәдек. Без Танайга ышандык.

Юлдаш. Ярар, тыңлале син мине, килен. Мин болайрак уйлыйм: көч сорап шүнәкләргә, Котас бигә кешеләр җибәрергә кирәк безгә. Күршеләр ярдәменнән башка без бу хурлыктан котыла алмабыз кебек.

Бигәнәй. Шулай да булсын. Ләкин син әйтмәдең: Сәринәне кая куясың, Юлдаш баба?

Юлдаш. Сәринә кияүдә. Аның эше катлаулы. Сәринәдән бигрәк безгә Сарайгырны, илне-көнне коткарырга кирәк.

Бигәнәй *(ныклык белән)*. Шүнәкләр дә, Котас би дә, баспурларны җиңсәләр дә, иң ахырда Сарайгырны үзләренә буйсындырырга тырышачаклар. Сарайгырны Сәринәдән башка беркем килеп коткармаячак, Юлдаш баба!

Юлдаш. Сүзең хак, кем, килен. Болай булгач иң элек безгә Сәринәне эзләп табарга кирәк. Кайтсын Сарайгырга. Алсын дилбегәне яңадан үз кулына!

Бигәнәй. Ул кайтканчы без үзебез дә йоклап ятмабыз.

Юлдаш. Ниткән йоклап яту ди ул?! Халык ачулы. Халыкны кузгату өчен бер сүз җитә хәзер.

Бигәнәй. Синең белән миңа да килмешәккә караган кебек карый башладылар.

Юлдаш. Карамыйча! Авыз йомып, Танайны, баспурларны яклап торгач, карарлар да шул.

Бигәнәй. Моннан соң авыз йомып тораммы соң! Сәринәм генә кайтсын. Утлы табага бастырабыз әле без аларны!

Танай керә. Аның янында ике баспур сугышчысы.

Танай. Исәнме, инәй. Исәнме, Юлдаш баба.

Бигәнәй. Исәнлеккә ис киткән, печәнлеккә ут киткән, улым.

Юлдаш. Исәнен исән дә, Танай улым...

Танай. Мин ага булгач та таралып беттегез дип әйтимме, яшеренеп ятасыз дип әйтимме... Кирәк чакта берегезне бер табып булмый.

Бигәнәй. Нишләп без синнән яшеренеп ятарбыз икән соң, улым Танай?

Юлдаш. Әйтсәм әйтим, кем, Танай улым, ага булып алгач та син үзең безне читләштердең.

Бигәнәй. Сиңа хәзер, улым, баспурлар якынрак.

Танай. Баспур патшасы Сатир сиңа кода туры килә, инәй.

Бигәнәй. Кодасын кода инде анысы.

Юлдаш. Сатир патша кода дип монда баспурларны түргә утыртырга сиңа беркем ирек бирмәгән.

Танай *(тәкәббер)*. Мин — ага. Кемне түргә, кемне ишек төбенә утыртырга кирәклеген үзем беләм.

Юлдаш. Белүен беләсеңдер дә... сарайгырлар синнән йөз чөерә шуңа күрә. Өйләрен, мал-туарларын алып, төркем-төркем булып күршеләргә качалар.

Танай. Сез, бәлки, үзегез котыртасыздыр аларны күршеләргә качарга, инәй?

Бигәнәй. Башыма тай типмәгән әлегә.

Юлдаш. Сарайгырның таркала баруын нишләп син бездән күрәсең әле, Танай улым? Сораусыз-нисез ярлыларның мал-туарын кем тартып ала? Син! Кызларга, яшь хатыннарга кем кул суза? Син!

Танай. Мин түгел, баспурлар.

Юлдаш. Алай булгач, кайтарып җибәр баспурларның берсен калдырмыйча үз илләренә!

Танай. Сәринә Филебне безгә ярдәмгә дип җибәргәч, баспурларны колач җәеп сез каршы алдыгыз бит!

Бигәнәй. Ялгыштык, улым, ялгыштык.

Танай. Юк, ялгышмадык, инәй, Филеб — безне коткаручы, баспурлар — минем таянычым.

Юлдаш *(аптырап)*. Алайса, без кем соң сиңа... сарайгырлар кем?

Танай. Бер таянычым — баспурлар, икенче таянычым — сез... инәй, Юлдаш баба.

Юлдаш. Бер дә безгә таянганың сизелми, кем, Танай улым.

Бигәнәй. Без әле кирәкмени сиңа?

Танай. Кирәк. Күршедә генә Котас би булганда, миңа сарайгырлар да, баспурлар да кирәк.

Юлдаш *(килешүчән)*. Сарайгырның... безнең иминлекне кайгыртуың яхшы анысы, кем, Танай улым. Шулай да тыңлале син мине: олы яу узды, Котас би җиңелеп кайтып китте. Котас би безнең баспурлар белән туганлашканны белә — безгә каршы корал күтәрүдән ул хәзер тыелып торачак. Рәхмәт әйтеп, яхшылап озатып җибәрергә кирәк баспурларны.

Бигәнәй. Әйе шул, әллә ничек кенә булды. Филеб киявемне рәтләп кунак та итә алмадым. Берәр атна сыйлыйк та, озатып куйыйк үз илләренә, улым. Алар китсә, үзеңә дә тынычрак булыр.

Танай *(ягымлы)*. Мин үзем дә менә шуның өчен киңәшергә дип, сезне эзләп килгән идем, инәй.

Бигәнәй. Киңәшик. Киңәшле ил таркалмас.

Танай. Башта ук шуны әйтим: минем сезгә үпкәм бар, инәй... Юлдаш баба.

Бигәнәй. Әле булса онытып бетермәдеңмени безгә булган үпкәңне, улым?

Юлдаш. Ага булам дидең — булдың. Тагын нинди үпкәң калды безгә?

Танай. Баспурлар мине генә түгел, сезне дә Котас бидән коткардылар. Шулай да сез миңа да, баспурларга да сыртыгыз белән торасыз. Мин инде бер айдан артык аларны үз исәбемнән ашатам-эчертәм, кунак итәм. Сез ничек тә читтә калырга тырышасыз.

Бигәнәй. Без беркая да китмәдек — үз урыныбызда, үз җиребездә яшәп ятабыз.

Танай. Ләкин Сарайгыр агасы Танай би урдасына килеп тә әйләнмисез, инәй!

Юлдаш. Яхшылап чакырсаң, барырбыз, кем, Танай улым.

Танай. Инәй! Син әле генә Филеб киявемне берәр атна кунак итәр идем, дидең.

Бигәнәй. Дидем, улым. Үз киявемне бер атна кунак иткәннән генә ярлыланмам, Алла боерса.

Танай. Биш йөз кешелек кунакны сыйларлык кына чамаң бар инде синең, инәй. Менә Юлдаш баба да читтә калмас.

Юлдаш. Биш йөз кешелек кунак?! Бөтен бер чирү!

Танай. Булса була инде, Юлдаш баба. Тиешенчә кунак итәрбез дә, җайлап кына озатып куярбыз. Әнә бара юллары! Баспурлар киткәч, гөрләтеп яшәрбез элеккечә, үзебезчә!

Бигәнәй *(сөенеп)*. Шулай шул, улым. Күршеләргә качкан кешеләребез дә кайтыр алар киткәч. *(Юлдашка.)* Бер атнага гына түзәрбез, Юлдаш баба. Танай улым шулай дип торганда... Итем-сөтем җитәрлек. Үзем сыйлармын. Килсеннәр, Танай улым!

Юлдаш. Кунак сыйлауга мин дә каршы түгел анысы. Ярый ла кунак булгач та кайтып китсәләр!

Танай *(ягымлы)*. Китәрләр, Юлдаш баба, китәрләр. Филеб алдында йөзгә кызыллык китерәсе дә килми бит. Баспур булса да, кияү бит ул безнең. Шулкадәр ерак җирдән арып-талып килсеннәр дә, безнең өчен кан койсыннар да, ничек итеп кисәк кенә: барыгыз кайтып китегез, дип әйтәсең аларга?

Юлдаш. Ахыры хәерле булсын, балалар. Чакыр кунакларыңны.

Танай. Миңа сездән шундый сүз генә кирәк тә. *(Чыга.)*

Тынлык. Бигәнәй бикә белән Юлдаш баба чыга. Бераздан якынлашып килгән нindидер гөрелте ишетелә. Ара-тирә өзек-өзек кычкырган тавышлар ишетелеп китә. Өйдән ашыгып Бигәнәй чыга.

Бигәнәй. Кем кычкырды ул? Җәликә! Мамиха! Кая олагып беттегез барыгыз да?

Җәликә керә. Кемнәндер качып ул бикәгә якынлаша. Аның артыннан баспур сугышчысы куып килә.

Җәликә. Бикә! Коткар! *(Бикәгә сыена. Исерек баспур сугышчысы аны әләктереп ала.)*

Бигәнәй *(баспур сугышчысына)*. Кит моннан, оятсыз!

Баспур сугышчысы бикәгә ташлана.

Бигәнәй. Син әле шулаймыни?! *(Билендәге кыныдан хәнҗәрен ала, баспур сугышчысына кадый, сугышчы егыла.)*

Җәликә. Менә шул кирәк аларга!

Бигәнәй *(тынычлана алмый)*. Минем җиремдә!.. Минем ашымны ашап!.. Минем кунагым булып!..

Мамиха керә.

Мамиха *(сүзен рәтләп сөйли алмый)*. Бикә! Бикә!

Бигәнәй. Тагын ни булды?

Мамиха *(бикәнең күкрәгенә каплана)*. Безнең ирләрне, безнең кызларны...

Бигәнәй *(ачуланып)*. Аңлатып сөйлә!
Мамиха. Кунаклар... баспурлар... кияү... Безнең ирләрне, безнең кызларны... *(Жылый.)*
Бигәнәй *(ярсып)*. Җебегән!
Җәликә. Мин дә күрдем, бикә! Исерек баспурлар тиктомалга безнекеләргә бәйләнә башладылар. Анда талаш, ызгыш, бикә!
Бигәнәй. Акылдан шаштыгызмы әллә — ни сөйлисез?!
Җәликә. Юлдаш баба арага кермәкче булган иде — Танай үз кулы белән чәнчеп үтерде.
Бигәнәй. Уф Алла! *(Хәлсезләнеп урынга утыра.)*

Ерактагы ямьсез тавышлар көчәя төшә.

Мамиха. Әнә алар!
Җәликә. Монда киләләр, бикә!

Филеб белән Танай керә. Алар сугышчы киемендә.

Филеб *(Танайга)*. Котлыйм сине, Танай. Синең батырлыгың, осталыгың аркасында сарматларның Сарайгыр ыруы тулысынча азат ителде. Синең тырышлыгың турында мин Сатир патшага әйтермен.
Танай *(Филеб алдында баш ия)*. Рәхмәт яусын сиңа, олуг Филеб. Әтиең Сатир патшаның яхшылыгын мәңге онытмам.

Ике баспур сугышчысы керә. Арттан килеп Бигәнәйне тотып алалар, кулларын каералар.

Филеб *(мыскыл белән)*. О, Зевс! Сөекле Сәринәмнең сөекле әнисе Бигәнәй бикә түгелме соң син?
Бигәнәй *(Филебкә)*. Ашаган ашың тамагыңа таш булып утырсын. Үлгән чагыңда кулың-аягың тартышып, җан бирә алмый азаплан. Тфү! *(Йөзенә төкерә.)*
Танай. Нишләтергә боерасың бу тоткынны, олуг Филеб?
Филеб. Кызы Сәринә янына алып китсеннәр. Өенә ут төртегез. Бигәнәйне алып китәләр. Тавыш, шау-шу, җылаш.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Котас би урдасы. Өй эче. Вакыт кич. Уртада учак яна. Котас би белән Бикә ашап утыралар. Ашаучылардан читтә, ишек төбендә — сарайгыр качаклары Карт белән Кортка. Карт белән Кортка үзара сөйләшәләр.

Кортка. Тышта кеше бар инде әллә?
Карт. Җилдер ул.
Кортка. Җил күптән тынды.
Карт. Алайса, песидер.
Кортка. Песи кеше кебек ыңгырашамыни, карт дивана!
Карт. Песи булмаса, албастыдыр.
Кортка. Бу караңгыда ни калган албастыга ишек төбендә?
Карт. Ышанмагач, бар, чыгып кара.
Кортка. Карармын да шул, син чыкканны көтеп утырмам. *(Чыга. Бераздан кире керә.)* Би! Бикә! Анда кемдер бар. Котым алынды — йөрәгем ярыла дип торам.
Карт. Калган синдә ярыла торган йөрәк.
Бикә. Кем дисең?
Кортка. Ишек төбендә ята. Теләнче микән, сарайгыр микән.
Бикә. Бетмәс анда теләнчеләр, сарайгырлар. Куалап җибәр.
Кортка. Куаладым — китми. Хәлсезләнгән.
Бикә. Әйтегез берәрсенә... өстерәп алып китсеннәр арырак.
Кортка. Үләр ул алай.
Бикә. Үлмәгәе! *(Кычкыра.)* Җәликә! Мамиха!

Ашыгып-кабаланып Җәликә белән Мамиха керә.

Җәликә. Бикә, син чакырдыңмы?
Мамиха. Бикә, без монда.
Бикә. Барыгыз әле тышка чыгып карагыз — анда ниндидер теләнче ята ди.
Котас *(сөяк кимерүеннән туктап)*. Башта карагыз — кем? Коралы юкмы? Яшьме, картмы... ирме, хатын-кызмы?..
Җәликә
Мамиха } Карарбыз, би.

Кортка. Карадым, би. Үзе яшь, үзе хатын-кыз затыннан.
Бикә *(ачулы)*. Илтеп ташлагыз берәр чокырга!
Җәликә
Мамиха } Ташларбыз, бикә.
Котас. Монда алып керегез!
Кортка. Керербез, би.

Чыгалар. Беркадәр вакыттан барысы да кире керәләр. Җәликә белән Мамиха, ике яктан култыклап, Сәринәне тотканнар. Сәринә хәлсез,
өтәләнгән. Аны танырлык та түгел.

Кортка. Менә ул, би.
Карт. Аягында көчкә тора. Шулай да йөрәге яхшы тибә.
Кортка. Әнә карт дивананың да теле ачылды.
Карт. Үзе яшь, үзе бик чибәр күренә, би.
Бикә *(ашавыннан туктап, Сәринә каршысына килә)*. Әдәмме, җенме син?
Сәринә. Мин... мин...
Котас *(табакка салып сөяк-санак бирә)*. Мәгез, ашасын, эчсен.

Җәликә белән Мамиха Сәринәне аерым табын янына утырталар. Карт
белән Кортка аңа ашарга-эчәргә китерәләр. Сәринә ашый, эчә.

Җәликә *(Сәринәне таный, куркып кычкырып җибәрә)*. Әнекәем!
Мамиха *(шулай ук таный, Җәликәнең авызын томалый)*. Ш-ш-ш!
Карт *(үзалдына)*. Әллә күземә күренә инде?!
Кортка. Тфү, тфү! Ул түгелдер.
Бикә *(тынычсыз)*. Бием! Йокларга вакыт. Иртәгә торасы да бар.
Котас *(майлы авыз-битләрен сөрткәләп, тук кыяфәт белән беравык кәефләнеп утыра)*. Каяле, китерегез әле монда. Инде хәл кергәндер.

Җәликә белән Мамиха, икесе ике яктан култыклап, Сәринәне аягына бастыралар һәм Котас би каршысына китерәләр. Икесе дә тавышсыз
гына җылыйлар.

Сәринә. Менә мин... Сәринә...
Котас *(урыныннан сикереп тора)*. Сәринә?!
Кортка *(Сәринәне кочаклый)*. Сәринә балакаем!
Карт. Кызым, Сәринә! *(Кочаклый.)*
Бикә. Шул булмыйча, шул! Ташландык! Сөйрәлчек!
Җәликә. Җыгылганны түбәләмиләр, бикә!
Мамиха *(Сәринәне Бикәдән гәүдәсе белән каплап)*. Бикә! Авыр сүз әйтмә безнең Сәринәгә!
Бикә *(тузынып)*. Килмешәкләр! Тамагыгыз туйдымыни?! Телләшә башладыгызмыни?! Ат койрыгына тактырам әле мин сезнең барыгызны да!
Котас *(Бикәне читкә этәреп)*. Бар әле, бар, йокларга ят. Иртәгә торасың да бар.
Бикә *(шыңшып)*. Йокылар качты болай булгач. *(Чыга.)*

Җәликә белән Мамиха да, картлар да чыгалар.

Сәринә *(табактагы калдык-постыкларны ашаган арада әкрен генә сөйләнә)*. Гаҗәпләнмә син, Котас би. Сәринә мин. Дүрт тәүлек буена берни капмадым. Төнлә кайттым, көндез качып яттым...
Котас *(мыскыл белән)*. Син бит җиңүче! Мине җиңгән кеше. Нишләп алай минем табакны яларга кайтасы иттең?
Сәринә *(тыштан тыныч, гамьсез, эчтән — киеренке)*. Синең табакны яларга кайттым, Котас би. Гаҗәпләнмә син. Кеше булсаң, андый гына нәрсәләргә исең китмәсен.
Котас. Таный башладым мин сине, теләнче хатын. Син чыннан да минем Барагымның башын чапкан Сәринә бугай.
Сәринә. Шул үзе, Котас би. Син әле аның әнисен дә беләсеңдер. Бигәнәй бикәне.
Котас. Белмәгән кая ул!
Сәринә. Менә шул Бигәнәй бикә белән Сәринәне Сатир патша төрмәгә яптырды. Бигәнәй бикә акылдан язды, Котас би. Шунда төрмәдә җан бирде.
Котас *(авыр сулап)*. А-а-а. Яхшы күңелле хатын иде. Урыны оҗмахта булсын.
Сәринә. Каравылчыларны алдап... качтым мин, Котас би. Сатир патшадан, баспурлардан качтым.
Котас. Шулай да нишләп минем бусагама килеп җыгылдың — шунысы аңлашылмый.
Сәринә. Мин далама, халкыма кайттым.

Котас. Синең инде далаң да, халкың да юк, сатлык Сәринә!

Сәринә. Син миңа теләсә нинди сүз әйтә аласың, тик миңа «сатлык» кына димә, Котас би.

Котас. Син даланңы, халкыңны ташлап, чит халыкка, дошман халыкка биреледең. Сатлык булмыйча, кем соң син?!

Сәринә. Сатир патшаның улына кияүгә чыгып мин үз халкымны талаудан, хурлыктан коткарам дип белдем, уйладым.

Котас. Син аңа бары талау, хурлык кына китердең!

Сәринә. Барысы өчен дә җәзасын татыдым инде мин, Котас би.

Котас. Миңа качып чыккан сарайгырларны кире үзеңә алырга җыенмыйсыңдыр ич син, Сәринә бикә?

Сәринә. Бирсәң, каршы килмәм.

Котас. Борыным төште дисең инде, ә? Хәтерлисеңме, теге вакытта син бөтенләй башкача сөйләшкән идең?

Сәринә. Мин барысын да белеп, уйлап килдем. Син минем кичәге дошманым. Шулай да бөтен далада, бөтен дөньяда синнән якын беркемем юк минем, Котас би.

Котас. Якын кешегә бүләк алып киләләр. Син ни алып килдең?

Сәринә. Мин сиңа ике башның берсен алып килдем, Котас би.

Котас. Каяле, мондамы ул?! Күрсәт миңа Барагымның бәхетсез башын!

Сәринә. Ул тегендә калды. Аны барып яулап аласы бар.

Котас *(үзгәреп, Сәринәгә таба омтылып)*. Төшендем мин сине, Сәринә! Мин ант итәм... хурланган яшьлегең өчен, тапталган җирең-суың өчен, коллыкка төшкән халкың өчен үч алырга мин ант итәм! *(Сәринәне кочмакчы була.)*

Сәринә *(чигенә)*. Синнән шундый сүз ишетү — минем өчен зур бәхет, Котас би.

Ишек артында шау-шу. Артлары белән чигенә-чигенә Җәликә белән Мамиха, Карт белән Кортка керә.

Кортка *(ярым пышылдап)*. Шауламагыз, биебез йоклый.

Котас *(ишек ягына кычкырып)*. Кем бар анда? Мин йокламыйм.

Җәликә. Би! Алар бик күп!

Котас. Нәрсә кирәк аларга?

Мамиха. Алар Сәринәне күрмәкче булалар, би.

Котас. Керсеннәр.

Ашыгып, бер-берсен узышып, ирләр, хатын-кызлар керә.

Тавышлар.

— Сәринә кайткан диләр. Дөресме шул?

— Сәринәне күрәсебез килә!

— Сәринә белән сөйләшәсе сүзебез бар!

Сәринә *(керүчеләр ягына борыла)*. Туганнар! Сарайгырлар!

Тавышлар.

— Без — шүнәкләр!

— Без дә синең туганнарың, Сәринә!

Сәринә. Туганнар! Сарайгырлар, шүнәкләр! Мин сезнең янга кайттым. Сез мине кире какмыйсызмы?

Тавышлар.

— Син безнеке, Сәринә!

— Син безнең амага, Сәринә!

— Без синең белән, Сәринә!

Котас. Сармат даласында Сәринәне белмәгән кеше юк. Баспурга каршы, Танайга каршы син кузгалсаң, бөтен дала сиңа иярәчәк. Бүгеннән башлап мин үзем сиңа буйсынам, Сәринә!

Сәринә. Таш сарайларга каршы, таш төрмәләргә каршы без бөтен Сармат илен аякка бастырырбыз! Сарайгырлар, шүнәкләр, аласлар... бергәләп без хыянәтче Танайны, баспурларны юк итәрбез, туган далабызны хурлыклы коллыктан коткарырбыз!

Котас *(Сәринәгә якынрак килеп)*. Шуннан соң син минеке булырсыңмы, Сәринәм?

Сәринә. Дошманнарны җиңгәч, тегендә калган бәхетсез башны коткаргач... мин синеке булырмын, Котас би. Шуннан соң ике баш та синеке булыр, Котас би!

Тавышлар.

— Баспурга — үлем!

— Танайга — үлем!

— Яшә, Сармат!

— Яшә, Сәринә!

Барысы да Сәринәне күтәреп алалар, югары чөяләр. Гомуми тантана.

**СОҢГЫ КҮРЕНЕШ**

Дала. Киез өйләр, түбәсе ябулы арбалар. Таң ата, кояш чыгып килә.
Якындагы өйдән Кортка чыга.

Кортка *(кире борылып, ишек ягына кычкыра)*. Сиңа әйтәм, тордыңмы?

Өйдән Карт чыга.

Карт. Ә? Нәрсә?
Кортка. Әнә кояш чыгып килә. Нинди матур, илаһым!
Карт *(кояш ягына карап)*. Тагын бер көн яшисебез бар икән әле бу якты дөньяда.
Кортка *(тезләнә, адарынып, кулларын югары күтәрә).* Тәңрем-Аллам, изгелегеңнән ташлама без гөнаһлы бәндәләреңне!
Карт *(тезләнә, адарынып, кулларын югары күтәрә)*. Бар ышаныч синдә, Ходаем. Илгә иминлек бир, бигә — акыл, үземә көч-куәт бир!
Кортка. Җыясы ризыкларыбыз, эчәсе суларыбыз бетмәсен, илаһым!
Икесе бергә *(дога кылып)*. Амин! Шулай булсын!

Аягүрә басалар, күтәрелеп килгән кояшка карап, сокланып торалар да ашыкмыйча гына өйләренә кире кереп китәләр. Җиһанда балкып
кояш чыга.

Пәрдә ябыла.
*1986 ел*

## ЭЧТӘЛЕК

*А.Әхмәдуллин.* Ерак тарихыбызга юл сызучы

Итил суы ака торур. *Тарихи роман*

Кол Гали. *Трагедия*

Сармат кызы Сәринә. *Тарихи драма*

Литературно-художественное издание

Фаттахов Нурихан Садрильманович

*(Нурихан Фаттах)*

Избранные произведения
в пяти томах

Том 3

(на татарском языке)

Мөхәррирләре *Р.Х.Корбанов, Ф.М.Хафизов, И.Г.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Р.В.Сабирҗанов, С.Н.Мифтахова, Р.Н.Кыямова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 18.09.2002. Форматы 84г108 1/32.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 24,36+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 24,68
Нәшер-хисап табагы 25,64+форз.0,36.
Тиражы 3 000 данә. Заказ Б-455.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111, Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.